Югары белемне — татар телендә

Д. К. САБИРОВА
Я. Ш. ШӘРӘПОВ

ВАТАНЫБЫЗ ТАРИХЫ

«МӘГАРИФ»
НӘШРИЯТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ФЛА
1991 елның 29 ноябрендә кабул ителде.



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ГИ

НЫҢ ДӘҮЛӘТ СИМВОЛЛАРЫ

ГЫ.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ГЕРБЫ.
1992 елның 7 февралендә кабул ителде.



ИНЫ. 1993 елның 27 августында кабул ителде.

Д. К. САБИРОВА, Я. Ш. ШӘРӘПОВ

ВАТАНЫБЫЗ ТАРИХЫ

(Иң борынгы чор — XX гасыр ахыры)

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2001

УДК 947.0
ББК 63.3(2Рос=Тат)я7
С12

Р е ц е н з е н т л а р ы: тарих фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы *И. Р. Таһиров*;
тарих фәннәре докторы *Р. У. Әмирханов*

Шушы китап материалларын нәшрият рөхсәтеннән башка яңадан бастырып чыгару «Автор хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында» Россия Федерациясе Законын бозу була. Моның өчен закон нигезендә җавапка тарту каралган.

БЗ—9(68)—128—2002/2003

ISBN 5-7761-0964-7
© «Мәгариф» нәшрияты, 2001

КЕРЕШ

КУРСНЫҢ ПРЕДМЕТЫ ҺӘМ ТАРИХИ КЫЙММӘТЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ ОРИЕНТАЦИЯЛӘРЕ

Тарих фәне. Борынгы заманнардан ук гакыл, хис һәм телдән аңлашу сәләтенә ия булган кеше антропоген чор дәвамында (соңгы миллион елда) аңлы тормыш рәвеше алып бара. Бергәләп уйлашып, киңәш-табыш итеп, кешеләр, үзләрен көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итү максатында, хуҗалыкларын (йортларын) булдыралар; рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү турында кайгырталар; үзләренең җәмгыятьләренең (социумнарын[1]) идарә итү системасын сайлап алалар. Әйтеп үтелгән матди, рухи һәм иҗтимагый сыйфатламаларга ия булган яшәү рәвешен Җир цивилизациясе дип, яисә Җир йөзендә кешенең яшәеш культурасы дип атап йөртергә күнегелгән.

Кешенең яшәү рәвеше һәм эчтәлеге матди, рухи һәм социаль яктан даими үзгәреп тора. Үз вакытында азык җыю хуҗалыгыннан җитештерү хуҗалыгына күчелә. Кешенең эшләү осталыгы камилләшә, хезмәт кораллары алышынып тора. Шуларга бәйле рәвештә аның матди тормышы шартлары да үзгәрә. Рухи тормыштагы үзгәрешләр дә игътибарга лаек. Әүвәлге әхлакый-этик традицияләрне һәм идеалларны чагылдырган тотемизмны мәҗүсилек алыштыра, ә соңгысының урынын үз чиратында борынгы мифологик аллалар били. Аннары дөнья диннәре тарала, ә алардан кеше рациональ әхлакый-этик традицияләргә табынуга күчә. Социум да

[1] С о ц и у м — кешеләрнең, уртак эшчәнлек максатында, билгеле бер тарихи строй кысаларында оешкан бергәлеге.

үзгәрешсез калмый. Җәмгыятьне идарә итүнең ыруглык системасыннан кеше акрынлап катлаулыракларына — ыруг-кабилә системасына, аннары кабиләләр берлекләре системасына һәм, ниһаять, дәүләт идарәсенә күчә.

Тарихи процесста кеше яшәешенең матди, рухи һәм социаль сыйфатламалары җәмгыять баскычларын чагылдыралар. Мәсәлән, борынгы җәмгыятьнең иң түбәнге баскычын азык җыю хуҗалыгы, таштан ясалган эш кораллары, тотемизм һәм ыруглык строе гәүдәләндерә. Моннан соң килгән һәр җәмгыять строе үз чиратында әлеге чорны чагылдырган матди, рухи һәм социаль сыйфатламалар гомумилеген (социаль модульне[1]) булдыра. Бер модульдән икенчесенә күчү билгеле бер социаль закончалыклар нигезендә үтә. Беренчедән, җәмгыять тормышының яңа модуленә күчкән вакытта кешеләр, инде гамәлдәге традицияләргә бәйле булган хәлдә, киләчәкне сайлауда ирекле булалар. Икенчедән, бер модульдән икенчесенә күчү — «яхшыдан яхшыракка — аннан да яхшыракка» кебек тылсымлы формула буенча хәрәкәт итү түгел, ә бәлки яңа идеалдагы тормыш мөмкинлекләрен генә гамәлгә ашыру ул.

Тарих фәне кешелек цивилизациясенең менә шул реаль тарихын өйрәнә. Тарих бу цивилизацияне анда социаль тормыш культурасы барлыкка килүе, үсеше һәм башкасы белән алышынуының өзлексез процессы буларак тикшерә һәм бу хәлдән гыйбрәтле нәтиҗәләр ясый. Тарих фәнен еш кына гомумхалык хәтере дип атыйлар. Тарихи эзләнүләр, өйрәнүләр нәтиҗәләре кешеләргә үзләренең бүгенге социаль тормышларын яхшырак аңларга, киләчәк тормыш идеалын табарга һәм формалаштырырга ярдәм итә.

Җир цивилизациясе тарихи рәвештә б. э. кадәр 12—11 меңьеллыкларда ук инде этномилли характер ала башлаган төбәк цивилизацияләре җыелмасыннан барлыкка килә. Кабиләләр территорияләре буенча да, телләре белән дә бер-берсеннән аерыла башлыйлар. Шуңа күрә теләсә кайсы илнең тарихы, шул исәптән Татарстан тарихы да, милли тарих буларак өйрәнелә. Дөнья тарихының бер өлеше булган Татарстан

---

[1] С о ц и а л ь м о д у л ь — *монда*: билгеле бер тарихи идарә строе, икътисади, этник, сыйнфый, рухи, мәдәни кысаларда барлыкка килгән иҗтимагый мөнәсәбәтләр җыелмасы.

тарихы аның гомуми закончалыкларына буйсына, әмма шул ук вакытта ул үзенчәлекле тарих.

Татарстан тарихы курсының төп чорлары түбәндәгеләр:

- Идел-Уралдагы бик борынгы төньяк төрки (шималь төрки) кабиләләр;
- Идел-Болгары — борынгы һәм урта гасырларда Идел-Уралдагы төрки-болгарлар дәүләте (IX—XV йөзләр);
- Казан ханлыгы — Идел буе төрки-татарлар дәүләте (XV—XVI гасырлар);
- Татарстан Россия империясе составында (XVI—XX гасырлар);
- Татарстан АССР һәм татар халкы СССР составында (XX гасыр);
- Татарстан Республикасы һәм татар халкы СССР таркалганнан соң.

Курсның «Ватаныбыз тарихы» дип аталуы очраклы хәл түгел. Татарстан тарихын бик борынгы Идел-Урал буйлары һәм Идел Болгары тарихы белән бәйләп өйрәнү өчен дә болай аталыш бик кулай, чөнки бүгенге татар милләте — бик борынгы төньяк төрки кабиләләрнең һәм Идел буе Болгарының хокукый варисы һәм аларның мәдәни, этник традицияләрен дәвам иттерүче.

«Татарстан» төшенчәсе. Татарстан — Европа континентының төньяк-көнчыгышына урнашкан бик борынгы дәүләтләрнең берсе. Әле б. э. кадәр 5—2 меңьеллыкларда ук Татарстан территориясе «Урал культурасы» дип аталган неолитик төбәк системасына керә. Бу Нил үзәнлегенең игенчелек культурасы, Һиндстан культурасы, Төньяк Кытай культурасы, Көнбатыш Европаның игенчелек культурасы, Байкал культурасы, Арал диңгезе буе Кәлтәминар культурасы, Мәвараэннәһер игенчелек культурасы, Көнчыгыш Европадагы урман зонасының зәвыклы керамика культурасы һ. б. неолитик культуралар чәчәк аткан чорлар була.

Татарстан җирендә бик борынгы кеше кулының һәм гакылының игелекле йогынтысы, дәлилләре, һичшиксез, аз түгел. Ул Идел буе татарларының ерак бабасы булган. Татарстан территориясендәге бик борынгы кешенең биосоциаль рәвешен 1937 елда Байсун тавындагы (Үзбәкстан) Тишек Таш мәгарәсендә табылган, антропологлар тарафыннан Homo Sapiensның (акылга ия булган кеше) европеид төренә кертелгән һәм Мустьер культурасы заманында Неандертальдә

яшәгән малайның төркиләргә хас сөякләре буенча күз алдына китерергә мөмкин.

Тарихи яктан Татарстан ил һәм дәүләт буларак беренче меңьеллык азагында борынгы татар дәүләте — Идел буе Болгары исеме астында формалаша. Татар халык дастанында бу уңай белән болай диелә:

И Идел-йорт,
Идел-йорт...
Идел — Җаек арасы
Елкы белән тулган йорт;
Казан — Болгар арасы
Кала белән тулган йорт;
Ашлы белән Ибраһим[1]
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам торткан йорт...

Урта гасырларда татар халкы дәүләте Казан ханлыгы чикләрендә яши. Дәүләт исеменең үзгәреше әкренләп ил исеменең үзгәрешенә алып бара. «Болгарлар иле» (Идел Болгары) төшенчәсе урынына «татарлар иле» (Татарстан) төшенчәсе кулланыла башлый (автор фикерен истә тотып, халкыбыз дәүләте исемнәре «Татарстан» дип бирелде.— *Ред. иск.*).

Совет хакимияте вакытында, 1920 елда Татарстан икенче «бүленүне» кичерә. Ленин хөкүмәте Автономияле Татарстан Республикасын тарихи территориясенең бер өлешендә генә игълан итәргә риза була, татарларның этник территориясенең яртысыннан артыграгын республика чикләреннән читтә калдыра. Шулай итеп, Идел-Уралда, асылда, «ике татар җире»: Автономияле Татарстан Республикасы һәм административ яктан Идел-Уралның рус губерналарына буйсынган этнокультуралы, социокультуралы татарлар төбәге барлыкка килә. Моннан соң үткән 70 елда бу ике территориаль-дәүләти структурада яшәгән татар халкы үзенең милли бердәмлеген югалтмады. Татарстаннан читтә яшәгән татарларның үзаңында үзләрен татар иле — Татарстан белән тиңләштерү саклана.

Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы Декларация (1990) әлеге чынбарлыкны тану нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасының дәүләт суве-

---

[1] Ашлы, Ибраһим — Урта Идел буендагы шәһәрләр.

ренитеты турындагы Декларация ике дәүләт — Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе структураларында яшәүче татар халкының милли бердәмлеген саклау һәм ныгыту зарурлыгына нигезләнә.

«Татарлар» төшенчәсе. Тарихчы галимнәрнең күпчелеге татарларны (Идел буе татарларын) Идел-Урал аборигеннары (төп халкы, җирле халкы) дип саный. Аларның бик борынгы бабаларының этник яктан оеша башлавы неолит чорына туры килә. Б. э. кадәр, чама белән 8—5 меңьеллыкларда, хәзерге заман тел гаиләләренең, шул исәптән төрки телләр гаиләсенең дивергенциясе (аерылуы) бара. Бу процесс барышында, мөгаен, Идел-Уралның урман-дала зонасында фәндә еш кына «шималь төркиләре» дип аталучы җирле төрки кабиләләрнең оешуы күзәтелә.

Хәзерге заман татарларының борынгы дәүләте — Идел буе Болгары чорындагы (IX—XV гасырлар) ерак бабаларын галимнәр *«болгар төркиләре»* дигән төшенчә белән атыйлар. Бу очракта «төркиләр» төшенчәсе («шималь төркиләре») этноним (этнос атамасы), ә «болгар» төшенчәсе политоним (дәүләт, ил атамасы) буларак кабул ителә. *«Татарлар»* төшенчәсе Идел буе төркиләренең этнонимы буларак XV гасырдан, ягъни Казан ханлыгы заманыннан башлап кулланылышка керә. Баштарак бу төшенчә Казан ханлыгында яшәүче татарлар мәгънәсендә политоним буларак яши. Тарихи әдәбиятта моңа параллель рәвештә «Казан төркиләре» төшенчәсе дә этноним буларак кулланыла. *Тора-бара «татарлар» төшенчәсе этноним сыйфатында Идел буе төркиләренә карата беркетеп кала һәм бу мәгънәдә «төркиләр» төшенчәсен кысрыклап чыгара.*

Өйрәнү предметы. Татарстан тарихы курсы татар халкының тарихи территориясендә һәм хәзерге Татарстанда борынгы заманнардан башлап безнең көннәргә кадәр булган, даими рәвештә яңарып торган социаль-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормыш характерын, аның төп юнәлешләрен һәм нәтиҗәләрен өйрәнә.

Матди һәм рухи кыйммәтләр тудырган, үзенең милли тормышын төзегән татар халкы һәрвакыт мул тормышка һәм гаделлеккә омтыла, социаль һәм милли тормышның хокукый һәм әхлакый нигезләрен ныгытырга тырыша. Мәгълүм тарихи материалларга таянып, без, Татарстан күп меңьеллыклар дәвамында цивилизацияле илләр рәтендә тора, дип әйтә

алабыз. Татар халкы үз илендә цивилизацияле җәмгыять төзеп кенә калмый, ә бәлки үзенең иҗат җимешләре белән дөнья цивилизациясен дә баета тора.

Татарстан тарихын өйрәнү барышында, без татар халкы үткән юлның никадәр катлаулы булуын күрербез. Тарихның билгеле бер этапларында аның язмышы драматик, хәтта фаҗигале була. Реаль тормыш күп кенә очракларда аның идеалына туры килми. Моның сәбәпләре шактый. Халыкның сайлар юлы күп вариантлы, һәм аны сайлау, кешеләрнең социаль ниятләрен гамәлгә ашыру — катлаулы тарихи процесс. Ул күп кенә факторларга, шул исәптән очраклы факторларга бәйле һәм аларның ничек булачагын алдан әйтеп кую мөмкин түгел. Татарстанда да социаль үсеш юлларының иң камиле сайланган дип әйтеп булмый. Милли ниятләрнең гамәлгә ашырылу ысуллары кайчак нәтиҗәсез булып чыга. Бу Татарстанның үзеннән генә тормый. Бер яктан — халык, икенче яктан, илне идарә итү өчен вәкаләт бирелгән социаль институтлар арасындагы көчләр балансының бозылуы кайчак канәгатьсезлекләр тудыра. Дәүләт мәнфәгате төп максат итеп куелып, гаделлекнең кешелекле эчтәлеге икенче планга күчерелгән очракларда тормыш аерата катлаулана. Татарстанның халыкара мөнәсәбәтләре дә шома гына бармый. Татарстан үзе чит илләр белән, барыннан да элек күрше дәүләтләр белән, мөнәсәбәтләрендә һәр як өчен дә файдалы хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшү сәясәте алып бара. Аның Киев Русе белән, Мәскәү Русе һәм Россия белән мөнәсәбәтләре нәкъ шундый була. Тарих монголларның — Чыңгыз хан империясенең — Болгар иленә карата көч куллануын, Казан ханлыгының Иван Грозный тарафыннан яулап алынуын, Россиянең Татарстанда колонизаторлык сәясәте алып баруын акламый. Барлык бу вакыйгалар татар халкы дәүләтенә өстәмә газап-җәфалар алып килә. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар. Татар халкы һәрвакыт, эчке һәм тышкы характерда булган кыенлыклардан чыгу өчен, үзенең милли абруен, милли территориясе булган Татарстанны саклау өчен җитәрлек көч таба килә.

Тарихи кыйммәтләрне бәяләү ориентацияләре. Тарихи фактларга, социаль-сәяси һәм мәдәни-рухи вакыйгаларга төпле анализ ясау, ил һәм халык язмышындагы тарихи борылышларга мөмкин кадәр объектив бәя бирү, төрле шәхесләрнең тарихи ролен ачыклау — җиңел эш түгел. Барлык бу

катлаулылыкларны аңлау-төшенүдә, тарихи процессларны дөрес аңлатып бирүнең оптималь ысулын сайлауда бүгенге көндә тарих фәне таянган кыйммәтләр һәм тарихи кыйммәтләрне бәяләү ориентацияләре ярдәм итә. Башкача әйткәндә, бу *тарих фәненең методологиясе, тарих фәлсәфәсе* дип атала.

Хәзерге заман тарих фәнендә кабул ителгән ориентацияләр безне тарихи фактларга, вакыйгаларга, шәхесләргә я «кара», яисә «ак» дип «ике төсле» итеп кенә бәя бирүдән саклыйлар, аларның төп эчтәлеге шуннан гыйбарәт. Теләсә нинди социаль күренеш, бер яктан, моңа кадәр булган вакыйга-хәлләрнең бер өлешен эченә ала, моңа кадәрге буын эшчәнлегенең нәтиҗәсен тәшкил итә, икенче яктан, ул алмашка килгән яңа буынның иҗат җимеше хисабына үсә. Боларның һәркайсына дөрес бәя бирә белү кирәк. Элек булган бар нәрсәне бары тик реакцион гына дип, ә һәр яңалыкны прогрессив кына дип бәяләргә ярамый. Халыкның үзенең үтәр юлын сайлау мөмкинлеге дә күптөрле. Һәр сайлап алынган тарихи юлны һәрвакытта да юлларның иң уңышлысы дип әйтеп булмый. Халыкларга бәя биргәндә дә «тарихилык» һәм «тарихи түгеллек» аларның сыйфат күрсәткече була алмый. Үз тарихының төрле чорларында бер үк халыкның активлыгы һәм оешканлыгы төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Бер дәүләт сайлап алган һәм кабул иткән сәясәт һәр ил өчен дә кулай сәясәтләрнең бердәнбере була алмый. Ул оптималь булырга, уңышсызрак яисә бөтенләй яраксыз булырга мөмкин. Халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне ике төрле генә (дусларча яисә дошмани) итеп карау да ярамый. Шартларга бәйле рәвештә бу мөнәсәбәтләрнең үзара аңлашу, конфликтка керү, каршы тору һәм башка төс алуы мөмкин. Позитив сәясәтнең бурычы мәсьәләне хәтта сөйләшүләр юлы белән хәл итеп була торган конфликт хәленә дә китереп җиткермәүдән гыйбарәт, ә сугыш хәленә китерерлек каршылыкларга җитү турында сүз дә булырга тиеш түгел.

Тарих фәне таянган кыйммәтләр һәм аларны бәяләү ориентацияләре, кешеләрнең, халыкларның үзенчәлеген һәм суверенлыгын саклаган хәлдә, аларны берләштерүгә өндәүче башлангычларны ныгыта, бер сыйныфны икенчесенә, бер милләтне икенче бер милләткә, дәүләтне кешегә, сәясәтне икътисадка, атеизмны дингә, материализмны идеализмга һ. б. каршы куйган очракта җәмгыятьне һәм тулаем бөтен дөнья

бердәмлеген аңлы рәвештә таркату куркынычы туачагы турында кисәтә.

Татарстан тарихы курсының эчтәлеге ул таянган кыйм-мәтләрнең һәм ул кыйммәтләрне бәяләүнең гомумтарихи ориентацияләренә туры килә. Шул ук вакытта бу курс таян-ган кыйммәтләрнең аерым үзенчәлекләре дә бар. Бүгенге Татарстан территориясендә бик борынгы заманнарда барлык-ка килгән төбәк цивилизациясе һәм шул ук нигездә үсеп чыккан Идел буе Болгары цивилизациясе татар милли циви-лизациясенең формалашуындагы бер-берсе белән бәйләнгән этаплар итеп карала.

Курс таянган кыйммәтләрнең берсе сыйфатында аның Татарстан тарихын милли тарих дәрәҗәсенә күтәреп өйрәнүен дәлил итеп китерергә мөмкин. Татарстан — Россия провин-циясе түгел, аның тарихы Россия тарихының төбәкне өй-рәнү дисциплиналарыннан берсе рәтендә йөрми. Татар-станның милли тарихы, Россиянең милли тарихы белән бәйле булганы хәлдә, бервакытта да Россия кысалары белән чикләнмәде. Безнең халкыбыз Европа цивилизациясенең чишмә башы булган Борынгы Греция һәм Рим культурасы белән элемтә тота. Бу элемтәләр Азовтан алып Алтайга кадәр сузылган б. э. кадәр VI гасырлардагы сәүдә юлы аша тор-мышка ашырыла. Бу турыда Геродот та үз язмаларында искә алып үтә. Шул вакытларда ук инде борынгы бабаларыбыз Кара диңгез буендагы Греция колонияләре белән үзара мөнә-сәбәтләргә тартыла.

Европаның Азия белән чиктәш булган төбәгенә урнашкан җирләребез бик борынгы заманнарда ук Ефәк юлы дип атал-ган кәрван юлына якын тора, Идел-Каспий аша үткән су юлларын үзләштерә, шулар аша Багдад һәм Мисыр, Иран һәм Һиндстан белән бәйләнешкә керә. Еллар, гасырлар үтә, илләр, халыклар, дәүләтләр алмаша, ә әлеге үзара багланыш дәвам итә, ныгый, киңәя һәм безнең көннәргә кадәр килеп җитә. Татарстанның көнчыгышта Алтайдан һәм Синьцзян-нан алып көнбатышта Төркиягә, көньякта Төрекмәнстаннан алып төньякта Башкортстанга кадәр җәелгән төркиләр дөньясы белән, Идел-Уралның фин-угор халыклары (марилар, мордвалар, удмуртлар) һәм дә дөньяның ислам мәдәнияте белән тарихи багланышлары зур игътибарга лаек.

БИК БОРЫНГЫ ТАТАРСТАН

ИДЕЛ-УРАЛ ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕНЕҢ БАШЛАНГЫЧЫ

Идел-Уралның геосферасы. Бик борынгы бабаларыбыз географик яктан кеше яшәү өчен уңайлы булган — Урал таулары һәм Идел елгасы (борынгы атамасы — Итил), дөресрәге, Урта Идел буенда гомер кичергәннәр. Урал таулары, Америкадагы Аппалач таулары кебек үк, Җир шарындагы тауларның иң борынгыларыннан (моннан 3,5 млрд еллар элек барлыкка килгән) санала. Мөгаен, Идел елгасы да шул заманнардан бирле агадыр. Иделгә Кама елгасы аркылы Урал тавының көнбатыш битләреннән агып төшә торган Агыйдел, Кара Идел (Дим), Ык, Самара елгалары һәм башкалар килеп кушыла. Урал таулары белән Урта Идел бассейны арасында урман, урман-дала һәм дала климатик зоналары барлыкка килгән. Татарларның бик борынгы бабаларының тормыш иткән урыны буларак, бик борынгы Татарстан, нигездә, урман-дала һәм су баса торган болыннар зонасында, ә өлешчә урман һәм дала зонасындагы Урта һәм Түбән Урал тау итәкләрендә урнашкан булган.

Идел-Уралның этносферасы. Бик борынгы кешеләрнең Җир шарында ничек урнашулары мәсьәләсендә галимнәрнең фикере төрлечә. Кайберәүләр, Җирне кешеләр бер үзәктән торып били башлаганнар, дип уйлыйлар. Мондый үзәкне алар Африка яисә Азия, аерым алганда, Тибет белән бәйлиләр. Барлык төрки халыклар да бер үзәктән , төгәлрәге, Алтайдан чыкканнар, дигән фикер дә яши. Татарстанның кайбер галимнәре исә татар халкының бик борынгы бабалары бирегә күчеп килгән кешеләр дигән фикердә тора. Мәсәлән, «Татарстан АССР тарихы»нда (1973 ел) болай диелә: «Алар, мөгаен,

бирегә көньяктан, ә, бәлки, бераз көнбатыштарак урнашкан өлкәләрдән килгәннәрдер».

Башка тарихчылар Җир шары этносферасының формалашуында күп үзәклелек турындагы фикерләрне яклап чыгалар. Мондый теория яклылар арасында, кеше яшәеше өчен уңай шартлары булган бик борынгы Идел-Урал Җир шарында бик борынгы кешеләрнең, ә соңрак Homo Sapiensның да беренче яшәү үзәкләренең берсе булып киткән, дип уйлаучылар бар. Болай фараз итү, бик борынгы кешеләр, башта җир асты җылылыгы белән җылытыла торган тау куышлары (мәгарәләр) эчендә табигый ышыклану урыннары табып, тау массивларында яшәгәннәр, дип гөманлаучы галимнәрнең теоретик фикерләрен раслый. Соңрак кешеләр таулардан төшкәннәр һәм, алга таба хәрәкәт итеп, сулыкларга — елгакүлләргә, диңгез-океаннарга барып җиткәннәр. Шул сулыклар ярларында аларның беренче цивилизацияләре үсеш алган.

Идел-Уралда элгәреге ыруглык строе кешесенең яшәеш культурасы. Хәзерге заман археология фәне материаллары палеолит чорында ук (моннан чама белән 100 мең еллар элек) Идел-Уралда кешеләр яшәгәнлеген раслый. Мондый материаллар бүгенге Татарстан, Башкортстан, Мордовия, Чувашстан, Марий Эл, Удмуртия республикалары һәм Россиянең Түбән Новгород, Киров, Пермь, Чиләбе, Оренбург, Самара, Ульяновск өлкәләрендә табып тикшерелә.

Иделнең уңъяк яры, Красная Глинка аймагы (Тәтеш тирәсендә) һәм Каманың сулъяк ярында (Ык тамагында Дәвек авылы тирәләрендә) үткәрелгән археологик казулар бик борынгы заманнарда ук хәзерге Татарстан территориясендә көн күргән кешеләрнең яшәеш культурасы турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Борынгы кешеләр үзләренең уттан файдаланганлыклары турында сөйли торган учаклар, көлкүмер калдыклары, хуҗалык эшчәнлекләренә ишарәләгән төрле таш кораллар һәм керамика, төбәкнең фаунасын билгеләргә мөмкинлек бирә торган хайван сөякләре (бозлык чоры хайваннары булган мамонтлар, куе йонлы мөгезборыннар аларның ау объектлары була), бу җирләрнең флорасы хакында сөйләүче һәм ризык буларак кулланылган кыяклы үсемлек орлыгы сибелмәләре аша үз эзләрен калдырганнар. Бу Җир шары цивилизациясенең беренче адымнары заманы да булган. Дәвек торулыгында, мәсәлән, археологлар стеналары агачтан салынган ярымземлянкалар рәвешендәге торак

калдыкларын тикшергәннәр. Хуҗалык алып баруның төп формасы үсемлек орлыклары җыю һәм аучылыктан гыйбарәт булган. Хезмәт бүленеше яшәгән: ирләр аучылык белән шөгыльләнгән, хатын-кызлар үлән азыклар җыючылар булган. Социум община рәвешендә яшәгән. Община әгъзалары арасында ана ягыннан туганлык мөнәсәбәтләре (матриархат) өстенлек иткән.

БИК БОРЫНГЫ ТӨНЬЯК ТӨРКИЛӘР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ

Неолит революциясе. «Неолит революциясе» төшенчәсен фәнгә академик Н. Н. Моисеев (1892) кертә. Аның фикеренчә, *б. э. кадәр 14—13 меңьеллыкларда (неолит чорында[1]) Җир шары цивилизациясе үсешендә тамырдан борылыш чоры була. Бу борылышның асылы Homo Sapiensның азык җыю ысулыннан җитештерү ысулына күчүеннән гыйбарәт.* Әгәр азык җыю ысулы өстенлек иткән палеолит чорын (Л. Г. Морган фикеренчә, кыргыйлык чоры яисә элгәре ыруглык строе) Җир шары цивилизациясенә әзерлек итеп карасак, неолиттагы җитештерүчеләр чорын (Морган буенча, нык үскән ыруглык җәмгыяте) дөнья цивилизациясенең формалаша башлавы дип бәяләргә кирәк.

Б. э. кадәр 5—2 меңьеллыкларда формалашкан 22 төбәк неолит культуралары арасында галимнәр Урал культурасын да атыйлар. Төньяк-Көнчыгыш Европаның урман зонасы культурасы (б. э. кадәр 3—2 меңьеллыклар), Байкал культурасы (б. э. кадәр 4—2 меңьеллыклар), Арал диңгезе буе культурасы (б. э. кадәр 2 меңьеллыктагы Кәлтәминар культурасы) бу культураның күршеләре булганнар. Шушы чорда, Карл Ясперс сүзләре белән әйткәндә, «борынгы заманның бөек культураларына» (Мисыр, Елгаара өлкә, Һиндстан, Хуанхэ, антик чор) күчелә.

Татарстанда неолит, бронза һәм тимер дәверләре. Татарстанда җитештерү хуҗалыгының формалашуы һәм *нык үскән ыруглык җәмгыятенә күчү* неолит чорында башлана. Профессор А. Халиков исә, бу чор бездә соңрак — б. э. кадәр 6 меңьеллык тирәләрендә башланган, дип исәпли. Татарстанның

[1] Неолит чоры — яңа таш гасыры.

Идел, Кама буйларында һәм аларның кушылдыклары ярларында борынгы кешеләрнең йөздән артык торулык калдыклары табыла. Утка елгасы тамагында табылган Гулькино һәм Займище авылы янындагы (Идел ярында), Мурзиха авылы (Кама буе) тирәсендәге борынгы торулык калдыклары шундыйлар рәтенә керә. Аларда табылган әйберләр һәм эш кораллары — таш һәм сөяктән ясалган үткен ук очлары, агач сапка беркетелгән чакматаш пычаклар, таш һәм сөяк очлы сөңгеләр, таштан эшләнгән килеләр (орлык угычлар), сөяк китмәннәр һ. б.— аларны ясаган кешеләрнең чын осталар булганлыклары турында сөйли. Җәя һәм ук тарту, балчыктан савыт-саба ясауны камилләштерү, ташны шомарту, кисү, ризыкны ут өстендә әзерләү алымнарын, аучылык продуктларын — җәнлек тиресен, сөяк һәм мөгезләрне — үз ихтыяҗлары өчен эшкәртү ысулларын уйлап табу — бу чор кешеләренең гаҗәеп зур казанышы. Б. э. кадәр 2 меңьеллык башында хәзерге Татарстан территориясендә бронза дәвере, ә б. э. кадәр 1 меңьеллык башында тимер дәвере башлана. Татарстанның һәм Россия Федерациясенең, безгә күрше булган республика һәм өлкәләрнең археологик карталарына Идел һәм Кама бассейннарындагы, шулай ук аларның кушылдыклары — Вятка, Иж, Ык, Чирмешән, Мишә, Казансу, Сумка, Сура һ. б. елга бассейннарындагы борынгы торулыклар төшерелгән. Биредә табылган әйберләр һәм эш кораллары кешенең, әзер материалларны (ташны, балчыкны, сөякне, агачны) эшкәртеп, яңа материаллар булдыруга — бакыр, бронза, тимер эретеп табуга кучкәнлекләрен раслый. Археологик табылдыклар арасында бронза очлыклы, ә соңрак тимер очлыклы уклар һәм сөңгеләр, агач саплы бронза һәм тимер балталар, кыска тимер кылычлар һәм хәнҗәрләр очрый. Керамик савыт-сабага еш кына төрле бизәкләр, хайван, кош, балык рәсемнәре төшерелгән була. Сөяктән, бронзадан, тимердән, ә кайчак көмеш һәм алтыннан эшләнгән бизәнү әйберләре очрый.

Идел-Уралдагы төрки кабиләләр. Җитештерү хуҗалыгына күчү белән төбәк халкының саны арта бара. Инде үзләштерелгән зоналар мәйданы киңәя; ул тау итәкләрен, елга үзәнлекләрен, урманлы районнарны, урман-дала зоналарын үз эченә ала бара.

Кешеләрнең социаль-икътисади тормышында да үзгәрешләр күзәтелә. Ыруглык общиналары җәмгыятьнең һәм

җитештерүнең төп ячейкалары булуларын дәвам итәләр. Идарә итүдә беренче планга ир-егетләр чыга. *Матриархат патриархат* белән алмашына. Община әгъзалары арасында хезмәтнең яшькә һәм җенескә карап бүленеше (җыючылар һәм аучылар) үз урынын катлаулырак бүленешкә бирә. Хуҗалыкта, игенчелек белән беррәттән, көтүлекләрдә йөртелә һәм аранда асрала торган терлекләр үрчетү төп урынны ала. Аучылык, үлән-җимеш җыю белән беррәттән йорт һөнәрчелеге ярдәмче тармак буларак үсә.

Кешеләр берлегенең яңа формасы — *кабиләләр* барлыкка килү бик әһәмиятле социаль үзгәреш була. Кабиләләр берберсенә якын торган, ыруг башлыклары, ягъни аксакаллар җитәкләгән авыл общиналары берләшмәсеннән гыйбарәт була. Ыруг башлыклары общинаның бүтән әгъзаларыннан көчле һәм кыю, батыр һәм тапкыр, тәҗрибәле һәм үз тәҗрибәләрен кабиләдәшләренә тапшырырга сәләтле булулары белән аерылып торган. Алар кабиләнең ыруг башлыклары советын хасил иткән. Кабиләнең абруйлы әгъзалары җыелышы — Җыен — кабилә эшләрен алып барыр өчен хәрби отряд (дружина) белән бергә кабилә башлыгын билгеләгән. Билгеләнгән кабилә башлыгы кабилә гореф-гадәтләре нигезендә һәм кабилә ихтыярына таянып эш иткән.

Кабилә өчен үзенең теле, атамасы, аерым территориясе булу характерлы. Күп кенә галимнәр телнең үсешендә борылыш чоры итеп *энеолит чорын* (б. э. кадәр 7—6 меңьеллыкта таштан бронзага күчү чорын) атыйлар. Бүгенге телләр гаиләләренең формалашуы шул чорга туры килә. Кайбер тюркологлар, б. э. кадәр 8—5 меңьеллыкларда төрки телләр гаиләсенең аерылып чыгуы башлана, дип уйлыйлар. Һәрхәлдә, Идел-Уралдагы кабиләләр б. э. кадәр 2 меңьеллыкта үзләренең телләре (төрки телләр, фин-угор телләре) белән аерылып торганнар. Үзендә яшәүче кабиләләрнең тел үзенчәлекләре буенча аерылып торган территорияләр дә барлыкка килгән.

Әгәр Идел-Уралда элгәреге ыруглык строенда яшәгән кешеләр Иделдә һәм Уралда бүген яшәүчеләрнең борынгы уртак бабалары булсалар, нык үскән ыруглык строеның җирле төрки кабиләләре өч төрки халыкның — татар, чуваш һәм башкорт халыкларының — уртак бабалары булганнар. *Идел-Уралның төрки кабиләләре тарих фәнендә төньяк төркиләр дип яисә Көнчыгыш Европаның төньяк-көнчыгышында яшәү-*

че европалы төркиләр дип каралалар. Төньяк төрки кабиләләр гомумтөрки ислам цивилизациясенең бер өлеше булып киткән җирле төрки цивилизациясенең чишмә башында торганнар.

Төньяк төрки кабиләләр таралып урнашкан территорияләр. Археология тикшеренүләре шуны күрсәтә: нык үскән ыруглык җәмгыяте чорында ыруглар булып оешудан авыл общинасына һәм идарә итүнең кабилә структурасына күчү шартларында Идел-Уралның төрле территорияләре үзләренең табигый һәм хуҗалык үзенчәлекләре белән генә түгел, аларда яшәгән халыкның этник характеристикасы белән дә аерылып торганнар. Төрки кабиләләр культурасы тел аермасыннан башка географик урын күрсәткече белән дә билгеләнә.

Галимнәр төньяк төрки кабиләләр белән фин-угор кабиләләре урнашкан территорияләрне бер-берсеннән аера торган «географик сызык»ны билгеләргә тырышып карыйлар. Камил булмаган бу «сызык» фин-угор кабиләләрен чагыштырмача төньякка, урман һәм болын зоналарына урнаштыра. Бер үк вакытта аларның көнбатыштагы (Финляндиягә кадәр) фин-угор кабиләләре (комилар, ненецлар) белән Урал аръягының, Төньяк Себернең шундый ук географик киңлегендә яшәүче фин-угор кабиләләре белән бәйләнышлары билгеләнә. Төньяк төрки кабиләләр (татарлар, башкортлар һәм чувашларның бабалары) чагыштырмача көньяктарак, Урал тауларының урта һәм көньяк итәкләрендә, Кама һәм Урта Идел, Самара елгалары (Җаекка кадәр) бассейннарының урман-дала, болын һәм дала зоналарында урнашалар. Биредә алар үзләренең борынгы цивилизация учакларын, дөресрәге, локаль культураларын булдыралар.

Б. э. кадәр 2—1 меңьеллыклардагы Казан яны (Приказанская) культурасы Займище, Олы Отар, Атабай авыллары тирәсендә үткәрелгән казу эшләре нәтиҗәсендә шактый җентекләп өйрәнелгән. Үзенең характеры буенча Кама буе һәм Урал буе культураларына якын булган бу культура бер үк вакытта Идел һәм Ока елгалары арасындагы культуралар (Фатьяново культурасы) белән бәйләнештә торган. Татарстанның Алабуга районындагы Ананьино авылы янында үткәрелгән казу эшләре нәтиҗәсенә табылган Ананьино (Кама буе) культурасы б. э. кадәр 1 меңьеллыкка карый. Б. э. кадәр 1 меңьеллык азагында һәм безнең эраның 1 меңьеллыгы башында яшәгән җирле кабиләләрнең яшәү рәвешен Пьяный

Бор (Красный Бор) авылы янында үткәрелгән казу эшләре нәтиҗәләре буенча өйрәнелгән Пьяный Бор культурасы һәм Имәнкискә (Лаеш районы) авылы янында ачылган Имәнкискә культурасы характерлый. Борынгы Болгар һәм Биләр культуралары турында аерым әйтеп үтәргә кирәк. Борынгы Болгар культурасы нәкъ менә шул бик борынгы төньяк төрки кабиләләр тарафыннан хәзерләнгән нигездә үсеп чыга.

Татарстан археологиясе әле бик яшь. Шуңа да карамастан, ул Урал таулары итәгеннән алып Идел һәм Ока елгалары арасына кадәр, шулай ук Идел буйлап Самара елгасына кадәр сузылган территориядә яшәгән төньяк төрки кабиләләр өстендәге томан пәрдәсен ачуга иреште.

Төньяк төркиләрнең яшәү культурасын бу төбәктәге финугор кабиләләренең яшәү культурасыннан аерып карау тарихи яктан бик үк дөрес булмас иде. Ул вакытларда әле кабиләләр үз территорияләренә бөтенләйгә килеп урнашырга өлгермәгән була. Географик һәм климатик шартлар якынлыгы, шулай ук кабиләләрнең үзара бәйләнештә булулары аркасында, аларның яшәү культураларында күп кенә охшашлыклар күзәтелгән. Археология материаллары шуны күрсәтә. Барыннан да элек, Ананьино культурасы кабиләләренең яшәү рәвеше белән Баланово культурасы кабиләләренең (чуваш халкының борынгы бабалары) яшәү рәвеше арасында уртаклык сизелә. Галимнәр шулай ук Ананьино культурасы кабиләләренең яшәү рәвеше белән Ахмеловка культурасы («челтәрле керамика» культурасы) кабиләләре — мари халкының борынгы бабалары яшәү рәвеше арасында да күп уртаклыклар табалар. Ананьино культурасы кабиләләренең Полтава культурасы кабиләләре белән һәм Бура культурасы (ул чорда мәетләрне кабердә махсус бура ясап күмә торган булганнар — культураның атамасы шуннан алынган) кабиләләре белән бәйләнешләре сизелә. Полтава һәм Бура культурасы кабиләләре Түбән Идел һәм Урал елгасыннан Днепрга кадәр, Оканың уңъяк кушылдыкларыннан Кубан елгасына кадәр сузылган дала районнарын б. э. кадәр 2—1 меңьеллыкларда биләп торганнар.

Бу бәйләнешләр һәм мөнәсәбәтләр үзләренең тамырлары белән элгәреге ыруглык строеннан нык үскән ыруглык җәмгыятенә күчү чорына барып тоташа. Идел-Урал территориясендә Түбән Идел буе, Кырым, Түбән Днепр һәм Таман ярымутравы культурасына (б. э. кадәр [redacted] хас

булган күп кенә әйберләр табыла. Әйтеп үтелгән бәйләнешләр Югары Идел буйларына — Фатьяново культурасы (атамасы Ярославль өлкәсе Фатьяново авылы исеменнән алынган) кабиләләренә дә кагыла.

«Бөтендөнья тарихы»нда (I том, Мәскәү, 1955 ел) ул чорда «кабиләләрнең Уралдан көнбатышка таба гына түгел, көнбатыштан (бу очракта Днепр һәм Дон буйларыннан) Идел-Уралга таба да күчүләре булган» дигән фаразлар бар. Чыннан да кабиләләрнең тик бер якка гына — «көнчыгыштан көнбатышка гына күчүләре» турындагы фаразларга тәнкыйть күзлегеннән карарга кирәк.

Тораклар. Татар халкының бик борынгы бабалары — төньяк төрки кабиләләр — 2—1 меңьеллыкларда нык үскән борынгы җәмгыять чорын кичерәләр. Аларның яшәү һәм тору урыннарының үзенчәлекләре сиземләнә башлый. Читтән һөҗүм була-нитә калганда, ышыклану урыны хезмәтен үтәгән шәһәрлекләр кабиләләрнең төп корылмасына әверелә. Шәһәрлек яртылаш җир эченә кертеп төзелгән, эчендә берничә ачык учак өчен урыннар калдырылган зур бүрәнә йорттан гыйбарәт була. Ул елга буена, текә яр өстенә салына. Кырга караган ягыннан саклану стенасы — утыртма бүрәнә койма корыла, тирәли тирән чокырлар казылып, алар кирәк чакларда су белән тутырыла торган була. Кабилә әгъзаларының гадәти тораклары читтәрәк төзелә. Казу эшләре вакытында ян-якларына таш өелгән каберләр табыла. Кабер өстенә, таш плитә куелып, аңа чокып, кораллы сугышчы сурәте төшерелә. Кабер эчендә, мәет янәшәсендә гадәттә корал, бизәнү әйберләре, савыт-саба куеп калдырылган була. Мөгаен, мондый каберлекләр кабилә башлыклары, хәлле сугышчыларныкы булгандыр.

Пьяный Бор каберлекләрендә табылган кораллар арасында рәвешләре белән сарматларныкына һәм римлыларныкына якын булган кылыч һәм көбәләр, шулай ук римлыларныкына охшаган боҗралы авызлыклар бар. Үз заманы өчен шактый камил булган кораллар кабилә дружиналарының сугыш кирәк-яраклары белән югары дәрәҗәдә тәэмин ителгән булуларын күрсәтә.

Хуҗалык. Идел-Уралдагы төньяк төрки кабиләләрдә акрынлап игенчелек камилләшә, көтүлекләргә чыгарыла һәм араннарда тотыла торган маллар асрау алга китә. Хәзер билгеле булган барлык игенчелек культураларының диярлек

үзләштерелүен һәм хайваннарның бик мөһим төрләренең ияләштерелгән булуын археологлар борынгы җәмгыять чорында кеше ирешкән иң зур казаныш дип исәплиләр. Башта кеше хайваннарның итен, тиресен, йонын, ә соңрак аларның сөтен дә файдаланган. Кеше атны да сугыш максатларында шактый иртә файдалана башлаган. Соңрак атлар йөк ташу һәм ерак араларга йөрү максатында транспорт чарасы буларак, игенчелектә сукалау, сөрү һ. б. эшләр өчен файдаланыла.

Агач китмәннәрдән тимер китмәннәргә күчү (китмәнле игенчелек), тимердән ясалган эш кораллары (пычаклар, балталар һ. б.) куллана башлау белән бергә хезмәт җитештерүчәнлеге дә күтәрелә. Һөнәрчелек тагын да үсеп китә. Һөнәрчеләрнең эш кораллары камилләшә, яңа технологияләр барлыкка килә. Чүлмәк ясау җәйланмасы, металлургиядә эретү мичләре күренә башлый. Хәер, һөнәрчелек әле мөстәкыйль тармакка әверелмәгән. Ярдәмче хуҗалык булган хәлдә, ул игенчелекне, аучылык һәм терлекчелекне үстерүдә этәргеч була, кешеләрнең шәхси тормышына, гаилә тормышына шатлык алып килә.

Һөнәрчелектә җитештерелгән әйберләрнең күпчелеге, элеккечә, йорт хуҗалыгы ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә китә. Сугыш кораллары һәм сугыш кирәк-яраклары дружина башлыгы һәм дружиначылар соравы буенча эшләнә. Кешеләрнең шәхси тормышын бизәүче һөнәрчелек эшләнмәләренең әһәмияте үсә. Игенчелек, терлекчелек, аучылык, шулай ук һөнәрчелектә өстәмә продукция җитештерү аларны башка нәрсәләр белән алмашуны яңа дәрәҗәгә күтәрә, базар яралгылары барлыкка килүгә китерә.

Сәнгать. Гакыл һәм сөйләм кебек үк, сәнгати һәвәслек тә кешенең табигатенә салынган. Һәм ул социаль тәҗрибә нигезендә һаман үсә бара. Гакылга нигезләнгән сөйләм тирәюньдәге әйбер һәм күренешләрне абстракт төшенчәләр ярдәмендә белдерә. Ә гакыл һәм хис белән тудырылган сәнгать аларны иҗади образлар аша чагылдыра. Сәнгать кешенең гакылы һәм хисе кебек үк борынгы нәрсә, ул сөйләм белән бер үк вакытта барлыкка килгән һәм аның белән параллель рәвештә үскән.

Сәнгатьнең сөйләм белән тагын бер уртак ягы бар: аның да асылында этник характеристика ята. Сәнгатьнең этник үзенчәлекләре, бәлкем, кабиләнең тел ягыннан башкалардан

аерымлануы белән бер үк вакытта формалашкандыр. Һөнәрчелектә этник иҗади юнәлеш тууның шул ук вакытка туры килүе мөмкин. Казан яны, Ананьино, Пьяный Бор, Имәнкискә һ. б. культуралар табылдыклары арасындагы сәнгать предметлары шул турыда сөйли. Бу коллекцияләрдә, бигрәк тә башлангычрак чорга караганнарында, балчыктан ясалган хатын-кыз сыннары күп. Бу хәл хатын-кыз культы белән бәйләнгән. Ә менә табылган коралларга исә еш кына ерткыч җәнлекләр һәм киек кошлар сурәте төшерелгән була. Ананьино культурасы коллекциясендә сөяктән ясалган поши башлары, ике һәм өч башлы кошларның бронзадан коеп ясалган сыннары һ. б. бар. Ананьино культурасына хас стильне чагылдыра торган геральдика үрнәкләре табылган. Сихерләү символларына якын булган сурәтләр дә очрый. Кешенең шәхси бизәнү әйберләре арасында төсле пыяладан ясалган беләзекләр һәм муенсалар, көнкүреш кирәк-яраклары арасында орнаментланган керамик савыт-саба бар.

Рухи мәдәният. Кешенең рухи мәдәнияте, матди мәдәнияте кебек үк, бик борынгыдан килә. Ул кешеләрнең матди тормышын чагылдырган шәүлә түгел, ә бәлки тулаем цивилизациянең һәм, гомумән, кешенең яшәү рәвешенең тигез хокуклы компоненты булып тора. Рухи мәдәният — кешенең, башлыча, психологик һәм эмоциональ кичерешләрен чагылдырган интеллектуаль эшчәнлеге җимеше ул.

Рухи мәдәният киң мәгънәсендә кешенең дөньяны танып белүен чагылдыра: үтелгән тормышка бәя бирү һәм бу тормышның гомумтанылган уңай сабакларын традицияләр төсендә беркетеп кую, ул яши торган хәзерге тормыш күренешләрен хокук һәм әхлак нормалары нигезендә кабул итү яки итмәү һәм кешене киләчәккә юнәлтә торган идеаллар — болар барысы да бик борынгы заманнардан бирле рухи мәдәниятнең нигезе булдылар. Тулаем алганда, тормышны болай танып белү «инанулар» дигән гомумиләштерә торган сүз белән белдерелә.

Тарихчыларның күпчелеге, бу борынгы инанулар палеолит чорында ук — б. э. кадәр 50—40 меңьеллыклардан башлап барлыкка килгәннәр, дигән карашта тора. Баштарак, язу-сызу һәм дөнья диннәре барлыкка килгәнче, кешеләрнең бу инанулары, без инде әйтеп үткәнчә, сәнгатьтә, күмү йолаларында һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән риваять-мифларда чагылыш тапканнар. Галимнәр, мәсәлән, стеналарына төрле

төстәге сурәтләр төшерелгән Капово мәгарәсенә[1] охшаш мәгарәләр кабилә кешеләренең аугa чыгар алдыннан уңыш теләп сихри көчләрдән үтенү, ә ау чыннан да уңышлы үткән очракларда, бу уңайдан шатлык белдереп, ритуал йолалар башкару урыны булгандыр, дип фаразлыйлар. Борынгы кешеләр уңыш китерә торган мондый көчләрнең булуына ышанган.

Борынгы кеше ул заманнарда ук инде фәлсәфи фикер йөртергә, үз яшәешенең асылын төшенергә омтылган. Үзенең үлемсезлегенә ышанып, төрбәләр төзегән, күмү йолалары булдырган һәм аларны төгәл үтәгән. Тикшерелгән каберлекләр күрсәткәнчә, алар мәет янына бизәнү әйберләре, сугыш һәм эш кораллары, азык-төлек куеп күмгәннәр. Димәк, «теге дөнья»га ышану ул вакытта инде булган дигән сүз. Күмелүченең җәсәденә кызыл төстәге минераль буяу (кровавик) сибә торган булганнар. Кызыл буяу канга тиңләнгән, кан — ул җан урыны, яшәү чыганагы, дип уйлаганнар.

Безгә кадәр килеп җиткән риваятьләрдән бик борынгы кешеләрнең гаделлеккә омтылган булуларын, нинди әхлак нормаларына таянуларын аңлыйбыз. Алар, табигать көчләре һәм күренешләрен (кояш, күк күкрәү, ерткыч хайваннар һ. б.) илаһи көчкә, сәләткә ия, дип уйлаганнар. Бу көчләр алар өчен, аларның кабиләләре өчен гаделлек эшлиләр: тырышларны канат астына алалар, хезмәт сөючеләргә уңыш юллыйлар, гаепсезләрне кызганалар һәм гаеплеләрне җәзага тарталар, дип ышанганнар.

Риваятьләрнең эчтәлеге тора-бара катлаулана. Алар кешенең үз көнкүрешенә, дөньяга, кабиләсенә һәм чит кабиләгә карашының тирәнәюен күрсәтә. «Күрше кабилә» дигән төшенчә каршы тору дигәнне генә түгел, үзара бәйләнештә булу дигәнне дә аңлата. «Тел кардәшлеге» дигән төшенчә барлыкка килә. Кабиләнең тел буенча аерымлануы, ягъни кабиләнең этник үзенчәлеккә ия булуы кешенең тел буенча үзенчәлеккә, ә аннары, тулаем, этник үзенчәлеккә ирешүне аңлавы белән бәйле. Күп кенә риваятьләрдә гомумтөрки символ булган бүре

---

[1] К а п о в о м ә г а р ә с е — ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән табигать истәлеге. Ул Башкортстанда, Агыйделнең югары агымында, елганың уңъяк ярында урнашкан. Мәгарә өч ярустан тора. Аларда зур-зур куышлар, киң аралыклар бар. Аның гомуми озынлыгы 2 километрдан артык. Җирле халык аны Шүлгән Таш (мәгарә аша шул исемдәге җир асты елгасы агып үтә) дип атый.

образының кабатлануы төньяк төркиләр үзләрен төркиләр дөньясына кертеп карый башлаганнар, дип фараз итәргә мөмкинлек бирә. Төньяк төркиләрнең мифологиясе әлегә бик аз өйрәнелгән. Шуңа күрә материалны гомумтөрки мифологиядән алырга туры килә.

Кешенең үз яшәешенә карата гомумиләштерүләре — аның кабилә вәкиле икәнлеген генә түгел, ә билгеле бер (тел буенча) кабиләдән икәнлеген аңлавы — аны үз язмышында катнашы булган көчләргә карата да яңа гомумиләштерүләргә китерә. Кешенең аңында аңардан читтә булган гаделлек көчләренең — аерым кешеләрне һәм тулаем бөтен кабиләне яклаучы көчләрнең — абстракт образы сурәтләнә башлый. Бу уңайдан галимнәр тарафыннан табылган кайбер рәсемнәр аерым игътибарга лаек (мәсәлән, балык башлы аждаһа өстендә сурәтләнгән кешеләр рәсеме). Галимнәр, бу рәсемнәрдә Яклаучы гаиләсе (Яклаучы-Ата, Яклаучы-Ана, Яклаучы-Балалар) сурәтләнгән, дип уйлыйлар.

Татарстан территориясендә бик борынгы цивилизациянең чишмә башын чама белән менә шулай күзалларга мөмкин. Татарстан тарихының асылын тәшкил иткән Болгар культурасы шушы цивилизация нигезендә формалашкан.

БОРЫНГЫ ТАТАРСТАН

БОРЫНГЫ БӨЕК ЦИВИЛИЗАЦИЯЛӘР СИСТЕМАСЫ

Гомуми характеристика. Борынгы бөек цивилизацияләр — кешенең неолит революциясе вакытында ук башланган иҗади хезмәт җимеше алар. Шулар арасында безнең цивилизация, ягъни Урта Идел буе Болгар дәүләте дә бар. «Зур тарихи этномилли культуралар» дип тә (А. И. Ракитов, 1992 ел) аталган бу цивилизацияләр шактый озак вакыт — б. э. кадәр 5 меңьеллыктан безнең эраның 1 меңьеллыгына кадәрге вакыт аралыгында формалашканнар. Бу цивилизацияләрнең иң өлкәннәре арасында, гадәттә, Мисыр белән Кытайны, Елгаара өлкә һәм Иранны, Һиндстанны һәм Көнчыгыш Урта диңгез буендагы антик дөньяны (Греция һәм Римны) атыйлар. Урта Идел буе Болгар цивилизациясе чагыштырмача яшьрәк цивилизацияләр рәтенә керә. Ул безнең эраның 1 меңьеллыгында барлыкка килә.

Барлык төбәкләрдә дә кеше үзенә хас рациональ һәм рухи-психологик характеристикалары булган индивидуум буларак яши. Үз теләкләренә табу салу (нәфес тыю) нәтиҗәсендә үзен җиңәргә өйрәнә (әхлак нормаларын үтәргә күнегә). Үзенең гәүдә-сыны матурлыгы турында һәрдаим кайгырту да кеше өчен шулай ук бик мөһим нәрсә. Борынгы цивилизация кешеләре гәүдәләрен мәңгеләштерелгән таш сыннарны күреп, бүген дә сокланмый мөмкин түгел.

Борынгы бөек цивилизацияләр тууы һәм үсешенең иң әһәмиятле параметрлары түбәндәге сыйфатламаларда чагылыш таба: тотрыклы берләшмә буларак, гаиләнең барлыкка килүе; тормышка яраклашкан җитештерүче хуҗалыкның (игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек һәм алыш-биреш итүнең) үсүе; язу барлыкка килү (б. э. кадәр 3 меңьеллык); җәмгыятьне социаль-психологик планда берләштерә торган һәм кеше-

ләрнең әхлакый мөнәсәбәтләрен, кешенең үз-үзен әхлаклы тотуын җайга сала торган рухи мәдәният үсеше; җәмгыятьне оештыруның сәяси формасы булган дәүләт формалашу. Бу очракта күп кенә галимнәр дәүләтне аерып күрсәтәләр, һәм *дәүләт оешу белән кешегә хас булган феномен — кешеләрнең социаль тормышы (җәмгыяви тормыш) тулысынча гамәлгә аша* дип исәплиләр.

Шул ук вакытта борынгы бөек цивилизацияләрнең һәркайсы уникаль (бердәнбер), аларның һәрберсенең үз йөзе бар.

Нил елгасы үзәнлеге *Мисыр цивилизациясе* үзәгенә әверелә. Б. э. кадәр 4 меңьеллыкта кабилә үзәкләренең берләшүе нәтиҗәсендә биредә фиргавен (*лат.* пер'о — зур йорт) җитәкчелегендәге иң беренче дәүләтләрнең берсе барлыкка килә. Мисырлыларның төп кәсебе сугарулы игенчелектән гыйбарәт була.

Елгаара өлкә цивилизациясе. Бу цивилизация безгә Вавилон (Бабил) патшасы Хаммурапи законнарын китереп җиткергән. Б. э. кадәр 2 меңьеллыкта теркәлгән бу мөһим истәлекләр аллаларның Хаммурапига «көчлеләр көчсезләрне җәберләмәсеннәр өчен» патшалык бирүе турында хәбәр итәләр. Мондый нигезләмә соңыннан күп кенә төбәкләрдә, шул исәптән Владимир Мономахның үгет-нәсыйхәтләрендә дә кабатлана. Бу нигезләмә борынгы Урта Идел буе Болгарының социаль тормышында да үзенә бер төрле чагылыш таба.

Урук шәһәре патшасына багышланган «Гильгамеш турында хикәятләр» дигән эпик поэмада тасвирланган борынгы Шумердагы тормыш та кызыксыну уята. Анда дәүләт тормышы турында гына түгел, Гильгамешның кыргый кеше Энкиду белән дуслыгы һәм аларның гаделлек хакына каһарманлык эшләүләре турында да матур тасвирлар белән сөйләнә. Поэмада үлем турындагы мәсьәлә үзенчә хәл ителә: кеше гомере мәңгелек була алмый, диелә. Шул ук вакытта геройлар кешене картаюдан саклый торган тылсымлы үсемлек табалар, ләкин аны югалталар. Үлгән кешеләрнең язмышы турында, аларның ачлыктан һәм сусаудан интегүләре, каберләрдә ашар азык һәм эчәр су калдыру, алар истәлегенә корбан чалу зарурлыгы турында бәян ителә. Имештер, шул поэмада сурәтләнгән вакыйгаларның шаһиты булган кешеләрнең берсе исеменнән Бөтендөнья туфаны турында сөйләнә. Тагын шунысы кызыклы: мәгълүм тел белгече Ә. Кәримуллин Шумер культурасы белән төркиләрнең тел культурасы

арасында туганлык күрә. «Алпамыш» дастанын әлеге эпос белән бәйләргә омтылучы галимнәр, бәлки, хаклыдыр.

Зороастр Ираны. Бу илнең үзенчәлекле цивилизациясе, үз чиратында, безнең борынгы тарихны аңлау өчен күп кенә гыйбрәтле материал бирә. Берләштерелгән Көнбатыш һәм Көнчыгыш Иранда б. э. кадәр VI гасырда Ахеменилар династиясенең куәтле дәүләте барлыкка килә. Урта Азиянең төрки халыклары да (Харәземдә, Бактриядә яшәүчеләр) бу дәүләт составына керә. Борынгы иранлылар табынган Зороастр диненең (нигез салучысы — пәйгамбәр һәм реформатор, Авестаның борынгы кисәген төзүче Заратуштра; ул б. э. кадәр X—VI гасырлар арасында яшәгән) изге китабы иранлыларның ул вакытта ук инде кабилә аллаларыннан гомумиран Ахурамазда Алласына — Күк Алласына — көчкән булуларын күрсәтә. Бу дин Борынгы Ирандагы Ахеменилар династиясе дәүләтенең ныгуына хезмәт итә. Зороастр динен тоткан, өлешчә Һиндстанда яшәгән иран телле игенчеләр «арийлар» дип аталганнар.

«Парсларның» (фарсыларның) Һиндстанда яшәүче вәкилләрендә әле дә булса үле кешенең җәсәден махсус эшләнгән таш манара өстенә кую йоласы сакланган. Алар фикеренчә, Җир, Ут, Су һәм Күк йөзе — изге нәрсәләр һәм аларны үле кеше гәүдәсе белән нәҗесләргә, мәсхәрәләргә ярамый. Шундый манараларны, әйтик, Бомбейда очратырга мөмкин. Алар өстенә куелган үле гәүдә биредә яшәүче ерткыч кошлар — грифлар өчен азык була. Ибне Фадланның Идел буе болгарларының тормышы турындагы язмаларында шуңа охшашрак нәрсә турында сөйләнә. Ул болай дип яза: «Әгәр бер болгар икенче бер болгарны алдан уйлап аңлы рәвештә үтерсә, ул җәзага дучар ителә. Әгәр ул теге кешене ялгышлык белән үтерсә, үтерелгән кеше өчен халаҗ агачыннан махсус әрҗә ясап, аның эченә мәетне салалар, ә аның янына өч кабартма (көлчә) һәм сулы чүлмәк куялар. Аннары бу әрҗәне баганага эләләр һәм: «Без аны җир белән күк арасына куябыз һәм яңгыр белән кояш ихтыярына калдырабыз»,— диләр...»

Борынгы Һинд цивилизациясе. Соңрак изге китаплар булып киткән һинд ведаларыннан (әдәбият истәлекләре, «веда» — «белем» дигән сүз), шулай ук «Махабхарата» (б. э. кадәр 1 меңьеллык урталары) һәм «Рамаяна» (б. э. кадәр 1 меңьеллык башы) дип аталган эпик хикәятләрдән күренгәнчә, Борынгы Һинд цивилизациясе таулар (Һималай) һәм елга-

ларны (Һинд һәм Ганг) эченә алган географик мохиттә барлыкка килә һәм үсә. Һиндлеләр фикеренчә, бу дәүләт Ашока патша (б. э. кадәр 273—236) вакытында чәчәк аткан. Һиндстан җәмгыятен һәм дәүләтен рухи яктан берләштерүче Будда диненең Брахманизм тәгълиматы булган. Нигез салучысы — галим, реформатор, соңыннан Будда, ягъни «Якты рух иясе» дигән исем алган Сиддхартха Гаутама (623—544). Ул вакытларда ук инде Һиндстан киң халыкара аренага чыга, Урта диңгез буе дәүләтләре белән мөнәсәбәтләр урнаштыра, эллин (грек) дәүләтләре белән, ә соңрак Рим белән дә дипломатик мөнәсәбәттә тора.

Менә шундый җәмгыятьнең Борынгы Иран һәм Урта Азия аша бик борынгы Урал культурасы үзәгенә — Идел-Уралга чыгу юлы да булмый калмагандыр.

Борынгы Кытай цивилизациясе. Ул б. э. кадәр 2—1 меңьеллыкларда Хуанхэ (төньякта) һәм Янцзыцян (көньякта) елгалары, Куньлунь (көнбатышта) таулар системасы һәм Тын океан (көнчыгышта) тирәлегендәге географик мохиттә барлыкка килә. Ул Үзәк Азиянең төрки цивилизацияләре — төньякта һуннар, көнбатышта уйгурлар (Кашгар) белән турыдан-туры чиктәш була. Нык үскән Кытай җәмгыяте һәм куәтле Кытай дәүләте — башында император (хуанди) торган империя — бөтен дөньяга үзенчәлекле хуҗалык һәм мәдәният үзәге буларак танылa. Сөрүле игенчелеккә кучу мөмкинлеге биргән сабан уйлап табыла. Туку һәм ефәк туку һөнәрчелеге зур үсеш ала. Кытайны Көнбатышның ерак илләре белән бәйләгән Төньяк сәүдә юлы — Римга кадәр илтә торган Бөек ефәк юлы барлыкка килә. Галимнәр ул вакытлардагы «Бай булырга теләгән кеше өчен һөнәрчелек игенчелектән өстенрәк, ә сәүдә һөнәрчелектән өстенрәк» дигән әйтемне еш кулланалар.

Бу илдә Конфуцийның (551—479) кешелеклелеккә, гаиләдәге һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне закон нигезенә куярга өндәүче этик-сәяси тәгълиматы (конфуцийчылык) киң таралган була, хакимият аны озак еллар буена кире кагып килсә дә, соңыннан бу тәгълимат дәүләтнең рәсми идеологиясенә әверелә. Безнең эраның I—II гасырларында Кытайда буддизмны рәсми рәвештә тарату башлана. Фән алга китә. Талантлы фикер иясе һәм уйлап табучы Чжан Хэн (78—139) күк җисемнәре хәрәкәтен кабатлый торган глобус ясый,

сейсмограф уйлап таба. Ике-өч катлы һәм аннан да биегрәк биналар төзелә башлый.

Инде әйтеп үтелгәнчә, мәшһүр Бөек ефәк юлы Кытайда башланып китә. Бохара, Сәмәркандтан соң ул төньякка борыла. Әлеге төньяк тармак, Харәзем аша үтеп, Каспий диңгезен әйләнеп чыга, көньякка таба юнәлә, Кавказ аръягы аша Урта диңгезгә чыга. Шулай итеп, Идел-Урал әлеге ерак елларда ук бу бөек сәүдә юлына җәлеп ителә.

Борынгы Урта диңгез буе. Дөньяның иң уңайлы, бәрәкәтле территорияләреннән булган бу төбәк борынгы еврей, борынгы гарәп һәм антик (Греция, Рим) цивилизацияләр ватанына әверелә. Гарәбстан ярымутравының муллык почмагы дип аталган өлешендә (ярымутрауның ясалма сугарулы игенчелек нык үскән көньяк-көнбатыш өлкәләрендә) б. э. кадәр 2 меңьеллыкта Шумер, Аккад, Ашшур һәм Борынгы Көнчыгышның башка дәүләтләре белән бәйләнештә булган Миней һәм Сабей дәүләтләре үсә. Гарәпләр исламга кадәрге алдынгы мәдәният тудыралар. Галимнәр аларның үз әдәбияты булган, ләкин, кызганычка каршы, ул «тулысынча юкка чыккан» дип исәплиләр. Соңрак гарәпләр беренчеләрдән булып бөек диңгез юлларын үзләштерәләр. 651 елда Гарәбстаннан Кытайга беренче илчелек җибәрелә.

Мисырның гегемониясе көчсезләнгәннән соң, ярымутрауның төньяк-көнбатышында б. э. кадәр 1 меңьеллык урталарында шәһәр-дәүләтләр, шул исәптән Фәластыйн (Палестина) барлыкка килә. Бу шәһәр-дәүләтне «Израиль» дигән атама астында берләшкән, ул тирәләргә б. э. кадәр XIII гасырда килеп урнашкан кабиләләр кулга төшерә. Телләре белән аларга якын булган ханаанлылар кысрыклап чыгарыла. Еврейләр дип атап йөртелгән икенче кабиләләр төркеме тау өлкәсенең көньягында (Үле диңгездән көнбатыштарак) урнаша һәм еврейләр дәүләтен — Иудеяне төзи. Ләкин бу ике дәүләтнең берләштерелгән дәүләттә яшәргә омтылулары уңышсызлыкка очрый. Ә аерым хәлдә алар озак яши алмый. Израиль 722 елда Ассирия басымы астында, ә Иудея Вавилон кысрыклавы нәтиҗәсендә яшәүдән туктый. Еврейләрнең беркадәресе Мисырга качарга мәҗбүр була, икенчеләрен Вавилонга куып алып китәләр. Ләкин аларның мәдәнияте тотрыклы булып чыга һәм бүтән мәдәниятләргә дә йогынты ясый.

Борынгы Европа цивилизациясе. Борынгы Европа цивилизациясенең чишмә башы бик борынгы Эгей диңгезе бассейнына барып тоташа. Грециянең материк өлешенең көньягы (Пелопоннес), утраулар Грециясе (Крит, Хиос, Самос, Родос...), хәзерге Төркиянең диңгез буе полосасы (Троя, Эфес, Милет, Галикарнас...) игенчелек белән шөгыльләнү һәм бакча культуралары (зәйтүн агачы, виноград) үстерү өчен бик уңайлы, ә җир асты файдалы казылмаларга (мәрмәр, көмеш, бакыр, кургаш, тимер, алтын) бай була. «Бу җирләрдән дә бәрәкәтлерәк җирне безнең башка бер генә илдә дә белгәнебез-күргәнебез булмады»,— дип яза Геродот.

Крит утравында дәүләт барлыкка килү б. э. кадәр 2 меңьеллык башларына туры килә. Б. э. кадәр XIII гасырда Крит утравында яшәүчеләрдән эстафетаны ахейлылар кабул итеп ала. Грециянең материк өлешендә аларның үз дәүләтләре (Пелопоннес ярымутравындагы Микены шәһәре) күтәрелеп чыга. Б. э. кадәр XII гасырда Микены патшасы Агамемнон җитәкчелегендә Трояга каршы ахейлылар алып барган сугышлар «Илиада» эпосында тасвирлана.

Антик Грециянең алга таба үсеше югарыда тасвирланган борынгы цивилизацияләр юлыннан китми. Б. э. кадәр VIII—VI гасырларда биредә дәүләт строе яңа формаларда оеша: полислар, ягъни шәһәр-дәүләтләр барлыкка килә. Полис бер үк вакытта гражданлык җәмгыяте буларак та эш итә. Аның әгъзалары җиргә милек хокукына ия була. Полислар сәүдә-сәнәгать үзәкләренә әверелә. Шуның нәтиҗәсендә икътисади яктан ирекле кешеләр даирәсе киңәя. Дәүләтне идарә итүдә аларның роле арта. Афина, Спарта, Милет, Галикарнас һ. б. әнә шундый үзидарәле бәйсез шәһәр-дәүләтләр булалар.

Борынгы Көнчыгыш Европа, борынгы Идел-Уралны да кертеп, Кара диңгез ярларына урнашкан Греция колонияләре аша, аерым алганда Ольвия, Ира, Херсонес, Феодосия, Пантикапей, Танаис, Фанагория, Гаргиппия, Питунт, Диоскуриада шәһәрләре аша, Борынгы Греция цивилизациясе орбитасына җәлеп ителә. Алар белән бәйләнеш б. э. кадәр VI гасырга кадәр гамәлдә булып, Азовтан алып Алтайга хәтле сузылган Геродот тасвирлаган сәүдә юлы аша алып барыла. Бу юл Дон һәм Идел буе аша үтә.

Борынгы Татарстанның социаль тормышына антик Римның да йогынтысы була. Рим цивилизациясе, мәгълүм булганча, көнчыгыш эллиннар белән генә бәйләнештә булып

калмый, б. э. кадәр VII—VI гасырларда Этруриядә (Италиянең үзәк өлеше) формалашкан һәм б. э. кадәр V—III гасырларда төзелгән Этруск Федерациясе белән дә мөгамәлә урнаштыра. Гадәттә, Көнбатыш тарихчылары этрускларның мәдәният өлкәсендәге казанышларына бәя биргәндә, аларның чынлыкта кем булганлыкларын аңлатмыйлар. Этрускларның чыгышлары белән Көнчыгыштан икәнлекләрен һәм аларның күп кенә матди культура истәлекләренең Көнчыгыш характерында булуларын гына билгеләп үтәләр («Бөтендөнья тарихы», т. I, 1995). Төрек галимнәре Казыйм Миршан (1970) һәм Адилә Айда фикеренчә (1972), этрускларның телләре төрки телләр гаиләсенә карый, ә этрусклар үзләре җирле төркиләрнең бик ерак бабалары булганнар. Шул ук «Бөтендөнья тарихы»нда, Этруск Федерациясе иң нык чәчәк аткан вакытта — б. э. кадәр VI гасырда — мөгаен Рим да аңа буйсынып яшәгән, дигән фараз әйтелә.

Римлылар хәрби өлкәдә дә зур уңышларга ирешәләр. Алардагы ул заманнар өчен алдынгы корал һәм сугыш кирәкяраклары, армияне оештыру системасы, сугыш алып бару тактикасы, буйсындырылган илләрдә армиянең үз-үзен тотышының хокукый нормалары — болар барысы да бүтән илләр өчен, шул исәптән Идел-Урал өчен үрнәк була. Римдагы дәүләт хокукы һәм гражданлык хокукы, аерым алганда, сенатның ролен күтәрү мәсьәләләре, җиргә хосусый милекне ныгыткан аграр законнар, консул Цицеронның илдәге «сословиеләрнең бердәмлеге турында»гы идеясе һ. б. бүтән илләрдә югары бәяләнә.

БОРЫНГЫ ТАТАРСТАНДА ЭЛГӘРЕГЕ ДӘҮЛӘТ ОЕШТЫРЫЛМАЛАРЫ

Мәсьәләнең куелышы. Кеше, социум субъекты буларак, даими рәвештә үзгәреп торган, социум үзе дә үзгәрешсез калмаган. Үзенә хас индивидуаль һәм социаль сыйфатламалары (идарә итү формалары, традицияләре, идеаллары, кешеләрнең рухи-психологик яктан бер-берсенә ияләшүләре, телләре) булган *ыруглык җәмгыяте* (родовое общество) башка төрле индивидуаль һәм социаль сыйфатламаларга ия булган *ыруглык-кабилә җәмгыятенә* (родоплеменное общество) әверелгән. Ә бу исә кешенең яшәү рәвеше дә үзгәргән дигән сүз. Бу ике этапта социум этник яктан бериш саклана.

Соңрак социум *«кабиләләр союзы»* формасын ала. Тарихчылар аны *«элгәреге дәүләт оештырылмасы»* дип атыйлар. Ниһаять, социумны идарә итүнең борынгы формасы — *борынгы дәүләт барлыкка килә*, һәм аның кысаларында *борынгы халыклар формалаша*, борынгы цивилизацияләр туа. Борынгы цивилизацияләрнең һәркайсы үзенә бертөрле, үзенчәлекле була: алар бик борынгы кеше тарафыннан хәзерләнгән җирлектә барлыкка килә, моңа кадәрге буын ирешкәннәрнең иң яхшысын мирас итеп ала, әлеге төбәкнең географик һәм климат шартларында үсеп китә.

Татарларның борынгы Болгар дәүләте, ягъни борынгы Урта Идел буе Болгары да, никадәр генә үзенчәлекле булмасын, шушы кагыйдә кысаларыннан чыкмый.

Идел-Уралдагы элгәреге дәүләт оештырылмаларының төньяк төрки этник нигезе. Русьны өйрәнү барышында рус историографиясе Кара диңгез буеның төньягында скиф-сармат кабиләләренә һәм аларның дәүләт оештырылмаларына, шулай ук Көнчыгыш Европаның төньяк җирләрендә шактый зур фин-угор катламына тап була. Бу тирәләргә соңрак килеп урнашкан көнчыгыш славяннар — руслар, украиннар, белоруслар — нәкъ менә шулар белән очрашканнар дигән теория туа. Ә, гомумән, Көнчыгыш Европаның төрки кабиләләре һәм Идел-Уралның төньяк төрки кабиләләре өчен күптәнге туган җир булганлыгы (төньяк төрки кабиләләрнең Идел-Уралда автохтонлыгы) турындагы мәсьәлә бөтенләй куелмый. Бирегә б. э. кадәр VII гасыр элек килеп урнашкан скифлар тоташ иран телле булганнар дигән фикер дә бар. Хәлбуки «скифлар» дигән җыйма атаманың иран телләрне дә, төрки телләрне дә эченә алганлыгы фәндә инде күптән билгеле. Бик борынгы Идел-Уралда төрки кабиләләрнең булуы Татарстан, Чувашстан, Башкортстан территориясендә табылган һәм тикшерелгән археологик культураларны кайбер галимнәр тарафыннан фин-угор культуралары дип атау юлы белән инкарь ителә. Бу галимнәр Бөек Венгрия Идел-Уралдагы беренче дәүләт булган дип тә игълан итәләр. Кара диңгез буендагы Болгар дәүләтен фин-угор дәүләте дип раслаучы басма хезмәтләр дә бар. Борынгы татар дәүләтен VIII гасырда Идел-Уралга килгән болгарларныкы гына дип исәпләүче концепция дә яши.

Революциягә кадәрге күп кенә татар тарихчылары борынгы татар дәүләтенең чишмә башын бик борынгы Идел-

Уралның үзендә күрәләр. Шиһабеддин Мәрҗани, мәсәлән, «болгар» сүзен борынгы төрки сүз дип, аны «болгамак» сүзеннән (бәлки, җирле төрки кабиләләрен кушу-болгатудандыр) китереп чыгара. Ризаэддин Фәхреддин дә «болгар» сүзенең җирле сүз булуы турындагы фикердә тора. Ул «болгар» сүзе «бол кар» — «күп кар» мәгънәсен аңлата дип исәпли. Р. Г. Кузеев та «болгар» сүзенең чыгышын җирле кабиләләр теле белән бәйли.

Дөнья историографиясендә «болгар» сүзенең глобаль чыганакларын эзләп, төрле фаразлар корып карыйлар. Шундый фаразларның берсе «болгар» сүзенең Идел исеменнән — «болгар»//«Бол-га» (Волга) килеп чыгуын раслый. Византия тарихчысы Григорас болай дип яза: «Җирле халык аны (елганы) «Булга» дип атый. Үзләренең атамаларын болгарлар шул елга исеменнән алганнар». Аның белән М. Щербатов та килешә. Ә менә В. Татищев аны кире кага. Ул болгарлар (Идел буе болгарлары) үзләренең исемнәрен төп шәһәрләре атамасыннан алганнар дип раслый. Мөгаен, В. Татищев бу мәсьәләдә хакыйкатькә якын торгандыр. Борынгы греклар бу елганы «Ра» дип атаганнар. Татарлар исә аны «Идел» диләр. Көнбатышта һәм Көнчыгышта урта гасырларда аны шушы исем (Итил-Этил) белән белгәннәр. Хәзер күп кенә галимнәр «болгар» сүзенең аңлатмасын төрки телдән эзләү ягында торалар. «Болгар» сүзенең чыгышы белән төрки телдән булуында шик юк»,— дип яза Болгария галиме В. Семионов. Үз чиратында ул шулай ук «болгар» сүзенең тотем сүз булуы ихтималын искәртә. Хәзерге татар историографиясе, борынгы лингвистик материалны өйрәнү нигезендә, төрки телле кабиләләр Идел-Уралда фин-угор кабиләләре белән күршеләр булып бик борынгы заманнардан бирле яшиләр (М. З. Зәкиев, 1995 ел) дигән фикердә тора.

Борынгы Биләр. Борынгы татар дәүләте булган Болгарның чишмә башы бронза һәм тимер дәверләренә (б. э. кадәр 1 меңьеллыкның икенче яртысы — безнең эраның 1 меңьеллыгының беренче яртысы) илтә. Ул вакытта ук инде, күп кенә галимнәр әйтүенчә, Урта Идел-Кама елгалары бассейнында төрле төньяк төрки кабиләләрнең «болгарларга кадәрге культура» яисә «Биләр-Болгар культурасы» дип аталган борынгы культурасы чәчәк ата. Археология табылдыкларына (шәһәрлекләр, буралап ясалган каберлекләр, бакыр балталар, бронза ураклар һ. б.) караганда, ул [redacted] яша-

гән. Ул вакыттагы шәһәрләрнең безгә билгелеләре арасында иң зурысы Кече Чирмешән яры буена урнашкан Биләр яисә Биар булган (төркичә «Би» яисә «Бил» — кабиләләр берләшмәсе йөрткән атама, ә «ар», «ир» — кеше). Биләрнең биләмәләре Кама буйлап Чишмә елгасына кадәр сузылган борынгы Әҗмәр һ. б. татар авылларын, Актай, Утка һәм Бизнә елгалары үзәнлекләрен эченә алган.

Эшкәртү өчен уңайлы булган уңдырышлы җирләр, язгы ташу вакытында су астында кала торган киң тугайлар төбәкнең хуҗалык һәм мәдәният ягыннан үсүенә йогынты ясаган. Иделгә чыгучы кайнап торган сәүдә юлында урнашкан һәм һөнәрчелек нык үскән Биләр шәһәре икътисади һәм административ яктан берләштерүче үзәк буларак формалашкан.

Бу территориядә табылган археологик культуралар раславынча, Утка елгасындагы Суар шәһәре, Каманың уңъяк ярында, хәзерге Олы Елга авылы (Балык Бистәсе районы) янында урнашкан Кашан шәһәре ул вакытта сәүдә-һөнәрчелек үзәкләре һәм кардәш кабиләләрне берләштерүче үзәк буларак формалашканнар. Иделнең уңъяк ярында «бортаслар» дигән гомуми атама астында берләшкән кабиләләр яшәгән. Зөя елгасы үзәнлегендә шундый берләштерүче үзәк сыйфатында Ашлы (Ошель) һәм Янтык шәһәрләре үсеп чыккан. Кабиләләр берләшмәләренә телнең аныклыгы һәм билгеле бер этник территория булу кебек күрсәткечләр уңай йогынты ясаган.

Элгәреге дәүләт оештырылмаларының барлыкка килүе. Безнең эраның 1 меңьеллыгы уртасы Идел-Камадагы төньяк төрки кабиләләр берләшмәләре тарихында борылыш чоры була. Ул Рим империясенең (V гасыр) һәм Кытайдагы үзәкләштерелгән Хань империясенең (VI гасыр) таркалу процессы белән бер үк вакытка туры килә. Европа һәм Азиянең бу империяләргә чиктәш булып яшәгән халыклар үзләренең цивилизация учаклары булган үз дәүләтләрен төзү юлына басалар. Борынгы Татарстан да бу процесска кушылып китә.

Борынгы Татарстан территориясендә менә шундый элгәреге дәүләт оештырылмасы Биләр (Бүләр) булган, дигән караш галимнәр арасында торган саен киңрәк тарала. Ул дәүләт оештырылмасы кардәш кабиләләрнең Биләр берләшмәсе нигезендә формалаша. М. З. Зәкиев аны болгарларга кадәр булган «Биарым» («Минем Биарым») дигән шартлы атама йөрткән, тышкы дөньяда «Биармия» дип аталган борынгы татар дәүләте буларак кабул итә.

М. З. Зәкиевнең бу кызыклы гипотезасы инде расланган дип әйтеп булмый. Ләкин VII гасырда Биләрдә татарларның элгәреге дәүләт оештырылмаларыннан берсенең барлыкка килүе бездә шик уятмый. Алай гына да түгел, кардәш кабиләләрнең башка берләшмәләрендә дә элгәреге дәүләт оештырылмаларына кучү тенденциясе сизелә. Бу турыда сөйләгәндә Суар шәһәрен һәм бортасларны мисал итеп алырга мөмкин. Суар — Иделгә коя торган Утка елгасының югарыгы агымында IX—XIV гасырларда яшәгән шәһәр. Археологик казулар вакытында биредә борынгы ныгытмалар, сарай бинасы, шәһәр йортлары калдыклары табыла. Болгар шагыйре Кятиб Чәләби: «Мин Сөләйман бине Дауд әс-Суари булам»,— дип яза. Чепца елгасы (Вятка елгасының янсуы, кушылдыгы) үзәнлегендә урнашкан Карин татар әмирлеге, Казансуның үрге агымында урнашкан Арча татар әмирлеге дә, бәлки, шундый ук чорны, ягъни элгәреге дәүләт оештырылмалары барлыкка килү чорын үткәннәрдер. Борынгы Болгар шәһәре урнашкан җирдә археологлар аннан да алдарак яшәгән шәһәрлекне табалар. Бу шәһәрлек тарихы да, бәлки, югарыда әйтелгән фикерне раслар.

Башка илләрнең дә борынгы тарихында шундый элгәреге дәүләт оештырылмаларының булганлыгы билгеле. Кайчак аларны протодәүләтләр яисә кенәзлекләр дип, ә Көнчыгышта бәклекләр дип атыйлар. Андыйларның берләшүе кайбер очракларда, федерация сымак бер этапны үтеп яисә ул этапны үтмичә генә, үзәкләштерелгән дәүләт оешуга китергән (греклар бу берләшә торган кенәзлекләрне пактиотлар дип атаганнар, «пакт» — шартнамә сүзеннән). Бу кенәзлекләрнең башында үз дружиналары булган кенәзләр (Көнчыгыш чыганаклары буенча әмирләр — «әмер бирү» дигән сүздән) торган. Кенәзләр (әмирләр) эшчәнлегенең төп максаты кабилә берләшмәсе территориясен тышкы һөҗүмнәрдән саклаудан гыйбарәт булган. Бер үк вакытта алар кабиләләр берләшмәсе территориясен киңәйтү һәм берләшмә халкын әсирләр хисабына арттыру функциясен дә үтәгән. Берләшмәнең ирекле халкы (Җыены) кенәзләрне, нигездә, шуның өчен билгели дә инде. Кабиләләр берләшмәсенең эчке эшләре, хөкем итүне дә кертеп, ыру башлыклары (аксакаллар) советы карамагында кала. Озак еллар уңышлы хезмәт иткән кенәзләр (әмирләр) әлеге ыру башлыклары советы составына кертелгән. Тора-бара советта гына түгел, Җыенда да аларның абруйлары үскән.

Борынгы Татарстандагы күрсәтеп үтелгән элгәреге дәүләт оештырылмалары үзәкләштерелгән борынгы татар дәүләте Болгарның башлангычлары булган.

БҮГЕНГЕ ТАТАРСТАН ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ БОРЫНГЫ ДӘҮЛӘТ ОЕШУНЫҢ АЛШАРТЛАРЫ

Борынгы Көнчыгыш Европа. Тарихчыларның күпчелеге, Көнчыгыш Европа территориясен нигездә фин-угор халыклары, көнчыгыш славяннар һәм төньяк төрки кабиләләр биләгән, дип гөманлый. Бу кабиләләр үзләренең борынгы тарихларын безнең эраның беренче меңьеллыгында Борынгы Рим империясе янәшәсендә яшәгән башка халыклар белән бер үк вакытта үткәннәр. Борынгы Көнчыгыш Европа цивилизациясендә рухи яктан Византиягә якын торган борынгы көнчыгыш славян дәүләте (Киев Русе) һәм гомумтөрки дөньясына этник һәм рухи яктан якын торган борынгы төрки дәүләтләр булган. Шул ук вакытта Көнчыгыш Европада урнашкан бу дәүләтләр, территорияләренең бер-берсенә якын булуы сәбәпле, башка дәүләтләр белән мөгамәләдә булудан битәр, үз араларында якынрак һәм тирәнрәк хезмәттәшлек урнаштыралар.

Көнчыгыш Европаның борынгы төрки дәүләтләре рәтенә, гадәттә, *азаккы Һун империясен, Кара диңгез буе Болгар дәүләтен* һәм *Хәзәр каһанлыгын* кертәләр. Бу дәүләтләрдән иң соңгысының — Хәзәр каһанлыгының таркалуын еш кына аның башкаласы Итилнең Киев кенәзе Святослав (957—972) яулары нәтиҗәсендә җимерелүе белән бәйлиләр. Хәзәр дәүләте таркалуның тарихи сәбәбен сугышта уңышсызлыкка очрауда гына түгел, башлыча Көнчыгыш Европада яңа буын дәүләтләрнең — борынгы татар дәүләте Идел Болгарының һәм борынгы Киев Русе дәүләтенең барлыкка килүендә күрергә кирәк. Асылда, Хәзәр каһанлыгы үзенең таркалуы белән бүгенге татарларның борынгы дәүләтенә үсәр мәйдан ача.

Азаккы Һун империясе. Элгәреге Һун империясе үз башлангычын б. э. кадәр 1 меңьеллык азагында Урта Себер яссытаулыгының төрле төрки кабиләләр яшәгән Байкал (Байкүл) буенда һәм Байкал аръягында ала. Кытайдагы язма чыганакларга караганда, бу дәүләт оештырылмасының башында Модэ (205—177) тора. Байкал аръягында Судже елгасы буенда үткәрелгән археологик казулар барышында галимнәр гранит

кантарлардан өелгән зур-зур курганнарга тап булалар. Тирәндә каберлекләр итеп ясалган бүрәнә буралар табыла. Каберләрдәге такта табутларда кеше сөякләре белән янәшәдә йорт кирәк-яраклары, бронза көзгеләр, корал, тимер авызлыклар, керамика, ефәк тукыма калдыклары һ. б. урнаштырылган булган. Биредә яшәгән халыкның утрак өлеше иген үстергән. Бу халыкка металлургия дә таныш булган.

Соңрак, безнең эраның III гасырында һуннар, көнбатышка хәрәкәт итеп, Арал диңгезе буйларын, Түбән Иделне үзләренә буйсындырган, ә 375 елда Баламир патша җитәкчелегендә Донны кичкәннәр. Нәкъ әнә шул вакытта Кара диңгез буе иңкүлеге киңлекләрендә (көнбатышта Дунай, көнчыгышта Кальмиус елгалары арасында), Кара диңгез буендагы элеккеге Греция һәм Рим дәүләт-шәһәрләрен дә кертеп, Кара диңгез буе азакки Һун империясе барлыкка килә. Византия Кырымдагы Херсонесны гына үз кулында саклап кала. V гасырда патша Аттила заманында Һун империясе чәчәк ату чорын кичерә (434—453). Готларга каршы, Византиягә каршы көрәшә, Рим империясенең таркалуына сәбәпче була. Ә тиздән Аттила патша үлгәннән соң үзе дә таркала.

Кара диңгез буе Болгары. Төньяк Кара диңгез буе тарихта этник яктан чуар төбәк буларак билгеле. Монда күп кенә культуралар күршедәш булып яши. Б. э. кадәр VIII—VII гасырларда биредә этник яктан бер төрле генә булмаган кимерийлеләр дип аталган халык яшәгән. Б. э. кадәр VII гасырдан алып безнең эраның III гасырына кадәр бу төбәк төрле кабиләләрнең, шул исәптән фарсы һәм төрки телләрнең, шулай ук сакланып калган кимерийлеләрнең бергә тупланулары үзәге булып китә. Барлык бу халыклар тарихка «скифлар» дигән гомуми атама белән кереп кала. Алар б. э. кадәр IV гасырда Скиф дәүләтен төзиләр. Безнең эраның III гасырында Төньяк Кара диңгез буендагы кабиләләр арасыннан сарматлар аерылып чыга башлый. V гасырда азакки Һун империясе кысаларында төбәкнең этник төрлелеге традициясе сакланып калган гына түгел, элеккеләренә тагын славян кабиләләре дә өстәлгән. Өстәвенә биредә грек һәм римлыларның шәһәрдәүләтләре дә сакланган була. Шулай итеп, биредә скиф, төрки һәм славян культуралары янәшә яши. Шул ук вакытта төбәкнең төркиләргә йөз тотуы көчәя. Әл-Мәсгуди (X гасыр), Төньяк Кара диңгез буеның этник составы турында сөйләп, «Хәзәрләр һәм аланнар күршесендә, алардан көнбатыштарак

Бажна (кыпчаклар, команнар), Бажнак (бәҗәнәкләр) һәм Навкарда (болгарлар), төрки кабиләләре һәм Бажгурдлар (венгрлар) яши»,— дип яза. Алардан тыш бу урыннарда славяннар яшәве турында да әйтеп үтә. Төрле культуралар янәшә яшәгән бу полиэтник төбәктә төрки телле болгар кабиләләренең беренче планга чыгуларына менә шушы әйтеп үтелгән гомумтарихи күзлектән чыгып карау фарыз. Ә «болгар» дигән, шулай ук «һун» дигән атамаларга килгәндә, аларны дәүләт оешу барышында ныгып калган политонимнар дип исәпләргә кирәк.

Һуннар империясенең варисы булган *Кара диңгез буе Бөек Болгар дәүләте* (башкаласы — антик грек дөньясының йортшәһәре Фанагория — Фанагурис) VI гасырда халыкара танылу таба. Дәүләтнең чәчәк атуы VII гасырның беренче яртыларына — балтавар (патша) Кубрат хакимлек иткән вакытка туры килә. Дәүләт үзәкләштерелгән идарәле берничә әмирлекне берләштерә. Башында Кубратның өлкән улы Аспарух торган, «Ак болгарлар» дип аталып йөртелгән кабилә Днепр буеннан Кубанга кадәр сузылган җирләрне биләгән. Ә «Кара болгарлар» дип аталганнары Кубрат ханның икенче улы җитәкчелегендә Дон елгасының түбәнге агымындагы җирләрдә яшәгән. Донец елгасының урта һәм үрге агымнарындагы территорияләрдә үзләрен «катраклар» дип атап йөрткән болгарлар көн иткән.

Илнең хуҗалыгы скифлар заманыннан ук килә торган шактый алга киткән традицион игенчелектән, терлекчелек, аучылык һәм балыкчылыктан гыйбарәт булган. Төбәктәге икътисадның бай булуы турында болгарлар белән сәүдә иткән, бу илдән ашлык, мал-туар, умарта балавызы, мех, коллар алган греклар язып калдырган. Греклар һәм римлылар заманында ук нигез салынган административ һәм сәүдә-һөнәрчелек үзәкләре (мәсәлән, хәзерге Керчь урынында урнашкан булган Пантикапей) һәм дә яңалары алга таба тагы да үсеп, куәтләнеп китәләр. Хәзинәләр оясы булган бу төбәктә үткәрелгән археологик казулар вакытында Кара диңгез буе болгарларыныкы булган күп кенә тарихи материал табыла. Хәзинәләр арасында 1912 елда Полтава тирәсендә (бәлки, «балтавар» дигән сүздәндер) табылган IV—VII гасырларга караган, рус историографиясендә «Перещепино хәзинәсе» дип аталган хәзинә дә бар. Галимнәр, бу хәзинә Кубрат ханның һәм аның агасы Арган ханның каберлеге булырга тиеш,

дигән нәтиҗәгә киләләр. Барлыгы 75 килограммлык 800 данә алтын һәм көмеш әйберләр табыла. Хәзер алар Санкт-Петербургта Эрмитажда саклана. Соңгы вакытларда Кара диңгез буе Болгары тормышын тасвирлаучы язма истәлекләр дә табыла. 1991 елда Әнкарада галимнәр фикеренчә, моннан 800 ел элек Киевта (борынгы Византия телендә — Шамбатус) яшәгән болгар шагыйре һәм кенәзе Микаил Баштуның «Шан кызы дастаны» басылып чыга.

Кара диңгез буе Болгары Дунайда (Болгария) һәм Урта Иделдә (Идел буе Болгары) яңа дәүләтләр башлап җибәрү өчен кыска гына бер мизгелгә кабынып алган дәүләт түгел. Бу халык Кара диңгез буе үзәнлегендә, башка халыклар белән бергә, бу тирәгә һуннар килгәнчегә кадәр үк яшәгән. Никифорос Григорас (XIV гасырда яшәгән Византия тарихчысы), болгарлар «үзләренең чыгышлары белән скифлар булганнар», дип яза. Биредә Һун империясе барлыкка килү белән, алар шул империя составына керәләр, ә аннары берләштерелгән дәүләткә баш булалар. Соңрак аларның бер өлеше эстафетаны кабул иткән Хәзәр дәүләте составында яши. Болгария этнологы Христо Тодоров-Вемберски Кубрат хан дәүләте урынында «дуалистик Хәзәр-Болгар дәүләте оешкан» дип исәпли.

Хәзәр каһанлыгы. Көнчыгыш Европаның борынгы төрки дәүләте буларак, Хәзәр каһанлыгы тарихи яктан борынгы татар һәм борынгы рус дәүләтләренә якын тора. Хәзәрләр — һуннарга, болгарларга, бәҗәнәкләргә (печенегларга) кардәш булган төрки телле кабиләләр берләшмәсе алар. Тарихчы, галим М. И. Артамонов хәзәрләрне һун-болгарлар дип атый. Л. Н. Гумилев алар европеидлар булганнар дип бара. Хәзәрләр Түбән Идел буенда, Каспий диңгезенең төньяк-көнбатышында, Дон буйларында яшәгән. Һун дәүләте составына, соңрак Бөек Болгар дәүләте составына кергәннәр. Әнә шул вакыттан ук хәзәрләр VI гасырда оешкан һәм 740 елга кадәр яшәгән Көнбатыш Төрки каһанлыгы белән тыгыз бәйләнештә торганнар. Көнбатыш Азиянең бу борынгы төрки дәүләте (Көнбатыш Төрки каһанлыгы), Җидесудан (Семиречье) алып Арал диңгезенә кадәр сузылган (Харәземне дә кертеп) территорияне биләп, Көнчыгыш Европаның төрки дәүләтләре белән дә бәйләнеш урнаштырган.

Хәзәр каһанлыгы мөстәкыйль дәүләт буларак VII йөз урталарында оеша. Бу Көнбатыш Төрки каһанлыгының таркалу

вакыты була. Кубрат хан үлгәннән соң болгарларның бүлгәләнүеннән файдаланып, Көнбатышта хәзәрләр аларны хакимияттән кысрыклап чыгаралар һәм төбәктә греклар-римлыларның һәм һуннар-болгарларның дәүләт традицияләрен дәвам иттерүчеләр булып китәләр. Каһанның хакимлеге Түбән Иделгә, төньяк-көнбатыш Каспий буена, Дон һәм Азов диңгезе буйларына,Кара диңгез буеның төньягына, Кырымга (Византия составында калган Херсонесны кертмичә) тарала.

Хәзәр каһанлыгының Византия белән мөнәсәбәтләре катлаулы була. Табигый ки, Хәзәр каһанлыгы, Кара диңгез буе Болгар дәүләтенең варисы буларак, грек һәм римлыларның элекке шәһәрләрен үз дәүләте чикләрендә саклап кала. Бу хәл алар арасында каршылык тудырмый калмаган. Шул ук вакытта Византия хәзәрләрнең көньяк җирләргә дәгъва иткән варягларга каршы торуларын яклый. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Шаркил шәһәр-кальгасы IX гасырда Византия ярдәмендә нәкъ менә шул максатларда төзелә.

Илдә игенчелек алга киткән. Аның дала өлешендә көтүлекле терлекчелек үсә. Һөнәрчелек-сәнәгать традицияләре дәвам итә, шәһәрләр саны арта. Илнең башкаласы башта — төньяк Каспийның көнбатыш ярында урнашкан Сәмәндәр шәһәре, ә VIII гасырның уртасыннан түбәнге Иделдәге Итил шәһәре була. Бу чорда исламның Кавказ аша әлеге төбәккә үтеп керүе башлана. Дәүләт элитасын төрки-мөселманнар тәшкил итә. Илдә шулай ук иудаизм һәм христианлык киң таралган була. Каһанлыкта төрки тел дәүләт теле итеп санала (М. И. Артамонов). Армия нигездә төрки сугышчылардан тора.

Борынгы Татарстандагы элгәреге дәүләт оештырылмаларының тышкы бәйләнешләре. Борынгы Татарстанның элгәреге дәүләт оештырылмаларының (Биләр, Суар, Бортас, Кашан) Көнчыгыш Европадагы борынгы төрки дәүләтләр белән бәйләнешләрен барлык тарихчылар таный. Ләкин бу бәйләнешләр әлегә аз өйрәнелгән. Кайбер тарихчылар һуннарның Көнчыгыш Европага явы бу җирләргә төрки кабиләләрнең беренче вәкилләрен «китереп ташлаган» дигән фикердә тора (Н. И. Воробьев, 1967). Һәм болай раслау Идел-Уралдагы төрки телле этник нигезне бирегә VII—VIII гасырларда килеп урнашкан төрки телле болгарлар салган дип баручы «болгар теориясе» белән чагыштырганда алга таба бер адым итеп тәкъдим ителә.

Һуннарның көнбатышка таба хәрәкәтенең юлы ул вакытта Урта Иделдән көньяктарак ята. Ул Түбән Идел һәм Дон буеның далалы районнары аша уза. Ихтимал, борынгы Татарстандагы элгәреге дәүләт оештырылмалары территориясендә һуннарның аерылып чыккан бер өлеше генә утырып калгандыр һәм шуның белән төрки телле җирлекне көчәйткәндер. Җәмгыятьне дәүләт итеп оештыруга оста һуннар тәҗрибәсенең, үз чиратында, биредә дәүләтчелек башлангычларын ныгытуга уңай йогынты ясаган булуы да ихтимал.

Борынгы Татарстан территориясендәге элгәреге дәүләт оештырылмаларының Төрки каһанлыгы белән бәйләнешләре эзләре төсмерләнә. Шундый версия бар: 576 елда Теле кабиләсе башлыкларыннан берсе (Л. П. Потапов фикеренчә, Теле — Төньяк Казакъстанда төпләнеп калган һуннар нәселеннән) Кара Чура үзенең дружинасы белән Идел-Кама төбәгендә булып китә. Идел-Урал Көнбатыш Төрки каһанлыгының тарихта билгеле булган территориясе составына керми. Аның каравы, Себер татарлары турыдан-туры Көнчыгыш Төрки каһанлыгы составына керә. Беренче дәүләтчелек сабакларын алар әүвәлге Һун каһанлыгы составында, ә аннары Көнчыгыш Төрки каһанлыгы составында алалар. Бу каһанлык составына алар элгәреге дәүләт оештырылмасы сыйфатында керәләр. Төркиләрнең борынгы (732 ел) язма истәлегендә (Урхун-Енисей язуы — V гасыр) шаһзадә Күлтәгинне күмү йоласына килгән кабилә вәкилләре арасында «Токкуз татар», «Отуз татар» дигән кабиләләр вәкилләре дә телгә алына.

Урхун-Енисейдагы истәлекле өч таш плитәгә (ташларның беренчесе — Күлтәгин баһадур хөрмәтенә 732 елда, икенчесе — Билге каһан хөрмәтенә 735 елда, ә өченчесе өч каһанның киңәшчесе булган Тонйокук хөрмәтенә 734 елда куелган) чокып язылган. Төрки каһанлыгының тарихына багышланган бу шактый озын текстлар күренекле әдәби әсәрләргә тиң. Аларның күп кенә гыйбарәләре соңрак, 1907 елда Көнчыгыш Төркестанда Дуньхуан будда монастыре китапханәсендә табылган рун язулы кульязмаларда очрый. Х. Ш. Мәхмүтов фикеренчә, X гасырның икенче яртысындагы Дуньхуан истәлеген төрки мәкаль һәм әйтемнәренең беренче тапкыр кәгазьгә төшерелүләре дип әйтергә мөмкин. Х. Ш. Мәхмүтов бу мәкаль-әйтемнәрнең татар халык иҗатында, татар әдәбиятында күп төрле вариантларын таба һәм югарыда искә алынган Билге каһан Күлтәгинне җирләгәндә әйткән:

Күрер күзем күрмәстәй,
Акыл-зиһенем белмәстәй булды... —

дигән кайгы сүзләре шагыйрь Акмулланың (XIX гасыр):

Бәла килсә, күрер күз күрмәз улыр,
Каза килсә, аяклар йөрмәз улыр,—

шигъри юлларында яңача яңгыраш тапкандыр, дип фаразлый.

Борынгы татарларның Иделнең уңъяк ярындагы элгәреге дәүләт оештырылмалары, Кара диңгез буе Болгары составына кермәсәләр дә, аның көнчыгыш һәм төньяк провинцияләре — төньякта яшәгән бәҗәнәкләр, Дон буйларында төпләнеп калган һәм Кубанга күчеп урнашкан болгарлар белән, шулай ук һуннарның Кутригур кабиләсе нәселеннән булган котраглар белән янәшә яшәгәннәр. Бераз соңрак Кара диңгез буе болгарларының бер өлеше борынгы татар дәүләтен оештыруда турыдан-туры катнашкан.

Борынгы Татарстанның сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләре Хәзәр иле белән аерата көчле булган. Хәзәр иленең башкаласы Түбән Иделгә күчерелгәннән соң, бу мөнәсәбәтләр тагын да көчәйгән. Исламлаштырылган Хәзәр иле, ихтимал, исламның борынгы Татарстанга үтеп керүе юнәлешләренең берсе булгандыр. Бер үк вакытта биредә Хәзәр иленең сәяси йогынтысы да көчәя. Бу, каһанлыкның ярдәменә җавап рәвешендә, безнең төбәктәге дәүләт оештырылмаларының каһанлыкка ясак түләүләрендә чагылыш таба. IX—X гасырларда яшәгән гарәп географы һәм сәяхәтчесе Әл-Бәлхи әйтүенчә, бик зур бу ил (Хәзәр иле) составына Сәмәндәр, Суар, шулай ук Бәләнҗәр (Болгар), Хәмлиҗ, Бәйдә шәһәрләре кергән.

Кара диңгез буе болгарлары борынгы Татарстанда. Кара диңгез буе болгарларының борынгы Татарстан җирләренә күчеп утырулары VII—VIII гасырларга — Кара диңгез буе болгарлары дәүләтенең таркалуы һәм төбәктә хакимиятнең хәзәрләр кулына күчүе вакытына туры килә. Тарих бу чорда Кара диңгез буе болгарларының төрле тарафларга: Днепр-Буг буе болгарларының («Ак болгарлар» дип аталган Аспарух җитәкчелегендәге болгарлар) көнбатышка, Дунай буена, Дон буе болгарларының — өлешчә көньяк-көнчыгышка, Төньяк Кавказга («Кара болгарлар» дип аталганнары, бу аталыш, бәлки, аларның Кубан елгасының «Кара ермагы»

буена килеп урнашуларыннан алынгандыр), ә өлешчә төньяк-көнчыгышка, Идел-Кама буйларына күчеп китүләрен билгеләп үтә. Шулай да бу күченүләрнең сәбәбе тирәндәрәк ятарга тиеш һәм моны әле ачыклыйсы бар.

Болгар кабиләләренең Идел-Камага таба юнәлеш алган берләшмәләре, Идел аша чыгып һәм Кама тамагына җитеп, биредә игенчелек, терлекчелек, аучылык, балык тотучылык өчен бик тә уңайлы, тормыш итү өчен инде җайлаштырылган җирләргә тап булалар. Климат биредә салкынрак булса да, хуҗалык алып бару шартлары Дон буйларын, бигрәк тә елганың урта агымын һәм аның кушылдыклары булган Хопер, Бузулук, Медведица буйларын хәтерләтә. Мондый шартлар болгарларга алдан ук таныш булган, алар биредәге элгәреге дәүләт оештырылмасы җитәкчеләре белән алдан сөйләшеп куйганнар дип уйларга кирәк. Кайбер социаль факторлар да үз рольләрен уйнамый калмагандыр. Монда алар этник яктан үзләренә якын булган төрки телле кабиләләргә тап булганнар. Ислам дине факторын да искә алырга кирәк. Ул вакытларда инде ислам Дон буе болгарларына Төньяк Кавказ аша, ә борынгы Биләргә Хәзәр иле аша таныш була.

Идел-Кама буйларына килеп урнашкан Кара диңгез буе болгарлары биредәге элгәреге дәүләт оештырылмасы Биләрнең инде гамәлдә булган җирле системасын үзләштерәләр, зур үсеш алган сәүдә һәм товар алмашу системасына яраклашалар.

БОРЫНГЫ ТАТАР ДӘҮЛӘТЕ ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫНЫҢ ФОРМАЛАШУЫ

Беренче адымнар. Кара диңгез буе болгарларының Идел-Кама буйларына килеп урнашулары белән Идел-Уралда халыкның төрки этник составы көчәя. Әмма төбәкнең төрки, фин-угор характерында булуы саклана. Бу нигездә Идел-Уралда төрки телле этносның күпчелекне тәшкил итүе сакланган борынгы полиэтник дәүләт формалаша. Элгәреге дәүләт оештырылмалары арасында Болгар белән Биләр берләшүне иң актив яклаучылар булалар.

Җирле әмирлекләрнең сәяси берләшүдә яңа баскычка күтәрелүләрен ике төрле сәбәп билгели. Беренче сәбәп Хәзәр каһанлыгының көчсезләнүе булса, икенче мөһимрәк сәбәп җәмгыятьнең берләшкән дәүләт буларак оешуга өлгереп

җитүе һәм әмирлекләрнең үз араларыннан әйдәп баручы итеп Болгар белән Биләрне алга чыгаруларыннан гыйбарәт иде.

Берләшкән дәүләтнең беренче адымнары турында без хәзергә аз беләбез. Шунысы билгеле: бу адымнар IX гасыр уртасында ясала. Шиһабеддин Мәрҗани раслаганча, бу дәүләтнең беренче идарәчесе (әмире) Тукый хан була. Аңардан тыш бу ханның варислары санап кителә: Айдар хан, Зөбәер хан, Силки хан (IX гасырның азагы — X йөзнең башы). Болгар тарихчысы Шәрәфетдин әл-Мөслими үзенең «Тәварихе Болгария» дигән китабында әле Тукый ханның улы Айдар хан исән чакта Болгарга бер төркем ислам фәкыйһләре (миссионерлары) һәм табибларының килүе турында аңа билгеле булган риваятьне сөйли, әлеге табибларның хан кызы чибәр Туйбикәне хасталыктан терелтүләрен бәян итә. Иран тарихчысы һәм сәяхәтчесе Зәкәрия әл-Казвини үзенең «Асасел билед» («Илләр истәлеге») дигән китабында Болгар идарәчесе Зөбәер хан бине Айдар ханның исемен телгә ала. Борынгы татар дәүләтенең беренче чоры турында кайбер мәгълүматларны (IX гасыр) Ибне Рустә китабыннан һәм ул файдаланган чыганаклардан табарга мөмкин. Тарихка Идел буе Болгары булып кереп калган дәүләт формалашу күзлегеннән карaганда, Силки ханның улы Алмас ханның (Җәгъфәр бине Абдулланың) патшалык итүе чоры бик әһәмиятле.

Багдадка йөз тоту. Халыкара танылу теләсә кайсы дәүләт өчен бик мөһим фактор. Борынгы татар дәүләте бу уңайдан ул заманнардагы абруйлы ил Багдад хәлифәлегенә йөз тота.

Гарәп цивилизациясе — дөньяда иң борынгы цивилизацияләрнең берсе. Б. э. кадәр X—II гасырларда Гарәбстан ярымутравының көньягында Миней дәүләте һәм Сабей дәүләтенең булуы билгеле. Б. э. кадәр II гасырдан алып безнең эраның VI гасырына кадәр Химьяритлар дәүләте яши. Бу гасырлардагы бай гарәп мәдәнияте, гадәттә, исламга кадәрге мәдәният дип йөртелә. Ул вакытлардагы гарәпләрнең тормышы бәдәвиләр (күчмә гарәпләр) шигъриятендә аеруча матур тасвирлана.

Борынгы татар дәүләте оешкан чорда гарәп цивилизациясендә инде ислам ныгып урнашкан була, ә VII гасыр башында оешкан Гарәп хәлифәлеге (дәүләте) үсеп бара торган иң абруйлы империя була. Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәштәшләреннән берсе булган Әбү Бәкер (572—634) 632 елдан беренче

хәлифә (дәүләт башлыгының титулы) булып китә, ә ил Билед әл-Ислам (ислам иле), «Мәмләкәт әл-Хәлиф» («Хәлифәләр мәмләкәте») дип атала. X гасырның башыннан алып Багдад хәлифәлеген Габбасилар (Мөхәммәд пәйгамбәрнең агасы) династиясеннән булган Җәгъфәр әл-Моктәдир идарә итә. Ул вакытта инде Багдад хакимиятен Иран, Азәрбайҗан, Саманилар дәүләте (Бохара), Харәзем (Җурҗания) таныганнар. VIII гасырда күп кенә илләрдә ислам зороастр динен алыштыра.

Болгар — Багдад мөнәсәбәтләре. Болгар—Багдад мөнәсәбәтләренең әүвәлге чоры турындагы мәгълүматлар гарәп тарихчысы һәм сәяхәтчесе, Иранда, Һиндстанда, Азәрбайҗанда булып кайткан Әл-Мәсгуди хезмәтләрендә сакланган. Шушы мәгълүматлар сөйләвенчә, Болгар идарәчесе Алмас бине Силки үз илчесен Абдулла бине Баштуны 921 елның язында Багдадка җибәрә. Соңгысы үз идарәчесенең хатын Моктәдир хәлифәгә илтеп тапшыра. Хатта Болгарга ислам диненә өндәүчеләр җибәрү һәм дарулар юллау, шулай ук Болгарда мәчет салуда, кальга төзүдә ярдәм итү турында үтенеч була. Әл-Мәсгуди үзеннән өстәп ул чакта Алмас хан сараенда хезмәт иткән Баштуның чыгышы белән Харәземнән булуы һәм шуңа күрә Хазәри дигән кушамат йөртүе турында яза. Әлеге Баштуның мөселман икәнлеген, Болгар белән Багдад арасында дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштыруда катнашы булуын гына түгел, шундый ук максат белән Харәзем һәм Хәзәр иленә дә килеп чыгуын да бәян итәргә мөмкин. Әл-Мәсгудинең сүзләренә караганда, хәлифә сараенда чыгышлары белән Болгардан булган А. Текин һәм Барыс хезмәт иткәннәр. Димәк, Болгар белән Багдад арасында дипломатик мөнәсәбәтләр элек үк урнаштырылган, һәм Баштуның миссиясе беренчеләрдән булмаган. Өстәвенә Багдадта Ибне Рөшд (XII гасыр) һәм кайбер башка гарәп авторларының китаплары буенча Болгар турында хәбәрдар булганнар.

Болгар белән Багдад арасындагы бәйләнешләр ул вакытта Харәзем, Бохара һәм Иран кәрван сәүдә юллары аша алып барылган. Ә Харәзем, Бохара, Иран белән дәүләтара мөнәсәбәтләрне Болгар моңа кадәр үк урнаштырган булган инде. Дөресрәге, бу мөнәсәбәтләр Биләр, Суар һәм Идел-Кама буендагы башка шәһәрләрнең традицион сәүдә мөнәсәбәтләре буларак дәвам иткән. Бу дәүләтләрнең икесе — Харәзем һәм Бохара — төрки телле дәүләтләр була (гәрчә аларда дәүләт теле булып фарсы теле саналса да).

Фактта периферия дә контролен югалтып та, хакимиятне югалтырга теләмәгән Хәзәр каһанлыгы белән Болгар дәүләте арасындагы мөнәсәбәтләр катлаулырак булгандыр дип уйларга кирәк. Баштагы елларда, Болгар белән Хәзәр каһанлыгы арасындагы мөнәсәбәтләрнең искечә калуын раслап, Болгар идарәчесе (илтабары) үз улын Итил шәһәрендә яшәткән.

Ислам динен кабул итүнең алшартлары. Татарларның борынгы дәүләте Болгарның оешуы элгәреге дәүләт оештырылмаларының хокукый һәм идеологик традицияләре, ягъни ыруг-кабилә һәм община хокукы җирлегендә, төньяк төркиләрнең мәҗүси диннәренең әхлак нормалары җирлегендә бара. Хәлбуки үзәкләштерелгән дәүләтне ныгыту өчен дәүләт диненең яңа хокукый һәм әхлакый нормалары таләп итеүлә. Бу бурыч Алмас хан идарәсе вакытында ислам кабул итеүлү белән үтәлә.

Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү билгеле сәбәпләр белән бәйләнгән. Чагыштырмача яшь дин ислам яңа шартлар өчен кулайрак булган. Ул үзендә кешенең шәхси, иҗтимагый һәм дәүләти тормышының барлык якларын да туплый алган. Ж.-Ж. Руссо «Иҗтимагый шартнамә» хезмәтендә болай дип яза: «Мөхәммәднең карашлары бик аек: ул бөтен сәяси системаны бергә бәйли». Чыннан да, ислам яклый торган дәүләт системасы дәүләти-хокукый, дини-идеологик һәм рухи-әхлакый принципларның бердәмлеген тәэмин итә, югары хакимият кануннарының яисә дини-идеологик догматларның берьяклы гына өстенлек алуына юл куймый.

Фән, мәгърифәт, мәдәният белән тыгыз бәйләнгән исламның күркәм яклары турында сөйләп, инглиз тарихчысы А. Д. Тойнби, иудаизмнан үзгә буларак ислам эллинизмның антиподы булмады, дип билгеләп үтә. Гарәп философы һәм табибы Ибне Рөшднең (Аверроэс, 1126—1198) күренекле философ, аристотельче булып китүе дә очраклы түгел. Динне белем чыганагы итеп танып, Ибне Рөшд, шул ук вакытта, белемнәрнең рациональ (фәнни) чыганагын да югары бәяли.

Галимнәр шулай ук исламның көндәлек тормыштагы кыйммәтләргә өндәвен дә билгеләп үтәләр. Мәсәлән, Гердер, исламның кеше гигиенасы, чисталык турындагы таләпләренә сокланып, болай дип яза: ислам халыкларының «матур булуына Коръән кушкан нәрсәләр дә булышлык итә, чөнки Коръән юынырга, тәнне пакь тотарга, чама белүгә өнди һәм

шул ук вакытта сөешү-яратышуга, дәрт-ләззәткә юл куя». Фәнни әдәбиятта исламның шәхси, җәмгыяви, сәяси тормышта зур әһәмияткә ия булган түземлек-сабырлыкка өндәү кебек мөһим сыйфаты билгеләп үтелә.

Исламны кабул итү өчен кирәкле алшартлар илнең үз эчендә дә өлгереп җиткән. Исламны рәсми төстә кабул итү вакытына илдә гарәп-ислам системасындагы мәктәпләр, мәчетләр, табиблар инде эшли башлаган булган.

Багдад вәкиллегенең Болгарга килүе. Багдад вәкиллегенең дипломатик максатларда Болгарга килүе көннәрендә рәсми төстә ислам дине кабул ителә. Бу вәкиллек дәүләт эшеннән башка, дини вазифа да башкара. Болар турында илчелекнең сәркатибе, төрки телләрне яхшы белгән, бай дипломатик тәҗрибәсе булган, илләр гизгән Ибне Фадлан бәйнә-бәйнә язып калдыра. Аның Итил буйларына бару һәм Болгарның ислам динен кабул итүе турындагы сәяхәтнамәсе безнең көннәргә кадәр сакланып калган.

Мөселман кешесе һәм исламга өндәүче буларак, Ибне Фадлан исламча яшәү рәвеше турында сокланып яза, төньяк төрки кабиләләрнең мәҗүсилектән килгән яшәү рәвешләрендәге күп кенә традицияләренә үзенең тискәре карашын ачыктан-ачык белдерә. Бу китап безнең өчен тарихи чыганак буларак аеруча мөһим. Вәкиллек 922 елның язында гадәти кәрван юлы белән Иран, Бохара, Харәзем аша килә. Алмас хан үзенең сараенда хатыны һәм күп санлы дәүләт эшлеклеләре катнашында югары илчелек хөрмәтенә олы мәҗлес үткәрә. Мәҗлестә Багдад хәлифәсе Әл-Моктәдирнең Болгар җәмгыятендә ислам динен кабул итү теләген хуплаган хаты укыла. Алмас хан, үз чиратында, дәүләтенең ислам дөньясына кушылуы һәм рәсми дәүләт дине сыйфатында ислам (әл-Иман) кабул ителүе турында тантаналы төстә игълан итә. Вәгъдә ителгән ярдәме өчен хәлифәгә рәхмәт белдерә. Аннары, Болгарның төрле якларына барып, исламны рәсми төстә кабул итү уздырыла. Халык катнашында тантаналы төстә үткәрелгән бу чара 922 елның (һиҗри белән 310 ел) 16 маенда була. Ләкин әлеге рәсми тантаналар бөтен халык берьюлы мәҗүсилектән ислам диненә күчкән дигән сүз түгел. Бу бигрәк тә читтәрәк урнашкан төбәкләрдә, аерым алганда, чувашлар, аерата фин-угор кабиләләре яшәгән җирләрдә шулай була. Соңгыларында исламны кабул итүчеләр азрак күзәтелә.

Борынгы Татарстанда сөнниләр юнәлешендәге ислам дине кабул ителә. Бу юнәлештәге мөселманнар, шигыйләрдән аермалы буларак, Әбү Бәкернең (Мөхәммәд пәйгамбәрдән соңгы беренче хәлифә) Мөхәммәд пәйгамбәргә тугрылык турындагы антын нигезле саныйлар. Шигыйләр исә бу антны урынсыз дип табалар һәм Гали бине Әбү Талибны (Мөхәммәднең киявен) пәйгамбәрнең бердәнбер варисы дип игълан итәләр.

Шушы вакыттан алып Болгар халкын «Әһле әс-сөннә вә әл-җәмәга» («Сөнни җәмәга (өммәт) тарафдарлары» дип, яки «сөнни мөселманнар») дип атый башлыйлар.

Идел Болгарында иҗтимагый тормыш. Ислам кабул ителү белән Болгарның йола буенча килгән хокук нормаларына, җирле этно-кабилә тормышы традицияләренә нигезләнгән иҗтимагый тормышы исламча яшәү рәвешенә, ягъни шәригатькә йөз тота башлый. Шәригать (әш-шари'а — канун, боерык, күрсәтмә) — мөселманнарның карашларын билгелүче, аларның әхлакый кыйммәтләрен һәм дини вөҗданын формалаштыручы, Коръән һәм Сөннәгә нигезләнгән күрсәтмәләр җыелмасы. Мөселманнар шәригать кагыйдәләренә таяналар.

Шул ук вакытта ил халкының борынгы хокукый аңы, илнең элеккеге этно-кабилә яшәү рәвешеннән килә торган хокукый нормалары һәм традицияләре юкка чыкмый, алар шәригать белән янәшә яшәүче гореф-гадәтләр буларак саклана. Гореф-гадәтләр җирле хокукый тормыш чынбарлыгын чагылдыра, ягъни исламны кабул иткәннән соң да үтәлә торган хокук һәм әхлак нормалары җыелмасын тәшкил итә. Нәтиҗәдә ислам шул җирлектә Болгар җәмгыяте чынбарлыгын чагылдырып формалаша.

Дәүләт төзелеше. Х гасырдан төрки болгарларның борынгы үзәкләштерелгән дәүләте оешу ислам дәүләт хокукы — әл-Фикыһка йөз тоткан хәлдә бара. Фикыһ (ислам хокук нигезләре, юриспруденция), гомумән, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне билгеләү белән бергә дәүләти хокук сыйфатында да эш итә. Хәлифәлекнең оешуы барышында гомумән ислам хокук системасы, аерым алганда дәүләт хокукы, Рим хокукының, Сасанилар, Талмуд, Византия хокукларының аерым элементларын үз эченә ала. Бу системаны галимнәр югары бәяли. Тойнби, мәсәлән, исламда канун һәм яңарыш (гадәт һәм шәригать) юлын үткән хокук мәктәбе формалашты дип исәпли. Ислам хокукы буенча дәүләт — җәмгыять өчен зарури нәрсә: «Хәтта гадел булмаган хакимият тә анархиягә караганда

кулайрак». Идарәченең хакимияте абсолют түгел. Иң югары хакимият — бары тик Алла кулында. Идарәче үзенең эшгамәлләрендә Коръән һәм Сөннә күрсәтмәләрен куллана. Дәүләтне идарә итү Шура (Совет) кебек орган аша консультатив тәртиптә алып барыла. Идарәче өммәт (община) тарафыннан сайлана һәм аның каршында җавап тота, иң мөһим дәүләт мәсьәләләре буенча аның белән киңәшләшергә тиеш була. Менә шундый идарәче генә, мондый күрсәтмәләрне боза торган идарәчеләрдән аермалы буларак, гадел санала.

Ибне Фадлан билгеләп үткәнчә, ислам динен кабул иткәннән соң ук, Алмас хан шәригать һәм әл-Фикыһ нормаларын тормышка ашыра башлый. Мөгаен, үзәкләштерелгән дәүләт ныгу белән, «идарәче» мәгънәсендә кулланылып килгән «илтабар» сүзе хәзәр телендәге «хакан» сүзеннән үзгәртеп алынган «хан» сүзе белән алмаштырыла. Шиһабеддин Мәрҗани, мәсәлән, Болгар илендә X гасырда идарә иткән ханнарны санап үтә: Әхмәд хан, Талиб хан, Мөэмин хан...

X гасырда, алар патшалык иткән елларда, Идел буе Болгары нык үскән идарә системасы булган һәм күп кенә чит дәүләтләр таныган суверен дәүләт буларак ныгый. Болгарда һиҗри белән 338 (949) елда Талиб хан исеме төшереп сугылган, һиҗри белән 366 (979) елда Мөэмин хан исеме төшереп сугылган тәңкәләр (акча) сакланып калган. Милади белән 985—986 елларда Идел буе Болгары белән Киев Русе арасында «таш суда йөзеп йөри, ә колмак бата башлаганга кадәр» тынычлык саклау турында дәүләтара шартнамә төзелә. Бу шартнамә бөек кенәз Изге Владимирның Болгар ханы кызына өйләнүе белән беркетелә.

Хан дәүләт башлыгы була. Ул конституцион башлангыч булып хезмәт иткән Коръән нигезләмәләренә таянып эш итә. Ханлык нәселдән нәселгә күчә. Дәүләттә ислам ныгый барган саен, иң югары хокукый авторитет булган хан тарафыннан билгеләнә торган *баш казый* дәрәҗәле, абруйлы чиновник сыйфатында алга чыга. Казый урыннардагы хөкемдарларның (казыйларның) эшчәнлеген күзәтеп-тикшереп тора. Шәригать һәм Фикыһны яхшы белгәнгә, ханның аны үзенең киңәшчесе итеп тә куюы мөмкин. Ә консультатив орган ролен хәрби-административ аксөякләр, руханилар, мөстәкыйль хуҗалык алып баручы башка гражданнар (сәүдәгәрләр, һөнәр ияләре, крестьяннар) катнашындагы съезд — Җыен үти. Хан тарафыннан чакырыла торган Җыен әһәмиятле дәүләт

мәсьәләләрен (сугыш игълан итү, солых төзү, яңа династия сайлау һ. б.) хәл итә.

Хөкүмәтне *баш вәзир* җитәкли. Аның аерым тармаклар буенча ярдәмчеләре — *наибләре* була. Гаскәр ханның даими гвардиясеннән (*хуан*) һәм илне саклау яисә чит илләргә яу чабу өчен кирәкле булганда җыела торган ополчениедән (*сарья*) тора.

Дәүләт идарәсенең иң түбәнге буынын халык сайлап куйган авыл башлыклары һәм мәхәллә (шәһәрләрдә) башлыклары тәшкил итә. Шулай итеп, кабиләләр демократиясе нигезендә идарә итү формасы дәүләти идарә ысулына үсеп әверелә. Үзәкләшкән хан идарәсе Җыен демократиясе һәм авыллар демократиясе белән кушыла. Хәрби стратегик һәм сәүдә-икътисади яктан отышлы урында урнашкан Болгар шәһәре илнең башкаласы булып китә.

Территориясе. Хан хакимияте астында булган территория баштарак әллә ни зур булмый. Берләшкән әмирлекләрнең ханга буйсыну дәрәҗәләре дә төрле була. Ибне Фадлан үз делегациясен кабул итү мәҗлесендә дүрт әмирлек башлыгының катнашуы турында яза. Бәлки, монда сүз дәүләтнең үзәк зонасы: Болгар, Биләр, Суар, Бортас турында гына барадыр. Хәер, бу дәүләт оештырылмалары гомуми бер дәүләт булып берләшүләре турында игълан итеп тә, эчке эшләрендә озак вакытлар үзләренең мөстәкыйльлекләрен саклаганнар. 70—80 нче елларда, мәсәлән, Болгарда Әхмәд хан улы Мөэмин идарә иткәндә Суарда шул ук Әхмәд ханның ир туганы, Хәсән ханның улы Мөэмин хан, зур автономиядән файдаланып, иркен ханлык итә. Безгә X гасырның 70—80 нче еллары азагына кадәр Суарда үз акчалары сугылганлыгы мәгълүм. Әйтеп үтелгән әмирлекләрнең үзәкләштерелгән дәүләт булып берләшүләре бары тик X гасырның икенче яртысында гына тәгәлләнә. XI гасырның башларына таба, мөгаен, үзәкләштерелгән дәүләткә буйсынучы территория бөтен борынгы Татарстанны, Иделнең уңъяк ярындагы әмирлекләрне (мәсәлән, Ашлыны), Каманың уңъяк ярындагы әмирлекләрне (мәсәлән, Кашанны), өлешчә мордва, чуваш, мари һәм удмурт кенәзлекләрен, Көнбатыш Башкортстанны эченә алган. Шул ук вакытта үзәкләштерелгән хакимиятне таныган территорияләрнең чикләре билгеләнә: көньякта — Самара борылышы (Самарская лука), Җаек елгасы; көнчыгышта — Ык елгасы, өлешчә Агыйдел; төньякта — Чепца елгасы; көнбатышта —

Сура елгасы. Ул заманнарда, әлбәттә, бүгенге мәгънәсендә дәүләт чикләре булмаган. Әле генә әйтелгәннәр — схематик сызгалаулар гына.

Көнчыгыш авторлары Идел буе Болгарында X гасырда ук инде кирмәннәр (кальгалар) булуын билгеләп үтәләр. Аерым алганда Әл-Казвини үзенең «Борынгы заман хәрабәләре һәм халыклар турында хәбәрләр» дигән китабында, Ягъкуб бине Ногманның «Болгар тарихы»на таянып, шундый ике кирмәнне (Шушит һәм Ватер-Бурун) искә алып үтә. Хәзергә ул кирмәннәрнең кайда булганлыкларын ачыклавы кыен. Бәлки, бу Алмас ханның Ибне Фадланга дошманнардан саклану өчен кирмәннәр төзергә ниятләве турында хәбәр итүе белән аңлатыладыр.

Халкы. Дәүләтнең оешуы дәүләт хакимиятенең формалашуы, бу дәүләт территориясенең билгеле бер чикләрдә урнашуы һәм бу территориядә урнашкан элгәреге дәүләт оештырылмаларының (протодәүләтләрнең) инде формалашкан хакимият тирәсенә оешулары һәм хакимиятне танулары белән бәйләнгән. Дәүләт булып берләшкән кешеләр төркемен, «кабилә»дән, «кабилә берлеге»ннән аермалы буларак, гадәттә «халык» дип атыйлар. Әлеге халыкның тора-бара үз атамасы, үз этнонимы, ә дәүләтнең үз политонимы барлыкка килә. Территория, гадәттә, чагыштырмача даими булган урын, җир — ил буларак кабул ителә. Безнең очракта кулланышка түбәндәге төшенчәләр керә: ил — Идел Болгары; дәүләт — Болгар (башкаласы Болгар атамасыннан). Халыкны ике этнос тәшкил итә: төньяк төркиләр һәм Идел-Урал фин-угорлары. Төньяк төркиләр этносы үзен Идел буе Болгарында «болгар» дип таный, ягъни шушы этнонимны кабул иткән була.

Дәүләт шартларында җәмгыятьнең социаль бүленеше беразүзгәрәк формалаша. Ибне Фадлан Болгар иле халкының өч төркемгә бүленүен күргән: затлылар, аксөякләр; ирекле гади халык; ирексез халык (коллар),— гадәттә, сугышта әсир ителеп кулга төшерелгәннәр. «Ирекле гади халык» — игенче крестьяннар, терлек асраучылар, община булып яшәгән һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр — халыкның күпчелеген тәшкил иткән. Бәйле (ирексез) кешеләр, кайчак голям (коллар) дип аталучылар, югары дәүләт түрәләренең хосусый хуҗалыкларында эшләгән, аларга мөһим дәүләт йомышлары да кушылган. Кайбер коллар өлешчә тышкы базарга чыгарылган. Борынгы Иран шагыйре Насыйр Хөсрәүнең мондый шигъри юллары бар:

Болгардан килгән
Кол кызлар күреп,
Халык таң калды.
Төрки гүзәлләр
Күз явын алды:

Сылу гәүдәләр
Ай, кояш йөзле,
Иреннәр якут,
Тешләре энҗе.

Ислам дине руханилары һәм укытучы-мөгаллимнәр, табиблар, фән һәм сәнгать эшлеклеләре Болгар дәүләтенең зыялылары рәтенә керә. Затлылар (рәисләр) арасында ыруг һәм кабилә башлыклары даирәсеннән чыккан наибләр дәрәҗәсендәге дәүләт чиновниклары, шулай ук дипломатлар, җирле әмирләр администрациясендә эшләүче кешеләр, хан гвардиясе һәм җирле әмир гаскәре әгъзаларыннан торучы хәрби катлау белән тулыландырылып торган югары дәүләт хезмәткәрләре бар.

Этник планда да халыкның составы катлаулы, чуар була. Дәүләтнең көнбатыш һәм үзәк өлешләрен төркиләр — чуваш, татар, башкортларның борынгы бабалары биләп торган, ә читтәрәк төбәкләрдә фин-угорлар — мордва, мари һәм удмуртларның бабалары яшәгән. Ул вакытта Болгарда әле руслар аз була. Булсалар да, аларны, нигездә, сәүдәгәрләр, аларның хезмәтчеләре, шулай ук, заманында әсир төшеп, я хосусый хуҗалыкларда ялчы хәлендә яисә иреклe һөнәрчеләр, башлыча тимерчеләр хәлендә булган кешеләр тәшкил итә.

Хуҗалыгы. Җир, шул исәптән сөрү җирләре, көтүлекләр, урман, болын, елгалар илнең төп байлыгын тәшкил итә. Шәригать буенча, Җир — Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә биргән бүләге, ягъни җәмгать байлыгы. Җир хан кулында була. Ул аны дәүләт алдындагы хезмәтләре өчен морзаларга һәм хан гаскәре башында торучы угланнарга, шулай ук ирекле крестьяннарга бүләк итеп бирә. Крестьяннар җирне гомерләре буе били, мирас итеп калдыра. Җирнең шактый өлеше сарай кешеләре, җирле әмирләр кулында кала.

Сөрүле игенчелек авыл хуҗалыгының төп тармагы була. Җир металл төрәнле сабан белән тирән итеп сөрелә. Игенчелектә төп культуралардан бодай, арыш, арпа, тары игелә. Ил үзен икмәк белән тулысынча тәэмин итә, өстәвенә чит илләргә дә чыгара. Терлекчелек авыл хуҗалыгының мөстәкыйль тармагы санала. Болгарда ат, сыер, сарык, кәҗә, кошкорт асрыйлар. Атлар транспорт чарасы буларак, шул исәптән

гаскәрдә хезмәт итү, физик көч өчен файдалану һәм, өлешчә, азык буларак куллану максатларында үрчетелә.

Чолыкчылык (кыргый бал кортларының балын җыю), сунарчылык, балык тоту, урманчылык кебек кәсепләр хуҗалыкта ярдәмче тармак булалар. Үзәкләштерелгән дәүләт һөнәрчелекне үстерү турында нык кайгырта. Һөнәрчелек, гадәттә, шәһәрләрдә зур үсеш ала. Бу заманнар өчен шактый зур саналган шәһәрләр хакимият үзәкләре, әмирлекләрнең үзәкләре, сәүдә, һөнәрчелек һәм мәдәният үзәкләре буларак үсә. Ибне Фадлан Болгар шәһәрендә X гасыр башында 10 мең кеше яшәгәнлеген билгеләп үтә. Уртача зурлыктагы һәм кече шәһәрләр җирле һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре буларак үсә. Зөя елгасының үрге агымындагы Шондык, шул ук елганың түбәнге агымындагы Янтык, Самара елгасыннан төньяктарак урнашкан Кондызча әнә шундыйларга керә. Бу шәһәрләрдә яшәүчеләр, нигездә, һөнәрчеләргә һәм сәүдәгәрләргә хезмәт күрсәтүгә йөз тотканнар. Алар арасында кәрвансарайлар һәм торак йортлар, ярдәмче биналар, сәүдә рәтләре төзүчеләр, тимерчеләр һәм балта осталары, хезмәтчеләр булган. Хакимият органнары бу шәһәрләрнең шактый зур табыш китерә торган сәүдә һәм һөнәрчелек үсешенә химая иткәннәр.

Җирле чималдан һәм Уралдан китертелгән рудадан тимер эретү, металл эшкәртү промыселлары аеруча зур үсеш алган. Вазифалары һәм эшкәртүнең катлаулылыгы дәрәҗәсе буенча тимерчелекләр күптөрле булган: авыл хуҗалыгы кирәк-яраклары, корал һәм көнкүреш әйберләре (йозаклар, чылбырлар, кайчылар һ. б.) җитештерү. Бронза металлургиясе нык үскән, бакыр казаннар, комганнар, эретеп ясала торган бакыр көзгеләр, бизәнү әйберләре җитештергәннәр. Күн эшкәртүдә, керамик әйберләр, көнкүреш кирәк-яраклары, агачтан балалар уенчыклары ясауда, туку эшендә зур осталыкка ирешелгән.

Сәүдә. Тышкы һәм эчке сәүдә үсеше, шәһәрләр челтәренең куелыгы — теләсә кайсы борынгы цивилизациянең чәчәк атуын чагылдыручы күрсәткеч. Бу — борынгы Татарстан өчен дә хас күренеш. Үзәкләштерелгән дәүләт булып берләшү илнең төрле төбәкләре арасында сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләрен киңәйтә. Һөнәрчелек товарлары җитештерүнең артуы һәм эчке базарның жанлануы тышкы сәүдәнең киңәюенә этәргеч була. Болгар шәһәреннән ерак түгел, үзенең порт корылмалары һәм кәрвансарае белән турыдан-туры Иделгә

чыга торган Ага-Базар сәүдә үзәге төзелә. Бирегә ил эчендә таратыласы товарлар да, чит илләргә китә торганнары да агыла. Чит ил кунаклары (сәүдәгәрләре) бирегә башлыча Идел буйлап килә: төньяктан — Весь, Муром, Вятка төбәкләреннән; көньяктан — Харәзем, Бохара, Ираннан һ. б. Транзит белән килә торган көньяк һәм төньяк товарлары (кыйммәтле мехлар, ефәк, кораллар һ. б.) белән беррәттән, Ага-Базар аша экспортка Болгар илендә җитештерелгән товарлар да: күн һәм күннән эшләнгән товарлар, корал (кылыч һәм уклар), хәрби кием-салым, ашлык, терлек, агач, бизәнү әйберләре һ. б. агыла. Ибне Фадлан бигрәк тә читкә чыгарыла торган «сусар тиреләре»н югары бәяли. «Аларда металл акчаны сусар тиресе алмаштыра»,— дип яза ул. Җәнлек тиреләре арасында шулай ук кеш, ас мехы, кондыз тиресе, камчат мехы, тиен, төлке, куян тиреләре югары бәяләнә. Тышкы базарда шулай ук бал һәм балавыз, агач материаллары, бал эчемлеге һ. б. дан тота. XI гасырда яшәгән атаклы төрки филологы Мәхмүд Кашгарый үзенең «Диване лөгатет-төрк» («Төрки телләр җыентыгы») дигән китабында суарлыларныкы дип мондый юллар китерә:

> Килә шайтан, кулында бал — балламакчы,
> Ефәккә киендергән булып — алдамакчы.

Тышкы дөнья белән һәм ил эчендәге сәүдә-икътисади бәйләнешләрнең алга китүенә, күп яктан, илдә акча системасының үсүе этәргеч була. Хәзерге нумизматика коллекцияләрендә 908—910 елларда Идел буе Болгарында сугылган һәм, 949 елда сугылып, Болгар ханы Талиб хан исеме төшерелгән тәңкәләр, 977 елда Мөэмин хан исеме төшерелеп сугылган тәңкәләр бар. X гасырга караган археологик катламнарда табылган тәңкәләр борынгы Болгарның чит илләр белән сәүдә элемтәләре турында сөйли. Алар арасында XI йөзгә кадәр Чехиядә сугылган тәңкә, X гасырның чама белән беренче чирегендә сугылган гарәп дирһәме бар.

Тулаем ил эчендә салым системасы тотрыклана бара. Гошер (кеше керменең уннан бер өлеше күләмендә), зәкят (бар керемнең ярлылар һәм дин файдасына бирелә торган кырыктан бер өлеше күләмендә) кебек төп салымнар кертелә. Болардан тыш җир, ямчылык, юл һәм башка салымнар да була.

Рухи тормыш. X гасыр дәвамында борынгы татар дәүләтенең аякка басуы һәм илдә исламның ныгып китүе барышын-

да җәмгыятьнең рухи тормышы үсешенең төп юнәлешләре билгеләнә. Җәмгыятьнең рухи тормышында төньяк төрки кабиләләрнең исламга кадәр булган табынуларыннан мирас итеп алынган кыйммәтләр, ягъни традицион катлам нигездә сакланып кала. Яңа, ислам катламы җәмгыятьнең рухи тормышына акрынлап һәм, әйтергә мөмкин, икегә бүленеп керә. Ислам кыйммәтләренең беренче башлап үтеп керүе исламның рәсми төстә кабул ителүенә кадәрге булган чорга туры килә. Ибне Рустә 913 елга кадәр үк, Әл-Бәлхи 921—922 елларда, Болгарны һәм Суарны тасвирлап, биредә мәчетләр һәм мөселман руханилары булуын, кешеләрне дәвалауның җайга салынганлыгын, димәк, табибларның да шактый икәнлеген билгеләп үтәләр. Ибне Фадлан да шуны ук раслый. Ислам бирегә, башлыча, бу динне элегрәк кабул иткән һәм аның кайбер йолаларын «төркиләштерү» тәҗрибәсен туплап өлгергән күрше ислам дәүләтләре — төрки телле Хәзәр каһанлыгы, Харәзем, Бохара аша үтеп кергән. Төркиләндерү, мәсәлән, дога Коръән телендә укылып беткәннән соң, вәгазьнең төрки телдә укылуында чагылган. Көндәлек тормышта, аерым алганда гаилә тормышында, ислам йолалары традицион йолаларга каршы килмәгән, алар арасында каршылык чыкмаган. Шуңа күрә исламны рәсми төстә кабул итү, ислам кушканнарны рәсмиләштерү инде әзерлекле нигездә бара. Шуның өчен дә борынгы Татарстанда урнаша башлаган исламча яшәү рәвеше Багдадныкына да, башка бер ислам иленекенә дә охшамаган, аларны кабатламаган, җирле традицияләр элементлары белән үрелеп яшәгән.

Һәр яңалык кебек үк ислам да башка илләрдәге сыман, шул исәптән Гарәбстанның үзендәге сыман ук, юлны каршылыксыз, тетрәүләрсез генә сала алмый. Халык арасында исламга каршылык та туа. Бу, башлыча, аны кертүдә көч кулланганда күзәтелә. Мәсьәләгә объектив якын килеп, шуны әйтергә кирәк: яңа дәүләт оешу шартларында җәмгыять тә, дәүләт тә яңа дингә мохтаҗ булалар. Хәлбуки ислам бер үк вакытта әл-Иманны да (Аллаһының хаклыгына ышану), әл-Ихсанны да (рухи гаделлек) чагылдыра, кешелеклелеккә һәм гаделлеккә нигезләнгән әхлакый кыйммәтләрнең кешеләр өчен аңлаешлы, ышандырырлык системасын булдыра. Ислам тыйган нәрсәләр кеше табигатенә хас үз-үзеңне чикләү сыйфатына туры килә, һәм кеше аларны шулай булырга тиешле нәрсә итеп кабул итә.

Идел-Урал борынгы цивилизацияләр системасында



Мәдәният. Ислам кабул итү, ислам дөньясы илләре, аларның мәдәниятләре белән танышу Болгар мәдәниятенең үсеш мөмкинлеген киңәйтә. Фарсы һәм гарәп теле зыялылар, югары дәүләт эшлеклеләре арасында болгарларның үз телләре белән янәшә кулланылучы телләргә әвереләләр. Мәчетләр салу тизләтелә, ә алар каршында мәдрәсәләр ачыла. Дәүләт теле итеп кабул ителгән борынгы болгар теле гарәп графикасы нигезендә үз имлясын булдыра.

Бу чорда иранлылар гына түгел, Бохара, Харәзем, Болгар кебек төрки илләрнең дин һәм фән әһелләре үз әсәрләрен гомуми тел ролен уйнаган гарәп телендә язалар. Гарәп телендә иҗат иткән һәм әсәрләре латин теленә тәрҗемә ителеп, Көнбатыш мәдәниятен баеткан олуг төрки зыялыларыннан Харәземдә яшәүче Мөхәммәд әл-Харәзми (787 — чама белән 850), Әбү Райхан Бируни (973—1048), Бохарадан Әбү Гали ибне Сина (980—1037) исемнәрен әйтеп үтү бик урынлы булыр. Хәзергә тулы булмаган мәгълүматларга таянып, Болгардан бу рәттә Ягъкуб бине Ногман (XII гасыр) һәм Хәмид бине Идриси (XII гасыр) исемнәрен атарга мөмкин.

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫ XI – XV ГАСЫРЛАРДА

ИҖТИМАГЫЙ СТРОЙНЫҢ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕНЕҢ НЫГУЫ

Дәүләти берләшү. XI гасыр башларына таба Идел буе Болгарында яңа сәяси вазгыять күзәтелә. X гасыр азагына кадәр биредә дәүләтнең берләшүе аның составына кергән әмирлекләр арасындагы шартнамәләргә нигезләнә. Ә әмирлекләр үзләре асылда мөстәкыйль булып кала бирәләр, кайчак хәтта акчага кадәр үзләре суга. XI гасырның башларында, Хәйдәр хан заманында, вазгыять үзгәрә. Дәүләтне үзәкләштерү башлана.

Дәүләтнең үзәк өлешен, элеккечә үк, Каманың сулъяк ярына урнашкан Биләр, Болгар, Суар әмирлекләре, Иделнең уңъяк ярындагы Ашлы әмирлеге тәшкил итә. Идел буенда, Самара борылышыннан көнбатыштарак, Европа бәҗәнәкләре белән чиктә бортаслар кенәзлеге урнашкан була. Ока һәм Идел елгалары арасында, өлешчә хәзерге Рязань, Тамбов, Түбән Новгород, Ульяновск өлкәләре территорияләрен биләгән мишәр әмирлекләре урнашкан була.

Мишәрләр (мишә — урман, ир — кеше) — Көнчыгыш Европадагы «иң борынгы төрки телле кабиләләрнең берсе» (М. З. Зәкиев, 1993). Аларның XI — XII гасырларда Ока елгасының урта агымында яшәгән бабалары өлешчә Владимир кенәзлеге (Бөек кенәз Юрий Долгорукий 1152 елда Городец Мещерский дип, ә 1471 елдан башлап Касыйм шәһәре дип аталган шәһәргә нигез сала) һәм Идел буе Болгары составына керәләр. Соңрак, Алтын Урда составында калып, чагыштырмача зур автономиядән файдаланучы Темников-Наровчат кенәзлеге төрки телләрен саклап калган мишәрләрне берләштерә.

Идел буе Болгарының үзәк өлешен тагын да киңәйтеп җибәргән яңа әмирлекләр барлыкка килә. Халыкның артуы

һәм сәүдә-икътисади активлыкның көчәюе сәбәпле, Җүкәтау әмирлегенең структурасы формалаша. Әмирлекнең үзәге X гасырда, текә яр өстендә, Камага коя торган Кили елгасы тамагында үсеп чыккан Җүкәтау шәһәре була. Дәүләтнең көнчыгыш чикләре Каргалы, Чишмә, Чаллы, Минзәлә, Зәй, Ык елгалары бассейннарына кадәр сузыла.

Берләшкән дәүләт шулай ук Кама елгасыннан төньяктарак урнашкан, борынгы заманнардан бирле төньяк төрки һәм фин-угор кабиләләре яшәгән җирләрне эченә ала. Биредә Кама елгасының уңъяк ярында X гасырларда төзелгән Кашан шәһәре шул ук исемдәге әсмирлекнең үзәге булып китә. Археологлар коллекциясендә «Шәһре Кашан» дип тамгаланган беләзек бар. Камадан төньяк-көнбатыштарак урнашкан, борынгы заманнарда ук фин-угор кабиләләре яшәгән җирләрне берләштерелгән дәүләтнең икътисади, сәүдә һәм мәдәни тормышына якынайтуда Кашанның зур роль уйнаган булуын билгеләп үтәргә кирәк.

X—XI гасырларда Казансу елгасы бассейнындагы җирләр актив рәвештә гомумдәүләт тормышына катнашып китәләр. Биредә Казан әмирлеге барлыкка килә. Казан шәһәренә илнең төньяк-көнбатышында, Казансу Иделгә кушылган урында 1004—1005 еллар чигендә нигез салына. Стратегик планда шәһәр якында гына күтәрелеп килә торган Түбән Новгород һәм Владимир кенәзлекләре белән үзара мөнәсәбәтләрне тәэмин итәргә тиешле үзәк була. Ул — дәүләтне төньяк-көнбатыш яктан саклау максатында кирмән буларак төзелә. Болгарның рус кенәзлекләре һәм алар аша Скандинавия илләре белән сәүдә үсеше Казанны илнең яңа сәүдә үзәгенә әверелдерә. Шәһәр шулай ук Болгарның икенче мәдәни үзәге буларак та үсеп китә.

Казан әмирлеге Идел буе Болгарының төньяк җирләрен, шул исәптән Чепца елгасы бассейнында яшәүче төрки-татарлар территориясен социаль-икътисади яктан үстерүдә аеруча зур роль уйный. Соңгы чорларда этнотерриториаль яктан бу татарларны Югары Чепца буе (Кыстым-Глазов), Урта Чепца буе (Юкон-Палагай), Түбән Чепца буе (Карин-Хурит) татарларына бүлеп йөртәләр. Чепца елгасы бассейнында урнашкан Карин әмирлеге һәрвакыт Казан әмирлегенә тартылган, аның белән якынаерга омтылган.

Казан Зөя елгасының түбәнге агымында икътисади тормышның җанланып китүенә, биредә шәһәрләр барлыкка

килүгә булышлык итә. Археологлар биредә шул чорга караган Әлмән, Городище, Луковка-Япанча шәһәрлекләрен билгеләләр. Мөгаен, ул заманнарда бүгенге татарларның бабалары Иләт елгасы һәм аның кушылдыклары булган Бәрәңге һәм Ировка бассейннарын (хәзерге Марий Элнең Бәрәңге, Морки, Мари-Турек районнары) интенсив үзләштерүдә катнашканнардыр. Кама елгасының уңъяк яры төньяк-көнчыгышка таба да үзләштерелә. Вятка елгасының түбәнге агымында, Тойма һәм Иж елгалары бассейннарында Алабуга янындагы мәгълүм Шайтан шәһәрлегенә охшаш сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләре барлыкка килә.

Берләшкән дәүләт булган Идел буе Болгарының дәүләт чиге яңача билгеләнә. Гарәп чыганаклары (Әл-Истархи һ. б.), Идел буе Болгары көньякта Җаек елгасы буйларына барып чыга, төрки угызлар белән чиктәш була, дип язалар. Археологлар карамагында X — XII гасырларда Кызыл Сөндекле шәһәрлеге казылмаларының материаллары (хәзерге Ульяновск өлкәсе), Самара борылышы тирәсендәге, монголларга кадәрге чорга караган күп кенә торулыкларның, мәсәлән, Идел буе Болгар дәүләте культурасына карый торган «Муром шәһәрчеге» дип аталган шәһәрлек казылмаларының материаллары бар. Идел елгасының түбәнге агымындагы Саксин шәһәре дә Идел буе Болгарына кагылышлы.

Илнең үзәгеннән ерак торган, сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышларында зуррак мөстәкыйльлектән файдаланган әмирлекләр сыйфатында, берләштерелгән дәүләт составына көнбатыш башкорт җирләре, шулай ук чуваш җирләре дә керә. Берләштерелгән Болгар дәүләте составына чама белән шундыйрак шартларда, мөстәкыйльлеген күбрәк саклаган хәлдә, Мукшы, Сура, Алатыр елгалары бассейннарына урнашкан Мордва кенәзлеге, берләштерелгән дәүләтнең төньяк өлешен тәшкил иткән Мари кенәзлеге дә керә. Удмурт халкының көньяк территориясе һәм аларның кенәзлеге берләшкән Идел буе Болгарының төньяк-көнчыгыш өлкәсен тәшкил итә.

Иҗтимагый тормыш һәм дәүләт төзелеше. Идел буе Болгарының чәчәк атуы чоры XI гасырга — XIII гасырның башларына, Болгар династиясен дәвам иттерүче Хәйдәр, Мөхәммәт, Сәгыйть, Бәрәш, Ибраһим, Сәлим һәм Илһам ханнар патшалык иткән вакытка туры килә. XI гасыр башларына монда борынгы татарларның (төрки болгарларның) иҗтимагый һәм дәүләт системасы формалаша. Этник планда

җәмгыять әле һаман бертөрле генә булмый. Берләшкән дәүләтнең үзәк өлешен башлыча җирле төньяк төрки кабиләләр һәм бу тирәләргә соңрак килеп урнашкан болгар төрки кабиләләре били. Берләшкән дәүләт төзү эше дә алар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла. Алар соңрак та дәүләтне төп оештыручылар ролен үтиләр. Фин-угор кабиләләренә килгәндә, аларның төп өлеше периферияда яши, азчылык кына үзәктә урнашып кала. «Төрки телле халыкның сан ягыннан өстенлеге соңрак та, монголлар заманында да саклана, һәм бу хәл безгә кайбер тикшеренүчеләрнең, Идел буе Болгарының этнокультура составы башлыча фин-угорлардан торган, дип раслаулары белән килешергә мөмкинлек бирми»,— дип яза Ф. Ш. Хуҗин.

Җәмгыятьтәге яшәү рәвеше төрки һәм фин-угор халыкларының җирле традицияләрен чагылдырган. Бу халыклар сәүдә һәм көчле товар әйләнеше булган уртак социаль-икътисади зонага тартылганнар, дәүләтнең берләшүен, үзәкләшүен теләгәннәр. Ә рухи юнәлешкә килгәндә, монда хәл бераз башкачарак торган. Фин-угор халкы, шулай ук чувашларның күпчелек өлеше үзләренең мәҗүсилек диннәренә табынуны дәвам иткәннәр. Ислам исә башлыча илнең үзәк өлешендә һәм күбесенчә хәзерге татарлар һәм башкортларның бабалары арасында таралган, дәүләт сәясәтен, идеологиясен билгеләгән. Тагын шуны да әйтергә кирәк: Идел буе Болгары, аның халкы мөселманлаша, ләкин гарәпләшми. Тел өлкәсендә дә, мәдәният буенча да. Дини йолалар буенча Идел буе Болгар дәүләте гарәп Багдадына караганда төрки Бохарага якынрак тора.

Идел буе Болгары Багдад хәлифәлеге белән дәүләтара мөнәсәбәтләрне алга таба да үстерә. Әл-Моктәдир хәлифә заманында ук инде (932 елга кадәр) Болгар иле идарәчесе Әхмәд ханның улы җитәкчелегендәге Болгар илчелеге Багдадка бара. Хәлифәгә алар алып барган бүләкләрне Болгарның Багдадка бәйлелеген раслый торган рәсми ясак итеп карау, мөгаен, урынлы булмас. Идел буе Болгары ул вакытта ук инде шактый бай ил була. Ибне Фадланның сүзләренә караганда, Алмас хан аның белән сөйләшкәндә, кальга төзү эшен мин үзем генә дә булдырыр идем, әмма хәлифәгә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәндә, кальга изге акчага салыначак, димәк, дошманнар ала алмаслык булачак, дип уйлап эш иттем, дигән. Чыннан да ныгытма шәһәрләр аның заманында да,

аннан соң да төзелгән. Мәсәлән, IX гасыр азагында Биләр тирәсендә төзелгән ныгытма телгә алына.

Шәһәрләрне хәрби яктан саклау турында кайгырту, ныгытмалар төзү, хан гаскәрен, кирәк булганда, ополчениене дә коралландыру һәм кирәк-ярак белән тәэмин итү яшь дәүләтнең сәүдә юлларын һәм һөнәрчелек-сәүдә үзәкләрен саклау өчен бик урынлы була.

Биләрнең (Биарым) VII—VIII гасырларда ук инде Скандинавия илләре белән сәүдә-икътисади һәм мәдәни багланышларын җентекләп өйрәнгән М. З. Зәкиев бу багланышларның XI—XII гасырларда да дәвам итүе турында билгеләп үтә. Моннан элегрәк булган багланыш юллары Идел, Кама—Чепца елгалары бассейны аша, Карин татар әмирлеге аша үтә. Ибне Фадлан Идел буе Болгарына үз товарлары белән килгән норманнар (руслар) турында яза. Шул ук вакытта норманнарның территорияләрне басып алу, халыкны талау белән шөгыльләнүче юлбасарлык отрядлары да була. Рус историографиясендә менә шундый төркемнәрнең, Днепрдагы инде җайга салынган сәүдә юлыннан файдаланып, көньяк төбәкләргә кадәр төшүләре, көнчыгыш славяннарның җирле кенәзлекләрен яулап алулары һәм аларга ясак салулары турында языла. Идел буе Болгары да шундый ук язмышка дучар була. Идел аша үтә торган сәүдә юлыннан файдаланып, мондый отрядлар еш кына Идел һәм Кама елгалары буена урнашкан Болгар шәһәрләрен талыйлар һәм хәтта Каспий диңгезенә кадәр төшеп җитәләр. Әл-Мәсгуди 913 елда, Болгар иленә Багдадтан илчелек килүдән сигез ел элек, руслар-норманнарның, 500 гә якын каекка утырып, 50 мең кеше составында Каспий диңгезенең көньяк ярына кадәр барып җитүләре, Гилянга, Тәбәрстанга һәм Дәйлимгә һөҗүм итүләре, ә аннары Баку тирәсендәге бер утрауда тукталулары турында яза. Икенче бер гарәп язучысы Ибне Хәукал 968—969 елларда руслар-норманнарның Иделдәге Болгар шәһәрен талауларын бәян итә.

Идел буе Болгар дәүләте тагын бер төньяк иле — 1136—1448 елларда мөстәкыйль яшәгән Новгород республикасы белән шулай ук башлыча Идел аша киң сәүдә мөнәсәбәтләре алып барган. Новгород сәүдәгәрләре үз товарларын Идел буйлап ушкуй дип аталган ишкәкле елга судноларына төяп алып килә торган булганнар. Ушкуйниклар дип исем бирелгән коралллы юлбасарлар да нәкъ шундый ушкуйларда елга буйлап хәрәкәт итеп, шәһәрләрне талап йөргәннәр. Алар

еш кына Идел һәм Камадагы шәһәрләрне талап-җимереп китә торган булганнар. Алга киткән игенчелеге һәм шәһәр мәдәнияте булган бай илне тышкы һөҗүмнәрдән саклау зарурлыгы Идел буе Болгарында дәүләти берләшүне тизләтә. XI гасыр Болгары иҗтимагый стройны һәм дәүләт төзелешен ныгытуда хәлиткеч чор була.

Тышкы сәяси үзгәрешләр. X гасыр урталарында Идел буе Болгарының тышкы сәяси элемтәләрендә Багдад үзенең өстенлеген югалта. 945 елда Багдад шигыйләр Ираны (Буидлар династиясе) тарафыннан буйсындырыла. X гасырның икенче яртысында Хәзәр каһанлыгы таркала. Көнчыгыш Европада яңа вазгыять барлыкка килә. Идел буе Болгары белән беррәттән, биредә көнчыгыш славяннарның яңа дәүләте — Киев Русе бик тиз көчәеп китә. Елъязмада беренче урында торган кенәз Рюриктан (862—879) башлап руслар тарихында яу чабулар белән дан тоткан кенәз Святославка кадәр үзенең берләшү чорын үтеп, Киев Русе 988 елда, Бөек Владимир кенәзлек иткәндә, Византиядән православие (каноник) христианлыгын кабул итә. Шулай итеп, Көнчыгыш Европада бер-берсен алыштыра килгән төрки дәүләтләр (Һун каһанлыгы, Кара диңгез буе Болгар дәүләте, Хәзәр каһанлыгы) урынын ике дәүләт: Идел буе төрки-ислам Болгары һәм христиан православиесе өстенлек иткән Киев Русе ала. Алар Көнчыгыш Европаның көнчыгыш һәм көнбатыш өлешләрен биләп торалар. Көнчыгыш Европаның төньяк өлешен фин-угор кабиләләре били. Аларның әле ул вакытта үз мөстәкыйль дәүләтләре булмый. Финляндия XII гасырның урталарында шведларның католик таҗы астында кала. Новгород республикасы үзенең йогынтысын ненецларга һәм комиларга кадәр җәелдерә. Идел-Уралның төньягындагы фин-угор кабиләләре Идел буе Болгар дәүләте составына керә. Көнчыгыш Европаның көньягындагы, Киев Русеннан тыш, калган Хәзәр каһанлыгы җирләре (Кырым, Түбән Днепр һ. б.), нигездә, төркиләр тәшкил иткән территория булып кала. Тарихчылар аны Днепрдан Иртышка кадәр сузылган гаять зур Евразия зонасына кертәләр. XI гасырда бу зона Дәшти Кыпчак дигән атама ала. Дәшти Кыпчак — Кыпчак иле — «Кыпчакстан» дигәнне аңлата. Шулай итеп, үзгәргән Көнчыгыш Европа мәйданга чыга.

Болгар—Русь мөнәсәбәтләре. X гасырда, барлыкка килү — оешулары дәверендә, Идел буе Болгар дәүләте һәм Киев Русе

бер-берсенә каршы булган төрле ике илгә йөз тоталар. Идел буе Болгары — Багдад хәлифәлегенә, Киев Русе — Византиягә. Ул чакларда ук инде бу ике ил үзара каршылыклы мөнәсәбәтләрдә торалар. Бер яктан, Киев Русе һәм Идел буе Болгары шулай ук яңа дәүләт оешу чорын кичергән католик динле Көнбатыш Европа илләре тарафыннан үзләренә потенциаль куркыныч янавын сизәләр. 962 елда Борынгы Рим империясе хәрабәләре өстендә «германнарның Изге Рим империясе» барлыкка килә, һәм ул славян җирләренә дәгъва итә башлый. XI гасырда төзелгән Швеция корольлеге дә Төньяк-Көнчыгыш Европаның фин-угор һәм славян җирләренә өмет итә. Киев Русена һәм Идел Болгарына норманнарның яуларын кире кайтарырга туры килә.

Шул ук вакытта дөньядагы ике зур дингә табынган һәм күтәрелештә булган Киев Русе белән Идел буе Болгары Көнчыгыш Европа мирасы өчен көрәштә капма-каршы якта калалар. X гасырның икенче яртысыннан, ягъни Святослав заманыннан башлап Киев кенәзләренең болгар җирләренә яулары рус чыганакларында аерым билгеләп үтелә.

Ә тулаем алганда, бер-берсенә көндәш булган Идел буе Болгары белән Киев Русе арасындагы дәүләтара мөнәсәбәтләр бу дәүләтләрнең бер-берсенә каршы әледән-әле яу чабуларын да, аларның тыныч шартларда сәүдә-икътисади хезмәттәшлектә булуларын да эченә ала. Сәүдә мөнәсәбәтләре, әлбәттә, өстенлек итә. 1006 елда Болгар белән Киев арасында сәүдә шартнамәсе төзелә.

Елъязмада кенәз Владимирның «һәр җирдә һәм һәр нәрсә белән ирекле рәвештә сәүдә итсеннәр өчен» болгар сәүдәгәрләренә «барлык шәһәрләрдә йөрергә яраклы мөһер» бирүе турында әйтелә. Идел буе Болгары да, үз чиратында, рус сәүдәгәрләре белән шундый ук мөнәсәбәтләр урнаштыра. Идел буе Болгары белән Киев Русе арасындагы 1500 километрга сузылган сәүдә юлын кәрваннар 60 көн эчендә үткәннәр. Бу сәүдә юлында һәр ике яктан — Болгар ягыннан да, Киев ягыннан да — туктап ял итү өчен унар пункт булдырылган.

Идел буе Болгарының Русь белән дәүләтара мөнәсәбәтләрендә, XII гасырның икенче яртыларында Төньяк Русь беренче планга чыккач, яңа вазгыять урнаша. Киев дәүләте составыннан аерылып чыккан һәм Юрий Долгорукий кенәзлек иткәндә (1154—1157), үзенең тулы мөстәкыйльлеген игълан иткән Суздаль кенәзлеге XII гасыр ахырына ныгып-

көчәеп китә. Төньяк Русьның башкаласы Суздальдән Владимирга күчерелә. Рус чыганаклары Көнчыгыш һәм Көньяк илләре белән киң сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган Идел буе Болгарының Төньяк Русьта сәүдә һәм икътисад алга китүдәге ролен, тулаем алганда, уңай бәялиләр. Иделнең югары агымында археологлар Көнчыгыштан һәм Көнбатыш Европа илләреннән килгән тәңкәләр табалар.

Идел буе Болгары булачак Украина дәүләтенең тарихи нигезе булып әверелә барган Киев Русе (Көньяк Русь) белән сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләрен һәм башка мөнәсәбәтләрне саклап кала. Бер үк вакытта, Идел буе Болгары үз составына кергән фин-угор кенәзлекләренең сәяси омтылышларын яклавын дәвам итә.

Сәяси һәм икътисади позицияләре ныгыганнан соң, Владимир кенәзлегенең сәяси ориентациясе үзгәрә. Ул барлык төньяк рус кенәзлекләрен генә түгел, көньяк кенәзлекләрне дә, шул исәптән Киевны да, үзенә буйсындырып, бөтен борынгы көнчыгыш славяннар дәүләтенең үзәге булып әверелүгә йөз тота. Идел буе Болгар дәүләтенең Көнчыгыш Европада дәүләтара мөнәсәбәтләрендә төп партнер булып Русьның булачак үзәге — Владимир кенәзлеге кала.

Владимир кенәзлегенең күтәрелүе болгар — рус мөнәсәбәтләрен катлауландыра. Шиһабеддин Мәрҗани язганча, 1163 елда, Ибраһим хан патшалык иткәндә, Андрей Боголюбский (1157—1174) Идел буе Болгар дәүләтенә яу чаба, Бряхимов шәһәрен (Болгар идарәчесе Ибраһим хан исеменнән. Әлеге кирмән-шәһәрне ул сала, һәм шәһәр Ибраһим кала дип аталып йөртелә башлый) яндыра. Бу шәһәрне башкача тагын Тышкы Болгар дип тә атаганнар. 1171 елда чираттагы бәрелешләрнең берсендә Болгар җиңүгә ирешә. Рус чыганаклары Владимир кенәзе Всеволод III Юрьевичның (1176—1212) «Кама болгарларына» яуга йөрүен аның зур казанышы итеп күрсәтәләр. Мөгаен, биредә сүз Болгар һәм Владимирның үзара бер-берсенә яу чабулары турында (1185) бара торгандыр. Ул чакта эш солых төзү белән тәмамлана. Шул ук чыганакларда аның улы Юрий II Всеволодович (1219—1238), үз чиратында, «мордва һәм Кама болгарлары белән уңышлы сугышлар алып барды һәм төньяк-көнчыгыш чикләрне саклау өчен Түбән Новгород ныгытма-шәһәрен салды» дип языла. Мөгаен, монда сүз 1218—1220 елларда русларның Урта Иделгә зур яу белән йөрүләре, нәтиҗәдә мордва

җирләренең бер өлешенең Владимир кенәзлегенә кушылуы һәм анда Түбән Новгород шәһәр-ныгытмасы салынуы турында барадыр. Шул ук яу вакытында Идел буе Болгарының Идел елгасының уңъяк ярына урнашкан шәһәрләре талана, шул исәптән Оша елгасы буенда урнашкан Ашлы шәһәре җимерелә.

XIII гасыр башында Болгар — Владимир мөнәсәбәтләренең шул рәвешчә кискенләшүе араның бөтенләй өзелүенә һәм зур масштаблы сугыш башлануга ук китерми. Халыкара сәхнәгә *Монгол империясе* күтәрелә. *Чыңгыз хан* гаскәрләренең Көнчыгыш Европа чикләренә бәреп керүе Болгар һәм Владимир арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзгәрүенә китерә. 1223 елда, Сәлим ханның улы Илһам хан патшалык иткәндә, Идел буе Болгары белән Владимир кенәзлеге арасында барлык әсирләрне азат итү һәм яхшы күршелек, үзара ярдәмләшү турында 6 елга шартнамә төзелә. Бу Идел буе Болгарына монгол яулары янаган заман була.

Идел буе Болгары һәм Кыпчак иле. Ул заманда Кыпчак иле (Дәшти Кыпчак) күп кенә төрки халыклар яшәгән илне аңлатучы сәяси (геополитик) төшенчә була. Әле сүз барган чорда бу халыклар арасында беренче планга кыпчаклар (руслар «половецлар» дип, ә европалылар «команнар» дип йөртәләр) чыга. Кыпчак даласы, дип билгеләп үтә Л. Н. Гумилев, XII—XIII гасырларда инде ялан сәхрәне хәтерләтми. Кыпчакларның этнокультурасы, бигрәк тә телләре, яхшы өйрәнелгән. Ләкин башка борынгы төрки халыклардан аермалы буларак, аларның бердәм дәүләтләре булмый, ә төбәктәге дәүләти оештырылмалар әлегә аз өйрәнелгән.

Көнчыгыш авторлары кыпчакларны Уралдан Дунай елгасына кадәр сузылган Дәшти Кыпчакның (Кыпчак даласының) уртак халкы дип карыйлар. Көнбатыш авторлары исә, Европа кыпчаклары турында сүз алып барганда, аларны ике тармакка — көнчыгыш кыпчакларына һәм көнбатыш кыпчакларына (команнарга) бүләләр. С. А. Плетнева, мәсәлән, көнчыгыш кыпчаклары Иделнең түбән агымындагы (Саксин кыпчаклары) җирләрне, Донец, Түбән Дон һәм Азов диңгезе буендагы далаларны биләгәннәр, Бөек Болгарның һәм Хәзәр каһанлыгының варислары булганнар, ә команнар Дунайдан көнбатыштарак булган территорияләрне биләгәннәр, дип яза. «Игорь полкы турында җыр»ның авторы руслар барып җитә алмаслык җирләрне, алар «белмәгән» җирләрне: Кара диңгез

буйларын, Сула, Сурож (Кырым) елгалары буйларын, Коршуньны, Тмутархан шәһәрен (руслар аны Тмутаракань дип атаганнар — Кубан буендагы шәһәр) санап чыкканда, әнә шул җирләрне күз алдында тота. XIII гасырда язылган бер тарихи хезмәттә, монгол башлыгы Җучиның бу җирләр турында: бөтен дөньяда моннан да күңелгә ятышлырак җирнең, биредәгедән дә яхшырак һаваның, мондагыдан да татлырак суның, болардан да иркенрәк болын һәм көтүлекләрнең булуы мөмкин түгел, дип әйтүе турында билгеләп үтелә (С. А. Плетнева, 1990).

Хәзәр каһанлыгыннан аермалы буларак, кыпчак урдалары, үз араларында вакытлы хәрби союзлар төзесәләр дә, үзәкләштерелгән дәүләт булып оеша алмыйлар. XI гасырда Кырымдагы зур сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге булган Су-Даг шәһәре көнчыгыш кыпчакларның сәүдә-икътисади үзәге булып китә. Зур шәһәрләр арасында шулай ук Сугров, Төньяк Донец елгасындагы Йөзем, Шарухан аерылып торганнар. Бу соңгылары белән Болгарның шактый җанлы сәүдә багланышлары урнаша. Рус чыганакларыннан мәгълүм булганча, XI йөз азагы һәм XII йөз башларында биредә идарәче булып Тогур хан (русча Тугоркан) тора (К. П. Базилевич, 1950). XII гасырның икенче яртысында илдә Кунчак хан идарә итә. Ул 1185 елда Новгород Северский кенәзе Игорь Святославичның дружинасын тар-мар итеп ташлый.

Кыпчаклардан гайре биредә бүтән төрки халыклар — бәҗәнәкләр, төрекләр (рус чыганакларында — «торки») дә яши. Алар барысы да тора-бара кыпчаклар белән кушылып бетә. Төньяк Кавказда яшәгән төрки халыклар — нугайлар, кумыклар, балкарлар, карачайлар — кыпчакларның ут күршеләре булганнар. Кыпчакларның төп шөгыльләре — игенчелек, терлекчелек, сәүдә, һөнәрчелек. Тарихка аларның Идел буе Болгары белән генә түгел, Киев Русе белән, ә аннан элегрәк норманнар-руслар белән хезмәттәшлек иткән булулары билгеле.

Галимнәр тарафыннан тикшерелгән Кыпчак курганнары мәдәни мирасны тулыландыручы чыганаклар булып торалар. Бу курган-каберлекләрдә үле сугышчы җәсәде белән бергә аның атын да күмә торган булганнар. Б. э. кадәр 2 меңьеллыктан башлап Европа һәм Азиянең төрки халыклары өчен характерлы булган «таш балбаллар» дип аталган сыннарның күбесен галимнәр үзенчәлекле кыпчак истәлекләре рәтенә кертеп карый. Бу очракта сүз атаклы Европа сәяхәтчесе

В. Рубруквис кыпчакларныкы дип аңлаткан Идел-Дон-Днепр төбәгендә таштан уеп ясалган ир кеше һәм хатын-кыз сыннары турында бара. XI—XII гасырларга, ягъни бу тирәләрдә кыпчаклар яшәгән вакытларга караган бу таш сыннар кабер өстенә куелганнар, һәм аларның биеклеге 1,5—3,5 метрга җиткән.

Дин мәсьәләсенә килгәндә, кыпчаклар мәҗүсилектән дөнья диннәренә күчү баскычында торганнар. Көнбатыш Кыпчак җирендә, бирегә Кавказ (Азәрбайҗан, Дагстан) аша килгән ислам белән беррәттән, күпмедер дәрәҗәдә Несторий юнәлешендә булган христианлык та таралган булган. Византиядә Константинополь патриархы булып торган, соңрак еретиклыкта гаепләнгән Нестор тарафыннан нигезләнгән несторианлык, христиан диненең төп догматларыннан берсе булган «троица»ны таный торган рәсми христианлыктан үзгә буларак, Иисус Христос тик соңрак кына мессиягә (кешеләрне афәттән коткару өчен күктән иңдерелгән затка — Алла улына) әверелә, дигән догматка таяна. Мәсьәләне болай аңлату төрки халыклар арасында киң таралган карашка, күк йөзендә Алла бер генә, Тәңре — бер ул, дигән карашка якын тора. Өстәвенә несторианлык миссионерлары Иисус Христосның тәгълиматын халыкка аңлаешлы булган төрки телдә аңлаталар. Этнолог Д. Исхаков, бәлки, баштарак христиан динен Кара диңгез һәм Азов буендагы грек колонияләрендә яшәгән төркиләштерелгән греклар тота башлагандыр, дигән караштa тора. Ул чакта андый грекларны «орымнар» («урумнар») дип атаганнар.

Идел буе Болгарының Азия кыпчаклары (көнчыгыш Арал диңгезе буенда һәм Сырдәрьяның түбәнге агымында урнашкан, башкаласы ул заманнар өчен мөһим сәүдә үзәге саналган Сыгнак шәһәре) белән даими сәүдә һәм икътисади бәйләнешлары булган. Бу сәүдә багланышлары, икътисади мөнәсәбәтләр кыпчаклар белән Идел буе болгарларының тел һәм мәдәният өлкәсендә дә якынаюларына китергән. Бу бигрәк тә кыпчаклар белән ут күршеләр булып яшәгән татар-мишәрләргә кагыла. Тел белгече Р. Г. Мөхәммәдова билгеләп үткәнчә, кыпчаклар болгар халкының формалашуында катнашканнар. Бу ике телнең — Идел буе Болгарында болгар теленең һәм кыпчак теленең — якынлыгы дәрәҗәсе турында XI гасырда яшәгән атаклы галим Мәхмүд Кашгарыйның (1072—1074) «Диване лөгатет-төрк» дигән хезмәте һәм

1245 елда Мисырда төзелеп, 1844 елда Голландия галиме М. Т. Хоутома бастырып чыгарган «Төркичә-гарәпчә сүзлек» буенча һәм башка тикшеренүләргә таянып фикер йөртергә мөмкин. Кыпчак теле Көнбатыш Европа галимнәре тарафыннан да өйрәнелә. Бу уңайдан XIII гасыр истәлеге — «Коман мәҗмугасы»н искә алып үтү урынлы булыр. Галим Х. Ш. Мәхмүтов анда хәзерге заман татар табышмакларына якын булган 20 ләп параллель таба.

Ерак илләр белән багланышлар. XI—XII гасырларда Идел буе Болгар дәүләтенең тышкы багланышлары әйтеп үтелгән илләр белән генә чикләнми. Аның Европа һәм Азиядәге бу илләрдән ераграк торган дәүләтләр белән дә мөнәсәбәтләре дәвам иттерелә. Идел буе Болгары турында Үзәк Европада да беләләр. XII гасырның Ауклин елъязмасындагы (атамасы Карпат тауларындагы бер үткел исеменнән алынган) язулар шул турыда сөйли. 1997 елда Казан Кремле территориясендә X гасырга кагылышлы һәм Прага университеты галимнәре раслаган чех акчасы табыла. Бу хәл ул вакытларда Болгар һәм Чехия арасында бәйләнешләр булганлыгы турында сөйли. Археология материалларында Көнбатыш Европадан экспорт белән килгән әйберләр, аерым алганда Урта Рейндагы корал остаханәләрендә ясалган кылычлар бар.

Идел буе Болгары XI—XII гасырларда Көньяк Казакъстан һәм Төньяк Үзбәкстан территориясендә урнашкан, башкаласы Талас елгасындагы Тараз (Талас) шәһәре булган Караханилар дәүләте белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Көньяк-көнчыгышта Идел буе Болгарына төрки угызлар дәүләте (Көнбатыш Казакъстан) күрше була. Бу дәүләтнең идарәчесе «йабгу» дигән титул йөртә. Ибне Фадлан Идел Болгарына килешли үзенең Устюрт яссытаулыгына урнашкан Ваб әт-төрк («Төрки угызлар иленең капкасы») шәһәр-кирмәнендә булуын тасвирлый. Ул Болгар идарәчесе Алмасның бу илнең хәрби башлыгы Әтрәкнең кияве булганлыгы турында яза. XI—XII гасырларда Идел буе Болгарының Газнавилар династиясе торган Бохара белән дә бәйләнешләре дәвам итә.

СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ ТОРМЫШ

Шәһәрләр иле. Идел буе Болгар дәүләтенең XI—XIII гасырларда чәчәк атуы социаль-мәдәни тормыш яңарышында — җитештерү дәрәҗәсенең, шәһәр һәм авылларда халыкның

тормыш дәрәҗәсенең күтәрелүендә, мәгариф һәм рухи ориентация өлкәсендәге уңай үзгәрешләрдә, этномәдәни һәм этносәяси аң үсешендә күренә.

«Идел Болгары — бай шәһәрләре булган куәтле бөек патшалык»,— безнең илгә XIII гасырның беренче яртысында килеп киткән Доминика монахы Юлиан үзенең көндәлек дәфтәрендә әнә шулай дип язып калдыра. Болгар, Казан, Биләр (Бүләр), Суар, Ашлы, Кашан һәм башка шәһәрләр моңа кадәр үк бөтен дөньяга билгеле булалар. XI—XIII гасырларда яңа шәһәрләр төзү кызу темплар белән бара. Үз заманы өчен шактый зур булган Җүкәтау, Арча шәһәрләре, шулай ук Ибраһим кала (Бряхимов), Кирмәнчек, Чалмат, Тухчин, Сабакүл, Чаллы, Тәмте һәм башкалар кебек уртача зурлыктагы һәм кечерәк калалар барлыкка килә. Археолог Ф. Ш. Хөсәенов XIII йөзнең беренче яртысында Болгарның өч дистәләп торак пунктын, һич икеләнмичә, чын шәһәрләр рәтенә кертергә мөмкин дип исәпли.

Иң атаклы шәһәрләр арасында Болгар белән беррәттән Кама буендагы элгәреге дәүләт оештырылмаларының иң борынгы үзәге Биләр телгә алына. Идел буе Болгарының үзәк шәһәре Болгардан Казанга күчерелгәнгә кадәр күпмедер вакыт ул Болгарның башкаласы булып та тора. Археологлар бу шәһәрләр биләгән җир мәйданының шактый зур булганлыгын билгеләп үтәләр. Биләрнең мәйданы ныгытмалар чикләрендә 620 гектар, ә бистәләре белән бергә 800 гектар тәшкил итә. Шәһәрнең архитектурасы үзенчәлекле була. Кагыйдә буларак, шәһәрләр цитадельдән (ныгытылган корылма), үзәк өлештән һәм тышкы шәһәрдән — бистәләрдән торган. Цитадельдә дәүләт хезмәте бинасы һәм Хан сарае урнашкан була. Үзәк өлештә җәмәгать бинасы, мәчетләр (Мәсҗиди Җами — Җамигъ мәчет, Мәсҗиди Адина — Җомга мәчете, гадәти мәхәллә мәчетләре), сәүдә рәтләре, җәмәгать мунчалары, шулай ук аксөякләр һәм хәллерәк кешеләрнең башлыча таштан салынган йортлары урнашкан. Тышкы шәһәр төрле һөнәрчеләр — металл эретүчеләр, тимерчеләр, бакырчылар, корал ясаучылар, ювелирлар, күнчеләр, постаучылар, пыяла өрүчеләр һ. б. төрле һөнәр ияләре бистәләреннән торган. Шунда ук аларның мәчетләре, сәүдә һәм күңел ачу бинасы урнашкан. Элеккегерәк җирле әмирләрнең бер үк вакытта утар хезмәтен дә үтәгән кирмәннәре булуы да мәгъ-

лүм. Мондый таш кирмәннәрнең түбәләре гөмбәз һәм чатыр рәвешендә ясалган була.

Шәһәр төзелешендә таш, агач, җирле кирпеч файдаланылган. Таштан төзү архитектурасы шактый алга киткән булган. Гаҗәеп матур, гөмбәзсыман түшәмле итеп, эчке яктан да колонналар белән бизәп эшләнгән Җамигъ мәчетләрнең булуы билгеле. Аларның фасад өлеше пилястралар (ярымколонналы чыгынтылар) белән матурланган булган. Монголлар яулап алганга кадәр Болгарда нәкъ менә шундый Җамигъ мәчет булганлыгы билгеле. Шиһабеддин Мәрҗани язганча, бу Җамигъ мәчетнең манарасы XIX гасырда гына ауган. Мәхәлләләрдәге, шәһәр читләрендәге, авыллардагы гадәти мәчетләрнең манаралары, төп бина түбәсеннән күтәрелә торган итеп, гади бүрәнәдән салынган була. Архитектура алымнары барысының да бер төсле — алар Мәккә юнәлешенә каратып салына. Барысында да бер үк стильдәге тәрәзәләр тезелеп киткән. Эчләрендә мөнбәр бар. Манара очын шулай ук Мәккәгә юнәлдерелгән ислам эмблемасы — ярымай бизи.

Археологлар шактый зур шәһәрнең истәлекле урыны итеп гөмбәзсыман түшәмле зур-зур заллары, идән астына урнаштырылган үзәктән җылыту җайланмалары булган ике катлы таш мунчаны билгеләп үтәләр. Елгалар аша салынган күперләр күзгә ташлана. Коры җирдән яисә су буйлап үтә торган олы сәүдә юлларындагы йөк төяү-бушату пунктлары булып хезмәт иткән шәһәрләрдә һәйбәт кәрвансарайлар һәм аларга кирәк булган ярдәмче биналар салынган. XII гасырда Ибраһим хан тарафыннан салдырылган Ибраһим каласында хәтта порт корылмалары да була. Аксөякләр һәм хәлле кешеләр өчен матур итеп таштан салынган биналарның, үзенчәлекле җирле орнамент кулланып, агачны сырлап бизәкләр төшерелгән, уеп орнаментланган колонналы агач йортларның тасвирламасы сакланган.

Торак биналарны эчтән бизәү дә тагы да затлырак була бара. Матур итеп җиз калайдан ясалган бизәкләр беркетелгән сандыклар киң таралыш ала. Йортларда урын-җир кую һәм ял итү өчен махсус почмак җиһазландырыла, такта сәке куела. Ул заманнарда эшләнгән бакыр һәм балчык савыт-саба, көзгеләр, йозаклар, алтын һәм көмештән ясалган бизәнү әйберләре безнең көннәргәчә сакланып калган. Ул вакытларда ук инде Казанның төп ныгытмасы — Кремль һәрьяктан

таш дивар белән әйләндереп алынган гаҗәеп корылма була. Кремль эчендә Хан сараеның затлы таш биналары, мәчетләр, хәрби корылмалар, төрле ярдәмче биналар урнашкан була.

Шәһәрдәге тормыш-яшәеш тә үзгәрә. Башлыча, сәүдә үзәге һәм крестьяннарның үз хуҗалыкларында җитештерә торган товарларын китереп сату урыны сыйфатындагы элекке шәһәрләрдән үзгә буларак, ул вакыттагы шәһәрләрнең даими рәвештә һөнәрчелек белән, сәүдә белән шөгыльләнүче һәм шул шәһәрдә төпләнеп гомер итүче үз халкы була. Акча системасын болгар дирһәмнәре тәшкил итә. Биредә сугылган озынча тәңкәләрне эзгерләр дип атап йөрткәннәр. Шәһәр интеллигенциясенең — зыялыларның саны арта, мәдәният үзәге буларак, шәһәрләрнең әһәмияте үсә. Болгарда крепостной крестьяннарның булмавы шәһәр халкын иреклe кешеләр хисабына тулыландыру мөмкинлеген җиңеләйтә.

Авыл тормышы. Үзгәрешләр авылларга да кагыла. Олы юллар, сәүдә юллары өстендә утырган авыллар еш кына шәһәрләр булып үсеп китә. Дәүләтнең үзәк өлешендә халык тыгызлыгы арту сәбәпле, илнең авыл зонасы периферияга таба киңәя. Яңа су юллары үзләштерелү (Мишә, Казансу, Зөя, Вятка, Тойма, Иж, Ык, Кили, Каргалы, Чишмә, Чаллы, Минзәлә һ. б.) уңаеннан, барлык бу төбәкләрдә яңа авыллар үсеп чыга, халык тыгызлыгы арта. Авылда җитештерүнең төп тармагы булып игенчелек кала бирә. Сөрүле җиргә ихтыяҗның артуы яңа җирләрне үзләштерү хисабына канәгатьләндерелә.

Сөрү җирләрен арттыру урманнарны кисү, төпләү, яндыру юнәлешендә бара. Моны ышна ачу дип атыйлар. Терлекчелек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен яңа болыннар үзләштерү, печән җирләрен культивацияләү, үлән чәчү үткәрелә.

Кырчылык һәм терлекчелек продукциясен төп җитештерүчеләр — җирләрен мирас итеп калдыру хокукына ия ирекле крестьяннар була. Алар бу җир өчен дәүләткә ясак түлиләр. Авыл халкының шактый өлешен арендаторлар тәшкил итә. Алар җирдән файдаланган өчен аның хуҗасына — җирбиләүчегә — җыеп алынган уңышның бер өлешен бирәләр. Эре җирбиләүчелек тарханнар йөзендә гәүдәләнә. Ханның вассалы ул биргән җир биләмәсе өчен салым түләүдән азат ителгән. Җир биләмәләре әмирләр, югары дәүләт хезмәткәрләре, дәрәҗәле ислам руханиларына бүлеп бирелгән. Дәүләттәге җирнең күп өлешен ханның үз җирләре тәшкил иткән.

Крестьян хуҗалыкларында өстәмә шөгыль рәвешендә төрле кәсепчелек таралган: җитен эшкәрткәннәр, йон теткәннәр, күн эшләгәннәр, агач эшкәрткәннәр. Хатын-кызларның барысы да диярлек туку белән шөгыльләнгән. Йорт һөнәрчелеге продукциясенең бер өлеше базарга киткән. Авыллар төрле зурлыкта булып, араларында дистәләп өйдән торганнары да, йорт саны йөзләп саналганнары да күзәтелгән. Алар, кагыйдә буларак, су буйларына, калкурак урыннарга урнаштырылганнар. Авыл архитектурасында милли чалымнар күренә башлый. Өйләр, гадәттә, дүрт почмаклы була. Өйнең арткы ягына янкорма — өйалды салына. Аның ишегалдына чыга торган ишеге һәм чормага менә торган баскычы була. Өйләр мич ярдәмендә җылытыла. Аш-су пешерү өчен мичкә чуен казан куела.

Крестьяннарга хас сыйфат — төптән уйлап, иплəп, сыйфатлы итеп эшләү. Борынгы болгарларда йорт-җир, каралтыкура, лапаслар уңай-җайлы булырлык итеп, җыйнак итеп урнаштырыла. Хуҗалык корылмалары терлек биналарыннан, келәт, сарай, баздан гыйбарәт була. Мунча ишегалдының бер читендәрәк салына. Капканы зур осталык белән бизәп-матурлап эшләү — болгарлардан калган гадәт.

Транспорт чаралары — җәен арба, кышын бер ат җигүле чана. Бәйрәм араларында, гадәттә, пар ат, ә кайчак өч ат җигеп чыгалар. Аеруча тантаналы очракларда кулланыла торган иярнең кашы биегәйтеп, бизәкле итеп эшләнә.

Авылда яшәүчеләр арасында, шәһәрләрдәге кебек үк, милек мөнәсәбәтләре шәригать кануннарына нигезләнеп җайга салына. Аларның үтәлешен мәхкәмә (суд) тәэмин итә. Кешеләрнең шәхси, гаилә һәм иҗтимагый тормышы әхлак нормаларына нигезләнә: бу — хәләл, димәк, бу ярый; бу — хәрәм, димәк, бу ярамый, бу — гөнаһ, димәк, бу гаепле эш, гөнаһлы эш. Әлеге кагыйдәләрнең үтәлү-үтәлмәвендә җәмәгатьчелек фикеренең роле зур була.

Мәдәни тормыш. XI—XIII гасырларда Идел Болгарында яшәү рәвешенең үзенчәлеге уртак рухи мәдәният формалаша башлавыннан гыйбарәт. Уртак тел, уртак территория белән беррәттән уртак рухи мәдәният һәм ислам кыйммәтләре болгар җәмгыятенең тыгыз туплануында мөһим факторлар булганнар.

Белемгә омтылыш, гыйлемлелек югары бәяләнгән. Мәчетләр санының артуы, мәдрәсәләр үсеше күзәтелгән. Теләсә

кайсы мәчетнең имамы бер үк вакытта үз мәхәлләсендәге ир балаларны укытучы мөгаллим дә була. Имамнарның хатыннары остабикәләр дә укымышлы кешеләр, мөгаллимәләр булганнар. Алар үз мәхәлләләрендәге кыз балаларны укырга өйрәткәннәр. Җамигъ мәчетләрендә югарырак дәрәҗәдәге уку йортлары — мәдрәсәләр ачылган. Уку-укыту җирле әдәби төрки телдә гарәп әлифбасына нигезләнгән борынгы татар язуында алып барылган.

Идел буе Болгар дәүләтендә ул вакытта рухани мәгърифәтчеләрдән, галимнәр һәм әдипләрдән торган шактый зур зыялылар катлавы формалаша. Җирле мәдрәсәләрдә белем алганнан соң, күп кенә яшьләр Харәзем, Бохара, Нишапур (Төньяк-Көнчыгыш Иран), Сүрия (Шам), Мисыр мәдрәсәләрендә укуларын дәвам итәләр. Алар гарәп һәм фарсы телләрен яхшы беләләр, ислам теологиясен тирәнтен өйрәнәләр һәм үз вакытларының күп кенә атаклы галимнәренең фәнни хезмәтләре белән якыннан танышалар. Тус (Хорасан) шәһәреннән чыккан, Нишапур шәһәрендә яшәп иҗат иткән теолог, философ Әбү Хәмид әл-Газали (1053—1111) ул вакыттагы шундый абруйлы галимнәрнең берсе булган. Газали үзенең хезмәтләрендә теология белән табигать фәннәре арасында компромисска омтыла, мантыйк, математика һәм физиканың күбесенчә дини догматлар эчтәлегенә карата битараф булуы турында, бу дисциплиналарның барлык мөселманнар өчен дә якын булуы турында яза. Шәкертләргә Әл-Хамавиның (1178/80—1229) «Могънәмәл билдан» («Илләр сүзлеге») дигән энциклопедик сүзлеге (биографик сүзлек — 1 мең сүз, географик сүзлек — 16 мең сүз) билгеле була. Идел буе Болгарында борынгы төрки телдә язылып, Төркестанда басылып чыккан теологик, фәлсәфи һәм тарихи хезмәтләр киң таралыш ала. Алар арасында 1069 елда Йосыф Баласагунлы (Бала Сагун — Көнчыгыш Төркестандагы шәһәр) тарафыннан язылган «Котадгу белек» («Бәхет китерә торган белем») дигән китап та була. Автор анда үзенең фәлсәфи һәм сәяси карашларын бәян итә. Төркестандагы Яса шәһәрендә яшәгән Хуҗа Әхмәд Ясәви (1166/67 елда вафат булган) беренче тапкыр буларак Коръән сүзләрен борынгы төрки телдә бәян иткән. Исламны тарату, аңа өндәү белән шөгыльләнүче бу хәрәкәт дәрвишләре үз ишаннарының «теге дөньяга гөнаһсыз килеш килергә һәм Аллаһы каршына гөнаһсыз килеш басарга» дигән идеяләрен тараталар. Алар фикеренчә, шулай итеп, дөньяны гадел-

сезлектән һәм золымнан арындыруга ярдәм итеп булачак. Ясәвичелек Идел Болгарында исламга өндәүче хәрәкәт буларак кына түгел, йогынтылы фәлсәфи мәктәп һәм билгеле бер әдәби юнәлеш буларак та тарала. Идел буе Болгарында Ясәвинең лирикасы да югары бәяләнә:

Гыйшык дәрте һәрчак яна! Гакыл җитмәс,
Баштанаяк җәфага бат, бетмәс-китмәс;
Үкенүләр, тәүбә итүләр тәэсир итмәс,—
Ля мәкянда[1] Хактан сабак алдым менә.

Идел буе Болгар дәүләтеннән чыккан фән зыялыларының бер өлеше, Шиһабеддин Мәрҗани әйтеп үткәнчә, илдән читтә дә эшен дәвам иттерә. Күпләр исә, укуны тәмамлап, бераз сәяхәт кылганнан соң өйләренә кайтып, эшкә чумалар. Әл-Гарнати үзенең «Гакыл бүләкләре» дигән китабында Болгарда булган вакытында (XII гасыр) «Болгар тарихы» дигән китапның авторы Ягъкуб бине Ногман белән танышуы турында яза. Ягъкуб Ногман Нишапурда белем ала, ә Болгар иленә кайткач казый булып тора. Шиһабеддин Мәрҗани безгә икенче бер тарихчы һәм юрист, шәригать белгече Хәмид бине Идриси әл-Болгари турында яза һәм аның әле 1106 елда исән булуын билгеләп үтә. Шиһабеддин Мәрҗани тагын шуны да хәбәр итә: Сөләйман бине Дауд әс-Саксини-Суари «Зөхрәтер рияз вә нөзхәтүл-колуб әл-мираз» («Авыруларның йөрәген савыктыручы розалар бакчасы») дигән китабында күп тапкырлар аның исемен телгә ала һәм аның әсәрләреннән өзекләр китерә. 1996 елда Иранның Милли китапханәсе Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә XIII гасырда яшәгән болгар галиме Таҗетдиннең медицинага багышланган трактаты күчермәсен тапшыра. Галимнәр алдында әле аны өйрәнү-тикшерү бурычы тора.

Идел буе Болгары борынгы заманнардан бирле халык авыз иҗаты һәм язма әдәбият белән дан тота. Иран тарихчысы Мирхонд (1433—1498) үзенең «Раузат әс-Сафа» (Бомбейда нәшер ителгән) дигән китабында Болгар җиренең ничек башлануы турында борынгы бер риваятьне хикәят итә. Бу риваятьнең эчтәлегеннән аның бары тик болгарлар илендә генә иҗат ителгән булуы аңлашыла. Анда бәян ителгәнчә, төрки кабиләләр Яфәс бине Нухның ике улыннан башланып

---

[1] Ля мәкянда — билгесез урында.

китә. Аларның берсе, Гомәри исемлесе, кәеф-сафага бирелеп, хозурланып яшәргә ярата. Бигрәк тә киек кошлар ауларга хирыс була. Көннәрнең берендә, шундый ау вакытында кызу чүлләрдән үзгә уртача климатлы бер урынга барып чыга. Биредә ул әле кеше аягы басмаган, шау чәчәктә утыручы болын-тугайларга тап була. Бу урын Гомәринең күңеленә хуш килә, һәм ул шунда төпләнеп калырга карар итә. Аллаһы Тәгалә аңа ике угыл бүләк итә. Ул аларның берсенә Болгар дип, икенчесенә Бортас дип исем куша. Үсеп буйга җиткәч, аның уллары икесе дә шул ук төбәктә мөстәкыйль көн итәр өчен җир сайлап алалар, башлы-күзле булалар, тормыш корып җибәрәләр. Һәм шул төбәктәге халык шулар токымыннан башланып китә. Күрүебезчә, бу борынгы риваять нәселнең башлануын бүре белән бәйли торган башка төрки авторлар әсәрләреннән («Угызнамә» һ. б.) аерылып тора.

Алтынчач, болгар мәргәннәре турындагы бәетләр кебек халык авыз иҗаты үрнәкләре безнең көннәргә кадәр килеп җитә. Шиһабеддин Мәрҗани «Ике былбыл кыйссасы», «Нәүрүз бәете» кебек әсәрләрне болгар чоры әдәбияты үрнәге итеп карый. Ул заманнарда (ә күп кенә мөселман илләрендә хәзер дә) яңа ел язгы көн тигезлеге көнендә (март аенда) билгеләп үтелә, һәм ул Нәүрүз бәйрәме дип атала.

Ул заманнардагы болгар әдәбиятының күренекле үрнәге бөтен дөньяга танылган шагыйрь Кол Галинең (1183—1236/38) «Кыйссаи Йосыф» поэмасы зур урын алып тора. Кол Гали — даһи язучы, тарихчы, философ — Болгар шәһәрендә туган, биредә мәдрәсәдә укыган. Бик күп сәяхәт иткән: Харәзем, Герат, Сүрия, Иерусалим һәм Мәккәдә булган. Ватанга кайткач, мәдрәсәдә дәрес биргән, шигырьләр язган. Аның безгә килеп ирешкән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы күләмле әсәрләрдән санала. Поэма 1223—1233 елларда гарәп хәрефләре белән язылган. Бу тел — борынгы төрки тел — бер Идел буе Болгарында гына түгел, кыпчаклар дөньясында һәм, чыгытай-үзбәк теле формалашканга кадәр, Караханилар дәүләтендә (Төркестан) дә кабул ителгән булган.

Кол Гали үзенең поэмасы өчен дини теманы, Коръән темасын сайлаган. Үз вакытында, XI гасыр башларында фарсы телендә язылган «Йосыф-Зөләйха» поэмасы шул ук темага багышланган. Шиһабеддин Мәрҗани «Кыйссаи Йосыф»ны беренче төрки поэма дип атый. Поэманың сюжет үзәгендә Зөләйханың Йосыфка булган мәхәббәте ята. Менә шул дини

сюжетта Кол Гали үзенең социаль-тарихи, фәлсәфи һәм этик-эстетик карашларын чагылдыра. Кол Галинең игътибар үзәгендә — гуманлык, гаделлек, үзара татулык һәм аңлашу проблемалары. Ул хәтта иң кыен вакытларда да (мәсәлән, илдә җиде ел буена рәттән кытлык хөкем сөргәндә дә) фән, белем, алдан уйланылган икътисади чаралар аркасында һәм дәүләт идарәсенең гадел булуы нәтиҗәсендә һәлакәттән котылырга, кешеләрнең тормышын саклап калырга мөмкин икәнлеген исбатларга тырыша.

Поэманың азагында Йосыф тарафыннан Нил елгасының каршы як ярында салынган, бары тик гаделлек нигезендә генә яши торган шәһәр тасвирлана. Бәлки, бу мотивларны язарга авторны Идел буе Болгарының моңа кадәр үткән елларда уңышлы гына үсеп килүе һәм илгә монгол явы куркынычының якынлашуы мәҗбүр иткәндер. Кол Гали ул чордагы шагыйрьләр гаиләсендә берьялгызы гына түгел. Ул шигърият һәм мәдәният күгендә шулкадәр ялтырап-балкып кабына ки, анда мәңге сүнмәс йолдызларның берсе булып кала.

Идел буе Болгар дәүләтендә декоратив-гамәли сәнгать тәнык үскән була. Безнең музейларда болгар ювелирлары ясаган алтын, көмеш бизәнү әйберләре, металлга (тимергә, бакырга, бронзага) чокып бизәкләр төшерү осталарының, керамика, сөяк эшкәртү осталарының эшләнмәләре тупланган. Аларның барысында да җирле талантлар тудырган үзенчәлекле болгар бизәкләре чагылыш тапкан.

XI—XIII гасырлардагы болгар мәдәниятендә акыл һәм кешелеклелек мәсьәләсе тагын да үстерелә. Анда халыкның сәяси-хокукый һәм рухи кыйммәтләре чагылыш таба.

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫ ҺӘМ АЛТЫН УРДА

Идел буе Болгарының халыкара хәле. XIII гасыр башларында Идел буе Болгары — халыкара мәйданда танылган, киң сәүдә-икътисади бәйләнешләре булган дәүләт. Харәземдә, Бохарада, Көнчыгыш Төрекестанда аның позицияләре шактый ныгый. Көнбатыш белән — Төньяк һәм Көньяк Русь белән — яңа мөнәсәбәтләр урнаша. Идел буе Болгарының бер Көнчыгышта гына түгел, башка илләр белән үзара мөнәсәбәтләрендә дә сәүдә-икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр өстенлек итә. Мондый бәйләнешләр Болгар—Русь мөнәсә-

бәтләрендә дә күзәтелә. X—XIII гасырларга караган күп кенә чыганакларда Болгар — Русь мөнәсәбәтләре һәр ике якның бер-берсенә туктаусыз яу чабулары итеп сурәтләнә. Әлбәттә, ул вакытларда болгарлар белән руслар арасында көндәшлек тә булмый түгел. Шуңа да карамастан, Болгар — Русь мөнәсәбәтләрендәге төп юнәлешне сәүдә-икътисади багланышларда күрергә кирәк.

Кайбер тарихчылар кыпчакларга карата да тискәре караш беркетү юнәлешендә шактый күп тырыштылар. Еш кына очракларда кыпчаклар көньяк җирләрне, көч кулланып, үз кулларына төшергән һәм шул биләмәләрдән торып рус җирләренә талау яулары оештырып торган явыз дала күчмәләре итеп сурәтләнәләр. Шик тә юк, кенәзлекләр арасында төрле хәлләр булган: тыныч сәүдә мөнәсәбәтләреннән алып бәрелеш-сугышларга кадәр. Шулай да өстенлек тыныч сәүдә-икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләр ягында була. Нәтиҗәдә X—XIII гасырларда Идел буе Болгарының үсеше кыпчак җирләре белән икътисади һәм мәдәни яктан якынаю юнәлешендә бара. Фин-угор халыклары белән мөнәсәбәтләргә килгәндә, биредә дә беренче планга икътисади һәм мәдәни мәнфәгатьләр чыга. Болгар Идел-Урал төбәгендәге бу халыкларны үзенә җәлеп итеп, тартып тора торган көч була. Ләкин ул беркайчан да империя үзәгенә әверелми.

Бу процесска ул чагында бөтен дөньяны тетрәткән яңа тарихи вакыйга килеп кушыла. Бу яңа тарихи вакыйга — монголлар явы — Җир шарының шактый зур өлешендәге — Кытай, Һиндстан, Иран, Урта Азия һәм Көнчыгыш Европадагы халыкларга кагыла. Шулар рәтенә Идел-Урал төбәге халыклары да керә.

Монголларның Идел Болгарына бәреп керүе. Монголия империясе 1206 елда Каракорым шәһәрендә Чыңгыз хан (Бөек хан) дәрәҗәсе алган император Тимучин җитәкчелегендә игълан ителә. Монголлар — телләре буенча төрки халыкларга якын торган һәм борынгыдан бирле алар белән Кытайның бер өлешендә, Көнчыгыш Себер, Көнчыгыш Төркестан территорияләрендә аралашып яшәгән иң борынгы халыкларның берсе. Алар дистә-йөз сугышчы бирә алырлык зур-зур авыллар булып яшиләр. Монголлар үзләренең союзниклары булган төрки халыклар, аерым алганда, уйгурлар һәм үзләренең беренче дәүләт оештырылмалары булган Урхун-Енисей татарларының кабилә берләшмәләре, Төньяк Кытайда чик сак-

чылары булып хезмәт иткән татар җайдаклары арасыннан да гаскәр туплыйлар. Шуңа күрә бу гаскәрләрне тарихта «монгол-татарлар» дип яисә «татарлар» дип кенә атау урын алган.

Монголларны рухи яктан берләштергән төп көч безнең эраның I гасырында Төньяк-Көнчыгыш Һиндстанда барлыкка килгән һәм Махаяна исеме астында Тибетта, Монголия, Бурятия, Тува, Калмык илендә киң таралган төньяк буддизм (Будда дине) була. Махаянада «Тенгриләр патшалыгына сәяхәт» дигән бүлек бар. Ихтимал, әлеге «тенгри» сүзе безнең телдәге «тәңре» белән бәйледер. Монголларның үз язулары була. Ул уйгур язуы аша арамей язуының бер төренә барып тоташа. Хәрефләр уңнан сулга, өстән аска языла. Империянең хәлиткеч сәяси көче яхшы коралланган һәм оста оештырылган армиядән гыйбарәт була. Сәяси һәм дини хакимият аңа буйсына.

Дәшти Кыпчак монгол явы корбаннарының берсе була. Беренче монгол гаскәрләре Көнчыгыш Европа кыпчаклары иленә — Дон буйларына — Кавказ аша барып чыгалар. Кунчак ханның улы Юрий гаскәрләре аларга тиешле каршылык күрсәтә алмый. 1223 елда көньяк рус кенәзлекләренең күпмедер ярдәм күрсәтүләренә карамастан, Катян хан да җиңелүгә дучар була.

Көнчыгыш Европада монголларның юлы өстендә чираттагы дәүләт булып Идел буе Болгары кала. Шул ук 1223 елда монгол гаскәрләренең бер өлеше Идел Болгарының көньяк чикләренә килеп җитә һәм ике юнәлештә: көньяк-көнчыгышта Урал елгасындагы үткел аша һәм Түбән Иделдә Саксин шәһәр-ныгытмасы районында һөҗүм башлый. Идел буе Болгар дәүләте шундый оста оештырылган дәһшәтле хәрби көч белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очраша. Өстәвенә ул вакытта аның көчле хәрби союзниклары да булмый. Идел буе Болгарының төньяк рус кенәзлекләре белән шартнамәләрендә сүз бер-беренә һөҗүм итешмәү турында гына бара, алар һәр ике якка берьюлы тыштан гомуми куркыныч булуны күздә тотмый. Рус кенәзләре гомуми куркынычны Көнбатыш католицизмында гына (Ливония, Литва) күрәләр. Алар уйлавынча, монгол явы болгар җирләреннән һәм кыпчак далаларыннан ары китмәскә тиеш була.

Шуларга да карамастан, ул заманнар өчен яхшы коралланган Болгар армиясе каршылык күрсәтергә шактый ук

сәләтле булып чыга. Идел Болгарының идарәчесе Сәлим хан сәргаскәрлек осталыгын күрсәтә. Ул илнең чигенә үк барып оборона оештыра. Шуның өстенә Дәшти Кыпчактагы Сыгнак шәһәре һәм Харәземдә Үргәнеч өчен булган моңа кадәрге сугышларда монголлар гаскәре шактый йончыган була. Монголларның Болгарга 1223 елгы һөҗүме уңышсызлыкка очрый. Аларга үз гаскәрләрен башкача төркемләү, резервларны якынрак китерү һәм запасларны тулыландыру белән шөгыльләнергә туры килә.

Ул арада империянең үзәге Каракорымда да хәлләр үзгәреп китә. 1227 елда Чыңгыз хан, аннары Җучи дөнья куялар. Әмма илнең җитәкчелеге империячел сәясәттән баш тартмый. Чыңгыз ханның варисы итеп Үгәдәй хан игълан ителә. Идел Болгарына яу чабуда җитәкчелек Чыңгыз хан оныгы, куәтле сәрдар Батуга йөкләнә. Батуның кул астында 1236 елда ул вакытлар өчен саны һәм куәте ягыннан тиңе булмаган 150 мең сугышчы, шул исәптән менә дигән атлы гаскәр, инженерлык гаскәрләре, ярдәмче хуҗалыклар, гаскәрләр артыннан хәрәкәт итеп, ярдәмгә әзер торучы коралсыз халык — сугышчыларның гаилә әгъзалары тупланган була. Ул Урта Азиядәге Чыгытай улусы кебек ныклы тыл булдыра, шулай ук Ирандагы, Төньяк Кавказдагы, Азов диңгезе һәм Дон елгасы буйларындагы монгол частьлары белән тәэмин ителгән ян фланглар төзи.

Идел Болгары территориясендәге бәрелеш бик каты була. Ләкин 30 мең кешелек кенә гаскәр җыя алган Болгар иленең сугышчан хәле мактанырлык булмый. Бәрелеш аның җиңелүе белән тәмамлана.

Сәяси бәйсезлекне югалту. Сәяси бәйсезлекне югалту Идел буе Болгар иле тормышында җитди кыенлыклар китереп чыгара. Монголлар хакимлегенең беренче елларын галим А. Х. Халиков «Монголларның Болгар белән тоталь сугышы» чоры дип атый. Гаскәр һәм бөтен халык басып алучыларга бик нык каршылык күрсәтә. Монгол гаскәрләре илне зур корбаннар бәрабәренә, җирле шәһәрләрне һәм авылларны җимерү-яндыру бәрабәренә буйсындыралар. Халыкның кораллы каршылык күрсәтүе гамәлләре ил эченә күчкәч, монгол җәза отрядларының җимерү эшләре анда да башлана. Болардан тыш тагын монгол гаскәрләре өчен азык-төлек, терлек азыгын күпләп тартып алулар, ачыктан-ачык талаулар өстәлә.

Монгол гаскәр башлыклары басып алынган җирләрдә яңа хакимият органнарын оештыручылар булып китәләр. Мәсәлән, Урта Азияне яулап алу һәм анда хакимият урнаштыру Чыңгыз ханның улы Чыгытайга тапшырыла, һәм анда Чыгытай улусы оештырыла. Дәшти Кыпчак, Идел буе Болгары һәм рус җирләре Чыңгыз ханның икенче улы Җучигә бирелә. Монголия империясе составында тагын бер ил — Җучи улусы барлыкка килә. Идел буе Болгар иле дә шушы улус составына керә. Рус җирләре монголлар тарафыннан Идел буе Болгарыннан соң яулап алына. Рязань, Владимир кенәзлекләре һәм Новгородтан кала башка төньяк рус җирләре 1237—1238 елларда, Галич-Волынь җире 1241—1242 елларда үзләрен Монголия империясенең вассаллары итеп таныйлар. Алга таба монголларны Рим папасы хакимлегендәге католицизм берләштергән илләр территорияләре кызыктыра. Монголларның аерым гаскәрләре, бу илләрнең кайберләренә яу чабып карасалар да, аларда төпләнеп кала алмыйлар.

Идел буе Болгары һәм Җучи улусы. Беренчерәк вакытларда монголлар тарафыннан яулап алынган территорияләр турыдан-туры Монголия империясе составына кертелә һәм Каракорымнан торып идарә ителә. Гаскәр башлыгы Бату Монголиянең яңа провинциясендә хәрби идарәче итеп билгеләнә.

Әлеге җирле монгол администрациясе һәм Идел Болгары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә ачыклык һәм төгәллек булмый. Башта Батый хан үзенең резиденциясе итеп Болгар шәһәрен сайлый. Ул ислам хокукы буенча формалашкан дәүләт идарәсе системасын таратып ташламый, аны үзенә буйсындыра гына. Бу дәүләт системасы Батыйның хакимиятенә әверелми, башында Сәлим ханның улы әмир Илһам торган килеш, үзенең мөстәкыйльлеген саклап кала. Илһам, бәлки, Идел буе Болгарында илне идарә итүне дәвам итәргә мөмкинлек бирүче ярлык алган беренче әмир булгандыр. Батый хан администрациясен Болгарда урнаштыру максатыннан, дәүләт идарәсенең җирле системасы өчен Биләрдән төньягырак яңа биналар салырга карар бирелә. Ул бинаны Идел Болгары әмиренең яшәү урыны итү күздә тотыла.

Батый хан сәүдә һәм һөнәрчелекнең гамәлдәге шәһәр системасында да үзе өчен файда күрә. Дәрәҗәле хәрбиләрнең башбаштаклыгына алмашка чагыштырмача тәртип урнаш-

тырган оккупация режимы килә. Җимерелгән Болгар шәһәре өлешчә торгызыла. Монгол хакимияте һәм гаскәре өчен биналар төзелә.

Җучи улусының башкаласы Иделнең түбәнге агымына — яңа төзелгән Сарай-Бату шәһәренә күчкәч, Идел буе Болгары иркенрәк сулыш ала башлый. Әмир Биләрдән Болгарга әйләнеп кайта. Ләкин Биләр, икътисади һәм мәдәни үзәкләрнең берсе буларак, әһәмиятен югалтмый. Тарихчылар билгеләп үткәнчә, Биләр әмирлегенең идарәчесе Илһам ханның улы Алимбәк була. Соңгысы вафат булганнан соң, 1260—1270 елларда Биләрне Бүлемшах ибне Алимбәк идарә итә. Болгарда: «Бүләртай ибне Бүлемшах әмир, 1323 елда вафат булды» дип язылган эпитафия әле дә булса сакланган. Мөгаен, ул кайчандыр хан булып та торгандыр. Илдә турыдан-туры талаулар тукталса да, Батый хан хакимияте салымнары халыкның көче җитмәс дәрәҗәдә зур була. Округларда салым (ясак) җыю өчен махсус баскаклар билгеләнә, ә аларга ярдәмгә шәһәрләрдә гаскәри частьлар тотыла. Батый хан Русьта да шундый ук ясаклы-буйсындырулы идарә урнаштыра.

Батый хан идарә иткән Җучи улусы составына Көнчыгыш һәм Көнбатыш Кыпчакстан, башкаласы Үргәнеч булган Харәзем, төрки-угызлар территориясе, Иделнең түбән агымындагы Нугай даласы да керә.

Күренекле дәүләт эшлеклесе Батый хан булачак Алтын Урда дәүләтенең хокукый нигезләрен сала. Батый ханның сәяси карашы универсаль дәүләт турындагы монгол идеясе кысаларында формалаша. Бу идея нигезендә беренче урында хокукый башлангыч — хокук нигезендә буйсындыру ята. Будда диненең монгол вариантына табынган Батый хан дини хискә нык бирелгән тәкъва кеше була. Ләкин дәүләт эшләрен мөстәкыйль төстә алып бара. Монгол буддизмын ул беркемгә дә көчләп такмый, дин ирекен таный.

Алтын Урда дәүләтенең формалашуы. XIII гасырның 60 нчы еллары башыннан Монголия империясе аерым дәүләтләргә бүленә башлый. Аңардан аерылып чыккан улуслар мөстәкыйль дәүләтләргә әверелә. Җучи иле, мөстәкыйль Алтын Урда дәүләте буларак, Батый ханның улы Бәркә хан вакытында формалаша. Дәүләти-хокукый планда Алтын Урда нигездә өч өлештән тора. Кыпчаклар иле «нигез» территория буларак формалаша һәм Түбән Идел буе улусы (Нугай улусы), Азов буе (Дон буе улусы) һәм Кырым кебек

өч улуска бүленә. Идел буе Болгар дәүләте һәм Мәскәү Русе (шулай ук Галич Русе) Алтын Урдага «кушылган улуслар» сыманрак территорияләр булалар. Дәүләтне диктатор вәкаләтләренә ия булган һәм монгол аксөякләре съезды (корылтае) тарафыннан сайланып куелган хан идарә итә. Тармак диваннары идарә органнары булалар. Аларның эшен хөкүмәт башлыгы вәзир җайга сала. 1260 еллар тирәсендә Сарай-Бату шәһәреннән ерак булмаган урында дәүләтнең яңа башкаласы Сарай-Бәркә үсеп чыга. Сарайчык, Үкәк, Саратов (Сарытау), Хаҗитархан (Әстерхан), Гөлестан, Маҗар (Төньяк Кавказда), Азак (Азов) — шундый ук зур шәһәрләр булалар.

Европадагы кыпчаклар даласы күчмә терлекчеләр җире генә түгел, ул игенчелек алга киткән һәм шәһәр мәдәнияте чәчәк аткан һөнәрчелек белән сәүдә нык үскән цивилизацияле ил була. Кыпчаклар иле, кыпчак халкы тарихын һәм килеп чыгышын өйрәнүче атаклы белгеч П. В. Голубовский кыпчакларны бик борынгы мәдәнияте булган халык дип атый. Н. М. Карамзинның аларны «ару-талуны белмәс явызлар» дип тасвирларга, ай-һай, төпле нигезе булдымы икән?! Алтын Урда дәүләте оешу белән кыпчаклар дәүләт төзелешенең яңа системасына ия булалар. Сарай хакимияте астында идарәне үзәкләштерү гамәлгә ашырыла. Тарихчыларның күпчелеге, Бәркә хан дәүләт төзелешендә, дәүләт хокукы кануннарына нигезләнеп, Батый хан юлын дәвам итә, дигән карашта тора. Хәлбуки бу дәүләт хокукы җирле халыкның рухи һәм психологик халәтен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Алтын Урданың Бәркә ханнан соңгы тарихында уңай эз калдырган кеше Туктай хан була (1291—1313). Рус чыганакларында ул «хакимлек сөюче көчле» шәхес һәм бер үк вакытта «гадел хөкемдар һәм теләсә кайсы диндәге кешеләргә тигез караучы» итеп тасвирлана. Монгол ханнары нәселеннән булган кешеләр арасында дәүләтне хокукый идарә итү сәясәтен, шулай ук илне социаль-икътисади һәм мәдәни яктан үстерүне дәвам иттерүчеләрнең берсе итеп Үзбәк ханны (1313—1341) күрсәтергә мөмкин. Ул төркиләр (кыпчаклар) гаиләсендә туа. Аның ата-аналары христиан (несториан) динен тота. Ул ханлык иткән вакытта ислам Алтын Урданың рәсми дәүләт диненә әверелә. Тарихчылар шул вакыттан башлап кыпчакларның һәм бу тирәләрдә утырып калган монголларның исламга таба йөз тотулары шактый көчәйгән дип билгеләп үтәләр. Төрки болгарлар һәм төрки кыпчакларның тел

берлеге икътисади һәм рухи-психологик якынаю белән ныгытыла.

Үзбәк хан православиене яклавы белән дә аерылып тора. Аның Алтын Урдада яшәүче русларның эшен бары тик православие динендәге митрополит кына карарга тиеш дигән указы билгеле. Бу указда православие чиркәвен мәсхәрәләгән өчен җинаять җаваплылыгына тарту каралган. Үзбәк ханның улы Җанибәк хан 1342—1357 елларда илне шундый ук рухта идарә итә. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута (1304—1377) XIV гасыр урталарындагы Дәшти Кыпчакның җентекле тасвирламасын калдырган. Хан сараен ул «Алтын таш» дип атый. Аның сүзләренә караганда, ул очына алтын ярымай куелган гаять зур гөмбәзле, ян-ягына манаралар утыртылган мәһабәт таш бинадан гыйбарәт була. Кабул итүләр өчен хезмәт иткән Зур залда тәхет урнаштырылган, ә тәхет артына дәүләт әләме эленгән була. Ибне Баттута Гөлестан, Үкәк, Бәлҗәмин, Хаҗитархан (Әстерхан), Маҗар, Азак, Су-Даг, Кара Феодосия, Кырым-Солхат, Аккирмән кебек сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләре булган күп кенә шәһәрләрне телгә ала. Илнең нык үскән акча системасы: бакыр, көмеш, хәтта алтын акчалары була. Үзенең таможня системасы (тамгачылары) эшли. Сарай шәһәре үзе, Баттута фикеренчә, Хәзәр каһанлыгының үзәк шәһәре Итилне хәтерләтә: урамнарында җанлылык хөкем сөрә; халкы күп, алар төрле диннәргә табыналар. Биредә кыпчак, болгар, монгол, черкаслар яши, мөселманнар, христианнар, буддилар очрый. Бик матур мәчетләр белән янәшәдә үк — чиркәүләр, будди храмнар. Сәүдә үзәгендә Мисыр, Иран, Гыйрак, Сүрия, Русь кебек төрле илләрдән килгән сәүдәгәрләр сату-алу иткән.

XIII—XIV ГАСЫРЛАРДА ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫНДА ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШ

Сәяси структура. Идел буе Болгарында иҗтимагый тормыш, элеккечә үк, шәригать кануннары белән җайга салына. Баш казый карамагында булган шәригать мәхкәмәсе (суды) эш итә. Ислам учреждениеләре, руханилар һәм дин белгечләре эшчәнлеге элеккечә дәвам иттерелә. Идел буе Болгарының халыкара хәле һәм аның ислам дәүләтләре белән бәйләнешләре дә тотрыклы саклана.

Әмма хакимият структураларын һәм аны гамәлгә ашыру ысулларын монгол дәүләт хокукы нормаларына якынайту юнәлешендә үзгәрешләр күзәтелә. Формаль рәвештә, Идел буе Болгарында Коръән күрсәтмәләренә буйсынучы хан җирле хакимияте калдырыла. Ә югары хакимият Болгар ханына «хакимлеге турында» ярлык, ягъни рөхсәт язуы бирүче Алтын Урда ханы кулына күчә. Шулай итеп, Болгар ханы дини (Коръән) һәм дөньяви (Урда ханы ярлыгы) хокук нормаларына таяна. Хәзер ул дәрәҗәсе буенча да Алтын Урда ханыннан түбәнрәк тора. Аны еш кына әмир дип кенә атый башлыйлар, чөнки аның өстеннән Аллаһы Тәгаләдән тыш тагын Алтын Урда ханы кулы астында берләштерелгән дәүләтнең дөньяви башлыгы да тора.

Яулап алынган территорияләр белән мөнәсәбәтләрендә монголлар римлылар принцибына таяна: буйсынучының үз гамәлләрендәге мөстәкыйльлеге аның Урда ханы ярлыгында бәян ителгән күрсәтмәләргә һичсүзсез тулысынча буйсынуы белән ярашырга тиеш була. Урда ханы ярлыгын Л. Н. Гумилев бәйлелек билгесе итеп түгел, бәлки дуслык һәм һөҗүм итешмәү турындагы акт дип күрсәтә. Урдадагы хәлне шәрехләп: «Урда һөҗүм итү белән куркытып, дәүләт эчендәге җирле этносларның башында тора»,— дип яза ул. Ярлык күрсәтмәләрен үтәмәү очраклары, бигрәк тә еллык ясакны үз вакытында һәм тулы күләмендә тапшырмау очраклары булганда, гаепләләр җәзага тартыла, аларга карата хәтта корал да кулланыла.

Әмир сараеның турыдан-туры идарәсендә Идел Болгарының үзәк өлеше — Болгар, Биләр, Суар, Җүкәтау, Кашан, Шонгыт, Казан, Наровчат шәһәрләре һәм алар тирәсендәге җирләр кала. Ил читендәрәк урнашкан кенәзлекләргә (нигездә фин-угор кенәзлекләренә) карата Болгар әмире Алтын Урданың югары хакимияте күрсәтмәләрен үтәүче буларак эш итә, Урда өчен ясак җыюда һәм гомумдәүләт тәртибен тәэмин итүдә җирле кенәзләргә ярдәм күрсәтә. Икенче төрле әйткәндә, Идел буе Болгары составына кергән фин-угор кенәзлекләре билгеле мохтарияттән (автономиядән) файдалануларын дәвам иттерәләр. Габдулла әмиргә кадәр булган идарәчеләр дә шушы тәртиптә идарә итәләр.

Яңа җирләр үзләштерүне дәвам итү. Сәяси мөстәкыйльлекне югалтуына карамастан, Идел буе Болгар дәүләте илдә социаль-икътисади тормышны яңарту процессын туктатмый.

Моның нигезендә халыкның максатчыл хезмәт сөюе, теләсә нинди шартларда да, хәтта сугыш китергән җимереклекләр, бүтән төбәкләргә күченеп китәргә мәҗбүр булуларга карамастан, үз тормышын җайга салырга омтылуы ята. Өстәвенә яңа дәүләт — Алтын Урда яшәвенең беренче йөз елында, илдә хокукый тәртип урнаштыру турында кайгыртып, илнең аерым төбәкләре арасындагы, илләр арасындагы бәйләнешларның үсүенә, яңа җирләр үзләштерүгә булышлык итә. Идел буе Болгары өчен бу Казан тирәсендәге җирләрне һәм Идел, Казансу һәм башка елгалар бассейннарының шәһәргә якын булган районнарын интенсиврак үзләштерүне аңлата. Казан Идел буе Болгарында гына түгел, бөтен Алтын Урдада иң зур сәүдә-икътисади үзәкләренең берсенә әверелә. Бу төбәктә Кирмән (Идел буйлап югарыга), Кашан (Камада), ә төньяк-көнчыгыштарак Нырса, Урмат шәһәрләренең булганлыгы билгеле. Мукшы елгасының уңъяк ярындагы көнбатыш җирләр, Мукшы һәм Цна елгалары кушылган урын, Донның кыпчаклар яши торган төбәкләренә турыдан-туры чиктәш булган Пьяна елгасы бассейны һәм Сура елгасының түбәнге агымы интенсив рәвештә үзләштерелгәннәр. Археологлар бу төбәктә Мухша, Юлово һәм башка шәһәр калдыкларын табалар. Урта Иделнең һәр ике ярындагы, Зөя елгасы буендагы җирләр яхшырак үзләштерелә. Аларда Шонгыт, Әтрәч, Карабулак, Кәкриш, Сембер шәһәрләре үсеп чыга. Самара һәм Кинель елгалары кушылган урында Самара шәһәре күтәрелә.

Көнчыгыш юнәлештә — Вятка, Кама, Агыйдел ярларындагы торак пунктларында — халык тыгызрак утыра башлый. Мамадыштан ерак түгел урнашкан Кирмәнчек шәһәренең, Каманың уңъяк ярындагы Алабуга, сулъяк ярындагы Чаллы шәһәрләренең әһәмияте арта.

Икътисад. Алтын Урда чорында моңа кадәр дә хуҗалыкның төп тармагы булган авыл хуҗалыгы тагы да зур үсеш ала. Кама аръягының кара туфраклы уңдырышлы җирләренә яңа үзләштерелгән төбәкләрнең балчыклы һәм көлсу туфраклы җирләре кушыла. Игенчеләргә бу җирләрдә бөртеклеләрне үстерүнең яңа технологиясен үзләштерергә, авыл хуҗалыгы коралларын камилләштерергә туры килә. Илдә башлыча бодай, тары, арпа, солы игәләр, басуларда арыш һәм кузаклы культуралар (борчак, ясмык) күренә башлый. Техник культуралардан җитен һәм киндер үстерәләр. Археологлар, кыяр һәм алма орлыклары табып, бу җирләрдә яшелчәчелек һәм

бакчачылык та булган, дигән нәтиҗәгә киләләр. Йорт хайваннарыннан сарык һәм кәҗә асралган, ә соңга табарак сыер да асрый башлаганнар. Терлек көтүендә атлар саны чагыштырмача кими. Хуҗалыкларда дөяләр, шулай ук авыр эш өчен файдаланыла торган үгезләр асралуы да билгеле.

Шәһәр хуҗалыгы һөнәрчелектән һәм сәүдәдән гыйбарәт була. Һөнәрчеләр күн иләгәннәр, тукыма тукыганнар, йон басканнар, шулай ук металл эшкәртү киң җәелгән. Бу эшләнмәләрнең сыйфаты торган саен яхшыра, ассортимент киңәя барган. Күп кенә археология табылдыклары шул турыда сөйли. Җүкәтау ювелир әйберләр хәзинәсе, Карашәм хәзинәсе, илнең үзендә һәм чит илләрдә сугылган акча тәңкәләр хәзинәләре шактый бай табылдыклардан санала. Алтын Урданың акча сугу йортларының берсе ул чагындагы Идел буе Болгары территориясендә, Мухша (Наровчат) шәһәрендә була. Иң зур акча берәмлеге булып сум йөри (1 сум — 200 грамм авырлыктагы көмеш коелма; ул бәһасе буенча 20 алтын динарга һәм 120 көмеш дирһәмгә тигез була). Акча әйләнеше, нигездә, дәүләтара сәүдәдә күзәтелә. Болгарның эчке базарында (илнең читтәрәк урнашкан төбәкләрен дә кертеп), башлыча, алмашу сәүдәсе (меновая торговля) киң таралган була. Идел буе Болгары халыкара сәүдәгә элеккечә киң күләмдә тартыла. Ул читкә традицион товарлар: ашлык, хайваннар, һөнәрчелек товарлары, ювелир эшләнмәләр чыгара. Читкә чыгару өчен мехны болгар сәүдәгәрләре төньяк дәүләтләрдән алалар. Ибне Баттутаның раславына караганда, бу максат өчен алар әлеге илләрдә «тукталу урыннары» (факторийлар) булдырганнар. Иң кыйммәтле мех булып ас тиресе, аңардан кала — кеш мехы саналган.

Болгар товарлары кыпчак һәм рус җирләрендә дә киң кулланылган. Көнчыгыш базарларына болгар сәүдәгәрләре инде мәгълүм булган Кытай сәүдә юлы белән: Урта Азия, Монголия, Кашгар, Иран аша үтеп барып чыгалар. Гурилар династиясе вәкиле Котб әд-Дин тарафыннан нигез салынган Дәһли солтанлыгы базарлары да үзләштерелә.

Идел буе Болгары Көнбатыш белән сәүдәсен Киев Русеннан үтүче (көньякка — Византиягә, көнбатышка — Болгариягә, Венгриягә, Италиягә, Рейнга, Балтыйк буена) кәрван юлы аша тормышка ашыра. Көнбатыш һәм Скандинавия белән сәүдә бәйләнешләре Коми, Югра кебек төньяк җирләре аша алып барыла.

Ул вакытларда халыкара сәүдә сәяси багланышларны җайга салуда һәм ныгытуда мөһим роль уйный. Еш кына шул ук миссияне Болгардан Мәккәгә һәм Мәдинәгә хаҗ кылырга баручы мөселманнар башкара. XIII—XIV гасырларда, мәсәлән, Идел буе Болгарының Мисыр белән багланышларының дипломатик каналы сәүдә юлы буенча башкарыла. 1330 елда Идел буе Болгар дәүләтенең илчелеге Каһирәгә килә һәм солтан Ән-Насыйрга Болгар әмиренең хатын тапшыра. Бу хатта әмир Мисыр солтаныннан изге ислам байрагы җибәрүен үтенә. Бу байрак Идел Болгарының, гәрчә ул Алтын Урда составына кертелгән булса да, мөстәкыйль ислам иле икәнлеген күрсәтергә тиешле символ була. Идел буе Болгарының Мисыр белән багланышлары моңа кадәр үк, Мисырда хакимият башына мәмлүкләр килгән вакыттан (1250—1381) ук башланган булырга тиеш, дигән фикер бар. Мисырдагы солтаннарның берсе Бибарс чыгышы белән Болгардан була. А. Х. Халиков фикеренчә, бу кушма исемнең бер компоненты (барс) безнең борынгы бабаларыбыз кабиләләреннән берсенең, ә соңрак, гомумән, болгарларның тотемнары (барс) белән бәйле булган һәм тора-бара болгарларның гербларына әверелгән.

Мәдәният. Рухи мәдәният (мәгърифәт һәм фән, матур әдәбият һәм сәнгать) таянган кыйммәтләр ике чыганакка нигезләнә: халыкның традицияләрдә, гореф-гадәтләрдә ныгып калган тормыш тәҗрибәсенә һәм үткән гасырлар дәвамында җирле халыкның холык-фигыленә, яшәү рәвешенә яраклашырга өлгергән ислам идеологиясенә. Болгар дин әһелләре сөнни юнәлешне яклый, дин нигезләрендә һәм гадәтйолаларында күбесенчә Бохарага таяна. Әмма тормышта бу якларда урнашкан ислам Бохара исламыннан, гомумән, Көнчыгыш исламыннан үзенең халыкчанлыгы һәм мәгърифәтлерәк булуы белән аерылып тора. Болгарда, мәсәлән, хатын-кызлар кимсетелгән хәлдә булмыйлар. Балаларга, шул исәптән кыз балаларга, аң-белем бирү саваплы эш санала. Өлкәннәрнең укый-яза белүләре, гореф-гадәтләрне ихтирам итүләре хуплана.

Идел буе Болгарында башка диндәгеләргә кимсетүле караш сизелми, һәм Алтын Урданың да шундый ук сәясәт алып баруы күзәтелә. Дөньяви белемгә ия булу (укый, яза, исәпли белү) мактаулы эш санала. Мөселман руханилары дөньяви хакимиятнең көндәлек эшләренә катнашмасалар да,

тәкъва идарәчеләрне (дин кушканча эш итүче хакимият әгъзаларын) ярдәмнәреннән ташламыйлар.

Ислам дине әдәбиятка, сәнгатькә, шул исәптән сынлы сәнгатькә дә каршы булмый. Дөрес, шәмаилләрне мөселманнар өчен мөкатдәс булган нәрсәләр белән генә бизәргә рөхсәт ителә. Кулдан язылa торган китаплар орнаментлар белән генә түгел, кеше һәм хайван сурәтләре белән дә бизәлә.

Идел буе Болгарында киң таралыш тапкан гарәп-ислам фәне XI—XII гасырларда яңа ачышлар белән баетыла. Табиб, галим, философ Әбүгалисина (980—1037 еллар тирәсе) исеме ихтирам белән телгә алына. Фәнни даирәләрдә һәм язучылар-әдипләр арасында гарәп табибы һәм философы Ибне Рөшднең (1126—1198) идеяләре киң таралыш таба. Рөшд белемнең ике төрле чыганагын: рухи чыганакны (дин аша) һәм рациональ чыганакны (фән аша) таный. Болгарлар югары белемне Бохара, Нишапур, Сүрия, Мисыр мәдрәсәләрендә алалар.

Идел буе Болгарында мәдәниятнең югары дәрәҗәдә булуын күп кенә галимнәр билгеләп үтә. Көнчыгышны өйрәнү буенча атаклы галим В. В. Бартольд, Идел буенда «диварлары мәрмәр һәм чынаяк кирпечләр белән капланган йорт калдыклары, сууткәргечләр, кабер өстенә куела торган ташлар, көмеш савыт-саба ватыклары, парта, Венеция пыяласы XIII—XIV гасырларда болгарлар тормышы турында, шулай ук аларның Көнчыгыштагы һәм Көнбатыштагы башка халыклар белән үзара мөнәсәбәтләре хакында сөйлиләр», дип яза. Үз чиратында, Шиһабеддин Мәрҗани XIII гасырда төзелеп XIV гасырда төзекләндерелгән зиннәтле Җамигъ мәчетен тасвирлый. Болгар шәһәрендә салынган бу мәчетнең дүрт почмагында дүрт манарасы һәм 73 баскыч биеклегендәге бераз гына читтәрәк тагын бер манарасы була. Әлеге манара 1841 елда авып төшә, әмма аның сурәте П. С. Палласның «Россия дәүләтенең төрле провинцияләре буйлап сәяхәт» (1773) дигән китабында автор үзе ясаган рәсемнәрдә сакланып кала. Галимнәр, XIV гасырда Касыйм шәһәрендә салынган һәм бүгенгәчә сакланган Хан мәчете манарасы буенча Болгар Җамигъ мәчетенең әлеге манарасын күз алдына китереп була, дигән фикердә торалар. Әлеге манара цилиндр рәвешендәге зур таш корылмадан гыйбарәт. Болгарда сакланып калган Кече манара да Касыймдагы Җамигъ мәчете манарасына охшаш. Дөрес, соңгысы түбән өлешендә дүрт почмаклы булып, югары таба гына цилиндр рәвешен ала. Шиһабеддин

Мәрҗани шулай ук Идел Болгарындагы мунчаларны, 16 метр биеклектәге манарасы булган мавзолейлар комплексын тасвирлап калдыра.

Идел Болгары мәдәниятенең язма истәлекләре кулъязма китаплардан һәм зур кабер ташлардан гыйбарәт. 1872 елда Шиһабеддин Мәрҗани Спас өязе Ташбилге авылы зиратындагы өч кабер ташының язуын беренче булып укый алган. Бу язуларның берсенә 745/1344 дип датасы куелган һәм «Энбел углы Хөсәен» дип язылган. Мәрҗани шулай ук Иделнең уңъяк ярында 1302—1346 елларда язылган кабер ташларындагы язуларны укып бирә. Безнең елларда кайбер кабер ташларындагы XIII гасырга караган эпитафияләрне Г. В. Юсупов һәм Ф. С. Хәкимҗановлар укыды.

Галимнәр Сарай шәһәренең күп кенә төрки илләрдәге укымышлыларны, шагыйрь һәм язучыларны үз тирәсенә туплаган атаклы мәдәни үзәк булганлыгы турында әйтәләр. Монда аеруча Идел буе Болгарының фән һәм мәдәният көчләре тупланган була. Сарай шәһәрендә мәдәният, рухи тормыш өлкәсендә (исламны кабул итү, мәчетләр салу һәм аларда гыйбадәт кылуны оештыру, мәдрәсә, фән, әдәбият һ. б.) нинди генә әһәмиятле вакыйга булмасын, аларның һәркайсында Идел буе Болгар дәүләте зыялылары турыдан-туры катнашкан. Әрмән-кыпчак кулъязмалары да (суд актлары, исәп-хисап кенәгәләре, елъязмалар, сүзлекләр һ. б.) Идел буе Болгары тарихын өйрәнүдә билгеле бер кызыксыну уяталар. Кыпчак җирендә һәм Алтын Урдада яшәгән һәм кыпчак телен үзләштергән әрмәннәр тарафыннан язылган бу чыганаклар, И. А. Абдуллин язганча, XI—XVI гасырларга, ә кайберләре XVI—XVII гасырларга карый. Поляк галиме Дж. Клозон исә бу кулъязмаларның әрмән-григориан динен кабул иткән кыпчаклар тарафыннан язылган булу мөмкинлеген дә кире какмый.

Шиһабеддин Мәрҗани Болгарның үзендә генә түгел, Сарайда, Бохарада яшәп иҗат иткән күп кенә Алтын Урда чоры болгары авторларының хезмәтләрен бик җентекләп бәяләп чыга. Сарайда 1357 (759) елда язылган «Нәһҗел-фәрадис» дигән китабы белән Мәхмүд бине Гали әс-Сараи Болгар историографиясендә билгеле эз калдыра. Тарихчы һәм философ буларак, Мәхмүд әс-Сараи пәйгамбәрләр, хәлифәләр һәм имамнар тормышы мисалларында үз чорының әхлак проблемалары турында яза һәм үзенең карашларын «оҗмахка

ачык юл» дип билгели. Үзе ул Болгар шәһәрендә туа, Кардәрдә (Харәзем) булгалый, соңрак Сарайда яшәп иҗат итә. Ә соңыннан Болгарда, Чирмешән елгасы буенда дөнья куя. Шул ук Сарай шәһәрендә Хисам Кятиб үзенең «Җөмҗөмә солтан» дигән фәнни-дидактик хезмәтен иҗат итә.

Алтын Урда Төрки каһанлыгы, Хәзәр каһанлыгы һәм Кара диңгез буе Болгар дәүләте белән чагыштырганда Идел буе Болгарын үзенә күбрәк «сеңдерә». Идел буе болгарлары һәм кыпчакларның социаль-иҗтимагый өлкәдә һәм мәдәният өлкәсендә үзара хезмәттәшлекләрен киңәйтә, Урта Идел һәм Урал буе мәдәниятенең яңа дәрәҗәгә күтәрелүе өчен юл ача. Бу чорда сәясәт өлкәсендә дәүләт төзелешенең бөтенләй яңа баскычына — татарларның милли дәүләтен төзүгә кучү өчен шартлар хәзерләнә, мәдәният өлкәсендә — киләчәктә иске татар теленнән формалашуы өчен, татар әдәбияты (сүз сәнгате) үсеше өчен ныклы нигез булдырыла.

Мәсәлән, Котбның Сарай шәһәрендә язылган «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы — шул чорда иҗат ителгән гаҗәеп әдәби җәүһәрләрнең берсе. Кулдан язылган бу китап Париж Милли китапханәсендә саклана. Котб Идел буе Болгар дәүләтенең көнбатыш җирләрендә — Иделнең уңъяк ярында 1297 еллар тирәсендә туа. Сарайда яши һәм чама белән 1353 елда вафат була. Эчтәлеге белән Котбның бу поэмасы, Азәрбайҗан шагыйре Низаминың (1141—1204) фарсы телендә язылган «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын хәтерләтсә дә, иске татар телендә язылган оригиналь әсәр булып тора. Нәваиның (1441—1501) иске үзбәк телендә (чыгытай телендә) язылган «Фәрхад вә Ширин» поэмасыннан элегрәк дөнья күрә. Поэма Алтын Урда ханы Җанибәкнең (Танибәкнең) хатыны Мәликәгә багышланган. Әсәрдә җирле тормыш һәм көнкүреш аеруча оста сурәтләнгән.

Шагыйрь Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» поэмасы (1391 елда язылган) аеруча игътибарга лаек. Сарай шәһәрендә шулай ук Харәземнән килгән Әл-Харәзми кебек олуг әдип тә иҗат итә. Бөекбритания музеенда аның иске төрки телдә язылган «Мәхәббәтнамә» дигән китабы саклана. 1245 елда төзелгән «Төрки-гарәп сүзлеге» һәм Насретдин Рабгузыйның 1310 елда язылган «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») әсәре дә Сарайда дөнья күрә.

Урдада болгавыр чор һәм аның нәтиҗәләре. XVI гасырның 60 нчы елларыннан башлап Алтын Урдада социаль-сәяси

вазгыятьнең үзгәрүе күзәтелә. 1357 елда Сарайда Үзбәк ханның улы, илне аңардан соң идарә иткән Җанибәк хан үтерелә. Зур Урда династиясе (Көнбатыш кыпчак-татар династиясе) белән Кече Урда династиясе (Көнчыгыш мангыт-кыпчак династиясе) арасында көчәеп киткән ызгыш-низаглар бөтен дәүләт системасын пыран-заран китерә. Бу низагларның орлыгы әле Батый хан исән вакытта ук сибелгән була. Башкаласы Сыгнак (хәзерге Кызыл Урда шәһәреннән көнбатышта) булган һәм күбесенчә мангыт-кыпчаклардан торган Дәшти Кыпчакның Азия өлеше Җучиның икенче улы Ирән ханга тапшырыла һәм ул территория мөстәкыйль Урда (Кече Урда) итеп танылa. Ызгыш-талашларга ул вакытта әле урда статусына ия булмаган Нугай җирләренең сәяси көчләре дә килеп кушыла. 1361 елда династияара аерымлану көрәшен башлап йөрүчеләрнең берсе Булат Тимер зур гына төркем гаскәре белән, башбаштакланып, Сарайдан Болгарга яу чаба һәм биредә хакимиятне үз кулына алуга ирешә. Ул Идел Болгарын үзенең терәгенә әверелдерергә ниятли. Әмир Габдулла үтерелә. Бу хәл гамәлдәге дәүләт хокукын тупас бозу адымы була. Булат Тимер явы нәтиҗәсендә Болгар зур зыян күрә. Хәлбуки, Булат Тимернең хакимлек итүе озакка бармый. Алтын Урда династиясе Болгарда яшәп китә алмый. 60 нчы елларның азагында Булат Тимерне алыштырган әмир Хәсән тәхеттә Болгар династиясен торгыза. Аның эшен соңрак әмир Мәхмүд һәм әмир Габдулла II дәвам итә. Идел Болгары бу кризистан чыга һәм ярлык нигезендә автономияле идарә итү тәртибенә кире кайта. Болгар шәһәре торгызыла. Ә Алтын Урдага килгәндә исә ул «буталчыклык», «тәртипсезлек» хөкем сөргән заманнарга, ягъни болгавыр чорга керә.

Болгавырлыкның сәбәбе Сарайдагы үзара тарткалашуларда гына дип әйтү дөрес булмас. Алтын Урда составына кергән дәүләтләр ныгыйлар, һәм аларга Алтын Урданың кирәге калмый. Алай гына да түгел, сәяси яктан буйсынган хәлдә яшәү һәм ясак түләп тору аларның милли абруена суга.

1380 елда Алтын Урда тәхетенә Җучи нәселеннән булган ханнарның иң активларыннан берсе Туктамыш хан утыра һәм Сарайда тәртип урнаштырырга, буйсынмаска теләгән территорияләрне тыңлатырга һәм Алтын Урданың халыкара абруен күтәрергә вәгъдә итә. Элегрәк Кара диңгез буе җирләрен идарә иткән, аннары Мәскәүгә каршы походта уңыш-

сызлыкка очраган Мамайның буйсынудан чыккан гаскәрләрен бастыра. 1382 елда Туктамыш хан үзе дә Мәскәүгә каршы яу белән чыга.

Алтын Урда чикләренә якын торган төрки илләрдә тагын ике сәяси эшлекле — әмир Тимер (Тамерлан) һәм солтан Баязит — сәяси амбициягә биреләләр. Хәзерге Үзбәкстан җирендә әмир Тимер 1370 елда башкаласы Сәмәрканд булган куәтле Тимериләр дәүләтенә нигез сала. 1389 елда госманлылар дәүләте тәхетенә Елдырым Баязит солтан утыра. Бу өч шәхес сәяси яктан көндәшләр булып кына калмыйлар, сугыш кырында да көч сынашалар.

1391 елның июнендә Иделнең сулъяк ярында Самара борылышы янында әмир Тимер белән Туктамыш хан арасында иң зур бәрелешләрнең беренчесе була, ләкин ул әле каршы торуның ни белән бетәчәген хәл итми. 1395 елда Туктамыш ханның әмир Тимер белән икенче бәрелеше була, һәм Туктамыш хан җиңелүгә дучар ителә. Бераз соңрак 1402 елда Тимер Баязитны да җиңә.

Казанның күтәрелүе. Илнең сәүдә-икътисади һәм сәяси тормышында Казан әмирлегенең стратегик яктан зур әһәмияте XII гасыр азагында — XIII гасыр башларында аеруча ачык күренә башлый. Казанның географик яктан уңайлы урыны Идел буйлап халыкара сәүдәдә Болгарның өстенлеген тәэмин итә. Никон елъязмасында Казан ике тапкыр: 1230 һәм 1236 елларда «Казан дип аталган бөтен Болгар җире» («Вся Булгарская земля, именуемая Казанью») рәвешендә телгә алына, ягъни Казан Болгарның төп шәһәрләре рәтенә кертелә.

Казанның чын-чынлап күтәрелүе илнең эшлекле активлыгы Төньяк-Көнбатышка: Җүкәтауга, Кашан, Кирмәнчек һәм Казанга күчкән вакыттан, XIII гасыр азагыннан башлана. Сарай һәм Русь Казанның, димәк, бөтен Болгарның күтәрелүен зур хөсетлек белән күзәтәләр. 1277—1278 елларда Ростов кенәзе Федор Черныйның (Черемнойның) Урда ханы Минтимер (Мәнгү Тимер) кушуы буенча Казанга җимергеч яу белән йөрүе, мөгаен, очраклы хәл булмагандыр. Ул чакта Казан Кремленең таш диварлары җимерелә, Кремль һәм шәһәр үзе талана, туздырыла. Шулай да бу хәлдән соң Казан сугыш яраларын тиз төзәтә. Рус гаскәрләренең Казанга чираттагы яулары 1376 елда була. 1399 елда, рус елъязмасында билгеләп үтелгәнчә, Казан шәһәренә тагын рус кенәзләренең явын кире

кайтарырга туры килә. Бу юлы әлеге һөҗүм кенәз Юрий Дмитриевич гаскәрләре тарафыннан ясала. Әмма Казан бу юлы да үзен саклап кала.

Болгар иле (1445 елга кадәр) һәм Русь (1480 елга кадәр), юридик яктан Алтын Урда составында булуларына карамастан, үзләрен шактый ук мөстәкыйль тоталар. Идел буе Болгары Сарайда булган ызгыш-талашларда бер якка да булышлык күрсәтми һәм Туктамыш ханның әмир Тимер белән бәрелешләрендә катнашмый диярлек. Шулай да илнең каршы торучы яклар армияләренең сугыш кыры булып әверелгән көньяк һәм көньяк-көнбатыш төбәкләре зур зыян күрә. Бу хәлләр Идел буе Болгар дәүләте башкаласын төньяк-көнбатышка — Казан әмирлегенә күчерүгә сәбәп була. Илнең яңа башкаласы булган Казан шәһәре кайчак Болгар әл-Җәдид дип, Яңа Болгар дип атап йөртелә. XIV йөз азагыннан һәм XV йөз башыннан алып чыганакларда илнең Болгар-Казан дәүләте дигән яңа исеме барлыкка килә.

Татарстан җире яңа чорга — татар дәүләтенең, тарихта Казан ханлыгы атамасы белән билгеле булган дәүләтнең оеша башлавы чорына керә.

Алтын Урда дәүләтенә тарихи бәяләмәләр. Тарихта Алтын Урда Кара диңгез буе Һун империясе, Кара диңгез буе Болгар дәүләте һәм Хәзәр каһанлыгы кебек дәүләтләр рәтендә үзенә тиешле һәм лаеклы урын алып тора. Әмма бу дәүләтне күп кенә авторлар монгол-татар яуларына бәйле рәвештә генә телгә алалар.

Әле күптән түгел генә Татарстан тарихы турында язганда «Болгар иле Алтын Урда изүе астында», «Шуның аркасында икътисад артта калган» кебек тапталган фикерләр очрый иде. Хәер, соңгы вакытларда, Р. Г. Фәхретдинов хезмәтләре басылгач, бу проблемага объектив якын килү үзен сиздерә башлады. Бүген күп кенә тарихчылар Алтын Урда дәүләтенең, анда булган болгавыр чорга кадәр, Көнчыгыш Европада тотрыклылыкны саклап калудагы әһәмиятен таныйлар.

Алтын Урда белән Идел буе Болгары арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм Алтын Урда дәүләтенең үзен ничек кенә бәяләсәк тә, тарихи ике фактны танымый мөмкин түгел: 1. Алтын Урда дәүләте яшәвенең беренче йөзьеллыгында (иң җаваплы йөзьеллыгында) бөтен бу территорияне тышкы экспансиядән, шул исәптән Русьны католицизм экспансиясеннән, ә Идел буе Болгарын рус экспансиясеннән саклап

килә. 2. Алтын Урда төркиләр, славяннар яшәгән бик зур зонада сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләрнең көчәеп китүенә булышлык итә. В. В. Бартольд: «...Монгол империясенең башлангыч дәвере барлык өлкәләрнең икътисади һәм мәдәни яктан чәчәк атулары чоры була. Бу өлкәләр иркен кәрван сәүдәсе нәтиҗәләреннән, шулай ук Көнбатыш һәм Көнчыгыш Азия арасындагы бу дәвердә тагы да үсеп киткән мәдәни багланышлар нәтиҗәләреннән файдалана алганнар»,— дип билгеләп үтә.

Алтын Урда һәм Идел буе Болгары арасындагы мөнәсәбәтләр катлаулы була, әмма беренче йөзьеллыкта алар уртак мәнфәгатьләрне кайгыртуга һәм Урда тарафыннан Болгар идарәчеләренә бирелгән ярлыкта (грамотада) күрсәтелгән уртак йөкләмәләрне үтәүгә нигезләнә. Бу документта Урдага ел саен бирелергә тиешле ясак (чыгым) микъдары күрсәтелә. 1257—1259 елларда илләрнең һәркайсында халык санын алу үткәрелә. Шуның нәтиҗәләреннән чыгып, еллык ясакның күләме билгеләнә. Ул илнең еллык керемен уннан бер өлешенә тигез була. Урда оккупацияне чагылдыручы хәрби гарнизон тотмый. Салым җыю өчен билгеләнгән кешеләрнең (баскакларның) бурычы асылда җирле идарәче кулына күчә. Бу соңгысы үзенең салым институтлары ярдәмендә Урда өчен салым җыеп тапшыра һәм моның өчен ул Сарай алдында җавап тота. Болардан тыш ярлык иясе илдәге тәртип өчен дә җаваплы була. Шушы максатларда ул үз карамагында махсус гвардия тота. Ләкин, шартнамә нигезендә, ул бу гвардияне башка максатларда файдалана алмый.

Алтын Урда. XIII г.



ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЕ

КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТЕ ФОРМАЛАШУ

Идел буе Болгарының дәүләт мирасын саклау. Алтын Урда чорында Идел буе татарлары милләтенең төп сәяси бурычы Идел буе Болгары мирасын саклап калу һәм шул нигездә Идел буе төрки татарларының мөстәкыйль милли дәүләте формалашуын тәэмин итүдән гыйбарәт була. Алтын Урда дәүләтенең таркалуы елларында бу бурычны хәл итү аерата кыенлаша. Сарайда хакимиятнең үлем газабы ярты гасыр диярлек дәвам итә. Һәр яңа хан хакимияткә кан түгеп килә һәм нәкъ шулай бәреп төшерелә. Сарайның соңгы рәсми идарәчесе Әхмәд хан тәмам чыгырыннан чыккан дәүләт системасын ныгытырга маташып карый, әмма уңышсызлыкка очрый. 1480 ел көзенең соңгы көннәрендә ул, «Угра елгасында каршы тору»дан соң Урдага буйсынырга теләмәгән Иван III гаскәрләренә һөҗүм итәргә җөрьәт итмичә, үз гаскәрләрен кире бора һәм 1481 елның гыйнвары башларында Ибәт хан (Ибәтулла) төркеме тарафыннан үтерелә.

Бу олы бурычны хәл итүдә Идел буе Болгарының тарихи традицияләрне саклаучы Болгар шәһәре тирәсендә тупланган көньяк төбәге һәм илнең киләчәге, аның өмете булып әверелә барган Казан шәһәре тирәсендә тупланган төньяк төбәге дә катнаша.

Билгеле бер этапта Сарайга Владимир кенәзлеге белән уртак тел табу һәм килешү мөмкинлеге булыр кебек тоела. Алтын Урданың берни эндәшмәвен үз гамәлләре белән ризалашуы һәм аларны хуплавы дип аңлап, Владимир кенәзе Василий I Сура елгасының түбәнге агымында, Идел буе Болгары чигендә Кормаш шәһәр-кирмәнен салып куя, ә 1392 елда Урда ханы Туктамыштан мишәрләр җиренең калган өлешен

дә үзенә кушу хокукын алуга ирешә. Ә бераз соңрак рус хакимияте бу җирләрдә үз буйсынуында булган Темников кенәзлеге һәм Касыйм ханлыгы оештыра.

Болардан тыш бу төбәктәге вазгыятьне катлауландырган тагын ике нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Илдә башланган чуалыш төрле җинаятьчел төркемнәрнең баш калкытуы өчен мөмкинлек ача. Ушкуйникларның Идел буе Болгары шәһәрләренә яу чабулары ешая. Ул болгавыр вакытлардагы ыгы-зыгыдан файдаланып, йомышлы кешеләрнең, яраннары һәм хезмәтчеләре белән бергәләп, Сарайдан башка дәүләтләр идарәчеләренә хезмәткә күчү очраклары күзәтелә. 1362 елда Подолияне Литвага кушканда, Литва идарәчеләре хезмәтендә күп кенә йомышлы татарлар кала. Соңрак аларның нәселеннән булган кешеләр Литвадагы татар диаспорасын тәшкил итәчәк. Галиция җирләренең Польша юрисдикциясенә күчүеннән соң бу җирләрдә төпләнеп калган йомышлы татарлар анда да татар диаспорасына нигез салалар. Үзәкләштерелгән рус милли дәүләтен төзүгә һәм моның өчен кирәкле куәтле армия булдыруга йөз тоткан рус кенәзлекләре йомышлы татарларны үз кулларына төшерү өчен аеруча тырышалар. Татар галимнәре (А. Х. Халиков һ. б.), шулай ук рус укымышлылары (Н. А. Баскаков) ерак бабалары үз вакытында Алтын Урдада югары дәрәҗәләргә ирешкән, ә болгавыр заманда рус кенәзлекләренә хезмәткә күчкән, соңыннан атаклы рус фамилияләрен йөрткән кешеләрнең, шул исәптән Годуновлар, Сабуровларның, татар нәсел җебен ачыкладылар. Мишәрләр илендә — Мещерада яшәгән Мәхмүд улы Бикләш тә әнә шундыйлардан була. Ул христианлыкны кабул итә, рус кенәзләренә хезмәткә күчә һәм атаклы кенәзләр — Бикләмишевләр фамилиясен башлап җибәрүче була. Кенәз Кугушев та (1863—1944) чыгышы белән әнә шундыйлардан. Аның нәсел җебе XIV гасыр азагында Сараклыч округын һәм шәһәрен биләп торган (бу шәһәрдә Саровский монастыре төзелә) Бихан исемле кешедән башлана.

Казан тәхетендә татар династиясе. XIV гасырның 80 нче елларында Габдулла II Идел Болгарын идарә итүгә Туктамыш ханнан ярлык ала. Туктамыш ханның Сәмәрканд әмире Тимер белән Иделдә Самара борылышы тирәсендә, Болгар иле чикләре буендагы бәрелешләре Болгардагы тормышны шактый катлауландыра. Урдада чуалышлар башлану белән дәүләтнең чынлыкта икенче башкаласы булып киткән Казан

хәлне әллә ни зурга җибәрми калуга ирешә. Дәүләт идарәсе әмирлек дәрәҗәсендә генә оештырылган булса да, Казан үзенең сәүдә-икътисади мәсьәләләрен мөстәкыйль рәвештә хәл итә. С. Х. Алишев билгеләп үткәнчә, XIV йөз ахыры — XV йөз башында әмирлектә ханзадә Янтык бәк, ә соңрак Талыш бәк идарә итәләр. XV гасырның беренче чирегендә Казан үз акчасын (тәңкәләрен) суга башлый. Идел буе Болгарының башкаласы Казанга күчерелә. Илнең әмире итеп Габдулла II нең улы Галибәк (рус чыганакларында — Либей) билгеләнә. Шулай итеп, Галибәк Казан-болгар династиясен башлап җибәрүче була.

Тора-бара Казан «Болгар әл-Җәдид» булудан битәр, туып килә торган яңа заман дәүләтенең — Идел буе татарларының милли дәүләтенең — башкаласына әверелә. XV гасырда Европаның урта гасырлардан яңа заманга борылуы аермачык расланa. Көнбатыш Европадагы Яңарыш, бер үк вакытта, милли дәүләтләр оешуга да йөз тота. Алтын Урда таркалу белән Көнчыгыш Европада да милли дәүләтләр оешуга юл ачыла. Иван III нең патшалык итү еллары фактта рус милли дәүләтенең формалаша башлавы еллары була. Мәскәү Русе Россия булып әверелә бара. Татарстан тарихы да менә шушы гомумевропа агымына кушыла.

Кайбер тарихчылар Казанда хакимияткә татар династиясенең килүен Олуг Мөхәммәт исеме белән бәйлиләр. Хәлбуки биредә яңа династияне аның улы Мәхмүд башлый, дип санаучылар, мөгаен, хаклырактыр.

Туктамыш ханның оныгы Олуг Мөхәммәт Урдада хакимият өчен ызгыш-бәрелешләрнең берсендә Идегәй (1352—1419) һәлак булганнан соң ханлык итә башлый. Шундый канлы бәрелештән соң була торган тынлыктан файдаланып, ул Урданы бераз җанландырырга тырышып карый. 1436 елда Олуг Мөхәммәт Сарайдан куыла. Шунда да ул тәхетне кире кайтару һәм Алтын Урданы җанландыру ниятендә кала. Әмма Алтын Урданың элекке куәтен инде кире кайтарып булмый. Урданың йогынтысыннан арыну теләге ул вакытта массакүләм төс ала. XIV гасыр азагында һәм XV гасыр башларында башкаласы Сарайчык шәһәре (Урал елгасы тамагында урнашкан) булган Нугай урдасы (Нугай татар дәүләте) мөстәкыйль урда статусын ала. Төньяк Кавказ азат ителә. 1433 елда Төньяк Кара диңгез, Азов һәм Дон буе территориясендә Азов буе Нугай татар дәүләте (ханлыгы) барлыкка килә.

Соңрак, 1502 елда, ул Кырым ханлыгына кушыла. Ә Кырым татар дәүләте үзе 1443 елда игълан ителә. 1459 елда Түбән Иделдә Әстерхан татар дәүләте — Әстерхан ханлыгы барлыкка килә. XV гасырның азагында Көнбатыш Себердә Тубыл һәм Иртыш елгалары арасында үзәге Чыңгыз Тура шәһәрендә (хәзерге Төмән) булган Себер татар дәүләте — Себер ханлыгы төзелә.

Кире кайтып шуны әйтергә кирәк: Урданы берләштерү эшендә Олуг Мөхәммәт үзенә көрәштәш табу кебек җитди максат куйган була. Андый көрәштәшне ул көчсезләндерелгән Болгар йөзендә түгел, Сарай белән көрәшергә сәләтле көчкә әверелгән рус кенәзлекләре йөзендә, аерым алганда, шәхсән Василий II йөзендә күрә. Василий II нең сәясәтче буларак зирәклеген бәяләми мөмкин түгел. Ул Олуг Мөхәммәтне көрәштәш буларак кабул итмәсә дә, аңардан катгый төстә йөз дә чөерми. Аның мондый икеле-микеле кыланышы Олуг Мөхәммәтне Василий II гә я хәрби басым ясауга этәрә, я аны яклавына сәбәп була. Эш шуңа кадәр барып җитә ки, 1445 елда Василий II һәм аның туганнан туган энесе кенәз Михаил Верейский әсир төшәләр һәм Олуг Мөхәммәт аларны үзе азат итә. Василий кенәзлек итүен дәвам иттерә. Алай гына да түгел, Олуг Мөхәммәтнең ике улы Якуб һәм Касыйм хәрби отрядлары белән Василий II гә хезмәткә күчәләр. Дөрес, Василий II гә каршы кешеләр аны татарларга ясак түләүне дәвам иттерүдә гаеплиләр. Чынлыкта бу фәкать татарларның хезмәте өчен түләү генә була. Василий II сәясәтенең асылын аңлатып, С. М. Соловьев: «Василий элек тә татар кенәзләрен хезмәткә ала һәм моның өчен аларны «туендырып тора[1]» иде. Варварларга каршы варварларны кую — бу бик әйбәт чара...» — дип яза. Ул шулай ук рус кенәзләренең бу чараны элегрәк тә кулланган булуларын искә төшерә. Мәсәлән, ди ул, Василий II нең әтисе, үз чиратында литвалыларны шул рәвешчә хезмәткә чакырган һәм хезмәтләре өчен аларны хәтсез мул туендырган. Чыннан да, Василий II, Олуг Мөхәммәт биргән көчләргә таянып, илдә үзенең хәлен беркадәр яхшырта. Бераз соңрак Якуб үзенең гаскәре белән Көнбатыш фронтта, Ливониядә сугыша. Әгәр Олуг

---

[1] XIV—XV йөзләрдә патша наместникларын һәм башка түрәләрне җирле халык исәбенә тоту.

Мөхәммәт 1445 елда Түбән Новгородта кинәт үлеп китмәгән булса, вакыйгаларның ничек дәвам иткән булуы ихтималын әйтүе кыен. Шул ук 1445 елда аның өлкән улы Мәхмүд Казан тәхетенә утыра. Мәхмүд Казан-болгар династиясендә алмашка килгән Казан-татар династиясенә нигез салучы була.

Тотрыклылыкка ирешүнең беренче адымнары. Кайбер тикшеренүләрдә, яңа татар династиясенең мәнфәгатьләре җирле болгар халкының мәнфәгатьләреннән, җирле болгар аксөякләренең мәнфәгатьләреннән аерыла, дигән караш киң таралган. Мондый тикшеренүчеләрнең фикеренчә, Мәхмүднең «татарлаштырулары» Болгарның үзенчәлеген саклап калырга омтылулар белән сыеша алмый. Чынбарлыкта исә Мәхмүд беркайчан да Идел буе Болгарын Сарайга да, башка бер чит ил хакимиятенә дә буйсындыру максатын куймый. Ул беренче көннәреннән үк Идел буе Болгар дәүләтенең тулы мөстәкыйльлеген торгызу өчен тырыша. Бу, бәлки, кайбер Казан-болгар сәяси көчләренең аның белән алдан ук сөйләшүләр алып баруы белән аңлатыладыр.

Яңа династия идарә итә башлаганда, илнең сәяси тормышында әллә ни катлаулылыклар күзәтелми. Шулай да тарихчылар 1445 елда, Мәхмүд Казанга килеп кергән көнне, җирле бер әмир Галибәкнең үтерелүен билгеләп үтәләр. Ихтимал, сүз Мәхмүд отрядының әмир гвардиясе белән вак-төяк бәрелешүләре турында бара торгандыр. Тарихчылар хәзергә, чуваш, мари, мордва, удмурт, башкорт җирләрен дә кертеп, үзәктә дә, урыннарда да яңа хакимияткә каршылык күрсәтүләр турында сөйли торган фактлар тапмыйлар. Ниндидер вату-җимерүләр турында да сүз әйтелми. Ә бит моңа кадәрге килмешәкләргә Казан, Болгар һәм башка шәһәрләр бик нык каршылык күрсәтеп киләләр.

Мәхмүд хан итеп игълан ителә һәм әмир булып түгел, нәкъ менә хан булып танылА. Бу хәл аның Алтын Урдадан бәйсез икәнлеген күрсәтергә тиеш була. Казанлылар белән әнә шулай уртак тел табып, ул үзен әтисенең гаскәр башлыкларыннан берсе итеп кенә түгел, дәүләт төзелеше мәсьәләләрендә мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итәргә сәләтле оста сәяси эшлекле итеп тә таныта. Ул агалары-энеләре юлыннан китми, Василий II гә хезмәткә ялланмый, үзен, Казанга таянып, Сарайга әйләнеп кайтырга омтылучы бер килмешәк итеп тотмый. Аның сәясәте бердәнбер максатка — бөтен дөньяда ихтирам белән файдалана торган бәйсез Казан татарлары

дәүләтен яисә, элек рус елъязмаларында әйтелгәнчә, Казан патшалыгын, ә безнеңчә Казан дәүләтен формалаштыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән була. Бу дәүләт соңрак тарих фәненә *Казан ханлыгы* атамасы белән килеп керә.

Хезмәттәшлеккә йөз тотып. Казан татар дәүләтенең (Казан ханлыгының) Россиягә карата тышкы сәясәте үзара тыныч мөнәсәтләрне дәвам иттерүгә юнәлдерелгән була. Бу сәясәтне тагын үзенең барлык күршеләре белән, шул исәптән Россия белән дә, хезмәттәшлек итү сәясәте дип тә атарга мөмкин булыр иде. Идел буе Болгарының Киев Русе, ә соңрак Владимир-Мәскәү Русе белән кораллы бәрелешләре, тулаем алганда, солых шартнамәләре белән төгәлләнә. Идел буе Болгары гаскәрләре Сарайның Мәскәүгә каршы операцияләрендә катнашмыйлар. Куликово кырындагы Мамай гаскәрләрендә һәм 1382 елда Туктамыш ханның Мәскәүне камап торган гаскәрләрендә дә алар (Болгар гаскәриләре) булмый. Алар Туктамыш ханның Тимергә каршы булган сугышларында да катнашмыйлар, Алтын Урда ханнарының үзара бәрелешләрендә дә аларны яклап сугышмыйлар. Урда ханы Булат Тимернең Идел буе Болгарына каршы явы вакытында да алар ярлык шартларының үтәлүе сагында торалар. Ә инде, үз илләрен яклап, аерым рус кенәзләренең Болгарга яуларын кире кайтармый калмыйлар. Хәер, үзләре дә әлеге кенәзлекләр территорияләренә шундый ук бөлдергеч яу чабулар оештыралар, гәрчә Алтын Урда вакытында бу яулар дәүләтара сугышларга әверелми. Хәзер, Казан ханлыгы, Урдадан бәйсез тормыш коруга йөз тоткан Кырым ханлыгы, Азов буе татар дәүләте, Себер ханлыгы, Нугай ханлыгы һәм Рус дәүләте кебек, Урдага каршы юнәлдерелгән сәясәтне алга сөрә. Барлык бу илләр объектив рәвештә бер лагерьда торалар һәм үзләренең бәйсезлекләрен ныгыту юлына басалар.

Мәхмүд хан Россия белән дусларча күршелек мөнәсәбәтләре урнаштыруны мәгъкуль күрә. Казан ханлыгы Мәскәүгә хезмәттәшлек юлын тәкъдим итә. Татар милли дәүләтенең аякка басуы ил эчендә тынычлык һәм үзара аңлашу, барлык илләр белән, шул исәптән Россия белән, халыкара хезмәттәшлек итү шартларында бара. Мәхмүд ханның егерме еллык идарә итүе Мәскәү белән Казан арасында урнашкан тынычлык шартларында үтә. Әлеге тынычлык һәр ике як тарафыннан саклана. Мәхмүд хан әтисенең Урданы торгызуга юнәлдерелгән сәясәтеннән ваз кичә. Шулай итеп, Василий II дә

1445 елда Олуг Мөхәммәт белән төзелгән авыр шартнамәдән азат ителә.

Территориясе. Ил хакимияте эшчәнлеге таралган территориаль системаны өйрәнүче тарихчылар Казан дәүләтенең территориясе Идел буе Болгары чикләрендә булган дигән карашта торалар. Гәрчә ул бераз кечерәк мәйданны биләсә дә.

Казан дәүләтенең Россия белән чиге Иделгә төньяктан һәм көньяктан килеп кушыла торган Ветлуга һәм Сура елгаларыннан көнбатыштарак узган. Көньяк-көнбатышта Казан дәүләте Кырым ханлыгы белән чиктәш була. (Соңрак Кырым ханлыгы үз составына Азов диңгезе буе татар ханлыгы җирләрен алган.) Наровчат, Сарытау (Саратов), Сарытын (Царицын) кебек шәһәрләр биредә Казан ханлыгының чик буе шәһәрләре булганнар. Көньякта чик чама белән Самара елгасы буйлап үткән. Монда Казан ханлыгының күршесе (башкаласы Җаек елгасындагы Сарайчык шәһәре) Нугай урдасы урнашкан. Көнчыгыш чик Кама (Чулман) елгасының югары агымы һәм Ык елгасы бассейннары аша уза. Арырак башкортларның этник җирләре башлана; ул Казан дәүләте чигеннән көнчыгышка — Уралга таба китә. Аннары Себер ханлыгы территориясе башлана. Төньякта Казан дәүләте составына Вятка, Кама, Чепца елгаларының югары агымындагы җирләр (Карин татар әмирлеге, Вятка җире, марилар җире) кергән. Тулаем Чувашстан һәм өлешчә Мордовия шулай ук Казан дәүләте составында булалар.

Халкы. Татарстан тарихчылары һәм этнологлары әле бүген дә татар халкының килеп чыгышы турындагы сорауга җавап эзлиләр. Үзләренең тамырлары белән Кубрат ханның Кара диңгез буендагы Бөек Болгар дәүләтенә китә торган һәм IX—XIII гасырларда Идел буендагы Болгар иле кысаларында халык булып формалашкан болгарлармы? Яисә Идел буе татарлары, барыбызга да мәгълүм татар дәүләте Алтын Урдадан чыгып, XV гасырда Казан ханлыгы составында халык буларак формалашканнармы? Безнең менталитетта нинди як әһәмиятлерәк: сәясәттә болгарларга хас йомшаклыкмы, әллә татарларга хас алдынгылыкка омтылышмы?

XIX гасырда Н. И. Ильминский һәм Н. И. Ашмариннар бу мәсьәләдә бертөрле фикердә булалар: татарларның килеп чыгышы, янәсе, Алтын Урда белән бәйләнгән, ә болгарлар — хәзерге чувашларның бабалары. Хәзер исә мондый ук катгыйлык сизелми. Дөньяда башка халыклар белән кереш-

мәгән, кушылмаган «чиста» халыклар булмавы инде шик тудырмый. Әмма татарлармы без, әллә болгарлармы (әллә сорауны башкачарак, «без болгар-татарлармы, дип куяргадыр?) дигән сорау һаман көн тәртибеннән төшми. Чынбарлыкта исә Казан дәүләтенең халкы үзенең составы буенча бик чуар һәм катлаулы була. Традицион үзәкнең (төньяк һәм көньяк Кама буе, Урта Иделнең уңъяк һәм сулъяк яры) күпчелек халкын борын заманнардан ук җирле төрки кабиләләр (шул җөмләдән, мишәрләр) варислары тәшкил итә. Аларга үз вакытларында бу тирәләргә күчеп урнашкан төрки телле һуннар һәм Кара диңгез буе болгарлары варислары кушыла.

XIII—XIV гасырларда Идел-Кама үзәге Алтын Урда кыпчак-татарларының сәүдә-икътисади яктан актив өлешенә килеп йөрү өчен тел комачаулыгы булмаган төбәккә әверелә. Үз чиратында зыялылары күп булган әлеге үзәк болгарлары кыпчак-татар теле һәм мәдәнияте белән мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен әзерлеклерәк булып чыгалар. Бу мөнәсәбәтләр Алтын Урда исламны кабул иткәч аеруча көчәеп китә. Казан татар дәүләте оешкан чорда аларның сәяси, мәдәни, рухи-психологик интеграциясе, якынаюы көчәя. Нәтиҗәдә XV—XVI гасырларда Казан ханлыгы составында Идел буе татарлары халкы формалаша. Соңрак аларга карата «татарлар» дигән этноним кулланыла башлый.

Шул ук вакытта Казан дәүләте Идел буе Болгарыннан мирас итеп алган этник яктан күптөрлелекне саклап кала. Илнең үзәктән ераграк өлешләрендә чуваш, фин-угор һәм башкорт халыкларының формалашуы дәвам итә. Казан дәүләтендә шулай ук качкын рус крестьяннарын һәм элекке әсирләрне берләштергән шактый зур рус общинасы да була. Алар сәүдә һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнәләр, зур хуҗалыкларда хезмәтчеләр булып торалар. Аларның күпчелеге православие динендә кала, күпмедер өлеше ислам диненә күчә. Дәүләттә яшәүче халык санын бер миллион чамасы дип исәплиләр.

Казан дәүләте белән Мәскәү дәүләте арасындагы, шулай ук алар белән элекке Урда территориясендә урнашкан башка дәүләтләр арасындагы дәүләт чикләре «үтә күренмәле» булып кала. Ул вакытта әле башлыча сәяси йогынты чикләрен билгеләү белән шөгыльләнәләр. Элек урнашкан социаль-икътисади бәйләнешләр өзелми.

XV—XVI ГАСЫРЛАРДА ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЕ

Дәүләт төзелеше. XV йөз Европа өчен Урта гасыр мәдәниятеннән Яңа заман мәдәниятенә күчүнең башлангычы була. XIV гасырда Италиядә башланган Яңарыш чоры континентның башка илләренә дә тарала. Дөньяга гуманистик караш, кешегә йөз белән борылу, аны шәхес итеп тану Яңарышның төп асылын тәшкил итә. Леонардо да Винчи, Рафаэль, Микеланджело, Тициан, Данте, Эразм Роттердамский, Коперник һ. б. шушы алдынгы карашны алга сөрәләр. Социаль планда милли бердәйлекне аңлауда, милли бердәмлеккә омтылуда, милли телнең абруе үсүдә гәүдәләнеш тапкан милли үзаңның формалашуы башлана. 1362 елдан башлап Англиядә суд эшләрен башкару инглиз теленә күчерелә. Шул вакыттан башлап парламент утырышлары да инглиз телендә ачыла башлый. Тарихчылар рус милли мәдәниятенең, рус милли дәүләтчелегенең формалашуы да XIV—XV гасырларда гамәлгә ашырылган дип исәплиләр.

Казан дәүләте дә бу процесслардан читтә калмаган. Кайбер тарихчыларның, Казан ханлыгы урта гасырга хас типик феодаль дәүләт булган һәм бу хәл аны «демократизмның барлык билгеләреннән мәхрүм иткән», дип раслаулары нигезсез. Аның дәүләт системасы шушы вакытлардан башлап конституцияле-консультатив формадагы үзәкләштерелгән ислам монархиясен тәшкил итә. Коръән иң югары дәүләти-хокукый авторитет булса, Шура (Совет) хан идарәсенең аерылгысыз атрибуты буларак эш итә. Авылларда сайланып куелган иң түбән баскычтагы хакимият эшли.

Яңа дәүләт төзелеше «Болгар дәүләте» дигән атаманы «Казан ханлыгы» дигәненә алыштырып кую нәтиҗәсендә генә урнашмый. Дәүләт төзелешендәге иң мөһим яңалыкларның берсе татар милли дәүләте нигезләрен кора башлаудан гыйбарәт була. Моңа кадәр дәүләт төзелешен билгеләп килгән ислам хокукы принциплары дәүләт төзелешенең милли принцибы — милли суверенлык принцибы белән тулыландырыла. Ә милли принцип үзе Идел буе татарларында милли хиснең һәм аңның үсүеннән һәм тирәнәюеннән килеп чыга. Икенче төрле әйткәндә, Идел буе татарлары милли дәүләтенең барлыкка килүе ислам теләктәшлеге хисен милли хис һәм аң белән тулыландыру шартларында бара. Идел буе

татарлары дәүләте XV—XVI гасырда, ислам дәүләте булудан туктамыйча, милли дәүләт булып китә.

Дәүләт идарәсе системасы. Казан ханлыгының дәүләт идарәсе системасында Идел буе Болгар дәүләтенә хас принциплар саклана һәм аңа, бу системага, бәйсезлекнең тулы күләмендә торгызылуы һәм милли дәүләт төзелешенең барлыкка килүе белән бәйле яңа элементлар өстәлә. Дәүләттә иң югары хакимият хан кулында туплана. Хан каршында хөкүмәт ролен үти торган Диван эшли. Диванда диван әгъзалары карачылар (нәзыйрлар) җыела. Аларның берсе олуг карачы итеп куела. Төрле вакытларда олуг карачы вазифасын Булат Ширин һәм аның улы Нургали үтәгәннәр. Халыкара бәйләнешләр мәсьәләләрен гадәттә өч кешедән: би, углан һәм бакшыдан торган хан илчелекләре хәл иткән. Татар дәүләте һәм Россия сөйләшүләре вакытында Нургали би үзен сәләтле дипломат итеп таныта. Аның кул астында югары дәрәҗәдәге чиновниклар — тамгачылар (таможня хезмәткәрләре), илчеләр (дәүләт илчеләре), ямчылар һ. б. эшли. Диванда руханилар башлыгы мөфти бик мөһим роль үти. Төрле вакытларда мөфти булып сәед Бораш (1491—1507), сәед Шаһ Хөсәен (1512—1516), сәед Боерган (1546), сәед Мансур (1546), сәед Мансурның улы сәед Колшәриф (1552) тора. Сәед — иң югары дин әһеле — дәүләттә ханнан кала икенче кеше була һәм мөһим дипломатик вазифалар да башкара. Мөфтине, кагыйдә буларак, «Шәех әл-Ислам» дип атап йөртәләр. Бүгенгечә әйткәндә, ул баш прокурор сымаграк бер кеше була: шәригать кануннарына аңлатма бирә, хан кабул иткән, Җыен кабул иткән законнарны ярлыкау да аның вазифасына кергән. Кайчакларда сәедләр ханга карата оппозициягә дә басалар. Сәед Боерган, мәсәлән, Сафагәрәй хан белән тыныша алмый. Тулаем алганда, Казан ханлыгын *вәкиллекле аристократик монархия* дип атарга мөмкин. Гомумдәүләт күләмендәге мәсьәләләрне хәл итү (сугыш игълан итү, солых төзү һ. б.) өчен дәүләт сановниклары, югары дәрәҗәдәге руханилар һәм хәрбиләр, хәлле шәһәр кешеләре, абруйлы җирбиләүчеләр катнашында, элеккечә, Җыен чакырыла. Хөкем органнары хан тарафыннан раслана торган баш казый җитәкчелегендәге казыйлардан тора. Алар шәригать кануннарына таянып эш итәләр. Ислам руханилары үзләренең дини эшләрендә автономияле булалар. Дәүләтнең әхлакый-этик таянычын тәшкил иткән бу руханилар дәүләт идарәсенең барлык органнарына керәләр һәм хан тарафыннан якланалар.

Дәүләтнең даими гаскәре зур булмый, ул бик яхшы коралландырылган, тәэмин ителгән хан гвардиясеннән һәм җирле хәрби отрядлардан тора. Тышкы сугышлар алып бару өчен гаскәр кирәк кадәр туплана торган була. Белгечләрнең исәпләвенә караганда, дәүләтнең сугышка сәләтле гаскәр тупларлык резервы (30 мең кешелек) була. Бу гаскәргә атлы гаскәр, җәяүле гаскәр (укчылар), пушкарьлар һәм судноларда йөзүче махсус гаскәрләр керә. Армия кылычлар, сөңге, җәя һәм уклар, туп һәм авыр мылтыклар (пищальләр) белән коралланган була. Туплар өчен ядрәләр чуеннан, сызгырып оча торганнары балчыктан ясала.

Ил белән үзәктән торып идарә итү хан хакимияте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Илнең территориясе элеккеге әмирлекләрне алыштырган даруxаларга (округларга) бүленгән була. Аларда хан наместниклары идарә итә. Дарухалар төмәннәргә (өяз кебегрәк административ бүленеш) бүленгән, алар белән арбаб дип атап йөртелгән чиновниклар җитәкчелек иткән. Авылларда халык тарафыннан сайланып куелган староста була. Карин татар әмирлеге, чувашларның этник территориясе, Идел буе марилары җире, Казан ханлыгы составындагы мордваларның этник территориясе, этник башкорт җирләренең бер өлеше, Удмурт җире (Вятка общинасы), үз чиратларында, автономияләрен саклыйлар. Аларның үз кенәзләре була. Чыганакларда, мәсәлән, Акпарс, Адай исемле чуваш кенәзләре телгә алына. Алар арасында исламны кабул иткәннәре дә була, әмма күпчелеге үзләренең мәҗүсилек динендә кала.

Җирле администрациянең төп функциясе салым җыюдан гыйбарәт була. Хәер, территорияләрнең дәүләт составына керүләре дә әнә шул салымнар белән билгеләнгән. Җирле хакимият аппаратында полиция хезмәтен хәтерләткән эш белән — салым җыюда тәртип урнаштыру белән шөгыльләнүче чиновниклар була. Кызганычка каршы, әлегә тарихчылар дәүләт идарәсе системасын җентекләп тикшерә алмыйлар. Казан дәүләтенең архивлары Иван Грозный әмере буенча юк ителгән. Тарихчылар карамагында Сәхибгәрәй хан ярлыгы (грамотасы) кебек аерым документлар гына бар. Сарай шәһәренең архивлары да юкка чыккан. XIX гасырда табылган бер хәзинәдә «татарча язылган кәгазь төргәкләре», «ком сәгатьләре, кара савытлары, акча тәңкәләре... юлбарыс сурәте төшерелгән кургаш мөһер» була. Әмма болары да юкка чыга.

Икътисадны савыктыру. Алтын Урдада шактый озак вакыт дәвам иткән болгавыр чор илнең икътисади һәм социаль тормышында авыр эз калдыра. Күп кенә шәһәрләр җимерелгән, авылларның да күбесе ташландык хәлдә, халык бөлгенлектә яши. Чуалышлар халыкның рухи-психологик халәтенә дә тискәре йогынты ясый. Илне идарә итү системасы какшый. Илнең аерым төбәкләре арасындагы багланышлар йомшара. Халык, ил киеренке билгесезлек хәлендә кала.

Таркалып бара торган Алтын Урда белән араны катгый өзеп, мөстәкыйльлек игълан ителү һәм, иң мөһиме, моннан соң ил эчендә татулык урнашу һәм күршеләр белән, бигрәк тә рус дәүләте белән ике арада тыныч мөнәсәбәтләр урнашу, халыкның сабырлыгы һәм түземлеге өчен Аллаһы тарафыннан иңдерелгән бәрәкәт итеп кабул ителә. Илдә икътисади савыгу башлана. Мәхмүд ханның тыныч шартларда егерме ел буе идарә итүе нәтиҗәсендә ил аякка баса, илгә тотрыклылык килә, бәрәкәт иңә. Казан шәһәре җирле архитектура нигезендә матур итеп яңадан диярлек төзелә. Яңадан торгызылган Кремльдә Хан сарае, соңрак Колшәриф мәчете дип аталган Җамигъ мәчет, бүтән мәчетләр, мавзолейлар төзелә. Кремль янышнан ук хәзерге Ирек мәйданына кадәр сузылган территорияне биләгән шәһәр үзе башлана. Биредә матур-матур мәчетләр, шәһәрнең атаклы кешеләренең йортлары, мунчалар, сәүдә рәтләре урнаша. Шәһәрнең янәшәсендә үк Болак ягында үзенең пристаньнары, су транспорты булган сәүдә-һөнәрчелек бистәсе сузылып китә. Арырак, Идел буенда зур Сәүдә йорты һәм Мәкәрҗә ярминкәсе урнашкан. Бу ярминкә ел саен 24 июньдә ачыла торган була. Кайбер чыганаклардан күренүенчә, Казанның халкы ул вакытта 20 меңгә җитә. Төзеклеге, матурлыгы ягыннан Казан дөньядагы күренекле шәһәрләрнең берсе була. Коры җир буйлап Казаннан Сарайчыкка, аннан Төркестанга кадәр Нугай юлы аша шактый җанлы сәүдә артериясе сузыла.

Идел буендагы башка калалар архитектуралары һәм планнары белән нигездә Казанны кабатлыйлар (тик аларда Кремль булмый). Аларның һәркайсында административ һәм рухи үзәк була. Шәһәрләрдә наместник сарае, баш рухани йорты, Җамигъ мәчет, күп очракларда аның каршында мәдрәсә, ирекле кешеләрнең таза итеп салынган йортлары урнаша. Зурлыкларына карап шәһәрләр мәхәлләләргә (һәркайсында торак кварталлар һәм мәчет), һөнәрчеләр һәм сәүдә

рәтләренә, ә кайчак тоташ сәүдә-һөнәрчелек бистәләренә бүленә.

Шәһәр халкы ирекле кешеләрдән (дәүләткә керменең уннан бер өлеше күләмендә салым түләүче шәһәр һөнәрчеләреннән һәм сәүдә кешеләреннән) һәм ирексез кешеләрдән — хан (дәүләт) һөнәрчеләреннән (ташчылар, шул исәптән таш уючылар, корал ясаучылар, ювелирлар, күнчеләр, итекчеләр, чүлмәк ясаучылар һ. б.), шулай ук хезмәтчеләрдән (аларны кирәк очракта теләсә нинди шөгыль белән көн күрүче ирекле кешеләр, нигездә чиновниклар һәм шәһәр байлары яллап эшләткән) торган. Хәрбиләр катлавы формалаша. Атлы гаскәрләр башында угланнар тора, ә гади җайдаклар казаклар дип атала торган була. Шәһәр халкының, бигрәк тә Казан халкының, шактый өлешен зыялылар, шул исәптән руханилар тәшкил итә.

Авыл да торгызыла. Шәригать кануннары буенча, җир, элеккечә, җәмгыятьнеке санала, һәм аның белән хан эш йөртә. Фактта исә ирекле крестьяннар үз иманалары белән мөстәкыйль рәвештә үзләре эш итәләр. Тик моның өчен дәүләткә ясак түлиләр. Казан ханлыгында Көнбатыш Европадагы кебек эре феодаллар булмый. Биредә шулай ук Россиядәге сыман крепостной хокук та, алпавытлар да булмый. Эре җирбиләүчелек исә хезмәт иткән өчен хан тарафыннан бирелгән җир хисабына барлыкка килә. Ул Россиядәге дворянлык системасын хәтерләтә. Гаиләләрнең ишәюе һәм бүленүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән аз җирле һәм бөтенләй җирсез крестьяннар җирне йә сатып алалар яисә еш кына очракларда натуралата (үстерелгән уңышның бер өлеше белән) түләү бәрабәренә эре җирбиләүчеләрдән арендалыйлар. Югары дәрәҗәле руханилар да кайчак эре җирбиләүчеләр булып китә һәм аларны «тархан» дип атый башлыйлар. Тархан җир салымы түләүдән азат ителә.

Илдә игенчелектән һәм терлекчелектән килә торган керемнәрнең артуы да үзен сиздерә башлый. Уңайлы һәм зәвык белән салынган йортлар, хуҗалык каралтылары хисабына авыллар матураеп китә. Берничә мәхәлләдән торган һәм берничә мәчете булган зур авыллар барлыкка килә.

Хуҗалыкның тотрыклылыгы башкортлар, марилар, мордвалар, удмуртлар яши торган территорияләрдә дә сизелә башлый. Алар да илнең сәүдә-икътисади тормышына җәлеп ителә. Бу халыкларның барысы да үзләренең тарихи төбәк-

ләрендә, үз җирләрендә яшиләр. Аларның авыл һәм шәһәрләрендә, башлыча, шушы халык вәкилләре яши. Башкорт шәһәр һәм авылларында үз мәчетләре, мәдрәсәләре, мәктәпләре була. Ул вакытларда ислам чувашлар һәм өлешчә фин-угор халыклары арасында да таралган була. Башта бу хәл Идел буе Болгарында исламны кабул итүгә бәйле рәвештә күзәтелсә, соңрак XIV гасырда Урдада Үзбәк хан идарә иткәндә ислам, дәүләт дине итеп игълан ителгәннән соң, кабат җанланып китә. Болгарда, Алтын Урдада, аннары Казан дәүләтендә барлык диннәргә карата да бертөрле караштa булу сәясәте бу халыкларга үзләренең мәҗүсилек диннәрен, үзенчәлекләрен саклап калырга мөмкинлек бирә. Ислам кабул иткән башкортлар да үзенчәлекләрен саклауда тоткарлык күрмиләр. Бер үк вакытта аларның тел һәм мәдәният өлкәсендә татарлар белән якынаюлары күзәтелә. Ул вакытта Казан ханлыгында рус авыллары булмый әле. Шәһәрләрдә алар аерым кварталлар яисә урамнар булып урнашалар. Авылларда исә аерым рус гаиләләре дә яши. Шәһәрдә шактый зур әрмән урамнары була.

Милли мәдәният. XV—XVI гасырлар татар милли мәдәнияте элементларының бер-берсенә бик тиз якынаюы, бергә кушылуы чоры була. Дәүләт эшләрен алып бару, судларның, Диванның, Җыенның эше татар телендә (иске татар телендә) алып барыла башлый. Татар теле фән һәм әдәбият теле булып әверелә. Ислам җәмгыятьне рухи-әхлакый берләштерүче бердәнбер көч булмый инде. Иҗтимагый аңда дини нигездәге, мөселманлык нигезендәге бердәмлекне аңлау белән беррәттән, милли тел һәм милли мәдәният нигезендәге бердәмлекне аңлау хисе дә үз урынын ала бара.

Бер үк вакытта татар халкында Идел буе Болгар дәүләтенең монголлар явына кадәр булган бәйсезлеге, аның гаҗәеп мәдәни мирасы, үзенең борынгы тарихы — Болгар һәм Биләр белән кызыксыну көчәя. Татар милли мәдәнияте, борынгы Болгар үрентесеннән үсеп, Алтын Урда чорындагы мәдәният казанышларын үзенә сеңдереп һәм XV—XVI гасырларда ирешелгәннәр белән тагын да баеп, мөстәкыйль тарихи юлга чыга.

Казан дәүләте мәктәп һәм мәдрәсәләрендә белем бирүнең ислам идеологиясенә һәм милли идеологиягә нигезләнгән яңа системасы формалашу башлана. Балаларны дога укырга гына

түгел, туган телдә укырга һәм язарга да өйрәтәләр. Мәдрәсәләр мөстәкыйль структура статусын ала. Аларда ислам тәгълиматы белән беррәттән дөньяви фәннәр (тарих, география, риторика һ. б.) дә укытыла. Зыялылар арасында да билгеле үзгәрешләр күзәтелә. Мөселман руханилары (мәчет имамнары, аларның ярдәмчеләре) зыялыларның төп массасын тәшкил итә. Догаларны гарәп телендә уку белән беррәттән туган телдә вәгазь әйтүләр дә кулланыла. Бу вәгазьләрдә төп урынны пәйгамбәрләрнең, беренче чиратта рәсүлүллаһ Мөхәммәднең тормышы, Аллаһының аңа Коръән сүрәләрен иңдерү тарихы, Мөхәммәднең гаиләсе, Адәм һәм Хава, Нух һәм Туфан, теге дөньядагы тормыш, Кабил һәм Һабил һ. б. турында сөйләнә. Вәгазьләрдә мораль, әхлак, әдәплелек, чисталык, пакьлек, гаилә һәм тормыш итү проблемалары, шәригать кануннары, дәүләт тормышы турында торган саен күбрәк һәм ешрак сөйләнә. Күп милләтле Казан дәүләтендә татарларның башка халыклар белән үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләләре кузгатыла. Мәскәү православие чиркәве әһелләренең мөселманнарга каршы чыгышларына карата күп тәнкыйть сүзләре әйтелә. Ләкин христиан диненә, аерым алганда православие диненә карата мөнәсәбәт һәрвакыт лояль була. Иисуска (Гайса пәйгамбәргә) негатив караш — Коръән өчен гомумән ят нәрсә. Ул Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәрләреннән берсе санала, Мәрьям ана улы, Аллаһы колы рәвешендә телгә алына.

Җирле мәчетләр халыкка аерата якын тора. Аларда туган тел ышанычлы яңгырый, халык традицияләре киң чагылыш таба. Гади мәктәпләр һәм мәдрәсәләр белән беррәттән, Шиһабеддин Мәрҗани язганча, Малмыж өязенең Адаев авылында суфичылык мәктәбе дә булган.

XV гасыр үзенең тамырлары белән Идел Болгарына тоташкан татар милли архитектурасының формалашуы чоры була. Казан әнә шул архитектура җимеше буларак калка. Кенәз Курбский язганча, Казанга төньяктан торып караганда аның патша палаталары, биек-биек таш манаралы мәчетләре, патша төрбәләре белән бизәлгән мәһабәт панорамасын бер караштa гына айкап чыгуы кыен. Курбский биш таш мәчетнең — Хан мәчетенең, Нургали мәчетенең, Колшәриф мәчетенең һ. б. манараларын күргән. Шиһабеддин Мәрҗани да «Таҗик чокыры» дип аталган урында 8 манаралы баш мәчет булуы турындагы риваятьне искә ала. Галимнәр, Болгарда, Алабуга

һәм Касыймда сакланып калган архитектура истәлекләре буенча инде юкка чыккан биналарны күпмедер дәрәҗәдә күзалларга мөмкин, дип уйлыйлар. Алабуга янындагы «Шайтан каласы» җирдән үсеп чыккандай тоелган таш цилиндр рәвешендәге манарадан гыйбарәт. Сөембикә манарасы, Болгардагы Кара пулат кебек үк, түбәнге якта дүрт почмаклы, аннары югарыга таба сигез почмаклы итеп эшләнгән. Касыйм шәһәрендә XVI гасыр уртасында салынган Хан сарае янындагы Шаһгали төрбәсе кенәз Курбский язган патша төрбәсенең аналогы була ала.

Казанның иң яхшы биналары таштан корылганнар һәм ташка уеп ясалган гарәп язуы үрнәкләре белән бизәлгәннәр. Казан агач архитектура үрнәкләренә дә бай була. Манаралы агач мәчетләр, ачык төсләргә буялган ике катлы матур йортларда милли төсмерләр чагылыш таба.

Милли мәдәният өлкәсендә шактый күп санлы дөньяви интеллигенция үзеннән зур өлеш кертә. Алар арасында язучылар, шагыйрьләр, тарихчылар, юристлар, табиблар һ. б. бар. Шуларның берсе — шагыйрь һәм фикер иясе Мәхмүд Мөхәммәдьяр. 1997 елда Татарстан җәмәгатьчелеге аның тууына 500 ел тулуны олылап билгеләп үтте. Аның тормышы һәм иҗаты татар әдәбияты белгечләре тарафыннан җентекләп өйрәнелде. Бу тикшеренүләр аның Европа һәм Көнчыгыш Яңарышының куәтле плеядасы вәкиле булуын раслады. Мөхәммәдьяр 1497 елда дин әһеле гаиләсендә туа. Гарәп, фарсы телләрен яхшы белә, Шәрык фәлсәфәсен өйрәнә, рус телендә әйбәт кенә сөйләшә, рус иҗтимагый-фәлсәфи фикере белән таныш була. 1549 елда Сөембикә ханбикә аны Казан ханлыгы илчелегенең тәрҗемәчесе итеп Мәскәүгә җибәрә. Явыз Иван бу илчелекне кулга алырга куша. Һәм Мөхәммәдьярның шуннан соңгы язмышы хәзергәчә мәгълүм түгел.

Мөхәммәдьярның иҗади мирасыннан аның гаҗәеп ике поэмасы: 1540 елда Казан шәһәрендә язылган «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») һәм 1542 елда иҗат ителгән «Нуры содур» («Күкрәкләр нуры») безгә иң таныш әсәрләреннән. Аларның беренчесе рус тюркологы И. Н. Березин тарафыннан 1856 елда Санкт-Петербургта Азия музее фондларында «Төрки-татарлар кулъязмалары» арасында табыла. Икенчесен 1940 елда күренекле татар язучысы һәм галиме Нәкый Исәнбәт таба. Һәр ике поэма татар милли дәүләтен рус дәүләтеннән

саклап-яклап калу мәсьәләләре кискенләшкән, илгә куркыныч янаган вакытларда язылa.

«Нуры содур» поэмасында Мөхәммәдьяр үзен татар милли дәүләтен ялкынлы яклаучы итеп таныта, илне коткарып калу хакына, гаделлек-дөреслек хакына ул хәтта сугышны да акларга әзер. Ул пәйгамбәрләр заманында идеаль җәмгыять булганлыгы турында хикәяли, үзенең гадел иҗтимагый стройны ничек аңлавын сөйләп бирә, гадел идарәче образын сурәтли. Аның фикеренчә, идарәче гаделлек, шәфкатьлелек, юмартлык, тыйнаклык, түземлелек, тугрылык, туры сүзлелек, күп сөйләшүдән тыела белү, гафу итә белү сәләте һәм батырлык кебек сыйфатларга ия булырга тиеш.

«Төхфәи мәрдан» поэмасында Мөхәммәдьяр күбрәк аерым кеше, гаилә, җәмгыять дәрәҗәсендәге этика һәм әхлаклылык проблемалары турында фикер йөртә. Ул илаһи изгелекне кеше күркәмлеге белән бергә куша һәм укучы алдына бөек гуманист буларак килеп баса. Мөхәммәдьяр кешенең фани дөньядагы уңай сыйфатларына — гүзәллеккә, гакылга, нәфислеккә, туры сүзлелеккә, тыйнаклыкка дан җырлый һәм кешенең җирдәге җитешсезлекләрен — тәкәбберлекне, икейөзлелекне, мактанчыклыкны, масаючанлыкны камчылый.

Мәхмүд Мөхәммәдьярның әсәрләре XV—XVI йөзләрдә формалашкан татар теле (иске татар теле) үрнәкләрен, татар милли әдәбиятының башлангыч этабын гәүдәләндерә. Аларда без Идел буе Болгары әдәбиятының даһи Кол Галидән һәм Болгар-Сараи чорыннан, Котбтан һәм Сәйф Сараидан килгән әдәби традицияләр чагылышын күрәбез. Мөхәммәдьяр белән иңгә-иң Өмми Кәмал, Мөхәммәтәмин, Гарифбәк кебек татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗат итә. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән кулъязма китапларда без аларның орнаментлар белән бизәү ысулларының, оста каллиграфия һәм миниатюра сәнгатенең югары дәрәҗәдә булганлыгын күрәбез.

Фәнни-фәлсәфи фикер ул вакытта нигездә шигырьләрдә, матур әдәбиятта чагылыш таба. Дини тәгълимат зур үсеш ала. Башлыча ул заманнардан халкыбызның, илебезнең тарихына багышланган хезмәтләр сакланып калган. Шундыйлар рәтенә, мисал итеп, 1551 елда Спас өязенең Ташбилге авылында Шәрәфетдин улы Хисаметдин язган «Тәварихе Болгария» («Болгар тарихы») дигән китапны атарга мөмкин.

Тышкы сәясәт үзенчәлекләре. Мөстәкыйльлек алу белән Казан дәүләтенең халыкара хәле дә үзгәрә. Соңгы ике йөз ел

дәвамында дөнья Идел буе Болгарын Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше итеп кенә белә. Ә хәзер Казан ханлыгын халыкара тану чоры башлана. Илнең тышкы сәяси багланышларны киңәйтүгә һәм ныгытуга юнәлдерелгән сәясәте торгызыла. Казанның Бохара белән күптәнге мөнәсәбәтләре яңартыла. Тимериләр дәүләте таркалганнан соң Үзбәкстанда хакимият башына Шәйбанилар килә (1500—1598). Фирганәнең элекке идарәчесе, соңыннан Төньяк Һиндстанда Бөек Моголлар династиясенә нигез салучы булып киткән Бабур үзенең «Бабурнамә» дигән китабында, Шәйбани хан (1483—1530) Казан ханы Мөхәммәтәмингә (1487—1518) танылган җырчы Голәм Шади Гудины эш белән җибәрде, дип яза. Казан дәүләтенең Мисыр һәм Көнчыгышның башка илләре белән дәүләтара мөнәсәбәтләре яңадан тергезелә.

Көнчыгышка юнәлтелгән халыкара багланышлар, әлбәттә, Казан өчен зур әһәмияткә ия була. Әмма Европа илләрендә башланган Яңарыш чорында бу элемтәләр генә татар дәүләтен канәгатьләндерә алмый. Казан ханлыгы Көнбатыш Европага чыгу өчен уңайлы юл эзли. Географик һәм сәяси планда мондый чыгу юлын бары тик күршедәге Россия һәм Төркия аша гына салып була. Казан дәүләте үзенең тышкы сәясәтендә төп игътибарны әлеге илләр белән мөнәсәбәтләргә юнәлдерә.

Татарстан — Россия мөнәсәбәтләре. Мәхмүд хан идарә иткән чорда (1445—1466) Татарстан һәм Россия арасында тыныч мөнәсәбәтләр урнаша. Урдага карата Кырым ханлыгы кебек үк тискәре мөнәсәбәттә булган Казан Сарайның Мәскәү белән бәхәсендә Мәскәү ягында тора. Әхмәд ханның Мәскәүгә яу чабуы вакытында, 1480 елда Кырым турыдан-туры Мәскәүне яклап чыга, үз гаскәрләрен Сарайның союзнигы булган Литвага каршы җибәрә, ә Казан Мәскәүгә карата нейтралитет позициясенә баса. Россиядә хакимияткә Иван III килгәч тә баштарак мөнәсәбәтләр тыныч булуында дәвам итә.

Ләкин тиздән Иван III Казанга каршы сәясәт алып бара башлый. Бу сәясәтне идеологик нигезләү элегрәк башлана. 1409 елда Мәскәүдә митрополит Киприан инициативасы буенча Гомумрус елъязмалар җыелмасы төзелә. Анда дала халыклары — Русьның күптәнге дошманнары, дигән идеологик фикер үткәрелә. Киприан үлгәннән соң, әлеге җыелмага Идегәй турындагы повесть өстәлә. Анда элеккеге «дошманнар» яңалары — татарлар белән тиңләштерелә. XV гасырдан башлап елъязмалар эше патшаларның үз кулларына күчкәч һәм

елъязмалар махсус дьяклар тарафыннан языла башлагач, аларда дәүләт идеологиясенең татарларга каршы юнәлдерелгәнлеге тагы да көчәя. Иван III үзенең Казанга каршы юнәлдерелгән сәясәтен шушы идеологиягә таянып акларга тырыша һәм чынлыкта Татарстанны Россиягә кушуга йөз тота башлый. Рус историографиясе ул вакытта Казанда бер-берсе белән көрәшүче ике партия була дип раслый. Аларның берсе, имеш, русларга йөз тотса, икенчесе Кырымга (Көнчыгышка) таба борылган. Ләкин бу фикер төгәл түгел. Казан дәүләтендә дәүләт бәйсезлеге позициясендә торучы сәяси көчләр тупланган була. Дөрес, аларның бу бәйсезлекне гамәлгә ашыру юлларына карашлары төрле булуы да ихтимал. Ул вакытта мәрхүм Мәхмүд ханның энесе Касыйм Мәскәүдә русларда хезмәттә була. Аңа Россия кул астындагы мишәр җирләренең бер өлешен бүлеп бирәләр. Россия бу җир биләмәсен мөстәкыйль Касыйм ханлыгы дип игълан итә. Шулай итеп, ике татар ханлыгы яши булып чыга: берсе Россия составында һәм Мәскәү белән дустанә мөнәсәбәттә торса, икенчесе Мәскәүгә карата дошманлык сәясәте алып баручы Казан ханлыгыннан гыйбарәт була. Димәк, бер партия, дәүләт бәйсезлеге партиясе — Казанда, ә икенче партия, «русларга юнәлеш тотучы партия» Россиянең үз составында тора.

Мәхмүд хан үлгәннән соң, 1467 елда Иван III Казан тәхетендә татар дәүләтчелеге вәкилен Мәскәүгә йөз тотучы партия кешесенә алмаштыру өчен беренче омтылышын ясап карый. Мәхмүд ханның Хәлил һәм Ибраһим атлы ике улы кала. Хакимлек аларның өлкәнрәге Хәлилгә күчә. Шул вакытта Иван III, болай итү гаделсезлек булачак, Казанда хакимлек өлкәнлек буенча мирас итеп Мәхмүднең энесе Касыймга бирелергә тиеш, дип белдерә. Касыйм яхшы коралланган отряд белән Казанга таба юнәлә. Ә икенче бер рус отряды бу вакытта Казан ханлыгының төньяк чигенә килеп чыга һәм андагы Вятка общинасы җирләрен били. Ләкин Иван III нең Казан тәхетенә Касыймны утырту планы җимерелә. Казанлылар Касыймның үзен дә, аның отрядын да шәһәргә кертмиләр.

Хәлил хан үлгәннән соң, хакимлек аның энесе Ибраһимга күчә. Ибраһим хан үзен зирәк сәясәтче, оста сәргаскәр, сәләтле һәм каты куллы татар дәүләтчесе, хөкемдар итеп таныта. Беренче җәендә үк ул Вятка җирләреннән рус гаскәрләрен кысрыклап чыгару буенча сугыш операцияләрендә шәхсән үзе

җитәкчелек итә. Ул төбәктәге җирле халык тулысы белән хан ягында була. Иван III үзенең Казан янында һәм Вятка җирләрендә җиңелүен танырга мәҗбүр була һәм Казан ханлыгы белән солых шартнамәсе төзүгә бара. Тарихчылар Ибраһим ханның бу уңышын «гүзәл җиңү» дип атыйлар. Шулай да аерым рус отрядлары чуваш һәм мари җирләренә яу белән йөрүләрен дәвам иттерәләр. Германиянең Россиядәге ул вакыттагы илчесе Герберштейн үзенең «Мәскәүдәге эшләр турында язмалар» дигән китабында бу уңайдан, чувашлар һәм марилар — төз атучы укчылар, һәм алар рус отрядларына зур бәлаләр китерәләр дип билгеләп үтә. Вятканың үрге агымында урнашкан шәһәр һәм авылларга рус ушкуйниклары еш кына яу белән йөреп йөдәтә торган була. Ибраһим хан аларга каршы да чаралар күрә. Ушкуйникларның башбаштаклыгына чик куела, җирле халыкның иминлеге тәэмин ителә.

1479 елда Ибраһим хан вафат була. Тәхеткә аның беренче хатыны Фатыймадан булган улы Илһам утыра. Ул да әтисенең дәүләт суверенлыгын саклауга һәм ныгытуга юнәлдерелгән тышкы сәяси курсын дәвам итә. Иван III Ибраһим хан белән төзелгән солых шартнамәсен үтәргә риза була. Казан белән Мәскәү арасында Мәхмүд хан (1445—1466) вакытында урнашкан егерме еллык тыныч мөнәсәбәтләр 1469 елда Ибраһим ханның Мәскәү белән төзелгән солых шартнамәсеннән соң тагын егерме ел диярлек дәвам итә. Казан дәүләте яраларын төзәтү эшенә керешә.

1487 елда Илһам үлә. Шул ук елны, казанлылар өчен һич көтмәгәндә, солых шартнамәсен явызларча бозып, Иван III Казанга каршы русларның зур армиясен җибәрә. Алдан җентекләп әзерләнгән, уйланылган агрессия була бу. 1480 елда Әхмәд ханның явын кире кайтарыр өчен дип әзерләнгән һәм ул вакытта ханга каршы сугышка кермәгән армия хәзер бар куәтенә Казан өстенә ташлана. Казан хөкүмәте Көнчыгышта гына түгел, Көнбатышта да сугыш алып бару тәҗрибәсен туплаган куәтле гаскәрнең һөҗүмен кире кайтарырга әзерләнмәгән була. Бу вакытта Төркиянең гарантияләрен алган Кырым ханлыгыннан үзгә буларак, Казанның көчле союзниклары да булмый. Иван III Казанны камап ала һәм кулга төшерә.

Шул ук 1487 елда, мөфти һәм аксөякләр алдында ант биреп, тәхеткә Ибраһим ханның икенче улы Мөхәммәтәмин

утыра. Мөхәммәтәмин дә, үз чиратында Мәскәү хезмәтен үткән була, Иван III холкыннан хәбәрдар, Россиядәге сәяси вазгыятьне аңлый, русларның хәрби стратегиясе һәм тактикасы мәсьәләләре буенча да үз фикере була. Аңа Көнбатыш фронтта да булырга туры килә. Чын татар дәүләтчесе, дипломат, Россиянең эчке тормышыннан хәбәрдар Мөхәммәтәмин хан Казан дәүләтенең бәйсезлеген саклап калуга ирешә. Мөхәммәтәмин даирәсендәге кешеләр — Кәлимәт, Урак, Садыр, Бахши Бозак, сәед Барат — ханның чын таянычы булалар.

Ныклы татар дәүләтчесе Мөхәммәтәмин Россия белән конфликтка керү юлына басмый. Ул рус хөкүмәтендә сугыш яки дипломатик юл белән Казан дәүләтен Россиягә кушу нияте булганлыгын яхшы белә. Россиянең куәтле гаскәргә ия булуы һәм аның татар иленә географик якынлыгы бу куркынычны тагы да көчәйтә. Иван III 1489 елда, Казан дәүләтенә каршы беренче походын оештырып, аның төньяк территорияләрен — Карин татар әмирлеген һәм Вятка җирләрен — кабат Россиягә куша. «Русларга юнәлеш тотучы Казан партиясен» көчәйтү өчен, ул җирләрдәге идарәчеләрне гаиләләре белән Мәскәүгә алып китә. Бу 1460 еллар ахырында Ибраһим хан белән төзелгән шартнамәне бозу була.

Мөхәммәтәмин Иван III нең 1487 һәм 1489 еллардагы мәкерле гамәлләрен кичергән сыман була. Либераль сәясәт үткәреп, ул бу конфликтларны дипломатик юлдан җибәрергә ниятли. Мондый сәясәт нигезендә бернинди агрессив ниятләре булмаган татар халкының төп мәнфәгатьләре ята. М. Г. Худяков: «Казан ханлыгы хөкүмәтенең беркайчан да рус дәүләтен яулап алырга омтылганы булмады»,— дип яза. Киресенчә, Мәскәү хөкүмәте үзенең барлык рәсми документларында, чит илләр белән язышкан хатларында, Казан 1487 елда рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынды, дигән сүзләрне кабатлый һәм, яулап алучы буларак, аны үз территориясе итеп саный. Казан дәүләтенә карата булган моннан соңгы барлык агрессив адымнарын рус хөкүмәте әлеге яулап алучы хокукы белән акларга һәм «тәртип урнаштыру» чаралары итеп күрсәтергә тырыша. Иван III, үзенең шул яулап алучы хокукын расларга теләп, үз-үзенә «Болгар кенәзе» («Князь Болгарский») дигән титул куша. Әнә ич Маркс та ялгыш фикердә тора, Иван III не истә тотып: «Казан аның аягы астында»,— дип яза. Хәлбуки Иван III үзе дә Казан

дәүләтенең бәйсез булуын, бу бәйсезлекнең күп тапкырлар раслануын аңламый түгел.

1505 елның октябрендә Иван III үлә. Мәскәүдә хакимият башына Василий III килә. Әтисе эзеннән барып, ул 1506 елда, Казанны кулга төшерүне бурыч итеп куеп, шәһәр өстенә 100 меңлек рус гаскәрен җибәрә. Армия Казанга якын ук килә, аны штурмлауга да керешә, әмма тулы җиңелүгә дучар ителә, күп кенә коралларын ташлап, Казан дәүләте чикләреннән ашыгып чигенергә мәҗбүр була. Мөхәммәтәмин бу юлы да үзенең сәяси өлгерлеген күрсәтә. Ул рус елъязмасында әйтелгәнчә, «борынгы гадәт буенча һәм дуслык өчен» («мир по старине и дружбу») солых төзергә тәкъдим итеп, Мәскәүгә илчелек җибәрә. Русларның хәрби әсирләре азат ителә. 1512 елда Казан белән Мәскәү арасында яңа солых шартнамәсенә кул куела. Бу Мөхәммәтәмин ханның зур хәрби һәм дипломатик җиңүе була.

1516 елда Мөхәммәтәмин хан авырып китә һәм 1518 елда вафат була. Мәскәү белән мөнәсәбәтләрендә Казан яңа катлаулы чорга керә. Мөхәммәтәмин ханның балалары булмый. Ул вакытта аның энесе Габделлатыйф та инде үлгән була. Турыдан-туры варислар булмаудан файдаланып, Василий III Казанга хан итеп Шаһгали куелуын таләп итә. Шаһгалинең әтисе — Урда ханы Әхмәднең туганнан туганының улы, 1502 елда, Сарай Кырым ханыннан җиңелгәннән соң, Мәскәүгә качкан һәм Мәскәүгә хезмәткә ялланган була. Аның улы Шаһгали исә шулай ук Россия патшасына хезмәт итә һәм, Касыйм хан үлгәннән соң, ул биләгән җирләрнең хуҗасына әверелә. Алай гына да түгел, 1519 елда Василий III, Мәскәүдән торып, аны Казан ханы дип игълан итә һәм шунда ук аның белән шартнамә төзи. Бу шартнамә буенча Шаһгали, Казан исеменнән, киләчәктә яңа ханны Мәскәү рөхсәтеннән башка кабул итмәскә йөкләмә ала. Казан хөкүмәте Василий III нең бу дошманлык гамәле уңаеннан ризасызлык белдерә һәм килеп туган хәлдән чыгу юлларын эзли башлый.

Казан — Кырым мөнәсәбәтләре. 1518 елда Мөхәммәтәмин үлгән елны Мәскәүдә Кырым — Мәскәү дуслык шартнамәсенә кул куелган була. Шуннан соңгы елда исә Мәскәүдә Казан тәхетенә Шаһгалине утырту хакында игълан ителгәч, Кырым белән Мәскәү мөнәсәбәтләре бозыла. Кырым Мәскәүнең аңа дошман булган Урда ханы Әхмәд нәселеннән булган Шаһгалигә булышлык күрсәтүе уңаеннан ризасызлыгын җиткерә,

аның Казан ханлыгының эчке эшләренә тыкшынуына каршы протест белдерә. Бу вакытта Кырымның сәяси хәле тотрыклы була. Аның тышкы иминлеген Төркия белән төзелгән шартнамә дә гарантияли.

Казанда тәхеткә Кырым ханы Миңлегәрәйнең кече улы Сәхибгәрәйне чакырырга булалар. Бу хәл туганлык җепләре белән аклана. Чөнки Ибраһим ханның тол хатыны, Мөхәммәтәминнең әнисе Нурсолтан, моңа кадәр үк Миңлегәрәйгә кияүгә чыккан була. Ханзадә Сәхибгәрәйне Казанда беләләр. Ул әле 1510 елда ук үги әнисе Нурсолтан Россиядә үзенең кече улы Габделлатыйфта кунакта булганда, ә аннары тугыз айдан артык Казанда өлкән улы Мөхәммәтәмин ханда яшәгәндә аның белән бергә килгән була.

Сәхибгәрәй Казанга 1521 елның язында килә һәм бернинди тоткарлыксыз тәхеткә утыра. Казанда ул озак түгел — 1524 елның язына кадәр генә идарә итә. Шуңа да карамастан, Казан дәүләтенең милли бәйсезлеген оста яклаучы буларак үзе турында уңай фикер тудырырга өлгерә. Ләкин ул үзен Кырым тәхете варисы итеп хәзерләү нияте белән Казаннан китәргә була. Шактый вакыт Төркиядә яши, реформаларына бәйле рәвештә Кануни дигән кушамат алган солтан Сөләйман идеяләре белән якыннан таныша. 1532 елда Кырым тәхетенә утыра, 1551 елга кадәр анда ханлык итә.

1524 елда, Казаннан китәр алдыннан Сәхибгәрәй абыйсының улы Сафагәрәйне Казанга чакырган була. Казан хөкүмәте һәм аксөякләр ризалыгы белән ул хан итеп игълан ителә. Әле шактый яшь булуына карамастан, ул үзен бәйсез, зирәк, шул ук вакытта үзара аңлашуга барырга сәләтле сәясәтче итеп таныта. Шиһабеддин Мәрҗани аны бик кодрәтле кеше дип атый. Ул халыкка, Казан дәүләтенең бәйсезлеге идеясенә тугрылыклы югары дәрәҗәдәге сәясәтчеләрне үз тирәсенә туплый. Чыганакларда Отуч би, аталык (яшь ханның киңәшчесе) Талыш, күренекле сәяси һәм хәрби эшлекле Мәмешбирде, Тәфкил, Ширмәрдән Чурачиков, Колай, Кадыш морзалар, углан Карамыш, Ибраһим ханның кызы Гәүһәршад һәм башкаларның исемнәре атала. Алар дәүләт эшләрендә һәм сугышларда ханга булышлык күрсәтәләр.

Сәхибгәрәйнең һәм Сафагәрәйнең идарә итүләре чорын (1521—1549) рус историографиясендә төрлечә бәялиләр. Рәсми рус историографиясе аны «Төрек протектораты чоры» дип атый, ә М. Г. Худяков «милли яңарыш чоры» дип бәяли. Чын-

лыкта исә Казан дәүләте чоры — бербөтен татар милли дәүләтенең формалашуы чоры ул. Аны «рус протектораты», «төрек протектораты» чорларына бүлү дөрес булмас. Бу чор тарихын, үзенең дәүләт бәйсезлеген яклап, тулысы белән бөтен татар халкы тудыра, ә хөкүмәт бу бәйсезлекне оптималь яклау өчен Россия, Кырым, Төркия белән, башка дәүләтләр белән теге яисә бу мөнәсәбәтләргә керә.

Татарстан — Россия мөнәсәбәтләренең кискенләшүе. Казан тәхетенә үз кешесен утыртырга маташулар барып чыкмагач, Мәскәү хөкүмәте, хәрби басымны көчәйтеп, үз максатына ирешмәкче була. 1523 елда ул Сура елгасы буенда, Казан дәүләте территориясендә Василий III хөрмәтенә Васильсурск дип аталган ныгытма-шәһәр салып куя. Рус православие чиркәве башлыгы митрополит Даниил бу уңай белән: «Ул шәһәр белән без бөтен Казан җирен алырбыз»,— дип белдерә. Моңа кадәр Казанга каршы яулар Новгородтан башланган булсалар, моннан соң аларны Васильсурскидан башлау күздә тотыла.

Янап торган бу куркынычны киметү максатыннан, Казан хөкүмәте үзенең Кырым, Нугай урдасы (Сарайчык), Әстерхан ханлыгы белән бәйләнышларын киңәйтә. Төркия хөкүмәте белән сөйләшүләр Казан өчен бигрәк тә отышлы була. Солтан Сөләйман Казанга, Кырым үрнәгендә, тышкы иминлек гарантияләре бирә. Төркиянең кораллы көчләре бервакытта да Россия белән Казан дәүләте арасындагы сугышларда катнашмый. Әмма Европада барган реформаларга ияреп, аларны мөселман иле шартларына туры китереп үткәрүгә ирешкән Төркия белән якынаю Казан өчен аеруча әһәмиятле була.

Васильсурскида яңгыраган янау чынга әверелә. 1524 елның җәендә төрле мәгълүматлар буенча саны 150 меңнән алып 180 меңгә кадәр кешедән торган рус гаскәрләре (атлылар һәм судноларга төялгән җәяүлеләр, туплар, олаулар) Казанга таба яу белән чыга. Казанга килеп җиткәч, гаскәрләр хәрби позиция алалар һәм шәһәрне штурмлауга керешәләр. Бу бәрелештә руслар җиңелә. Бер атлылар отряды Зөя елгасы буенда ук тар-мар ителә. Герберштейнның сүзләренә караганда, «ул каршы алган чирмешләр тарафыннан җиңелде, һәм нибары 9 кеше көч-хәл белән котылып калды. Авыр яраланган воевода өченче көнне дошманнары кулында үлде». Тарихчылар фикеренчә, Казанның бу җиңүе дә «менә дигән» җиңү була. Казанны яклаучылар арасында сугышларда дан казанган, шәһәр өчен барган моннан соңгы бәрелештә 1530 ел-

да һәлак булган аталык Мөхәммәт Гали дә була. Рус командованиесенең үтенече буенча солых төзелә. С. М. Соловьев язганча, «поход уңышсыз булды, көткәнне акламады, Василий III Сафагәрәйне танырга риза булды».

1530 елда Василий III Казанга каршы походын тагын кабатлый. Бу юлы ул казанлыларга хан итеп Шаһгалинең энесе Җангалине тәкъдим итәргә ниятли. Русларның армиясе бу юлы да гадәтләнгән юлдан хәрәкәт итә. Шәһәрне штурмлауда да яңалык булмый. Һәм рус армиясе, шулай ук гадәтләнгәнчә, җиңелүгә дучар була.

1533 елда Василий III, тәхетне үзенең 3 яшьлек улы Иван IV кә калдырып, үлеп китә. Иван IV рәсми төстә тәхеткә утырганга кадәр,— ә бу хәл 1547 елда була,— Мәскәү хөкүмәте тагын бер тапкыр Казан ханлыгын Россиягә кушарга маташып карый. Бу юлы Россия гаскәрләренең һөҗүме 1545 елның җәендә оештырыла. Ләкин алар бу юлы да Казанны ала алмыйлар. Кайту юлында, Зөя тамагында морза Мортаза Тәфкилевнең утарын туздыралар. Яндыру, талау, үтерүне булдыралар, ә Казанны ала алмыйлар.

Шулай итеп, Иван III, Василий III ләр патшалык иткәндә, Глинская регент булып торуның һәм «боярщинаның» йөз еллык диярлек чорында Казан ханлыгын Россиягә кушарга маташулар уңышсыз чыга. Монда Казан дәүләтенең эчке ныклыгы төп рольне уйный. Ул вакытта Көнчыгыш Европа дәүләтләренең мораль-сәяси булышлык күрсәтүләре дә эзсез калмый.

Үзеннән алда булган идарәчеләрнең сәясәтен дәвам иттереп, Сафагәрәй хан, үз чиратында, Казан дәүләтенең мөстәкыйльлеген саклап калуга ирешә. Казан ханлыгы тарихын бик җентекләп өйрәнгән М. Г. Худяков Казанда Мөхәммәтәмин ханның апасы Гәүһәршад (Һ. Атласи версиясе буенча — Хөршидә) тирәсенә җитәрлек дәрәҗәдә көчле дәүләт бәйсезлеге партиясе (түгәрәге) туплана дип билгеләп үтә. Бу партиягә русларның Казанга үз ихтыярларын көчләп тагарга маташуларын катгый рәвештә кире кагучы, сүзләре үтә торган, абруйлы сәяси эшлеклеләр керә. Сафагәрәй хан теге яисә бу якка авышарак башлаган очракларда, алар көчле оппозициягә басалар. Нәтиҗәдә бик кыен вакытларда да килеп туган хәлдән чыгуның оптималь юлы табыла.

Сафагәрәй Нугай урдасы, Әстерхан һәм Себер ханлыклары белән мөнәсәбәтләрне яхшырта. Ул Нугай ханы Йосыф-

ның кызы Сөембикәгә өйләнә. Сөембикә ханга сөекле хатын да, аның үзенә тиң сәяси юлдаш та, ышанычлы ярдәмче дә була. 1549 елда Сафагәрәй, Сөембикәгә ике яшьлек улы Үтәмешгәрәйне калдырып, үлеп китә. Үтәмешгәрәй бик яшь булу сәбәпле, ил белән идарә итү йөге Сөембикә җилкәсенә төшә.

Казан дәүләте өчен бик тә катлаулы вазгыять урнаша. Тәхеткә регент әнисе белән әле нарасый гына булган хан утыртыла. Мәскәүдә, С. М. Соловьев сүзләре белән әйткәндә, патша титулын Россиядә беренче булып алган гына түгел, патша булуның тәмен инде татып та өлгергән, рәсми рус историографиясе раслаганча, «авыру дәрәҗәсендәге кыргый явызлыгын сиздерә башлаган» Иван Грозный утыра.

БӘЙСЕЗЛЕК ӨЧЕН СУГЫШ

Көнчыгыш Европада империя төзүгә таба борылыш. XVI гасыр Татарстанга гаять зур сынаулар алып килә. Көнчыгыш Европада милли дәүләтләр оешу һәм алар арасында дәүләтара мөнәсәбәтләр урнашу процессы өзелә. Һәм бу хәл, барыннан да элек, иң тотрыклы милли дәүләтләр Россия һәм Татарстанга да кагыла. Бер-бер артлы каршылыклар туып торуга да карамастан, Татарстан һәм Россия моңа кадәр мөстәкыйль дәүләтләр булып киләләр. Бу ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрнең үз үзенчәлекләре була. С. Х. Алишев «Казан һәм Мәскәү: XV—XVI гасырларда дәүләтара мөнәсәбәтләр» дигән китабында бу турыда шактый җентекләп яза. Аның фикеренчә, бу мөнәсәбәтләр нигездә халыкара хокук нормалары кысаларында бара. Татарстанны яулап алганнан соң, рус милли дәүләте күпмилләтле рус империясенә әверелә башлый. Ә Татарстан үзенең бәйсезлеген югалта. Тарихчылар инде күптән: «Бу ничек һәм ни сәбәпле шулай килеп чыккан соң?» дигән сорауга җавап эзлиләр.

Татарстанның үз дәүләтчелеген югалту сәбәбен кайберәүләр «тарихи халыклар» һәм «тарихи булмаган халыклар» теориясе белән аңлатырга тырыштылар. Бу теория буенча руслар «тарихи халыклар», ягъни дәүләтчел халыклар лагерена кертелә, ә татарлар «тарихи булмаган» (дәүләтчел булмаган) халыклар арасында калдырыла. Хәзерге вакытта күпләр Л. Н. Гумилевның «пассионар теориясе» (пассио — дәрт дигән сүздән) ягында торалар. Бу теория нигезендә, янәсе, ул вакытта руслар «пассионарлыкның» иң югары ноктасында торганнар,

ә татарлар, башка төрки халыклар кебек үк, бу вакытта инде үзләренең «пассионарлыкларын» моңа кадәр булган империяләрдә (Алтын Урдада, Хәзәр каһанлыгында, Кара диңгез буе Болгарында, азаккы Һун империясендә) сарыф итеп бетергәннәр, дигән фикер ята.

Моңа охшаш теорияләр бу мәсьәлә белән тирән кызыксынучыларны канәгатьләндерә алмый. Бәлки, җавапны «универсаль теорияләрдә» түгел, конкрет халыкның конкрет тарихында эзләргә кирәктер. Идел буе Болгары заманыннан ук татарларда: дәүләт ул — борынгыдан бирле яшәүче һәм халыкның тормыш корырлык хәлгә китерелгән үз территориясендә хезмәт итү, ул территорияне саклау, яшәү өчен җайлаштыру вазифасын башкаручы ярдәмчел социаль оешма, дигән караш яши. Татарлар үз территорияләрендә игенчелектә һәм терлекчелектә шактый гына уңышларга ирешәләр, аларның ярыйсы гына төзекләндерелгән авыллары була, сәүдәдә һәм һөнәрчелектә дә алар аерата маһир. Әле Идел буе Болгары ук бөтен дөньяга шәһәрләр иле буларак таныла. Алар халыкара мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә дә үзләренчә якын киләләр. Монда да сәяси һәм территориаль мотивлар түгел, сәүдә һәм һөнәрчелек мотивлары беренче планга чыга. Аларның характерында яңа территорияләрне колониягә әверелдерү теләге түгел, аларны сәүдә өчен «үзләштерү» омтылышы көчле була. Татар халкының табигатенә үк хезмәт сөючәнлек салынган. Татарстан башка илләргә, аларның ихтыяҗына бәйле рәвештә, бик күп йомышлы кешеләр бирә. Мәсәлән, Төркестанда, күбесенчә мәгърифәт һәм мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр, Россиядә шулар белән бергә тагын хәрбиләр дә хезмәт итә. Һәм аларның хезмәте һәркайда югары бәяләнә.

Сәүдә, һөнәрчелек, хезмәт — барыннан да бигрәк азатлыкка һәм тигез хокуклылыкка, мөстәкыйльлеккә һәм үзара аңлаша белүгә мохтаҗ. Татарларның сәяси берләшү ягында торулары, бәлки, нәкъ менә шуның белән аңлатыла да. XVI гасырның урталарында Көнчыгыш Европада зур абруйлы ике татар дәүләте — Казан һәм Кырым ханлыклары яши. Азов буе татар дәүләте (Зур Урда) 1502 елда Кырымга кушыла. Татар дәүләтләре арасында берләшү процессы шуның белән туктый. Казан дәүләтендә Кырым, Себер, Әстерхан, Нугай дәүләтләре белән бәйләнешләрне ныгыту сәясәте тормышка ашырыла. Ләкин бу дәүләт дәрәҗәсендәге пантатар берләштерү идеологиясе һәм сәясәте булудан ерак тора. Инде

гамәлдә булган мөселманлык бердәмлеген үстерү белән чикләнелә. Хәлбуки татар дөньясының эшләре ул чакта үз территориясен киңәйтү, Көньяк һәм Үзәк Европада үз позицияләрен ныгыту белән мәшгуль Төркияне аз кызыксындыра.

Россиядә исә беркадәр үзгәрәк вазгыять урнаша. XVI гасырда биредә, мөстәкыйль Новгород һәм Псков республикаларын да кертеп, төньяк рус кенәзлекләрен бердәм милли дәүләт итеп берләштерү процессы тәмамлана. Иван IV көньяк рус (Украина) җирләренең Польшада һәм Литвада калган өлешен дә Мәскәү тирәсенә берләштерү максатын ачыктан-ачык белдерә. Ул гына да түгел, Иван III һәм Василий III ләр заманында ук туган дөнья державасы төзү идеологиясе һәм сәясәте Иван Грозный вакытында тәмам формалашып җитә. «Дәрәҗәләр китабы» («Степенная книга»; XVI гасыр), патша хакимиятен «Алла үзе яраткан» булуны раслап, Мәскәү кенәзләренең нәсел җебен үз вакытында беренче булып шәхси хакимият урнаштырган Рим императоры Августка ук тоташтыра. «Хак динне» саклап калу максатларында да Россиянең Рим империясе белән бәйлелеге идеясе алга сөрелә. Бу «Мәскәү — ул өченче Рим (Римнан һәм Византиядән кала)» дигән гыйбарәдә дә чагыла (гыйбарәнең авторы — XVI гасырда Псковта яшәгән Филофей атлы кеше). Шулай итеп, Мәскәүнең дөньяви һәм дини хакимиятләре рус җирләрен берләштерүдән Мәскәүгә башка дәүләтләрне кушу эшенә күчүгә йөз тоталар.

Иван IV нең 1551 елгы агрессиясен кире кайтару. Сөембикә һәм Казан хөкүмәте, Мәскәүнең Казанны ничек кенә булса да буйсындырырга һәм, шулай итеп, империячел экспансия сәясәтен дәвам иттерергә карар кылуы сәбәпле, Татарстанга нинди зур куркыныч янавын аңлыйлар. Сөембикә улы Үтәмешгәрәй һәм үзе исеменнән Иван IV кә сөйләшүләр башларга тәкъдим итә. Мәскәү Сөембикәнең тәкъдимен кире кага. Иван Грозныйның үзен Иван Пересветов дип атаган бер киңәшчесе, Казанны «гәрчә ул дустанә мөнәсәбәттә булган очракта да» яулап алырга кирәк, дип, «чөнки Казан патшалыгы — ул бар кешенең күңеленә хуш килердәй оҗмах җире»,— дип яза. Казанның Россиягә беркайчан да янаганы булмаса да, ул Казанны яулап алуны «дәүләтне саклау максатларында» эшләнә дип атый.

Татарстанны яуга каршы торырга әзерләргә — килеп туган хәлдән чыгуның бердәнбер юлы әнә шуннан гыйбарәт була.

һәм җаваплы, һәм патриотик бу бурычны хәл итүне зирәк сәясәтче Сөембикә үз өстенә ала. Казанның, татар милләтенең изге нияттәге барлык кешеләре Сөембикә ханбикә тирәсенә туплана. 1546—1551 елларда Казан ханлыгы хөкүмәтен җитәкләгән Кошчак шәһәрдән киткәч, аның урынын Ходайкол били. Сәед Колшәриф җитәкчелегендәге мөселман руханилары Сөембикәгә тулы ышаныч белдерәләр һәм кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышалар. Карачы биләр Нургали Ширин, Япанча, морза Шунак, Борнаш һәм башкалар һәрвакыт Сөембикәнең янәшәсендә булалар. Дошман явын кире кагуга хәзерлек эшләре урыннарда да, шул исәптән рус гаскәрләренең юлы өстендәге чуваш, мари җирләрендә дә алып барыла.

Казан ханлыгына каршы яу йөрүләрнең беренче икесе Иван Грозный әмере буенча 1549 һәм 1550 елларда оештырыла. Бу елларда Казан гаскәрләре, Сөембикә үзе, аның даирәсе һәм аларның сәясәте сынауны уңышлы үтәләр, русларның һәр ике явы уңышсызлыкка очрый. Әмма Россия патшасының сәясәте торган саен аяусызлана бара. Киңәшчеләре Иван Грозныйга Казанга һөҗүмне традицион булмаган юл белән ясарга тәкъдим итәләр. 1550 елда Россиядә хәрби реформа үткәрелә. Патша гвардиясен тәшкил иткән хәрби тәҗрибәле даими укчылар корпуслары булдырыла. Подразделениеләргә баш итеп, бояр балаларыннан үзгә буларак, хакимияткә үрмәләү өчен дәүләт хезмәтендә булу кирәклеген аңлаган провинциаль дворяннар куела. Армия өчен, бигрәк тә артиллерия һәм инженерлык частьлары өчен, Көнбатыштан яңа белгечләр кайтартыла. Россия хәрбиләштерелгән илгә әверелә. Барлык бу эшләрдә патшага митрополит Макарий булышлык итә.

1551 елда иртә килгән язның бер көнендә патша җитәкчелегендәге рус гаскәрләре, чикне узып, Татарстан территориясенә үтеп керәләр. Башка сугыш кирәк-яраклары белән бергә, алар үзләре белән кирмән (крепость) салу өчен кирәк булачак бар нәрсәне төяп алып баралар. Кирмәнне Казаннан ерак түгел урынга, Зөя елгасы буена куярга һәм шуннан торып Казанга каршы һөҗүм башларга карар ителә. Шәһәрне штурмлауның зур җимерелүләргә һәм корбаннарга китерәчәген аңлаган хәлдә, Сөембикә һәм Казан хөкүмәте Иван IV кә сөйләшүләр башларга тәкъдим итә. Россия хөкүмәте Казанга түбәндәге таләпләрне куя: Сөембикәне һәм аның улы нәни Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә әсир итеп тапшырырга; руслар олавында

килгән, казанлыларга инде таныш булган Шаһгалине хан итеп кабул итәргә; барлык рус әсирләрен иреккә чыгарырга; дәүләт хезмәтендә булган барлык кырымлыларны шәһәрдән куарга; Казан дәүләтенең Иделнең уңъяк ярындагы өлешен Россиягә кушарга. Шулар бәрабәренә рус хөкүмәте Казан дәүләтендә мөселман администрациясе булдырырга, җирне хан кулында калдырырга, финанс автономиясе бирергә вәгъдә итә.

Бу ультиматум турындагы мәсьәлә 1551 елның 14 августында махсус чакырылган Җыенда тикшерелә. Ультиматумның шартлары авыр була, ә Казан дәүләтен кисәкләргә бүлү һәм аның уңъяк ярдагы өлешен Россиягә кушу турындагы таләп һич кабул ителерлек булмый. Сәед Колшәриф, баш казый, биләр Зәйнәш, Ислам, Галикәй, Көбәк, Дәрвиш бертавыштан әлеге таләпкә каршы чыгалар. Шәһәрнең җимерелүен, кешеләрнең күпләп корбан ителүен булдырмас өчен, Җыен ультиматум белән ризалаша, әмма дәүләтне кисәкләргә бүлүгә каршы чыга. Ул вакытта иң мөһиме дәүләтнең үзен саклап калу булганлыктан, Җыен руслар тәкъдим иткән Шаһгалине Казан ханы итеп кабул итәргә ризалаша.

Үз чиратында, Сөембикә ханбикә Казан дәүләтен саклап калу, зур корбаннар, җимерелүләр булдырмау хакына улы Үтәмешгәрәй белән бергә иректе рәвештә русларга әсирлеккә китәргә ризалык белдерә. Мондый карарга килү аның өчен, әлбәттә, бик кыен була. Бәлки, бу аның Ватанын гомерлеккә ташлап китүедер? Бәлки, ул мәрхүм иренең кабере белән бөтенләйгә саубуллашадыр? Үзенең халкы өчен, иле өчен башка берни дә эшли алмавын ул бик авыр кичерә. Сөембикә үзенең улы Үтәмешгәрәй белән, рус укчылары сагы астында, башта Зөя каласына, аннары Мәскәүгә озатыла. Нугай урдасы ханы Йосыфның кызы Сөембикәне аңа кайтарып бирү турындагы үтенечен Иван IV кире кага. Үз чиратында Шаһгали, шулай ук рус укчылары сагы астында, Казанга керә һәм Казан тәхетенә утыра.

Шаһгалинең хакимият башына нинди ният белән килгән булуын әйтүе кыен. Ул биредә үзен яратмаганлыкларын да, кабул итмәячәкләрен дә, алай гына да түгел, форсат чыгу белән аңардан котылырга тырышачакларын да аңлый. Шуңа да карамастан, аның беренче адымы, ультиматумның бәхәсле калган беренче пунктында казанлыларга ташламага барудан һәм Иделнең уңъяк ярындагы территорияне кайтарып бирүне үтенеп, Иван Грозныйга мөрәҗәгать итүдән гыйбарәт була.

Мәскәүгә ул җибәргән илчеләр Шаһгалинең позициясен менә болай аңлаталар: Шаһгали хан патшадан илнең Тау ягын кире кайтарып бирүне үтенә; әгәр бу мөмкин булмаса, шул як халкыннан салымны Казан ханлыгы файдасына җыюга рөхсәт сорый; төзелергә тиешле шартнамә патша анты белән беркетелергә тиеш. Казан ягыннан инде бу шарт үтәлә.

Бу мөрәҗәгать бер Шаһгали ханныкы гына булмый. Күп кенә тарихчылар билгеләп үткәнчә, тынычлык ягында торучы Казан килеп туган кризисны компромисс ярдәмендә хәл кылырга әзер була. Мәскәүгә исә бары бер генә адым ясарга — татар дәүләте бөтенлегенең һәм аның мөстәкыйльлегенең саклануы белән килешергә генә кала. Һәм Казан моңа дусларча теләктәшлек белән җавап бирергә әзер була. Ләкин Мәскәү «юк» дип җавап кайтара. Алай гына да түгел, әлеге илчелекнең барлык әгъзалары заложниклар сыйфатында кулга алыналар.

Нәтиҗә үзен озак көттерми. Шаһгали ситуацияне кулда тоту сәләтен югалта. Даирәсендәге барлык кеше аңардан йөз чөерә. Бөтенләй берьялгызы калган хан Россия илчесе Палецкий кубызына бии башлый һәм Казанның бәйсезлеге ягында торучыларны юк итәргә керешә. Нәкъ шул максат белән хан тарафыннан махсус оештырылган кабул итү мәҗлесендә һәм шуннан соң ук бөтен шәһәрдә башланган эзәрлекләүләр вакытында 70 тән артык татар дәүләтчелеге тарафдарлары үтерелә. Алар арасында агалы-энеле Бибарс һәм Янбарс морзалар, Колай морза, Карамыш углан, Кадыш баһадур һ. б. була.

Россиянең 1551 елгы агрессиясенең нәтиҗәләренә йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: Иван Грозный үзенең куйган максатына ирешә алмый. Шәһәр оборонасын оештыруның югары дәрәҗәдә булуыннан, югары катлау кешеләре арасындагы бердәмлектән, халыкта патриотик рух хөкем сөрүдән хәбәрдар патша уңышсызлыкка очравы ихтимал булган эшне — шәһәрне штурмлауны кичектереп торырга һәм ул арада Казандагы дәүләт җитәкчеләре арасына таркаулык кертү, шәһәргә мораль-психологик басымны көчәйтүгә йөз тота.

Казанның җиңелүе. 1552 елда да катлаулы сәяси вазгыять дәвам итә. Россия Казан дәүләтенә Идел аръягындагы җирләрен кайтарып бирүдән баш тарта. Хәлне тотрыклыландыру Шаһгали ханның кулыннан килми. Бу чордагы рус чыганаклары Татарстанның Тау ягында булган күпсанлы чуалышлар турында хәбәр итә. Шаһгали ханга әлеге хәлдән чыгу өчен

бердәнбер юл кала — тәхеттән ваз кичү. Һәм ул шулай эшли дә. 6 мартта, үзенең бу гамәлен патша белән килештереп, ул үзенең сакчылары — рус укчылары белән бергә Зөя шәһәренә чыгып китә. Иделнең уңъяк ярындагы оккупация гаскәрләренең хәле тагын да катлаулана. Чыганаклар хәбәр иткәнчә, рус наместнигы карамагында тик Зөя кирмәне генә кала. Бүтән районнарга җирле халык контрольлек итә.

Казанда Мәскәүнең яңа поход башлаячагын аңлыйлар. Илне саклауны оештырырга кирәк. Казан тәхетенә Әстерхан ханзадәсе Ядегәр чакырыла. Сәясәттә һәм хәрби эштә ул инде яңа кеше түгел. Бу вакытта ул Нугай дәүләтендә яши. Ә аңа кадәр сигез ел буена русларда хәрби хезмәттә була. Дөрес, Казан дәүләтендәге хәлләр белән ул әлегә аз таныш. Шундый кискен моментларда аерата кирәк була торган абруй да әле җитәрлек түгел. Ләкин, Шаһгалидән аермалы буларак, ул татар дәүләтчесе була. Казанда яңа хөкүмәт оештырыла. Аның составына Шәйх әл-Ислам Колшәриф сәед, Чапкын Отучев, Галикәй Нарыков морзалар, баш казый һ. б. керә. Алар арасында иң актив эшчәнлек күрсәткән шәхес ул да булса Колшәриф була. Ул — милләтнең киң танылган абруйлы дин әһеле генә түгел, дипломатия, дәүләт сәясәте мәсьәләләрен яхшы белгән акыл иясе дә. Моңа кадәр дә аңа руслар белән күп тапкырлар сөйләшүләр алып барырга туры килә. Ул хәрби яктан да сәләтле кеше була.

Милли-патриотик көчләр әлеге хөкүмәт тирәсенә туплана. Һади Атласи билгеләп үткәнчә, Казан өчен хәлиткеч булган ул көннәрдә Шаһгалинең эзәрлекләүләреннән куркып, Казанны ташлап киткән күп кеше кире әйләнеп кайта.

Урыннарда, шул исәптән чуваш һәм мари җирләрендә өстәмә мобилизация үткәрелә. Иделнең уңъяк ярында яшәгән чувашлар патша наместнигын һәм аның укчыларын Зөя кирмәненнән чыгармыйча тоталар. Казан ныгытыла. Шәһәрдән читтә дә ныгытылган, яхшы коралланган каршылык күрсәтү пунктлары булдырыла. Арча һәм Биектау юнәлешләрендә хәрәкәтчән хәрби подразделениеләр куела. Яңа агрессия куркынычы халыкны туплый, берләштерә. Казанга бары тик бер генә нәрсә — халыкара булышлык күрсәтү генә җитми.

Төркия, Кырым, шулай ук Татарстанның күршесендәге башка илләр аның язмышына карата битараф калалар дип әйтеп булмый. Ләкин Төркия һәм Кырым ханлыгы, Россия—Татарстан сугышын халыкара конфликтка әверелдерергә

теләмичә, бу сугышта турыдан-туры бер яктан да катнашмыйлар. Аларның, Мәскәү һәм Казан, моңа кадәр инде булгалаган кебек, бу юлы да һәр ике якны канәгатьләндерә торган карарга килерләр, дип фаразлаулары да ихтимал. Иван Грозныйның 1551 елда үзенең яу йөрүен Казан тәхетендә Сөембикәне үз кешесе Шаһгалигә алыштыру белән чикләргә карар итүе Россия — Татарстан мөнәсәбәтләренең җайга салына башлавы итеп кабул ителә. Ул вакытта хәтта бертөркем татар сәясәтчеләре (Нургали Ширин, Костров, Хуҗа Алимәрдән) алга сөргән Россия һәм Татарстан униясен төзү идеясен гамәлгә ашыруга да аларның әллә ни исләре китми.

Ул арада Россия хөкүмәте үзенең армиясен Казанга кабат яу чабу өчен әзерли. Хәзерлек эшләре майда ук башлана. Июньдә гаскәрләр янына патша үзе килә.

Татарстанның дәүләт чиген рус армиясе 5 августта кичә. Гаскәрләрне митрополит Макарий үгет-нәсыйхәт әйтеп озата. Сез «алласыз» һәм «бозык» мөселманнарны христиан итү өчен изге эш белән, Алла эше белән барасыз, ди ул сугышчыларга. 30 августта рус армиясе Казанны чолгап ала. Шәһәрне камау өчен 150 мең кешелек армия, шул исәптән немецлардан һәм поляклардан торган 10 мең кешелек отряд, шулай ук Шаһгалинең татарлардан торган отряды туплана. Аларга каршы үз халкына таянучы 33 мең кешелек Казан армиясе тора. Бу сугыш үзенең кискенлеге белән моңа кадәр булганнарын уздыра һәм тарихтагы иң зур бәрелешләрнең берсе була.

Казан стеналары янында турыдан-туры бәрелеш август ахырында башлана. Руслар 30 сентябрьдә кальга стенасын шартлатуга ирешәләр. Чыганаклар хәбәр иткәнчә, 4 сентябрьдә алар шәһәрне су белән тәэмин итә торган чыганакны да шартлаткан булалар. Шартлатудан җимерелгән аралыктан һөҗүм итүчеләр ябырыла. Ләкин алар шәһәрне саклаучыларның көчле уты астына эләгә. 2(15) октябрьдә ныгытма диварларында тагын бер каты шартлау яңгырый. Бу шартлауларның иң һәлакәтлесе була. Барлыкка килгән ачыклыктан руслар шәһәргә бәреп керә. Урам сугышлары башлана. Колшәриф җитәкчелегендәге шәкертләр отряды Кремльдә соңгы бәрелештә катнаша. Колшәриф үзе шул бәрелештә каһарманнарча һәлак була. Шәһәрне саклаучылар, көньяк юнәлешендә чигенеп, Казанны калдырырга мәҗбүр булалар. Рус гаскәрләре Хан сараен кулга төшерәләр, Ядегәр ханны әсирлеккә алалар. Аны Мәскәүгә озаталар һәм төрмәгә ябалар. 2 (15) ок-

тябрь (һиҗри буенча 959 елның 13 шәүвәле) — шәһри Казанның җиңелүе көне — халык күңеленә милли кайгы һәм фаҗига көне булып кереп кала.

Иван Грозный Хан сараен үзе килеп карый. Рус патшасының Казандагы наместнигы итеп кенәз А. Б. Горбатый-Шуйский билгеләнә. Илне басып алуны тәмам беркетү өчен Казанда һәм Зөядә (Свияжскида) оккупация армияләре калдырыла.

Казанны басып алу Россиягә бик кыйммәткә төшә. Шәһәр мәңгегә бирелә ятып калган уннарча мең рус солдатларының гомерләре бәрабәренә яулана. Алар хөрмәтенә Казансу буена куелган һәйкәл бүген дә моны искә төшереп тора. Хәрби җитәкчеләр арасында да югалтулар зур була. Рус гаскәрләре белән командалык иткән кенәз Курбский берничә тапкыр каты яралана. Рус һәм татар халыклары арасында моңа кадәр яшәп килгән дуслык мөнәсәбәтләренә зур зыян китерелә. Ләкин әле Татарстан тулаем яулап алынмаган. Казанның алынуы татар халкы өчен һичнәрсә белән дә чагыштырыла алмаслык зур югалту була. Ләкин бәйсезлек өчен көрәш әле тәмамланмый.

Оккупациягә каршы көрәш. Казанны кулга төшергәннән соң, рус гаскәрләре өч зур операция үткәрәләр: Казанда яшәүче бар халыкны шәһәрдән куып чыгаралар; Кремль һәм шәһәрдә татарныкы булган барлык архитектура истәлекләрен, шул исәптән Кремль диварларын һәм капкаларын, сарай һәм мәчетләрне җимерәләр; куылганнарның бар мал-мөлкәтен, шул исәптән йорт-җирен талыйлар. Татар Казаны күпмедер вакытка бөтенләй юкка чыга. Татарстанның башка төбәкләрендә дә оккупация тәртибен урнаштыру башлана. Патшага «хыянәт итүдә» шик астына алынган кешеләрне җәзалыйлар. Беренче көннәрдә үк патша наместнигы әмере буенча Казан янында каршылык күрсәткән йөзбашы Тугай отрядыннан (марилар) «Тугай балалары» дип аталган 38 кеше асып үтерелә. Зөядәге наместник та аңардан калышмый. Аның фәрманы буенча, чыганакта әйтелгәнчә, гаскәрләргә каршылык күрсәткән өчен, Цивильск чувашларыннан 74 кеше җәзалап үтерелә. Кама һәм Вятка елгалары ярлары буйлап Д. Ф. Адашев командалыгындагы хәрби отряд рәхимсез кылана. Боларның барысына да җавап итеп, илдән рус оккупация гаскәрләрен куып җибәрү өчен куәтле халык хәрәкәте башлана. Хәрәкәтне Галиәкрам хан җитәкли.

Шәһәрдән кысрыклап чыгарылган Казан ханлыгы гаскәрләре, төньяк-көнбатыш юнәлешендә чигенеп, Татарстан — Россия чигеннән ерак булмаган стратегик яктан бик мөһим урында, Чалым кальгасында тупланалар. Әлеге ныгытма һәм шәһәр Иделнең текә ярында, бүгенге Марий Эл Республикасының Козьмодемьянск шәһәреннән ерак түгел урнашкан була. Иделнең сулъяк ярында — мари болыннары. Кальга итәгендә Идел ага, ә ерак түгел генә пристань урнашкан. Элек шәһәр Россия — Татарстан сәүдәсе базаларыннан берсе булган. Язмыш Чалымга дүрт ел дәвамында оккупациягә каршы сугышучы Татарстанның вакытлы башкаласы булырга язган. Дәүләтнең башлыгы сыйфатында Казанга Сарайчыктан Сөембикәнең энесе Галиәкрам морза чакырыла. Ул нугайлардан торган отряды белән Чалымга килә. Килүе белән үк аны Казан тәхетенә утырталар. Хөкүмәт башына Зәйнәш би куела. Илбасарларга каршы көрәштә чуваш һәм мари халкы да катнаша. Мәсәлән, йөзбашы Мәмешбирде отряды шундыйлар рәтеннән.

Илнең башка төбәкләрендә дә каршылык күрсәтү учаклары оештырыла. Мишә елгасының югары агымындагы Мишә-Тамак шәһәрчеге шундый пунктларның берсе була. Биредә каршылык күрсәтү операцияләре белән сәед Хөсәен җитәкчелек итә. Биектау һәм Арча җирендәге каршылык күрсәтү отрядлары бик актив хәрәкәт итәләр. 1552 елның җәеннән башлап Арча юлы (тракты) буйларында Япанча бәкнең отряды бик нәтиҗәле сугыша. Татарстанның уңъяк Идел буе җирләрендә оккупантларга каршылык күрсәтү киң колач ала. Биредә воевода Борис Морозов җитәкчелегендәге җәзалау отряды бөтенләй юкка чыгарыла, ә каршылык күрсәтү көчләре воеводаның үзен әсирлеккә төшерә. Халыкның рус администрациясенә буйсынмавы гомуми төс ала.

Халыкның — татар, чуваш, мариларның — ясак түләмәве турындагы хәбәрләр Мәскәүгә торган саен күбрәк барып ирешә. Оккупация гаскәренең хәлне үз кулында тотарга сәләтсез булуы көннән-көн ныграк ачыклана. 1553 елның сентябрендә Мәскәү Татарстанга кенәзләр С. М. Микулинский һәм И. В. Шереметев җитәкчелегендә яңа гаскәри көчләр җибәрергә мәҗбүр була. Шул ук елның көзге-кышкы операцияләре вакытында алар, башлыча үзәктә, Казан тирәсендә, каршылык күрсәтү пунктларын һәм отрядларын югалтуларга дучар итәләр. Мишә елгасындагы Мишә-Тамак кальгасына һөҗүм оештыралар. Тарихчы С. М. Соловьев сүзләренә кара-

ганда, рус гаскәрләре биредә ир-егетләрдән 6 мең, хатын-кызлардан 15 мең кешене әсир итәләр. Әмма каршылык күрсәтүчеләр җиңелми.

1554 елның җәендә оккупантларга ярдәмгә тагын армия җибәрелә. Илнең яңа башкаласы бирешмәс Чалым кальгасы, Зөя белән Васильсурск арасында Идел буйлап элемтәне өзеп, Мәскәүгә тынгылык бирми. Кенәз И. Ф. Мстиславский шәхсән үзе Чалымга каршы һөҗүм сугышлары белән җитәкчелек итәргә алына. Ләкин нәтиҗә генә ул көткәнчә килеп чыкмый. Чалымлыларның каршылык күрсәтүе легендар вакыйгага әверелә.

1556 елда Татарстанда халык басып алучыларга каршы баш күтәрә. Бу бәйсезлек өчен көрәшнең иң югары ноктасы була. Ләкин көчләр тигез булмый шул. Өстәвенә Мәскәү әхлак һәм халыкара хокук нормалары белән исәпләшмичә эш итә. Соңгы дүрт ел дәвамында тупланган хәрби көчләре белән ул халык күтәрелешен канга батыра. Бу сугышта Мәмешбирде җитәкчелегендәге марилар отряды да тар-мар ителә. Ә ул үзе, М. Г. Худяков «бәйсезлек өчен көрәш юлбашчысы» дип атаган кеше әсир ителеп, Мәскәүгә озатыла һәм анда асып үтерелә. Рус гаскәрләре Чалым кальгасын камый, Казанны алгандагы тәҗрибәне кулланып, аның диварларын шартлата һәм кальганы үз кулларына төшерүгә ирешә.

Шушы вакыттан татар халкының бәйсезлек өчен көрәше әкренләп сүрелә башлый, ләкин каршылык күрсәтү башка рәвешләрдә дәвам итә.

Россия хәрби администрациясенә каршылык күрсәтү. Әле Казанда булганда ук Иван Грозный, илнең һәр төбәгендә татар-ислам хакимиятен таратып, рус администрациясе булдыру турында фәрман чыгара. Бу элек Казан дәүләте составына кергән һәм үз администрацияләре булган мордва һәм удмурт җирләренә дә кагыла. Хәрби характердагы яңа хакимият органнары татарлар хакимиятен һәм җирле халыкны стратегик яктан мөһим торак пунктларыннан кысрыклап чыгарып урнаштырыла. Аларның башында воеводалар тора. Тәрҗемәчеләр сыйфатында бу хакимият органнарында эшләү өчен патшага тугрылык анты эчкән татарлар җәлеп ителә. Хәрби администрация, укчылардан торган гарнизон басып алынган шәһәрләрдән татарларны куа һәм бу шәһәрләрне анда яшәүчеләрнең милли составы буенча гына түгел, исемнәре буенча да русныкы итә. Идел, Кама, Зөя, Казансу

буйларындагы стратегик яктан мөһим зоналарны, шулай ук әһәмиятле юллар тирәсендәге стратегик зоналарны, җирле халыктан чистарта һәм һәр төбәктә гомумроссия тәртибен урнаштыра.

Шулай итеп, сугыш хәрәкәтләре китергән җимерекләргә озак еллар буе дәвам иткән оккупация талавы өстәлә. Казан бик зур зыян күрә. Җирле халыкка шәһәргә керү тыела. «Писцовая книга»да Хан сараеның һәм аның белән янәшә торган мәчетнең корал складына әвереледерелүе һәм икенче бер мәчетнең дары склады ителүе турында язу сакланган. «Нургали палатасы» (Нургали Шириннең бай гына йорты һәм мәчете) ватык туплар һәм җимерек тәгәрмәчләр склады итеп файдаланыла башлый. Казан әйләнәсендә татарларга яшәү тыелган 50 километрлы зона булдырыла. Идел, Кама, Вятка елгаларының һәр ике як ярларында һәм олы юллар буйларында да татар авыллары юкка чыга. Казан үзенең үзенчәлекле архитектурасын югалта. Туган-яшәгән җирләреннән куылган кешеләр Татарстанның эчкәреге төбәкләрендә сыеныр урын эзләргә, җәфа чигәргә мәҗбүр булалар. Халыкның сәүдә һәм һөнәрчелеккә нигезләнгән, инде гадәтләнгән яшәү рәвеше бозыла. Халык өстенә салынган ясак хуҗалыктагы бөлгенлек шартларында авыр йөк булып төшә.

Төбәкнең башка шәһәрләре, шул исәптән Болгар, Биләр ташландык хәлгә килә. Аларда да күп кенә архитектура ядкәрләре җимерелә. Яндыру-җимерүләр соңрак та дәвам итә. Мәсәлән, тарихчыларның сүзләренә караганда, Казандагы Хан сарае әле XVIII гасырда чагыштырмача төзек була. Аны 30 нчы елларда төзелгән комендант йорты составына кертәләр. Ә XIX йөзнең 40 нчы елларында, бу урында губернатор йортын салыр өчен, аның калган кадәресен дә сүтеп бетерәләр. Кремльнең бүгенге диварлары да күп дошманнарга каршы торган элекке диварларның нык фундаментына салынган.

Казан җимерелгәннән соңгы матди авырлыкларга рухи бәла-казалар өстәлә. Аларны ил өстенә митрополит Макарий алып килә. 1555 елда Казанда архиепископ кафедрасы оештырыла. Аның алдына җирле халыкны чукындыру бурычы куела. С. М. Соловьев бу гамәлгә Казанны буйсындыруның тәгәлләнүе дигән бәяне бирә. Архиепископ белән бергә Казанга православие миссионерларының бөтен бер гвардиясе килә.

Үзенең яңа тәртибен урнаштырырга омтылып, хәрби адми-

нистрация теләгәненең киресенә генә ирешә. Җирле халык белән хәрби администрация арасында аңлашылмаучылык һәм дошманлык упкыны тирәнәя генә. М. П. Покровскийның билгеләп үтүенә караганда, Казан җиңелгәннән соң алты ел дәвамында рус гарнизоннары җирле халык тарафыннан «камап алынган» хәлдә яшиләр. Агрессия белән бәйле булган кан түгелү һәм үтерүләргә, талау һәм көчләп чукындыруларга, дини хис һәм милли абруйны мәсхәрәләүгә җавап итеп, Татарстан халкы 1556 елдан соң да озак еллар буе оккупантларга каршылык күрсәтә. Бу каршылык еш кына аерым күтәрелеш учаклары булып кабына, ә кайчакларда гомумхалык акциясенә дә әверелеп китә.

Чыганакларда 1572 елда, Кырым гаскәрләре Мәскәүгә каршы яу йөргәндә, Татарстан халкының киң күләмдә чыгыш ясавы турында хәбәр ителә. Иделнең уңъяк ярында баш күтәргән татар һәм мари отрядлары русларның хәрби частьларын кысрыклап баралар, Кама Тамагы тирәсендә алар белән йөзгә-йөз очрашалар, кабынып киткән бәрелештә 87 кешене үтерәләр. Иделнең сулъяк ярдагы өлешендә баш күтәргән татар, мари, башкорт отрядлары хәрәкәт итә. Оккупацион гаскәрләргә ярдәмгә Мәскәү воевода Н. Р. Одоевский командалыгында зур хәрби отряд җибәрергә мәҗбүр була. Оккупациягә каршы 1582 елдагы гомумхалык восстаниесе шулай ук куәтле була. Рус елъязмасында бу уңайдан болай язылa: «Казан буйсындырылганнан соң 31 ел үтә һәм мәлгунь басурманнар патша хәзрәтләре кул астында яшәргә теләмәделәр, гаскәр булдырдылар, күп кенә шәһәрләрне кайтардылар. Патша, аларның буйсынмавын күреп, аларны әсир итү максатында, Казанга каршы бояр һәм воеводаларын җибәрде. Ләкин кыргый җанвар төсле явызлар Мәскәү гаскәрләренә каршылык күрсәттеләр, станнарда да, походларда да Мәскәү кешеләрен үтерделәр; боярлар һәм воеводалар аларны бастыра алмады». Никон елъязмасыннан китерелгән бу өзекне шәрехләп торуның кирәге бар микән?!

Россия ни ота соң? Татарстанны буйсындырганнан соң, Россия рус җирләрен туплау һәм милли дәүләт төзү сәясәтеннән Евразия төбәгенең башка илләре территорияләрен колонияләштерүгә күчә. Иван Васильевич патшалык иткәндә Россиядә нибары 10 миллион кеше яши. Илдә җир җитәрлек була, әмма ул начар эшкәртелә, уңышны аз бирә. Дәүләт үз территориясен киңәйтү һәм империя төзүне максат итеп куя.

Яңа территорияләр басып алуны аларның, янәсе, борынгы рус җирләре булулары белән аңлаталар.

Казан дәүләте территориясе, шул исәптән чуваш, мари, башкорт җирләре дә русларны үзләренең байлыклары белән җәлеп итә. Татарстанны басып алуда турыдан-туры катнашкан кенәз А. М. Курбский болай дип яза: «...Ул җирдә басулар бик зур, бик тә уңдырышлы, орлыкны бик мул бирә торган... авыллар еш утыра, анда төрле-төрле ашлык шул тикле мул үсә, истигъфар вакытында әйтсәң дә кеше ышанмаслык: күк йөзендәге йолдызлар кадәр; шулай ук терлек көтүләренең исәбе-хисабы юк...»

Үз җирендә тормышны җайга салу турында кайгыртумы, әллә күршеләрдә инде булганны эксплуатацияләүме,— Россия хөкүмәте бу ике юлның соңгысын сайлый.

Иван Грозный сайлаган юл — Татарстанны басып алу һәм аны Россиягә кушу юлы,— чыннан да, аның колониаль империягә әверелүе өчен юл ача. Әмма монда бер сорау туа: бу юл иң оптималь юл булганмы соң? Әгәр дә Россия үзенең күршеләре белән уртак тел табу юлыннан киткән булса, бәлки бу аның бөек державага әверелүе өчен отышлырак булыр иде. Татарстанны яулап алу аңа бик кыйммәткә төшә. Без инде әлеге канлы сугышта Россиянең нинди зур корбаннарга барган булуы турында әйтеп үткән идек. Өстәвенә Россиянең башка халыклар алдында абруе бик нык какшый. Рәсми рус историографиясендә Иван IV нең «Грозный» дип аталуы аның «опричнинасы һәм күпләгән үтерү-җәзалаулары аркылы Россиядә бөтен халыкның котын алып торуы белән» аңлатыла дип раслана. Татар халкының хәтеренә ул «Явыз Иван» буларак кереп калган. Россия Кырым, Төркия һ. б. дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен боза. Россия цивилизациялерәк юлны сайлар һәм хәтәр адымнарга бармас, дип исәп тоткан Кырым һәм Төркиядә аның бу гамәле тискәре мөнәсәбәт тудыра. Һәм алар үч алу чараларына керешәләр. 1572 елның язында Кырым гаскәрләре, русларның каршылык күрсәтүен җимереп, Мәскәүне алалар. Иван Грозный, фронтны ташлап, Ярославльгә китеп бара. Тарихчылар Кырым ханының ул вакытта әйткән сүзләрен китерәләр: «Россияне бары тик Казан һәм Әстерхан өчен генә яндырам һәм корытам»,— ди ул. Ул вакытта бер Мәскәүдә һәм аның тирәләрендә генә дә 800 мең кеше үтерелә. 150 мең кеше әсирлеккә алып кителә.

Идел буе татарлары дәүләте (Казан ханлыгы). XV—XVI гасырлар



Католиклар Европасы ул вакытта ислам дөньясы алдында христианлыкны яклаган өчен Россияне мактый, әмма шул ук вакытта аны католиклар дөньясына да кертми. Россия, ислам динендәге һәм католик динендәге күршеләре белән ызгышып беткәч, бу күршеләрен көч-корал ярдәмендә үзенә буйсындыруга йөз тота башлый. Россия үзенең дәүләте, территориясе, армиясе, православие мәдәнияте белән куәтле илгә әверелсә дә, икътисади тормышта, халык мәдәнияте һәм көнкүреше өлкәләрендә түбән тәгәри, артта кала бара. Буйсындырылган илләрдә талап алынган байлык зур армия тотуга, бөлдергеч яңа сугышлар алып баруга, кирмән-ныгытмалар төзүгә һәм яулап алынган илләрдә гарнизон тотуга китә торган чыгымнарны каплауга да җитми. Татарстанны дәүләт бәйсезлегеннән мәхрүм итеп, Россия татар халкының үсешен тоткарлый.

ТАТАРСТАН РОССИЯ ИМПЕРИЯСЕ СОСТАВЫНДА

РОССИЯ КОЛОНИАЛИЗМЫ АСТЫНДА

Россия колонияләштерүенең үзенчәлекләре. «Колонияләштерү» төшенчәсе сүзлекләрдә ике төрле аңлатыла: буш яткан җирләргә колонистлар китереп утырту; басып алу юлы белән нинди дә булса илне эксплуатация объектына әверелдерү. Болар — колонияләштерүнең классик мисаллары. Көнбатыш илләре, соңгысына өстенлек биреп, аны XVI гасырда гамәлгә ашыра башлый. Африка, Азия, Латин Америкасы илләре колонияләштерү объектларына әверелә. Колонизаторлар эксплуатацияләү ысулларын акрынлап үзгәртәләр: буйсындырылган илләрдәге байлыкны (алтынны һ. б. файдалы казылмаларны, табигый байлыкларны) турыдан-туры илдән чыгарудан колониаль сәүдәгә күчәләр, ә аннары аларның үзләрендә колониаль җитештерү оештыралар.

Россиянең Татарстанны колонияләштерүе дә XVI гасырда башлана. Ләкин ул колонияләштерүнең классик формасыннан аерыла. Тарих фәнендә Россиянең колониаль төбәкләре үсеш дәрәҗәсе буенча аның үзеннән югарырак баскычта торалар дип исәпләнелә. Үзенең «оҗмах кебек» җире һәм нык үскән шәһәрләре, мәдәнияте һәм һөнәрчелеге белән Татарстан да әнә шундый илләр рәтендә тора. Алга таба да Татарстан Россиянең «аягында гер» булмый. Ул сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни өлкәләрдә Россиянең алга китүенә зур өлеш кертә. Татарстанның Россия империясе составында ирешкән уңышларын игътибарсыз калдырып булмаган шикелле, аның колония халәте үз үсешенә тоткарлык ясавын да билгеләп үтми мөмкин түгел.

Россиянең Татарстанны колонияләштерүдәге тагын бер үзенчәлек рус дәүләтенең һәм татар халкының Татарстан киләчәген төрлечә аңлауларыннан гыйбарәт. Көнбатышта

мондый очракларда һәр ике як (колониаль державалар һәм алар басып алган илләр) мондый кушылуның вакытлыча гына икәнлеген аңлыйлар һәм күпмедер вакыт үтү белән алар арасындагы мөнәсәбәтләр бөтенләй икенче төрле булачак дип саныйлар. Россия тарафыннан яулап алыну фактына Татарстан да нәкъ әнә шулай карый һәм киләчәктә үзенең бәйсезлеген торгызачагына ышана. Татарстанның Россия империясе составындагы дәверендә бәйсезлекне торгызуга юнәлдерелгән стратегик линиясе татар милли хәрәкәте өчен даими һәм үзгәрешсез саклана. Милли идея һәм аны гамәлгә ашыру тактикасы исә үзгәреш кичерәләр. Бу планда, һәрхәлдә, тактик өч этапны аерып күрсәтергә мөмкин булыр иде: милләт буларак саклану (XVII гасыр азагына кадәр); милли тергезелү (XVIII—XIX гасырлар); милли азат ителү (XX гасыр).

Сәяси колонияләштерү. Татарстанны сәяси колонияләштерүнең асылы татар дәүләтчелеген бетерүгә һәм илдә түбәннән югарыга кадәр рус дәүләтчелеген урнаштыруга кайтып кала. Бу бик төпле итеп, киләчәктә татар дәүләтчелеген торгызу мөмкинлеген булдырмауга исәп тотып эшләнә. Каршылык күрсәтү чорында Татарстан милләтнең иң яхшы вәкилләренең бөтен бер буынын югалта. Яңа буынга исә милли сәяси тормышка керү юлы тулысынча бикләнә.

Россия патшасы үзен «Казан патшасы»дип атый башлый, Татарстанда бөтен хакимиятне үз кулына ала. Мәскәүдә патша каршында Казан сарае Приказы (Казан Приказы) дигән орган оештырыла. Татарстанның бердәм территориясе бүлгәләнә. Бу юлда беренче адым булып ике воеводалык: Татарстанның Иделдән көнчыгышка таба булган өлеше белән идарә итү өчен Казан воеводалыгы, ә Татарстанның Иделдән көнбатышка таба булган өлеше белән идарә итү өчен Зөя воеводалыгы оештырыла. Шулардан Казан Приказына Татарстанның бары тик көнчыгыш өлешенең генә эшләрен алып бару тапшырыла. Татарстанның көнбатыш өлеше исә идарә итүдә гадәти рус җирләре белән тиңләштерелә. Дарухалар һәм автономияле кенәзлекләр бетерелә. Башларында воеводалар торган воеводалыклар һәм алар каршындагы хәрби гарнизоннар җирле хакимиятне тәшкил итә. Стратегик яктан мөһим булган татар торак пунктларыннан җирле халыкны куып чыгарып, аларны воеводалык үзәкләре өчен җайлаштыралар, яңа кальгалар — баструклар төзелә. XVI—XVII гасырларда элекке Казан дәүләтенең бөтен территориясе шундый баструк-

лар белән каплана. Алар Арчада, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Зәй, Спас, Тәтеш, Сембер, Самара, шулай ук Темников, Саранск, Арзамас, Чабаксар, Алатыр, Козьмодемьянск, Царевококшайск (марилар җире), Малмыж, Уржум, Белоярск, Зирекле, Яңа Чишмә һәм Уфада (Агыйделнең һәм Уфа елгасының түбәнге агымында) төзелә.

1571 елда Иван IV каравыл хезмәте уставын раслый. Анда бу баструклар тышкы оборона сызыгы итеп тәкъдим ителә. Чынлыкта аларның бурычы басып алынган территорияләр халкын тынычландырып, буйсындырып тотудан һәм яңа җирләрне басып алу өчен терәк базалары хезмәтен үтәүдән гыйбарәт була. Баструклар шулай ук рус кешеләре хөкүмәткә каршы күтәрелә калганда, аларны бастыру өчен дә файдаланыла. Бу сызыкларда тышкы агрессияне кире кагу очраклары булмый. Воеводалыкларда административ бурычларны хәл итү (ясак җыю һ. б.) өчен махсус дьяклар хезмәт итә. Җирле халык белән аралашу өчен, шул як халкы арасыннан чыккан һәм патшага тугрылык анты эчкән кешеләр тәрҗемәчеләр итеп җәлеп ителә.

Сәяси бәйсезлегеннән мәхрүм ителгән Татарстан тышкы дөнья белән традицион багланышларын да югалта. 1555 елда Себер татар дәүләте Мәскәү белән вассаллык бәйлелеге турында шартнамә төзи. Ләкин Мәскәүне бу гына канәгатьләндерми. Россия хөкүмәте XVI гасырның азагында көчле сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә Көнбатыш Себерне Россиягә куша. 1595 һәм 1596 еллардагы ике Азов походы нәтиҗәсендә Петр I, 75 мең кешелек армия һәм махсус төзелгән хәрби диңгез флоты ярдәмендә, башкаласы Азак (Азов) шәһәре булган Азов диңгезе буе татар дәүләтен үзенә буйсындыра. 1557 елда рус гаскәрләре Әстерханны яулап алалар — Әстерхан татар дәүләте яшәүдән туктый. Шулар нәтиҗәсендә Татарстан Россия белән күрше булган илдән Россия уртасында калган илгә әверелә.

Икътисади колонияләштерү. Яулап алынуның беренче көннәреннән үк Татарстанны икътисади колонияләштерү башлана. Сугыш хәрәкәтләре барышында рус армиясенең ихтыяҗлары хан (дәүләт) мөлкәтен һәм каршылык күрсәтүдә катнашкан кешеләрнең мөлкәтен талау һәм халыкның калган өлешеннән ясак җыю хисабына канәгатьләндерелә. Һәр кеше керемнең уннан бер өлешен тәшкил иткән ясакның күләме арттырыла. Җирле хәрби администрация үз ихтыяҗларын каплау өчен өстәмә салымнар кертә.

Казан дәүләтенә каршы поход башланыр алдыннан вәгъдә ителгәнчә, русларның сугышта катнашкан йомышлы кешеләренә Татарстанда зур-зур җир кишәрлекләре бүлеп бирелә. 1563—1567 елларда үткәрелгән ревизия күрсәткәнчә, бу максатлар өчен Татарстанда булган барлыгы 6 миллион дисәтинә җирнең 1,6 миллион дисәтинәсе, шул исәптән Иделнең уңъяк ярындагы өлешендә 200 мең дисәтинә һәм Иделнең сулъяк ярындагы өлешендә 1,4 миллион дисәтинә конфискацияләнә. Барлык дәүләт (хан) җирләре патша карамагына бирелә. Каршылык күрсәтүдә катнашкан кешеләрнең (әмир, углан, морза, сәед һ. б. җирбиләүчеләрнең, шулай ук сугышта һәлак булган гади игенчеләрнең) җирләре бояр балалары, чиновниклар, йомышлы дворяннар арасында бүленә, яңа монастырьларга бирелә. Бу җирләрдә русларның поместьелы җирбиләүчелеге оеша — рус алпавытлары һәм дворяннарының, Казан епархиясе һәм православие монастырьларының эре хуҗалыклары барлыкка килә. Бу хуҗалыкларда, башлыча, русларның элеккеге качкын крестьяннары, Татарстанда төпләнеп калырга теләк белдергән элеккеге рус әсирләре, шулай ук хуҗалары үзләре белән алып килгән крестьяннар һәм холоплар урнаша. XVI гасырның азагында патша Федор Ивановичның (Иван Грозныйның улы) крестьяннарга бер урыннан икенче урынга күчү мөмкинлеге биргән Юрий көнен гамәлдән чыгару турындагы фәрманы биредәге крестьяннарга да кагыла. Рус крестьян хуҗалыгы Татарстанда алпавыт крепостной хуҗалыгы булып формалаша.

Бер үк вакытта, бирегә үз ирке белән күченеп килүчеләрне урнаштыру бара. Андыйларга җир зур елга буйларында, әһәмиятле олы юл әйләнәсендә, рус гаскәрләре урнашкан шәһәрләр, яңа кирмән һәм баструклар тирәләрендә бүлеп бирелә. Андый урыннардан җирле халык көчләп куылган. Гамәлдә болар инде күптән үзләштерелгән, илдәге иң яхшы җирләр була, һәм андый җирләргә рус крестьяннары бик теләп килеп урнаша. Алар биредә җир эшкәртү алымнарын һәм крестьян хуҗалыгын алып баруның җирле ысулларын үзләштерә. Гадәттә мондый җирләрдә шактый төзек рус авыллары үсеп чыга.

Төп халкы куылып, бушап калган татар шәһәрләренә, рус гаскәрләреннән һәм рус администрациясендә эшләүчеләрдән тыш, аларга элегрәк килеп төпләнгән һәм Россиядән яңа күченеп килгән рус сәүдәгәрләре, һөнәрчеләре урнаша.

Татарстанның сәүдә юллары, шулай ук һөнәрчелек үзәкләре тулысы белән руслар кулына күчә.

Этник ассимиляция сәясәте. Россия империясенә көчләп кушылган халыкларны руслар рәсми телдә «туземецлар» дип атый башлый. Владимир Даль бу сүзне «та земля», «человек от той земли», ягъни «чит җирдән килгән кеше» мәгънәсендә аңлата. Бу сүзне «туземить кого — принять его в свои сограждане», ягъни «кешене үз гражданың итеп кабул итү» дип шәрехли. Әлбәттә, «туземец»ны үз җәмгыятеңнең тулы хокуклы әгъзасы итеп кабул итү — теләсә кайсы милләт өчен ихтирамга лаек эш. Әмма мәсьәлә бу гамәлне ничек башкаруда: аны үз араңа кабул итеп, көчләп ассимиляциялисеңме, әллә аңа интеграцияләнергәме, юкмы икәнен үзенә хәл итәргә мөмкинлек бирәсеңме? Татарларның христиан динен үз теләкләре белән кабул итүен, рус телен өйрәнүләрен һәм, ниһаять, кайбер татарларның тулысынча рус милләтенә күчүен тискәре бәяләү — гайре табигый нәрсә. Татарлар арасында мондый хәлләр русларның Татарстанны яулап алуларыннан шактый элек тә булган. Р. А. Әхмәтҗанов әйтүенчә, Нестор яклы христианнар (рәсми чиркәү тарафыннан 431 елда хөкем ителгән Константинополь митрополиты Нестор исеме буенча) миссионерлары VII—IX гасырларда Азов диңгезе буе, Дон буе, Каспий буе көнбатыш кыпчаклары арасында билгеле бер уңышка ирешәләр. Несторианлык Алтын Урдада үз позицияләрен саклап кала. Бәлки Алтын Урдадагы күп кенә татар-кыпчак гаскәр башлыкларының һәм сәясәтчеләренең, православиене кабул итеп, русларга хезмәткә каршылыксыз гына күчүләре шуның белән аңлатыладыр да. Татарлар соңрак та тиешле өстенлекләр бәрабәренә рус армиясендә хезмәт итәргә каршы килмиләр. XVII гасырда йомышлы татарлар бөтен Россия армиясенең 6—10 процентын тәшкил итә.

Әмма татарлар үзләрен милли мәдәнияттән һәм исламнан көчләп аеруга, мөселман татарларга православие динен көчләп тагуга һәм татар милләтенең рус милләте эчендә әкренләп йотылуына, ассимиляцияләнүенә йөз тоткан православие чиркәве яклавындагы рус дәүләт идеологиясе белән ризалаша алмыйлар. Алар рус дәүләтенең «бердәм ил (Россия), бердәм дәүләт (рус дәүләте) һәм бердәм халык (рус халкы)» формуласы белән билгеләнгән рәсми сәясәтен кабул итмиләр. Соңрак, XIX гасырда, бу идеология һәм бу сәясәт: «рус самодер-

жавиесе, рус православиесе һәм рус халкы» дигән формулада гәүдәләнә башлый. Ислам һичшиксез дошман дин дип игълан ителә. Татар халкы православиенең аң-белем бирүенә һәм русларның яклавына мохтаҗ «мәдәниятсез һәм адашкан» халыклар рәтенә кертелә. Күпчелек руслар һәм хәтта европалыларның да бер өлеше бу «уйдырма»га ышана. Карл Маркс Петр I нең Азов походлары турында сүз алып барганда бу төбәктә яшәүче татарларга карата «күчмә татар юлбасарлары» дигән гафу ителмәслек билгеләмә куллана.

1555 елда оештырылган Казан епархиясе, Татарстандагы православие динен тотучы русларга хезмәт күрсәтү белән беррәттән, махсус миссионерлык хезмәте аша татар торак пунктларында мөселманнарны чукындыру буенча киң кампания башлап җибәрә, яңа чукындырылган кешеләр өчен православие храмнары төзүне җәелдерә, рухани остазлар хәзерли. Алар өчен салым ташламалары билгеләнә. Рус хөкүмәте һәм православие чиркәвенең татар милли яшәү рәвешенә һөҗүме бөтен XVII гасыр буена дәвам итә. Иван IV нең эшен дәвам иттергән патша Федор Ивановичның, «Алла кушкан эш» дип атап, барлык татар авыл һәм шәһәрләрендәге мәчетләрне җимерү турындагы указы аеруча гаделсезлек үрнәге була. Мәчетләр җимерелү белән татар халкы мәктәп-мәдрәсәләрсез дә кала, ягъни халык мәгарифенең милли системасыннан мәхрүм ителә. Илдә барлык дәүләт эшләре рус телендә алып барыла башлый. Патша Федор Иванович 1593 елда, Казан митрополиты Гермогенның «яңа чукындырылганнар тәгълиматны (православие тәгълиматын) кабул итмиләр һәм татар гореф-гадәтләрен ташламыйлар» дигән хәбәрен алгач, андыйларны «төрмәләргә утыртырга, җәза таягы белән кыйнарга һәм богау кидертергә» куша.

Алга таба икътисади чаралар эшкә җигелә. Патша Алексей Михайловичның Законнар җыелмасы (Соборное уложение), яңа чукындырылганнарны православие динендә саклап калу максатларында, чукындырылган һәм чукындырылмаган татарлар арасында бәйләнешләрне киметү, яңа чукындырылган татарлар белән чукындырылмаганнар арасында җир алышбирешләрен тыю кебек чараларны күздә тота. Барлык бу чаралар нәтиҗәсендә XVII гасырда Татарстанда яңа чукындырылган татарлар, ягъни керәшеннәр төркеме формалаша. Алар үз вакытында Россиядә рус баринына хезмәткә күчкән татар крестьяннарының, шулай ук православиегә күчеп, үзенең

матди хәлен бераз яхшырткан элеккеге һәм яңа буын чукындырылганнар сафын тулыландыра. Татарларның үзенчәлекле православиечел яшәү рәвеше барлыкка килә. Керәшеннәрнең рухи тормышы ничектер икегә бүленә. Дине буенча ул православие кешесенә әверелә — православиенең күп кенә гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен кабул итә: чиркәүгә йөри, догасын укый, дини бәйрәмнәрне үткәрә, православиедәгечә никахлашу, кеше күмү йолаларын башкара. Әмма аның яшәү рәвешендә, психологиясендә татар тамырлары саклана. Аеруча мөһиме: алар татар телендә сөйләшүләрен дәвам итә.

МИЛЛӘТ БУЛАРАК САКЛАНУ

Милләт буларак саклану идеясе. Татарстанның руслар тарафыннан басып алынуы илнең тулысынча сәяси һәм икътисади колонияләштерелүе белән төгәлләнә. Һәр ике як — патша хөкүмәте һәм татар халкы — алга таба үзара мөнәсәбәтләр формуласын эзлиләр. Патша хөкүмәте Татарстанда классик колониаль эксплуатацияләү юлыннан бара алмаячагын аңлый. Югары сәяси, икъдисади һәм мәдәни үсешкә ирешкән халыкка карата мондый тактиканы куллануны ул куркыныч саный. Татарларның этник яктан тулысынча йотылуы, православие динендә, рус халкы эчендә ассимиляцияләнүе сәясәте сайлап алына.

Татар халкында милли идея калка. Аны татарларның милләт буларак сакланып калу идеясе дип тә атап булыр иде. Аның төп кыйммәтләре түбәндәгеләр: русларның сәяси һәм икътисади хакимлегенә яраклашып, киләчәктә милли тергезелү мөмкинлеген саклап калу; сәяси буйсыну; әмма, тыюга да карамастан, милли һәм рухи мәдәниятне югалтмау; үзләренең ислам оешмалары өчен чикләнгән генә булса да мөстәкыйльлекне хакимият органнарыннан көрәшеп алу. Татар халкы милли хәрәкәте якын киләчәктә шушы максатларны күздә тотып эш итә.

Ике линия — татар халкының этнос буларак тулысынча йотылуына юнәлдерелгән патша хөкүмәте линиясе һәм милли үзенчәлекне яклап көрәшүче татар милли хәрәкәте линиясе — Татарстанның XVII гасыр тарихы асылын тәшкил итә.

Икътисади яктан сакланып калу. Рус милли икътисады хакимлеге урнашуын таныса да, татар милли хәрәкәте татар милли икътисадын оккупация тарафыннан тулысынча йоты-

лудан коткарып калу, Россия икътисады составында аның мөстәкыйльлеген үк булмаса да, үзенчәлеген саклап калу бурычын куя. Моны, кыскача, икътисади саклануга юнәлдерелгән эшчәнлек дип атап булыр иде.

XVII гасырда патша хөкүмәте Татарстанны икътисади үзләштерү сәясәтен дәвам итә. Шәһәрләрдән кысрыклап чыгарылган татарларга кире әйләнеп кайту тыела. Һәм бу шәһәр кешеләре авыл тормышына җайлашырга мәҗбүр ителәләр. Үз авылларыннан куылган крестьяннар да яңа урыннарда бернинди ярдәм күрмичә яңа тормыш башларга тиеш була. Авыллар вагая, натураль хуҗалыкта йомылып яшәргә мәҗбүр була. Татар сәүдәгәрләренә хәтта сәүдә эшләре буенча да шәһәрләргә килү тыела. Вак һөнәрчелек аерата зур кыенлык кичерә. 1649 елгы Законнар җыелмасы буенча татарларга металл эшләнмәләр ясау тыела.

Шушы гаделсез чараларга да карамастан, руслар татарлар милли икътисадының бөтенләй йотылуына ирешә алмыйлар. Татарлар үз территорияләрендә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Алар үзләре яшәгән үзәк Идел-Кама төбәгендә, Иделнең уңъяк ярында, Казансу һәм Мишә елгалары бассейннарында, Вятканың үрге агымында (Нократ-Карин), Иж, Ык, Агыйдел елгаларының түбәнге агымында бик нык чикләнгән хәлендә булса да, хосусый милекне, шул исәптән җиргә, җитештерү һәм сәүдә оешмаларына хосусый милекне саклап калалар. Бер үк вакытта Касыйм ханлыгындагы мишәрләрнең һәм шулай ук Ока, Мукшы, Цна, Пьяна елгалары бассейннарындагы Темников, Алатыр, Кормаш, Кадом, Инсар татарларының икътисади тормышында консолидация бара. Вассал хәлендә генә булса да Касыйм ханлыгының яшәве бу төбәкнең икътисади хәленә уңай йогынты ясый.

Милли-мәдәни һәм рухи яктан сакланып калу. XVII гасырның азагына таба, ассимиляцион басымга карамастан, татар халкының төп массасы Казан дәүләтендә формалашкан милли мәдәният һәм телне саклап, исламның рухи кыйммәтләренә тугрылыклы булып кала. Татарларның Идел буе Болгар дәүләте чорында, ә аннары Казан дәүләтендә тирән тамыр җибәрергә өлгергән милли характеры, татар милли менталитеты шактый тотрыклы булып чыга. Милли үзаң, милли бердәмлек хисе юкка чыгарыла алмый.

Татарларның дәүләт һәм җәмәгать оешмалары куып таратылганнан соң, милләтне рухи берләштерү вазифасын үз

өсләренә мәчетләр ала. Бу ислам теократизмының тантана итүе булмый. Татарстанда мәчетләр гомер-гомергә икеләтә эш башкарып килә: дини-рухи һәм дөньяви-мәдәни эшләр. Шунысы да бар: халыкны сәяси түгел, ә дини оештыру чарасы сыйфатындагы мәчетләрне рус дәүләт хакимияте органнары каршында яклау да җиңелрәк бит. XVII гасыр азагына мөселман татарларның барлык торак пунктларында диярлек өр-яңадан мәчетләр төзелә. Алар әлегә таштан дә эшләнмәгән, зиннәтле итеп тә бизәлмәгән. Зурлыклары буенча да әллә ни искитәрлек булмаган гап-гади агач биналар. Аның каравы, исламның барлык кагыйдәләренә туры китереп салынганнар. Ә иң мөһиме: алар һәр җирдә бар. Мәчет имамнары традиция буенча ике вазифа башкаралар (рухи остазлар һәм укуязуга өйрәтүчеләр), мәчетләр каршында яңадан мәдрәсәләр ачыла, мәктәпләр барлыкка килә. Һәм мәчетләр яңадан аң-белем учаклары, мәгърифәт, фән, мәдәният үзәкләренә әверелә.

Россия хөкүмәте бары тик керәшен татарларының гына рухи һәм мәдәни тормышына булышлык итә. Ислам милли мәдәнияте халык түләп килә торган иганәләр хисабына гына яши. Ул вакытларда, нигездә, мәчет имамнарыннан торган татар милли зыялылары мәчетләр химаячелеге аркасында гына көн күрә. Татар имамнары бер үк вакытта халык арасында мәгърифәтчелек идеяләрен таратучылар һәм мәгърифәтчелек хәрәкәтен оештыручылар да, балалар укытучы мөгаллимнәр дә, шагыйрьләр, галимнәр, табиблар да булалар.

Мәчетләрнең рухи һәм мәдәни эшчәнлеге торгызылу белән беррәттән, XIV гасырда Нәкышбәнди (Баһаветдин Мөхәммәд бине Мөхәммәд Нәкышбәнди әл-Бохари, 1318—1389) тарафыннан нигез салынган дини-фәлсәфи нәкышбәнди агымы эчендә урта гасыр ислам суфичылыгы идеяләре һәм оешмалары да җанланып китә. Шәйбанилар һәм Аштарханилар династияләре вакытында Мәвараэннәһерне (Амударья һәм Сырдәрья елгалары арасындагы Сәмәрканд һәм Бохара шәһәрләре урнашкан территория шулай аталган) һәм Көнчыгыш Төркестанны исламлаштыруда үз ролен үтәгән дини-фәлсәфи нәкышбәнди агымы XVII гасырда Татарстанда да таралыш таба. Биредә ул читтән кертелгән суфичылык булмыйча, татарлардагы сөнничелек исламы кысаларындагы бер агымны тәшкил итә. Бу агым тарафдарлары «әдәплелек һәм пакьлек» идеясен тараталар. Үзләренең яшәү урыннарын

(хәнәкәләрен) мөселманлыкка өндәү үзәгенә әверелдергән утрак сәед-дәрвишләр пәйда була. Суфичылык изгеләре җирләнгән урыннарны (төрбәләрне) зиярәт итү башлана.

Татар язучылары да үзләренең әсәрләрен дини кысаларга туры китереп яза башлыйлар. Шагыйрь Мәүла Колыйның иҗаты XVII гасырның икенче яртысына туры килә. Әсәрләре җыентыгына кереш сүздә ул, бу әсәрләр Болгар җирендә язылдылар һәм 1677 елда (милади белән) төгәлләнделәр, дип яза. Аның хикмәтләре (ул үз әсәрләрен «хикмәтләр» дип атый) һәм газәлләре (шигырьләре) үзенең Аллаһы Тәгаләгә тугрылыклы булуын бәян итү, шулай ук бөтен тормышының һәм бар кылган гамәлләренең бөек Аллаһы кушканнарга туры килеп бетмәгән булуын тану рәвешендә язылган. Аларда шулай ук ул вакытларга хас булган җәмгыяви проблемалар да күтәрелә. Ул игенчеләрнең мәшәкать-борчулары, җәберләнгәннәрнең кыен тормышы, кешеләр арасында туганлык мөнәсәбәтләре урнаштыруның әһәмияте, әхлаклылык, шулай ук мәхәббәт һәм гашыйклар турында яза.

Ислам оешмалары, ассимиляция басымын йомшартырга тырышалар, әмма Россиянең башка халыкларыннан читләшүгә бармыйлар. Татарлар, үзләрен милләт буларак саклап калу белән генә чикләнмичә, Россиянең башка халыклары, чит ил гражданнары һәм төрки дөнья белән бәйләнешләрен торгызалар, дәвам иттерәләр. Казан татарларын элеккечә Көнчыгышта да, Көнбатышта да яхшы беләләр. Әйтик, XVII гасырда Римда басылып чыккан «Татар теле грамматикасы» күпләргә мәгълүм. «Codexus Cumanicus»тан соң (1303) бу — Көнбатышта дөнья күргән татар басмаларының берсе.

Татар милли мәдәниятенең, милли телнең сакланып калуы христианнарга һәм мөселманнарга бүленгән татар милләтенең эчке бердәмлеген саклауда зур роль уйный. Күп кенә йомышлы татарларның рус дәүләт хезмәтенең югары эшелоннарында булып та мөселман булып калганлыклары билгеле. Генерал-майор дәрәҗәсенә кадәр җиткән Котлымөхәммәт Тәфкилев, йомышлы дворяннар (морзалар) Ишеевлар, Яушевлар да менә шундыйлардан булалар. Аларның күбесе татар телен һәм, өлешчә, татарларның гореф-гадәтләрен дә саклап кала, татар милләте белән арасын өзми. Күбесе керәшен общиналарына берләшеп яши.

Халык чуалышлары. Халык чуалышлары милли ризасызлыкның бер төре була. Чыганаклар бу ризасызлыкны

чагылдыручы гомуммилли чыгышларны теркәмәгән. Ләкин бу әле милләт эндәшмәгән дигән сүз түгел. Ул вакытлардагы хәлдән ризасызлыгын халык гомумрус социаль кризислары, гомумрус чыгышларына кушылу юлы белән белдергән.

Иван III, Василий III һәм Иван Грозныйның ничәмә-ничә миллион кеше гомерен алып киткән, халыкка зур бәла-казалар китергән сугышлары аркасында тәмам өметсезлеккә төшкән рус җәмгыяте XVII гасырда икегә бүленә. Бу чорларда рус җәмгыятен, бер үк вакытта католиклар Көнбатышына һәм мөселманнар Көнчыгышына каршы куюны дәвам иттерергәме, әллә икенче бер юл табаргамы, дигән сорау борчый. 1649 елгы Законнар җыелмасын төзү комиссиясе әгъзасы, тарихчы Ф. И. Грибоедов Рюриковичлар (Иван Грозный) һәм Романовлар династияләренең сәяси линияләре бердәмлеген яклаучылар карашын чагылдыра. 1674 елда дөнья күргән «Киев синопсисы» «татар-төрек золымы»на каршы көрәштә барлык славяннарны берләштерүне, фин-угорлардан читләшүне яклап чыга.

Язучы Юрий Крижанич 1659 елда, Хорватиядән Мәскәүгә килеп, Россиядә Европа тибындагы абсолютизмны кабул итәргә чакыра. Тарихчы А. И. Лызлов үзенең «Скиф тарихы» дигән китабында (1692) бөтен Көнбатыш өчен уртак булган проблема — «күчмә халыкларның Европадагы утрак халыкларга басымы» проблемасы, шул исәптән Казан татар дәүләте тарихы турында фикер йөртеп, күчмәләрне «юк итүне» түгел, бәлки алар белән ныклы шартнамә төзү кирәклеген яклап чыга.

Мондый фикер каршылыклары XVII гасырда Россиядә ике төрле кризис туугa сәбәп була. Аларның беренчесе XVII гасыр башындагы чуалышларда чагыла. Ул вакытта хакимият башына, берсен берсе алыштырып, ике Ялган Дмитрий һәм боярлар килә, эш хәтта хакимияткә полякларны чакыруга кадәр барып җитә. Татар җирендәге рус хакимияте, әлеге тарткалашларда катнашып, шактый көчсезләнә. Ул арада чуалышлар татарлар арасында да массакүләм төс ала. Чыганаклар хәбәр иткәнчә, бу чуалышларның иң зурлары 1615—1616 елларда үтә. Алар ясакның микъдары арту һәм аны җыюның аеруча кырыслануы шартлары белән ризасызлыктан башланып китә. Хакимият органнары татар халкына махсус грамоталар белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Бу грамоталарда татарлар «Алланы һәм ислам динен истә тотып, тәртип сакларга»

чакырыла. Шуннан соң чуалышларда катнашучы татарлар арасында «Россиядән аерылып чыгуга ирешү» турындагы чакырулар таратыла. Ләкин бу таләп бәйсезлек өчен үткәндәге сугышларның кайтавазы гына булып кала. Россия, хакимияткә Романовларны чакырып, кризистан чыга һәм элеккеге сәясәтенә тугрылыклы кала. Татарстандагы чуалышлар бастырыла.

XVII гасырның икенче яртысында Татарстанда чуалышлар Россиядәге крестьян күтәрелешләре белән бәйләнгән. 1670 елда Степан Разин җитәкчелегендә баш күтәрүчеләр, көньяктан Россиянең үзәгенә таба хәрәкәт итеп, Самара районында Самара—Сызрань—Пенза дәүләт хәрби линиясен өзеп, аннары Сембер районында көнбатыштан көнчыгышка таба сузылган икенче дәүләт хәрби линиясенә (Воронеж — Козлов — Тамбов — Саранск — Сембер — Биләр — Зәй — Белоярск) килеп җитәләр. Баш күтәргән рус крестьяннары отрядлары һәм аларга каршы сугышыр өчен җибәрелгән регуляр гаскәрләр арасында бәрелеш Татарстанның Идел аръягында була. Иделнең сул ярындагы Татарстан территориясендә баш күтәргән рус крестьяннарының көчләре җитәрлек булмый. Биредә аларга хакимият органнарының гамәлләре белән риза булмаган татар, мари, чуваш крестьяннары ярдәмгә килә. Әмма татар крестьяннарының бу чыгышлары милли чыгыш формасын алмый.

Милли үзенчәлекне саклау. Рус хөкүмәте даирәләре, Татарстанны Россиягә кушу буенча ирешкән уңышлары эзеннән барып, аны тулысынча «үзләштерү» эшен ахырынача җиткерергә ашыгалар. Әмма хөкүмәтнең бу сәясәте уңышсызлыкка очрый. Моны рус историографиясе дә билгеләп үтә. В. О. Ключевский XVII гасырны истә тотып: «...һәм ул (рус халкы.— *Авт. аңлатмасы*) язмыш аңа Көнбатышта һәм Көнчыгышта «көчләп таккан», аңа бөтенләй чит булган төрле характердагы халыклар һәм кавемнәр белән нишләргә икәнен белмичә интегә, бу халыкларны яулап алу һәм идарә итү өчен тотылган чыгымнарны, үз тормыш дәрәҗәсенә китерелгән зыянны кыенлык белән каплап, аларны үзенә әхлак ягыннан буйсындырырга хәленнән килмичә җәфа чигә, бу халыклар йөзендә үзенә хезмәттәшләр түгел, ә дошманнар таба... Россия озакка сузылган бу чорда ашказанына кирәгеннән артык азык тутырып та аны сеңдереп бетерә алмаган кешегә охшый»,— дип билгеләп үтә.

Нәтиҗәдә Татарстан милли үзенчәлеген тулысынча саклап кала алмый. Ил милли яктан бастырылган татар һәм хаким милләт кешеләреннән торган рус общиналаларына бүленә. Татарлар үзләренең милли дәүләтчелеген югалтып кына калмыйлар, ә бәлки тагы да кысылырга һәм территорияләренең шактый өлешен үзмилли тормыш уклады, икътисады, теле, мәгариф системасы, мәдәнияте булган, православие динен тоткан рус общинасына бирергә мәҗбүр ителәләр. Әмма милли икътисад һәм көнкүреш традицияләре, шундый кысу хәлендә булса да, татар мәгариф системасы, милли тел һәм мәдәният, кыскасы, милли яшәү рәвеше саклана. Шуның белән бергә, Татарстанда әлеге ике общинаның үзара позитив бәйләнешләре башлана.

XVII гасыр татар милләтенең рухы көчле, сакланып калырга сәләте зур икәнлеген күрсәтә. Дәүләтчелеген югалткан хәлдә дә ул, үзенең тарихи җирендә тарихи традицияләргә тугрылыклы булып, этномәдәни һәм икътисади мөстәкыйльлеген һәм бәйсезлеген саклап кала. Татарстанның үзендә татарларның этномәдәни яктан сакланып калулары Себер, Нугай, Әстерхан татарларына, Рязань, Тамбов һәм Пенза җирләрендә яшәүче мишәр-татарларга, шулай ук башка рус шәһәрләрендәге татар диаспорасына рухландыргыч йогынты ясый.

МИЛЛИ ТЕРГЕЗЕЛҮГӘ ТАБА

Мәгърифәт җилләре. XVIII—XIX гасырларда тарихка киң һәм тирән мәгънәле «мәгърифәт» атамасы белән кереп калган цивилизацияле яңа феномен дөнья алгарышы байрагына әверелә. Мәгърифәтчелек Көнбатыш Европада старт ала. Аның иң күренекле вәкилләре Бөекбританиядә — Дж. Локк, Франциядә — Вольтер, Ж.-Ж. Руссо, Д. Дидро, Германиядә — Г. Э. Лессинг, И. Г. Гердер, И. В. Гете, АКШта Т. Джефферсон, Б. Франклин, Т. Пейн булалар. Алар тарафыннан тәкъдим ителүче социаль үзгәрешләрнең асылы, сословиеләрне бетереп, кеше иреген тану һәм тәэмин итү, һәркемгә хосусый милеккә ия булу, гражданлык хокукларыннан файдалану иреген тану кебек идеяләрдән гыйбарәт була.

Мәгърифәтчеләр җәмгыятьне үзгәртеп коруның абсолют монархияне бетерми торып мөмкин булмаячагын аңлыйлар. Халык суверенлыгы, милли суверенлык идеяләре күтәрелә.

Дин бердәмлегенә нигезләнгән империяләргә алмашка милли дәүләтләр килә. XVIII гасыр азагында «Халык үзенә яраксыз дәүләт режимын бәреп төшерү хокукына ия» дигән мәгърифәтчелек лозунгы астында башкарылган Француз революциясе җәмгыятьне абсолют монархия системасыннан азат итү һәм парламент республикасы системасына яисә парламентлы монархия системасына күчү өчен юл ача. Үзләренең карашларын шәрехләп, француз мәгърифәтчеләре, сословиесезлеккә, азатлык, тигезлек, туганлыкка ирешүче һәм үз тормышын үзенең милли территориясендә, милли дәүләтендә алып баручы халыкны билгеләү өчен, «милләт» төшенчәсен кулланышка кертәләр. Якобинчылар клубына нигез салучылардан берсе булган, Кеше һәм граждан хокуклары декларациясен эшләүдә катнашкан аббат Сьейес (1748—1836), бу төшенчәгә аңлатма биреп: «Милләт — бер үк гомуми закон нигезендә яшәүче һәм үзләренең ихтыярын бердәм закон чыгару хакимиятендә гәүдәләндерүче иптәшләр берлеге ул»,— дип белдерә. Шушы вакытлардан *«милләт»* сүзе ике мәгънәдә: *этномәдәни берлекне аңлата торган* элекке *социаль-этник мәгънәдә* һәм *социаль-сәяси (дәүләти) бердәмлекне белдерүче* яңа *мәгънәсендә кулланыла башлый.*

Россиядә мәгърифәтчелек һәм яңартып кору идеяләре. Ул вакытта Россиядә иң кискен һәм иң кичектергесез хәл ителәсе проблемалар: техник-икътисади артталыкны бетерү, крепостной крестьяннарны азат итү, патша самодержавиесенең дәүләт төзелешен яңартып кору (модернизацияләү), буйсындырылган рус булмаган халыкларга милли хокуклар бирүдән гыйбарәт була.

Көнбатыш Европадан аермалы буларак, бу проблемаларны хәл итүдә инициативаны самодержавие хакимияте үз өстенә ала. Русларның милли проблемаларын хәл иткәндә, ул Россиянең Көнчыгыш православиесе иле үзенчәлеген югалтмаска, яңартып коруны озаккарак сузарга тырыша. Рус булмаган халыкларга карата аларны колонияләштерүне тәгәлләүнең бераз йомшартылганрак сәясәте сакланып кала.

Император Петр I Россиядә хәрби һәм хәрби-диңгез технологиясе кертү өлкәсендә күп көч куя. Металлургия, кораблар төзү, сәүдә эшләре бик нык алга китә. Ә менә дәүләт төзелеше мәсьәләләрендә ул, рус дворяннары элитасы йөзендә дәүләтнең яңа таянычын формалаштырып һәм хакимиятнең чиркәү белән «изге союзын» төзеп, патша самодержавиесе режимын

алга таба ныгыту юлына баса. Европадагы техник яңалыкларны кабул итү һәм үзләштерү максатларында, Европага Балтыйк диңгезе аша да «капка» ача. Ә менә рус крестьяннарының хәле тагын да авырая, рус булмаган халыкларның хокуксызлыгы тагын да көчәя генә.

Императрица Екатерина II, дворяннар элитасын тагын да югары күтәреп, патша самодержавиесенең дәүләт төзелешен ныгытуда тагын бер адым ясый. Рус дворяннары армия өчен офицерлар гына түгел, фән, әдәбият, сәнгать эшлеклеләрен дә бирә. Дворяннар монархиясе мәгърифәтле монархия дип игълан ителә. Җәмгыятьтә бүленү көчәя. Бер якта хәрби яктан куәтле, фәне, мәдәнияте, сәнгате шактый үскән мәгърифәтле дворяннар монархиясе һәм икенче якта яңартып корудан читтә калдырылган рус крепостной крестьяннары берберсенә каршы торалар.

XIX гасырга керү белән рус җәмгыятендә крепостной крестьяннарны азат итү һәм рус милли дәүләтен оештыруның Европадагыча формаларына күчү турында сөйләшүләр башлана. Яшь Александр патшалык итүенең беренче елларында реформа үткәрергә тырышып карый, әмма тиздән бу фикердән кайта. Реформаторлык идеяләре белән мәйданга алдынгы карашлы дворяннарның декабристлар дип аталган кечкенә бер төркеме чыга. Француз революциясеннән соң 30 ел үткәч, алар самодержавиене конституцион монархия белән (Н. Муравьев) яисә конституцион республика белән (П. Пестель) алмаштырырга тәкъдим итәләр. Ләкин XIX йөз урталарына кадәр Россиядә мәгърифәтчелек идеяләрен гамәлгә ашыруда әллә ни алга китеш булмый. В. О. Ключевский ачыну белән болай дип яза: «Безнең дәүләтнең территориясе киңәйгән саен, халыкның ил эчендәге иреге кысыла барды», «Көнбатыш Европа мәдәнияте җимешләреннән никадәр киңрәк файдалансак, аның тигезлеккә һәм азатлыкка булган төп омтылышларыннан шулкадәр читләшә бардык». Декабристларның тәкъдимнәрен тормышка ашыруга Россия XIX гасырның 60 нчы елларыннан соң гына керешә.

Татар халкының (рус булмаган башка халыкларның да) аерым милли мәнфәгатьләренә килгәндә, монархлар сүздә үзләрен татарларны яклаучылар итеп күрсәтергә тырышсалар да, бу мәнфәгатьләр игътибарсыз калып килә. Әле Петр I үк татарларның Болгардагы борынгы ядкәрләрен җимерүгә чик куярга боерган махсус фәрман чыгара. Чынбарлыкта исә бу

фәрманның нәтиҗәләре булмый. Биредә ул вакытка әле җимерелеп бетмәгән истәлекләрне саклау һәм реставрацияләү өчен берни дә эшләнми. Нәтиҗәдә алар бөтенләй диярлек юкка чыга. Екатерина II 1762 елда Болгарда булганнан соң Вольтерга язган хатында: «Татар шәһәре Болгар җимерелә»,— дип хәбәр итә. Татар ядкәрләрен җимерүдә артык тырышлык күрсәткән архиепископ Канашевичны ул «әзәрлекләүче» дип атый. Чынбарлыкта Екатерина рус булмаган халыкларның хокуклары белән бөтенләй исәпләшми. Аның инициативасы буенча Украинада гетманлык бетерелә. Украина халкы Украинаның Россия белән кушылуы вакытында вәгъдә ителгән автономиянең соңгы калдыкларыннан да мәхрүм кала. Екатерина патша татар мәгърифәтчеләренең татар телендә китап бастыруга рөхсәт бирү турындагы үтенечен кире кага, рус крестьяннарының крепостнойлыкка каршы чыгышларын бастыруда рәхимсез була, язучы-мәгърифәтче Н. И. Новиковны Шлиссельбург крепостена яптыра, А. Н. Радищевны Себергә сөрдерә.

Татарстан территориясен административ бүлгәләүнең төгәлләнүе. Романовлар йорты хөкүмәте Татарстанны, шулай ук Россиягә кушылган рус булмаган башка халыкларның территорияләрен үзләштерү сәясәтен дәвам иттерә. 1681 елда Касыйм татар ханлыгы бетерелә. Россия административ бүленешендә соңгы татар атамасы юкка чыгарыла. *1708 елда* Петр I хөкүмәте *Казан губернасын* булдыру турында игълан итә. Гомумән, Россиядә территорияләре буенча шактый зур булган 10 губерна (Мәскәү, Санкт-Петербург, Киев, Азов, Казан, Сембер һ. б. губерналар) оештырыла. Казан губернасы идарәсенә, башлыча, моңа кадәр Казан Приказына буйсынган территорияләр керә. Идарәнең статусы үзгәрә. Элеккеге Казан татар дәүләте шартларын теге яисә бу рәвештә исәпкә алган «махсус» Приказ урынын русларның гадәти административ идарәсе ала.

1775 елда Екатерина II хөкүмәте, инде булган губерналарның мәйданын кечерәйтеп һәм шуларга башкаларын (Польша, Финляндия, Балтыйк буе дәүләтләрен, ә бераз соңрак Кырымны) өстәп, губерналар санын арттыра. Казан губернасында нибары 13 өяз (Казан, Арча, Лаеш, Мамадыш, Чистай, Спас, Зөя, Тәтеш, Ядрин, Козьмодемьянск, Царевококшайск, Цивильск, Чабаксар өязләре) калдырыла. Татарлар яши торган бүтән җирләр Вятка, Уфа, Самара, Сембер, Оренбург, Түбән Новгород губерналары арасында бүленә. Кечкенә-кечкенә

кисәкләр булып татар җирләре шулай ук Саратов, Пермь, Рязань, Тамбов, Пенза губерналары һәм Себердәге губерналар составына кертеләләр.

Татарларның иң тыгыз урнашкан губернасы булып Казан губернасы санала. Әмма анда да алар халыкның азчылыгын тәшкил итәләр. 1796—1798 елларда үткәрелгән бишенче тапкыр халык санын исәпкә алу мәгълүматларына караганда, губернаның 900 мең кешедән торган халкының 40 процентын татарлар, 52 процентын руслар, 8—10 процентын чуваш, мари, удмурт, мордвалар тәшкил итә. Башка губерналарда татарлар саны тагын да кимрәк була. Петр I нең һәм Екатерина II нең административ реформалары Татарстан территориясен кисәкләргә телгәләүне төгәлли. 1781 елда Казан, Саратов һәм Пенза губерналарын берләштергән наместниклык оештырыла. 1792 елда аны бетерәләр. Алга таба наместниклыклар Россия читендәге милли территорияләрдә барлыкка килә. 1815—1874 елларда Польша патшалыгында, 1844—1917 елларда Кавказда император наместнигы идарә итә.

Татар җирләрендә дәүләт хакимияте. Составларына татарлар кергән губерналарның барысында да самодержавие идарәсенең төп таянычы руслар була. Аларда урнаштырылган рус гаскәрләре, элеккечә, рус дәүләт хакимияте сагында тора. 1719 елда Казан губернасында дүрт хәрби полк урнашкан була. Алга таба губернада рус гаскәрләренең саны тагын да арта. Казан зур хәрби округ үзәгенә әверелә.

Губерна күләмендә генә түгел, ә татар өязләре, волостьлары һәм хәтта авылларында да рус дәүләт идарәсе урнаштырыла. Өяз үзәкләре һәм улус идарәләре рус торак пунктларына куела. Өяздә җирле рус дворяннары тарафыннан сайланып куела торган утырышчылар белән берлектә капитан-исправник идарә итә.

Россиягә яңа территорияләрне (Эривань кенәзлеген һәм һәм Нахичевань ханлыгын) кушкан, Польшада 1830—1831 еллардагы азатлык восстаниесен рәхимсез рәвештә бастырган, Украинадагы униатларны (грек-католик христианнарын) православие диненә көчләп күчергән император Николай I татар эшләренә дә кул суза. 1834 елда авыл һәм волость башлыклары итеп православие динен тоткан шәхесләрне генә сайларга кирәклеге турында әмер игълан ителә. Татар авылларында бу вазифаларны бары тик махсус сайлап алынган

керәшен татарларына гына ышанып тапшыралар. Фактта хәтта татар авылларында үзидарә бетерелә. Милли изү аппаратының бер өлеше булган хөкем органнарының барысы да рус милләте вәкилләреннән генә тора. Хакимият функцияләрен башкаручы рус чиновниклары (өяз полициясе башлыгы капитан-исправник, аның тарафыннан билгеләп куела торган частный пристав (шәһәрләрдә) һәм становой пристав (авылларда), приставның иң якын ярдәмчесе булган урядник, салым җыючы откупщик, авыл кятибе һ. б.) белән татар халкы арасындагы каршылыклар тирәнәя. Каршы тору шулай ук, бер яктан, татарлар һәм, икенче яктан, хөкем органнарының бары тик руслардан гына торган чиновниклары һәм XIX гасырның урталарында министр П. Д. Кисилев реформасы нигезендә төзелгән Дәүләт мөлкәте министрлыгы чиновниклары арасында да тирәнәя. Бу каршылык нигезендә, башлыча, чиновникларның ришвәт алуы ята. Чыганакларда теркәлгәнчә, шәхсән губернатор хәрби хезмәттән азат иткән өчен 20 сумнан 50 сумга кадәр ришвәт ала, чиновникларның хезмәт урыны белән сату итә.

Тергезелүнең икътисади кыенлыклары. Патша хакимияте вертикален ныгыту белән беррәттән, рус хөкүмәте Татарстанны икътисади йоту сәясәтен алып бара. XVIII гасыр башларында Петр I хөкүмәте татарларның эре җир биләүләрен чикли торган күп кенә фәрманнар чыгара. Татарларның хуҗалыкларында эшләүче крестьяннар дәүләт крестьяннары, ягъни салымны дәүләткә түли торган крестьяннар разрядына күчереләләр. Йомышлы татарлар хәрби хезмәт үтәүдән төшереп калдырылалар. Һәм алар үзләренең морзаларга тиешле өстенлекләреннән мәхрүм ителәләр. 1713 елда, әлегә чукындырылмаган татар морзалары ярты ел эчендә православие динен кабул итәргә тиешләр, дигән фәрман чыгарыла. Болай булмаган очракта әлеге фәрман «аларның җир биләмәләрен (вотчиналарын), крестьяннары белән бергә казнага алырга» куша. Ләкин аларның күбесе чукындырылуга бармый. Аларның хуҗалыклары кечерәя, ә үзләре, ул вакытларда халык арасында әйтелгәнчә, «чабаталы морзалар»га әвереләләр. Татарстанда бары тик рус алпавытлары гына кала.

Дискриминация чаралары татар сәүдәгәрләренә дә кагыла. Сәүдә өчен файдаланылучы су юллары һәм пристаньнар тулысынча рус сәүдәгәрләре кулына күчә. Татар сәүдәгәрләре коры юл сәүдәсе, бигрәк тә Көнчыгыш илләре белән сәүдә

позицияләрен кулга төшерә башлагач, хөкүмәт биредә дә алар өчен чикләүләр кертә. Татар эшмәкәрләренә дәүләт сәнәгатендә катнашу өчен юл ябыла, кредитлар алу кыенлаша, аларга металл эшкәртү предприятиеләре тоту гомумән тыела.

Гади татар крестьяннары да үз хуҗалыкларын алып баруда өстәмә кыенлыклар кичерәләр. Аларның күбесе дәүләт өчен суднолар төзи торган, Казанда оештырылган адмиралтействога беркетеләләр, ел саен берничә айга адмиралтейство өчен урман хәзерләү эшләренә җибәреләләр һәм хуҗалыкларыннан аерылып торырга мәҗбүр булалар. Андыйларны халык «лашманчылар» дип йөртә. Урал металлургия һәм бакыр эретү заводларына беркетелгән татар крестьяннары да шундый ук хәлдә була. Татар крестьяннары үз араларыннан шактый күп эш көче бүлеп бирәләр һәм аларны Санкт-Петербургка, Кронштадтка төзелеш эшләренә, Ладога каналын казуга, Ригада, Азовта портлар төзүгә җибәрәләр.

Рухи һәм мәдәни изүгә каршы тору. XVIII йөзнең беренче яртысында патша хөкүмәте татарларны этник ассимиляцияләү буенча өстәмә чаралар күрүгә керешә. 1720 елда православие динен кабул иткән татарларга салым ташламаларын күздә тотучы фәрман чыгарыла. Чукындыру дулкыны яңадан кузгала. Чиркәү мәгълүматларына караганда, 1724 елга Казан губернасында керәшен татарлары саны 2184 кешегә, 1724—1731 елларда тагын 811 кешегә арта. Татарларны христианлаштыру башка губерналарда да дәвам итә.

30 нчы елларда Петр I нең бу сәясәтен императрица Анна Иоановна дәвам иттерә. 1731 елда «Казан һәм Түбән Новгород мөселманнарын һәм башка чит халыкларны чукындыру комиссиясе» оештырыла. 1740 елда аның исеме «Яңа чукындырылганнар эшләре конторасы» дип үзгәртелә. Комиссия каршында православие миссионерларының эшчәнлегенә ярдәм итәргә чакырылган махсус хәрби частьлар була. Чыганакларда язылганча, 40 нчы елларда бу эштә халыкта «Аксак Каратун» дип йөртелүче Казан архиепископы Лука Канашевич аерата тырышлык күрсәтә. Еш кына миссионерлар, татарларның балаларын урлап, православие рухында тәрбияләү өчен монастырьларга урнаштыра торган булганнар. Архивларда сотник Кутлинның, ясаклы татар А. Хәсәновның, йомышлы морза Б. Исламовның, М. Дусаевның һ. б. шикаятьләре сакланган. Алар көчләп чукындыру вакытында үзләренә карата рәхимсез газаплау чаралары кулланылу турында язалар. Көчләп чукын-

дыру белән беррәттән мәчетләрне, мөселман руханиларын эзәрлекләүләр дәвам итә.

Этник ассимиляцияләү сәясәте императрица Елизавета Петровна заманында ачыктан-ачык дәвам иттерелә. 1744 елда, аның фәрманы нигезендә, Татарстанны Россиягә кушудан соң төзелгән 536 мәчетнең 418 е җимерелә. Татарстанны Россиягә кушканнан соң, яңадан төзелгән мәчетләрне җимерү кампаниясе Сембер, Әстерхан губерналарында һәм башка губерналарда да булып уза. Хәер, бу юлы әлеге сәясәт татар халкының кыюрак каршылык күрсәтүенә очрый. 1744 елда әлеге фәрман буенча Казан губернасында тагын 118 мәчет җимерелергә тиеш була. Ләкин халык моңа юл куймый. Көчләп христианлаштыруга кискен каршылык татар халык авыз иҗатында да чагылыш таба. Каюм Насыйриның халыктан «Аксак Каратун» риваятен язып алганлыгы билгеле.

Этник ассимиляция сәясәтенә каршы тору, әлбәттә, нәтиҗәсез үтми. Көчләп чукындырылган татарларның православиедән китүләре ешая. Чыганакларның берсендә 1851 елда Чистай өязенең Мөслим волостенда 12 татар авылында бөтен халыкның бер үк вакытта исламга кире кайтуы турында хәбәр ителә. Бу хәлдән хәвефкә төшкән хакимият һәм православие чиркәве ашыгыч чаралар күрә башлый. Әлеге татарларның бер өлешен, үгетләү максатларында, мәҗбүриләп монастырьларга җибәрәләр. Башкаларына карата хуҗалыкларын бөлгенлеккә төшерә торган икътисади чаралар кулланыла. Андый кешеләрне кулга алу, Себергә сөргенгә җибәрү очраклары да була.

XIX гасыр азагына таба бу мәсьәләдә билгеле бер тотрыклылык урнаша. Хөкүмәт татарларны православиегә күчерү сәясәтен дәвам иттерә. Әмма чынбарлыкта татарларны күпләп христианлаштыру да, чукындырылган керәшен татарларының ислам диненә күпләп кайтулары да күзәтелми. 1857 елда керәшен татарлары арасында православиене ныгыту максатында «Изге Гурий җәмгыяте» («Братство святого Гурия») оештырыла. Дини мөнәсәбәттә икегә аерылган татарлар чынбарлыкта татар милләтен формалаштыру юлыннан баралар. В. Н. Никольскийның тикшеренүләренә нигезләнеп, Р. У. Әмирханов, XX гасыр башында бөтен татар халкының 5,5 процентын 122 300 кеше керәшеннәр (православие динендәге татарлар) тәшкил иткән, дип саный. Керәшен татарлары общинасы барлыкка килү татарларның милли бердәмлеген бозмый.

МИЛЛИ ТЕРГЕЗЕЛҮНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Яңа милли ориентирлар. Милләт буларак сакланып калуга ирешелгәч, милләтнең тәмам аякка басуына йөз тоткан милли идея формалаша. Бу идея империячел милли кысулар сәясәтенә каршы торуга, татарлар тупланып яшәгән барлык тарихи территорияләрдә татарларның милли тормышын интенсив рәвештә аякка бастыруга, төрле губерналарда яшәүче һәм төрле дин (ислам һәм православие) тотучы татарларның уртак милли тел һәм уртак милли мәдәният нигезендә бердәмлегенә ирешүгә, киләчәктә татарларның милли дәүләтчелеген торгызуга юнәлеш ала.

Бу милли идеяне гамәлгә ашыру милли хәрәкәтнең төп максатына әверелә. Ә милли хәрәкәт үзе исә XVIII гасырда формалашкан рус демократик мәгърифәтчелек хәрәкәте белән мөнәсәбәтләр урнаштыруга һәм хезмәттәшлеккә бара. Россиянең демократик мәгърифәтчелеге милли хәрәкәтне самодержавиене камилләштерү өчен түгел, рус халкының үзенә дә, рус булмаган халыкларга да азатлык һәм тигез хокуклылык алып киләчәк демократик дәүләт строена алыштыру өчен көрәшүе белән җәлеп итә.

Милли хәрәкәт бурычлары. «Милли хәрәкәт» төшенчәсе тар һәм киң мәгънәдә шәрехләнә. Билгеле бер халык яки ил куәтлерәк дәүләт тарафыннан яулап алынган булып, илне азат итү максаты куелса, бу милли хәрәкәтнең тар мәгънәдә аңлатылуы булыр. Бу очракта ул *милли-азатлык* хәрәкәте дип атала. Киң мәгънәдә милли хәрәкәт, гомумән, милли үсешне тәэмин итүче социаль-сәяси, икътисади һәм мәдәни эшчәнлекнең бер формасы буларак аңлатыла. Башка сүзләр белән әйткәндә, милли үсешнең теге яисә бу чорында милли идеянең төп эчтәлеге нинди булса, милли хәрәкәтнең юнәлеше дә шундый була.

Милли хәрәкәтнең әйтеп үтелгән киң мәгънәдә чагылышын XV—XVI йөзләр тарихында күрергә мөмкин, бу чорларда Казан татар дәүләте оеша. XVII гасырдан башлап исә бу хәрәкәт башка юнәлештә — Россия империясе составына кергән татар халкының милли мәнфәгатьләрен яклау юнәлешендә бара. XVIII гасырда аның төп эчтәлеге татарларны милләт буларак саклап калу сәясәтеннән милләтне тергезү сәясәтенә күчүдән гыйбарәт була.

Гомумән алганда, милли тергезү әлеге этапта милләтне

кичекмәстән азат итү бурычын һәм таләбен куймый. Ул вакыттагы дәүләт хакимиятенә карата лояльлек, гражданлык буйсынучанлыгы, ил эчендә законлылык һәм тәртип саклау, илне тышкы һөҗүмнәрдән яклау буенча хакимият үткәрә торган чараларда актив катнашу кирәк дип таныла. Татар крестьяннарының Степан Разин һәм Емельян Пугачев восстаниеләрендә катнашуы милли хәрәкәт төсен алмый. Илне Наполеон бәреп керүеннән саклауны исә татарлар милли мәнфәгатькә туры килә дип карыйлар һәм Россия патриотлары ягында булалар.

Милли хәрәкәт тактикасы түбәндәгеләрне үз эченә ала: ислам оешмалары кысаларында милли тормышның чагыштырмача мөстәкыйльлегенең инде ирешелгән дәрәҗәсен хакимият алдында яклау; милли тел, милли мәдәният һәм милли мәгарифне тергезү һәм үстерү, мәдәни һәм белем бирү учреждениеләренең чагыштырмача мөстәкыйльлеген саклау һәм киңәйтү; гомумроссия икътисад кыры һәм гомумроссия базары кысаларында хуҗалык эшчәнлегендә татар эшмәкәрләренең һәм татар халкының тигез хокуклылык нигезендә катнашуы хокукын яклау; татарларның милли үзәге буларак Казанның тарихи ролен тергезү.

Милли хәрәкәтнең үз махсус оешмасы булмый, чөнки мондый оешмалар эшчәнлеге тыелып килә.

Татар җәмгыяте үзенең милли максатларын гамәлгә ашыру өчен теләсә нинди рәсми мөмкинлекләрдән файдалана. 1766—1769 елларда «Яңа законнар эшләү комиссиясе»ндә татарларның 24 вәкиле, шул исәптән Әюп Еникеев та катнаша. Алар суд эшен татар телендә алып бару, көчләп христианлаштыруга чик кую һ. б. таләпләрне алга сөрәләр. Милли икътисад һәм милли мәдәниятне торгызуда рәсми мөмкинлекләрдән татар җәмгыяте шактый уңышлы файдалана. Милли хәрәкәт, татар милли идеясе асылының чагылышы буларак, Россиядә дә, Татарстанда да индустриаль цивилизация барлыкка килүгә бер этәргеч хезмәтен үти.

Татар шәһәрләре һәм бистәләре. XVIII гасырда Казан губернасына һәм башка губерналар составына кергән тарихи татар шәһәрләрендә (Казанны да кертеп) милли тормыш шактый җанлана. Яшәүчеләренең милли составы буенча, башлыча, руслардан торган Казан һәм башка татар шәһәрләрендә рус милли тормышы өстенлеге әле дәвам итә. Казанда православие учреждениеләренең киң челтәре (кафедраль

собор, патриархия, чиркәүләр, монастырьлар, дини уку йортлары) эшли. 1726 елда биредә Петр һәм Павел соборы төзелә, императорлар (Петр I, Екатерина II, Николай I) булып китә. Казан рус милли мәдәнияте һәм мәгарифенең Идел-Урал төбәгендәге иң зур үзәгенә әверелә. XVIII—XIX гасырларда монда бөтен Россиягә мәгълүм булган гимназияләр һәм император университеты булдырыла.

Татар шәһәрләренең икътисады (дәүләти һәм хосусый икътисады), башлыча, руслар кулында туплана. 1718 елда Казанда, башлыча, хәрби-диңгез флоты өчен һөҗүм итү корабльләре, фрегатлар, бриглар, транспорт суднолары, ишкәкле җиңел корабльләр төзи торган дәүләт предприятиесе — Казан Адмиралтействосы ачыла. 10 ел эчендә биредә 400 дән артык судно төзелә. 1722 елда, Казанда булган вакытында, Петр I верфьне дә карый. 1714 елда дәүләт сукно (постау) мануфактурасы, 1719 елда дәүләт күн эшләү мануфактурасы ачыла. Болгар шәһәрлеге территориясендә селитра заводы эшли башлый. 1786 елда дары заводына нигез салына.

XVIII гасырның икенче яртысыннан башлап Казанда рус эшмәкәрләренең күн, сукно, текстиль мануфактуралары барлыкка килә. Алар мондый мануфактура һәм заводларын шулай ук өязләрдә дә төзиләр. Урал предприятиеләре белән көндәшлек итәрлек бакыр эретү мануфактуралары, аракы куу һәм поташ заводлары әнә шундыйлардан. Бу предприятиеләрдә эшчеләрнең күпчелеген крепостной крестьяннар тәшкил итә. Ялланып эшләүчеләр бу вакытта әле аз була. Ялланып эшли торган эшчеләр арасында аз гына булса да татарлар да күренгәли.

Россиядә сәнәгать перевороты башлану белән, XIX йөз башында Татарстанда машиналар кулланыла торган хосусый һәм дәүләти рус предприятиеләре барлыкка килә. 1851 елда Казанда пар казаннары белән җиһазландырылган Свешниковлар чуен кою заводы эшли башлый. Аннары бертуган Крестовниковларның сабын заводы, Алафузовларның күн заводы эшкә керешә. Шул ук Алафузовлар 1865 елда җитен эрләү фабрикасы ачалар. Спас тирәсендәге елга култыгында судноларны ремонтлый торган мастерскойлар пәйда була. Идел һәм Кама буйлап Казан эшмәкәрләренең пароходлары йөзә башлый. Елга сәүдәсенә 50 гә якын пристань хезмәт күрсәтә. Татарстан территориясенә тимер юллар якынлаша. 1862 елда Мәскәү — Түбән Новгород тимер юлы сафка кертелә. 1871 елда

Оренбург — Самара тимер юлында, 1890 елларда Екатеринбург — Чиләбе, ә соңыннан Мәскәү — Казан тимер юлларында хәрәкәт башлана. Оренбург тракты (Казан — Лаеш — Чистай — Оренбург), Себер тракты (Казан — Арча — Вятка губернасы), Мәскәү тракты (Казан — Зөя — Чабаксар — Васильсурск — Мәскәү), Спас — Сембер тракты җанлы сәүдә юлларына әверeләләр.

Шулар белән беррәттән татарларның шәһәр тормышын тергезү дә башлана. Татар шәһәрләре һәм бистәләре мануфактуралар, шулай ук машиналар кулланыла торган сәнәгать предприятиеләре барлыкка килгән һәм сәүдә үзәкләренә әверелгән зур авыллардан үсеп чыгалар. Казан губернасы территориясендәге Кукмара, Мамадыш, Минзәлә һ. б. әнә шундыйлар рәтеннән.

Күп кенә очракларда татарларның шәһәр тормышы күптәнге татар шәһәрләре янында барлыкка килгән бистәләрдәге тормыш рәвешендә тергезелә. XVIII гасырда татарларга үзләренең элекке шәһәрләренә кире кайтырга һәм, алардагы инде формалашкан рус үзәкләренең бөтенлегенә зыян китермичә генә, шәһәр читләрендә бистәләр булып урнашырга рөхсәт ителә. Казанда, мәсәлән, ике татар бистәсе барлыкка килә: Болак аръягындагы Иске татар бистәсе һәм аннан беркадәр арырак — Яңа татар бистәсе (Яңа бистә). Тора-бара бу бистәләрнең икесе дә икътисади эшмәкәрлек үзәгенә, татар милли мәдәниятен, татарларның ислам диненә бәйле булган тормышын тергезү нигезенә әвереләләр. Казанны татар шәһәре буларак, татар милләтен, дәүләтен тергезү үзәге буларак аякка бастыру менә шулардан башлана.

1782 елда патша фәрманы белән Казанда Иске һәм Яңа татар бистәләренең эшләрен идарә итү буенча җәмәгать үзидарәсе органы татар ратушасы оештырыла. Ул Казан шәһәренең рус ратушасы белән параллель рәвештә эш итә. 1784 елның 4 ноябрендә әлеге ратушага Иске татар бистәсеннән 132 депутат, Яңа татар бистәсеннән 106 депутат сайлана. Ратушаның җитәкче составына абруйлы татар сәүдәгәрләре һәм предприятие хуҗалары М. Юнысов, Й. Юнысов, Н. Юнысов, М. Гайсин, М. Салишев, И. Апанаев һәм башкалар сайлана. Алар үз чиратларында шәһәр башлыгын һәм ике бургомистрны сайлап куялар. Моннан соңгы сайлаулар тугыз елдан соң, 1793 елның 22 декабрендә үткәрелә. Шәһәр башлыгы итеп Мөхәммәтрәхим Юнысов сайлана. Бургомистрлар итеп Йосыф Абдулов һәм

Гаделша Гомәров, ратманнар (ратуша әгъзалары) итеп А. Исхаков, М. Якубов, Р. Рәхмәтуллин, Г. Якубов, староста итеп Г. Рәхимов һәм судьялар итеп Г. Исхаков, А. Беляев сайланалар.

Ратуша вазифасына татар сәүдәгәрләренең, эшмәкәрләрнең сәүдә һәм сәнәгать өлкәсендәге эшләре (аларны төрле гильдияләргә караган сәүдәгәрләргә яисә мещаннарга аеру, сәүдә һәм сәнәгать эш-йомышлары буенча кая да булса бару өчен аларга паспортлар бирү, ризасызлык белдерелгән вексельләр буенча бурычларны түләтү, ике татар бистәсендә яшәүчеләрдән салымнар җыйнау, урман хәзерләүгә һәм башка дәүләт эшләренә кешеләр җибәрү буенча разнарядкаларны үтәү һ. б.) белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү керә. Ратуша дәүләт хакимияте органнарына буйсына. Аның составына бары тик патша хакимиятенә тугрылыклы булу турында ант иткән һәм хакимият органнарының ризалыгын алган кешеләр генә депутат итеп сайлана ала. Махсус «ант вәгъдәсе» хәзерләнә, һәм сайлауларга барганда сайлаучыларга шул ант язмасын өләшәләр. «Вәгъдә»дә болай диелә: «Мин ратушага булачак сайлауларда бистәдә яшәүче мөселман кардәшләрем арасыннан үзен Император Галиҗәнапларының тугрылыклы колы булуын күрсәткән кешене сайлаячагым турында Аллаһы Тәгалә һәм Коръән алдында вәгъдә биреп ант итәм...»

Татар авылларын тергезү. Татарстанның авыл территориясе үз чиратында ике этник зонага бүленә. Татарлар, чуваш һәм мариларның яшәү рәвеше белән беррәттән русларның авыл тормышы да формалаша. Рус авыллары башлыча крепостной хезмәткә нигезләнгән алпавыт хуҗалыкларыннан тора. Казан архиерей йорты, чиркәү һәм монастырьлар шулай ук зур җир кишәрлеге һәм крепостной крестьяннар биләүче булалар. Татарстанда шулай ук кайбер Россия алпавытларының, Мәскәү янындагы Троице-Сергий монастыреның һәм кайбер башка монастырьларның җир биләмәләре була. Алар кара туфраклы иң яхшы сөрү җирләренең зур-зур кишәрлекләрен һәм шәһәрләргә, зур елгаларга, олы юлларга якын болынлыкларны, урманнарны биләгәннәр. Ирекле булган ясаклы рус крестьян хуҗалыклары Татарстанда чагыштырмача аз була.

Татар авылларында эре җирбиләүче татар алпавытлары калмаган диярлек. Җирләре 1552—1580 еллардагы сугышлар барышында конфискацияләнгәннән соң, аларга үз хуҗалык-

ларын яңадан торгызырга рөхсәт ителми. Хакимият органнарының төрле икътисади чикләүләре нәтиҗәсендә Дөбердиевләр, Таишевлар, Усмановлар, Рәхмәтевләр, Тәфкилевләр, Алкиннар кебек йомышлы татарларның зур-зур утарлары юкка чыга. Крепостной хокук, гомумән, татар крестьяннарына кагылмый. Татар авыллары халкын ирекле булган ясаклы крестьяннар тәшкил итә. Аларның йорт-җирләре, каралты-куралары һәм ихаталарының төзеклеге күзгә ташланып тора. Бу хуҗалыклар башлыча игенчелек белән шөгыльләнә. Уңыш үз вакыты өчен ярыйсы гына була: чәчелгән бер пот орлыктан биш-алты пот уңыш алына. Бу крепостной хезмәткә нигезләнгән хуҗалыклардагыга караганда югарырак була. Җыелган ашлыкның бер өлеше сату өчен бүлеп куела. Йорт терлекчелеге торгызыла.

Авыллар үзләре дә төзекләнә, эреләнә. Торгызылган мәчетләр яңадан авылларның күркәм рухи үзәгенә әверелә. Мәчетләр каршында ачылган мәдрәсә һәм мәктәпләр милли белем бирү системасын тергезә. Авылларның үз зыялылары үсеп чыга. Һәр авылның үз итек-читекчеләре, тегүче, буяучылары һәм башка һөнәр ияләре була. Тире иләү, күн эшкәртү, аяк киеме, тун, бүрек тегү, бияләй бәйләү иң күп таралган һөнәрләрдән санала. Постау һәм киндердән кием-салым тегү күп таралыш ала. Хатын-кызлар йон, җитен эрләргә бик маһир була.

Бу продукциянең бер өлеше авылдан читтә сатуга чыгарыла. Баштарак аларны авылга килеп, арадашчы сәүдәгәрләр сатып ала торган була. XVIII гасырда товарларны җирле базарларга сатуга чыгаручы татар сәүдәгәрләре барлыкка килә. Әтнә, Ашыт, Алат, Саба, Матак һ. б. Казан губернасындагы шундый базар үзәкләренә әвереләләр. Түбән Новгород, Пермь, Самара, Сембер, Уфа губерналарында татар сәүдәсе үзәкләре барлыкка килә. Тора-бара бу базарлар татар-рус базарлары булып әверелә.

Милли сәүдә капиталының барлыкка килүе. 1754 елда патша хөкүмәте эчке пошлиналарны бетерә. Россия икътисади системасы, Россия базары интенсиврак, нәтиҗәлерәк эшли башлый. 1763 елда Сенат «Сәүдә эшләре белән төрле шәһәрләргә йөрүче йомышлы татарларга тоткарлык ясамау турында» Указ кабул итә. 1776 елда кабул ителгән регламент буенча татарларга көнчыгыш районнарда гына түгел, бөтен Россиядә сәүдә итәргә рөхсәт ителә. Татар милли икътисады

гомумроссия икътисад системасына, гомумроссия базарына кереп китә. Бу хәл Татарстанның административ бүлгәләнүенең тискәре йогынтысын беразга киметә. Төрле губерналар составында калган татар шәһәрләре, бистә һәм авыллары үзара икътисади бәйләнешкә җәлеп ителә. Татар эшмәкәрләре киң мәйданлы бөтенроссия сәүдәсенә кушылу һәм чит ил базарларына чыгу мөмкинлеге ала.

XVIII—XIX гасырларда татар эшмәкәр-миллионерлары, мәдәният химаячеләре Юнысов, Апанаев, Бурнаев, Арсаев (Әхмәров), Усманов һәм Сәйдәшевләр династияләре башлангыч ала.

Татарстанның гомумроссия икътисад системасына, гомумроссия базарына кушылуының ике яклы нәтиҗәсе була. Беренчедән, аякка басып кына килүче татар милли икътисады бөтенроссия икътисадына әверелә барган рус милли икътисадына буйсынган хәлдә кала. Шул ук вакытта, гомумроссия икътисад системасына керү татар милли икътисади тормышы бердәмлеге саклануына, аның яңадан торгызылуына булышлык итә.

Җир биләүдә үз өстенлекләреннән мәхрүм ителгән йомышлы татарлар милли сәүдә капиталы формалашуда зур роль уйный. Алар сәүдә белән шөгыльләнүгә хакимият органнарыннан беренчеләрдән булып рөхсәт алалар һәм шәһәрләрдә, зур ярминкәләрдә, чит илләр белән сәүдәдә гомумроссия сәүдә системасына керәләр. Күп кенә татар сәүдәгәрләре сәүдә эшен авыл базарларында башлаган хәлле крестьяннар арасыннан чыга. Ашлык сәүдәсендә шактый дәрәҗәдә алар катнаша. XIX гасырда Вятка һәм Кама елгалары буенча үтүче су юллары бергә кушылган җирдә урнашкан Мамадыш ашлык сәүдәсе үзәгенә әверелә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, шәһәрдә барлыгы 145, ә өяздә 198 сәүдәгәр теркәлә. Шуларның күпчелеге татарлар була. Уңдырышлы сөрүле җирләр тирәсендә урнашкан Алабуга, Спас, Чистай шәһәрләре шундый ук сәүдә үзәкләренә әверелә.

Зөя елгасында урнашкан Зөя (Свияжск) шәһәре, Идел ярындагы Кама Тамагы һәм Тәтеш нык үскән сәүдә үзәкләре булып китәләр. Шәһәрләрдә ел саен ярминкәләр уздырыла. Үзенең зур Сәүдә йорты, Печән базары, «Болгар» кунакханәсе булган Казан берләштерүче сәүдә үзәгенә әверелә. Югарырак дәрәҗәле татар сәүдәгәрләре Мәскәү, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Вятские Поляны, Рыбинск, Оренбург, Эрбет һәм

Ростовта сәүдә итәләр. 1523 елда Василий III тарафыннан Казаннан Түбән Новгородка күчерелгән Мәкәрҗә ярминкәсе Россиянең Европа өлеше белән Себер арасында сәүдә алмашуы үзәге булган Екатеринбург губернасындагы Эрбет ярминкәсе (1647 елдан соң ел саен үткәрелә башлаган), Урта Азия һәм Казакъстан белән сәүдә итүдә төп рольне уйнаган Оренбург ярминкәсе аеруча дан казаналар. Оренбург губернасындагы Сәет бистәсендә татар сәүдә үзәгенә нигез салына. Бу үзәк сәүдәгәрләре, рус сәүдәгәрләре белән берлектә, Урта Азия һәм Казакъстанны сәүдә ягыннан үзләштерүдә катнашалар. Бу сәүдәгәрләр арасында казанлылар Гали Ишморатов, агалы-энеле Даутовлар, Мәмәтов һ. б. була.

1753 елда Сәет сәүдәгәрләре Надыйр һәм Якуб Сәфәровлар Оренбургтан Һиндстанга сәүдә сәяхәте ясыйлар. Кытаев фамилиясе белән танылган татар сәүдәгәре Кытай белән сәүдә итүдә катнаша. 1796 ел мәгълүматларына караганда, Казан губернасында 595 татар сәүдәгәре, шул исәптән эре сәүдәгәрләр теркәлгән. 1785 елда Екатерина II тарафыннан шәһәрләргә бирелгән Бүләк грамотасы (Жалованная грамота) нигезендә, Казанда 1799 елда 32 татар гаиләсе гильдияле сәүдәгәр исемен йөртә, шул исәптән икенче гильдияле 8 һәм өченче гильдияле 24 сәүдәгәр була.

XIX йөздә татар сәүдә капиталы Россия икътисадында шактый зур финанс көченә әверелә. Пай нигезләрендә дәрәҗәле сәүдә йортлары барлыкка килә. Алар акционерлар җәмгыятьләре чорын ачып җибәрә. 1892 елда татарларның 10 сәүдә йорты теркәлә.

Мануфактура эшмәкәрлеге. Көнбатыш Европада XVI гасыр урталарында туган мануфактура җитештерүе Татарстанда XVII йөз азагы — XVIII йөз башында киң колач ала башлый. Казна, посессион һәм вотчина мануфактуралары өстенлек иткән Россиядән аермалы буларак, татар эшмәкәрләре, башлыча, ялланган хезмәткә нигезләнгән мануфактуралар ача. Мондый мануфактураларга нигез салучылар үз вакытында сәүдә эшенә күчкән йомышлы татарлар була. Ә тора-бара татарларның үз сәнәгатьчеләре дә үсеп чыга.

Мануфактура җитештерүенең беренче предприятиеләре бакыр эретү заводлары була. Әмма андый предприятиеләр ачу бары тик йомышлы керәшен татарларына гына рөхсәт ителә. 1643 елда Тумашев дигән кеше Кама буенда (Казан губернасы) үзенең бакыр эретү мичен төзи. Соңрак, 1743 елдан Кукмарада

(Мамадыш өязе) Әсәдулла Иноземцев һәм аның компаньоны Әбсәләмовның бакыр эретү заводы эшли башлый. Анда осталар һәм эшчеләрнең гомуми саны 450 кешедән арта. Заводта 5 мич һәм 77 рудник була. Бу предприятие ел саен базарга 1500 пот бакыр чыгара. 1751 елда Минзәлә өязенең Иштирәк авылында Иноземцевлар гаиләсенең бакыр эретү заводы корыла. 1763 елда Вятские Поляныда Кобелевның бакыр эретү заводы эшли башлый. Тәфкилев тә үзенең бакыр эретү заводын ача. Татар эшмәкәрләре поташ җитештерүгә үз өлешләрен кертәләр. 1795 елда Царевококшайскида Мөхәммәткәрим Кәримовның пыяла, сабын һәм башка төрле товар җитештерүдә файдаланылучы продукция (калий карбонаты) эшләп чыгара торган поташ заводы ачыла.

Татар эшмәкәрләре үзләренең мануфактура эшчәнлеген нигездә алар өчен тыюлар булмаган җитештерүдә сыныйлар. Киҗе-мамык туку, җитен туку, күн, постау җитештерү, сабын кайнату әнә шундый хезмәт өлкәләре була. Бу эшмәкәрләр үз предприятиеләрен татар халкы шактый территорияләрне биләгән Казан, Вятка, Сембер, Самара, Саратов, Әстерхан губерналарында төзиләр. 1718 елда Казанда сәүдәгәрләр Апанаев, Әбсәләмовларның тире-күн заводлары эшли башлый. Соңрак Исхак Галиевнең, Әбдрәшит Галанскийның һәм башкаларның күн заводлары ачыла. XVIII гасыр урталарында Казанда татар эшмәкәрләренең тире-күн заводлары саны 17 гә җитә. Татар эшмәкәрләренең Вятка губернасында да тире-күн заводлары була. Карин волостенда Сәгыйт Мостафин, Самат Дәүләтьяров, Мөслим Абдуловның өч тире-күн заводы эшли. Слободской шәһәрендә (Вятка губернасы) Мостафа Габдрәхимовның, Малмыж өязендә Мөхәммәтрәхим һәм Габдулла Үтәмешевләрнең, Глазов шәһәрендә (удмурт җире) Госман Касыймов һәм Госман Кәримовларның үз тире-күн заводлары була. Эшмәкәрләр әле эшкәртелмәгән күнне, өлешчә, Оренбург ярминкәсендә сатып алалар. Ә әзер продукция Россия шәһәрләре һәм Көнчыгыш илләрендә сатыла.

Казандагы 18 сабын кайнату мануфактурасының 11 е татар эшмәкәрләренеке була. Татар эшмәкәрләре туку һәм постау җитештерүдә активлык күрсәтәләр. Казан, Арча, Мамадыш, Царевококшайск, Уржум һәм Малмыж өязләрендә (Вятка губернасы) татар эшмәкәрләренең комач (ачык кызыл төстәге киҗе мамык тукыма) мануфактуралары эшли. Алар эрләгән киҗе-мамык җепне Урта Азиядә сатып алалар. Ә әзер

продукцияне Түбән Новгород (Мәкәрҗә ярминкәсендә), Мәскәү һәм Ростовта, өлешчә чит илләрдә саталар.

Күренекле тарихчы Х. Х. Хәсәнов мәгълүматларына караганда, XVIII гасыр азагында татар эшмәкәрләренең 100 мануфактурасы теркәлә. XIX гасыр башларында яңа җитештерү тармакларында да татар эшмәкәрләре мануфактуралары барлыкка килә. 1815 елда Мөэмин Хуҗасәетовның язу өчен кәгазь җитештерүче ике фабрикасы эшли башлый. Сәгыйт Измайлов һәм Әбсәләм Үтәгәневләр Казан шәһәрендә туңмай эретү заводын сафка кертәләр.

Машина кулланучы сәнәгать. Татар эшмәкәрләре XIX гасыр урталарында үз мануфактураларын машина техникасы кулланучы фабрикалар итеп үзгәртеп кора башлыйлар. Ялланган эшчеләр хезмәтен куллануга тагы да элегрәк керешәләр. Хәзер исә үз предприятиеләрендә энергия базасын тамырдан үзгәртү турында сүз бара. Татар эшмәкәрләренә үз предприятиеләрен булдырырга рөхсәт ителгән сәнәгать тармаклары шул ук кала: күн, текстиль, сабын кайнату, азык-төлек, язу өчен китә торган кәгазь җитештерү. Җиңел сәнәгатьнең шушы тармакларына тагын мех һәм аяк киеме җитештерү тармаклары өстәлә. Татарлар йөзен әнә шулар билгели. Татарстанда үсә башлаган авыр һәм хәрби сәнәгать, машиналар төзелеше, шул исәптән авыл хуҗалыгы өчен машиналар һәм кораллар җитештерү, химия предприятиеләре рус эшмәкәрләре кулында кала. Татар эшмәкәрләре үз предприятиеләре өчен машиналарны Европа илләреннән һәм Россия шәһәрләреннән сатып алалар.

Татар эшмәкәрләренең постау җитештерү буенча эре предприятиеләре Сембер губернасында тупланган була. Кырым сугышы елларында армия өчен постауның аерата зур партияләрен саткан Әхмәт Алиев (1848 ел), Сөләйман Акчурин (1849 ел) биредә үз предприятиеләрен тоталар. Армия өчен постауны Самара губернасында Хәмит Алиев һәм Саратов губернасында Мостафа Дөбердиевләр җитештерә.

Казан губернасында М. Т. Хуҗасәетов, У. С. Хуҗасәетов (Царевококшайск өязе), К. М. Борнаев (Мамадыш өязе) бояу цехлары булган мамык җеп тукыма фабрикалары тоталар. Кайбер туку фабрикалары үзәк Россиядәге ситсы фабрикалары белән конкуренцияне исәпкә алып профильләрен үзгәртәләр: китайка (Кытайдан кертелә торган ефәккә охшатып җитештерелгән тукыма) эшләп чыгара башлыйлар. Аппаков,

Азимов, Уразов, Абдуллин, Бикмөхәммәтовның китайка җитештерә торган шундый фабрикалары була. Абдуллин һәм Фәйзуллин татар милли аяк киеме тегү буенча ике фабрика төзиләр.

Россиядә крепостной хокук бетерелгәннән соң сәнәгатьне либеральләштерү елларында татар эшмәкәрләре зур кыенлыклар белән булса да сәнәгатьнең яңа тармакларына үтеп керә башлыйлар. 1868 елда Закир һәм Шакир Рәмиевләр Оренбург губернасында меңгә якын кеше эшли торган ике алтын приискасы ачалар. Әхмәтҗан Сәйдәшевнең Казан губернасында зур пыяла заводы була. Казан губернасының Мамадыш өязендә һәм Рязань губернасының Касыйм өязендә мехчылык үзәкләре барлыкка килә. М. Мусаев Касыйм шәһәрендә мех фабрикасы төзи. Тагын ике мех фабрикасы биредә Ширинскийларныкы һәм Дәүләткилдиевләрнеке була. Тарихи Мещераның Ока, Мукшы, Цна, Пьяна елгалары бассейннарындагы татар районнарында (Темников, Алатыр, Кормаш, Кадом, Инсар татарлары яшәгән урыннарда) да сәнәгать җанланып китә.

Татар эшмәкәрләре Казан губернасында шырпы, крахмал, бәрәңге балы (патока) җитештерүне, Оренбург губернасында туңмай эретүне җайга салалар. Х. Х. Хәсәнов мәгълүматларына караганда, татар эшмәкәрләренең 1890 елда Россиянең Европа өлешендә генә дә 76 предприятиесе була. Болардан тыш алар Себердә, шулай ук Урта Азия һәм Казакъстанда предприятиеләр тота. Алар арасында Россиянең банк капиталы белән бәйләнеш торган Акчурин, Дөбердиев, Рәмиев, Яушев, Хөсәенов, Алиев, Сәйдәшев, Арсланов һәм Үтәмешевләр кебек фабрикантлар һәм завод хуҗалары аерым игътибарга лаек. 1907 елда татар сәнәгатьчеләренең беренче җәмгыятьләреннән булган, 16 фирманы берләштергән Сембер губернасы постау фабрикалары бергәлеге оеша.

Милли мәдәниятне тергезү приоритетлары. Татарстанның индустриаль үсеш юлына аяк басуы татар халкының милли-мәдәни һәм рухи үсешендәге приоритетларның алмашуына китерә. Татар халкының милләт буларак сакланып калуы ислам оешмалары, ислам кыйммәтләре кысаларында һәм алар химаясендә милли мәдәниятнең, милли мәгарифнең үсеп китүе белән дә аңлатыла. XVIII гасырдан башлап мәдәниятнең ислам дине белән мондый кушылганлыгы әкренләп бетә бара. Милли мәдәният, милли мәгариф, ислам кыйммәтләре белән

багланышларын өзмәгән хәлдә, үзләренең мөстәкыйль оешмаларын булдыралар, европачыл һәм милли мәгърифәт идеяләренә йөз тоталар.

Милли-мәдәни тергезелү барышында татарлар өчен ике үрнәк күз алдында тора: беренчедән, Европа һәм милли мәгърифәт идеяләренә юнәлеш тотып, православие үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, рус милли мәдәнияте үсеше, икенчедән, ислам белән бәйле үзенчәлек сакланган хәлдә, Европа һәм милли мәгърифәт идеяләренә йөз тотып, төрек милли мәдәниятенең алга китүе. Аңлашыла ки, дәүләт булышлыгыннан мәхрүм ителгән татар милли мәдәнияте әлеге илләрнекедәй уңышларга исәп тота алмый. Шуңа да карамастан, бу илләр тәҗрибәсе татар җәмгыяте өчен бик әһәмиятле була.

XVIII йөздә Петр I Европа дәрәҗәсендәге рус милли интеллигенциясен булдыру өчен күп көч куя. Яңа гражданлык әлифбасы кертелә. Чиркәү-мәхәллә мәктәпләре үзгәртеп корыла. Санкт-Петербургта 1714 елда рус милли китапханәсе (Кунсткамера) эшли башлый. 1725 елда атаклы рус галиме М. В. Ломоносов инициативасы белән Фәннәр академиясе ачыла. Китап басу эше үсеш ала. Моннан соңгы елларда рус мәдәнияте яңа адымнар ясый. 1755 елда Мәскәү университеты ачыла. 1756 елда профессиональ рус театры оештырыла. Шул ук елны Художество академиясенә нигез салына, беренче рус газетасы чыга башлый. XIX йөздә Санкт-Петербург, Казан, Харьков, Дерпт шәһәрләрендә университетлар, ә Санкт-Петербугта технология институты ачыла.

Сынлы сәнгать, музыка, матур әдәбият заман таләпләренә җавап бирер дәрәҗәгә күтәрелә. А. С. Пушкин, А. С. Грибоедов, М. Ю. Лермонтов, И. С. Тургенев, Л. Н. Толстой, П. И. Чайковский, М. П. Мусоргский, И. Е. Репин һәм башка бик күпләр бөтен дөньяга таныла. Рус милли мәдәнияте ул вакыт татар мәдәниятенең Европага чыгуы өчен кирәкле күперләрнең берсе була. Татар егетләре рус уку йортларына укырга керә. Казан университетының Көнчыгыш факультетына татар тарихы, этнографиясе, тел гыйлеме өлкәләрендә тикшеренүләр алып баручы белгечләр (К. Фукс, И. Хәлфин һ. б.) чакырыла.

XVIII гасырда Төркиядә дә Европа мәгърифәтчелеге идеяләре формалаша. Аларны гамәлгә ашыру буенча практик адымнар солтан Сәлим III заманында ясала. XVIII гасыр азагында һәм XIX гасыр башларында биредә «Низами җәдид» («Яңа система») дигән атама алган реформалар үткәрелә.

XIX гасырның 40—70 нче елларында үткәрелгән һәм «Тәнзимат» («Тәртипкә салу») дип аталган реформаларның яңа этабы инициаторы булып атаклы сәяси эшлекле һәм дипломат Рәшид паша тора. XIX гасырның 60 нчы елларында танылган дәүләт эшлеклесе Мидхәт паша Төркиядә Европа илләре тибындагы конституцион строй урнаштыру турындагы тәкъдимнәре һәм үзенең Конституция проекты белән чыга. Бу Конституция 1876 елда игълан ителә.

Социаль реформалар милли мәдәният һәм мәгариф үсешенә этәргеч ясый. XIV—XV гасырларда Госманлы дәүләтенең оешуы чорында чәчәк аткан ислам мәдәнияте аң-белемгә, акылга юнәлеш тоткан милли мәдәнияткә өстенлек бирә башлый. 1453 елда нигез салынган Истанбул университетына техник университет (1773), Коммерция һәм икътисад фәннәре югары мәктәбе (1883), Роберт-колледж (1886) өстәлә. Ходавендигяр мәчете (XVI гасыр), Яшел мәчет (XV гасыр), Сөләйман мәчете (XVI гасыр) йөзендә төрек ислам архитектурасы сакланып кала, һәм шул ук вакытта төзелеш сәнгатендә Европа мотивлары чагыла башлый. «Тәнзимат» елларында сынлы сәнгать яңа үсеш ала. 1882 елда художество мәктәбе, 1859 елда профессиональ театр ачыла. 1727 елда башланган китап басу эше җанланып китә. 1882 елда Баязид исемендәге Милли китапханә ачыла. Төркиянең яңа әдәбияты туа. Үзенең алтын чоры традицияләрен дәвам иткәне хәлдә, ул Көнбатыш Европа әдәбиятына йөз белән борыла. Төркиянең әдәби даирәләре рус әдәбиятына да югары бәя бирәләр.

Татарстанда иҗтимагый фикер үз чиратында индустриаль цивилизациягә йөз тота башлый. Татарстанның Россия, Төркия һәм башка илләр белән мәдәни хезмәттәшлеге яңа баскычка күтәрелә. Мәгърифәт идеяләре нигезендә үзгәртеп корылган югары мәктәпләр татар яшьләрен дә җәлеп итә. Төркиядә басылып чыккан китаплар Татарстанда да таралыш таба. Истанбулда нәшер ителгән Ван Кулиның өч томлык сүзлеге «Лөгать», Чәләбинең «Җиһаннамә»се («Дөнья энциклопедиясе» — 1889 ел) шундыйларга керә. Төркиядә татар мәгърифәтчеләренең Россия цензурасы тарафыннан тыелган китаплары басылып чыга. Бередә Г. Барудиның китабы төрек телендә дөнья күрә, Муса Акъегетзадәнең «Европа мәдәнияте нигезләренә караш» дигән китабы басылып чыга.

Татар исламындагы реформаторлык. Милли тергезелү татар җәмгыятендә исламның иске рухи кыйммәтләре белән

генә канәгатьләнмәгән сәүдә, сәнәгать, авыл хуҗалыгы эшмәкәрләрен һәм гуманлы, дөньяви зыялылар кебек яңа социаль катлауларны тормыш мәйданына чыгара. Татар исламында, гомумән, мәгърифәтчелек чоры исламына хас булганча, кешенең яңа ихтыяҗларына йөз белән борылган яңа көчләр алга чыга. Алар, ислам позицияләрендә торып, кешенең гадәти, дөньяви ихтыяҗларын исәпкә алырга тырышалар. Химаячеләр сыйфатында эш итүче сәүдә-сәнәгать даирәләре белән татар исламындагы яңа юнәлеш арасында үзара аңлашу туа. Мәһабәт мәчет биналарын салу мөмкинлеге киңәя. 1767 елда Казанда (Иске татар бистәсендә) хәзер Мәрҗани исемен йөртүче мәчет корыла. XIX гасырда мондый монументаль мәчетләр саны тагы да арта. Мәсәлән, 1849 елда беренче гильдия сәүдәгәр Г. М. Юнысов акчасына Апанай мәчете салына. Ул мәчеттә исламдагы яңа юнәлеш эшлеклесе Габдулла Апанаев (1861—1919) имам булып тора. Г. Баруди (1857—1922), Р. Фәхреддин (1854—1936), Г. Буби (1871—1922) һ. б. исламда реформация юнәлеше вәкилләре булалар. Ислам тарихы буенча күренекле галим Ризаэддин Фәхреддин үз укучыларын Ибне Рөшднең тормыш юлы һәм карашлары белән таныштыра. Үзенең күпкырлы эшчәнлеге белән татар мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертә.

Татар исламында реформаторлык юнәлеше барлыкка килүгә тагын бер нәрсә сәбәп була. 1773 елда Екатерина II «Диннәргә ихтирам турында» («О веротерпимости») Указ чыгарган була. Дәүләт хакимияте белән Татар исламы арасындагы конфронтация беразйомшара төшә. Алар арасында диалог башлана. Хакимият органнары мәчетләрнең ачыктан-ачык эш итүләре белән ризалашулары турында белдерәләр һәм мөселман руханиларына Коръән кагыйдәләрен вәгазьләү ирегeн бирәләр. Әмма моның бәрабәренә аларның эшчәнлеген хакимият органнары контроленә буйсындыру шарты куела.

1788 елда патша хөкүмәте фәрманы белән Уфада Ислам дине җәмгыяте (Мусульманское духовное собрание) оештырыла. Анда мөфти җитәкчелек итә. Хакимият органнары зур мәчетләрнең имамнарын үз указлары белән билгели башлыйлар. Шуңа күрә андый мөселман руханиларын «указлы муллалар» дип атап йөртәләр. Шиһабеддин Мәрҗани, мәсәлән, 1850 елда шундый указлы мулла булып китә. Ислам дине җәмгыяте Татар сәүдә-сәнәгать берләшмәсеннән кала хакимият контроле астында эшли торган икенче җәмәгать оешмасы

була. Ул Үзәк Россия, Себердәге ислам җәмгыятьләрен һәм мөселман руханиларын берләштерү, дини-рухи һәм мәдәни эшчәнлекне император хакимиятенә тугрылыклылык юнәлешендә алып бару вазифасын башкара. Мөфтияткә, хакимият органнары белән алдан ук килешенеп, абруйлы, режимга тугры булган имамнар сайлана. Мөфтинең сайлау тәртибе дә шундый ук була. Мөфти соңыннан хакимият органнары фәрманы белән раслана. Беренче мөфти итеп ахун (югары дәрәҗәдәге мөселман рухание) Мөхәммәтҗан Хөсәен сайлана. Император аны дәүләттән зур хезмәт хакы алу мөмкинлеген бирүче генерал дәрәҗәсенә билгели.

Ислам дине җәмгыяте һәм мөфтият (Диния Нәзарәте) ике төрле бурыч үтиләр: татарларның рухи тормышын тергезүгә булышлык итәләр һәм ислам җәмгыятьләренең эшчәнлеген хакимияткә карата лояль мөнәсәбәттә булуга юнәлдерәләр. Мөфтият составына кергән ислам җәмгыятьләре ачыктан-ачык (легаль) эш итү хокукы алалар. Имам, мәчеттә хотбә укыганда императорның исемен атап, үз мәхәлләсендә яшәүче мөселманнарның хакимияткә тугрылык саклавын белдерә.

Милли мәгариф һәм мәдәният. Милләтнең тергезелүе милли мәгарифнең дөньяви системасы һәм заманча милли әдәбият үсешендә ачык чагыла. Татар милли икътисады кебек үк милли белем бирү системасы һәм милли мәдәният тә Россия татарларының уртак территориясенең административ бүлгәләнгәнлегенә бәйсез рәвештә аларның уртак хәзинәсе була. Милли тергезелү процессы үзәгендә Казан губернасы, Казан шәһәре тора.

Татар милли мәгариф системасының һәм милли мәдәниятенең үсүе, фактта дәүләт булышлыгыннан мәхрүм ителгән хәлдә, җәмәгатьчелек яклавына һәм хималчеләрнең матди ярдәменә нигезләнә. Россия Дин эшләре һәм халык мәгарифе министрлыгы исә үзенең төп бурычын белем бирүнең милли системасын үстерүдә түгел, православие динендәге кешеләрнең христиан булмаганнар белән никахлашуын тыя торган законның катгый үтәлүенә, шулай ук рус булмаган, христиан булмаган халык вәкилләренең һәм балаларының ислам динен кабул итмәүләренә ирешүдә күрә.

Яңа милли мәгариф системасын яңа ысул («ысулы җәдит») белән дөньяви белемнәр кертеп укыта торган мәктәпләр һәм мәдрәсәләр тәшкил итә. Укыту планнарында укырга, язарга, исәпләргә өйрәтү күздә тотыла. Ислам дине сабаклары

белән беррәттән дөньяви фәннәр дә укытыла торган урта һәм югары сыйныфлы мәдрәсәләр ачыла. Казандагы Галимҗан Баруди җитәкчелек иткән Мөхәммәдия мәдрәсәсе шундый юнәлеш ала. Казанда тагын өч мәдрәсә — 1771 елда Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре һәм 1780 елда Әмирханов йорты каршындагы мәдрәсә — шундый ук рухта эшли башлыйлар. Башка шәһәрләрдәге — Оренбургтагы Хөсәения һәм Уфадагы Галия мәдрәсәләре шулай ук абруйлы югары уку йортларыннан саналалар. Аларда укыту эшен атаклы татар галимнәре Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин, Ф. Халиди, З. Бигиев, Г. Ильяси һ. б. алып бара. Абруйлы урта уку йортлары арасында Иж-Буби авылындагы (Вятка губернасы) агалы-энеле Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар мәдрәсәсе дә була.

Ислам теологиясен тирәнрәк өйрәнергә һәм мәчетләрдә имам булып хезмәт итәргә теләге булган яшьләр Бохарада һәм Көнчыгышның башка шәһәрләрендә теология мәдрәсәләрендә укуларын дәвам иттерәләр. Ә дөньяви белемнәрен тирәнәйтергә теләгәннәр Россия, Төркия һәм башка ил университетлары һәм институтларына күчәләр.

XIX йөзнең азагында мәчетләр каршындагы мәктәпләр белән беррәттән дөньяви мәктәпләр ачыла. Яңа буын мәктәп укытучыларының башында И. Терегулов, З. Һади, Г. Рафиков һ. б. тора. Рус-татар мәктәпләре барлыкка килә. Татар балаларының бер өлеше рус гимназияләрендә һәм башка төрле махсус мәктәпләрдә укый. 1876 елда Казанда Татар укытучылар институты (Казан педагогия университетының элгәресе) ачыла. Оренбургта Гани Хөсәенов химаячелегендә укытучылар семинариясе төзелә. Анда тарихчы Һади Атласи, язучы Гаяз Исхакый кебек бөек шәхесләр белем ала. Яңа татар зыялыларының бер өлешен Казан император университеты үстерә.

Православие чиркәве тарафыннан керәшен балалары өчен оештырылган чиркәү-мәхәллә мәктәпләре (церковно-приходские школы) дә татар милли мәгарифе системасында үз урыннарын алалар. Баштарак бу мәктәпләрдә балаларга, нигездә, православие гыйбадәте өйрәтелә. Аннары уку, язу, хисап кебек дөньяви предметлар өстәлә. Укыту татар телендә, кириллица нигезендә төзелгән әлифба буенча алып барыла. Бу мәктәпне тәмамлаганнар белем алуны 1863 елда Казанда ачылган Үзәк керәшен татарлары мәктәбендә дәвам итә ала. Укытучы кадрлар 1872 елда ачылган «инородецлар» өчен

булган укытучылар семинариясенең керәшен татарлары бүлекчәсендә хәзерләнә.

Татар милли әдәбияты яңа сулыш ала. Ул акрынлап милләтне саклап калу чорыннан калган суфичылык һәм нәкышбәнди (суфичылыкның бер төре.— *Тәрҗ. искәрмәсе*) йогынтысындагы ислам-татар орбитасыннан чыгып, дөньяви юлга баса. Милли тергезелү белән бер үк вакытта заманча татар милли әдәбияты үсеш ала. Габдерәхим Утыз Имәни (1754—1834), Габделҗәббар Кандалый (1797—1860), Гали Чокрый (1826—1889), Мифтахеддин Акмулла (1831—1895), Яков Емельяновлар (1848—1893) бу әдәби үсеш баскычларын башлап җибәрүчеләр булалар.

Утыз Имәни үзенең «Бәяннар» («Аңлатмалар») әсәрендә милли тергезелү чорында татар җәмгыяте проблемаларын чагылдыра. Ул кеше булуның (егет булмак) ни икәнлеге, галим кешенең нинди булырга тиешлеге, кешеләр арасында фикер бердәмлеге һәм дуслыкның асылы, туган телне ихтирам итү зарурлыгы, бай кешенең үзен ничек тотарга тиешлеге турында фикер йөртә. Аның «Тәнзих әл-әфхәр» («Фикерләрне пакьләндерү»), «Мөһиммәттез-заман» («Замананың мөһим хәлләре») дигән поэмалары татар милләтенең киләчәк үсеше турында уйланулар рухында язылганнар. Үз заманының зур укымышлысы Утыз Имәни хезмәтләрен татар, гарәп, фарсы телләрендә яза. Аның үз илендә генә түгел, чит илләрдә дә абруе зур була. Габделҗәббар Кандалыйның «Сахибҗәмал», «Мулла белән абыстай» поэмаларында татар җәмгыятенең яшәү рәвеше чагылдырыла.

XIX гасырның 80 нче елларында татар әдәбияты өчен яңа жанр — драматургия әсәрләре күренә башлый. Фатих Халиди (1851—1923), Заһир Бигиев (1870—1902), Габдрахман Ильяси (1856—1895) кебек укымышлылар үз әсәрләре белән әдәбият мәйданына чыга. Әдәбият шактый киң даирә укучыларга аңлаешлы була бара. Милли үзаңны үстерүдә, милли тергезелүгә йөз тоткан халыкның рухын ныгытуда әдәбиятның роле тагы да көчәя.

Тергезелүнең уңышлары тарих, фәлсәфә, табигать белеме, тел белеме, әдәбият белеме фәннәренә игътибар артуда да чагыла. Г. Сәгъди сүзләре белән әйткәндә, «милли тарихның нигез ташларын салган» Шиһабеддин Мәрҗанинең хезмәтләре Татарстан тарихында иң кыйммәтле хәзинәләрдән санала. Аның «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»

(«Казан һәм Болгар тарихы буенча чыганаклар») дигән ике томлык зур хезмәте 1885 һәм 1900 елларда басылып чыга.

Габденнасыйр Курсави (1776—1812) үзенең фәлсәфә өлкәсендәге хезмәтләре белән билгеле. Ул Казан өязендә туа, Малмыж шәһәрендә мәдрәсә тәмамлый, Әл-Фәраби һәм Ибне Сина хезмәтләре буенча фәлсәфә өйрәнә, уннан артык фәлсәфи хезмәт язып калдыра. Алар арасында бигрәк тә «Әл-иршаде лил-гыйбад» («Туры юлга өндәү») дигән хезмәте аерылып тора. Ул Коръәнне рациональ шәрехләүне яклап чыга, үзенең тормыш юлын сайлауда шәхеснең ирекле булуына өнди. Каюм Насыйри, Ибраһим Хәлфин, Мөхәммәтгали Мәхмүдовның хезмәтләрендә татар тел белеме һәм татар әдәбияты белеме зур үсеш ала. Шиһабеддин Мәрҗани йолдыз санаучы Хәмзә дигән кушамат бирелгән Хәмзә ибне Мөхәммәт әл-Казани әл-Баразавиның (1826 елда вафат) математика һәм астрономия өлкәсендәге хезмәтләре турында яза. Ул үзенең астролябия приборын һәм глобусын эшли, йолдызлар каталогы һәм календарьлар төзи.

Шәрыкны өйрәнүче рус галимнәренең дә татар тел белеме һәм Татарстан тарихы белән кызыксынулары арта. Казан университетында 20 елдан артык мөгаллимлек иткән А. К. Казембек (1802—1870) үзенең «Грамматика турецко-татарского языка» дигән мәгълүм хезмәтен яза. И. Н. Березин (1818—1896) «Татарский летописец», «Булгар на Волге» хезмәтләрен бастырып чыгара. К. Ф. Фукс (1776—1846) үзенең күпьеллык тикшеренүләре нәтиҗәләрен «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» дигән китабында бәян итә. Шәрыкны өйрәнүче танылган галим Вельяминов-Зернов «Исследования по истории Касимовских царевичей» хезмәтен нәшер итә. 1884 елда В. В. Радловның «О языке куманов»дигән китабы дөнья күрә.

1799 елда император Павел I татарларның басмаханә ачуны сорап яудырган үтенечләреннән соң татар телендә китап нәшер итүгә рөхсәт бирергә мәҗбүр була. Казанда беренче татар басмаханәсен прапорщик Габделгазиз Бурашев ача. Бу басмаханәдә беренче китап 1801 елда дөнья күрә. Башта рөхсәт дини китаплар чыгаруга гына бирелә. Казан дәүләте заманыннан ук бездә Коръән Гарәп хәлифәлегенең өченче хәлифәсе Госман кушуы буенча VII гасырда төзелгән һәм соңрак кануни (законлы) дип аталган рәсми редакциядә таралып килә. Әлеге «Госманның изге Коръәне» Санкт-Петербург

китапханәсендә саклана. Коръәннең татар телендәге аңлатмалары кулдан язылган хәлдә генә таралып килә. Мәсәлән, 1513 елда язылган Коръән тәфсире (аңлатмасы) мәгълүм. XIX йөздә Коръән тәфсиренең, Ислам догалыкларының, Казанның үзендә татар телендә басылганнары күренә башлый.

Тиздән дөньяви китаплар бастыру да башлана. 1842 елда «Татар хрестоматиясе» — татар халык җырлары, әйтемнәре, табышмаклары җыентыгы басылып чыга. 1859 елда Салихҗан Кукляшевнең «Диване хикәяте татар» («Татар хикәятләре җыентыгы») исемле хрестоматиясе дөнья күрә. Мәдрәсәләр һәм мәктәпләр татарча басма китаплар белән тәэмин ителә башлый. Татар әлифбасы, уку китаплары басылып чыга. 1839 елда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының беренче басмасы дөнья күрә. Аннары татар фольклоры ядкәрләре, «Кыйссаи Таһир-Зөхрә», «Мең дә бер кичә»дән һәм «Кәлилә вә Димнә»дән, башка төрки халыклар фольклорларыннан («Кыйссаи Кёр-углы»), Ибне Сина, Фәраби, Җами, Низами, Газали, Пушкин, Лермонтов, Крылов шулай ук башка язучылар һәм галимнәрнең әсәрләреннән тәрҗемәләр үз укучыларын таба. Ә. Кәримуллинның исәпләүләре буенча (1975) бары тик Казанда гына да 3500 татар китабы басылып чыга.

Шул ук елларда татар вакытлы матбугатын булдыру омтылышы ясала. Каюм Насыйри үзенең «Таң йолдызы» дигән газетасын чыгару өчен рөхсәт ала алмый. Хакимият органнарын моңа һич күндереп булмый. Керәшен татары М. Г. Никольскийның «Бәхрүл әхбәр» («Хәбәрләр диңгезе») дигән газета чыгару турындагы үтенече кире кагыла. Беренче татар газетасы бары тик 1905 елда гына дөнья күрә. Ә моңарчы Каюм Насыйри 1871 елдан 1897 елга кадәр үзенең еллык өстәл календарьларын чыгарып килә. Алар укучыларга фән һәм тормышның төрле өлкәләреннән мәгълүмат бирә. Исмәгыйль Гаспралы тарафыннан Кырымда чыгарылган «Тәрҗеман» газетасы да үзенең уңай ролен уйный.

Милли тергезелү милли мәдәният, шул исәптән монументаль-декоратив сәнгать һәм сынлы сәнгать, милли музыка барлыкка килүдә һәм үсүдә дә чагылыш таба. Китапларны пейзаж һәм сурәт белән бизәү сәнгате барлыкка килә. Гарәп язуы үрнәкләреннән үсеп чыккан каллиграфия дә сәнгатькә әверелә. Музыка өлкәсендә Г. Сафиуллинның уңышлы эшчәнлеген билгеләп үтми мөмкин түгел. Ул татар халык җырларын ноталарга күчерә һәм татар халык музыка уен коралларын

башкаручы оста булып танылa. Профессиональ татар музыкасы туа. Тулаем алганда, татар мәдәнияте дәүләт ярдәме булмаган шартларда монументаль булудан бигрәк, күбрәк рациональ була, кыен язмышлы халыкның хисләрен тирән чагылдыра.

Татар мәгърифәтчелеге. Татар мәгърифәтчелеге татар иҗтимагый аңы һәм иҗтимагый хәрәкәте үсешендә яңа дәвер ача. Мәгърифәтчелек үсеше XIX гасыр буена милли тергезелүнең икътисади, социаль, мәдәни һәм рухи өлкәләрдәге уңышлары нигезендә бара. Мәгърифәтчелек нуры яктылыгында Татарстан татар халкының язмышында зур үзгәрешләр тудырган XX гасырга керә. Татар мәгърифәтчелеге идеяләре милли тергезелүне, шул исәптән милли азатлыкка ирешүне тәгәлләүгә юл тота. Тарихчы галим Р. И. Нәфыйков мәгърифәтчеләрнең таләпләре «абсолютизмга каршы юнәлдерелгән була» дип билгеләп үтә.

Татар мәгърифәтчелегенең үз үзенчәлекләре була. Мәсәлән, Франциядә мәгърифәт идеяләре формалашу һәм аларны гамәлгә ашыру чагыштырмача кыска вакыт эчендә — бер XVIII гасыр дәвамында хәл ителә. Көнбатыш Европаның башка илләрендә мәгърифәтчелек идеяләренең гамәлгә ашырылуы XIX гасырга, ә Россиядә XX гасырга туры килә. Татарстанны яңартып кору Россиядә мәгърифәтчелек идеяләренең тормышка ашырылуына, барыннан да элек, самодержавие монархиясен рус булмаган халыкларны милли азат итүгә юл алачак демократик дәүләт строе белән алыштыруга бәйле була.

Татар мәгърифәтчелеген башлап җибәрүчеләр дип Галимҗан Ибраһимов Каюм Насыйрины, Хөсәен Фәезханов һәм Шиһабеддин Мәрҗанины атый. Алар, Г. Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, XIX йөзнең икенче яртысында «бердәм реформаторлык фронтына чыгалар». Алга таба бу «реформаторлык фронты» сафлары тагы да ишәя, шуның белән мәгърифәтчелек хәрәкәте дөньяга карашлар төрлелеге белән тулылана. Хәрәкәттә аерым сыйныфлар һәм җәмгыять катлаулары мәнфәгатен чагылдыручы төрле юнәлешләр формалаша. Әйтергә кирәк, Татарстанны яңартып коруга, татарларның милли тормышын тергезү эшен тәгәлләүгә булган гомуми юнәлеш сакланып кала.

Бу феноменны билгеләү өчен татар әдәбиятында ике төрле төшенчә кулланыла: «татар җәдитчелеге» һәм «татар мәгърифәтчелеге». Беренче төшенчә нигездә 1917 елгы революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы беренче елларда, шул

исәптән 1926 елда Галимҗан Ибраһимов тарафыннан кулланыла. Икенче төшенчәгә М. Х. Гайнуллин өстенлек бирә. Ул болай дип билгеләп үтә: татарларның тормышын европалаштыру, гражданнарны агарту һәм халыкка яңача (җәдитчә) дөньяви белем бирүне кертү аны рус мәдәниятенә якынайту турындагы фикерләр, Ватанга мәхәббәт — татар мәгърифәтчеләренең кредосы менә шулар.

Татар мәгърифәтчелек хәрәкәтен башлап җибәрүчеләр Көнбатыш Европа мәгърифәтчелек идеяләреннән турыдан-туры (бигрәк тә француз чыганаклары аша) да, рус мәгърифәтчеләре, Мисыр, Төрки, Кырым мәгърифәтчеләре аша да хәбәрдар булалар. Кырым-татар мәгърифәтчелеген башлап җибәрүче Исмәгыйль Гаспринскийны (Гаспралыны) татар тарихчылары мәгърифәтчеләр белән беррәттән телгә алалар. Татар мәгърифәтчеләре Урта Азиядә һәм Казакъстандагы фикердәшләре белән турыдан-туры бәйләнештә торалар.

Мәгърифәтчеләр энциклопедист галимнәр булганнар. К. Ф. Фасеев Каюм Насыйрины (1825—1902) замандашлары «белем һәм яңа фикерләр чәчүче» итеп тасвирлаган дип билгеләп үтә. Каюм Насыйри татар укучысын Колумбның ачышлары белән, китап басучы Гутенберг белән таныштыра, татар телендә «Россиянең кыскача тарихы»н, «Әбүгалисина кыйссасы»н яза, алда билгеләп үтелгәнчә, 20 ел дәвамында үзенең халык календарьларын чыгарып килә. Аның татар мәктәпләрендә татар телен, тарихын һәм мәдәниятен, табигать турындагы фәннәрне өйрәтүне гамәлгә куюга керткән өлеше аерата зур. Ул география, арифметика, геометрия, татар теле грамматикасы буенча дәреслекләр төзи һәм бастырып чыгара.

Күренекле тарихчы, философ, теолог Шиһабеддин Мәрҗани (1818—1889) татар мәгърифәтчелегендә тирән эз калдыра. Халыкны милли агарту, аның милли аңын үстерү проблемалары турында, дөньяви белемнәр, ислам белемен бирү кирәклеге һәм юллары хакындагы фикерләрен 1870 елда Казанда басылып чыккан, илдә дә, аннан читтә дә танылган «Назурәтел-хак» («Хакыйкатьне күзаллау») дигән китабында бәян итә. Мәрҗани азатлык һәм гуманлык идеяләренә өнди, теләктәшлекне, милләт бердәмлеге өчен зарур үзара ярдәмләшүне яклап чыга. Халыкның XVI гасырда рус гаскәрләренә каршы азатлык сугышында җиңелү сәбәбен үзара дошманлыкта, тарткалашуларда, әхлакның түбән тәгәрәвендә күрә. Татарстанны яңартып коруны, шул исәптән милли азатлыкка

ирешүне ул Россиядә мәгърифәтчелек, Европадагыча демократия җиңеп чыгуы белән бәйли. Ул еллардагы хакимияткә карата лояль булу зарурлыгын шуның белән аңлата. Фатих Әмирхан бераз соңрак аның турында кыска гына, әмма мәгънәле итеп: «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе»,— дип, тикмәгә генә әйтмәгән.

Үзенең 1883 елда язылган «Элгәрләрнең некрологлары һәм аларның киләчәк буынга васыятьләре» дигән китабына кереш сүзендә Шиһабеддин Мәрҗани, тикшеренүче М. Х. Юсупов билгеләп үткәнчә, күп кенә илләрнең тарихи мисалларында, дәүләтнең иминлеге, халыкның мәдәнияте һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрү мәгърифәт һәм фәннең чәчәк атуына нигезләнә, дип яза. Һәм, киресенчә, мәгърифәт һәм фәннең түбән дәрәҗәдә булуы торгынлыкка алып бара дип раслый. Мәрҗани Татарстанның Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятен яклавы белән беррәттән, дөнья мәдәниятенә үз өлешен кертүче үзенчәлекле ил булуын да аңлый.

Мәрҗани мәктәбен тәмамлап чыккан Хөсәен Фәезханов (1821—1866) милли тергезелү проблемаларын үзенчә күрә һәм аның бурычларын үзенчә тәгъбирли. Шәрыкны өйрәнүче танылган белгеч, гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белүче галим буларак, ул Көнчыгыш факультеты укытучысы итеп Санкт-Петербург университетына эшкә чакырыла. Татарларның милли тергезелүен ул, барыннан да элек, яхшы куелган халык мәгарифе белән бәйли һәм ул, ягъни халык мәгарифе, дәүләт эше булырга тиеш дип исәпли. Фәезханов татар дәүләт гимназиясе оештыру проектын эшли һәм тәкъдим итә. Анда укытуны өч телдә: татар, рус һәм Көнбатыш Европа телләренең берсендә алып баруны күздә тота. Ул үзе «Татар теленең кыскача грамматикасы»н яза һәм 1862 елда бастырып чыгара.

Үзенең фикердәшләре-мәсләктәшләре мәгърифәтчеләр кебек үк, телне яхшы белү белән беррәттән, үз тарихыңны белү — милли тергезелүнең мөһим шарты дип санап, татар халкы тарихын өйрәнә. Ул Тәтеш тирәсендә һәм Касыйм ханлыгында татарларның күп кенә ташъязма истәлекләрен ача һәм аларны уку-аңлауга ирешә. Ул шулай ук күп кенә шәркый чыганакларны, шул исәптән төрек чыганакларын, татарчага тәрҗемә итә. Аның Кырым ханлыгының тарихы буенча тикшеренүләре дә билгеле.

Татар мәгърифәтчеләре татарларның эчке милли проблемалары кысаларында гына йомылып калмыйлар. Милли тер-

гезелүнең язмышы Россиядәге социаль-сәяси яңарыш белән тыгыз бәйләнгән булуны аңлаган хәлдә, алар рус халкының, илдәге рус булмаган барлык халыкларның чәчәк ату юллары турында бердәй караштта торалар. Алар, мәсәлән, татар һәм рус халыклары арасында уңай мөнәсәбәтләр урнашуда татарларның — рус телен, ә русларның татар телен өйрәнү-белүләре зур роль уйный дип саныйлар. Каюм Насыйри татар мәктәпләре өчен «Рус телендә уку кагыйдәләре»н (1889), «Рус теле грамматикасы»н яза һәм бастырып чыгара. Үз чиратында Казан гимназиясендә, ә аннары Казан университетында татар теле укыткан Ибраһим Хәлфин (1778—1828) һәм Мөхәммәтгали Мәхмүдов (1824—1891), шулай ук Оренбургта кадетлар корпусында курсантларны татар теленә өйрәткән Салихҗан Кукляшев рус уку йортлары өчен татар телендә дәреслекләр, уку әсбаплары, сүзлекләр («Татар теленең әлифбасы һәм грамматикасы», «Татар хрестоматиясе», «Татар хрестоматиясе өчен сүзлек» һ. б.) төзиләр.

Мәгърифәт, без аны ничек кенә югары бәяләсәк тә, һәр бәладән коткара торган чара була алмый. Ул абсолют гаделлекне тормышка ашыра торган идея булып китә алмый. Мәгърифәтчелек моңа кадәр яшәп килгән диннәр урынын биләми, бөтендөнья диненә әверелми. Мәгърифәт үзе — халыкның җанлы тормышы. Ул халыкның, аның социаль структураларының сәләтен күтәрергә, җәмгыять үсешенең иң оптималь юлларын табарга чакырылган. Мәгърифәтчелек, аның идеяләре заманның җанлы тормышыннан ничек өйрәнергә кирәклеккә һәм теге яисә бу вазгыять өчен кулланма булырдай яңа идеяләрне ничек эзләргә һәм табарга кирәклеккә өйрәтәләр.

Милли һәм социаль ризасызлык чагылышлары. Милли тергезелү өлкәсендә беренче вакытларда бу хәрәкәткә иң актив катнашучылар җәмгыятьнең яңа катлаулары — сәнәгатьтәге борылыш чоры эшмәкәрләре, яңа зыялылар була. Тора-бара халыкның түбән катлаулары да активлаша. Бу активлык, барыннан да элек, милли тергезелүгә юнәлдерелгән уңай эш-гамәлләрдә чагыла. Бер үк вакытта халыкның социаль активлыгы милли изелүгә һәм социаль гаделсезлеккә түзеп тора алмауда, ризасызлык күрсәтүдә дә күренә.

Дәүләт хакимияте органнарына хатлар һәм петицияләр җибәрү милли ризасызлык белдерү формаларыннан берсе була. 1763—1788 елларда патшабикә Екатерина II оештырган «Яңа уложение (Законнар җыелмасы) төзү комиссиясе» эшләгән

вакытта аның адресына судларда татарларга туган телләреннән файдалануны, татар крестьяннары өчен урман полосалары бирүне, татарларны дәүләт заводларына көчләп беркетүне туктатуны, татар сәүдәгәрләренә һәм сәнәгатьчеләренә һ. б. карата дискриминацияне бетерүне таләп иткән хатлар җибәрелә.

1773—1775 елларда Емельян Пугачев җитәкчелегендәге рус крестьяннарының дворяннарга каршы күтәрелеше барышында Татарстан крестьяннарының да көчле чыгышлары булып уза. Пугачев гаскәре, Татарстанның көньяк чикләренә якын булган районнарда тупланып, өлешчә Татарстан территориясе аша үтә, һәм күп кенә татар крестьяннары да шушы баш күтәрүчеләргә кушыла.

Теге яисә бу формада хакимият органнарының мөселман татарларны көчләп чукындыруларына каршы, шулай ук яңадан исламга кайта торган керәшен татарларына карата җәза чаралары куллануга каршы да милли протест белдерелә. 1865 елда Тәтеш исправнигы, өяздәге 5105 җан керәшен татарларының «барысы да диярлек православиедә калырга теләмиләр», дип яза. Хакимият җавап чаралары куллана башлый. Моннан соңгы 1866 елда шул нигездә хакимият вәкилләре белән бәрелешләргә кадәр барып җиткән җитди чуалышлар булып уза.

Дәүләт крестьяннары булган татарлар да элек кеше кеременең уннан бер өлешен тәшкил иткән ясак күләмен арттыруга каршы үзләренчә ризасызлык белдерәләр. Бу бөлгенлеккә төшкән крестьяннарның ясак түләүдән баш тартуларында чагыла. Казан губернаторы П. Салтыков 1814 елда Сенатка җибәргән хатында: «Бөек патша хәзрәтләре билгеләгән салымны түләргә теләмәүче ясаклы крестьяннар күбәеп китте»,— дип зарлана. Аларның кайберләре үз ризасызлыкларын ераграк районнарга күченеп китү белән белдерәләр. Казан губернаторы А. П. Волынский 1830 елда, качкын рус крестьяннары башкорт җирләренә күчеп киткән ясаклы татарларның җирләрен ала, дип билгеләп үтә. Недоимкаларны җыю өчен хөкүмәт көч куллану чараларына бара. Ә бу хәл үз чиратында яңа ризасызлык чыгышлары тудыра. 1854 елда Казан өязенең күп кенә авылларында недоимкаларны җыю вакытында крестьяннарны рәхимсез кыйныйлар, ә аларның берсе хәтта әлеге кыйналудан үлеп тә китә. XIX гасырның 30 нчы елларында татар крестьяннары хакимият органнары-

ның чынлыкта крепостной хокук кертергә маташуларына каршы ризасызлык белдерәләр. Эш менә нәрсәдә була. 1797 елда элек патша сараеныкы булган җирләр (земли царского двора) удел җирләре итеп игълан ителә, ә бу җирләрдә утырган крестьяннар удел крестьяннары дип атала башлый, ягъни крепостной хокук — оброк түләү һәм башка йөкләмәләрне үтәү — аларга да кагыла булып чыга. Алга таба Дәүләт милке министрлыгы фәрманы буенча андыйларның сафлары ирекле (ясаклы) крестьяннар хисабына тулыландырыла башлый. Һәм менә 1797 елда чират ясаклы татар крестьяннарына да җитә. Беренчеләрдән булып удел крестьяннары разрядына күчерү өчен Буа өязенең ясаклы крестьяннары сайлап алына. Ләкин крестьяннарның көчле ризасызлыгы аркасында, хакимият бу чараны тормышка ашыра алмый.

Рус алпавытларының татар крестьяннары җирләрен тартып алуларына каршы да татарлар ризасызлык белдерәләр. 1852 елда алпавыт Еримеев Зөя өязенең Нурлат авылы җирле крестьяннарының 31,5 дисәтинә җирен тартып ала. Суд та аның файдасына карар чыгара. Үз җирләрен саклап калырга дип җыелган татар крестьяннары куып таратыла. Крестьяннар чуалышында актив катнашучы Хөсәенов, Халитов, Әхмәтовлар кулга алына.

Урманнарны үз белдекләре белән рөхсәтсез кисү крестьян ризасызлыгы чыгышларының тагын бер формасы була. Татарстан Россия тарафыннан яулап алынганнан соң,барлык урманнар дәүләт һәм рус алпавытлары кулына күчә. Урман кисү кебек башбаштак чарага баруларын крестьяннар төзелеш чималы сатып алырга мөмкинлекләре булмау белән аңлаталар. Мондый хәл, мәсәлән, Спас өязендә булып уза. Судта Зәбиров, урманны «ярлы булганлыктан, каралты-кураны төзәтү өчен агач табу хәлебездән килмәгәнлектән кистек», дип сөйли. Никрутлар җыюның гадел булмавы да крестьяннарда ризасызлык уята. Хезмәт итү срогы 25 ел булганлыктан, әйтик, бердәнбер улны солдатка җибәрү хуҗалык өчен бик авырга туры килә. Чыганаклар күп кенә крестьян чуалышларының шул сәбәпле башлануы турында хәбәр итә.

Рус крестьяннарының социаль ризасызлыгы, башлыча, крепостной изүгә каршы юнәлдерелгән була. 1861 елда патша Александр II крепостной хокукны бетерү турында Манифест чыгара. Әмма бу Манифест крестьяннар тормышына әллә ни уңай үзгәреш алып килми.

1878— 1879 елларда крестьяннар арасындагы чуалышлар массакүләм төс ала. Ул вакытта хөкүмәт «ихтыяҗларны канәгатьләндерү, мәсәлән, чиркәүләр төзү һәм аларга булышлык күрсәтү, авыл училищелары булдыру һ. б. өчен» илдә җәмәгать (мир) җыемнары һәм йөкләмәләре кертү турында карар кабул итә. Бу карарда татар мәчетләренә, мәктәпләренә чыгымнар күздә тотылмаганлыктан, татарлар моңа нык ризасызлык белдерәләр. Казан өязендә эш кайбер волость канцелярияләрен тар-мар итүгә кадәр барып җитә. Чуалышларны бастыруда Казан губернаторы Скарятин шәхсән үзе җитәкчелек итә. Каршылык күрсәтүдә актив катнашучылардан өч кешенең (М. Ибраһимов, Х. Габидуллин, С. Шаһиәхмәтов) һәрберсе 4,5 елга каторга эшләренә хөкем ителә. Чуалышлар шулай ук Самара, Сембер, Вятка, Уфа, Пенза губерналарында да була. Татар психологиясен аңлар өчен хакимият органнарына хәтта Коръәнгә дә күз төшерергә туры килә. Шәрыкны өйрәнүче танылган галим Г. С. Саблуков (1804—1880) Коръәнне рус теленә тәрҗемә итә.

Мануфактуралар, ә алга таба машиналар кулланып эшләүче предприятие эшчеләре дә социаль ризасызлык белдерүләрдә катнаша. Татарстанда мондый предприятиеләрнең күпчелеге дәүләт кулында яисә рус капиталистлары кулында була. Аларда эшчеләрнең күпчелеген руслар тәшкил итә. Шуңа күрә ризасызлык белдерүчеләрнең беренче сафларында нәкъ менә алар була. Эшләп чыгару нормаларының көч җитмәслек югарылыгы, эш көненең бик озынлыгы, хезмәт һәм тормыш шартларының авырлыгы ризасызлыкның төп сәбәбе була. Эшче чуалышлары рәхимсез рәвештә бастырыла, чыбык белән суктырулар, солдатка җибәрүләр, Себергә сөрү кебек җәза алымнары еш кулланыла. Крепостной хокук белән бер вакытта посессионлык хокукы да бетерелгәнгә кадәр посессион эшчеләрнең ризасызлыгы аерата көчле була.

Сәнәгатьтә машина системасына күчү белән ялланган эшчеләрнең милли һәм социаль ризасызлык чыгышлары көчәя. XIX гасырда дәүләт предприятиеләрендә һәм русларның хосусый предприятиеләрендә, нигездә, квалификациясез кара эшләргә тартылган татар эшчеләре ризасызлык чыгышларында руслар белән бер сафта торып катнаша. Татар эшчеләренең үз социаль һәм милли хокуклары өчен мөстәкыйль чыгыш ясый башлаулары XX гасыр башларына туры килә.

МИЛЛИ АЗАТЛЫК ЮЛЫНА БАСУ

Дөньяда яңа тарихи тенденция. Индустриаль җәмгыятьнең формалашу һәм үсү тенденциясе XX гасырда үз орбитасына яңадан-яңа илләрне ала. Ләкин бу тенденциянең гамәлгә ашырылуы тоткарлыкларга очрый. Социаль тигезсезлек һәм халыкның тормыш дәрәҗәсенең түбән булуы, халыкның гражданлык хокуклары һәм ирекләре белән хакимият органнарының исәпләшмәве күп кенә илләрдә революцияләр һәм гражданнар сугышлары килеп чыгуга сәбәп була. Колониаль изүнең дәвам итүе милли-азатлык хәрәкәтен һәм азатлык сугышлары мөмкинлеген көчәйтә. Бөек державалар арасындагы каршылыклар дөнья сугышын якынайта. Боларның барысы да дөньядагы бердәмлекнең үсүе өчен уңайлы җирлек булудан бик ерак тора.

Татарстан XX гасырга үзенең дәүләтчелеген торгызуга һәм илдә югары культуралы мәгърифәтчел-индустриаль җәмгыять формалаштыруга зур өметләр белән керә. Шул ук вакытта бу максатка ирешүнең бик зур тырышлык таләп итәчәге ачык һәм аңлаешлы була. Бөтен дөньядагы колониаль державалар үзләренең колонияләреннән аерылырга әзер түгелләр һәм моны теләмиләр. Сүз Азия һәм Африкадагы колонияләр турында гына бармый. Хәтта Европада да ул вакытта Ирландия, Чехия, Словакия, Польша, Болгар кенәзлеге, Албания бәйле илләр статусында кала бирәләр. Россиядә дә милли бәйсезлек мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән килеп баса.

Россиядә милли азатлык проблемалары. XX гасырда рус самодержавие монархиясе империячел бөеклегенә нык ышанган хәлдә керә. Эш Россиянең чәчәк атучы илгә әверелгән булуында түгел. Халкының тәэмин ителгән имин тормышта яшәвеннән ул әле бик ерак тора. Россия Александр II реформаларының дәвам иттерелүенә мохтаҗ була. Шуңа да карамастан Николай II 1894 елда тәхеткә утырганда әтисе Александр III нең 1889—1892 еллардагы «контрреформаларына» тугрылыклы булачагы турында ант итә, «самодержавие нигезен ныклык белән һәм тайпылышсыз рәвештә саклаячакмын», дип белдерә.

1913 елда Романовлар йортының 300 еллыгы бәйрәм ителгән көннәрдә зур тантана белән купшы итеп билгеләп үтелгән Россия олпатлыгының төп күрсәткечләрен яулап алынган зурзур территорияләр һәм көчләп буйсындырылган күп кенә

халыклар тәшкил итә. Бу Россия самодержавие империясенең территориаль яктан иң нык киңәйгән вакыты була. Иң башта колонияләштерелгән Идел буе һәм Урал таулары итәгендәге татар, мари, мордва, чуваш, удмурт һәм башкорт халыкларын милли изү дәвам итә. Рус халкында аларга карата нәфрәт кабызу өчен бөекдержавачылык акцияләре оештырыла. 1892—1896 елларда Вятка губернасының Иске Мултан авылыннан бер төркем удмурт крестьяннарына дини максатларда кеше үтерделәр дигән ялган гаеп ташлап, алар өстеннән суд процессы оештырыла. XIX гасыр азагында Украина, Белоруссия, Польшада еврейләргә каршы чираттагы погромнар дулкыны үтә. Польшада мөстәкыйль милли учреждениеләрне чикләү һәм бөтенләй бетерү чаралары үткәрелә. Почта мөстәкыйльлеге бетерелә, Финляндия эшләре комитетының эшчәнлегенә чик куела. Төньяк Кавказны үзләштерү зур кыенлыклар белән бара. Биредә XIX гасыр башыннан кертелгән оккупация режимы төбәккә тынычлык алып килми. XX гасыр башында Россия территориясе тагын бер юнәлештә — Казакъстан һәм Урта Азия юнәлешендә киңәя һәм «туземецлар сәясәте»н тудыра. Империя тотучы рус халкының саны (43 %) милли дәүләт хокукыннан мәхрүм ителгән рус булмаган халыклар саны (57 %) белән чагыштырганда кимрәк булып чыга.

Шуңа да карамастан, патша хөкүмәте үз территориясенә яңадан-яңа җирләр өстәү планнарын кора. Дарданелл бугазын яулап алу һәм Урта диңгезгә чыгу планнарын, Балкан ярымутравында яшәүче православие динендәге славяннарны рус халкы тирәсенә туплау планнарын эшләү бара. «Контрреформаларны» рухландыручыларның берсе булган М. Н. Катков «рус телен гомумславян теле итеп тану» турында хыяллана.

Милли консолидация. XVIII—XIX гасырларда татар җәмгыяте патша хөкүмәте белән компромисс нигезендә милли консолидация (милли туплану) этабын шактый уңышлы үтә. Идел буе татарларының төрле төркемнәре (Болгар-Казан татарлары, Касыйм татарлары, мишәрләр һәм алар эчендә яшәп килгән төрле төркемчәләр — типтәрләр, Пермь татарлары, Чепца татарлары һ. б.) арасында милли-мәдәни якынаю күзәтелә. Бу мәгърифәтчелек мәдәниятенә, исламча рухи тормышка нигезләнгән милли гомумилекнең яңа дәрәҗәсе була. Милли үзаң, үзенчәлекле милли рух ныгый. Православие динен тотучы татарлар, әлегә үзләрен керәшеннәр итеп хис

итсәләр дә, татарларның милли туплануы процессына активрак кушыла баралар.

Тарихи әдәбиятта бу процесс *татар милләтенең формалашуы* дип билгеләнә. Күпмилләтле Россия дәүләтендә яшәүче барлык татарлар аларның барысы өчен дә уртак булган татар телендә сөйләшәләр, гарәп графикасына нигезләнгән гомуммилли язудан файдаланалар. Башлангыч, урта һәм югары мәктәпләрне үз эченә алган милли мәгариф системасы уңышлы эш итә, күп жанрлы милли әдәбият һәм милли китаплар бастырып чыгару гомумтанылган күренешкә әверелә, профессиональ татар музыкасы, милли сынлы сәнгать яралгылары күренә. Шушы төбәккә хас хуҗалык алып бару рәвеше һәм гореф-гадәтләре, татар халкы территориясенең милли характеры сакланып кала. Себер татарлары да татар телен һәм язуын, татар әдәбиятын үзләренеке итеп кабул итәләр. Мәскәү һәм Санкт-Петербургта, Украина һәм Кавказда, Казакъстан һәм Төркестанда, Ерак Көнчыгыш һәм Донбасста яшәүче татар диаспорасында милли үзаң, татар милләтеннән булуын аңлау хисе югары була.

Бу милли консолидация татарларның милли-сәяси консолидациясе өчен юл ачкан яңа этап булып тора.

XX гасыр башына татар җәмгыяте. 1897 елда үткәрелгән бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләренә нигезләнеп, Идел-Урал төбәгенең 12 губернасында татарлар санын Д. М. Исхаков 2249,5 мең кеше дип күрсәтә. Губерналар буенча бу сан менә болай бүленә (меңнәрдә): Казан губернасы — 675,4; Урал губернасы — 609,1; Самара губернасы — 259,8; Вятка губернасы — 147,2; Сембер губернасы — 133,9; Оренбург губернасы — 126,2; Саратов губернасы — 94,6; Пермь губернасы — 81,2; Пенза губернасы — 58,5; Түбән Новгород губернасы — 41,3; Тамбов губернасы — 17,0; Рязань губернасы — 5,0. Бу губерналарның берсендә дә татарлар күпчелекне тәшкил итми, руслар күбрәк була. Патша хакимияте, шуңа таянып, татарларны күпсанлы рус халкы арасына «сибелгән» милли азчылык итеп күрсәтергә тырыша. Чынбарлыкта исә татарлар рус җирләренә килеп урнашкан килмешәкләр булмый. Патша самодержавиесенең колонизаторлык сәясәте аркасында гына бу шулай килеп чыга. Административ яктан бүлгәләнгән булуга карамастан, татар халкының милли бердәмлеге ныгый. Татарлар үзләренең тарихи җирләрендә үзләрен милли азчылык итеп хис итмиләр.

Ике миллионнан артык кешесе булган бу бердәм милләт социаль структура ягыннан авыл хуҗалыгы һәм сәнәгате үсеш алган җәмгыять сыйфатында формалаша. Әйтеп үтелгән халык санын алу нәтиҗәләре буенча (13 губерна мәгълүматлары) мөстәкыйль хуҗалык алып баручы татарларның һәм аларның гаилә әгъзаларының санын Х. Х. Хәсәнов 1865,1 мең кеше дип билгели. Ул вакыттагы рәсми социаль бүленеш нигезендә шулардан крестьяннар — 1 734 733 кеше (93,01 процент), сәүдә-сәнәгать эшмәкәрләре — 7565 кеше (0,41 процент), эшчеләр — 68 626 кеше (3,68 процент), мещаннар — 32 726 кеше (1,75 процент), руханилар — 11 084 кеше (0,59 процент), чиновниклар — 8861 кеше (0,48 процент), башкалар 1547 кеше (0,08 процент) тәшкил итә.

XX гасыр башына татарларның XVI гасырда туздырылган шәһәр тормышы шактый дәрәҗәдә тергезелә. Татар халкының гомуми күләмендә шәһәрдә яшәүчеләр 1912 елда 5 процент тәшкил итә (ә гомумроссия күрсәткече — 15 процент). Казан губернасындагы 675 мең татар кешесенең шәһәрләрдә яшәүчеләр саны 35 мең (5,2 процент), 833 мең рус кешесенең шәһәрләрдә яшәүчеләре 143 мең кешедән (17 процент) гыйбарәт була. Шәһәрләрдә яшәүче татарлар санының гомумроссия күрсәткеченнән күпкә калышуы, шулай ук татар сәнәгатенең артта калуы бу өлкәләрдә татарларга карата үткәрелеп килгән максатчан тоткарлау һәм чикләү сәясәте нәтиҗәсе була.

Татар җәмгыяте үзенең рус җәмгыяте белән берлектә рус дәүләтендә яшәвен яхшы аңлый. Татар җәмгыятенә тотрыклылыкны гасырлар дәвамында корылган гаилә һәм гаиләгә карата мөнәсәбәт тәэмин итә. Татарлар көнкүрештә һәм иҗтимагый тормышта милли традицияләрен җаваплылык хисе белән саклыйлар, үзләренең рухи ислам кыйммәтләрен югары бәялиләр. Алар шулай ук гражданлык бурычларына да зур җаваплылык хисе белән карыйлар, дәүләттә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне билгеләүче хокук нормаларына таянып яшиләр. Бер дәүләт гражданнары булып яшәү татарларны руслар һәм башка милләт вәкилләре белән якынайта. Милләтләр дуслыгы һәм үзара ярдәмләшү, эшмәкәрләрнең сәүдәсәнәгатьтә намус белән бергәләп эш итүләре гадәти бер күренешкә әверелә. Төрле милләт вәкилләренең никахлашуы еш кабатланып тора. Мөселманнарның һәм православие динен тотучыларның бер конфессиядән икенчесенә күчүләре дә булмый тормый. Татарларның милли мәнфәгатьләре бер

Татарстан кысаларында гына түгел, бәлки, билгеле дәрәҗәдә, рус дәүләте кысаларында да формалаша. Илдә рус халкы һәм башка халыклар мәнфәгатьләрен үз эшчәнлегенең үзәгенә куячак демократик дәүләт урнаштыру уртак бер максат буларак карала. Сәяси азатлык таләп итү озак еллар дәвам иткән милли изү өчен рус халкыннан үч алу итеп каралмый. Ул рус дәүләтен какшатуны максат итеп куймый.

Сәнәгать концентрациясе. Россиядә XX гасыр башы капиталистик ширкәтләр (концерннар, трестлар һ. б.) яралу һәм үсү, банк системасының аякка басуы белән характерлана. Татарстанның милли икътисады шул системада үсә, аның өчен дәүләт тарафыннан билгеләнгән регламент белән исәпләшеп эш итә. Татар эшмәкәрлеге нигездә җиңел сәнәгатьтә (күн, мех, аяк киеме, киҗе-мамык, җитен туку, сабын кайнату), азык сәнәгатендә, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һәм сәүдәдә колач җәя. Капитал һәм җитештерүнең шактый зур концентрациясе нәкъ менә шул өлкәләрдә башлана, предприятиеләрнең энергия куллануы арта, сәүдә-сәнәгать ширкәтләре һәм сәүдә йортлары барлыкка килә.

Акчуриннарның 1893 елда Сембер губернасының Сингәләй өязендә салынган «Иске Тимошкино постау мануфактурасы ширкәте» 1913—1914 елларда елына миллион сумлык диярлек постау җитештерә. 1914 елда Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгында теркәлгән, Сембер губернасының Сызрань өязендәге «Тимербулат Акчуринның сәүдә-сәнәгать ширкәте» предприятиеләрендә 3 меңгә кадәр кеше эшли. 1916 елдан Саратов губернасында төп капиталы 500 мең сум булган «Дөбердиевләрнең сәүдә-сәнәгать ширкәте» эшли башлый. Пермь губернасының Оса шәһәрендә төп капиталы 150 мең сум тәшкил иткән «М. М. Мансуровның сәүдә-сәнәгать ширкәте» оештырыла. Ул нигездә авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү белән шөгыльләнә. Аның 2 пар тегермәне һәм башка предприятиеләре була. 1912 елда төзелгән «Алим Агишевның сәүдә-сәнәгать ширкәте» 1915 елда үзенең төп капиталын ике тапкыр арттыра һәм аны 800 мең сумга җиткерә. Бу ширкәтнең Сембер, Саратов, Пенза губерналарында предприятиеләре эшли. Х. Х. Хәсәнов мәгълүматларына караганда, төп капиталлары 4 530 мең сум булган сәүдә-сәнәгать ширкәтләре ел саен 10 миллион сумнан артыграк товар җитештерә. Ул предприятиеләрдә 6,5 мең кеше эшли, һәм аларның күпчелеген татарлар тәшкил итә.

Акционерлар предприятиеләре белән беррәттән, акционерларныкы булмаган предприятиеләр дә эшли. 1914 елгы рәсми мәгълүматларга караганда, татар эшмәкәрләренең заман техникасы белән җиһазландырылган 141 сәнәгать предприятиесе була. «Россия империясенең фабрика-завод предприятиеләре» дигән китапта китерелгән мәгълүматлар буенча, аларның 110 ында 12 мең чамасы кеше эшләгән. Идел-Урал төбәгеннән башка татар эшмәкәрләренең Төркестанда (19 предприятие), Казакъстанда (18 предприятие), Кавказда (6 предприятие) үз предприятиеләре була. Төркестанда, мәсәлән, С. А. Мөхәммәтҗановның, К. С. Сабировның мамык чистарту заводлары эшли.

Бөтен Россиядәге кебек үк, бу предприятиеләрдә дә эшчеләрнең хәле бик авыр була. Эшчеләр турындагы дәүләт законнары Көнбатыш Европа илләрендәгедән артта кала. 1897 елның 2 июнендә кабул ителгән закон нигезендә эш көненең озынлыгы 11,5 сәгать итеп билгеләнә, шулай ук бәйрәм көннәре тәгаенләнә, якшәмбе атналык ял көне итеп карала. Эшчеләрне социаль яклау чаралары ул вакытта әле күздә тотылмый. Татар эшмәкәрләренең предприятиеләрендә эшләүче татар эшчеләре үзләрен аз гына иркенрәк хис итәләр, чөнки алар анда үзара туган телләрендә аңлашалар, җомга көннәрендә ял итәләр, ислам бәйрәмнәрен бергәләп үткәрәләр. Ләкин барлык татар эшчеләре дә мондый предприятиеләрдә эшли алмый. Аларның бер өлеше дәүләт предприятиеләренә һәм рус капиталистларына яллана, рус эшчеләре коллективларында эшли. Алар, нигездә, ярдәмче эшләрне генә башкаралар, әмма эшчеләр турындагы законнарның бөтенләй булмавыннан яисә камил түгеллегеннән рус эшчеләре белән бер үк дәрәҗәдә интегәләр. Шуның өстенә тагын рус телен начар белүләре, русларча яшәү рәвешенә күнегергә, әйтик, җомгада түгел, якшәмбедә ял итәргә мәҗбүр булулары һ. б. аркасында да уңайсызлык кичерәләр. Шуңа да карамастан, гомумән алганда, татар эшчеләре рус эшчеләре коллективларына җиңел ияләшәләр.

Татар эшчеләренең зур өлеше Россия эре сәнәгать үзәкләрендә — Мәскәү, Санкт-Петербург, Донбасс, шулай ук Себер, Казакъстан, Төркестан һәм Кавказда эш эзләргә мәҗбүр була. Кайбер мәгълүматларга караганда, Донбасста 100 меңгә якын татар эшчесе эшли. Ерак районнарга эшкә, гадәттә, кыю һәм инициативалы кешеләр киткән. Андыйлар эштә тырышлык-

лары, пөхтәлекләре белән аерылып торган. Яңа җирдә алар еш кына колонияләр булып (бер поселокта, бер урамда һ. б.) яшәгәннәр, үзләренең милли-мәдәни оешмаларын булдырганнар, хәтта мәчетләр дә төзегәннәр. Тарихи ватаннары белән дә багланышларын өзмәгәннәр, әледән-әле туган якларына кайтып йөргәннәр.

Сәүдә эшмәкәрлегә эреләнү. 1914 елда татар сәүдәгәр акционерларыныкы булган сәүдә йортларының саны 154 кә җиткән. Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сәүдә бүлеге мәгълүматларына караганда, теркәлгән сәүдә йортларының 18 е бер үк вакытта сәнәгать җитештерүе белән шөгыльләнгән. Алар арасында Троицкида һәм Оренбургта мамык чистарту заводлары, пар тегермәннәре булган «Бертуган Яушевлар» сәүдә йорты, 1908 елда Семипалатинскида (Казакъстан) нигез салынган, 400 мең сумлык устав капиталы булган «Садыйк Мусин варислары» сәүдә йорты, 1913 елда теркәлгән «Ф. Халитов һәм К°» сәүдә йорты була.

136 сәүдә йорты бары тик сәүдә белән генә шөгыльләнә. Россиянең үзәк районнарында «Х. Х. Галиев һәм К°» (Казан), «Бертуган Хәлфиннәр» (Минзәлә), «Гайфулла Усманов һәм К°», «Усмановлар һәм К°», «Бертуган Мортазиннар», «Зариф Хәбибуллин уллары белән һәм К°», «Бертуган Нигъмәтуллиннар», «Кәримов, Хөсәенов һәм К°», «Бертуган Шәмсетдиновлар» сәүдә йортлары уңышлы эшләгән. Россия дәүләт чикләрендәге базарларда сәүдә белән «Бертуган Габделҗаббаровлар» (Казакъстан һәм Кыргызстан) «Тимергали, Мөхәммәтҗан һәм Якуб Хөсәеновлар» (Семипалатинск, Җидесу өлкәләре, Кытай белән чиктәш районнар), «Бертуган Маннаповлар» (Себер) сәүдә йортлары эш алып барган. Алар мех, аяк киемнәре, хайван, ашлык, күн эшләнмәләр, канцелярия товарлары, китап, җиләк-җимеш һ. б. белән сату иткәннәр. Татар сәнәгатьчеләре һәм сәүдәгәрләренең кредитка мохтаҗлыгын Россия банклары канәгатьләндергән. XIX гасыр азагында ук татар капиталистлары С. М. Аитов, С. С. Галикәев 1873 елда Казан сәүдәгәр банкы тарафыннан төзелгән совет әгъзалары булып китәләр. 1912 елда Санкт-Петербургта, нигездә, татар эшмәкәрләренә хезмәт күрсәтүче Мөселман банкы оештырыла. Россия-Азия банкының Казан һәм башка шәһәрләрдәге бүлекчәләре дә шул ук вазифаны башкара.

Аграр мәсьәләнең кискенләшүе. Татар крестьян хуҗалыклары хакимият органнарының икътисади чикләүләрен дә

кичерәләр. «1861 ел Нигезләмәсе» буенча Казан губернасында рус крепостной крестьяннары, азат ителгән вакытта, ревизия үткән һәр җан башына (на ревизскую душу) уртача 3—4 дисәтинә җир алалар. Рус дәүләт крестьяннарына җан башына бирелгән җир мәйданы уртача 5,23 дисәтинә тәшкил итә. Ә 8389 татар крестьянының иманасы ревизия үткән һәр җан башына 1 дисәтинә генә була. Шунысы да бар: авыл крестьяннары саны ревизия үткәрелгән вакыттагыга караганда кайчак 20 процентка кадәр диярлек күбрәк була. Вятка губернасында татар крестьяннары юридик яктан дәүләт крестьяннары разрядына керә. Шуңа да карамастан, алар җир белән рус крестьяннарына караганда кимрәк тәэмин ителә. Өстәвенә аларның җире начар сыйфатлы була. 1889—1892 елларда «контрреформалар» башлану белән хакимиятнең крестьяннарга басымы тагын да көчәя. 1889 елда чыгарылган Нигезләмә буенча татар крестьяннарының язмышы тулысынча рус дворяннары арасыннан билгеләп куелган земство башлыгы кулында була.

Яңа башланган XX гасыр да крестьяннарга җиңеллек алып килми. Столыпин реформалары барышында (1906—1915) Казан губернасында 5300 татар крестьян хуҗалыгы общинадан бүленеп чыга һәм бүленгәндә алган җир мәйданын үзенең хосусый милке итеп законлаштыра. Ләкин бу, 1861 елда булган кебек, мәсьәләне хәл итә алмый. Бу барыбер татар крестьяннары кулындагы болай да аз күләмле җирне яңадан бүлгәләү генә булып чыга. Җир фондының шактый зур өлеше, элеккечә, рус алпавытлары һәм монастырьлар кулында кала. Өстәвенә татар крестьяннарының нибары 2,5 проценты гына общинадан бүленеп чыга. Православие динендәге татар (керәшен) крестьяннары Казан губернасында һәм башка губерналарда җир белән, гомумән алганда, шулай ук начар тәэмин ителә, өстенлекләрдән файдаланмый. Димәк, Татарстанда аграр мәсьәлә хәл ителмәгән килеш кала бирә. Шуңа да карамастан, XX гасыр башында татар авылы базар мөнәсәбәтләре юнәлешендә кыю адымнар ясый.

Милли әдәбият. XX гасырның беренче ике унъеллыгындагы милли мәдәният татар җәмгыятенең милли-мәдәни тергезелүенең иң югары ноктасын чагылдыра һәм шул ук вакытта милли азатлыкның алхәбәрчесе дә була. Милли мәдәниятнең бу миссиясе, беренче булып татар әдәбиятында, И. З. Нуруллин сүзләре белән әйткәндә, аның яңа дәрәҗәдә кабатланган «алтын чорында» чагылыш таба. Бу чордагы

татар язучылары мәгърифәтчелекнең яңарыш, тергезелү дип аталган җимешләрендә тәрбияләнеп, танылган гуманистлар, фидакарь мәгърифәтчеләргә үсеп әвереләләр. Бер үк вакытта алар «милли азатлык» дип аталган бөек идеалларның сөрән салучылары да булалар. Татар әдәбиятын Габдулла Тукай (1886—1913), Гаяз Исхакый (1878—1954), Галимҗан Ибраһимов (1887—1938), Фатих Әмирхан (1886—1926), Галиәсгар Камал (1879—1933), Мәҗит Гафури (1880—1934) кебек әнә шундый данлы исемнәр бизи. Дистәләрчә роман, повестьлар, йөзләрчә пьеса иҗат ителә. Алар арасында «Шүрәле», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Безнең көннәр», «Фәтхулла хәзрәт», «Хәят», «Беренче театр», «Банкрот», «Акчарлаклар», «Яшь йөрәкләр», «Галиябану» һәм башкалар кебек мәдәниятебез җәүһәрләре бар.

Санап үтелгән язучылар милли бердәмлекнең иң югары казанышы булган милли әдәби телне назлап-кадерләп үстерәләр. Габдулла Тукай, бу телне мактап, «Туган тел» шигырендә:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы,—

дип яза.

Бу — туган телне мактау гына түгел, аның хакында зур кайгырту да. Татар язучылары телне гарәп, фарсы алынмалары кертеп чуарламаска һәм шул ук вакытта аны чистарту белән дә шөгыльләнмәскә чакыралар. «Милли әдәби тел,— дип яза Гаяз Исхакый,— ул бөтен байлыгы белән безнең үз телебез, ул телдә без үзара аралашабыз: аны аңлыйбыз, ул телдә укыйбыз һәм язабыз». Татар язучылары һәм шагыйрьләре милләт өчен кыен булган чорларда (ә татарлар өчен XX йөзнең башлары нәкъ шундый чор) милли әдәбият алдында нинди социаль бурычлар торуын яхшы аңлыйлар. 1905 елда, 17 октябрь Манифесты чыкканнан соң, Габдулла Тукай дусларына:

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр,—

дип мөрәҗәгать итә.

Күп кенә татар шагыйрьләре һәм язучылары тарафыннан аерым шәхес, аерым гаилә кысаларында да гомумтатар, гомумроссия күләмендә милли азатлыкка ирешүнең социаль проблемалары куела.

Татар язучылары һәм шагыйрьләре әдәби тәрҗемә осталары буларак та танылалар. XIX гасыр традицияләрен дәвам итеп, алар рус язучылары һәм шагыйрьләренең (А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, И. С. Тургенев, М. Горький, А. П. Чехов), шулай ук чит ил авторларының (Гете, Гейне, Гюго, Шекспир, Байрон һәм башкалар) әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итәләр.

Тагын икенче бер нәрсә дә: кешеләрнең социаль проблемалар белән кызыксынулары да көчәя. Укучылар саны ишәя, китапка ихтыяҗ арта. Китап чыгару эше киңәя. 1901 елда Галиәсгар Камалның «Мәгариф» китап нәшрияты, ә соңрак «Сабак» китап нәшрияты оеша. Бер Татарстанда гына түгел, Мәскәү, Омск, Томск, Соль-Илецк, Троицк, Чиләбе, Ташкент һәм Семипалатинскида махсус татар китабы кибетләре ачыла.

Милли театр. Татарларның профессиональ театрын булдыру турындагы күптәнге хыял, ниһаять, тормышка аша. 1906 елның 22 декабрендә Казанда татар телендә беренче мәртәбә ачык спектакль куела. Бу көн татар профессиональ театры туу көне булып мәдәният тарихында урын ала. 1907 елда беренче татар профессиональ труппасы «Сәйяр» оештырыла. Аның составына талантлы артистлар И. Б. Кудашев (Ашказарский), В. Мортазин (Иманский), Н. Сакаев һ. б. керә. Труппаны танылган артист һәм режиссер Габдулла Кариев җитәкли. 1912 елда Уфада мәшһүр артист С. Гыйззәтуллина (Волжская) җитәкчелегендә «Нур» дигән татар театр труппасы оештырыла. Аның составында танылган артистлар С. Г.-Волжская, Ш. Шамильский, Г. Казанский, Ф. Латыйпов, Б. Тархановлар уйный. 1915 елда Оренбургта да «Ширкәт» исеме астында профессиональ театр труппасы оеша. Бу театр сәхнәсендә М. Мутин, Г. Мангушев, З. Камская, Ф. Ильская, Камал I кебек артистлар дан казана.

Театрларда татар драматурглары пьесалары куела. Мирхәйдәр Фәйзинең (1891—1928) «Галиябану» драмасы буенча куелган спектакль аеруча зур популярлык казана. Татар сәхнәсендә рус (Н. Гогольнең «Ревизор»ы һ. б.) һәм чит ил (Шекспирның «Мәкер һәм мәхәббәт»е һ. б.) авторларының пьесалары татарчага тәрҗемә ителеп күрсәтелә. Труппалар еш кына гастрольләргә чыгып китә. «Сәйяр» труппасының Идел һәм Урал буе, шулай ук Себер, Кырым, Казакъстан, Төркестан шәһәрләрендәге гастрольләре аеруча зур уңыш белән бара. Санкт-Петербург, Мәскәү, Пермь, Сембердә үзешчән театр труппалары эшли башлый. Әстерхандагы үзешчән труппа

З. Солтанов, Җ. Байкин, С. Байкина кебек күренекле артистларны үстерә.

Милли музыка уен коралларында профессиональ башкару сәнгате аваз сала. 1914 елда талантлы композитор Заһидулла Яруллин (танылган композиторлар Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарның әтисе) Казанда «Шәрык» клубы каршында татар кыллы инструментлар оркестры оештыра. Шул оркестр башкаруы өчен ул мәшһүр «Тукай маршы»н яза. Мәшһүр талантлы музыкаль башкаручылар үсеп чыга (гармунчы Фәйзулла Туишев, скрипкачы Г. Зайкин, җырчылар К. Мотыйгый, Ф. Гомәров). 1916 елда халык көйләрен җыючы талант иясе Мансур Солтанов төзегән «Татар һәм башкорт көйләре» җыентыгы басылып чыга.

Милли мәгариф системасы. XX йөз башларында милли мәгариф системасын яңарту дәвам итә. Хөкүмәт бөтен Казан губернасының мәгариф ихтыяҗлары өчен җан башына елына 12,5 тиен акча бүлеп бирә. 2,5 миллион халкы булган губернада гомуми белем бирү мәктәпләрендә нибары 114 мең бала белем ала. Казна хисабына тотылган бу уку йортларының бары тик 35 е генә татар мәктәпләре була. Ә калган татар мәктәпләре (ә алар Казан губернасында 1067 була һәм аларда 84 мең бала укый) татар эшмәкәрләренең хәйрия фонды хисабына тотыла. Татар мәктәпләре ачуга рөхсәтне алар 1905 елда чыгарылган хөкүмәт карары нигезендә алуга ирешәләр. Ә мәчетләр каршындагы мәктәпләрдә күп кенә имам һәм аларның хатыннары бөтенләй түләүсез яисә бик аз түләү хисабына гына эшлиләр. Авыллардагы дөньяви мәктәпләрнең күпчелегендәге укытучылар да әнә шундый фидакарь энтузиастлар була. 1906 елда Казанда укытучымөгаллимнәрнең беренче съезды була. Биредә милли белем бирү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләнә һәм кабул ителә. Бу тәкъдимнәр «Мөгаллимнәргә нәмунә» дигән документта бәян ителә. Казанда татар укытучылары берлеге оештырыла. Казан, Оренбург, Уфа, Чита һәм башка шәһәрләрдә һөнәри белем бирү буенча милли мәктәпләр, шул исәптән сәүдә-сәнәгать мәктәпләре ачыла. Пермьдә татар мәгърифәтчелек-техник җәмгыяте каршында татар һөнәр училищесы, Сембердә татар хатын-кызлары мәктәбе эшли башлый.

Фән. XX гасыр башларында татар галимнәре үзләренең фәнни тикшеренүләрен дәвам итәләр. Һ. М. Атласов, мәсәлән,

фән дөньясының күренекле вәкиленә әверелә. Академик В. В. Бартольд аны «татар патриоты» дип атый. Һ. М. Атласов (Һади Атласи, 1876—1938) Чүпрәле районында дөньяга килә, Буа мәдрәсәсендә белем ала, аннары Оренбургта Гани бай Хөсәенов тарафыннан нигезләнгән татар укытучылар семинариясен тәмамлый. Рус, немец, гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белә. Гасыр башында аның беренче гыйльми хезмәтләре «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне»), «Тарихе табигать» («Табигать белеме тарихы») дөнья күрә. 1907 елда ул Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлана. Үзенең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген Татарстан тарихы буенча тикшеренүләре белән бергә алып бара. 1911—1914 елларда аның «Себер тарихы», «Казан ханлыгы», «Сөембикә» дигән хезмәтләре басылып чыга.

1909—1910 елларда матбугатта атаклы татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Коләхмәтовның «Тарих сәхифәләре» дигән гомуми баш астында бик борынгы тарихка багышланган тикшеренүләр сериясе басылып чыга. Аның вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән, күп кенә Көнбатыш илләренең конституцион строе асылы аңлатылган, Бөекбритания, Германиянең конституцияләрен анализлаган популяр мәкаләләре танылу таба.

Педагог, философ, журналист Һади Максуди (1868—1941, танылган татар җәмәгать эшлеклесе Садри Максудиның абыйсы) — философия фәне вәкиле. 1902 елда Санкт-Петербургта аның «Мизанел әфкар» («Фикерләү философиясе») дигән китабы басылып чыга. Аның «Шәрык философиясенең квинтэссенциясе. Шәрык мантыйгы» дигән хезмәте бастырып чыгарылмыйча кала. Һади Максуди тирән белемле кеше була. Рус, немец, француз, гарәп телләрен яхшы белә, татарча-русча сүзлек төзи, «Уку китабы» бастырып чыгара, татар китаплары китапханәсен оештыра. Күп кенә татар зыялылары аны үзләренең остазлары итеп саныйлар. Ул мөгаллимлек иткән мәдрәсәдә Гаяз Исхакый укый.

Вакытлы матбугат. Татар милли вакытлы матбугаты гражданлык мәгърифәтенең төп трибунасы була. Бик күп тапкыр катгый мөрәҗәгать итүләрдән соң 1905 елның августында хакимият органнары Санкт-Петербургның танылган ислам эшлеклесе Гатаулла Баязитовка Санкт-Петербургта татар телендә «Нур» исемле газета чыгарырга рөхсәт бирә. Аның беренче номеры 1905 елның 2 сентябрендә дөнья күрә. 1905 елның 17 октябрь Манифесты чыгарылганнан соң,

Матбугат турында вакытлы кагыйдәләр игълан ителә. Алар басма органнарны оештыру эшләрен бераз җиңеләйтеп җибәрә. Татар зыялыларында җыелып килгән эш инициативасы шунда ук конкрет гамәлгә әверелә. 1905 ел азагына кадәр тагын өч татар газетасы чыга башлый: Казанда — «Казан мөхбире» (редакторы — С. Г. Алкин), Санкт-Петербургта — «Өлфәт» («Бердәмлек», редакторы — Р. Ибраһимов), Уральскида — «Фикер» (редакторы — Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин).

1906 елдан татар телендә журналлар чыга башлый. Беренче әдәби-сәяси журнал «Әлгасрел-җәдид» («Яңа тормыш») Уральскида дөнья күрә. Алга таба аңа «Шура», «Яшен», «Икътисад», «Аң», «Сөембикә», «Ак юл» кебек мәшһүрлек яулаган басмалар килеп кушыла. Тулы булмаган мәгълүматларга караганда, 1905—1917 елларда 120 гә якын татар газетасы һәм журналлары оештырыла. Алар Уфа, Әстерхан, Самара, Сембер, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Минзәлә, Оренбург, Саратов, Томск, Семипалатинск, Уральск, Троицк, Петропавловск (Казакъстан), Ташкент, Коканд һәм кайбер башка шәһәрләрдә чыгарыла.

Бу басмалар татар җәмгыятенең барлык катлауларына хезмәт күрсәтүгә исәп тота. Журналлар арасында әдәби, иҗтимагый-сәяси, фәнни-популяр, сатирик басмалар бар. Балалар өчен «Тәрбияи этфаль» («Балалар тәрбиясе»), хатын-кызлар өчен «Сөембикә» кебек махсус журналлар чыгарыла. Ислам диненә, этикасына, ислам дөньясына багышланган «Әл-галәм әл-ислам» («Ислам дөньясы»), «Әд-дин вә әл-әдәп» («Дин һәм әдәп») дигән басмалар журналлар арасында мөһим урын тота. Аларның сәяси юнәлешләрен шартлы рәвештә милли-либераль, милли-радикаль, ислами-либераль дип билгеләргә мөмкин. Шул ук вакытта аларның барысына да татар халкының милли хокукларын рәхимсез рәвештә кысучы милли җәберләү сәясәтен дәвам иттерүче самодержавие монархиясе режимына карата оппозициядә тору хас. Милли берләшү һәм милли тормышның барлык сфераларын яңарту, шул исәптән Россиядәге тормышны яңарту — бу басмаларның лейтмотивы әнә шулардан гыйбарәт. Беренче татар газетасының «Нур» дип аталуы да тикмәгә түгелдер. «Азатлык» һәм «яңарту» төшенчәләре бу елларда чыккан барлык басмаларның эчтәлеген тәшкил итә. Бу күп кенә газета һәм журналларның исемнәрендә дә чагылыш таба: «Азат», «Әл-ислах» («Реформа»), «Яңа тормыш» һ. б. Вакытлы матбугатта авторлар сыйфатында

татар җәмгыятенең барлык катлау вәкилләре катнаша. Бу басмаларны татар шагыйрьләре һәм язучылары, сәясәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре, галимнәр үз гакыллары белән генә түгел, ә чын мәгънәсендә үз куллары белән дә иҗат итәләр.

Татарстанның вакытлы матбугаты татар җәмгыятенә үзара фикер алышу өчен шактый киң мөмкинлек тәэмин иткән демократик трибунага әверелә. Бу фикер алышу барышында Россиядә якынлашып килүче революциядә милли азатлыкны үзмаксат итәчәк милли идея эшләнә. Татарларның вакытлы матбугаты бу идеяне гамәлгә ашырырга чакырылган милли хәрәкәтнең ныгуына булышлык итә.

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ХӘРӘКӘТ

Татар җәмгыятендә сәяси хәл. Икътисади ныгуына һәм мәдәни яктан үсүенә карамастан, татар җәмгыяте әле һаман Россия империясенең сәяси хокуксыз милләтләре арасында калып килә. 1905 елгы революция Николай II не әтисеннән мирас итеп алган «контрреформалар» сәясәтеннән баш тартырга мәҗбүр итә. «Патша самодержавиесе» төшенчәсе «патша монархиясе» төшенчәсе белән алмаштырыла. Самодержавие монархы каршында Дума барлыкка килә. Ләкин татар җәмгыятенең сәяси хәле үзгәрми. Революция вакытында бераз гына йомшара төшкән самодержавие моннан соң башланган реакция елларында янәдән һөҗүмгә күчә. 1910 елда Министрлар Советы Рәисе П. А. Столыпин, документта күрсәтелгәнчә, «Идел буе краенда татар-мөселман йогынтысына каршы тору өчен» чаралар эшләү буенча махсус киңәшмә җыя. Хакимиятне бигрәк тә татарларның дини-милли тупланганлыгы борчый. Бу документта шулай ук, татарлар «рус дәүләт тормышының гасырлардан килгән нигезләрен генә түгел, сәяси һәм мәдәни көчләрнең инде ныклап урнашкан кебек булган нисбәтен какшатучы милли-мәдәни эшне» нык торып алып баралар, дип әйтелә. Хөкүмәткә татар-ислам оппозициясенең «астыртын» казынуларына каршы чаралар күрергә тәкъдим ителә. Шовинистик матбугатта татар милли хәрәкәтен, янәсе, православиегә һәм рус халкына куркыныч тудыра торган панисламизмда һәм пантюркизмда гаепләүче «фаш итү» кампаниясе җәелдерелә. Бер үк вакытта хөкүмәт алда торган сугышка бәйле рәвештә Төркиягә каршы кампанияләр өчен нигез әзерли.

Әлеге кампаниянең беренче ударлары милли хәрәкәттә катнашучы иҗтимагый яктан иң актив ислам эшлеклеләренә каршы юнәлдерелә. Жандармнар «күренекле панисламистларның» исемлеген төзиләр. Алдан уйланылган ялган әләк буенча 1911 елның башында Иж-Буби мәдрәсәсе туздырыла. Мәдрәсә җитәкчеләре һәм мөдәррисләре кулга алына. Шул ук вакытта Казанда Галимҗан Барудиның һәм Печән базарындагы мәчет имамы Габдулла Апанаевның өйләрендә тентү үткәрелә. Жандармерия идарәсе, Баруди һәм Апанаев, Һади Максуди белән берлектә, янәсе, Татарстанны Россиядән аеру максатында сәяси партия оештырганнар, дигән әләккә таяна.

Шул вакытта ук Столыпин хөкүмәте гарәп графикасындагы татар алфавитын кириллицага алмаштыру планнары белән йөри. Бу вакытта кириллица инде православие динендәге татарлар (керәшеннәр) арасына кергән була. Бу эшкә каршы чыккан татар зыялылары репрессиягә эләгә. Шул исәптән Һади Атласи да кулга алына. Хакимият органнары татар милли хәрәкәтен русларга һәм православие диненә каршы юнәлдерелгән хәрәкәт итеп күрсәтергә тырыша. Милли хәрәкәтнең азатлык хәрәкәте характерында булуы турында ул вакытта бу хәрәкәтнең күп кенә вәкилләре язып чыга. Алар татарларның руслар белән бергәләп тормыш итүләренең иң яхшы традицияләренә тугрылыклы булуларын басым ясап әйтәләр. Тукайның «Китмибез!» дигән катгый сүзләре шовинистлар матбугатында басылып чыккан «Рәсәй тәртипләре ошамаса, солтан җиренә китегез» кебек белдерүләргә җавап була. Татар милли хәрәкәтенә, чыннан да, Россиядәге самодержавиенең милли изүгә корылган тәртибе ошамый. Ләкин бу тәртипләрне хәзер инде рус җәмгыяте, рус халкы да кабул итә алмый. Самодержавиегә каршы булган татар милли хәрәкәте һич русларга каршы хәрәкәт булмый.

Милләтне азат итүгә юнәлдерелгән гомуми стратегик линиясе булган татар милли хәрәкәте XX гасыр башында милли-либераль хәрәкәт буларак формалаша.

Милли-либераль хәрәкәтнең формалашуы. Бу хәрәкәтне формалаштыруның инициаторлары татар эшмәкәрләренең, милли зыялыларның социаль-сәяси планда иң актив вәкилләреннән, ислам әһелләре даирәсеннән үсеп чыккан либераль көчләрдән гыйбарәт була. Алар арасында галим-теологлар, ислам тарихы, ислам әдәбе (этикасы) һәм ислам хокукы буенча хезмәтләр авторлары Ризаэддин Фәхреддин

(1859—1936), Муса Бигиев (1873—1949), Казандагы иң зур мәдрәсәләрнең берсе «Мөхәммәдия» мөдәррисе Галимҗан Баруди (1857—1922), Иж-Буби мәдрәсәсе мөдәррисе Габдулла Буби (1871—1922), ислам теологы, социолог һәм журналист Рәшит Ибраһимовлар (1852—1944) бар. Теолог-галимнәр һәм мәдрәсә мөдәррисләре буларак, алар XIX гасыр азагында ук инде татар исламын яңарту, аны искергән догмалардан арындыру идеяләре белән чыгалар. Муса Бигиевнең «Мөселман хокукы теорияләре», «Шәригать нигезләре» дигән хезмәтләре зур абруй казана. Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» («Эзләр») фәнни-библиографик энциклопедиясе үз укучысын таба. Галимҗан Баруди үз мәдрәсәсендә уку-укыту процессын яңарта. XX гасыр башларында бу мәдрәсәдә 500 дән артык шәкерт укый. Анда ислам теориясе генә түгел, үз заманы дәрәҗәсендәге дөньяви предметлар да укытыла. Анда Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, шулай ук милли мәдәният һәм иҗтимагый хәрәкәтнең башка танылган эшлеклеләре укый. Бер мәдрәсә өчен генә түгел, мәктәпләр өчен дә дәреслекләр әзерләнә. Галимҗан Баруди татарча-гарәпчә-фарсыча сүзлек төзи һәм мәктәпләр өчен «Сәвадхан» («Уку китабы») яза.

Либераль хәрәкәтне башлап җибәрүчеләр арасында эшмәкәр Х. Хөсәенов, тарихчы, журналист Йосыф Акчура (1876—1935), юрист, сәясәтче Садри Максуди (1879—1957), галим, философ Һади Максуди, адвокат, журналист С. Г. Галкин аерылып торалар. Алар үз игътибарларын Россиядә конституцион-парламентлы монархия кертү лозунгы астында чыгыш ясаучы «Союз освобождения» дигән сәяси хәрәкәткә юнәлтәләр һәм конституцион монархия режимында милли-азатлык хәрәкәте өчен шартлар уңайлырак булыр, дип уйлап, шуларны яклыйлар.

Татарларда беренче сәяси партия. 17 октябрь Манифесты игълан ителгәнче, 1905 елның гыйнварында Казанда конспиратив шартларда үткән киңәшмәдә либераль-конституцион юнәлештәге татар сәяси партиясен оештыруга хәзерлек турында карар кабул ителә. Партиянең платформасына милли һәм дини чикләүләрне бетерү, гражданлык хокукларын Россиядәге татар халкына да бирү турындагы таләп куелырга тиеш була. 1905 елның августында Түбән Новгородта, конспиратив шартларда (күңел ачу пароходында), татар милли хәрәкәте әһелләренең съезды җыела. Съезд «мөселманнарны

барлык сәяси, гражданлык һәм дини хокукларда бөтен рус дәүләте халкы белән тулысынча тигезләү» платформасын кабул итә.

17 октябрь Манифесты кабул ителгәннән соң, 1906 елның гыйнварында Санкт-Петербургта татар милли либералларының II съезды җыела. Съезд партиянең оештырылу структурасын билгели. Партияне «Иттифак әл-мөслимин» дип атарга һәм бөтен Россия мөселманнарының (татарларының) партиясе итәргә карар кылына. Съездда Кырым һәм Кавказ вәкилләре — ул чакта бөтен төркиләр дөньясында билгеле булган «Тәрҗеман» газетасы редакторы Исмәгыйль Гаспралы, Азәрбайҗан юристы, «Каспий» һәм «Хәят» («Тормыш») газеталары редакторы Г. Топчибашев һәм башкалар катнаша. Партиягә татарлардан тыш Россиядәге башка мөселман халыклары вәкилләре дә керә ала дип күздә тотыла. Съездда кабул ителгән устав нигезендә партия 16 район оешмасыннан тора (Санкт-Петербург, Казан, Әстерхан, Уфа, Оренбург, Уральск, Минск, Иркутск, Омск, Семипалатинск, Ташкент, Ашхабад, Верный (Алматы), Баку, Симферополь оешмалары).

1906 елның августында партиянең өченче съездында аның программасы төсендә белдерелгән идеологик максатлары һәм сәяси платформасы билгеләнә. Рус либералларының Россиядә конституцион монархияле дәүләт строе урнаштыруга юнәлдерелгән линияләрен яклап, съезд татар милли хәрәкәте таләпләрен формалаштыра. Аграр мәсьәлә буенча «Иттифак» татар крестьяннарының җирләрен алпавыт һәм монастырь җирләре хисабына киңәйтүгә һәм бу иманаларны аларның хосусый милке итеп беркетүгә ирешергә омтыла. Эшчеләр мәсьәләсе буенча аларның төп таләпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: профсоюзлар эшчәнлегенә ирек бирү, 8 сәгатьле эш көне кертү, мәҗбүри страхование. Алар арасында җыелышлар үткәрү иреге, берлекләр (союзлар), җәмгыятьләр, учреждениеләр оештыру иреге; дәүләтнең үзәк оешмаларында, армиядә, флотта дәүләт телен куллану һәм урыннарда күпчелекне тәшкил иткән халыкның телен иркле рәвештә куллануны билгеләү; җирле үзидарәгә күчү; конфессияләрнең (диннәрнең) тигез хокуклылыгы кебек мөһим таләпләр дә бар.

Съездда милли мәктәп турындагы мәсьәлә аеруча игътибар белән карала. Белем бирүнең бердәм системасын булдыру максатка ярашлы дип табыла, мәчетләр каршындагы барлык мәктәпләрне җәмгыять кулына тапшырырга, барлык мәктәп-

ләрне дәүләт һәм җирле үзидарәләр хисабына тотарга тәкъдим ителә. Гомуми башлангыч белем бирү, урта мәктәп программаларына мәҗбүри дисциплина итеп рус телен өйрәнүне кертү мәсьәләсе хәл ителә.

Съездда турыдан-туры ислам оешмаларына кагыла торган мәсьәләләр каралмый. Мөселман оешмаларының үзләрендә бу уңайдан ике төрле фикер булуы ачыклана. Санкт-Петербург ахуны Гатаулла Баязитов тарафдарлары хөкүмәт контроле астында эшли торган, бөтен Россиягә бер булган мөфтият булдыруны яклап чыгалар. Күпмедер вакыттан соң әлеге Баязитов үзе үк мөфти булып китә. Г. Баруди исә бу органны демократияләштерергә, Россиядә биш мөфтият (Оренбургта, Таврида (Кырым), Төркестанда һәм Кавказда: монда икәү) булдырырга һәм аларның эшчәнлеген урыннардагы милли шартларга яраклаштырырга тәкъдим итә.

«Иттифак әл-мөслимин» партиясенең милли-либераль программасы милли хәрәкәтнең либераль этабында аның нигезен тәшкил итә. Бу программа татарларның вакытлы матбугаты битләрендә киң тикшерелә. Аның конституцион-парламентлы монархия шартларында татар милләтенең гражданлык ирекләренә һәм милли-мәдәни мохтарияткә ирешүе турындагы төп положениеләрен Һ. Максудиның «Йолдыз» газетасы, Р. Ибраһимовның «Миръат» («Көзге») журналы, С. Г. Алкинның «Казан мөхбире» («Казан хәбәрләре») журналы һәм башка басмалар яклап чыга.

Россия Дәүләт Думасында татар оппозициясе. 1906 елгы 1 нче чакырылыш Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында Россия җәмгыятендә конституцион монархия идеясе позицияләре шактый нык була. Кадетлар, Думада 179 мандат алып, беренче урынга чыга. Бер үк вакытта 107 мандат алган крестьян депутатларының да Думада позицияләре нык була. Алар җирне крестьяннарга «хезмәт нормасы» принцибыннан чыгып бүлеп бирүне таләп итәләр һәм хөкүмәткә карата кадетлардан ныграк оппозициядә торалар. Думада кадет-крестьяннар оппозициясенең җиңүендә татар милли хәрәкәте дә зур роль уйный. Дөрес, татар депутатлары үзләре, гомуми мөселман фракциясе составында калган хәлдә, аерым төркем булып оешырга өлгермәгән булалар.

1906 елның июлендә I Думаны таркатып, патша хөкүмәте кадетлар партиясенә көчле удар ясый. 2 нче чакырылыш Думада, кадетлар үзләренең союзниклары белән берлектә

99 мандат алып, беренчелекне 104 мандаты булган трудовикларга бирәләр. Бу конституцион монархия идеясенең «уңа» башлавын күрсәтә. Аның каравы, крестьяннарның сулгарак авышуы дәвам итә. Кадетларның дәрәҗәсе төшү һәм крестьяннарның суллаша баруы шулай ук татар милли хәрәкәте тактикасында да чагылмый кала алмый. Думага татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләре Йосыф Акчура, Садри Максуди, Һади Атласи һәм башкалар сайлана. Татар оппозициясе үзенең ориентациясен үзгәртә, кадетларга йөз тотудан туктап, хезмәтчел крестьяннар фракциясенә таба борыла. Кәлимулла Хәсәнов җитәкчелегендәге алты татар депутаты «Мөселман хезмәт таифәсе» («Мөселман хезмәт төркеме») исеме астында трудовикларга кушылалар һәм җир мәсьәләсе буенча «104 проекты»н яклап чыгалар.

Россиянең реакция юлына басуы. 1907 елның 2 июнендә Николай II 1905 елгы революция аңардан тартып алган ташламаларны нигездә юкка чыгара торган яңа Манифест игълан итә. Манифест нигезендә 2 нче чакырылыш Дума таркатыла. Бу акт тарихка 3 июнь перевороты буларак керә.

Патша үзенең бу адымын, янәсе, «Дәүләт Думасының бер өлешенең дәүләткә һәм патша хакимиятенә каршы заговоры ачылды», дип аңлата. Яңа сайлауларны 1907 елның 1 ноябренә билгеләп, ул, Россиянең Төп Законы (1906 елның 23 апрелендә кабул ителгән Закон күз алдында тотыла) һичсүзсез үтәлергә тиеш, дип кисәтә. Сүз, барыннан да элек, Югары самодержавие хакимиятенең асылы турында бара. Законның 4 нче статьясында, бөтен дәүләт чикләрендә идарә итү хакимияте бөтен тулылыгы белән Россия императоры кулында, дип, Дума тарафыннан кабул ителгән һәм Дәүләт Советы тарафыннан яклау тапкан законнар бары тик император раслагач кына көчләренә керәләр, дип күрсәтелә. Бер үк вакытта Николай II, рус булмаган халыклар элеккечә «икенче разрядлы гражданнар» булып калалар, дип кабат искә төшерә. Манифестта болай диелә: «Россия дәүләтен ныгыту өчен төзелгән Дәүләт Думасы рухы белән дә рус Думасы булырга тиеш.

Безнең Держава составына керүче башка халыкларның Дәүләт Думасында үз ихтыяҗларын кайгыртучы вәкилләре булырга тиеш, әмма алар руслар турындагы мәсьәләләрне хәл итүдә катнашучылар рәтендә була алмыйлар һәм шулай булырга тиеш тә.

Гражданлык аңы тиешенчә үсеп җитмәгән чит халыклар өлкәләрендә Дәүләт Думасына сайлаулар туктатылып торырга тиеш». Бу шартларда «Россия руслар өчен» дигән шовинистик лозунгка табынучы Столыпинның Министрлар Советы Рәисе итеп куелуы тикмәгә генә булмый.

3 нче чакырылышта, ниһаять, хөкүмәт күндәм Думалы булуга ирешә. Крестьяннар вәкилләре — трудовиклар — анда нибары 13 урын алалар. 1910 елда Дума Россиядә алпавыт җирбиләүчелеген саклау турында закон кабул итә. Мөселманнар фракциясенең бу Думада 10 мандаты була. Шуларның икесе Казан (Садри Максуди, Гаисә Еникеев), дүртесе Уфа, берсе Оренбург губерналарыннан, берсе Кырымнан, икесе Кавказдан чакырыла. Фракцияне Садри Максуди җитәкли. Милли хәрәкәт көчләренең эшчәнлеге өчен сәяси вазгыять начарлана. Г. Баруди сөргенгә сөрелә. Й. Акчура һәм Р. Ибраһимов эмиграциягә китәргә мәҗбүр булалар.

Рус социалистлары. «Столыпин реакциясе» кыяфәтендә ил өстенә ябырылган «контрреформалар»ның икенче редакциясеннән өметсезлеккә төшкән рус җәмгыяте үз өметен патша самодержавиесен халык республикасы белән алыштыру юлын (ил өчен альтернатив юлны) тәкъдим иткән рус социалистларына юнәлтә башлый. 1898 елда игълан ителгән Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (РСДРП) һәм 1902 елда оешкан Россия социалист-революционерлар партиясе (РСРП) бу программаны аеруча хуплый. Рус социалистлары җәмгыятьне милли оештыру (милли дәүләт, милли партияләр, милли мәдәният һ. б.) урынына җәмгыятьне сыйнфый оештыру (сыйнфый дәүләт, сыйнфый партия, сыйнфый мәдәният һ. б.) кирәк, дип белдергән Көнбатыш Европа социалист-марксистларына йөз тоталар. Дөрес, рус социалистлары программаларында илне, милләтне билгесез нәтиҗәләргә, хәтта гражданнар сугышына китерү куркынычы да була. Бу уңайдан җәмәгатьчелек фикерен тынычландыру өчен, алар милләтләр арасындагы аерымлыклар беткәнче, милли үзенчәлекләр исәпкә алыначак дип белдерергә мәҗбүр булалар. Ә иң мөһиме: рус социалистлары крестьяннарны, республика аларга, һичшиксез, алпавыт җирләрен бирәчәк, дип, ә рус булмаган милләтләрне, алар милли азатлыкка ирешәчәкләр, дип ышандырырга тырышалар. Рус социалистларының илдә хакимлек иткән режимны бәреп төшерергә чакырулары Эшче депутатлары Советларында да яклау таба.

Гомуми линияләре социалистик булган бу ике партия (В. И. Ульянов һәм В. М. Чернов) беренчелек өчен бик нык көндәшлек итәләр. РСДРП, бигрәк тә 1912 елдан большевистик (ленинчыл) канат өстенлек алганнан соң, чиктән тыш сул оппозиция партиясе булып китә, РСРПга карата дошманлык позициясенә баса, блоклар оештыруга зур кыенлыклар белән бара, компромиссларны кире кага. Ул илдә сыйнфый Совет республикасы урнаштыру, анда хакимиятне үзәкләштерү, большевиклар гына юнәлеш бирәчәк демократия ягында, сәнәгатьне, сәүдәне, җирне национализацияләү позициясендә тора. Башкача әйткәндә, ул «дәүләт социализмы» моделен яклый.

Социалист-революционерлар битараф калмыйлар. Алар РСДРПга карата килешмәс позициягә басалар, большевикларның «бюрократия» тарафыннан идарә ителүче «дәүләт социализмы»на каршы чыгалар. Эсерлар партиясе «демократик республика урнаштыру», «өлкә һәм общиналарга киң автономия бирү», «аерым милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә карата федератив башлангычларны киңрәк куллану, аларның үзбилгеләнү хокукларын берсүзсез тану» кебек бурычлар билгели.

Татар социалистлары. Патшаның Дума белән һичнинди тәкәллефсез мөгамәләсе, Столыпин реакциясе татар милли хәрәкәтендә Россиянең конституцион монархия юлына басуы мөмкинлегенә ышанычны киметә. «Иттифак» активистларының бер өлеше милли хәрәкәттә катнашудан читләшә. Татар милли хәрәкәтендә акрынлап радикаль көчләр өстенлек ала башлый. Килеп туган шартларда алар милли азатлык перспективасын Россиядә республика игълан итү белән бәйләү ягына күчәләр.

Үз карашларын РСДРП программасына юнәлткән революцион татар яшьләре арасында Хөсәен Ямашев (1882—1912) та була. Ул Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, аннары Татар укытучылар институтын тәмамлый. 1905 елгы революция елларында профессиональ революционерлык юлына баса, рус социал-демократлары белән якынлаша. З. Ш. Садыйков (1883—1912), Г. З. Сәйфетдинов (1882—1918) һәм татар милли хәрәкәтенең кайбер башка яшь вәкилләре аның белән иңгәиң эшлиләр. Рус социал-демократлары ярдәмендә Х. Ямашев 1907 елда Оренбургта татар телендә «Урал» газетасын чыгара башлый. Газета белән Г. Сәйфетдинов, танылган язучы Гафур

Коләхмәтов хезмәттәшлек итәләр. Газета, «Иттифак»ның милли азатлыкка конституцион монархия кысаларында ирешүгә йөз тоткан программасы белән максатка ирешеп булмый, дип аңлата. Газета, татар милли хәрәкәте социалистик программаны кабул итәргә һәм Россиядә республика урнаштыруда социал-демократларга булышлык күрсәтергә һәм шул республика составында милли азатлыкка ирешергә тиеш, дип саный. Бу матбугат органы, татар крестьяннары, социал-демократлар таләп иткәнчә, җирне бары тик алпавыт җирләрен конфискацияләү нәтиҗәсендә генә ала алачаклар, дип ышандырырга тырыша. Әмма алар татар социал-демократлары партиясе булып оеша алмыйлар.

Демократик централизм принцибында оештырылган һәм Россия республикасын киләчәктә унитар дәүләт итеп кенә күзаллаучы РСДРП Россиядә социал-демократлар оешмаларын милли билгеләр буенча төзүгә, бигрәк тә аларның автономияле булуларына каршы чыга. РСДРП әгъзалары булып киткән татар социал-демократларына бары тик җирле комитет каршында милли бер группа төзү хокукы гына бирелә. Мондый статус аларга милли хәрәкәт составында мөстәкыйль көч буларак эш итү мөмкинлеген бирми. Барлык мәсьәләләрне социал-демократлар комитеты хәл итә. Татар группасы исә милли хәрәкәттә әлеге комитет линиясен үткәрергә, социал-демократик пропаганданы татар телендә алып барырга гына хаклы була.

РСРП белән якынлашкан татар социалистларының үзләрен иркенрәк тоту мөмкинлекләре була. Бу партия милли оешмаларның «социалист-революционерлар» флагы астында мөстәкыйль рәвештә (автономия башлангычларында) эш итүләрен тыймый. 1906 елның башында Казанда Татар социалист-революционерлары партиясе төзелү турында игълан ителә. Аның «Таң йолдызы» дигән газетасы чыга башлый. Басманың сәркатибе итеп профессиональ юрист, Казан университетын тәмамлаган Фуад Туктаров билгеләнә. Бу татар телендә чыга торган беренче татар социалистлар газетасы була. Партиянең Казан оешмасын үзәкләре итеп таныган җирле комитетлар Уфада, Оренбург һәм Сембердә барлыкка килә. Татар эсерлары партиясе «Иттифак әл-мөслимин»нән үсеп чыга дисәк тә ялгыш булмас. Партиянең лидеры Садри Максуди «Иттифак» партиясе Үзәк Комитеты әгъзасы була. Татар эсерлар партиясе составына үз вакытында «Иттифак»

партиясен төзү буенча инициативалы группа составында булган язучы Гаяз Исхакый һәм профессиональ юрист С. Г. Алкин керә. Соңрак, 1913 елда Петербургта редакторы Гаяз Исхакый булган «Ил» газетасы чыга башлый (соңыннан ул Мәскәүгә күчерелә). Икенче Думага Садри Максуди Казан губернасыннан татар эсерлары партиясе вәкиле буларак сайлана. Бу партия 3 нче, ә аннары 4 нче чакырылыш Думада да мөстәкыйльлеген саклап кала. Казан губернасының жандарм идарәсе документларының берсендә: ...бу партия «тулысынча диярлек» РСРП программасын кабул иткән, әмма аңардан «милләтчелек башын калкыткан... Хәтта бу оешманың вәкилләрен социалист-революционерлар дип түгел, милләтче-революционерлар дип атау теләге дә бар иде»,— дип әйтелә.

Россия дөнья сугышына катнашып киткәч, татар милли хәрәкәтенә үз эшчәнлеген туктаткан «Иттифак» партиясе белән бәйләнештә булмаган һәм татар социалистлар оешмаларының берсенә дә иярмәгән яшь көчләр килә. Алар арасында аеруча сәләтле публицист, ялкынлы оештыручы Мулланур Вахитов (1885—1918), талантлы язучы, публицист Галимҗан Ибраһимов (1887—1938) була. Алар Россиядә патша монархиясенең мөмкин кадәр тизрәк җимерелүен телиләр һәм иҗатлары белән татар халкында гражданлык үзаңы ныгуында булышлык күрсәтергә тырышалар. Галимҗан Ибраһимов 1914 елда 1905 елгы революциягә багышланган «Безнең көннәр» дигән романын иҗат итә. «Гасыр» нәшрияты романны бастырып чыгару өчен әзерли, ләкин хакимият аны конфискацияли.

ТАТАРСТАН 1917 ЕЛ РЕВОЛЮЦИЯСЕНДӘ

РОССИЯ ДЕМОКРАТИК РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН

Патша монархиясен бәреп төшерү. 1905 ел революциясе бастырылганнан соң, «контрреформалар» заманына кире кайту, «Бөтенроссия Императоры — самодержавиеле һәм чикләнмәгән монарх» дип белдергән 1892 елгы законның яңартылган икенче басмасын чыгару патша монархиясе өчен һәлакәтле адым була. 17 октябрь Манифестыннан соң халык ил реформалар юлы белән китәчәк дип көтә һәм шуңа өметләнә дә. Ә патшага исә Россияне реформалар түгел, бәлки «рус үзенчәлеген» ныгыту коткарачак төсле тоела. Беренче рус революциясеннән соң башланган реакция елларында, ә аннары беренче бөтендөнья сугышы вакытында самодержавие строе үз абруен бөтенләй югалта. Рус җәмгыяте, рус булмаган халыклар бу стройны савыктырырга мөмкин түгеллеккә, аның реформаларга бирешмәячәгенә тәмам ышаналар. Гаскәрләр Россия — Германия фронтында җиңелүгә дучар ителәләр, хуҗалык таркала. Илдә җимереклек хөкем сөрә. Халык бөлгенлеккә төшә.

Моңа кадәр хөкүмәтне яклап килгән сәяси, хәрби һәм социаль-икътисади көчләр тынычсызлана, хафалана башлый. Үләр алдыннан, 1911 елда ук Столыпин: «Сугыш Россиягә һәм хакимлек итүче династиягә һәлакәт китерәчәк»,— дип язган иде. Элеккеге эчке эшләр министры П. Дурново 1914 ел башында патшага җибәргән бер рәсми кәгазендә сугыш йомгакларын болай күрәзәли: «...башта җирне бүлешәчәкләр, аннары барлык кыйммәтле әйберләрне, мөлкәтне гомуми бүлешү булачак». Сугыш елларында хаким итүче даирәләрдә шомлану-хафалану көчәя. Земский союзның лидеры кенәз Г. Львов, патшага мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Император Галиҗәнаплары! Хакимиятне яңартыгыз... Ялган белән

томаланган иске идарәне җиңүдәге бу бердәнбер юлны илгә ачыгыз». Патшага буржуа оппозиция тарафыннан яңарыш таләп итеп җибәрелгән мөрәҗәгатьләр дә шундый ук характерда була. Николай II хакимият структурасында таянычын югалта баруын аңлый, ләкин бу хакимият структурасының хәлиткеч мизгелдә патшаның тәхеттән ваз кичүен таләп итүгә үк барачагын башына да китерми. Һәм бирешергә җыенмый. 1915 елда ул Югары Башкомандованиене үз кулына ала. Думаны тарата. Үзенең шәхси хакимиятен көчәйтеп, хәлне уңай якка үзгәртергә маташып карый.

Әмма илдә бит әле өченче көч тә — халык та була. Һәм Николай II тарафыннан моңа кадәр санга сугылмаган әлеге өченче көч, 27 февральдә самодержавие монархиясенә каршы чыгып, фактта аның язмышын хәл итә. Формаль рәвештә таратылган булуга карамастан, үз утырышына җыелган Дума җитәкчелегендәге хакимият структураларына илдә самодержавиенең бәреп төшерелүен рәсмиләштерәсе генә кала. 4 мартта бер үк вакытта ике дәүләт акты халыкка игълан ителә. Аларның берсе император Николай II нең үз энесе Михаил Александрович файдасына тәхеттән ваз кичүе турында, ә икенчесе бөек кенәз Михаилның Югары хакимиятне кабул итүдән баш тартуы һәм хакимиятнең бөтен тулылыгы белән Дума тарафыннан оештырылган Вакытлы хөкүмәт кулына күчүен тануы турында була. Самодержавие монархиясе бәреп төшерелеп кенә калмый, монархияне кире торгызу мөмкинлеге дә юкка чыгарыла.

Вакытлы хөкүмәт. Вакытлы хөкүмәт 2 мартта Дәүләт Думасының өч фракциясе вәкилләреннән (кадетлар, октябристлар һәм эсерлардан) оештырыла. Анда кенәз Г. Е. Львов җитәкчелек итә. Аны хөкүмәт эшчәнлегенә контрольлек итү буенча комиссия төзегән Эшче депутатларның Петроград Советы яклап чыга.

3 мартта Вакытлы хөкүмәт үзенең декларациясен халыкка игълан итә. Анда сәяси тоткыннарга амнистия, сүз, матбугат иреге, полицияне милли милиция белән алыштыру, солдатларга гражданлык хокуклары бирү турында хәбәр ителә. Элекке патшаны һәм аның гаиләсен кулга алу турында фәрман бирелә, Оештыру җыелышы (Учредительное собрание) чакыру турында игълан ителә һәм дәүләт төзелеше турындагы мәсьәләне хәл итүнең аңа тапшырылачагы турында белдерелә. Аграр мәсьәләне хәл итүдә беренче адым ясала. Хөкүмәт патша

фамилиясендәге шәхесләр җирләрен, удел җирләрен конфискацияләү турында игълан итә. «Оештыру җыелышы тарафыннан җир мәсьәләсе хәл ителгәнчегә кадәр кичектергесез вакытлы чаралар эшләү өчен» Җир комитетлары булдырыла. Сугыш мәсьәләсендә Вакытлы хөкүмәт «патриотик позицияләрдә» кала. Союзникларга «дөнья сугышын тәмам җиңгәнгә кадәр җиткерү омтылышы һәм Вакытлы хөкүмәтнең союзникларга карата алган йөкләмәләрне үтәргә ниятләве» турында әйтелгән нота тапшырыла. Самодержавие монархиясен бәреп төшерү факты һәм Вакытлы хөкүмәтнең демократик адымнары бөтен җәмгыять тарафыннан һәм Көнбатыш тарафыннан хуплап каршы алына. 9 мартта Вакытлы хөкүмәтне АКШ, ә 11 мартта Бөекбритания һәм Франция таный.

Социал-демократ большевиклар вәкилләре Вакытлы хөкүмәттә катнашуга чакырылмый. Элек самодержавие монархиясенә каршы, республика өчен көрәшеп килгән рус социалистларының яшерен союзы таркала. Эсерлар: «Бөтен хакимият — Оештыру җыелышына!» дигән яңа лозунгларын алга сөрәләр. Ә социал-демократ большевиклар: «Бөтен хакимият — Советларга!» дигән лозунг астында көрәшәләр. Төп оппозицион көч булып калган хәлдә, Ленин партиясе, Вакытлы хөкүмәтнең патша хөкүмәтенә альтернатива булмыйча, аның дәвамы булуын мисаллар белән исбатлап, шактый уңышлы рәвештә бу хөкүмәтнең абруен төшерә башлый. Бу кара-каршы көрәштә Вакытлы хөкүмәт үзенең эш йөртү сәләтен торган саен югалта бара.

Татар милли хәрәкәте Февральдән соң. Традиция буенча әле һаман мөселман хәрәкәте дип аталып йөртелгән татар милли хәрәкәте самодержавие монархиясен бәреп төшерүне зур өметләр баглап каршы ала. Дүртенче Думаның Садри Максуди җитәкчелегендәге мөселман фракциясе башка думачыларның Вакытлы хөкүмәт төзү буенча тырышлыкларын хуплый. Игълан ителгән иректән файдаланып, милли хәрәкәт үзе дә легальләшә. Татар эсерлары партиясе (С. Максуди, Ф. Туктаров), меньшевистик юнәлештәге татар социал-демократлары партиясе (Ибнеәмин Әхтәмов, Г. Терегулов), милли-ислам эшлеклеләре (Г. Апанаев) вәкилләре Мөселман комитетын яңадан торгызырга карар итәләр. Либераль милли хәрәкәт оешмасы буларак, Мөселман комитеты 1914 елда ук инде «Иттифак әл-мөслимин»гә алмашка килә. Ул вакытта аның рәисе татар коммерсанты Бәдри Апанаев була. Ә хәзер

сүз комитетның бөтен Россия буенча татарлар яшәгән төбәкләрдә легаль эш итүче челтәрен булдыру турында бара. Март-апрельдә мондый комитетларны формалаштырган татар милли җыелышлары булып үтә. Казанда мондый җыелыш 7 мартта Казан юристы Вәлидхан Таначев җитәкчелегендә үтә. Комитет рәисе итеп Фуад Туктаров сайлана. 2 июльдән комитетның «Корылтай» дигән газетасы чыга башлый. Мөселман комитетлары Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Уфа һәм күп кенә башка шәһәрләрдә оештырыла. Өяз, волость мөселман комитетлары, татарлар яши һәм эшли торган предприятиеләрдә мөселман комитетлары барлыкка килә башлый. Мөселман комитетлары һәм аларның Үзәк Башкарма Комитеты эшчәнлеген татар вакытлы матбугаты — «Йолдыз» (Петроград), «Кояш» (Казан), «Вакыт» (Оренбург), «Ил» (Мәскәү) газеталары яклый. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеяләрен тарату комитеты» барлыкка килә. Аңа Ибнеәмин Әхтәмов һәм Г. Терегулов җитәкчелек итә.

Мөселман комитетлары татар милли хәрәкәтендә Февральдән соңгы чорны башлап җибәрүчеләр булалар. Бу Вакытлы хөкүмәт юмарт вәгъдәләр биргән, татар милли хәрәкәте бу хөкүмәткә ышаныч белдергән вакыт була. Мөселман комитетының программасы элеккечә кала — милли азатлыкка ирешү. Программаны тормышка ашыру бу юлы, Февральгә кадәр булганча конституцион монархия белән түгел, Вакытлы хөкүмәт белән бәйләнә. «Милли азатлыкка ирешү» идеясенең Февральдән соңгы чордагы эчтәлеге әле ачыклана гына, милли хәрәкәтнең конкрет сәяси таләпләре әле эшләнә генә. Милли хәрәкәт эшлеклеләре һәм активистлары массаларда иҗтимагый-сәяси эшне ачыктан-ачык һәм киң күләмдә алып бару юлына басалар. Мөселман комитетлары җыелышларында, милли хәрәкәт проблемаларын тикшерүләрдә, гадәттә, радикаль даирәләр — большевистик юнәлештәге социал-демократлар һәм сул эсерлар вәкилләре дә катнаша. Утырышлар шау-шулы бәхәсләрдә үтә. Үзәк мәсьәләдә — милли азатлыкка ирешүдә — барысы да нигездә бер фикердә була. Максатка Вакытлы хөкүмәт тарафыннан игълан ителгән демократик республика кысаларында (либераллар) ирешергәме, әллә Вакытлы хөкүмәтне башка хөкүмәткә алыштыру (радикаллар) юлы беләнме, дигән мәсьәләдә генә аерма күзәтелә. Хәлбуки милли азатлыкка ирешү эшенең уңышы аларның бердәмлегенә бәйле була.

4 апрельдә Садри Максуди «Вакыт» газетасында «Безнең бурычлар һәм хәзерге сәяси хәл» дигән мәкалә белән чыгыш ясый. Ул революция легаль эшләү өчен мөмкинлекләр ачты һәм «мизгелне ычкындырырга ярамый» дип саный һәм милли көчләрне берләшергә, «ызгышларны» ташлап, «милләтнең киләчәге өчен», «реаль милли теләкләрне, иң якын киләчәктәге бурычларны» күздә тотып, Вакытлы хөкүмәтнең уңай адымнарын яклап, берләшергә чакыра. Ф. Туктаров та милли хәрәкәтнең бердәмлеген ныгытуга өнди. «Корылтай» газетасының редакторы буларак чыгыш ясап, ул: «Берәүләр милләтчеләр булып киттеләр, ә икенчеләр, гомумән, милләтне танымыйлар... Халык төрлегә аерылды»,— дип яза һәм барлык сыйныфлар берләшкән тәкъдирдә генә азатлыкны яулап алырга мөмкин, дип билгеләп үтә.

Милли көчләр бердәмлеген ислам әһелләре дә яклап чыга. Галимҗан Баруди шул ук «Вакыт» газетасында: «Мондый вакытта мөселманнар сыйнфый һәм шәхси мәнфәгатьләрне читкә ташларга тиешләр, без бер фикердә булырга һәм гомуми максатларга хезмәт итәргә тиешбез. Коръән безгә шулай куша»,— дип яза.

Милли хәрәкәт эшлеклеләре милли бердәмлек турында гына түгел, рус һәм татар халыкларының гомумдемократик мәнфәгатьләренең тәңгәл килүе турында, бүтән мөселман халыклары белән, аерым алганда Төркестан, Казакъстан, Кырым, Кавказ халыклары белән якынлашу турында сөйлиләр. Казан делегациясе башлыгы сыйфатында Габделбари Баттал Ташкентта үзбәкләрнең «Шураи исламия» («Ислам берлеге») оешмасы съездында катнаша.

Милли хәрәкәтнең радикальләшүе. Татар милли хәрәкәтенең Вакытлы хөкүмәткә мөнәсәбәте ул әле оешкан гына вакыттан ук бердәй булмый. Оппозицион большевиклар партиясе сафларында татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләре: Казанда — Мирсәед Солтангалиев (1892—1939), Галимҗан Сәйфетдинов (1882—1918), Камил Якуб (1894—1919), Екатеринбургта — Сәхибгәрәй Сәедгалиев (1894—1939), Галиулла Касыймов (1893—1942), Сызраньда — татар язучысы Шамил Усманов (1898—1937), Әстерханда — Борхан Мансуров (1889—1942), Ижевскида Вәлиулла Хөснетдинов (1880—1922) эшлиләр. Алар милли хәрәкәтнең гомуми сәяси акцияләрендә актив катнашалар һәм, үзләренең партия комитетлары линиясен үткәреп, Вакытлы хөкүмәтне

яклауга каршы чыгалар. Үз матбугат органнары булмау сәбәпле, русларның большевистик басмаларында, мәсәлән, Казандагы «Рабочий» газетасында татар телендә аерым сәхифәләр бирәләр. Еш кына татар милли басмаларының, мәсәлән, Фатих Әмирханның «Кояш» газетасы битләрендә дә чыгыш ясыйлар.

Февральдән соңгы ай азагында яшь татар социалистларының бер өлешендә Вакытлы хөкүмәткә карата ышаныч бетә. 30 мартта Галимҗан Ибраһимов, язучы Фатих Сәйфи (Казанлы) белән бергәләп, Уфада «Ирек» газетасы чыгара башлый. Газета үзен Вакытлы хөкүмәткә карата оппозициядә дип игълан итә, сугышны дәвам итүгә ачыктан-ачык каршы чыга. 13 апрельдә басылып чыккан «Вакытлы хөкүмәт һәм мөселманнар» дигән мәкаләдә, татар милли хәрәкәте Вакытлы хөкүмәтнең демократик сәләте турындагы буш хыялдан баш тартырга тиеш, дигән фикер белдерелә.

Татар җәмгыятенең төрле катлауларында Вакытлы хөкүмәткә карата оппозиционлык көчәя. Рус крестьяннары кебек үк татар крестьяннары да кабинет җирләрен һәм удел җирләрен аларга тапшыру турындагы һәм крестьян комитетлары оештыру турындагы Вакытлы хөкүмәт актын хуплыйлар. Бу комитетларның составы руслардан тора. Үзләренең губерна һәм өяз съездларына алар татар крестьяннарын да чакыралар. Татар һәм рус крестьяннарының аларга алпавыт җирләрен бирү турындагы таләпләре бердәй була.

20—27 апрельдә Казанда татар мөгаллимнәренең Бөтенроссия милли съезды була. Анда, башлыча, татар мәктәпләрендә белем бирүне камилләштерү мәсьәләләре тикшерелә. Съезд мөселман мөгаллимнәренең Үзәк бюросын сайлап куя. Бюроның рәисе итеп танылган галим, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Газиз Гобәйдуллин (1887—1938) билгеләнә. Съезд милли үсеш мәсьәләләре буенча да үз фикерен белдерә. Сугышны дәвам итү сәясәте гаепләнә, Россиянең дәүләт төзелешен федеральләштерү юнәлешендә үзгәртү һәм татар халкына милли-территориаль автономия бирү турындагы тәкъдим яклана. Татар хатын-кызларының апрель азагында Казанда булып үткән Бөтенроссия съезды делегатларын да татар милләтенең киләчәге борчый. Хатын-кызлар хәрәкәте активистлары Әминә Мөхетдинова, Рауза Чанышева татар милли хәрәкәтендә хатын-кызларның ролен активлаштыру турында тәкъдим белән чыгалар.

Мөселман социалистлар комитеты. Февральдән соң милли хәрәкәтнең киңәюе барышында яңа иҗтимагый-сәяси оешма — Мөселман социалистлар комитеты (МСК) туа. МСК 1917 елгы Россия революциясе чорының атаклы татар җәмәгать эшлеклеләреннән берсе, бу юлга әле 1905 елгы революция елларында ук баскан Мулланур Вахитов инициативасы буенча формалаша. Бу комитетны оештыруда татар хатын-кызлары хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе Әминә Мөхетдинова да (1893—1944) катнаша.

Мөселман социалистлар комитетының максатлары аның уставында тәгъбир ителә, татар эшчеләре һәм крестьяннары арасында социализм идеяләрен таратуны, аларны милли һәм социаль азат итү өчен көрәшкә туплауны күздә тота. Июнь аенда комитетның «Кызыл байрак» дип исемләнгән газетасы чыга башлый. Газета, татарларны милли яктан азат итү Россиядәге революциянең киләчәк үсеше белән һәм Вакытлы хөкүмәтне яңа хөкүмәткә алыштыру белән тыгыз бәйләнгән, дип аңлата. Эшче, крестьян, солдат депутатлары Советлары төзегән хөкүмәт, буржуаз Вакытлы хөкүмәттән аермалы буларак, биргән вәгъдәләрен үтәр һәм татар халкына үз язмышын үзенә хәл итәргә мөмкинлек бирер дип күздә тотыла.

МСК эшчеләр, солдатлар һәм татар халкының башка катлаулары хокукларын аңлатуны үз эшчәнлегенең төп максаты итеп куя. Казан шәһәренең эшчеләр үзәкләрендә район оешмалары төзелә, предприятиеләрдә кечкенә китапханәләр, укый-яза белмәүчелекне бетерү курслары булган эшчеләр клублары барлыкка килә. Шундый клубларның берсе Алафузовлар фабрикасының эшчеләр театры бинасында эшли башлый. Әминә Мөхетдинова хатын-кызлар арасында эш алып бару өчен җаваплы итеп билгеләнә. «Кызыл байрак» газетасында ул «Хатын-кызларга азатлык» дигән мәкалә белән чыгыш ясый. Милли хәрәкәттә актив катнашучылар сафларына Гыйззениса Таҗетдинова (1894—1969) МСК аша килә. МСКда ул солдат хатыннарының мөселман бюросын җитәкли.

Оештырылу ягыннан МСК татар милли хәрәкәтенең мөстәкыйль иҗтимагый-сәяси оешмасы буларак эш итә. Бүтән татар социалистлары аның тирәсендә берләшә. Татарларның сул эсерлар партиясен оештыручы һәм аны җитәкләүче Галимҗан Ибраһимов та МСК тирәсендә берләшүчеләр арасында була. Галимҗан Ибраһимов тормышын һәм эшчәнлеген

өйрәнүче һәм тикшерүче академик М. Х. Хәсәнов билгеләп үткәнчә, «Ирек» газетасы әлеге партиянең рәсми органы булып китә. Мөстәкыйль рәвештә эшләргә мөмкинлек булмау белән ризалашмаган большевик юнәлештәге татар социал-демократлары да МСК сафларына килә. Галимҗан Сәйфетдинов, Мирсәед Солтангалиевлар Мулланур Вахитовның көрәштәшләре булып китәләр. Мартта Казанда оештырылган Приказчиклар һәм контора хезмәткәрләре бюросы МСК каршында эшли. Бу бюро эшенә күренекле публицистларның берсе, МСКны оештыруда Мулланур Вахитовның көрәштәше Шаһид Әхмәдиев җитәкчелек итә. Бюро каршында «Аваз» газетасы чыга башлый. Мөселман комитеты һәм Мөселман социалистлар комитеты кебек бер-берсенә карата оппозицион ике канаттан тору татар милли хәрәкәте өчен отышлы гына була. Бу хәл комитетларның эшен активлаштыра гына.

Бөтенроссия мөселманнар съезды. 1917 елның 1—11 маенда Мәскәүдә мөселман оешмаларының I Бөтенроссия съезды эшли. Аның эшендә Идел-Урал төбәгеннән, Төркестан, Казакъстан, Кырым, Кавказ аръягы һәм Төньяк Кавказ төбәкләренең мөселман оешмаларыннан меңнән артык делегат катнаша. Съездда татар милли хәрәкәтен Мөселман комитеты (либераль канат) һәм Мөселман социалистлар комитеты (радикаль канат) гәүдәләндерә. Россиядә дәүләт төзелешенең милли планда нindирәк булырга тиешлеген билгеләү һәм мөселман халыклары милли оешмаларының Февральдән соңгы стратегик бурычларын ачыклау съезд эшендә төп урынны алып тора.

Съездның эше Вакытлы хөкүмәтне дә кызыксындыра. Бу хөкүмәт Россиядәге мөселман халыклары милли хәрәкәтләренең «бердәм һәм бүленмәс» рус дәүләтенең сакланып калуы кысаларында үсүен теләи. Хакимият даирәсендәгеләрнең фикеренчә, Россиянең мөселман халыклары рус дәүләте составында милли азчылык хәлендә калырга һәм шуның бәрабәренә элек үк кадетлар партиясе тарафыннан тәкъдим ителгән милли-мәдәни автономия алырга тиеш булалар. Съездны Вакытлы хөкүмәт составында вәкилләре булган рус партияләре, шул исәптән кадетлар партиясе вәкилләре котлый. Съезд эшен Петроград һәм Мәскәүнең төп газеталары хәбәрчеләре, шулай ук чит ил журналистлары яктырта.

Мөселман халыклары милли хәрәкәте вәкилләре конституцион монархияне таләп итү инде соң булган, Россия инде

демократик республика дип игълан ителгән бу яңа шартларда милли мәсьәләне хәл итүнең радикальрәк формуласын эшләп карарга ниятләгән булалар. Фикер алышу барышында мәсьәләгә ике төрле караш булуы ачыклана. Бер караш федерацияне якласа, икенчесе унитар дәүләт ягында тора. Россия чигендәге төбәкләр (Кавказ аръягы, Төркестан) делегатларының күпчелеге Россиянең федератив төзелешен һәм мөселман халыкларына гомуми кабул ителгән мәгънәдә киң автономия бирү, ягъни үзләренең тарихи җирләрендә дәүләт хакимиятен мөстәкыйль рәвештә тормышка ашыру хокукын бирү идеясен яклый. Алар арасында Расул-задә, Ибраһим Әфәндиев, Г. Топчибашев, З. Дусмөхәммәдовлар була. Төньяк Кавказ вәкиле Әхмәт Цаликов Россияне унитар дәүләт сыйфатында саклап калу һәм мөселман халыкларына, территорияләрен үзләренә беркетмичә генә, милли-мәдәни автономия бирү турында тәкъдим кертә.

Ул вакытта рус иҗтимагый аңында да милли мәсьәләне хәл итүгә охшаш бер фикер формалаша башлый. Рус җәмәгать эшлеклеләренең бер өлеше, Россия чикләрендә яшәүче рус булмаган халыкларга (финнарга, Балтыйк буе халыкларына, полякларга, ә бәлки украиннаргададыр) рус дәүләте составында территориаль автономия бирергә, ә «Эчке Россия»нең (Төньяк Кавказның, Идел-Урал төбәгенең) рус губерналарында «милли азчылыкны» тәшкил иткән халыкларга милли-мәдәни автономия бирергә кирәк, дип исәпли. Тулаем алганда, съездда тавыш бирү вакытында унитар дәүләтне саклау ягында торучылар делегатлар тавышының дүрттән бер өлешен генә алалар. Делегатларның иң зур күпчелеге федерализмны яклап тавыш бирә.

Рус губерналарында таралып яшәү сәбәпле, ул губерналарның һәрберсендә дә азчылыкны тәшкил иткән татарлар, хәлбуки, үзләрен азчылык милләт дип санамыйлар. Милли һәм дини ассимиляция сәясәтенә карамастан, алар үзләрен саклап калалар, заман милләте булып оешалар, үзләренең милли дәүләтләрен исләрендә тоталар, аның яңа шартларда һәм яңа сыйфатлы булып торгызылачагына ышанып яшиләр. Татар делегациясе составына керүчеләрнең күпчелеге федерация яклыларга кушыла һәм бу федерациядә Идел-Урал төбәгенең төрки-татарларына милли-территориаль автономия бирүне таләп итеп чыга. Шунысын да әйтергә кирәк: милли хәрәкәтнең либераль (мөселман комитетлары, Зәки Вәлиди

һ. б.) һәм радикаль канаты (Мөселман социалистлар комитеты) вәкилләре татарлар белән башкортларга милли-территориаль автономия бирү һәм Россия дәүләтен федерация формасында оештыру таләпләрен яклап чыгалар. 1917 ел азагында шушы идеяләр татар милли хәрәкәтендә хакимлек итә.

Татар делегациясенең катгый таләбе буенча мөселман халыкларының милли хәрәкәтенең башка аспектлары да — эшчеләр мәсьәләсе, аграр-крестьян мәсьәләсе, хатын-кызлар турындагы, мөселман гаскәри частьлары турындагы мәсьәләләр тикшерелә. Съезд Бөтенроссия «Милли Шура»сын һәм Әхмәт Цаликов җитәкчелегендә аның Башкарма Комитетын сайлап куя.

Вакытлы хөкүмәт белән конфликт. Мөселман халыкларының I съездында Россиянең федератив төзелеше турында һәм мөселман халыкларына милли-территориаль автономия бирү турында күпчелек тавыш белән кабул ителгән карар Вакытлы хөкүмәтне кыен хәлгә куя. Рус булмаган башка халыкларның да федерация таләп итүләре ачыклана. Украинаның Үзәк Радасы илнең мөстәкыйльлеге турында «Универсал» (Манифест) чыгара. Вакытлы хөкүмәткә Карелия, Белоруссия, Кавказ автономияләре турында проектлар тәкъдим ителә. Финляндия сеймы илнең мөстәкыйльлеген тануны таләп итә. Вакытлы хөкүмәт, «бердәм, бүленмәс Россия» позициясендә калып, әлеге барлык таләпләрне кире кага. Күпчелеге кадетлардан торган Төркестан комитеты: «Колония буларак Төркестан үзидарә мәсьәләсендә инглиз һәм француз колонияләренә охшатып оештырылырга тиеш»,— дип белдерә. Кадетлар газетасы украиннар «Универсал»ы турында ачу белән: «Украин әфәнделәр Россия белән начар шаяралар»,— дип яза.

Рус булмаган халыкларның Россияне федерация итеп оештыру турындагы таләпләренә рус оппозициясе үзенчә җавап бирергә карар итә. Социалист-революционерлар партиясенең әле моңа кадәр үк, самодержавие монархиясе бәреп төшерелгәннән соң федерация төзелү ихтималы бар дию искә төшерелә. 4—28 майда Петроградта эсерлар химаясе астында үткән Бөтенроссия крестьян депутатлары съезды Россиядә федератив дәүләт строе урнаштырылуы мөмкин дип исәпли. Большевиклар да бу хәлдән үз максатларында файдаланырга уйлый. Эшче һәм солдат депутатларының 3—24 июньдә

Петроградта булып үткән Бөтенроссия съездында большевиклар лидеры Ленин: «Россия ирекле республикалар берлеге булсын»,— дип белдерә. Аның фикеренчә, крестьяннар съезды, «федератив» республика турында сүз башлап, «рус республикасы бер генә халыкны да яңача да, искечә дә изәргә теләми, дигән фикерне әйтте инде».

Боларның барысы да рус оппозициясе тарафыннан бәхәс кызуында гына, Вакытлы хөкүмәтнең абруен төшерү өчен генә әйтелә. Хәлбуки ул вакытта әле оппозиция хакимият башына килә-нитә калганда, аның үзен ничек тотачагы мәгълүм булмый. Вакытлы хөкүмәтнең федерациягә мөнәсәбәте башта ук тискәре була. 6 майда коалицион хөкүмәт төзелү турында игълан ителә. Аның составына рус социалистларыннан А. Ф. Керенскийдан тыш, эсерлар партиясе лидеры В. М. Чернов, трудовик П. Н. Переверзев, халык социалисты А. В. Пешехонов, меньшевистик юнәлештәге ике социалдемократ М. Г. Церетели, М. И. Скобелев керәләр. Яртылаш социалистлардан торган бу коалицион хөкүмәт, үз чиратында, унитар дәүләт позициясендә кала. Шулай итеп, Вакытлы хөкүмәт рус булмаган халыкларның милли хәрәкәтләре белән конфликтка керә. Татар милли хәрәкәтендә милли азатлыкны яулап алуда Вакытлы хөкүмәт белән хезмәттәшлек итүгә өмет югала бара.

Милли хәрәкәт консолидациясе. Казанда мөселманнарның ике тармак съезды булып уза: Мөселманнарның Бөтенроссия хәрби съезды һәм Мөселман руханилары съезды. Аларга параллель рәвештә үк Мөселманнарның II Бөтенроссия съезды эшли. Майда булып үткән I съездан аермалы буларак, ул бары тик татар-башкорт делегатларыннан гына тора. Тармак съездларының да һәр икесе шундый ук була. Татар һәм башкорт халыкларының тормыш шартлары якынлыгыннан, ул вакытта аларның милли хәрәкәтләре дә бергәләп үрелеп үсә. Бу съездлар мөселманнарның майда булып үткән съездыннан соң барлыкка килгән шартларда татар һәм башкорт милли хәрәкәтләренең стратегиясе һәм тактикасы мәсьәләләрен тикшерәләр. Бу вакытта ике төрле яңалык күзәтелә. Беренчедән, милли-территориаль автономия һәм рус республикасы белән федерациягә керү таләбе мөселманнарның уртак таләбенә әверелә. Икенчедән, Вакытлы хөкүмәтнең моңа бармаячагы торган саен ачыграк аңлашыла.

Мөселманнарның Бөтенроссия хәрби съезды, эшен 17 июльдә башлап, татар һәм башкорт солдатларының һәм офицерларының милли хәрәкәттә тоткан урыны һәм роле турындагы мәсьәләне тикшерә. Аларның эшчәнлеген координацияләү өчен «Хәрби Шура» оештырыла. Аның җитәкчесе итеп прапорщик Ильяс Алкин билгеләнә. Шура составына шулай ук У. Токумбәтов, Г. Монасыйпов, С. Мәмлиев, Г. Баһаветдиновлар керә. Алар, нигездә, татар һәм башкорт эсерлары вәкилләре булалар, татар һәм башкортлардан торган хәрби частьларда хезмәт итәләр. Татар-башкорт хәрби частьларында солдат комитетлары оештыру хакында карар кабул ителә. Съезд карарында болай диелә: «Әгәр Вакытлы хөкүмәт баш тартса һәм әлеге карарлар белән килешмәсә, комитетларны рөхсәтсез генә оештырырга».

Татар һәм башкорт ислам руханилары съезды үзенең эшен 18 июльдә башлап җибәрә һәм милли хәрәкәттә руханиларның урыны турындагы мәсьәләне тикшерә. 21 июльдә Мөселманнарның II Бөтенроссия съезды ачыла. Аның эшендә милли хәрәкәттәге барлык юнәлешләрнең дә: татар-башкорт эсерлар партиясе, мөселман комитетлары, Мөселман социалистлар комитеты, татар-башкорт сул эсерлары, большевистик һәм меньшевистик юнәлешләрдәге татар-башкорт социал-демократлары вәкилләре катнаша. Бераз соңрак аларга хәрби съезд һәм руханилар съезды делегатлары кушыла. Мөселманнарның II Бөтенроссия съезды милли хәрәкәтнең иң киң форумы була һәм Октябрь дәүләт перевороты алдыннан милли көчләрнең тупланганлыгын күрсәтә.

Съезд милли азатлыкка ирешүнең гомуммилли концепциясен эшли. Бу концепциянең асылы халык ихтыяры буенча милли-территориаль автономия булдырудан һәм шул ук вакытта руслар белән моңа кадәр яшәп килгән тату мөнәсәбәтләрне саклап калудан гыйбарәт була. Россиядәге рус булмаган халыкларның, Россиядә республикалар оештырып, федератив дәүләт строе төзү турындагы тәкъдимнәрен съезд яклап чыга. Рус оппозициясенең кайбер вәкилләре дә бу тәкъдимне яклый.

Милли хәрәкәтнең бу стратегик мәсьәләсендә делегатларның карашы бердәм була. Әмма булачак республиканың милли-сыйнфый асылын билгеләүдә һәм бу максатка ирешү юлларын сайлап алуда аларның фикерләре аерыла. Татар эсерлары партиясе, мөселман комитетлары, меньшевистик юнәлештәге татар социал-демократлары, мөселман рухани-

лары (либераллар) стратегик максатка ирешүне Вакытлы хөкүмәт белән бәйлиләр, аның федерация һәм автономия турындагы мәсьәләләрнең Оештыру җыелышы тарафыннан хәл ителәчәге турындагы вәгъдәләренә ышаналар. Мөселман социалистлар комитеты, татарларның сул эсерлары, большевистик юнәлештәге татар социал-демократлары (радикаллар), милли азатлыкның төп шарты Вакытлы хөкүмәтне алмаштыру, дип уйлыйлар.

Милли республиканың милли-сыйнфый асылы турындагы мәсьәлә буенча либераллар «Иттифак әл-мөслимин» традицияләренә тугрылыклы калалар һәм, ул гомуммилли булырга, җәмгыятьтәге барлык сыйныфларның республикасы булырга тиеш дип баралар. «Россия мөселманнары,— дип белдерә Садри Максуди,— үзбәкләргә, кыргызларга, төрекмәннәргә һәм буржуйларга, эшчеләргә һәм крестьяннарга бүленә... Сыйнфый һәм милли аермалыклар милләтләрне берләштерүгә комачаулык итә алмый». Радикаль канат исә, милли республика милли берләшкәнлекне гәүдәләндереп кенә калмый, ул хезмәт иясе сыйныфлар — эшче, крестьян, солдатлар — мәнфәгатьләренең өстен булуын да танырга тиеш, дигән фикерне куәтли. Галимҗан Ибраһимов «Ирек» газетасында бу фикерне болай бәян итә: Мөселманнар алдында ике төрле бурыч тора: 1) мәдәният һәм сәясәт өлкәсендә милли мәсьәләне хәл итү; 2) социаль һәм сыйнфый мәсьәләләрне хәл итү. Беренче мәсьәлә буенча барлык мөселманнар да бергә бара алалар. Ләкин икенче мәсьәләдә — икътисади һәм сыйнфый мөнәсәбәтләрдә, сез нинди генә көч сарыф итсәгез дә, бу берләшү мөмкин түгел.

Тактик мәсьәләләрдә каршылыклар булуга карамастан, съезд киләчәктә үзенең яшәргә сәләтле икәнен күрсәтәчәк милли концепция эшли һәм кабул итә. И. Р. Таһиров һәм Р. К. Вәлиев бу концепцияне «Казан платформасы» дип атыйлар. Милли республика төзү милли хәрәкәтнең стратегик максатына әверелә.

Халык хәрәкәте. Һаман дәвам иткән сугыш һәм хуҗалык җимереклеге рус һәм татар халыклары хәлен бер үк дәрәҗәдә начарлата. Аларның Вакытлы хөкүмәткә карата оппозициясе көчәя. Аерыммы яисә рус эшчеләре һәм крестьяннары белән берлектә чыгыш ясыйлармы, татар эшчеләре һәм крестьяннары солых турындагы, хуҗалыкның тотрыклы, тормыш шартларының канәгатьләнерлек булырга тиешлеге турындагы

гомумдемократик лозунгларны алга сөрәләр. Татар эшчеләре һәм крестьяннарының гомумсыйнфый таләпләре рус эшчеләре һәм крестьяннарыныкы кебек үк яңгырый: крестьяннарга — җир, эшчеләргә — 8 сәгатьлек эш көне. Ниһаять, аларда, Вакытлы хөкүмәт бу таләпләрне канәгатьләндерергә сәләтсез, дигән гомуми караш формалаша.

Болардан тыш татар халкында (эшчеләрдә, крестьяннарда, эшмәкәрләрдә, зыялыларда, руханиларда) соңгы унъеллыклар дәвамындагы актив социаль тормыш барышында милли үзаң нык үсә. Татар халкы, үз алдына мөстәкыйль милли республика төзү бурычын куеп, милли хәрәкәттә катнаша башлый. Милли азатлыкка ирешү лозунгы татар эшчеләре һәм крестьяннары чыгышларында сыйнфый таләпләрдән бер дә ким яңгырамый. Татар эшче-крестьяннарының сыйнфый хәрәкәтләре рус эшче-крестьяннарыныкы белән бер үк гомуми агымда бара һәм, шул ук вакытта, татарларның гомуммилли хәрәкәтенә дә килеп кушыла. Милли хәрәкәтнең үзенә килгәндә исә, ул татар халкының сыйнфый һәм милли мәнфәгатьләрен чагылдыручы булып китә.

Бу елларда татар солдат массалары милли хәрәкәтнең йогынтылы көченә әверелә. Россия дөнья сугышына кушылганнан соң, күп кенә татар солдатлары мобилизация белән армиягә чакырыла. Гомумармия частьларында, фронтта һәм тыл гарнизоннарында алар сугыш авырлыкларын татыйлар. Февраль революциясе аларның солых урнашуга булган өметләрен акламый. Солдатлар арасында сугышка каршы настроениеләр, милли азатлык идеясе көчәя. Мөселманнарның июль хәрби съезды оештырган Хәрби Шура чакыруы буенча фронт армия частьларында һәм тыл гарнизоннарында полк, дивизия, армия мөселман комитетлары барлыкка килә. И. Р. Таһиров әйтүе буенча, июль аенда аларның саны инде 56 га җитә. Хәрби Шура эшләгән устав нигезендә комитетларның җитәкчелеге һәр дүрт ай саен алыштырылып (сайланып) торырга һәм Хәрби Шурага буйсынырга тиеш булалар. Устав нигезендә татар һәм башкорт солдатлары милли батальоннар һәм роталарга җибәрелеп тора.

Солдатлар арасында оештыру эше белән Киев хәрби округында Йосыф Мозаффаров, Уфада Ш. Ходайбердин, Екатеринбургта Сәхибгәрәй Сәедгалиев шөгыльләнәләр. Беренче милли хәрби частьлар да төзелә башлый. Казанда урнаштырылган дүрт полк составында дүрт рота оештырыла. Бу роталарда

координацияләү эшен Вәли Шәфигуллин һәм Казан хәрби училищесы курсанты Якуб Чанышев алып бара. Уфа, Саратов, Сембер, Пенза, Одесса гарнизоннарында шундый ук роталар оештырыла. Аларның кайберләре шул ук хәлдә фронтка да китеп бара. Милли частьларны оештыру һәм аларны милли хәрәкәткә җәлеп итү мәсьәләләре белән танылган сәяси эшлеклеләр Мулланур Вахитов һәм Мирсәед Солтангалиев шөгыльләнә.

МИЛЛИ РЕСПУБЛИКАГА ИЛТҮЧЕ ЮЛ

Россиядә Октябрь перевороты. 1917 елның көзендә Вакытлы хөкүмәт өчен озакка сузылган кризислар чоры башлана. Ул халык ышанычын тәмам югалта, һәм аның язмышы хәл ителә. Вакытлы хөкүмәт мирасына иң оешкан ике сәяси көч дәгъва итә: сул эсерлар белән союзда булган большевиклар һәм гаскәриләрнең югары даирәләре белән союзда торган кадетлар. Бу ике көчнең берсе дә халыкның күпчелеген үз артыннан ияртә алмый. Большевиклар түбән катлауларны җәлеп итсә дә, урта сыйныфларны сагайта торган совет экспериментын алга сөрәләр. Кадетлар һәм югары дәрәҗәле хәрбиләр исә элеккеге «тыныч заманнарны» кире кайтарудан гайре берни дә вәгъдә итә алмыйлар. Әлеге «тыныч заманнар» урта катлауларны әллә ни кызыктырмый.

Вакытлы хөкүмәткә ышанычын югалткан рус халкы большевикларга да, кадетлар белән хәрбиләргә дә «якты йөз күрсәтергә» ашыкмый.

Вакытлы хөкүмәтне үз хөкүмәтләренә алыштыру адымын беренче булып югары даирә хәрбиләр белән бергә кадетлар ясый (Корнилов заговоры). Рус халкының күпчелеген ияртә алмаган фетнә уңышсызлыкка очрый. Мираска дәгъва иткән икенче көч (большевиклар һәм сул эсерлар) бу юлы заговорны бастыруда Вакытлы хөкүмәткә ярдәм күрсәтә. Бераз әзерләнгәннән соң большевиклар һәм сул эсерлар октябрьдә үзләре Вакытлы хөкүмәткә һөҗүм башлыйлар. Халык йөзендә таяныр көче булмаган, кадетлар һәм хәрбиләрнең ярдәменнән мәхрүм ителгән Вакытлы хөкүмәт большевикларга бирелергә мәҗбүр була. 25 октябрьдә Петроградта Вакытлы хөкүмәтнең бәреп төшерелүе һәм хакимиятнең Советлар кулына күчүе турында игълан ителә. Бу хәбәр һичкичекмәстән телеграф буенча урыннарга җиткерелә. Большевиклар

күпчелекне тәшкил иткән Казан Советы бу хәбәрне 26 октябрьдә иртән ала. Шул ук көнне Казан Вакытлы революцион комитеты оештырыла, һәм ул халыкка: «Моннан сигез ай элек патша хакимиятен бәреп төшергән иректе рус халкы менә хәзер иң соңгы, иң авыр богауны да алып ташлады»,— дип мөрәҗәгать итә. Бераз соңрак Казан большевикларының берсе Я. С. Шейнкман болай дип белдерә: «Халык Комиссарлары Советының Октябрь переворотыннан соң алып барган сәясәте эшче-крестьяннар мәнфәгатьләренә җавап бирүче бердәнбер сәясәт булып тора».

Ул вакытта Казан рус хакимиятенең Идел буендагы иң нык терәк пунктларының берсе, хәрби округ үзәге була. Хакимият Советлар кулына күчкәч тә, бу шулай булып кала. Казан Советында һәм Казан социал-демократлар комитетында татарлар бик аз була. Татарларның милли оешмалары — Мөселман социалистлар комитеты, Казан губерна милли җыелышы (корылтае) Казан бистәләрендә, Болак артында бик кысан шартларда эшли.

Советларның II Бөтенроссия съездында, Петроградта большевикларның Ленин җитәкчелегендәге бер партияле Вакытлы Совет хөкүмәте — Халык Комиссарлары Советы (ХКС) төзелә. Ленин тирәсенә Л. Д. Троцкий (тышкы эшләр халык комиссары), Л. Б. Каменев (Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе) Г. Е. Зиновьев (Петроград Советы Рәисе), А. В. Луначарский (мәгариф халык комиссары), А. И. Рыков (эчке эшләр халык комиссары), А. М. Коллонтай (социаль тәэминат халык комиссары), А. Г. Шляпников (хезмәт халык комиссары), П. И. Стучка (юстиция халык комиссары) кебек шактый өлгер һәм кыю, Көнбатыштагы сәяси тормыш белән яхшы таныш булган сәяси эшлеклеләр туплана. «Чит ил мәктәбен» үтмәгән, ләкин массалар арасында митинглар оештыруда һәм журналистлык эшендә зур тәҗрибә туплаган, сөргеннәрне һәм төрмәләрне үткән эшлеклеләр рәтендә И. В. Джугашвили (милләтләр эше халык комиссары), Я. М. Свердлов (Большевиклар партиясе Үзәк Комитеты секретаре) һ. б. була. Вакытлы хакимият органы буларак, бу хөкүмәт большевиклар вәгъдә иткән Оештыру җыелышы чакырылганга кадәр эш итәргә тиеш була. 1918 елның гыйнварында чакырылган Оештыру җыелышы большевиклар хөкүмәтен танырга теләми, һәм шуңа күрә Совет хөкүмәте аны тарата. Шуннан соң ук Ленин хөкүмәте «Вакытлы» дигән сүзне

алып ташлый да «совет экспериментын» үткәрергә керешә.

Рус җәмгыятенең Совет моделе. Ленин хөкүмәте хакимият башына рус җәмгыятен, рус милли дәүләтен революцион юл аша (тамырдан) яңарту программасы белән килә. Кадетларның конституцион монархиясен, ә аннан соң Вакытлы хөкүмәт тәкъдим иткән конституцион республиканы кире кагып, большевиклар конституцион Совет Республикасын игълан итәләр. Совет хакимиятенең сәяси асылын билгеләп, Ленин 25 октябрьдә: «...Бу переворотның әһәмияте шуннан гыйбарәт ки, бездә буржуазиянең бернинди дә катнашы булмаган үз Совет хөкүмәтебез, үз хакимият органыбыз булачак»,— дип белдерә. Рус җәмгыяте чынбарлыкта сәяси яктан ике өлешкә — хакимиятне «кулда тотучыларга» (хезмәт ияләренә) һәм «хакимияттән мәхрүм ителгәннәргә» (ирекле эшмәкәрләргә) бүленә. Совет Республикасының парламенты итеп Эшче, крестьян һәм солдат депутатлары Советлары съезды игълан ителә. Советларда шәһәр һәм авыл эшмәкәрләре катнашмый. «Хезмәт иясе һәм эксплуатацияләнүче халыкларның хокуклар декларациясе», исеме үк әйтеп торганча, хокук һәм ирекне бары тик хезмәт ияләренә генә бирә, ә эшмәкәрләрне бу хокук һәм иректән мәхрүм итә. Совет хөкүмәтенең беренче декретлары арасында, бер яктан, солых төзү, 8 сәгатьлек эш көне кертү, катлауларны һәм гражданлык чиннарын бетерү, чиркәүне дәүләттән һәм мәктәпне чиркәүдән аеру, крестьяннарга җир бирү һ.б. кебек ил өчен инде күптән өлгереп җиткән проблемаларны хәл итә торганнары да, икенче яктан, рус җәмгыятен үстерүнең алпавытлар һәм эре капиталистлар өчен генә түгел, урта катлаулар өчен дә кабул ителмәслек юлларны күздә тота торганнары да була. Соңгылары арасында җирне крестьяннарга хезмәт нормасы нигезендә бүлеп бирүдән аны национализацияләүгә (дәүләт кулына тапшыруга) күчү турындагы; сәнәгать предприятиеләрендә һәм транспортта эшче контроле кертү, киләчәктә аларны национализацияләү, ә соңрак халыкның урта катлауларын хосусый милектән мәхрүм итү турындагы декретлар да бар. Революцион трибуналлар оештыру, Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (ВЧК) һәм кызыл террор кертү турындагы декретлар алпавытлар, капиталистлар һәм рус җәмгыятенең урта катлаулары өчен һәлакәтле була.

Совет хөкүмәтенең милли сәясәте. XX гасыр башында халкының күпчелеген рус булмаган халыклар тәшкил иткән Россия яңа милли сәясәткә мохтаҗ була. Вакытлы хөкүмәт бу

сәясәтне билгеләргә өлгерми кала. Совет хөкүмәте исә өлгеррәк булып чыга. 2 ноябрьдә «Россия халыкларының хокуклар декларациясе» кабул ителә. Декларациядә түбәндәге вәгъдәләр бар:

1. Россия халыкларының тигезлеге һәм суверенлыгы.

2. Россия халыкларының аерылып чыгуга һәм мөстәкыйль дәүләт оештыругача булган ирекле үзбилгеләнү хокукы.

3. Барлык һәм һәртөрле милли, милли-дини өстенлекләрне һәм чикләүләрне бетерү.

4. Россия территориясендә яшәүче милли азчылыкларның һәм этнографик төркемнәрнең ирекле үсүе.

Бу күптән өлгереп җиткән һәм рус булмаган халыклар тарафыннан хуплап каршы алынган акт була. Декларацияне гамәлгә ашыру уңышлы гына башлана. 1917 елның 18 (31) декабрендә Совет хөкүмәте Финляндия бәйсезлеген таный. Аннары Польша, Эстония, Латвия һәм Литваның мөстәкыйльлеге танылa. Илдә рус халкы һәм рус булмаган халыкларның саннардагы чагыштырмасы рус халкы файдасына үзгәрә. Руслар бөтен Россия халкының 57 процентын тәшкил итә башлый. Дәүләт составындагы башка рус булмаган халыклар милли азчылык дип игълан ителә. Урыннарда Советлар рус хакимияте буларак формалаша. Казанда да бу нәкъ шулай була. Советларның губерна Башкарма Комитеты бюросы 9 кешедән оештырыла. Аның составына, соңыннанрак, губернадагы азчылык милләт вәкилләре сыйфатында, татар, чуваш, марилардан берәр кеше кертелә.

1918 елның гыйнварында Ленин хөкүмәте милли хәрәкәтләргә ташлама ясарга мәҗбүр була. Советларның III Бөтенроссия съезды Россияне федерация дип игълан итә. Рус булмаган халыкларга милли-территориаль автономия вәгъдә ителә. Ләкин, әйтергә кирәк, бу автономияне биргәндә үзәккә Россиянең «бердәмлеген» саклап калырга мөмкинлек бирүче шартлар куела. «Хезмәт иясе һәм эксплуатацияләнүче халыкларның хокуклар Декларациясе» нигезендә автономия тулаем милләткә түгел, бәлки «...хезмәт иясе массаларына һәм аларның вәкаләтле органнарына — Эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларына» бирелә. Россия Федерациясе «Россиядәге барлык милләтләр хезмәт иясе сыйныфларының чын мәгънәсендә азат һәм ирекле, тулы һәм нык берлеген» тәшкил итәргә тиеш була. Икенче төрле әйткәндә, рус булмаган халыкларга автономия рус үрнәгендә, сыйнфый үрнәктә төзе-

лерлек булса гына вәгъдә ителә. Инде игълан ителгән һәм игълан ителергә әзерләнгән милли-демократик республикалар законсыз дип белдереләләр.

Идел-Урал Республикасы. Татар милли хәрәкәте Идел-Урал Республикасын (Штатын) игълан итүгә озын-озак юл үтеп килә. Милли-территориаль автономия лозунгы астында ул (милли хәрәкәт) Февраль революциясен яклап чыга. Советлар «Россия халыкларының хокуклар Декларациясе»н игълан иткәннән соң милли автономияне гамәлгә ашыруга өмет яңадан да кабынып китә. 6 ноябрьдә Казанда татар милли хәрәкәте вәкилләре җыела, һәм алар үзләренең Совет хакимиятенә карата уңай мөнәсәбәттә булуларын белдерәләр, аның Оештыру җыелышын чакырырга вәгъдә бирүен хуплап чыгалар.

12 ноябрьдә Казанда Бөтенроссия Милли Шурасы, Бөтенроссия Хәрби Шурасы, Мөселман руханилары җәмгыяте, губерна Милли Шурасы, Мөселман социалистлар комитеты, Казан мөселманнарының округ хәрби комитеты, Мөселман мөгаллимнәренең үзәк һәм губерна бюролары, Мөселман хатын-кызлары бюросы, Казан Советының эшчеләр фракциясе вәкилләренең утырышы булып уза. Анда агымдагы хәл һәм милли хәрәкәт алдында торган бурычлар тикшерелә. Утырышта катнашучылар татарларга милли азчылык итеп караган Казан Советының гамәлләрен гаеплиләр. Башкортларның милли оешмалары белән берлектә уртак Милләт Мәҗлесе төзүгә карар ителә. Бу Милләт Мәҗлесе уртак республика төзү буенча Оештыру җыелышына әверелергә тиеш була.

Россиядә Совет хөкүмәте төзелүдән соң бер ай үтәр-үтмәс, 20 ноябрьдә Уфада Эчке Россия һәм Себер мөселман төрки-татарларның Милләт Мәҗлесе утырышы ачыла. Утырышта татарлар һәм башкортлар яшәгән губерналарда сайланган 110 депутатның 96 сы катнаша. Идел-Уралның тарихи территориясендә милли-территориаль автономия төзү идеясен гамәлгә ашыру мәсьәләсен тикшереп, Милләт Мәҗлесе 29 ноябрьдә кабул иткән карарында, «Идел-Урал мохтар (бәйсез) җөмһүрияте» төзү зарурлыгын таный һәм аны Идел-Урал Штаты дип атарга карар итә. Аннары шул ук карарда әлеге Штатның (Республиканың) территориясе, аның дәүләт төзелеше, статусы һәм Россия Федерациясе белән мөнәсәбәтләре алдан билгеләп куела.

Идел-Урал Республикасы составына: «Бөтен Казан губернасы, бөтен Уфа губернасы, Оренбург губернасының көнбатыш өлеше, Пермь губернасының төрки-татарлар яши торган һәм Уфа, Сембер губерналарына янәшә булган көньяк өлеше, Вятка губернасының төрки-татарлар яшәгән өлеше, Сембер губернасының Уфа һәм Казан губерналары янәшәсендәге төрки-татарлар яшәгән өлеше, Самара губернасының Казан һәм Уфа губерналары янәшәсендәге мөселман, төрки-татарлар яшәгән өлеше керәчәк»,— дип күздә тотыла. Әйтеп үтелгән территорияләр башкортлар һәм Идел буе татарлары яшәгән төбәкләрнең этник чикләренә тәңгәл килә.

Милләт Мәҗлесе милли хәрәкәтнең икенче бер таләбенә — Россияне Федерация итү таләбенә дә тугрылыклы кала. Милләт Мәҗлесе карарында болай диелә: «Идел-Урал Штаты идарә ителү рәвеше буенча демократик республика булып, башка штатлар белән берлектә Россия Федератив Республикасын тәшкил итә». Гыйнварда үтәсе Оештыру җыелышы сессиясенең Россиядә дәүләт төзелешенең нинди формасын яклаячагы, шулай ук Совет хакимиятенең нинди дәүләт төзелеше формасын кабул итәчәге бу вакытта әле билгеле булмый. Мәҗлес Россиянең Демократик Федерация булуын һәм аның составына керәчәк республикаларның да демократик республикалар булырга тиешлеген яклап чыга. Карарның 4 нче пунктында: «Гомуми, тигез, пропорциональ, турыдантуры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән сайлап куелган Идел-Урал Штаты парламенты, карарның бу пунктыннан соң килүче 5—7 нче пунктлары белән аның карамагыннан чыгарылган мәсьәләләрне исәпкә алмаганда, штатка һәм аның эчке тормышына карый торган барлык мәсьәләләрне хәл итүче бердәнбер иң югары закон чыгару органы булырга тиеш»,— диелә. Карарның 5 нче һәм 6 нчы пунктларында федераль парламент каравына тапшырылырга тиешле мәсьәләләр бәян ителә. 7 нче пунктта, республика парламенты штаттагы башка халыкларның милли эшләренә тыкшынмый, аларны хәл итүне һәрбер милләтнең Бөтенроссия милли органнарына тапшыра, диелә.

Милләт Мәҗлесенең беренче сессиясе үз эшен 1918 елның 11 гыйнварында Милли идарә һәм республиканы игълан итүгә хәзерлек буенча махсус Коллегия төзеп тәмамлый. Милли идарә составына Садри Максуди (рәис), Галимҗан Баруди (руханилар идарәсе башлыгы — мөфти), Ильяс Алкин (финанс

нәзарәте), Н. Корбангалиев (мәгариф нәзарәте) һәм башкалар керә. Коллегия составына исә Галимҗан Шәрәф (рәис), Фатих Сәйфи, Сәләх Атнагулов, Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфиннәр керә. Алар татар милли хәрәкәтенең, большевикларны да кертеп, төрле оешмалары карашларын чагылдыра.

Милләт Мәҗлесе карарларыннан күренүенчә, төзеләчәк республика, дөньяви республика булып, исламның иҗтимагый традицияләре белән бәйләнешне саклап калырга тиеш була. «Исламның татар милләте белән бергәлеге — яңа туып килә торган төрки-татар мөселман штатларының уңышлы үсеше нигезе»,— дип яза «Корылтай» газетасы. Милләт Мәҗлесе карарлары татар вакытлы матбугатында, җыелышлар һәм митингларда киң тикшерелә. Аларны яклап, хуплап та, каршы чыгып та төрле фикерләр әйтелә. Милләт Мәҗлесе материаллары һәм Коллегиянең республиканы игълан итүгә хәзерлек буенча эшчәнлеге «Корылтай» газетасында һәм «Мохтарият» журналында яктыртылып барыла.

1918 ел башында Коллегия Уфадан Казанга күченеп килә. Шәһәр ике өлешкә бүленә: большевистик Казан Советы урнашкан руслар өлешенә һәм милли республиканы хәзерләү буенча Коллегия резиденциясенә әверелгән Яңа татар бистәсенә. Казанда үзенә бер төрле ике хакимиятлелек (двоевластие) хасил була. Милли республика игълан итүгә хәзерлек эшләре биредә дә җәелеп китә. 8 гыйнвардан 3 мартка кадәр татар, башкорт солдат һәм офицерлары вәкилләренең Хәрби Шура тарафыннан хәзерләнгән II съезды эшли. Съездга килгән кунаклар арасында Украина Радасы делегациясе һәм поляк частьлары вәкиле дә була. Хәрби мәсьәләләр белән беррәттән, съезд шулай ук милли республиканы гамәлгә ашыру чараларын тикшерә.

Гыйнварда III Бөтенроссия Советлар съезды Россияне Федератив Республика дип игълан итә. Шуңа нигезләнеп хәрбиләрнең II съезды либераль канаты вәкиле Йосыф Мозаффаров республиканы «солдат, эшче һәм крестьяннарның» социаль мәнфәгатьләрен яклаучы «Идел-Урал Совет Республикасы» дип атарга тәкъдим итә. Оппонент сыйфатында чыгыш ясаган Сәхибгәрәй Сәедгалиев «Эшче, крестьян һәм солдатларның милли республикасы» дигән исемне яклап чыга. Ә тулаем алганда, Идел-Урал төбәгендә милли-территориаль автономия төзү платформасын ике як та (либераллар һәм радикаллар) хуплый. Съезд милли хәрби частьлар булдыру турындагы

тәкъдим белән дә килешә, әмма бу тәкъдимгә Сәхибгәрәй Сәедгалиевнең: бу частьлар «бөек революция, эшче һәм крестьяннар» мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә тиеш, дигән искәрмәсен өсти.

Съездның милли республика төзү һәм Хәрби Шурага буйсыначак милли хәрби частьлар булдыру турындагы компромисслы карары Казан Советына ошамый. 17 февральдә аның вәкилләре съездны ташлап чыгып китә. Үзләренең декларацияләрендә алар съездны «контрреволюцион» дип игълан итәләр һәм, Казан губернасы җирлегендә милли республика булдыруга юл куймас өчен, үз рецептларына нигезләнгән милли автономияне тормышка ашыру буенча параллель кампания башлап җибәрәләр. Казан Советы Идел-Урал төбәгендәге 10 губернаның (Түбән Новгород, Сембер, Самара, Саратов, Әстерхан, Оренбург, Уфа, Пермь, Вятка, Пенза) Советларына «Идел буе һәм Урал алды өлкәләре федерациясен» төзү һәм бу федерациядә «Аерым халыклар эшләре буенча генераль комиссарлык» оештыру юлы аша милли азчылык мәсьәләсен хәл итүне тикшерү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә.

Тарихчы М. Мөхәррәмов бу уңайдан: «Мондый автономия федерация эчендәге федерация дигән сүз булыр иде»,— дип яза. Әлеге мәсьәлә әйтеп үтелгән губерна Советларының 21—22 февральдә Казанда үткәрелгән съездларында тикшерелә. Съездга татар милли хәрәкәте вәкилләре дә чакырыла. Эш барышында фикерләр аерыла. Милли хәрәкәт вәкилләре (Ильяс Алкин, Галимҗан Шәрәф, Енбаев һ. б.) Идел-Урал Штатын яклап чыгалар. Совет вәкилләренең күпчелеге Казан авторлары (Шейнкман, Гинсбург һәм Грасис) проектын яклыйлар. «Идел буе һәм Урал алды федерациясе» төзелүне көтмичә, Казан Советы 1918 елның 26 февралендә Казан республикасын игълан итә, республиканың Халык Комиссарлары Советын төзи, аның рәисе итеп Я. С. Шейнкманны билгели.

Мөселман эшләре комиссариаты. Татар һәм башкортларның үз республикаларын булдыруга юнәлдерелгән милли хәрәкәтенең киң колач ала баруын тоеп, Ленин хөкүмәте инициативаны үз кулына алырга карар итә. 17 гыйнварда, Россия Федератив Республика дип игълан ителгәннән соң, Россия Халык Комиссарлары Советы Милләтләр эшләре халык комиссариаты каршында Мөселман эшләре комиссариаты оештыру турында Декрет кабул итә. Комиссар итеп элекке

Оештыру җыелышының Казан губернасы вәкиле Мулланур Вахитов, аның урынбасарлары итеп Оештыру җыелышының Уфа губернасы вәкиле Галимҗан Ибраһимов һәм Оренбург губернасы вәкиле Шәриф Манатов билгеләнә. Милләтләр эшләре халык комиссариаты, үз чиратында, губерна һәм өяз Советлары каршында Үзәк мөселман комиссариатының хезмәт, крестьян, хәрби, мәдәни-агарту бүлекләрен булдыру турында карар кабул итә.

Мулланур Вахитов һәм аның көрәштәшләре 7 гыйнварда Смольныйда булган озакка сузылган әңгәмә вакытында Ленинның Мөселман эшләре комиссариаты төзү хакындагы тәкъдимен кабул итәләр. Ә моңа кадәр, 1917 елның декабрендә Сталин Бөтенроссия Милли Шурасы рәисе Әхмәт Цаликов белән сөйләшүләр алып барган һәм аңа Совет хакимияте белән хезмәттәшлек итәргә тәкъдим иткән була. Сталин, унитаризм һәм мәдәни автономия позицияләрендә торучы Цаликов хезмәттәшлек өчен кулайрак кеше булыр, дип уйлый.

Татар милли хәрәкәте Цаликов позициясен кабул итми. Милләт Мәҗлесе рәисе Садри Максуди Цаликовка Сталин тәкъдимен кабул итмәскә киңәш бирә. Шуннан соң Ленин мөселман хәрәкәтенең федерализм яклы канаты вәкиле, Галимҗан Ибраһимов «Шәрыкның бөек революционеры» дип атаган Мулланур Вахитовка мөрәҗәгать итә.

Әңгәмә вакытында Мулланур Вахитов Лениннан Идел-Урал төбәгендә татар һәм башкортларның милли республикасын төзү турында Нигезләмә хәзерләүгә мандат ала. Бу милли хәрәкәт белән Совет хакимияте арасында компромисс килешүе була. Совет хакимияте татар-башкорт милли хәрәкәтенә бу территориядә милли республика төзергә ризалык бирә, ә милли хәрәкәт вәкилләре Совет хакимияте алга сөргән шартны — «Эшче-крестьян Совет республикасын оештыру» шартын кабул итәргә тиеш булалар.

Комиссариат аппаратын формалаштыру шактый тиз башкарыла. Комиссариатның басма органы — «Чулпан» газетасы чыга башлый. Россиянең татарлар һәм башкортлар яшәгән шәһәр һәм губерналарында Мөселман комиссариаты бүлекләре төзелә. Тиздән комиссариат Идел-Урал төбәгендә Татар-Башкорт Республикасы (ТБР) төзү турындагы Нигезләмә проектын эшли һәм Совет хөкүмәтенә тәкъдим итә. Милли хәрби частьлар турындагы мәсьәлә яңача хәл ителә. Россия Федерациясенең Хәрби эшләр комиссариаты, Мөселман

эшләре комиссариаты белән берлектә, март ахырында «Мөселманнарның эшче-крестьян армиясен төзү турында» уртак боерык чыгара. Бу боерыкны гамәлгә ашыру өчен Мулланур Вахитов җитәкчелегендә Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе (ҮМХК) оештырыла.

Казан Советы каршындагы Мөселман комиссариаты 1918 елның 21 февралендә Милләтләр эшләре халык комиссариатының телеграммасында күрсәтелгәнгә караганда киңрәк составта оештырыла. Аның составына Мирсәед Солтангалиев (комиссар), Сәхибгәрәй Сәедгалиев (хезмәт бүлеге), Шаһид Әхмәдиев (мәгариф бүлеге), Галиулла Хафизов һәм Камил Якуб (хәрби бүлек), Гыйззениса Таҗетдинова (хатын-кызлар бүлеге), Вәли Шәфигуллин (нәшрият бүлеге) керә. 12 мартта комиссариат органы булган «Эш» газетасы — хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасының элгәресе чыга башлый. Газета редколлегиясенә В. Шәфигуллин, Х. Урманов, К. Каспранский керә. Чистай, Тәтеш, Мамадыш һәм Лаешта комиссариатның өяз бүлекләре оештырыла. Комиссариат Идел-Урал төбәгендә милли республика төзелүне яклап чыга.

Идел-Урал Республикасын тарату. Идел-Урал Республикасын игълан итү 23 февральдә тантаналы шартларда Казанның Театр мәйданында булачак дип күздә тотыла. Ленин хөкүмәте, Казан Советына һәм төбәкнең башка Советларына таянып, бу көнне татар милли хәрәкәтенә һич көтелмәгән «һөҗүм» оештыра. 17 февральдә Казан Советы вәкилләре Мөселманнарның II Бөтенроссия хәрби съездын ташлап чыгып киткәннән соң, Идел-Урал Республикасын игълан итүне өзүгә юнәлдерелгән чараларга хәзерлек башлана. Революцион штаб (Я. С. Шейнкман, А. Г. Гинсбург) төзелә. 28 февральдә Казанда драматик вакыйгалар башлана. Казан шәһәре һәм Казан республикасы хәрби хәлдә дип игълан ителә. Мөселманнарның хәрби съездын оештыручылар — Хәрби Шура җитәкчеләре Ильяс Алкин, Йосыф Мозаффаров, Усман Токумбәтов кулга алына. Мөселман эшләре комиссариатының һәм Казан Мөселман социалистлар комитетының актив яклавы нәтиҗәсендә аларны төрмәдән чыгаралар. Съезд үз эшен дәвам иттерә. Ләкин милли республиканы массакүләм тантаналы игълан итү акты өзелә. Татарларның милли хәрәкәте милләтчеләр хәрәкәте дип, контрреволюцион хәрәкәт дип игълан ителә, аңа яла ягу башлана. Идел-Урал Республикасы «Болак арты республикасы» дип яисә «Забулачка» дип түбәнсетелә. Хәрби Шура «Тимер

дружиналар» төзегән һәм алар ярдәмендә Казанда Совет хакимиятен бәреп төшерергә җыена, дигән гайбәт таратыла. Шул ук көнне (28 февральдә) билгесез шартларда Идел-Болгар мөселманнары җәмгыяте башлыгы Гайнан Вәисев үтерелә.

Бу җәмгыять XIX гасырда рәсми мөфтияткә оппозиция буларак барлыкка килгән була. Аны Бохарада, ә аннары Иранда ислам белеме алган имам Баһаветдин Вәисев оештыра. 1883 елда җәмгыять әгъзалары патша хөкүмәте репрессиясенә эләгәләр, Себергә сөреләләр. Вәисев үзе кулга алына һәм шифаханәдә үлә. Аның Казандагы гыйбадәт йорты җимерелә. Б. Вәисев эшен дәвам иттерүчеләрне, үзләрен «хакыйкать кешеләре» дип атаучыларны 1905 елдан соң аның улы Гайнан Вәисев җитәкли. Берәүләр Гайнан Вәисевне Казан Советы органнары үтерде дип саныйлар, икенчеләре исә җаваплылыкны «ислам милләтчеләре» өстенә йөклиләр.

Казан Советы, янәсе, Совет хакимиятенә куркыныч тууы турында хәбәр итеп һәм ярдәмгә гаскәр җибәрүләре турында үтенеч белдереп, Мәскәүгә телеграмма җибәрә. Моңа җавап йөзеннән Казанга Балтыйк флоты матрослары отряды җибәрелә. Отряд Казанга 25 мартта килеп җитә. Шул ук көнне Милли идарә урнашкан Татар бистәсен гаскәрләр камап ала. Казан Советының Мәскәүгә юллаган мәгълүматларына караганда, ул вакытта Хәрби Шура карамагында 10 мең солдаттан торган гаскәр була. Татар милли хәрәкәте хәрби юл белән каршы торудан баш тарта. Татар милли частьлары Казан Советы тарафыннан гаскәрләр һәм матрослар отряды ярдәмендә оештырылган бу сәяси тамашада катнашмый. Милли идарә Совет хакимияте декреты белән таратыла. Милли хәрәкәтнең татар милли дәүләтчелеген торгызу буенча озак еллар буена әзерләнгән эше аяк астына салып таптала. Ләкин хыял һәм тәвәккәллек кала. Милли идарәнең ул вакытта әле сакланып калган рухи бүлеге (Г. Баруди, Р. Фәхреддин, Х. Урманов) хакимият органнарының тыныч милли хәрәкәтне хәрби көч кулланып бастыруына ризасызлык белдерә. Вакытлы хөкүмәт эшләргә җөрьәт итмәгәнне Совет хөкүмәте эшли.

Совет хөкүмәте Идел-Урал Республикасын куып тарату белән генә чикләнми. Үзәктә һәм урыннарда милли хәрәкәт оешмаларына, матбугат органнарына һәм эшлекләренә карата репрессия чаралары кулланыла. Мартта-апрельдә Хәрби Шураның матбугат органнары — «Бөтенроссия Мөселман

Шурасы хәбәрләре» һәм «Безнең тавыш» газеталары, татар эсерлары партиясе органы «Ил» газетасы ябыла. «Корылтай», «Йолдыз», «Кояш» (Казан), «Вакыт» (Оренбург), «Тормыш» (Уфа) газеталарын , «Аң» (Казан), «Шура» (Оренбург) журналларын һ. б. чыгару тыела. Казандагы 95 нче мөселман полкы демобилизацияләнә, Уфада һәм Оренбургта мөселман полклары таратыла, Петроградта җыелма мөселман гвардия полкы таратыла, Казанда Хәрби Шураның һәм башка шәһәрләрдәге бүлекләренең эшчәнлеге тыела.

Татар-Башкорт Республикасы. Март-апрель репрессияләре татар милли хәрәкәтенә зур зыян китерә. Идел-Урал Республикасын оештыру буенча 1905 елгы рус революциясеннән үк башланган зур эш сызып ташлана. Милли азатлыкка ирешү юлында кабат зур тырышлыклар таләп ителә. Совет хакимияте белән компромисска бару юлы никадәр генә кыен булмасын, милли хәрәкәт шул юл белән барырга, Совет хөкүмәтенең милли республиканы большевиклар рецепты буенча оештыру турындагы тәкъдиме белән ризалашырга карар итә. «Совет милли-территориаль автономиясе»нең шартлары кырыс-катгый була. Алар бердәм татар милләтен большевикларча төрле сыйныфларга бүлүне, эшче-крестьяннардан башкаларны сәяси тормышта катнашудан мәхрүм итүне, хосусый милекне бетерүне, төзелүче республикада Советныкы булмаган барлык партия һәм оешмалар эшчәнлеген тыюны, большевиклар атеизмы идеологиясен кабул итүне, РКП(б)ны бердәнбер җитәкче партия итеп тануны, үзәк Совет хакимияте диктатурасы сәясәтен кабул итүне һәм гамәлгә ашыруны таләп итә. Бу шартлар татар милли хәрәкәтен бик нык зәгыйфьләндерә. Мөселман руханилары җәмгыятен (Г. Баруди), Мөселман комитетын һәм аның органы — «Корылтай» газетасын, татар эсерлар партиясен (С. Максуди), «Хәрби Шураны» (И. Алкин) бу хәрәкәттә катнашудан читләштерәләр.

Шуңа да карамастан, М. Вахитов, Г. Ибраһимов һәм Ш. Мөнатов бу шартлар белән ризалашалар. Аларның милли хәрәкәт буенча көрәштәшләре белән принципиаль каршылыклары булган һәм бу адымга үзләренең сәяси конкурентларыннан котылу теләге белән барганнар дип ышануы кыен. Милли хәрәкәт тарихы күрсәткәнчә, милли азатлыкка ирешүнең төп мәсьәләләрендә — милләт бердәмлеген саклап калуда, Идел-Уралның тарихи территориясендә күп партияле демократик дәүләт системасыннан гыйбарәт милли республика төзүдә,

исламның рухи кыйммәтләрен саклап калуда, Россия белән союз турында — алар һәрвакыт көрәштәшләре белән бер фикердә торалар. Әмма тактикада аларның үз карашлары була. Ул вакытта татар милли хәрәкәтенең бурычлары Совет хөкүмәте ризалыгы чикләрендә генә булса да гамәлгә ашырылырга тиеш дип табыла.

Милли республика оештыруның Мөселман эшләре комиссариаты хәзерләгән проекты 22 мартта Милләтләр эшләре халык комиссариатының «Татар-Башкорт Совет Республикасы турындагы Декреты» рәвешендә матбугатта басылып чыга. Декрет Татар-Башкорт Совет Республикасын Көньяк Урал һәм Урта Идел территориясендә оештыруны күздә тота. Республика бөтен Уфа губернасын, Оренбург губернасының башкортлар яши торган өлешен Казан губернасын (чуваш-марилар яши торган өлеше кертелми), Пермь, Вятка, Сембер, Самара губерналарының мөселманнар яши торган өлешен эченә ала. Республика чикләрен тәгаен билгеләүне Республика Советларының Оештыру съезды башкарырга тиеш була. Совет хөкүмәте җитәкчесе Ленин, Татар-Башкорт Республикасы турындагы Нигезләмә белән килешеп, Казан, Уфа, Оренбург, Сембер, Пермь, Вятка, Екатеринбург Советларына шул шәһәрләрдәге Совет вәкилләрен һәм Мөселман эшләре комиссариаты вәкилләрен Татар-Башкорт Республикасы мәсьәләсен тикшерү өчен Мәскәүгә җибәрүләрен сорап телеграмма юллый.

Татар-Башкорт Республикасы оештыру турындагы мәсьәләне тикшерү буенча киңәшмә 10—16 майда Мәскәүдә үтә. Татар һәм башкорт милли хәрәкәтләре вәкилләре киңәшмәдә ясаган чыгышларында, татарларның һәм башкортларның урыннардагы милли оешмалары киңәшмә адресына җибәргән телеграммаларында Татар-Башкорт Республикасын төзү турындагы тәкъдимне яклыйлар. Татар милли хәрәкәтенең сыйнфый сәбәпләр аркасында киңәшмәгә чакырылмаган вәкилләре, Татар-Башкорт Республикасын оештыруны ярым-йорты чара итеп санасалар да, аны төзүгә каршы чыкмыйлар. Җирле Советларның киңәшмәдә катнашкан вәкилләре арасында мондый бердәмлек булмый. Карл Грасис (Казан Советы), И. Я. Тунтул һәм Ф. Ф. Сыромолотов (Екатеринбург Советы), Х. Рәмиев (Сембер Советы), әлеге Нигезләмәне гамәлгә ашыру «үзе белән халык хуҗалыгының таркалуын, һәлакәтен һәм бер үк вакытта пролетариатның да һәлакәтен алып килә», чөнки Татар-Башкорт Республикасы төзелгән очракта милли

хөкүмәт барлык урманнарны, җир асты байлыкларын, алтын приискаларын, азык-төлекне һ. б. үз кулына алачак, дип белдерәләр. Казанга кайтканнан соң К. Грасис, Советның «Знамя революции» газетасында мәкаләләр белән чыгып, аларда Татар-Башкорт Республикасын «панисламизм белән сукырайган Вахитовларның һәм Ибраһимовларның эше», дип атый.

Менә шундый каршылыклар булуга карамастан, киңәшмә Татар-Башкорт Республикасының Оештыру съездын чакыру турында карар кабул итә. Бу эшне финанслауны Милләтләр эшләре халык комиссариаты гамәлгә ашырырга тиеш була. Татар милли хәрәкәте белән Совет хөкүмәте арасындагы мөнәсәбәтләрдә Идел-Урал Республикасының таратылуы белән килеп туган киеренкелек Татар-Башкорт Республикасын төзү вәгъдә ителү сәбәпле йомшара төшә. Моннан соң инде Ленин хөкүмәтенә ашыкмаска да мөмкин була. Милләтләр эшләре халык комиссары урынбасары С. С. Петровский: «Сталин бу эш белән ашыкмаска кушты»,— ди.

Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе. Татар-Башкорт Республикасын оештыру турындагы Нигезләмә кабул ителү сәбәпле, үзен Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты итеп үзгәрткән Мөселман эшләре комиссариаты «Үзәк мөселман комиссариаты» дигән исемгә әйләнеп кайта. Мулланур Вахитов Татар-Башкорт Республикасын оештырганда, гомумән, татар милли хәрәкәтенең һәм, аерым алганда, Үзәк мөселман комиссариатының ышанычлы таянычы булырдай милли сәяси партия оештыруны максат итеп куя. Бу вакытка кадәр Үзәк мөселман комиссариаты мөселман социалистлар комитетларына (МСК) таянып эш итә. Бу комитетлар кысаларында урыннарда татар социалистлары, коммунистлары, социалист-революционерлары бергәләп хезмәттәшлек итәләр. Октябрьдән соң татар милли хәрәкәтенең бу иҗтимагый-сәяси оешмалары челтәре шактый киңәя. Совет хакимияте Коммунистлар партиясеннән кала барлык башка партияләр эшчәнлеген тыйгач, Мөселман социалистлар комитеты татарларның легаль эшли торган бердәнбер оешмасы булып кала. 1918 елның җәенә мөселман социалистлар комитетлары Казаннан тыш тагын Оренбургта (Урал Мөселман социалистлар комитеты), Архангельскида, Вологдада (бу соңгы ике шәһәрдә татар һәм башкорт солдатлары шактый күп була), Мәскәүдә, Петроград, Пермь, Самара, Сембер, Саратов, Әстерхан, Томск, Төмән һәм Ташкентта эшли. Бу мөселман социалистлар комитетлары

әлеге шәһәрләрдә җирле мөселман комиссариатларын оештыручылар була.

1918 елның мартында Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариатының һәм Казан, Мәскәү, Петроград һәм кайбер башка шәһәрләр мөселман социалистлар комитетларының инициативасы белән Россия мөселман эшчеләре конференциясе булып уза. Анда Татар-Башкорт Республикасы турындагы Нигезләмәне гамәлгә ашыру хакындагы һәм бу уңайдан яшәп килгән мөселман социалистлар комитетлары җирлегендә сәяси партия төзү хакындагы мәсьәлә тикшерелә. Конференция беренче этапта җирле мөселман социалистлар комитетлары эшчәнлеген координацияләү өчен Үзәк мөселман социалистлары комитеты (ҮМСК) һәм аның Башкарма Комитетын булдырырга карар итә. Башкарма Комитет рәисе итеп социалист Мулланур Вахитов, аның урынбасары итеп коммунист Сәхибгәрәй Сәедгалиев сайлана. «Кызыл байрак» газетасы ҮМСК органы дип игълан ителә. Үзәк мөселман социалистлар комитеты оешу татар милли хәрәкәтен совет платформасында консолидацияләү юлында мөһим адым була. Үзәкләштерелгән ике орган — Үзәк мөселман комиссариаты һәм Үзәк мөселман социалистлар комитеты Татар-Башкорт Республикасы турындагы Нигезләмәне гамәлгә ашыру юнәлешендә бергәләп эшли башлый.

Яңа милли партиянең нигезенә дә беренче таш салына. Инде булган җирле мөселман социалистлар комитетларын мөселман социалистлар-коммунистлар комитетлары итеп үзгәртергә карар ителә. Үзәк мөселман социалистлар комитетына һәм аның Башкарма Комитетына Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясенең программасы проектын хәзерләргә һәм партиянең оештырылуын игълан итү өчен махсус конференция чакырырга кушыла. Мөгаен, Мулланур Вахитов бу партияне совет платформасында торучы, РКП(б)га автоном буларак кушылучы, РКП(б) белән федератив мөнәсәбәтләрдә торучы милли партия дип күз алдына китергәндер.

Конференция РКП(б)ның VII съездында Ленин докладында бәян ителгән РКП(б) программасының баштагы проектын хуплый. Бу хуплау очраклы хәл түгел. Әле бу вакытта программаның үзе булмый. Ленин тәкъдим иткән «Партия программасын яңадан карап чыгу өчен материаллар»да демократик Россия республикасы Конституциясе тәэмин итәргә тиеш булган нәрсәләр санап чыгыла. Бу исемлекнең 9 нчы

пунктында болай диелә: «Дәүләт составына кергән барлык милләтләргә ирекле рәвештә аерылып чыгу һәм үз дәүләтен оештыру хокукы бирелә. Рус халкы республикасы башка халык һәм кавемнәрне үзенә көчләү юлы белән түгел, бары тик уртак дәүләт төзү турында ирекле килешү юлы белән җәлеп итәргә тиеш». Конференциядә катнашучылар, мөгаен, Татар-Башкорт Республикасының, башка милли республикалар кебек үк, «рус халкы республикасы белән» хезмәттәшлеккә шул ук принципларда җәлеп ителәчәгенә ышанганнардыр. Табигый ки, Татар-Башкорт Республикасының милли-территориаль автономия статусы халыкның сәяси, социаль-икътисади, мәдәни һәм рухи тормышының милли характерда булуын тәэмин итә алган булыр иде. Соңрак, Татарстан АССРны оештыру уңаеннан, Россия Федерациясенең Милләтләр эшләре халык комиссариаты вәкиле С. Диманштейн, 1918 елда, ТБР турында мәсьәлә куелганда, «сүз социалистик республика оештыру турында түгел, бары тик Совет Республикасы оештыру турында гына барды», дип яза. Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе программасы проекты ТБРның бу үзенчәлеген чагылдырырга тиеш була.

Россия Мөселман Коммунистлар партиясе. Россия мөселман эшчеләренең март конференциясе карарлары нигезендә 1918 елның июнендә мөселман социалистлар-коммунистлар комитетлары вәкилләре Татар-Башкорт Республикасын игълан итүгә хәзерлек инициативасын үз кулына алырдай сәяси партия төзү турындагы мәсьәләне тикшерү өчен Казанга җыелалар. Бу конференциянең эшендә Казан, Мәскәү, Архангельск, Петроград, Пермь, Самара, Сембер, Саратов, Әстерхан мөселман социалистлар-коммунистлар комитетларыннан 25 делегат катнаша.

Бу вакытка Россиядә вазгыять аеруча катлаулана. Яңа гына дөнья сугышыннан чыккан ил киң масштаблы гражданнар сугышы алдында кала. Совет хөкүмәте һәм РКП(б) диктатураны кырыслаталар. Татар милли хәрәкәте алдында яңа кыенлыклар туа. Хөкүмәт Үзәк мөселман комиссариатының Кызыл Армияне тугрылыклы татар-башкорт хәрби частьлары белән тәэмин итүгә кучүен таләп итә. 31 майда комиссариатның Хәрби бүлеге Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе итеп үзгәртеп корыла. Аның рәисе итеп билгеләнгән Мулланур Вахитов бөтен игътибарын башлыча Мөселман Кызыл Армиясе частьларын туплауга юнәлдерергә мәҗбүр

була. 14 июньдә Ленин һәм Вахитов барлык мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгатькә кул куялар. «Кадерле иптәшләр, әгәр сез зур газаплар белән туып килүче Татар-Башкорт Республикасының ирекле гражданнары булырга теләсәгез, ...мөселман социалистлары армиясе байрагы астына ашыгыгыз»,— диелә анда. Мулланур Вахитов, мөгаен, әлеге татар-башкорт хәрби частьлары киләчәктә Россия Совет Федерациясе составындагы җитәрлек дәрәҗәдә мөстәкыйль булган Татар-Башкорт Республикасының терәген тәшкил итәрләр, дип өметләнгәндер.

Үзәк мөселман комиссариаты һәм Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясендә эшләү Мулланур Вахитовка бу конференцияне чакыру мәсьәләләре белән шәхсән шөгыльләнергә мөмкинлек бирми. Конференцияне чакыру инициативасын Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясенең Мирсәед Солтангалиев җитәкчелегендәге Казан комитеты үз өстенә ала. Татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләреннән берсенә әверелгән Мирсәед Солтангалиев милли азатлыкка ирешүне Октябрьдән соң хакимияткә килгән Ленин партиясе белән бәйләвен яшерми. 1917 елның декабрендә «Кояш» газетасында басылып чыккан «Редакциягә хат»ында үзенең большевиклар белән хезмәттәшлеге турында: мин алар тирәсендә ялагайлану өчен йөрмим, мине алар янына халкыма булган мәхәббәтем тарта. Алар янына мин большевиклар эшенең халык эше икәнлегенә бар җаным белән ининганга күрә йөрим, дип яза.

Стратегик мәсьәләләрдә конференция март позицияләрендә кала, ә партиянең исеме турындагы мәсьәләдә бу позициядән читләшә. Агымдагы хәл һәм милли хәрәкәтнең бурычлары турындагы мәсьәләне тикшереп, мөселман социалистлар-коммунистлар комитетларын мөселман коммунистлар комитетлары (МКК) итеп үзгәртеп коруны һәм аларны Россия Мөселман Коммунистлар партиясенә (РМКП) берләштерүне яклап чыга.

Моннан алда үткәрелгән конференциядә кабул ителгән «Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе» дигән исем оешма кысаларында милли хәрәкәттә катнашучыларның киңрәк катлауларын, ягъни эшче, крестьян, солдатларны гына түгел, урта катлауларны да берләштерергә мөмкинлек бирер иде. «Коммунистлар» дигән исем исә партиянең социаль нигезен тарайта. Бәлки бу очракта конференция Совет

хакимиятенең Россия Федерациясендә Коммунистлар партиясеннән гайре башка партиянең булуына түзеп тора алмаячак дигән караштан чыгып эш иткәндер. Соңрак «Коммунистлар партиясе» дигән исем астында милли партияләрнең оешуы практикасы Россиянең башка төбәкләрендә дә кабатлана. Төркестанда, мәсәлән, Төрки Коммунистлар партиясе барлыкка килә. Еврей Коммунистлар партиясе оештырыла.

Конференция делегатлары фикеренчә, РМКП, автономияле милли партия буларак, киләчәктә РКП(б) белән федератив мөнәсәбәтләргә керергә тиеш. М. Солтангалиев, М. Вахитов, Х. Гайнуллин, М. Дулат-Али, Б. Мансуров, И. Рәхмәтуллин (Үзәк Комитет әгъзалары) һәм Ш. Измайлов, Х. Садриев, Н. Яруллин (Үзәк Комитет әгъзалыгына кандидатлар) составында РМКП Үзәк Комитеты сайлана. Март конференциясе юлыннан атлап, делегатлар РКП(б) программасының башлангыч проектын хуплыйлар.

Казан конференциясендә игълан ителгәннән соң, РМКП тагы да киңрәк танылу таба, Татар-Башкорт Республикасын оештыру ягында торучылар арасында йогынтылы көч булып әверелә. Аның җирле мөселман коммунистлары комитетларында коммунистлар, социалистлар, сул социалист-революционерлар элеккечә үк иңгә-иң эшлиләр. Партиягә яңа әгъзалар кабул итү җиңеләйтелә, социаль, дини чикләүләр бетерелә. Үзәк мөселман комиссариаты белән хезмәттәшлек итеп, РМКП эшче, крестьян, солдат, укытучы, хезмәткәрләрне, вак һәм урта эшмәкәрләрне, түбәнге катлау ислам руханиларын үзендә берләштергән милли хәрәкәттә үз урынын таба. РМКП Үзәк Комитеты документларына караганда, 1918 ел азагына партиянең җирле комитетлары Петроград, Архангельск, Мурманск, Рыбинск, Мәскәү, Түбән Новгород, Пермь, Оренбург, Пенза, Тамбов, Самара, Сембер, Тәтеш, Чистай, Донбассның милли армия частьлары каршында һәм мөселман комиссариатларында эш итә. Алар, башлыча, җирле татар һәм башкорт халкы арасында, бу районнарда урнашкан хәрби частьларның татар һәм башкорт солдатлары арасында эш алып баручы 21 мең партия әгъзасын берләштерә. Татар телендә 12 газета нәшер ителә. Җирле комитетлар эшендә зур урынны гражданлык хокукларын һәм Татар-Башкорт Республикасын оештыруның әһәмиятен аңлату алып тора. Алар шулай ук татар-башкорт милли хәрби частьларын оештыруда катнашалар.

Россиядә гражданнар сугышы. Октябрь перевороты вакытында оттырган, ә соңрак Оештыру җыелышында да реванш ала алмаган социалист-революционерлар, кадетлар, меньшевистик юнәлештәге социал-демократлар, Совет хакимиятен танырга теләмәгән хәрби даирәләр белән берләшеп, 1918 елның җәенә тәмам тупланып бетәләр. Куып таратылган Оештыру җыелышы әгъзаларыннан альтернатив рус хөкүмәтенең нигезе сыйфатында Оештыру җыелышы комитеты (Комуч) төзелә. Фетнәче генералитет Ак армия оештыра һәм рус тәхетенә дәгъва итүче үз хөкүмәтен (генерал Деникин хөкүмәтен һәм соңрак адмирал Колчак хөкүмәтен) булдыра. Совет хөкүмәтенең бу оппозициясе Россиянең сугыштагы элекке союзниклары ярдәменә таяна.

Совет хакимияте белән оппозиция арасындагы компромисска булган өмет РСФСР Конституциясе кабул ителгәннән һәм сул эсерлар Совет хөкүмәте составыннан куылганнан соң бөтенләй югала. Конституциянең беренче бүлеген «Хезмәт иясе һәм эксплуатацияләнүче халыкның хокуклар Декларациясе» тәшкил итә. Бу Декларация концепциясен тирәнәйтә барып, Конституциянең икенче бүлеге хәзерге Россия күчеш моментын кичерә һәм хакимиятнең бурычы: «Буржуазияне тулысынча бастыру һәм социализм урнаштыру максатларында, шәһәр һәм авыл пролетариатының, ярлы крестьяннарның куәтле Бөтенроссия Совет хакимияте рәвешендәге диктатурасын кертүдән гыйбарәт»,— дип аңлата. Россия — федератив дәүләт, дип әйтеп үтүдән тыш Конституциядә бу федерациянең асылы һәм формалары турында бер нәрсә дә әйтелми. 9 нчы статья Россияне «барлык милләт хезмәт ияләренең теләктәшлегенә нигезләнгән» үзәкләштерелгән республика дип тәкъдим итә. Бу гражданнар сугышында катнашучы якларның һәр икесе, гомуммилли мәнфәгатьләрне, Россиянең дә, рус халкының да ахыр чиккәчә көчсезләнү ихтималын бөтенләй онытып, соңгы тамчы кангача көрәшәчәкләрен белдерә.

Татар халкы гражданнар сугышында. Россиядәге гражданнар сугышы татар милли хәрәкәтен дә үз даирәсенә тартып кертә һәм аңа бик тә зарарлы йогынты ясый. Ул үз ихтыярыннан башка, русларның үзара сугышучы ике хәрби-сәяси көче арасында кала. Бу көчләрнең һәр икесе милли хәрәкәтне үз ягына кыстый. Татар милли хәрәкәте үз чиратында икегә аерыла. Милли хәрәкәтнең либераль канаты акгвардиячеләр лагерена кушыла. Башкортларның сәяси һәм хәрби эшлек-

лесе Зәки Вәлиди үзенең милли гаскәрләре белән Башкортстанны кызылгвардиячеләрдән азат итү өчен Колчакның акгвардиячеләре белән иңгә-иң торып сугыша. Совет хакимияте куып тараткан Милләт Мәҗлесе, Милли идарә составына кергән татар сәяси эшлеклеләренең бер өлеше, Хәрби Шура офицерлары, шулай ук Идел-Урал Республикасын куып тарату барышында Совет хакимияте тараткан татар-башкорт милли хәрби частьларының күп кенә офицер һәм солдатларының бер өлеше Оештыру җыелышы комитеты, ә соңрак Колчак хөкүмәте ягында калалар.

Совет хакимиятенең татар халкына Татар-Башкорт Республикасы (ТБР) рәвешендә милли-территориаль автономия бирү турындагы вәгъдәсе белән бәйләнгән милли хәрәкәтнең социалистик канаты сугышка Кызыл Армия ягыннан кушыла. Мулланур Вахитов, Милләтләр эшләре халык комиссариатының коллегия әгъзасы сыйфатында, Ленин кул куйган мандат белән «икмәк хәзерләү һәм озатып тору өчен» Казан губернасына җибәрелә. Биредә, Колчак тарафдарлары кулына төшкән Казанда, ул 1918 елның 19 августында әлегә ачыкланмаган шартларда үтерелә. Милләтләр эшләре халык комиссариаты коллегиясенең икенче бер әгъзасы, Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясенең рәисе итеп билгеләнгән Мирсәед Солтангалиев Кызыл Армия өчен татар-башкорт милли частьларын туплау һәм аларны Совет хакимияте өчен барган сугышларда катнаштыру өчен фронтка җибәреп тору белән шөгыльләнә.

Шунысы бар: милли хәрәкәтнең һәр ике канаты уртак максат өчен — милли азатлыкка ирешү өчен көрәшә. Либераллар, Ак гвардия җиңгән очракта, Россия конституцион монархия яисә демократик республика дип игълан ителер, татарлар һәм башкортларның милли демократик республикаларын булдыру өчен мөмкинлекләр яңадан ачылыр, дип өметләнәләр. Социалистлар һәм коммунистлар исә Советлар җиңеп чыккан тәкъдирдә Татар-Башкорт Республикасының гамәлгә ашырылачагына исәп тоталар.

Милли республика төзү татар милли хәрәкәтенең Россиядәге гражданнар сугышында катнашуының бердәнбер максаты булмый. Дәүләтчелек рухында тәрбияләнгән татар халкы үз өстенә йөкләнгән дәүләт йөкләмәләрен һәрвакыт намус белән үтәп килә. Дөнья сугышына карата тәнкыйди караштa торсалар да, татар солдатлары һәм офицерлары ул сугышта бирелгән антларына тугры калалар. Алар әлеге гражданнар сугышында

да яңа Россия дәүләтенең киләчәген үзләренчә күзаллаган хәлдә катнашалар. Үзенең иң якын күршесе рус халкы белән уңай мөнәсәбәтләрне саклап калу да татар халкы өчен мөһим нәрсә була. Хакимият органнары тарафыннан үткәрелеп килгән милли изү сәясәтен катгый рәвештә кире какса да, ул үзенең сәяси ризасызлыгын, гомумән, рус халкына күчерми. Татар халкы Февраль революциясендә рус халкы сайлаган юлга ихтирамлы була. Октябрь революциясенә дә ул рус халкы сайлаган юл итеп карый. Татар милли хәрәкәтендәге социалистлар (М. Вахитов) һәм коммунистлар (М. Солтангалиев) җитәкләгән совет юнәлеше әнә шуның аркасында барлыкка килә дә.

Россиядәге гражданнар сугышы фронтларында Кызыл Армия составында халык җырларында җырланган ике легендар татар бригадасы: Беренче Аерым Идел буе татар укчы бригадасы (командиры — Ю. М. Ибраһимов, комиссары — Шамил Усманов) һәм Икенче Аерым Идел буе татар укчы бригадасы (командиры — Х. А. Мөхетдинов, комиссары — Г. К. Әлмөхәмәдов) сугыша. Болардан тыш аерым татар батальоннары һәм махсус частьлары Көнбатыш, Көнчыгыш һәм Көньяк фронтлардагы күп кенә армияләр составында сугышларда катнаша. Бу частьлар өчен командирлар составын хәзерләүдә 1919 елның башында Казанда оештырылган мөселман курсларының (курслар мөдире — генерал-майор Искәндәр Тальковский) роле зур була. Татар хәрби частьлары Ак армия сафларында да оешкан төстә катнашалар. Үз чиратларында, алар да ирекле Татарстанның киләчәге өчен, Россия җәмгыятендә социаль һәм милли гаделлек тантанасы өчен көрәшүләренә ышаналар. Татар милли хәрәкәтенең бу өлеше шулай ук милләт алдындагы үз бурычын үти. Шул ук вакытта күп кенә татар милли хәрәкәте эшлеклеләре татар хәрби частьларын Урта Азиядә җирле милли хәрәкәтләрне бастыруда Кызыл Армия сафларында катнашу өчен җибәрүне хупламыйлар.

ТАТАРСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛҮ

Социалистик ориентация. Россия империясе составында озак еллар, гасырлар буена «туземецлар», «инородецлар» сыйфатында, ә соңрак «милли азчылык» булып яшәгәннән соң, Идел буе татарларының төрле рус губерналары арасында

бүленгән милли территорияләрен бергә җыю өчен реаль мөмкинлек ачыла. Бу татар халкы тарихында исәп буенча өченче «милли тупланыш» була. Безнең халыкның борынгы милли-дәүләти берлеге IX—XV гасырлардагы Идел буе Болгарында гәүдәләнеш таба. Ул вакытта безнең бабаларыбыз болгарлар алдынгы халыкларның берсе буларак халыкара аренага чыгалар. XV гасырда Көнчыгыш Европадагы Алтын Урда империясе таркалганнан соң, Идел буе татарларының милли-дәүләти берләшмәсен Казан татарлары дәүләте (Казан ханлыгы) гәүдәләндерә. «Татар җирләрен җыю»ның өченчесе XX гасыр башларына туры килә һәм ул, Идел-Урал Демократик Республикасын (Идел-Урал Штатын) һәм Татар-Башкорт Совет Республикасын оештыру омтылышы уңышсызлыкка очраганнан соң, 1920 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү рәвешендә мөмкин була.

Татар милли хәрәкәтенең европачыл демократизм позициясеннән Россия коммунизмы позицияләренә күчүе, башлыча, иң якын күрше рус халкының гамәлләре белән аңлатыла. Рус коммунистларының бернинди компромиссыз басымы астында Россия халкы социалистик экспериментка риза була. Ул чакта С. Сәедгалиев Россия Федерациясен «Дәү апа» дип атый. Социализмга юнәлеш алган татар милли хәрәкәте бер үк вакытта Татарстанның булачак автономиясен «коммунистлар йотуыннан» сакларга тырыша.

Россия Мөселман Коммунистлар партиясенең I съезды. Россия Мөселман Коммунистлар партиясен (РМКП) төзү игълан ителүне Совет хакимияте, РКП(б) Үзәк Комитеты һәм аның урыннардагы комитетлары өнәмичә каршы алалар. Дәүләт төзелеше буенча федерациягә ризалашсалар да, алар партиянең үзендә федерация булу мөмкинлеген кискен рәвештә кире кагалар. Совет хакимияте федерациядә бер партияле система булуын яклый, дәүләттә бердәнбер Коммунистлар партиясе хакимлеген генә таный. РКП(б) рәтләрендә составы һәм программасы милли характерда булган оешмалар рөхсәт ителми. Шуңа да карамастан, РМКП җитәкчеләре РКП(б) Үзәк Комитеты белән, Ленин хөкүмәте белән үзара аңлашуга ирешергә исәп тоталар. Нәкъ шушы максат белән РМКП съездын чакырырга карар ителә. Съезд 1918 елның ноябрендә Мәскәүдә эшли. Аның эшендә Әстерхан, Азиево, Басьяновский, Васильсурск, Инсар, Казан, Корсунь, Мәскәү, Мурманск, Түбән Новгород, Пенза, Пермь, Петроград, Рыбинск, Саратов,

Самара, Сембер, Тәтеш, Тамбов, Уфа, Чистай шәһәрләренең татар-башкорт мөселман коммунистлар комитетларыннан делегатлар катнаша. Кунаклар сыйфатында съездда Азәрбайҗан «Һиммәт» оешмасы, Кырым, Төркия коммунистлары вәкилләре була.

Делегатлар партия Үзәк Комитеты (Мирсәед Солтангалиев) отчетын тыңлыйлар һәм съезд вазифаларын билгеләүгә күчәләр. Делегатларның күпчелеге партиянең Россия мөселман эшчеләренең Мәскәүдә булып үткән март конференциясе билгеләгән һәм РМКПның Казанда булган июнь конференциясе яклаган статусын, ягъни федератив башлангычларда РКП(б) составына керүче автономияле милли коммунистик оешма буларак билгеләнгән статусын хуплый һәм, шуңа нигезләнеп, съездны да шушы партия органы итеп танырга тәкъдим итә. Съездда РКП(б) Үзәк Комитеты вәкиле сыйфатында чыгыш ясаган Сталин Россиядә автономияле милли коммунистик оешманың яшәве РКП(б) Үзәк Комитеты һәм Совет хакимияте өчен кабул ителмәслек нәрсә дип белдерә. РКП(б) Үзәк Комитеты фикерен бәян итеп: «Татар коммунистлары үз партияләрен РКП(б) Үзәк Бюросы җитәкчелегендә эшли торган милли секциягә үзгәртергә тиешләр»,— ди ул. Съездның карары башкача булган очракта, Совет хакимиятенең РМКПны бөтенләй таратачагы көн кебек ачык була.

РКП(б) Үзәк Комитеты таләбе буенча съезд РМКПны бетерү белән ризалаша, ләкин җирле коммунистлар комитетларының мөстәкыйльлеген саклау позициясендә кала. Бу комитетлар «РКП(б)ның мөселман оешмалары» дип атала башлыйлар. РКП(б) мөселман оешмаларының Үзәк Бюросы булдырыла. Съезд резолюциясе нигезендә РКП(б)ның мөселман оешмалары РКП(б)ның җирле оешмалары белән параллель рәвештә эш итәләр, үз әгъзаларын мөстәкыйль рәвештә теркиләр һәм әгъзалык взносларын мөстәкыйль җыялар. Партиягә кабул иткәндә керүчеләргә карата сыйнфый һәм дини мәсьәләләрдә рус партия әгъзаларына караганда җиңеләйтелгәнрәк таләпләр куела. Бу оешмалар агымдагы милли тормыш куйган бурычларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәләр. Бу бурычларның иң мөһимнәре яңа хәрби частьлар туплаудан һәм милли республика оештырудан гыйбарәт була.

Съезд РКП(б)ның мөселман оешмалары Үзәк Бюросын сайлый. Соңрак, РКП(б) Үзәк Комитетында расланган вакытта, съезд карарларына кайбер үзгәрешләр кертелә. Гәрчә чынында

алай булмаса да, съезд Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмаларының (КХКО) I съезды дип атала башлый. Үзәк Бюроның штаб-квартирасы Мәскәүдә, РКП(б) Үзәк Комитеты каршында була. Үзәк Бюро И. Сталин, М. Солтангалиев, Х. Юмангулов (Кече Башкортстан, ягъни Уфа губернасы кертелмәгән башкорт җирләре), Г. Ялымов, К. Якубов (Үзәк Бюро әгъзалары), И. Рәхмәтуллин, Н. Яруллин, М. Коннов, М. Дулат-Али (Үзәк Бюро әгъзалыгына кандидатлар) составында раслана. Үзәк Бюро составына шулай ук ул вакытларда Россия Федерациясендә эш иткән «Һиммәт» дигән Азәрбайҗан коммунистлары оешмасы вәкилләре Б. Сардаров һәм Д. Буниатзадә дә кертелә. Сентябрь аеннан бирле РМКП органы сыйфатында Казанда чыгып килгән «Эшче» газетасы Үзәк Бюро органы дип игълан ителә һәм Мәскәүдә чыгарыла башлый. Бу вакытта Үзәк мөселман комиссариаты каршында нәшер ителгән 17 газета (шуларның 15-е татар телендә) РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыкларының коммунистлар оешмалары (КХКО) Үзәк Бюросы карамагына күчерелә.

Совет милли сәясәтендәге үзгәрешләр. 1919 елның азагына Совет хакимиятенең гражданнар сугышында өстен чыгуы тәмам ачыклана. Рус халкы Совет Республикасы ягына авыша. Совет хакимияте исә, моңа җавап итеп, Россия Федерациясе йөзендә рус дәүләтчелеген ныгыта. Бер яктан караганда бу процесс аңлаешлы һәм аңлатырлык та. Совет хакимияте хакына күп көч сарыф иткән һәм күп корбаннар биргән рус халкы милли берләшүгә һәм дәүләти күтәрелешкә лаек. Ләкин бу адымның иске рецептлар буенча башкарылуы, рус булмаган халыкларны яңача кимсетүләр бәрабәренә эшләнүе тарихи яктан акланмый һәм кешелеклелек ягыннан гадел булмый. Совет хакимиятенең милли сәясәттә мондый борылыш ясавыннан Октябрьдән соң Совет хакимиятенә йөз белән борылган һәм Россиядәге гражданнар сугышында бихисап корбан биргән татар милли хәрәкәте аерата зур зыян күрә.

1919 елның октябрендә РКП(б) Үзәк Комитеты күрсәтмәсе буенча эшләнгән «РКП(б) комитетлары каршында азчылык милләтләр арасында агитация һәм пропаганда бүлекләре оештыру турындагы Нигезләмә проекты» игълан ителә. Бу проектта татар халкы «Россия Федерациясендә рус халкы көрәштәше» булудан «милли азчылыклар» дәрәҗәсенә төшерелә. Татар коммунистлары оешмаларын, «РКП(б)ның милли

оешмалары» статусыннан мәхрүм итеп, аларга «РКП(б) җирле комитетының татар милли азчылыгы арасында эш алып бару буенча милли секциясе» статусы бирергә тәкъдим ителә.

Үзенең бу планын тормышка ашыру өчен РКП(б) Үзәк Комитеты Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмаларының II Бөтенроссия съездын чакырырга карар итә. Аңа, 1918 елдагыча татар һәм башкорт коммунистлар оешмалары вәкилләре генә түгел, Көнчыгыш халыкларының — Төркестанның һәм ул вакытта Россия Федерациясе составына кермәгән Азәрбайҗанның, Хива һәм Бохараның коммунистлар оешмалары вәкилләре дә чакырыла. 1919 елның 22 ноябреннән 3 декабренә кадәр булып үткән съезд эшендә 82 делегат катнаша. Съездны Сталин ача һәм котлау сүзе белән Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты (БҮБК) Рәисе М. И. Калинин чыга. Съезд эшенең беренче көнендә үк Ленин агымдагы хәл турында доклад ясый. Делегатларга мөрәҗәгатенең асылын ул РКП(б) белән «кушылырга» дигән бер сүз аша аңлата. «Сезгә,— ди ул,— революцион көрәштә, революцион хәрәкәттә зур роль уйнарга һәм халыкара империализмга каршы көрәштә безнең белән кушылырга», «гомуми көрәштә башка илләрнең пролетарийлары белән кушылырга» туры килер.

Съезд алдыннан үткәрелгән башлангыч киңәшмәдә, ә соңыннан съездның үзендә дә большевик лидерлары «Россия халыкларының хокуклар Декларациясе» турында, анда халыкларның үзбилгеләнүгә һәм суверенлыкка хокуклары бәян ителгәнлеге турында ләм-мим бер сүз дә әйтмиләр, «рус республикасының» Россиядәге рус булмаган халыклар белән берлеге турындагы элекке белдерүләрен гүя оныталар. «Үзара бәйләнеш» түгел, Совет хакимиятенең бу халыкларның «милли үзенчәлекләрен» бер яклы, ягъни Совет хакимияте тарафыннан гына исәпкә алынуы тәкъдим ителә. Ленинның әлеге киңәшмәдәге чыгышының матбугатта игълан ителгән тезисларыннан күренгәнчә, ул Советларга «*һәрбер милләтнең конкрет* мәсьәләләрен аның үсеш дәрәҗәсенә, аның үзенчәлекләренә һ. б. карап» хәл итү зарурлыгын күтәрә. Советларның милләтара партнерлыктан ваз кичүгә, рус булмаган аерым халыкларның милли үзенчәлекләрен һәм милли ихтыяҗларын Үзәктән торып кына билгеләү, шуңа карап милли республикаларны дәрәҗәләргә бүлү — Советларның яңа милли сәясәте әнә шулай аңлатыла.

Мондый милли сәясәтне гамәлгә ашыру өчен милли республикаларны мөстәкыйль сәяси партияләрдән, хәтта коммунизмга йөз тотканнарыннан да мәхрүм итәргә кирәк була. Шуңа күрә съездда Көнчыгыш халыкларының коммунистлар оешмалары статусы турында Сталин тарафыннан игълан ителгән, бу оешмаларны РКП(б)ның җирле оешмалары белән тулысынча кушуны күздә тотучы РКП(б) Үзәк Комитеты тәкъдиме һәм М. Солтангалиев керткән икенче тәкъдим йөзгә-йөз киләләр. Үзенең съезддагы чыгышында М. Солтангалиев Көнчыгыш халыкларының милли республикаларында автономияле берәмлекләр сыйфатында РКП(б) составына керүче һәм үз республикаларының милли ихтыяҗларын мөстәкыйль рәвештә билгеләүче милли коммунистлар оешмалары төзүне кабат яклап чыга.

М. Солтангалиевнең тәкъдиме делегатларның күпчелегендә яклау тапса да, РКП(б) Үзәк Комитеты вәкилләре аны катгый рәвештә кире кага. Ләкин съездга Көнчыгыш халыкларының коммунистлар оешмаларын РКП(б)ның җирле комитетлары белән тулысынча бергә кушу турындагы тәкъдимне көчләп тагарга маташу да барып чыкмый. Съезд Көнчыгыш халыкларының коммунистлар оешмалары Үзәк Бюросының яңа составын сайлый. Татар коммунистлары секцияләренең РКП(б) җирле комитетларына карата мөстәкыйльлек статусы саклану Татарстан Автономияле Республикасын оештыруны хәзерләүдә уңай йогынты ясый.

Татарстан Автономияле Республикасы турындагы Нигезләмә проекты. Башкорт милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе Зәки Вәлиди инициативасы белән һәм аның катгый таләбе буенча Башкортстан Республикасы (Кече Башкортстан) игълан ителгәч, Татар-Башкорт Республикасы турындагы Нигезләмәнең гамәлдәге вариантын тулаем тормышка ашыру мөмкин булмый. Татар милли хәрәкәте алдында милли автономия турында яңа Нигезләмә эшләү бурычы килеп баса. Дәвамчанлыкны да сакларга, үзгәргән вазгыятьне дә исәпкә алырга кирәк була.

Идел-Урал Республикасы (С. Максуди, И. Алкин, Г. Баруди) тамырдан аграр реформа үткәрелергә, хосусый милек һәм хосусый эшмәкәрлек сакланырга тиешле, үз парламенты, гаскәре, мөфтияте булган демократик республика итеп планлаштырыла. Күп партияле сәяси системасы һәм үз гражданлыгы булган Идел-Урал Республикасы Россия белән федератив

мөнәсәбәтләргә керергә тиеш иде. Татар-Башкорт Республикасы исә (М. Вахитов, Г. Ибраһимов, М. Солтангалиев) Россия Совет Федерациясе белән федератив мөнәсәбәтләргә керә торган Совет Республикасы буларак планлаштырыла. Республиканың үз милли партиясе — социалистлар-коммунистлар партиясе, үз парламенты, үз гаскәрләре, үз гражданлыгы булырга тиеш иде.

Татарларның милли автономиясе турындагы яңа Нигезләмә татар коммунистлары (М. Солтангалиев, С. Сәедгалиев, Б. Мансуров) тарафыннан партия дисциплинасы кысаларында эшләнә. Аларның үзләре белән күзгә-күз әңгәмә вакытында Владимир Ленин төзелә торган республика биришле генә социалистик (хакимият бары тик хезмәт ияләре кулында гына) һәм бары тик атеистик (руханилар бөтенләйгә читләштерелә) булырга тиеш дип билгели.

Оештырылмый калган Татар-Башкорт Республикасы урынына Татарстан Республикасы төзү турындагы мәсьәлә Казан губернасы һәм башка губерналар җәмәгатьчелеге арасында тикшерелә. 1919 елның 12 октябрендә Казан коммунистлары оешмаларының җаваплы хезмәткәрләре үзләренең киңәшмәләрендә, М. Бурундуков тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасы оештырылуны яклап чыгалар. Шул ук елның 4 ноябрендә татар коммунистларының Казан губерна конференциясе Казан губернасы һәм ул вакытта әле Башкортстан Республикасы составына кермәгән Уфа губернасы чикләрендә Татарстан Республикасы төзү турында карар кабул итә. Республиканы төзү турындагы Нигезләмә проекты Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмаларының Үзәк Бюросы исеменнән рәсми рәвештә Россия хөкүмәтенә тәкъдим ителә. Проект нигезендә Республика составына Казан губернасының татар районнары, Уфа губернасының Башкортстан Республикасы чикләренә кермәгән, татарлар һәм башкортлар яши торган өлеше (Казан һәм Уфа шәһәрләрен дә кертеп), шулай ук Самара, Сембер, Вятка һәм Пермь губерналарының татарлар яши торган этник территорияләре кертелә. Бөтен бу территориянең мәйданы 123 мең квадрат километр булып, халкын 4900 мең кеше тәшкил итә. Шулардан татарлар һәм башкортлар 2678 мең, руслар 1750 мең, башка милләт вәкилләре (чувашлар, марилар, удмуртлар) 500 мең чамасы кеше. Киләчәктә, милли оешу барышында, башкортлар, чувашлар, марилар һәм удмуртлар үзләренең милли-территориаль автономияләрен мөстәкыйль рәвештә хәл итәчәкләр, дип күздә тотыла.

Совет хөкүмәте, үз чиратында, Үзәк Бюро проектын губерна Советларына җибәрә һәм аларга бик кыска срокта үз фикерләрен белдерергә тәкъдим итә. Проектны тикшерү барышында ике төрле фикер әйтелә. Казан губернасы җитәкчелеге (губерна Башкарма Комитеты рәисе И. И. Ходоровский, РКП(б)ның губерна комитеты секретаре Г. С. Гордеев, губерна профсоюзлары советы рәисе А. И. Догадов), татарлар арасында «республиканы идарә итүне тапшырырга мөмкин булырдай әзерлекле коммунистлар» булмауны сылтау итеп, Татарстан Республикасын оештыруга каршы чыгалар. Татарларның милли хәрәкәте вәкилләре Проектны хуплыйлар. Аерым алганда, татар коммунистлары оешмаларының 1920 елның 22 мартында булып үткән 2 нче Казан губерна конференциясе шундый резолюция кабул итә.

Проект өстендә алга таба эшләү өчен С. Сәедгалиев, М. Солтангалиев (Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмаларының Үзәк Бюросыннан) һәм К. Егоров (Россия Федерациясе Эчке эшләр халык комиссариатыннан) составында ведомствоара комиссия оештырыла. Комиссия составына экспертлар сыйфатында Г. Енбаев, Г. Шәрәф, И. Фирдәвес чакырыла. Комиссия эш барышында проектка җитди үзгәрешләр кертә. Аерым алганда, Эчке эшләр халык комиссариаты вәкиленең таләбе буенча республика составына Уфа губернасыннан бары тик Минзәлә өязен генә кертү карала. Проектның бу варианты Татарстан Республикасын Казан губернасының, чувашлар һәм марилар яши торган 5 өязен кертмичә, калган 12 өязе составында оештыруны күздә тота. Республика составына өстәмә рәвештә Самара губернасыннан Бөгелмә өязенең 26 волосте, Вятка губернасыннан Малмыж өязенең 7 волосте, Сембер губернасыннан Сембер өязенең 3 волосте, Буа өязенең 10 волосте кертелә. Республиканың территориясе — 67,8 мең квадрат километр, ә халкы 2900 мең кеше исәпләнә, шуларның 51 процентын татарлар, 39,2 процентын руслар тәшкил итә. Бу территория татар халкының тарихи ватаны булган Идел-Урал буендагы чын территориясеннән шактыйга ким. Татар халкының яртысыннан артыгы һәм татар халкы җирләренең шактый өлеше рус губерналары составында калдырыла.

Менә шул хәлендә Татарстан Республикасын оештыру турындагы Нигезләмә проекты 1920 елның 27 маенда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Россия Федерациясе Халык Комиссарлары Советы карары белән раслана.

Милли территориянең менә шулай шактый киселгән булуына һәм татар халкының яртысыннан артыгының, милли азчылык хәлендә, аның милли дәүләтчелеге чикләреннән читтә калдырылуына карамастан, татар җәмәгатьчелеге Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Россия Федерациясенең Халык Комиссарлары Советы Декретын уңай кабул итә. Татар халкының үз дәүләтчелеген торгызу турындагы 400 ел буе күңелендә кадерләп саклап килгән хыялы нигездә әнә шул вакыттан гамәлгә ашырыла башлый.

Республиканың статусы һәм хакимият структурасы. Татар халкы тарафыннан 1920 елда гамәлгә ашырылган милли-территориаль автономияне югарыдан торып чикләнгән, совет тибындагы автономия дип атарга мөмкин. Бу автономия татар милли хәрәкәте белән федераль үзәк арасындагы компромисс нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Татар милли хәрәкәте Татарстан территориясенең бер өлешендә ТАССР төзүгә һәм Татарстан территориясенең калган өлешендә татар милли-мәдәни автономиясен гамәлгә ашыруга ризалык бирә. Федераль үзәк, үз чиратында, татар халкының милли-территориаль автономиягә һәм милли-мәдәни автономиягә хаклы булуын таныган хәлдә, автономиянең һәр ике формасы, параллель рәвештә, нигездә татар милли хәрәкәте тарафыннан гамәлгә ашырылачагы белән ризалаша.

Республиканың статусы һәм хакимият структурасы Совет хакимияте Декреты (27 май, 1920 ел) белән билгеләнә. Бу Декретта болай диелә: «Татарстан Автономияле Социалистик Совет Республикасын Россия Федератив Социалистик Совет Республикасының өлеше итеп оештырырга». (1918 ел Конституциясендә билгеләнгән «Социалистик Совет Республикасы» төшенчәсе, 1922 елда СССР төзелгәч, «Совет Социалистик Республикасы» дип үзгәртелә.) Автономияле республиканың дәүләт хакимияте аппараты РСФСР Конституциясе нигезендә җирле Советлар, Үзәк Башкарма Комитетыннан һәм Халык Комиссарлары Советыннан оеша. Почта һәм телеграф идарәләре булган Эчке эшләр халык комиссариатын, Юстиция, Мәгариф, Сәламәтлек саклау, Социаль тәэминат, Җир эшләре, Азык-төлек, Финанс халык комиссариатларын, Эшче-Крестьян инспекциясен, Хезмәт һәм юл эшләре бүлекләре булган Халык Хуҗалыгы Советын булдыру күздә тотыла.

Декретта автономиянең сферасы һәм күләме билгеләнә. Эчке эшләр (почта һәм телеграфны кертмичә), Юстиция,

Мәгариф, Сәламәтлек саклау, Социаль тәэминат һәм Җир эшләре халык комиссариатлары үз гамәлләрендә турыдан-туры Республика Үзәк Башкарма Комитеты (ҮБК) алдында җаваплы итеп билгеләнәләр. Бу халык комиссариатларының тиешле федератив органнар белән үзара бәйләнеше махсус эшләнгән нигезләмәләргә һәм шартнамәләргә туры китереп гамәлгә ашырыла. Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты «Татарстан Автономияле Социалистик Совет Республикасы идарәсен оештыру турында», «ТАССРның эчке сак гаскәрләре турында» махсус декретлар кабул итә, «Татарстан Республикасында халык мәгарифе турындагы Нигезләмә»не раслый. Бу Нигезләмәдә, мәсәлән, республика хөкүмәте, Россия Федерациясе Мәгариф халык комиссариаты белән килештереп, өяз халкының ким дигәндә 10 процентын тәшкил иткән милли азчылыклар (чувашлар, марилар һ. б.) өчен булган мәктәпләр белән эш итәргә тиешле махсус бүлек булдыра, дип күрсәтелә. Казан университеты, рус университеты буларак, федерациянең Мәгариф халык комиссариаты карамагында калдырыла. Аның каршында «җирле тарих, археология, этнография һ. б. кафедралары булган, җирле телләр дә, Көнчыгыш телләре дә укытылачак край факультеты» ачу күздә тотыла. Федерация Мәгариф халык комиссариаты йөкләмәләренең Татарстан Республикасы Мәгариф халык комиссариаты өчен дә мәҗбүри булуы искәртелә.

Азык-төлек, Финанс халык комиссариаты, Халык Хуҗалыгы Советы, Хезмәт һәм юл эшләре бүлеге, Эшче-Крестьян инспекциясе, Почта һәм телеграф идарәсе Федераль халык комиссариатларының турыдан-туры буйсынуында торалар. Федерация республиканы кирәкле финанс средстволары һәм техника белән тәэмин итүне үз өстенә ала. Чит илләр белән бәйле эшләр, тышкы сәүдә, хәрби эшләр тулысынча федераль хакимият органнары карамагында кала. Хәрби эшләрне алып бару өчен Округ хәрби комиссариатына буйсынучы Татарстан хәрби комиссариаты төзелә. Контрреволюциягә каршы көрәш Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (ВЧК) карамагында кала.

Республиканың федератив хакимият вертикаленә буйсынуының күрсәтеп үтелгән шартларына тагын республикада эш итүче, әмма бары тик РКП(б) Үзәк Комитетына гына буйсынучы РКП(б) өлкә комитетының һәм аның шәһәр, өяз, волость, предприятие һәм учреждениеләрдәге җирле комитетлары контроле өстәлә. Менә шулай элек гомуми кулла-

ныштa булган «автономия» (мохтарият, бәйсезлек) төшенчәсе урынына федерация күләмендә үзәкләштерелгән РКП(б)ның катгый контроле астына куелган «совет автономиясе» төшенчәсе барлыкка килә. Республика хакимиятенең (закон чыгару, башкару, суд) теләсә кайсы дәрәҗәдәге теләсә кайсы органының теләсә кайсы карары бары тик РКП(б) (Татарстан өлкә яки җирле) комитеты хуплавыннан соң гына көченә керә ала. Кадрларны билгеләүдә дә шундый ук тәртип саклана.

ТАССР Ревкомы. Федерациянең ТАССРны оештыру турындагы карарыннан соң Казан губерна хакимияте дә бу мәсьәләгә карашын үзгәртә, ул республикада хакимият структурасын төзүдә татар милли хәрәкәте белән хезмәттәшлек итәргә ризалык белдерә. ТАССРны оештыру буенча Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты (БҮБК) 10 июньдә раслаган Вакытлы Революцион Комитет Сәхибгәрәй Сәедгалиев (рәис), Кәрим Хәкимов, Исхак Казаков, Кашаф Мохтаров (татар милли хәрәкәте), И. И. Ходоровский, А. И. Бочков, Б. И. Гольдберг (РКП(б)ның Казан губерна комитеты) составында оештырыла. Республика партия җитәкчелеге РКП(б) Казан губерна комитеты кулында кала, аның исеме генә РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты дип үзгәртелә. Аның составына Сәхибгәрәй Сәедгалиев тә кертелә. Татарстандагы татар коммунистлары секцияләрен 25 июньнән таратырга карар ителә.

Татар эсерлар партиясе һәм татар сул эсерлар партиясе тыелганнан соң, РКП(б)ның татар коммунистлары оешмалары татар милли хәрәкәтендә милли сәяси традицияләрне бердәнбер дәвам иттерүчеләр булып кала. 1918 елның июнендә үткәрелгән Казан конференциясеннән соңгы чор эчендә алар татар җәмгыятендә йогынтылы көчкә әверелергә өлгерә. 1920 елның 22 мартында узган II Казан конференциясе ачылу көненә татар коммунистлары оешмалары Тәтеш, Алабуга, Чистай, Лаеш, Апас, Зөя, Мамадыш, Краснококшайск өязләрендә эшли. Казанда шәһәр оешмасыннан тыш шәһәр районнарындагы оешмалары, шулай ук Россия Федерациясенең Казанда урнашкан Запас армия оешмасы була. Аларга бу конференциядә сайлап куелган татар коммунистлары оешмаларының Губерна Бюросы җитәкчелек итә. Аның составына И. Казаков (рәис), Н. Яруллин, И. Фирдәвес, С. Баимбәтов, Ш. Усманов керә. Татар коммунистларының Казан губерна оешмасы Татарстан Республикасын хәзерләүнең бу этабында массалар арасында сәяси эш алып баручы төп көч була.

Татар коммунистлары оешмаларын тарату ТАССРны төзү эшенә тискәре йогынты ясый. Татар милли хәрәкәте киләчәккә милли ориентирларны мөстәкыйль рәвештә билгеләргә, автономияне тулырак гамәлгә ашырырга һәм массалар арасында сәяси эш алып барырга тиешле сәяси оешмасыннан мәхрүм ителә. Үз вакытында ТАССР төзелүгә каршы чыккан РКП(б) Казан губерна комитетының республикада бердәнбер партия комитеты буларак күтәрелүе җитәкче кадрлар арасында башта ук таркалу тудыра, аларны автономияне тулырак гамәлгә ашырырга тырышучы (дәүләт аппаратында эшләүчеләр) һәм бу курска электән үк каршы килгән РКП(б) губерна комитетының элекке составында эшләүчеләргә аера. РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, татар хезмәткәрләрен «уңнарга» һәм «сулларга» аеру юлы белән, федераль хакимият алдында аларның абруен төшерү, «уңнарын» да, «сулларын» да республиканы советча идарә итәргә сәләтсез милләтчеләр итеп күрсәтергә тырыша.

Автономияле Татарстан Республикасын игълан итү. Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы Татарстан Советларының Казанда булып узган I Оештыру съездында (1920 елның 26—27 сентябре) игълан ителә. Ә моңа кадәр Республиканы игълан итү турындагы мәсьәләне тикшергән, җирле Советларны кабат сайлаган һәм Советларның өяз съездларына делегатлар күрсәткән авыл һәм волость съездлары уза. Август ахырында һәм сентябрь башында, шундый ук көн тәртибе белән, республика съездына делегатлар сайлаган өяз съездлары була. Республика оешуын профсоюзлар, хатын-кызлар һәм яшьләр оешмалары, эшчеләр һәм крестьяннар җыелышлары яклап чыга. Республиканың тиешенчә нигезләнмичә расланган чикләре милли хәрәкәтнең күп кенә вәкилләрен канәгатьләндерми. Татарстан Республикасы оештырылуга каршы ризасызлык белдерүләр дә булмый калмый. Республиканың Халык Хуҗалыгы Советы рәисе М. Г. Рошаль «күңелне кайтара торган ямьсез күренеш»нең шаһиты булуын, халык төркеменең Воскресенский урамына күтәрелүен, «Рус халкы кабат татарлар кабаласына бара»,— дип шашынып кычкырган тавышлар ишетелүен исенә төшереп яза. Ләкин мондый хәлләр күп булмый. Татарстандагы руслар Республика оештыруны яклап чыгалар, һәм бу хәл түбән катлауларда татар-рус бердәмлеге яшәгәнлекне күрсәтә.

Съезд эшендә 348 делегат катнаша, аларның 152 се татарлар, 167 се руслар була. Съезд республиканың закон чыгару, башкару, контрольлек итү, боеру (Үзәк Башкарма Комитеты — ҮБК) һәм башкару, боеру (хөкүмәт — Халык Комиссарлары Советы) органнарын сайлый. Сайлау вакытында Советларда урыннарның өчтән ике өлеше коммунистларныкы булырга тиеш, дигән Үзәк хакимият бөтен Россия өчен билгеләгән кагыйдә үтәлә. Татарстанның Үзәк Башкарма Комитеты 59 кеше составында сайлана. Әгъзаларның яртысыннан артыгын татарлар тәшкил итә. Алар арасында милли хәрәкәтнең күренекле вәкилләре С. Сәедгалиев, М. Солтангалиев, Б. Мансуров, Т. Гайнуллин, Х. Гайнуллин, Н. Яруллин, М. Коннов, Ш. Ибраһимов, М. Ендаков, В. Шәфигуллин, З. Баимбәтова, Г. Касыймов, Г. Баһаветдинов, Ш. Усманов, К. Хәмзин һ. б. бар. 7 кешедән торган Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы (рәис — Борһан Мансуров, Президиум әгъзалары — Самохвалов, Таняев, Денисов, Яруллин, Коннов, Х. Гайнуллин) сайлана. Халык Комиссарлары Советы 15 кеше (рәис — Сәедгалиев) составында сайлана.

Съезд республика хөкүмәтенең социаль-икътисади һәм мәдәни-агарту программасын (җир мәсьәләләре һәм азыктөлек мәсьәләләре, халыкның сәламәтлеген саклау) билгели торган карарлар, шулай ук дәвам итүче гражданнар сугышына бәйле рәвештә республиканың йөкләмәләре (гомуми хезмәт йөкләмәсе һәм җигүле транспорт бүлеп бирү, татарларның милли хәрби частьларына өстәмә мобилизация үткәрү) турындагы мәсьәләләр буенча махсус карарлар кабул итә.

ТАТАРСТАН СОВЕТЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДА

ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕНДӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Дөньяда геосәяси вазгыять. Татарстан автономиясе урнашу дөньядагы шактый мөһим үзгәрешләр фонында бара. 1919—1920 елларда беренче бөтендөнья сугышына йомгак ясаучы солых шартнамәләре төзелә. Дөньяда яңа геосәяси вазгыять барлыкка килә. Индустриаль цивилизация бу сугышта үзенең матди, рухи һәм кеше потенциалының шактый өлешен югалта. Физик һәм рухи яктан гарипләнгән, «югалган буын» дип аталган зур төркем кешеләр пәйда була.

Сугыш әйдәп баручы державалар арасында тупланган каршылыкларны бетерә алмый. Моннан соң бу каршылыклар башка төрле сәбәп белән, башка төрле идеологик нигезләмә алып, башка яссылыкта үсә башлый. Европаның җиңеп чыккан илләре, АКШ ярдәмендә, традицион капитализм юлыннан китә һәм дөньяның калган өлешенә дә шул ук юлны көчләп тага башлый. Көнбатыш дөньяның сугыштан иң нык зыян күргән, халыклары тәмам бөлгенлеккә төшкән илләре сәясәтче-экспериментчыларның тәҗрибә ясау мәйданына әверелә. Россия исә, марксистик интернациональ социализм төзәчәге турында игълан итеп, мондый юлга барысыннан да элегрәк баса. Тиздән Италия, җәберләнгән, мәхрүм ителгән итальяннарны «Фашино» («Бәйләм») оешмалары җитәкчелегендә берләштереп, хәерчелектән чыгару юлын сайлый. Беркадәр соңрак Германиядә дә национал-социализм хакимлек итә башлый.

Дөнья яңадан үзара дәгъвалар объектына әверелә. Капитализмны социализм белән алмаштырырга теләве турында белдереп, Россия дөньяда беренчелеккә радикаль дәгъва белән чыга. Җир йөзендә яңа тәртип урнаштырырга омтылуы турында игълан иткән Германиянең дәгъвалары дөнья өчен

тагын да куркынычрак була. АКШның һәм аның союзникларының сугыштан соң үзләре урнаштырган ирекле эшмәкәрлек тәртипләре нигезләрен теләсә нинди кул сузулардан якларга әзер торулары турындагы белдерүләре дә шактый катгый була. Америка Кушма Штатлары 1934 елга кадәр Россияне һәм ул төзегән Советлар Союзын танырга теләми. Төзелгән солых шартнамәләрен үтәүнең нәтиҗәле юлларын табу, гомумтанылачак иминлек, куркынычсызлык системасын булдыру дөнья бергәлеге кулыннан килми. Нибары 20 елдан соң ук кабынып киткән икенче дөнья сугышының сәбәпләре инде ул вакытта ук Җир шарының бүлгәләнгән булуында, телгә алынган дәгъваларда чагыла. Халыкларның гаять зур тырышлыгы нәтиҗәсендә ирешелгән беренче дөнья сугышыннан соңгы икътисади һәм мәдәни тотрыклылык, яуланган фән-техника казанышлары чираттагы бөтендөнья сугышы мичендә кабат яндырыла.

Ике дөнья сугышы арасындагы чорны бөек державалар тарихы гына дип әйтеп булмый. Дөнья бергәлеге яңа дәүләтләр һәм дәүләт оештырылмалары белән тулылана. Алар, дөнья вакыйгалары барышын үзгәртә алмасалар да, Европа һәм дөньядагы тарихи процессларга йогынты ясый башлый. 1918 елда, Австро-Венгриядә булган революция Австрия, Венгрия, Чехия һәм Словакияне республика сыйфатында мөстәкыйль үсеш юлына чыгара, Европада демократик тенденцияләрне көчәйтә. Россиядә самодержавие империясенең юкка чыгуы анда яшәгән рус булмаган күп кенә халыкларга дәүләт булып оешу мөмкинлеген ача. Татарстан да шундыйлар арасында була.

Республика буларак формалашу перспективасын гамәлгә ашыруда Татарстан үзенең күптәнге дәүләтчелек тәҗрибәсенә генә түгел, күршедәге дәүләтләр — Чехия, Словакия, Азәрбайҗан тәҗрибәсенә дә таяну мөмкинлеге ала. Татарстан 1920 елда Мостафа Кемальнең хакимияткә килүеннән соң Төркиядә башланган милли тергезелүгә яңача карый башлый. Ул чакны Мостафа Кемаль паша Төркиянең яңа сайлап куелган Бөек Милли Мәҗлесе Рәисе итеп билгеләнә. 1923 елда Төркия территориясе оккупантлардан чистартыла. Киң сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни реформалар барышында, 1923 елда Төркия республика дип игълан ителә. 1924 елда Конституция кабул ителә, һәм аның нигезендә Мостафа Кемаль Ататөрек республиканың Президенты итеп сайлана.

СССР төзелү. Октябрьдәге дәүләт перевороты көннәрендә «Россия Демократик Республикасы» дигән атама «Россия Совет Республикасы» дигәне белән алыштырыла. Ул вакытта әле большевиклар унитар дәүләт строе позициясендә тора. Владимир Ленин уйлаганча, Финляндия, Польша (ә бәлки тагын кайсы да булса өлгереп җиткән милли территория), үзбилгеләнү хокукы нигезендә, бәйсезлек алырга тиеш була. Россиянең калган территориясендә, дип фараз кыла ул, милли мәсьәлә, «хәзерге заманның хуҗалык тормышы» таләпләрен искә алып һәм бу гамәлне «халыкның милли составына мөмкин кадәр» яраштырып, илнең административ-территориаль бүленешен яңадан карап чыгу юлы белән хәл ителәчәк. Димәк, ул әле большевикларның 1913 елда ук тәгъбир ителгән милли программасына тугрылыклы кала. Әлеге программада болай диелә: «Дәүләттә халыкның тормыш-көнкүреш яисә милли составы үзенчәлекләре белән аерылып торган барлык өлкәләр үзидарәдән һәм автономиядән файдаланырга тиешләр...»

1918 елда Россияне федерация дип игълан итү большевиклар өчен катлаулы һәм киеренке вакытка — Оештыру җыелышын куып тарату көннәренә туры килә, һәм бу рус булмаган халыкларның милли хәрәкәтләре таләпләренә ташлама ясау мәҗбүриятеннән чыгып эшләнә. «Россия Федерациясе» формуласының эчтәлеге һәм аны гамәлгә кую механизмы ул вакытта әле ачылып җитмәгән була. Рус булмаган халыкларның суверен милли республикалары оештырылу шартларында Ленин Россиянең бердәмлеген саклап калу һәм рус милли республикасын аерып күрсәтми генә рус милли дәүләтен ныгыту мәсьәләләренә җавап эзли.

Тиздән мәсьәләне хәл итү юлы табыла. Милли совет республикалары, суверен дәүләтләр буларак, Россия Федерациясе белән ике яклы шартнамәләр төзи. Әлеге республикаларның Россия Федерациясе белән конфедерацияне хәтерләтә торган берлеге (союзы) барлыкка килә.

1922 елда бу конфедератив союз бердәм Советлар Союзы (СССР) итеп үзгәртелә. Моңа кадәр яшәп килгән ике яклы дәүләтара шартнамәләр гомуми Союз шартнамәсе белән алыштырыла. Барлык суверен социалистик республикалар өчен уртак булган Союз шартнамәсе алга таба федерализмның аерым бер формасына — социалистик федерализмга күчәргә мөмкинлек бирә. Социалистик федерализмда федератив форма

унитаризм эчтәлеге белән кушыла. СССР Конституциясендә мондый дәүләт «бердәм союз дәүләте» дигән исем ала.

СССР төзелү турындагы Декларация Советларның I Бөтенсоюз съездында (1922 ел, 30 декабрь) кабул ителә. Шул ук көнне Союз шартнамәсенә кул кую тантанасы була. Россия Федерациясе Халык Комиссарлары Советы фактта Союз хөкүмәтенә әверелә. Ленин СССР Халык Комиссарлары Советы Рәисе итеп сайлана һәм шул ук вакытта Россия Федерациясе Халык Комиссарлары Советы Рәисе постын да саклый. Бер үк вакытта СССР Халык Комиссарлары Советы Рәисе һәм Россия Федерациясе Халык Комиссарлары Советы Рәисе вазифасын Ленинга алмашка килгән А. И. Рыков та 1929 елга кадәр алып бара.

Совет автономиясе статусы. Татар милли хәрәкәте беренчеләрдән булып Россиянең федерация булырга тиешлеге һәм бу федерациядә татарларның автономияле дәүләтчелеге турындагы мәсьәләне күтәрә һәм 1905 елгы рус революциясе вакытыннан алып бу максатка ирешергә омтыла. Бу юлда ул Россия хөкүмәтләре — патша хөкүмәте, Вакытлы хөкүмәт, Совет хөкүмәте — тарафыннан иң кискен каршылыкка очрый. Соңгы мизгелдә, 1920 елда Россия Федерациясенең Халык Комиссарлары Советы комиссиясе (И. Сталин — милләтләр эшләре халык комиссары, М. Владимирский — эчке эшләр комиссары, С. Сәедгалиев — татар милли хәрәкәте эшлеклесе) Татарстан Автономияле Республикасын төзү турында яңа республиканы башка Совет Республикалары белән чагыштырганда бер дәрәҗәгә түбәнрәк куючы декрет проекты эшли. Украина, Белоруссия, Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Грузия кебек милли республикалар, шулай ук Россиянең элекке протекторатлары булган Бохара, Харәзем шартнамәле Совет Республикасы статусы ала. Алар Россия Федерациясе белән мөнәсәбәтләрен 1920—1921 елларда төзелгән шартнамәләр нигезендә билгели. Бу республикалар Союз составыннан чыгу хокукына ия суверен республикалар буларак конституцион статус алалар.

Татарстанның шартнамәле республика статусы алу турындагы үтенече кире кагыла. Федератив форма сакланган хәлдә Россия дәүләтчелегенең унитар эчтәлеген көчәйтү юлларын эзләүне дәвам иттереп, большевик җитәкчеләр *Совет федерациясенең ике формасы: шартнамәле республикалар федерациясе һәм автономияле республикалар федерациясе*

турындагы постулатны алга сөрәләр. Башкортстан белән Татарстан «Автономияле Совет Социалистик Республикасы» дип билгеләнгән республикалар рәтендә кала. Россия Федерациясе Конституциясе бу милли республикаларны гадәттәге рус административ-территориаль берәмлекләренә (өлкәләргә) тиңли һәм аларга «автономияле республика үзенчәлекләрен искә алу» кебек өстәмә хокуклар бирә. Россия Федерациясе Конституциясе аларны милли дәүләт итеп танымый. Алар дәүләт суверенлыгыннан файдаланмый, Россия Федерациясе составыннан ирекле чыгу хокукына ия булмый. Әлеге «автономияле республика үзенчәлекләрен» дә, аларга ярашлы тиешле сәясәтне дә, үзәкнең гомуми күрсәтмәләреннән чыгып, РКП(б) өлкә комитеты билгеләргә тиеш була. Хәтта партия өлкә комитетлары секретарьлары арасында да, автономияле республикалар хокукы — милли хәрәкәтләргә вакытлыча бирелгән ташламалар гына, дигән караш өстенлек итә.

1921 елның июлендә С. Сәедгалиев Ленинга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә: «1. Россия Совет Федерациясендә, гомумән, вак автономияле республикаларның яшәве һәм аерым алганда Татарстанның яшәве зарурмы?

2. Зарур булса, күпме вакытка, яисә, башкача әйткәндә, нинди бурычларны үтәгәнгә кадәр һәм нинди максатларга ирешкәнгә кадәр?..»

Ленин сорауларга кыска гына итеп: «Әйе. Әле озакка»,— дип җавап бирә.

РКП(б)ның XII съездында С. Сәедгалиев Ленинның бу сүзләрен ТАССРны саклап калу файдасына әйтелгән дип аңлатма бирә. «Хәзер инде,— ди ул,— беркайчан да, бернинди шартларда да бер милләтне икенчесеннән аермаган һәм бернинди автономияле республиканың да булуы мөмкин түгел, дип сөйләнгән кешеләрнең хаксызлыгы аңлашыла». Бераз соңрак, 1925 елда Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты сессиясендә ясаган чыгышында ВКП(б) өлкә комитеты секретаре И. Т. Морозов, үз чиратында, үзтәнкыйтьле булырга тырышып: «Хәзер инде милли республикаларның ни өчен әле озак яшәргә тиеш булуын барыбыз да аңлый»,— дип белдерә.

Союз шартнамәсе һәм Татарстан. Гражданнар сугышы тәмамлану белән хөкүмәт Россиядә икътисади сәясәтне либеральләштерү турында игълан итә. Тоталь национализацияләү сәясәтен (хәрби коммунизмны) хуҗалык тормышында вак һәм урта хосусый эшмәкәрләр катнашуына юл куючы һәм

дәүләт контроле астында базар мөнәсәбәтләре үсүенә мөмкинлек бирүче яңа икътисади сәясәткә (*нэпка*) алмаштыру күздә тотыла. Совет капиталистлары (яңа буын хосусый эшмәкәрләрне ул вакытта шулай атыйлар) пәйда була. Алар сәүдәне җанландырып җибәрергә, сугыш һәм революция нәтиҗәсендә җимерелгән сәнәгатьне торгызырга ярдәм итә. Яңа урта сыйныф формалаша башлый. Акча системасы тотрыклылана. Экспроприацияләнгән һәм бөлгенлеккә төшкән капиталистлардан, көн күрер нәрсәсе калмаган интеллигентлардан һәм хәтта эмиграциянең бер өлешеннән торган килешмәс оппозиция даирәләрендә Советка карата мөнәсәбәт бераз йомшара. Россияне чит илләр таный башлый.

Бер үк вакытта большевикларның лидерлары Россиядә милләтара мөнәсәбәтләрнең либеральләшүе, икътисади тормышта көтелгән яңалыклар турында сөйли башлый. Мондый перспективалар Татарстанда милләтне җимерүче сыйнфый көрәштән котылуга, Татарстанның Союзда суверен республика дәрәҗәсенә күтәрелүенә мөмкинлек тудырыр дип кабул ителә. 1921 елдагы күп кенә чыгышларында, шул исәптән РКП(б)-ның X съездында ясаган чыгышында да, М. Солтангалиев, федераль үзәктә Татарстан вәкиле буларак, Татарстанның хокукларын киңәйтергә һәм статусын күтәрергә тәкъдим итә. Аның бу тәкъдиме СССР төзелү эшендә Татарстанны оештыручы республикалар (республики-учредители) дәрәҗәсендә катнаштыру максатын күздә тота.

Бу акыллы тәкъдимне шартнамәле республикалар яклап чыгарлар да, милли республикаларның бердәм фронты барлыкка килер кебек тоела. Ләкин кергән тәкъдимнәрне өйрәнү һәм аларга бәя бирү өчен махсус төзелгән В. В. Куйбышев җитәкчелегендәге комиссия аны «милләтчелеккә тайпылу» дип, ягъни партиянең стратегик линиясенә каршы килә дип бәяли һәм катгый рәвештә кире кага. Үзе тарафыннан исә комиссия Союз дәүләтен төзмәскә, ә Россия Федерациясенең үзен шартнамәле республикаларны үз составына кабул иткән һәм аларга бу федерациянең автономияле республикалары статусын биргән Союз дәүләтенә әверелдерергә тәкъдим итә. Ләкин мондый «тигез хокуклылык» бу юлы шартнамәле республикаларның лидерларына ошамый.

Украина хөкүмәте рәисе Х. Г. Раковский Украинаның суверенитетын бозуларга бик нык каршы чыга. Белоруссия, Грузия вәкилләре дә бик катгый рәвештә үз республикала-

рының суверенитеты саклануын таләп итәләр. Оештырылып килүче Союзны коткару өчен, авыру хәлендәге Ленин Союзны шартнамәле республикаларның суверенлыгы сакланган хәлдә төзү турында игълан итәргә мәҗбүр була. Ул Татарстан куйган таләпне яклап маташмый. Шартнамәле республика суверенлыкларыннан мәхрүм итү белән өркетеп, милли республикаларның мөмкин булган бердәм фронтын булдырмый калуы белән РКП(б) да тантана итә ала. Татарстанга исә Союз шартнамәсенә кул кую хокукы гына бирелә. Советларның I Бөтенсоюз съезды эшендә Татарстан һәм Татарстаннан читтә яшәүче татар халкы вәкилләре — Милләтләр эшләре халык комиссариаты каршындагы Үзәк татар-башкорт комиссиясе рәисе М. Х. Солтангалиев, Татарстан хөкүмәте рәисе К. Г. Мохтаров, Татарстан Республикасы Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе Р. Ә. Сабиров һәм башкалар катнаша.

Татар милли хәрәкәте эш иткән ике мәйдан. Татар җәмгыяте милли дәүләтчелеген XVI гасырда югалткан булса да, Россиядә үзенең социаль-икътисади һәм мәдәни берлеген саклап кала. 1920 елда Татарстанның Россия хакимияте Декреты белән тарихи территориясе чикләнгән Татарстан АССР төзелү татар җәмгыятен ике төрле дәүләт структурасы: автономияле татар дәүләт структурасы һәм Россиянең күп кенә губерналарындагы дәүләт структуралары арасында бүлә.

Татарстан АССРда татар милләтенең бер өлеше башка милләт вәкилләре белән берлектә автономияле дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра башлый. Рәсми төстә Россия Федерациясе составына кертелгән Татарстан АССР асылда Советлар Союзын оештыручыларның берсе буларак эш итә. Татарстан автономиясен дәүләт юнәлешендә оештыруны хәзерләү органы булган Үзәк мөселман комиссариаты үзенә йөкләнгән бурычларны үти һәм үзенең урынын Татарстан АССРның хакимият органнарына бирә.

Татарстан тарихи территориясенең һәм татар җәмгыятенең икенче бер өлеше күршедәге рус губерналары чикләрендә кала. Татар халкының бу өлешендә, милли тормышны ничек оештырырга һәм татар милләтенең бердәмлеген саклауны һәм ныгытуны ничек тәэмин итәргә, дигән яңа проблема барлыкка килә. Шулай итеп, социаль-мәдәни бурычларны үтәүче татар милли хәрәкәтенә эш итәр өчен Татарстан АССРдан тыш тагын бер мәйдан ачыла. Бу төбәкләрдә аерылып калган гомумтатар милли хәрәкәте көчләре оеша. Җирле татарларның милли-

мәдәни автономиясен гамәлгә ашыру алар җилкәсенә төшә. Бу оешмаларны милли хәрәкәтнең күренекле эшлеклесе Мирсәед Солтангалиев җитәкли. 1921 елның 1 гыйнварында Солтангалиев инициативасы белән Мәскәүдә Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмаларының Бөтенроссия киңәшмәсе җыела. Мөселман халыкларының милли республикалары төзелү сәбәпле (Татарстан һәм Башкортстан Республикаларын да кертеп), моннан элек төзелгән Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмалары Үзәк Бюросы эшчәнлеге туктатыла. Киңәшмәдә милли республикалары территорияләреннән читтә калган төрки халыклар (нигездә татарлар һәм башкортлар) коммунистлар оешмаларының (секцияләренең) эшчәнлегенә җитәкчелек итү һәм аны координацияләү өчен яңа Үзәк Бюро төзелә. Шул ук елның маенда ул татар һәм башкорт коммунистлары секцияләренең Үзәк Бюросы итеп үзгәртелә. Үзәк Бюро М. Солтангалиев, Ш. Ибраһимов, М. Таһиров, Г. Дәүләтшин, Ш. Измайлов составында сайлана. Мәскәүдә Үзәк Бюро органнары булган «Эшче» һәм «Игенчеләр» газеталарын һәм «Кызыл Шәрык» журналын чыгару дәвам итә. Губерналардагы секцияләр дә үз газета һәм журналларын чыгаралар. Эшчәнлек өчен ике мәйданы һәм ике төрле оешмасы булган (Татарстан милли дәүләтчелеге һәм татар милли-мәдәни автономиясе) бердәм милли хәрәкәтнең саклануы татар милләте бердәмлеген саклап калырга һәм ныгытырга мөмкинлек бирә.

Россиядә гражданнар сугышы чорында, бигрәк тә аның тәмамлануы этабында татар халкының шактый өлеше эмиграциягә китә. Эмиграцияне нигездә Россиядә акгвардиячеләр хәрәкәтендә катнашкан татар офицерлары, Оештыру җыелышының таркатылуы акты белән ризалашмаган татар сәяси эшлеклеләре, ягъни әлеге җыелыш әгъзалары, коммунистик идеология белән килешмәгән татар зыялылары, хуҗалык итү сферасыннан көчләп куылган татар эшмәкәрләре тәшкил итә. Аларның эмиграциядә барлыкка килгән оешмалары Россиягә һәм Татарстанга көчләп тагылган социалистик экспериментлан ризасызлык белдерәләр. Аларның күбесе Россиядә большевиклар хакимиятенең тиздән җимереләчәгенә ышана һәм татар милли үсешенең альтернатив юлын тәкъдим итә. Шулай итеп, чит илләрдә (Көнчыгышта — Маньчжуриядә, Көнбатышта — Төркиядә, Германиядә, Франциядә) бөтендөнья демократик хәрәкәте белән, шул исәптән рус эмиграциясе белән бәйләнештә булган татар милли хәрәкәте бүлекчәсе форма-

лаштырыла. 1922 елда Садри Максуди, Фуад Туктаров Оештыру җыелышының эмиграциядәге әгъзалары киңәшмәсендә катнашалар. Маньчжуриядә эмиграциядә булган Гаяз Исхакый «яңа басмадагы» империячел сәясәтне дәвам иттергән коммунистик хакимиятнең вакытлы булуына ышана. Көнбатыш Европага күченеп килгәннән соң, ул Фуад Туктаров белән берлектә, Идел-Урал Комитетын төзи. 1933 елда Берлинда үзенең «Идел-Урал» дигән китабын бастырып чыгара. Анда ул, Россиядә үзгәртеп корулар әле тәмамланмаган, алар «Европа Көнчыгышы халыкларына азатлык» алып килгәннән соң гына тәмамланачаклар, дип яза. 1935 елдан 1945 елга кадәр Мукденда Гаяз Исхакый тарафыннан оештырылган «Милли байрак» газетасы чыгып килә. Газета тирәсенә җирле татар язучылары берләшә. Татарстанда инде рус язу графикасы — кириллица кертелгән вакытта газетада гарәп графикасы саклана. 1955 елда Төркиядә «Идел-Урал төркиләренең мәдәнияте һәм үзара ярдәмләшү җәмгыяте» төзелү Гаяз Исхакый эшенең дәвам ителүен раслаучы дәлил булып тора.

АВТОНОМИЯ ЮЛЫНДА

Кыен башлам. XX йөз башында татар милләте үз милли дәүләтчелеген торгызу һәм үстерү өчен барлык икътисади, мәдәни мөмкинлекләргә, кадрларга ия була, аның Россияне демократик үзгәртеп кору эшенә үз өлешен кертү мөмкинлеге дә күзәтелә. Әмма Россиядәге 1917 елгы революция һәм гражданнар сугышы татар милли хәрәкәте хәлен кискенләштерә. Милли мәдәният чиктән тыш зыян күрә. Җиде ел чамасы барган сугыш нәтиҗәсендә бөлгенлеккә төшкән милли хуҗалык национализацияләү аркасында тәмам җимерелә. С. Сәедгалиев җитәкчелегендәге хөкүмәт үз эшен әнә шундый авыр шартларда башлап җибәрә.

Федерация тарафыннан күрсәтелгән сызык буенча чикләргә төгәллек кертү нәтиҗәсендә 1921 елның 1 маена республика территориясе билгеләнә. Хөкүмәт каршындагы административ комиссия татар авылларының һәм башка авылларның Татарстан Республикасы составына күчәргә теләве һәм бу күчү белән ризалашуы турындагы гаризаларын игътибар белән карап тикшерә, бу мәсьәләне шушы авыллар элек кергән губерналарның администрацияләре белән килештерә. Бер үк

вакытта республиканың җирле администрациясе формалаштырыла. Барлыгы 13 кантон (административ район): Арча, Бөгелмә, Буа, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Зөя, Спас, Тәтеш, Чистай, Алабуга, Чаллы һәм Әгерҗе кантоннары төзелә. 2892 мең кешенең 2639 меңе авыл җирләрендә яши.

1920 елның декабрендә республиканың Үзәк Башкарма Комитеты (ҮБК) сессиясендә Хакимият турындагы Нигезләмә кабул ителә. 10 мең кешегә бер делегат исәбеннән сайланучы Татарстан Советлары съезды ТАССРның иң югары хакимият органы дип белдерелә. Ул Советлар съездлары арасындагы чорда республиканың хакимият органын тәшкил итәчәк һәм 50 кешедән торачак Үзәк Башкарма Комитетын (ҮБК) сайлый. ҮБК ТАССРның Татарстан Советлары съезды һәм Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты каршында җаваплы идарә итүче, закон чыгаручы һәм контрольлек итүче органы дип белдерелә. Параллель рәвештә, законда каралмаган тәртип урнаша: республика органнарының теләсә нинди карары алдан РКП(б) җирле өлкә комитеты тарафыннан хупланырга тиеш була. Өлкә комитеты белән килештерелмәгән карарга карата гадәттә РКП(б) Үзәк Комитетында ризасызлык белдерелә, һәм бу карар, кагыйдә буларак, кире кагыла.

Республиканың федератив хакимият органнары белән үзара мөнәсәбәте механизмы эшләнә. Мондый үзара мөнәсәбәтләрне алып бару өчен Россия Федерациясе Милләтләр эшләре халык комиссариаты каршында Татарстан Вәкиллеге оештырыла. Вәкиллеккә ТАССР ҮБК Президиумы тарафыннан билгеләнгән М. Солтангалиев җитәкчелек итә.

Республиканың хакимият органнары (Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы) милли мәнфәгатьләрне тулырак канәгатьләндерүгә — милли дәүләтчелекне, икътисадны, мәдәниятне тизрәк торгызуга йөз тота. Республикада федератив хакимиятнең бердәнбер югары вәкиле роленә дәгъва итүче РКП(б) өлкә комитеты, киресенчә, интернациональ мәнфәгатьләр милли мәнфәгатьләрдән өстенрәк булырга тиеш, дигән сылтау белән үзәк мәнфәгатьләрен беренче планга куя. Менә шундый икегә бүленгәнлек шартларында карарлар кабул итү аеруча кыенлаша. Үзәкнең турыдан-туры тыкшынуы белән кабул ителгән мондый карарлар еш кына республиканың милли мәнфәгатьләре файдасына булмый.

Ачлыктан котылу чаралары. Автономиянең беренче елы Татарстанга җиңеллек алып килми. Россиядә гражданнар

сугышы дәвам итә. Хуҗалык — бөлгенлектә, җимерек хәлдә. 1920 елда Казан губернасында 1909 елда җыелганның биштән бере кадәр генә уңыш җыеп алына. Республика составына башка губерналардан кергән районнардан хәл аерата хәвефле була. Республика үзәктән 10 120 мең пот ашлык тапшыру турында күрсәтмә ала. Бу йөкләмә Татарстанда Азык-төлек мәсьәләләре буенча киңәшмәнең (рәисе В. В. Кураев) һәм республика Азык-төлек комиссариатының (нарком — А. С. Изюмов) гадәттән тыш чаралары аркасында гына үтәлә. Ашлыктан тыш декабрь ахырына 380 мең поттан артыграк ит, 1652 мең пот бәрәңге, 17 миллион данә йомырка, 11 мең пот май, 8880 пот бал хәзерләнә. 1920 ел дәвамында дәүләткә 227 344 данә тире, 13 276 пот йон, 4838 пот җитен, 4639 пот киндер сүсе тапшырыла. Республиканың тегү һәм аяк киеме предприятиеләре армиягә аяк киемнәре һәм кием-салым җибәреп тора. Октябрьдә фронттагы сугышчылар өчен җылы әйберләр җыю үткәрелә.

Гражданнар сугышының тәмамлануын Татарстан зур өметләр баглап көтеп ала. Ләкин республика яңа афәткә — моңа кадәр күрелмәгән корылыкка дучар була. 1921 елда бер дисәтинәдән уртача 63 пот ашлык җыеп алына. Бу корылыклы 1891 елдагыдан да ике тапкыр түбәнрәк күрсәткеч була. Бер ел эчендә терлекләр саны 40 процентка кими. Ачлык башлана. Ваба һәм тиф авырулары котырына. Эпидемияләрдән үлү 7—12 процентка җитә. Татарстан Советларының 1922 ел июнендә булып үткән II съезды корылык нәтиҗәләрен җиңү буенча үткәреләчәк гадәттән тыш чараларны игълан итә. Ләкин бөтен Идел буен чолгап алган корылыкның гаять зур масштабта булуы аркасында, республика хөкүмәтенең тырышлыклары да әллә ни нәтиҗәләр бирми. Татарстан халкы бары тик Россия хезмәт ияләре (үзләренә дә җитәр-җитмәс паекларының бер өлешен ач калган кешеләргә ярдәм фондына күчергән эшчеләр, соңгы запасларының бер өлешен корбан иткән крестьяннар) теләктәшлеге аркасында гына исән кала. Федерациянең хакимият органнары, Россиянең аерым губерналары, милли республикалар Татарстанга азык-төлек белән ярдәм итә. Кайбер чит илләрнең — АКШның, Англиянең, Германиянең, Норвегиянең, Иранның, Финляндиянең, Швециянең, Эстониянең — азык-төлек ярдәме дә шактый сизелерлек була. Татарстан чит илләрдән ярдәм төсендә 1700 мең пот ашлык ала. Республикага килгән бөртекнең күп

өлешен 1922 елның язгы чәчү компаниясе өчен чәчүлек материалы сыйфатында салып куярга туры килә. М. А. Сәйдәшева китергән мәгълүматларга караганда, Татарстанга мондый бөртек Россиядән 4414 мең пот, чит илләрдән 160 мең пот китерелә.

Татарстан хөкүмәтенә тәмам таркалган сәнәгать мирас була. Татарстан Халык Хуҗалыгы Советы Президиумы Рәисе М. Г. Рошаль 1920 елда билгеләп үткәнчә, сәнәгать предприятиеләрендәге эш кораллары һәм техника «10 ел дәвамында алыштырылмаган, машиналар ямаулар белән капланган, искергән». Гражданнар сугышы тәмамланганнан һәм хәрби заказлар туктатылганнан соң, сугыш ихтыяҗлары өчен эшләп килгән предприятиеләр дә туктый. Шул ук вакытта Татарстанда сәнәгатьне национализацияләү дә тәмамлана. 1921 елның гыйнвар-февраль айларында Казанда 35 сәнәгать предприятиесе, Чистайда 14 предприятие национализацияләнә.

Хөкүмәт алмашыну. Татарстан Советларының I Оештыру съездында төзелгән С. Сәедгалиев хөкүмәте бик катлаулы шартларда бер ел чамасы эшли. Татарстан Советларының 1922 елның 25—28 июнендә булып үткән II съездында С. Сәедгалиевне Халык Комиссарлары Советы Рәисе постында Кашаф Гыйльфан улы Мохтаров алыштыра. Ул татар милли хәрәкәтенең бу хәрәкәткә коммунистларның милли оешмасы аша килгән күренекле вәкилләреннән берсе була. Сәедгалиев җитәкләгән хөкүмәттә ул сәламәтлек саклау халык комиссары булып эшли. С. Сәедгалиевне Мәскәүгә чакыртып алалар. Республиканың Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе итеп Рәүф Әхмәт улы Сабиров сайлана. Халык комиссарлары составында да үзгәрешләр була.

С. Сәедгалиевнең Мәскәүгә күчүе кайбер тарихчылар аңлатканча, татар хезмәткәрләренең үзләре арасындагы көрәш («уңнар» һәм «суллар» арасындагы көрәш) нәтиҗәсе түгел, ә, бәлки, бер яктан, Үзәк Башкарма Комитет һәм Халык Комиссарлары Советының милли автономияне ныгытуга йөз тоткан татар хезмәткәрләре һәм, икенче яктан, үзәк сәясәтен гамәлгә ашырып килгән РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты арасында туган каршылыклар нәтиҗәсе була. Бу мәсьәлә беркадәр алданрак, 1921 елның 23—24 июнендә (Советларның II съезды алдыннан) булып үткән партия конференциясендә тикшерелә. Сәедгалиевне алыштыруның сәбәбе турындагы

сорауга өлкә комитетының беренче секретаре Н. И. Барышев, С. Сәедгалиев кандидатурасы «кабул ителмәслек», дип кенә җавап кайтара.

Хәлбуки Россиядә яңа икътисади сәясәтнең, ягъни нэпның либеральләштерү рухы хөкем сөрә. Чын асылы әле беркемгә дә мәгълүм булмаган, әле беркем дә күрмәгән, беркем тарафыннан да тасвирланмаган социализм төзү юлын Россия үзенеке итеп сайлый. Республиканың яңа хөкүмәте әнә шул юлдан — социализм төзү юлыннан барып татар милли дәүләтчелеген торгызу курсын гамәлгә ашыруны үзенең төп бурычы итеп куя. Республика хөкүмәте Татарстанны милли йөзе булган төбәк итеп күрергә тели. Башка сүз белән әйткәндә, хөкүмәт Татарстан Республикасының сыйнфый дәүләт булып формалашуын гына түгел, бәлки, барыннан да элек, татар милләтенең ышанычын казанган һәм нинди милләтнеке булуына бәйсез рәвештә республикадагы барлык халыклар турында кайгыртучанлык күрсәтүче милли дәүләт булып әверелүенә юл тота.

1921 елның 25 июнендә республиканың Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы Татар телен гамәлгә кертү турында Декрет кабул итәләр. Бу вакыттан башлап татар теле «барлык дәүләт учреждениеләрендә» рәсми тел буларак игълан ителә. Республикада русларның шактый зур процент тәшкил итүләрен исәпкә алып, Декрет «татар теле белән беррәттән дәүләт теле хокукларында рус теле дә кулланышта кала» дип билгели. Бер үк вакытта дәүләт аппаратына «төп милләт» кешеләрен туплау эше алып барыла. Дәүләт учреждениеләренә эшкә татар хезмәткәрләре күрсәтелә, аларда эш татар телендә алып баруга күчерелә. Дәүләт учреждениеләрендәге калган рус хезмәткәрләре һәм бүтән милләттән булган хезмәткәрләрнең татар телен белмәгәннәре аны өйрәнергә тиеш булалар. Татар милли дәүләтчелеген торгызуга юнәлдерелгән бу зур чара, Татарстанда элек-электән яшәгән русларның һәм бүтән милләт вәкилләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алып, эзлекле рәвештә үткәрелә. Тиешле уку йортларында татар кадрлары хәзерләнә. Башка милләт вәкилләреннән булган чиновникларны татар теленә өйрәтү эше җайга салына. Татар телендә эш алып баруга күчү авыл Советларыннан башлана, ә соңыннан бу эш кантоннарга күчерелә. Спас, Зөя (Свияжск) кебек кантоннарда, күбесенчә руслар яшәгән авыл Советларында татар депутатларының саны арт-

тырыла. 1925 елда 23 050 авыл Советы әгъзасының 11 285 е татар, 9071 е рус; 1911 шәһәр Советы әгъзасының 505 е татар, 1268 е рус була.

Дини учреждениеләр эшчәнлегендә билгеле либеральләшү сизелә. Галимҗан Баруди вафат булганнан соң, 1922 елдан Үзәк Россия һәм Себер мөселманнары мөфтие урынын күренекле ислам эшлеклесе, элек казый булып торган Ризаэддин Фәхреддин били. Республикада мәчетләрнең дини-рухи һәм милли-мәдәни эшчәнлеге җанлана. Имамнар яңа хакимияткә теләктәшлек белдерәләр.

Татарстанда яңа икътисади сәясәт. Гражданнар сугышы елларында өч ел буена хуҗалык итү тәҗрибәсе коммуналь юлның хосусый милектән һәм хосусый эшмәкәрлектән башка киләчәксез, өметсез юл икәнлеген күрсәтә. Шәһәр белән авыл арасында үзәктән торып турыдан-туры товар алмашу кертергә маташуны халык кире кага. Моны аңлаган Ленин яңа икътисади сәясәт (*нэп*) тәкъдим итә. Тулысынча национализацияләнгән (дәүләт кулында тупланган) хуҗалыкны оештыруның коммуналь асылы үзгәрми. Җимерелгән хуҗалыкны торгызу чорына хезмәтчел крестьяннар өчен берникадәр җиңеллекләр кертелә. Азык-төлек развёрсткасы (крестьяннарның артып калган барлык азык-төлекне дәүләткә бушлай тапшыруы) дәүләт билгели торган салым белән алыштырыла. Крестьяннарга азык-төлекне үзләре теләгәнчә җитештерергә һәм аның салым түләгәннән соң калганын ирекле базарда сатарга рөхсәт ителә. Дәүләттән патент алу һәм салым түләү шарты белән вак һәм урта эшмәкәрлеккә, хосусый рәвештә ваклап сәүдә итүгә, вак һөнәрчелеккә (кустарьчылыкка) рөхсәт бирелә.

Бу яңалыклар хосусый милек һәм хосусый эшмәкәрлекнең сакланып калуын күздә тоткан татар милли хәрәкәтенең икътисади программасыннан ерак була. Шуңа да карамастан шул конкрет вазгыятьтә нэп Татарстанда уңай каршы алына. Кайберәүләр нэпны советларның хуҗалык сәясәтенең радикаль үзгәрүе итеп бәялиләр. Ничек кенә булмасын, республиканың икътисады кыенлык белән булса да җанлана башлый.

Галимнәр Р. В. Шәйдуллинның һәм Р. К. Вәлиевнең исәпләүләренә караганда, Октябрьдән соң үткәрелгән аграр үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә 714 мең дисәтинә алпавыт җирләре, удел, чиркәү җирләре, башка төрле җирләр национализация-

ләнә. Шуларның 26,2 проценты татар крестьяннары арасында (җан башына 0,12 шәр дисәтинә), 64,3 проценты рус крестьяннары арасында (җан башына 0,38 дисәтинә) бүлеп бирелә. Татар крестьяннары кулындагы җир биләмәсенең уртача мәйданы җан башына 1,52 дисәтинә, ә рус крестьяннарыныкы җан башына 1,89 дисәтинәгә җитә.

Республикада аз җирлелеккә тагын башка кыенлыклар өстәлә. Сугыш елларында крестьян хуҗалыклары төп тарту көче булган атларның шактыеннан мәхрүм ителәләр. Ачлык елларында барлык терлекләрнең, шул исәптән атларның да саны бик нык кими һәм 1923 елда 1920 елгы дәрәҗәнең нибары 47,7 процентын тәшкил итә. Республикада чәчүлек орлык җитешми. Хуҗалык өчен кирәкле бар нәрсәне крестьяннар, зур процентлар түләп, кредитка алырга мәҗбүр була. Кредитны алар 1923 елда ачылган Россия авыл хуҗалыгы банкының Казан бүлекчәсендә ала. 1923 елда республикага кредитлар хисабына 3,5 мең ат кайтартыла. Крестьяннар чәчүлек орлыкны да кредит хисабына алалар. 1923 елда республика хөкүмәте авылда салымны натуралата түләтүдән акчалата түләтүгә күчәргә карар итә. Бу хәл игенчелекне интенсивлаштырырга мөмкинлек бирә.

Республика органнары мәгълүматларына караганда, ул вакытта авылда яшәүчеләрдән өчтән беренең даими эш урыны булмый. Җимерек сәнәгать аларны эш белән тәэмин итәргә сәләтсез була. Киеренкелекне бераз киметү өчен республика хөкүмәте авылда вак һөнәрчелек кәсепләрен үстерү чаралары күрә. Республика хөкүмәте, гадәттән тыш чара сыйфатында, 1921 елда 100 мең крестьянның эш эзләп Россия губерналарына китүенә рөхсәт сорап, Мәскәүгә үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була.

Республика территориясендә урнашкан барлык эре (цензлы) предприятиеләр, революциягә кадәр кем кулында (дәүләт кулында, рус яисә татар хосусый эшмәкәрләре кулында) булуларына карамастан, федераль милеккә, Россия Федерациясе Халык Хуҗалыгының Югары Советы (ХХЮС) буйсынуына күчереләләр. Бу мөлкәт белән, гамәлләрен республика хөкүмәте аша килештереп, ХХЮСның җирле органы булган республика Халык Хуҗалыгы Советы идарә итә. Әлеге предприятиеләр тармаклар буенча (Татарстан тегү сәнәгате тресты — Татшвейтрест, Татарстан урман сәнәгате тресты — Татлестрест һ. б.) федерация буйсынуындагы трестларга берләшә.

Казанда Мулланур Вахитов исемендәге завод (элекке Крестовниковлар заводы), җитен эрләү фабрикасы (элекке Алафузовлар фабрикасы), элекке Дары заводы торгызыла һәм эшли башлый. Шәһәрдә суүткәргеч төзәтелеп, сафка кертелә, 1922 елда трамвай йөри башлый. 1925 елда Казан шәһәр электр станциясе эшләүче предприятиеләр сафына баса. Идел пыяла заводы, Печище известь заводы, Паратск комбинаты, бер-бер артлы, эшләүче предприятиеләр рәтенә басалар. Яңа икътисади сәясәткә таянган, хосусый милеккә нигезләнгән хосусый эшчәнлек нигездә ваклап сәүдә итү предприятиеләре белән, вак һәм уртача предприятиеләр, вак һөнәрчелек сәнәгате белән чикләнә. 1926 елда республикада 30 мең хуҗалыкны берләштергән 614 вак һөнәрчелек артеле була. Республика хуҗалыгын җайга салуда 1924 елда СССРда үткәрелгән акча реформасы һәм тотрыклы валюта — червонецның гамәлгә керүе уңай роль уйный.

Милли мәдәният яңа шартларда. XX йөз башында күтәрелеш кичергән татар милли мәдәнияте рус булмаган халыкларга карата столыпинчыл дәүләт шовинизмы котырынган елларда җитди сынауларга дучар ителә. Беренче бөтендөнья сугышы чорында, халыкның бөлгенлеккә төшүе елларында, аның хәле тагын да начарлана. Октябрьдән соң аңа яңа куркыныч яный башлый. Большевиклар, ул вакытка кадәр үсеп килгән бөтен милли мәдәниятне социализм идеалларына һәм Совет хакимияте максатларына каршы килә, дип белдерәләр.

Татар милли мәдәнияте әһелләренең мондый сәясәт белән килешәселәре килми. Алар икегә аерыла. Бер өлеше, Гаяз Исхакый кебек, шунда ук чит илгә китә, эмиграцияне кулай күрә. Икенче бер өлеше, Совет шартларында да татар милли мәдәниятендә үзләренә урын табарга өметләнгәннәре, илдә торып кала. Андыйлар арасында Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал, К. Тинчурин, Ш. Усманов кебек язучылар, Һ. Атласи, Г. Гобәйдуллин, М. Сәгыйдуллин кебек тарихчылар һ. б. була. Алар 20 нче елларда татар милли мәдәниятен торгызуда әһәмиятле роль уйныйлар, Татарстан Автономияле Республикасын аякка бастыруда зур өлеш кертәләр.

Галимҗан Ибраһимов 1911 елда ук әле «Без татармыз» дигән мәкаләсендә, XX гасыр башларында формалашкан татар мәдәнияте ул — милли мәдәният, дип белдерә. Аның фикеренчә, бу мәдәният 20 нче елларда да шундый ук була, милли

позициясен дәвам итә. Г. Ибраһимов үзе революциягә кадәрге татар милли хәрәкәтендә татарларның милли демократик республикасын төзү позициясендә тора. Татар милли совет республикасы канаты астында татар милли мәдәнияте уңышлырак үсеш алыр, дип өметләнә һәм татар милли совет республикасын яклап чыга. Ул үзенең яңа әсәрләрен һәм әдәби тәнкыйть буенча хезмәтләрен менә шул максатка хезмәт итүгә багышлый. Үзенең җәмәгать эшчәнлеге белән дә Г. Ибраһимов Татарстанның аякка басуына зур өлеш кертә, 1925 елда республиканың Академия үзәгенә җитәкчелек итә, Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы була.

Күренекле артист һәм драматург, академия театрының художество җитәкчесе һәм режиссеры Кәрим Тинчурин татар мәдәниятенең милли рухына тугрылыклы кала. Республика аякка баскан елларда ул үзенең «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл» һ. б. кебек мәшһүр пьесаларын иҗат итә. Фатих Әмирхан үзенең «Татар милли республикасы һәм татар демократик әдәбияты» дигән мәкаләсендә яшь Татарстан Республикасына үзенең изге теләкләрен белдерә. 1921—1924 елларда «Кызыл Татарстан» газетасының һәм «Чаян» журналының редакторы булып эшләгән күренекле драматург, публицист Фәтхи Борнаш үз иҗатын Татарстан Республикасының аякка басуы белән бәйли. Заманында «революция җырчысы» дип аталган Шамил Усмановның иҗаты милли мәдәният үсешендә шактый зур урын алып тора. Аның Россиядәге гражданнар сугышында катнашкан татар милли хәрби частьлары турындагы «Канлы көннәрдә», Февраль революциясе алдыннан татар эшчеләре тормышыннан алып язылган «Беренче адым» пьесалары, гадел дәүләт идарәсе турындагы «Памирдан радио» дигән фантастик повесте тирән милли эчтәлек белән сугарылганнар, революциядә татар милли характерының, татар милли идеалының чагылышын күрсәтәләр.

Татар язучылары совет мәдәнияте дип аталган татар милли мәдәнияте тарихында яңа сәхифәләр ачалар. Милли идеягә тугрылык аларны рус булмаган халыкларның милли идеясен кире кагучы коммунистлар хакимияте белән конфликтка китерә. Әмма алар татар шовинистлары булмыйлар, башка халыкларны изүгә чакырмыйлар. Алар башка халыкларга түбәнсетеп караучы эгоист татар милләтчеләре дә түгел, ә бәлки үз милләтләрен яратучы милләтчеләр булалар. Совет хакимияте белән хезмәттәшлек иткән хәлдә, алар коммунистик

җәмгыятьне дә сыйнфый планда гына түгел, татар милләте дә чәчәк атарга тиеш булган милли җәмгыять планында да күрергә телиләр. Фаҗига шунда ки, соңрак нәкъ менә шул татар милләтенә карата булган мәхәббәтләре өчен коммунистик хакимият аларны милләтчеләр — халык дошманнары дип игълан итә.

Татар милли хәрәкәте 20 нче елларда Татарстан АССРда гына түгел, республикадан читтә татарлар яшәгән районнарда да халык мәгарифен торгызу һәм үстерү турында кайгыртучанлык күрсәтә. Республикада бу эш белән турыдан-туры Мәгариф халык комиссариаты шөгыльләнә. Республикадан читтә татарлар яшәгән районнарда бу турыда төп кайгыртучанлыкны ул вакытта РКП(б)ның җирле губерна комитетлары һәм губерна халык мәгарифе бүлекләре каршындагы татар-башкорт секцияләре үз өсләренә ала. Мәгарифнең милли системасы саклаңган хәлдә, татар җәдит мәктәпләреннән совет татар мәктәпләренә күчү гамәлгә ашырыла. Мәктәпне чиркәүдән (һәм мәчеттән) аеру турындагы Декрет нигезендә барлык татар мәктәпләре дөньяви дәүләт мәктәпләре итеп үзгәртелә. Рус мәктәпләрендә православие дине сабаклары бетерелгән кебек, татар мәктәпләрендә дә ислам дине сабакларын укыту туктатыла. Халык мәгарифе системасы «Бердәм хезмәт мәктәбе турында»гы хөкүмәт Нигезләмәсе һәм һөнәри-техник белем бирү турындагы хөкүмәт карары нигезендә оештырыла.

Рәсми статистика буенча, 1925 елда республикадагы 2118 башлангыч һәм урта мәктәпнең 1048 е татар мәктәбе булып, аларда 76 200 бала белем ала. Квалификацияле эшчеләр хәзерләү өчен фабрика-завод өйрәнчеклеге (ФЗӨ) мәктәпләре системасы формалаша. 1925 елда республиканың ФЗӨ мәктәпләрендә 4764 бала, шул исәптән 1537 татар баласы укый. Урта буын кадрларын хәзерләү өчен техникумнар һәм махсус һөнәри училищелар ачыла. 1921—1922 елларда укытучылар хәзерли торган кыска сроклы курсларга алмашка килгән 8 педагогия техникумы махсус урта белемле укытучылар хәзерли башлый. Казан университетында татар бүлеге ачыла. 1919 елда ачылган Казан политехника институты һәм 1922 елда ачылган авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты югары квалификацияле белгечләр хәзерләүгә керешәләр. Урта мәктәпләр өчен укытучыларны Казан педагогика институты хәзерли. Югары уку йортларына керү өчен яшьләрне

өлешчә бу уку йортларының үзләре каршында ук оештырылган эшчеләр факультетлары (рабфаклар) хәзерли. Өлкән яшьтәгеләрне уку-язуга өйрәтү өчен укый-яза белмәүчелекне бетерү мәктәпләре (ликбезлар) системасы булдырыла.

Халык мәгарифенең совет системасына күчкәндә татар милли мәктәбенең мең еллык милли традицияләрен саклап калуга ирешелә. Аерым алганда, татар имлясын кириллицага күчерү турында революциягә кадәр үк берничә тапкыр күтәрелгән мәсьәлә көн тәртибеннән төшереп калдырыла. Гарәп графикасына нигезләнгән татар имлясы камилләштерелә. Бу эш әле XX йөзнең башында Казанда гына да саны 30 дан артып киткән яңа мәдрәсәләр галимнәре тарафыннан бик актив алып барыла. 20 нче елларда Г. Ибраһимов һәм башка тел белгечләре инициативасы белән бу юнәлештәге эш дәвам иттерелә. Китап басу эше киңәя. Шушы шрифтка нигезләнгән язу машинкалары җитештерелә башлый. Озак вакытлар дәвамында татар теленең үзенчәлекләренә яраклаштырылган, тиз басуга көйләнгән бу машинкалар, бүгенгә кадәр әһәмиятләрен югалтмыйча, фәнни һәм тарихи-мәдәни тикшеренүләрдә файдаланыла килә.

20 нче еллар урталарында татар милли имлясын латин графикасы нигезенә күчерү инициативасы туа. «Яңалиф» җәмгыяте барлыкка килә. Җәмәгатьчелек башта мондый тәкъдимнәргә сагаеп карый. Күпләр моңа каршы чыга. Гарәп имлясы белән теркәлгән мәдәни байлыкны югалтасы килми.

Шуңа да карамастан бу күчү гамәлгә ашырыла. Ул татарлар арасында милли үзаңны тирәнәйтүгә, аларда гомумтөрки бердәмлегенең әһәмиятен аңлауга булышлык итә. Татар милли хәрәкәтенең күп кенә эшлеклеләре, аерым алганда Гаяз Исхакый, моңа кадәр үк, татар-рус бергәлегенең әһәмиятен аңлау белән беррәттән, татар милләтен, мәдәниятен торгызуда башка төрки халыклар тәҗрибәсен дә онытмаска чакырып килгән була. Латин графикасын беренчеләрдән булып кабул иткән Төркия ул чакта төркиләр арасында иң алдынгы илләрдән санала. Аңардан соң Азәрбайҗан бара. Татарстанның дәүләт, кооператив учреждениеләрендә, җәмәгать оешмаларында эш алып бару 1929 елның февраленнән латин графикасына күчерелә. Газеталар һәм журналлар, нәшриятлар, уку йортлары яңа алфавитка күчә. Дөрес, рус булмаган халыкларның революциягә кадәрге мирасына каршы коммунистик һөҗүм алып барылган шартларда яңалифкә күчү зур мәдәни

югалтуларга китерә. Татар халкы үзенең гарәп язуында тупланган тарихи мәдәни мирасыннан шактый дәрәҗәдә читтә кала.

Совет Татарстанының бишьеллыгы. 1925 елда Татарстан АССР төзелүгә биш ел тулу билгеләп үтелә. Бу бишьеллыкның иң мөһим нәтиҗәсе татарларның милли тормышының ике төрле территориаль кырда дәвам итүеннән гыйбарәт була. Татар халкының азчылык өлешенең милли тормышы татар милли хәрәкәте ирешкән территориаль автономия (ТАССР) кысаларында, ә күпчелек өлешенең милли тормышы исә ТАССРга күрше булган рус губерналарында һәм Идел-Уралдагы рус булмаган халыкларның милли-территориаль автономияләрендә дәвам итә. Дәүләти яктан икегә (Татарстан АССР һәм Россия) бүленүгә карамастан, татар милләте Советлар Союзында үз бердәмлеген — милли тел, милли икътисад, милли мәдәният һәм милли рух бердәмлеген, тарихи традицияләрен саклап кала. Милләтне рухи берләштерүдә татар мөселман руханиларының роле дә кимеми. 1922 елда Мөфтият (Ризаэддин Фәхреддин) Казанда Кабан арты мәчетен төзеп бетерүгә рөхсәт ала. 1926 елда аны рәсми ачу тантанасы була. Татарстан АССР йөзендә татар милли дәүләтчелеге бөтен татар халкының дәүләтчелеге итеп кабул ителә. Татар мәдәниятчеләре милли телне, милли мәдәниятне өйрәнүне гомуммилли кысаларда алып баруны дәвам иттерәләр. Ләкин Союзның рәсми хакимиятендә бераз башкачарак караш формалаша. «Татарстан» төшенчәсе рәсми рәвештә Татарстан АССР территориясенә генә беркетелә. Татар халкының, татар милләтенең тарихын өйрәнү Татарстан АССР белән генә чикләндерелә.

Рәсми мәгълүматларга караганда, яшәвенең беренче бишьеллыгында ТАССР ул вакытта милли икътисадтан (татарларның ялгыз крестьян хуҗалыклары һәм татар нэпман-эшмәкәрләре хуҗалыклары) һәм Союз хакимияте кулында тупланган икътисадтан торган халык хуҗалыгын торгызуның зур юлын үтә. 1925/26 хуҗалык елында чәчү мәйданнары 1913 елгы дәрәҗәнең 98 процентын, бөртекле культуралар уңышы бу дәрәҗәнең 71,1 процентын тәшкил итә. Вак терлекләрнең баш саны сугышка кадәрге дәрәҗәгә җитә диярлек, ат һәм сыерларның баш саны 1913 елгы дәрәҗәнең өчтән ике өлешен тәшкил итә. Авыл хуҗалыгының акрын торгызылу сәбәбен федераль хакимиятнең дәүләт сәнәгатен авыл хуҗалыгындагы индивидуаль җитештерүче хисабына үстерү

сәясәте алып баруында күрергә кирәк. Республиканың тулысы белән федераль хакимият кулына күчкән эре (цензлы) сәнәгать предприятиеләре (текстиль, тегү, күн-мех сәнәгате, сабын, азык-төлек, төзелеш, агач эшкәртү, полиграфия, энергетика сәнәгате) 1925 елда сугышка кадәрге продукциянең 70 процентын бирә. Татарстан сәнәгатендә 14 мең кеше эшли, шуларның биштән бер өлешен татар эшчеләре тәшкил итә. Республикада яшәүче халык составында татарларның өлеше беразга кими. 1926 елда халык санын алу нәтиҗәләре буенча республика халкын 2 915 277 кеше тәшкил итә. Татарлар саны 1 266 818 кеше (48,9 процент), руслар саны 1 116 005 кеше (43,1 процент) исәпләнә. Татарлар саны нигездә республикадан читкә эш эзләп киткән кешеләр хисабына кими, ә руслар саны республикага сәнәгать предприятиеләрендә, совет һәм партия учреждениеләрендә эшләргә килгән белгечләр хисабына арта. Шәһәрләрдә яшәүчеләр арасында татарлар 23,6 процент, руслар 72,9 процент тәшкил итә. Татарларның күпчелеге авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә, алар авылда яшәүчеләрнең 54,2 процентын тәшкил итәләр.

РОССИЯ КОММУНИСТИК АБСОЛЮТИЗМЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН

Коммунистик абсолютизмның алшартлары. Марксистик материализмның төп постулаты күрсәтүенчә, «аң яшәеш белән билгеләнә». Шуңа да карамастан социализм Россия кешеләренең аңына матди тормыш аша түгел, киләчәктә булачак гаделлекне һәм матди яктан тәэмин ителгән тормышны идеаль күзаллау рәвешендә сеңә. Коммунистлар, бары тик Совет хакимияте генә Россияне дөнья сугышында җиңелү хурлыгыннан коткарырга, аны Көнбатыш өчен чимал чыганагы булган илдән хәрби һәм гражданлык даны булган чәчәк атучы державага әверелдерергә сәләтле, дип, кешеләрне ярлыларга һәм байларга аеручы тормыш укладын тәмам җимергәннән соң гына, илдә социализм төзелгәннән соң гына, россиялеләр хәзерге чарасызлык халәтеннән чыга алачаклар, дип аңлаталар. Һәм большевикларның бу аңлатулары бик гади, тормышның ачысын-төчесен татыган түбән катлаулар өчен бик аңлаешлы, бик кызыктыргыч була. Шулай килеп чыга: гадел булган җәмгыять (социализм) гадел булмаган җәмгыятьнең (капитализмның) антиподы икән. Һәм социа-

лизм тантана итсен өчен, бар нәрсә дә үзенең антиподы белән: милли идея — сыйнфый идея белән, традицион милли идеология — марксизм белән, рус милли дәүләте — Россия дәүләте белән, хосусый эшмәкәрлек — дәүләт предприятиеләрендә коллектив эшләү белән, шәхси ирек социализмга шәхси бирелгәнлек белән алыштырылырга тиеш. Шул ук вакытта кешеләрнең үзләренә әллә ни мәшәкатьләнеп торасы да юк. Аларга әйтәләр: большевикларга ышаныгыз, аларны яклагыз, аларга ярдәм итегез, һәм алар бар кирәк нәрсәне үзләре эшләр. Кем моңа ышанмый, димәк, шул кеше халыкка социалистик бәхет теләми, кем дә кем шушы идеяне якламый — шул юк ителә.

Халыкның түбән катлаулары, үз чиратларында, мондый аңлатулардан гап-гади нәтиҗә ясый: түшәвен бик йомшак түши болар, әмма алдагы якты көннәр хакына түзәргә, билбауны кысыбрак бәйләргә туры киләчәк икән. Иң мөһиме: алдагы көнгә, киләчәккә өмет бар. Татарларның руслар белән бергә дә, алардан башка да никадәр авырлык кичергән түбәнге катлаулары большевикларга ышаныбрак карый башлый. Алар да социалистик бәхет йолдызына таба атлап китә. Россия җәмгыятенең күпчелеген тәшкил иткән түбән катлауларның сукырларча ышанып каравы тоталитар режим урнашуга сәяси нигез була, ә бу режим басымы Россия социализмының кендек әбисе ролен уйный.

Ленин Россияне Октябрьгә кадәр үк инде мондый басымга әзерли. Законга нигезләнгән хакимиятне, сайлап куела торган хакимиятне ул буржуаз хакимият дип атый. Бу хакимияткә алмашка килүче пролетариат диктатурасын ул «законга түгел, сайлауларга түгел, ә турыдан-туры кораллы көчкә» таянучы хакимият итеп, «буржуазиягә каршы *көч куллануның аерым оешмасы*» итеп билгели. Гражданнар сугышы елларында Совет хакимияте иске дәүләт машинасын гына түгел, дәүләт хокукы нигезләрен дә җимерә. Россия җәмгыятенең элек дәүләт хакимиятен һәм сәясәтен формалаштыруда катнашкан даирәләре сәясәттән читләштерелә, сайлау хокукыннан мәхрүм ителә. Алар инде яңа сәясәтнең аякка басуына йогынты ясый алмый. Халыкның хезмәт иясе булган өлеше дә хакимиятне һәм сәясәтне формалаштыруда фактта катнашмый. Яңа хакимиятне конструкцияләү, сәясәтне билгеләү яхшы оештырылган, үз халкын бәхетле итәргә чын күңелдән омтылган коммунистларның фанатикларча ярдәменә таянган

сәяси лидерларының тар даирәсендә башкарыла. Мессианлык чире белән агуланган бу коммунистлар халык массалары мәнфәгатен кайгырту бурычын үз өстенә ала. Коммунистлар партиясе аша гамәлгә ашырылучы халык хакимияте, халыкның үзенә иҗат итүче роле түгел, «хуплаучы» роле генә биргән хакимият әнә шулай барлыкка килә.

Советларның Ленин җитәкчелегендә Россияне биш ел дәвамында идарә итүләре рус халкына да, рус булмаган халыкларга да матди җиңеллекләр алып килми. Алар үзәк карарларына бер үк дәрәҗәдә бәйле кала.

Владимир Ульянов исән булса, үзен ничегрәк тотар иде икән, моны әйтүе кыен. Ул «Россияне коткаручы» данына күмелгән хәлендә үлеп китә. Аның исеме халыкара мәйданда башка милли лидерларның — Ллойд Джорджның, Вильсонның, Клемансоның исемнәре белән беррәттән телгә алына. Ул вакытта әле Ленин «ленинизмга, Коммунистлар партиясенә, Совет дәүләтенә, халыкара коммунистлар хәрәкәтенә... нигез салучы» булмый. Аны соңрак шундый итәләр. Ленин культы илдә тоталитаризмга күчү өчен, бу тоталитаризмны аклар өчен булдырыла.

Сталин хакимиятенең ныгуы. 1922 елның декабрендә Ленин тагын авырып китә һәм бер ел дигәндә дөнья куя. Мондый шартларда аның тарафдарлары мирас өчен көрәш башлар, дип уйлау — табигый нәрсә. Бу чыннан да шулай була, һәм көрәш шактый озакка — 1927 елның азагына кадәр сузыла. Бу көрәш Ленин яшәгән вакытта гомумтанылган, илдә «икенче кеше» булган Л. Д. Троцкий белән Троцкийның бу абруен ничек тә булса тартып алырга омтылган Сталин арасында бигрәк тә көчле була. «Универсаль-көнбатышча» юнәлеш белән «традицион җирле» юнәлеш арасындагы бу көндәшлектә соңгысы өстенлек ала.

Сталин хөкүмәттә Ленин урынына утырырга омтылмый һәм Троцкийның да бу урынны ала алмавына ирешә. Алар икесе дә үз урыннарында калалар. Сталин — партия лидеры, Троцкий — хәрби лидер. Гражданнар сугышы тәмамлана. Табигый ки, хәрбиләр хакимияте, димәк, Троцкий үзе дә арткырак планга күчә. Сталин һәм аның тарафдарлары тырышлыгы белән партия хакимияте ныгый, үсә, һәм ул закон чыгару хакимиятен дә (Үзәк Башкарма Комитет), башкарма хакимиятне дә (хөкүмәт) тәмам үзенә буйсындыра. Партия хакимият институтына, ә аның генеральный секре-

таре дәүләтнең иң югары вазифалы кешесенә әверелә. Сталин тәкъдим иткән кешеләр дәүләтнең җитәкче органнарына билгеләнә. 1922 елда ВЧКны алмаштырган Баш Сәяси Идарә — ГПУның (СССР оештырылганнан соң — ОГПУ) кадрларын Сталин шәхсән үзе билгели.

Ләкин оппозиция бирешергә теләми. 20 нче еллар уртасында Россиянең киләчәк юлы турында яңа дискуссия башлана. Сталин төркеменә каршы булган гомуми оппозициягә троцкийчылар дип аталган оппозиция, либераль рус эмиграциясе, рус булмаган халыкларның милли хәрәкәтләре керә. Тулаем алганда, оппозиция Россия сайлаган социализм төзү юлын кире какмый, әмма сугыштан соңгы торгызу елларында туган «совет капитализмы уклады»ның параллель рәвештә яшәвенә юл куярга кирәк дип исәпли. 1926 елда күренекле рус публицисты Н. В. Устрялов: «Хәзер яңа маневр, яңа импульс кирәк, кинаяләп әйтсәк, нео-нэп (яңа нэп) кирәк»,— дип яза. Аның фикеренчә, икътисади плюрализмга юл куя торган нэпны тагы да тирәнәйткәндә, ул сәяси плюрализмга этәргеч була алыр иде. Совет хөкүмәте составындагы сул канат, аерым алганда СССР һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советы Рәисе А. И. Рыков инде барлыкка килгән нэп күп укладлылыгын саклауны яклап чыга. Аның карашларын күренекле публицист, коммунист Н. И. Бухарин да уртаклаша. Мондый борылыш рус социализмын Көнбатыш Европа социализмына якынайткан булыр иде.

Хөкүмәт составындагы Сталин төркеме, ВКП(б)ның телдән үткәрелгән һәм басма пропагандасы челтәренә таянып, шулай ук ОГПУ яклавыннан файдаланып, дискуссияне остарак үткәрүгә ирешә. Россиянең социаль-икътисади һәм дәүләт системасын цивилизацияле башка илләр системасына якынайтуга йөз тоткан тәкъдимнәр Россиядәге артталыкның саклануына, аның чит илләр капиталына бәйлелеген көчәйтүгә алып баручы «капитулянтлык» тәкъдимнәре дип игълан ителә. Россияне артталыктан тартып чыгару өчен *индустрияләштерү* (илнең барлык матди ресурсларын, шул исәптән нэпманнар кулында булганнарын дәүләт кулында туплау); *коллективлаштыру* (җир, авыл хуҗалыгы машиналары, фәнни агротехника, авыл мәктәпләре һәм шифаханәләр дәүләт кулында булган хәлдә, крестьян хуҗалыкларын колхозларда берләштерү); җәмгыятьнең ярлыларга һәм байларга бүленүен бетерү (Россияне тигез хокуклы һәм бер үк дәрәҗәдә бурыч

йөкләнгән гражданнар иленә әверелдерү) кебек өч төрле программа алга сөрелә.

Бу программалар Россия халкының күпчелеген тәшкил иткән квалификациясез эшчеләрдән, шул исәптән авыл хуҗалыгы эшчеләреннән, ярлы крестьяннардан, батраклардан торган түбән катлаулар һәм дәүләт, партия аппараты хезмәткәрләре йөзендә яклау таба. Алар, барысы да кая эшләүләренә карамастан, дәүләтнекеме ул, әллә хосусый предприятие яки оешма хезмәткәреме, хезмәт хакы хисабына яшәргә өмет тоталар. Индустрияләштерү аларны, хезмәт хакы түбән булса да, эш урыннары белән тәэмин итә; колхозлар исә аларны җир турында, терлекләр һәм техника турында, чәчүлек материаллары, хуҗалык корылмалары турында кайгыртудан азат итә. Илдә рәсми эшсезлек бетерелә, хезмәт биржалары ябыла, элеккеге мәгънәсендә «эксплуатация» төшенчәсе юкка чыга — бар кеше дәүләткә эшли.

Шулай итеп, 20 нче еллар азагына илдә оппозиция бастырыла. Троцкий 1929 елда, Советка каршы эшчәнлектә гаепләнеп, СССРдан куыла, ә 1940 елда Мексикада үтерелә. 1930 елда А. И. Рыков СССР Халык Комиссарлары Советы Рәисе постыннан алына, аның урынына ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре булып эшләгән В. М. Молотов куела. А. И. Рыковтан соң Н. И. Бухарин, Г. Е. Зиновьев, Л. Б. Каменев та эш урыннарыннан азат ителә.

30 нчы елларда Сталин командасы социализм яклылардан һәм аңа каршы кешеләрдән торган яңа бер оппозиция белән йөзгә-йөз килә. Бу оппозиция составы төрлечә була. Бер яктан, нигездә социализмга йөз тоткан коммунистларның бер өлеше («иске коммунистлар»), Сталинны партия лидеры постыннан төшерергә теләп, аңа каршы чыга. Икенче яктан, антисоциалистик оппозиция оеша. Монысы авылда кулакларны юк итүгә, сәнәгатьтә һәм сәүдәдә хосусый эшмәкәрлеккә чик куюларга, руханиларны, буржуазия яклы дип карала торган элекке интеллигенцияне эзәрлекләүләргә каршы чыга. Берберсеннән аерым эш иткән бу оппозицион көчләр тагын да рәхимсезрәк рәвештә бастырыла. 30 нчы еллар терроры иске һәм яңа оппозициянең чын һәм мөмкин саналган лидерлары тормышын алып китә, аларның чын һәм потенциаль активистларын лагерьларга озата. Вәгъдә ителгән һәм көтелгән социалистик мул тормышка әле ерак була. СССРда коммунистларның абсолют хакимияте чынбарлык булып әверелә.

Җәмгыятьне әледән-әле «сыйнфый чистарту» даими күренешкә әйләнә. «Сыйнфый чистарту» буенча чираттагы кампанияне башлап, Сталин 30 нчы еллар башында, якын киләчәктә «хосусый сәнәгатьчеләрне һәм аларның хезмәтчеләрен, хосусый сәүдәгәрләр һәм аларның иярченнәрен, элекке дворяннар, поплар, кулаклар һәм кулак куштаннарын, элекке ак офицер һәм урядникларны, элекке полицейский һәм жандармнарны, буржуаз интеллигентлар һәм советка каршы башка элементларны юкка чыгару зарур», дип белдерә. Монда сүз үзенең хосусый хуҗалыгын торгызырга өлгергән һәм аның кадерен белүче крестьяннар турында; рәсми рәвештә рөхсәт алып, тиешле салымнарны түләп, үз предприятиесен эшләтеп һәм үз сәүдәсен җайга салып җибәргән нэпманнар турында; икътисади тормышны оештыру хакында үз карашы булган элеккеге инженер-техник хезмәткәрләр турында; юриспруденция, медицина, белем бирү, сәнгать практикасы һәм башка төрле практика белән шөгыльләнергә теләүче интеллигенция турында; кешеләрнең рухи тормышында әһәмиятле урын тоткан руханилар турында бара. Принципта мондый максат — ялгыш һәм аңа ирешү мөмкин түгел. Ул җәмәгать ихтыяҗлары белән сыеша алмый. Шуңа да карамастан большевиклар шушы максат өчен көрәш башлыйлар.

Ил үсешен тоткарлаган бу программаны тормышка ашырып, ОГПУ 1928 елда иске мәктәп инженер-техник хезмәткәрләрен кулга ала. 1930 елда, матбугатта күрсәтелгәнчә, «Промпартия»нең, «Крестьян хезмәт партиясе»нең, «Меньшевиклар союз бюросы»ның актив әгъзалары кулга алына. Тулаем 30 нчы елларда, «халык дошманы» дигән стандарт мөһер сугылып, миллионнарча кеше төрмәләргә һәм лагерьларга озатыла. Аларның күбесе атып үтерелә, рәхимсез тормыш шартларында һәлак була. Халыкның Совет хакимиятенә лояль калган өлешен идарә итү өчен «идарә итүдә команда-административ система» дип атаган аерым система барлыкка килә.

Татарстан үз автономиясе сагында. СССР оештырылу белән милли мәсьәлә башка төсмер ала. Моннан болай мәсьәлә үзәгенә Союз дәүләтенең милли республикалар белән үзара мөнәсәбәтләре куела. Союз хөкүмәте, дәүләтнең унитар булуына ирешергә теләп, республикалар суверенлыгын һәм автономиясен ныграк чикләргә омтыла. Республикалар исә суверенлык һәм автономияне саклау өчен көч туплау белән

җавап бирәләр. Үзәк белән менә шундый капма-каршы көрәштә ТАССР да катнаша. Болардан тыш татар милли хәрәкәтенә ТАССРдан читтә калган татарларның социаль-мәдәни ихтыяҗларын да якларга туры килә.

1918 елдан 1923 елга кадәрге чорда Мәскәү милли республикалар вәкилләре белән 4 очрашу оештыра: 1918 елның ноябрендә мөселман коммунистларның I съездын, 1919 елның ноябре-декабрендә Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмаларының II съездын, 1921 елның гыйнварында Россия Федерациясендә яшәүче төрки халыклар коммунистлар оешмалары вәкилләре киңәшмәсен, 1923 елның июнендә республикалар һәм өлкәләр җаваплы хезмәткәрләренең IV киңәшмәсен үткәрә һәм аларда милли республикалардан үзәкләштерү линиясен яклауны таләп итә. Әлеге киңәшмәләрнең беренче өчесендә татар милли хәрәкәтендәге социализм көчләренең Совет хакимияте белән хезмәттәшлеге барышында туган Россия Мөселман Коммунистлар партиясе язмышы турындагы мәсьәлә күтәрелә. РКП(б) Үзәк Комитеты бу партиянең Үзәк Комитетын бетерүне һәм аның җирле оешмаларын РКП(б)-ның җирле комитетларына тулысынча кушуны таләп итә. Татар коммунистлары җитәкчесе М. Солтангалиев исә партия оешмасыннан мәхрүм ителгән милли хәрәкәт үзенең мөстәкыйльлеген югалтачак һәм Россия Коммунистлар партиясенә тулысынча буйсынган хәлдә калачак дип исәпли. Россия Мөселман Коммунистлар партиясенең мөстәкыйльлеген яклап, ул 1918 елда: «...Мин РКП(б)ның уртак Үзәк Комитеты белән кушылуга каршы»,— дип белдерә. Ул вакытта РКП(б) ҮКы белән татар коммунистлары арасындагы каршылык компромисс белән тәгәлләнә. РМКП Үзәк Комитеты бетерелә. Ләкин мөселман (татар) коммунистларының җирле оешмалары сакланып кала һәм РКП(б) Үзәк Комитеты бүлеге сыйфатында эш итә торган Үзәк Бюрога берләшә. Бу юлы Ленин үзе бик нык тырышса да, РКП(б)ның җирле комитетлары белән бөтенләйгә кушылуны татар коммунистларына көчләп тагу 1919 елда да барып чыкмый. 1921 елда татарлар тупланып яшәгән рус губерналары һәм милли республикаларда татар коммунистлары оешмаларын (секцияләрен) татар милли хәрәкәте органнары итеп саклап калуга ирешелә.

Татарстан АССРның үзендә мөстәкыйль эшләп килгән татар милли коммунистик оешмаларын бетерү тиздән М. Солтангалиевнең хаклы булуын раслый. РКП(б)ның Татарстан

өлкә комитеты, аларны «йотып», республикада татар милли хәрәкәтен сәяси яктан коралсызландыра. Моны асылда Ленин үзе дә раслый. РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты катнашы белән Мәскәүгә чакырып алынган С. Сәедгалиев 1921 елда Ленинга башкалары белән бергә шундый сорауны да язып җибәрә: «Әгәр, РКП(б) X съездының милли мәсьәлә буенча карарларын гамәлгә ашыру барышында элек хакимлек иткән милләтнең бөтен яктан югарырак торган коммунистлары элек изелүдә булган, исемнәре автономияле республикаларга кушылган милләтләрнең коммунистларына һәм барлык хезмәт ияләренә карата педагоглар һәм нянькалар ролен уйнарга тиешләр, дигән караште торсам, мин хаклы буламмы?» Үз җавабында Ленин РКП(б) X съезды позициясен болай бәян итүне кире какмый, бары тик: «Педагоглар һәм нянькалар түгел, ярдәмчеләр»,— дип язып, төзәтеп кенә куя. Ленин фикеренчә, рус булмаган милләтләрнең тормыш юлын үз коммунистлары билгели алмый, аларга ярдәмчеләр кирәк.

М. Солтангалиев Россия Федерациясендә милли төзелешнең башка мәсьәләләре буенча да РКП(б) Үзәк Комитеты һәм федераль хөкүмәт юнәлешенә каршы була. Милли суверенлыкны ныгыту максатларында ул милли республикаларда Кызыл Армиянең үз милли частьларын булдырырга, бу республикаларның милли коммунистик оешмалары эшчәнлеген координацияләү өчен махсус орган төзергә, милли республикаларга халыкара аренага мөстәкыйль рәвештә чыгарга рөхсәт итәргә кебек тәкъдимнәр белән чыга.

Моннан алда үткән киңәшмәләрдән аермалы буларак, IV киңәшмә милли төзелеш мәсьәләләрен ачык дискуссиядә хәл итү өчен түгел, ә татар милли хәрәкәтен ачыктан-ачык җәзалау максаты белән җыела. Әле киңәшмәгә кадәр үк РКП(б) Үзәк Комитетының Үзәк Контроль Комиссиясе «партиягә каршы, советка каршы элемент» дип Мирсәед Солтангалиевне партиядән чыгара. Ул кулга алына һәм хөкем ителә, киңәшмә эшендә дә катнашмый. Моңа җавап итеп күп кенә татар җәмәгать эшлеклеләре, шул исәптән Шамил Усманов тарафыннан юлланган протест-хат кире кагыла. Татар милли хәрәкәте, Россиядәге рус булмаган башка халыкларның милли хәрәкәтләре М. Солтангалиев кебек милләт мәнфәгатьләрен яклап килгән күренекле сәясәтчесен югалта.

Киңәшмә Татарстан җитәкчелегендәге бөтен татарларны, шул исәптән Кашаф Мохтаров рәислегендәге Татарстан хөкү-

мәтен милләтчелектә дәлилсез гаепләү трибунасына әверелдерелә.

Шуның белән беррәттән киңәшмә оештыручылары, «милләтчелеккә таба тайпылу» «урыннардагы рус иптәшләрнең бөекрус шовинизмына каршы реакция» булып тора, дип билгеләп үтәргә мәҗбүр була. Ләкин әлеге «иптәшләр», ягъни РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты әгъзалары, моның өчен җәзага тартылмыйлар. Киресенчә, алар, татар милли хәрәкәте һәм татарларның милли мәнфәгатьләрен яклау позицияләрендә калган кешеләрне вазифаларыннан азат итүгә кадәр барып җитеп, җәза бирү өчен вәкаләт алалар. Моның өчен алар партия составында татар коммунистларының азрак булуыннан файдаланалар. 1930 елда Татарстан партия оешмасы составында руслар 52 процент, татарлар 38 процент тәшкил итә. Советлар съезды тарафыннан билгеләп куелган хөкүмәт рәисе Кашаф Мохтаров һәм аның командасы әгъзалары Г. Мансуров, А. Енбаев һ. б., шулай ук Советларның Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе Рәүф Сабиров хезмәт урыннарыннан партия карары белән азат ителә. Татар хезмәткәрләре дәүләт оешмаларына бары тик партия өлкә комитеты тәкъдиме буенча гына урнаша ала. 1926 елның 14 мартында өлкә комитеты Халык Комиссарлары Советы Рәисе вазифасына Хаҗи Габидуллинны, җир эшләре халык комиссары хезмәтенә А. А. Әхмәтшинны, хезмәт халык комиссары урынына Ш. С. Измайловны тәкъдим итә. Республиканың Үзәк Башкарма Комитеты (ҮБК) аларны хезмәт урынына бары тик Мәскәү расланганнан соң гына билгели.

Солтангалиевчелектә һәм милләтчелектә гаепләүләр, эзәрлекләүләр губерналарда һәм милли республикаларда яшәүче татарлар арасында эшләгән татар хезмәткәрләренә дә кагыла. Бу губерналарда һәм республикаларда татар һәм башкорт коммунистлары оешмаларының (секцияләренең) эшчәнлеге туктатыла. Алар нәшер итеп килгән газеталар ябыла башлый.

Совет хакимиятенең бу репрессив чаралары Татарстанда татар милли хәрәкәте позициясен какшата, Татарстаннан читтә яшәүче татар интеллигенциясенең милли-мәдәни эшчәнлеген кыенлаштыра. Ләкин татар милли хәрәкәтенең үзен бөтенләй юк итә алмыйлар. Татар милли хәрәкәте легаль рәвештә яшәвен дәвам итә. 20 нче елларның икенче яртысы Союз хакимияте органнары белән татар милли хәрәкәте эшлеклеләре арасында яңа ачык дискуссияләр чоры була. Татар-

станда һәм Россиядә татар дәүләтчелеге тарихы, татар милли икътисады, мәдәнияте, фәне мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләр бастырыла. Татар милли хәрәкәтенең милләтчелектә гаепләнгән эшлеклеләре үз милләтләренә хезмәт итүләрен дәвам иттерәләр. Шунысы игътибарга лаек: алар үз фикерләрен ачыктан-ачык, легаль төстә бәян итәләр. Солтангалиев, Мохтаров, Сабиров Мәскәүдә үзләренең советка каршы үзәкләрен булдыралар икән, дигән сүзләр, мөгаен, менә шуннан киткәндер. Калган татар милли хәрәкәте эшлеклеләре рәтендә алар Советларга каршы түгел, ә Россиядә билгеләнгән марксизмны, сукырларча күчереп, татар җәмгыятендә кабатлауга каршы чыгалар, татар җәмгыятендә милли гореф-гадәтләргә әверелгән ислам традицияләрен саклау кирәклегенә ышаналар. Татар милләтен сыйныфларга бүлгәләү сәясәте аларны канәгатьләндерми. Алар татар милли җәмгыятендә эшчеләрне, хезмәтчел крестьяннарны, вак һәм урта эшмәкәрләрне, эре милли буржуазиянең (сәнәгать буржуазиясенең), милли интеллигенциянең алдынгы өлешен берләштерүне күздә тоталар.

Хәер, алар Россия язмышына да битараф булмыйлар. М. Солтангалиев, бу хәлендә СССРның киләчәге юк, дигән караштa тора. Барыннан да бигрәк, дип яза ул, Россиянең милли кисәкләргә бүленүе, мөстәкыйль яшәүче яңа дәүләт организмнары хасил итүе ихтимал. Милли республикаларның уртак, коллектив хакимияте оешу да мөмкин. Аның фикеренчә, бу мөстәкыйль яшәүче милли дәүләтләрне тану булачак.

Татарстанда үзәк хакимияте. 1929 елда большевистик үзәкнең татар милли хәрәкәтенә каршы яңа һөҗүме башлана. Мартта Сталин милли мәсьәләне ничек аңлавын бәян итеп чыгыш ясый. Ул бигрәк тә үзе биргән милләт билгеләмәсенә тагын бишенче билгене, ягъни милләтнең үз милли дәүләте булырга тиеш, дип өстәргә тәкъдим итүчеләрне тәнкыйть итә. Чыннан да СССРда ул вакытта ук инде рус булмаган күп кенә милләтләр үз республикаларын булдыруга ирешәләр, һәм аларда милли дәүләт оешу процессы бара. Бу хәл татар милләтенә дә кагыла. Әйе, дип җавап бирә Сталин, феодализмның таркалуы һәм капитализмның үсеш алуы чорында, бу чыннан да шулай булган. Бу вакытта үзләренең милли дәүләтләре булган француз, инглиз, итальян милләтләре, Төньяк Америка милләте һәм башка милләтләр формалашкан. Аларны буржуаз милләтләр дип атау дөресрәк. Ул вакытта буржуазия һәм аның милләтче партияләре милли хәрәкәтнең башында

торган һәм милләтнең бердәмлеге хакына аның эчендә сыйнфый тынычлык идеясен алга сөргән. Ләкин бездә, СССРда, дип дәвам итә Сталин, хәзер инде буржуаз партияләр юк, алар урынына яңа совет (социалистик) милләтләре барлыкка килде. Бездә милли изү дә юк, «милли дәүләт киртәләре инде күптән бетерелде», милли хәрәкәтләрнең яшәве өчен җирлек тә юкка чыкты.

Бу сүзләр татар милли хәрәкәте (М. Вахитов, М. Солтангалиев, Г. Ибраһимов, С. Сәедгалиев) белән 1920 елда төзелгән килешүдән һәм бу вакытта ирешелгән компромисстан бер яклы гына ваз кичү өчен теоретик аклану була.

1929 елда Совет хакимияте, ОГПУ органнары катнашында, татар милли хәрәкәтен буржуаз милләтчелек хәрәкәте дип игълан итеп, аны эзәрлекли башлый. М. Солтангалиев кабат кулга алына. Татарстан Республикасының элекке җитәкчеләре Кашаф Мохтаров, Рәүф Сабиров, милләтчелек эшен дәвам иттерүдә гаепләнеп, репрессиягә эләгәләр. Бу репрессияләр Татарстаннан читтә — Мәскәүдә, Ленинград, Урал, Себер, Донбасс, Кавказ һәм Урта Азиядә яшәүче татарлар арасында эш алып барган татар милли хәрәкәте эшлеклеләренә дә кагыла. 1930 елда ВКП(б) Үзәк Комитеты рус өлкәләрендәге һәм башка милли республикалардагы җирле партия комитетлары каршында эшләп килгән барлык татар коммунистлары оешмаларын (секцияләрен) бетерү турында карар кабул итә. Ә бу оешмалар үзләре буржуаз милләтчелек оешмалары дип игълан ителә, аларның лидерлары репрессияләнә. 30 нчы елларда татар милли хәрәкәтенә аеруча авыр һөҗүм ясала. Татар халкының үзәк хакимияткә хуш килмәгән меңнәрчә вәкиле — дәүләт, җәмәгать, хуҗалык, мәдәният эшлеклеләре, дин әһелләре — «халык дошманнары» дип игълан ителә һәм репрессияләнә. Аларның барысына да бер үк стандарт гаеп тагыла — дәүләткә хыянәт итү. Гаепләү нәтиҗәсенең гаепләнүче яшәгән төбәк исеменнән, аның милләтеннән, эшләү-хезмәт итү сферасы атамасыннан кала барлык тәгъбирләре бер үк төрле була. Татарстанда репрессияләнгән татарларга карата булган гаепләү язмаларында, мәсәлән, болай диелә: «(Исем-фамилиясе куела) Татарстанда уң-троцкийчыл милләтчелек эшчәнлегендә гаепләнә. С. М. Кировны үтерүне оештырган, иптәш Сталинны, партия һәм хөкүмәтнең башка җитәкчеләрен физик яктан юк итү буенча террорлык актлары әзерләгән контрреволюцион троцкийчыл-пантюркистик Казан

үзәгендә актив катнашкан. Совет хакимиятен корал кулланып бәреп төшерү һәм капитализмны торгызу өчен оештыру эшләре алып барган. Советка каршы оешмаларга яңа әгъзалар җәлеп итүдә катнашып ... өлкәсендә (гаепләнүченең эшчәнлек сферасы күрсәтелә) корткычлык эшләре җәелдергән...»

СССРда законсыз дип игълан ителгән татар милли хәрәкәте чит илләрдә легаль рәвештә эшли, ә Союзның үзендә подпольега күчәргә мәҗбүр була.

Татар милли хәрәкәтенең тыелуы Союзда татар җәмгыятенең язмышына авыр йогынты ясый. Татар милләте милли идеянең генераторы һәм бу идеяне гамәлгә ашыру өчен массаларны оештыручы легаль милли иҗтимагый-сәяси үзәктән берничә дистә елга мәхрүм ителә. Юридик яктан татарларның автономиясе саклана, чынбарлыкта исә Татарстанда үзәкнең абсолют хакимияте урнаша. Сталин сүзләре белән әйткәндә, «милли дәүләт киртәләре» күптән бетерелгәнлектән, большевистик лидерлар Татарстан территориясенә милли территория итеп карамый башлый. Юридик яктан автономияле хакимият органнары — республиканың Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы саклана. Чынбарлыкта Татарстанга ВКП(б)ның җирле өлкә комитеты беренче секретаре сыйфатында Мәскәүдән җибәрелгән партия функционеры хәлиткеч фигурага әверелә. 1928—1937 елларда Татарстанда беренче секретарь постын М. П. Разумов, аннары А. К. Лепа били. Алар, үз чиратларында, ОГПУ контроле астында тора. Союзда теләсә нинди оппозицион сәяси гамәл Җинаять кодексы статьясына эләгә.

ВКП(б) өлкә комитеты бюросы чынбарлыкта республикадагы административ хакимият башында тора. Аның тәкъдиме буенча 1930 елда республика Үзәк Башкарма Комитеты сессиясе ҮБКның Рәисе итеп Харис Моратхуҗинны сайлый. Хөкүмәт (Халык Комиссарлары Советы) Рәисе постына К. А. Абрамовны билгели. Алар, республика хакимиятенең башка әгъзалары кебек, халык алдындагы үз бурычларын аңлыйлар, автономия өчен җаваплы булуларын беләләр. Ләкин, партия дисциплинасы белән кул-аяклары бәйләнгән хәлдә, үзәкнең татар милли хәрәкәте линиясенә каршы килгән күрсәтмәләрен берсүзсез үтәргә мәҗбүр булалар. Республиканың халык комиссариатлары, суд һәм башка органнары Союзның һәм Россия Федерациясенең үзәк учреждениеләренең гади вәкилләкләренә әверелә. Россиянең рус өлкәләрендә һәм башка

республикаларда татар милли районнары, татар милли авыл Советлары бетерелә.

Икътисади үзгәртеп корулар. Татар милли икътисадын җимерү Октябрьдән соң милли сәнәгать һәм җирне национализацияләүдән башлана. Татарларның сәнәгать предприятиеләре һәм сәүдә йортлары Россия дәүләте файдасына экспроприацияләнә. Татарларның крестьян хуҗалыклары кулакларга каршы комбедлар сәясәте белән көчсезләндерелә. Соңрак, 20 нче елларда Татарстанда, шулай ук рус губерналарының һәм башка республикаларның татар районнарында милли крестьян хуҗалыклары нигездә торгызыла. Шул вакытта ук татар нэпманнары милли сәнәгать предприятиеләрен һәм сәүдә йортларын торгызуга керешә.

Индустрияләштерү һәм коллективлаштыруның Совет хакимияте тарафыннан кабул ителгән ысуллары гамәлгә керү белән нэп чорында Россиядә башланган икътисади үзгәртеп корулар тәмамлана. Татар халкы яңадан үзенең милли икътисадыннан мәхрүм кала. Бу икътисад Союз дәүләте һәм Союзның Россия Федерациясендәге органнары карамагына күчә. Татар халкының табигый байлыклары да Союз дәүләте карамагында була. Автономия икътисади автономиясез кала.

30 нчы елларда Татарстанда икътисад үсеше гадәттәгечә генә бармый. Сугыш алдыннан булган өч бишьеллык дәвамында күп кенә эре хәзерге заман объектлары: җылылык станцияләре, авиация һәм мотор төзү заводлары, синтетик каучук заводы, аяк киеме фабрикасы һәм башкалар төзелә. Элекке дары заводы, җитен комбинаты, Вахитов исемендәге комбинат, Менделеев химия заводы һ. б. реконструкцияләнә һәм яңача эшли башлый. Рәсми статистикага караганда, 1940 елда республикадагы эре сәнәгать продукциясенең күләме 1913 елгы белән чагыштырганда — 12 тапкыр, машиналар төзелешендә һәм металл эшкәртүдә — 71 тапкыр, төзелеш материаллары җитештерүдә 1928 ел белән чагыштырганда 7 тапкыр арта. Боларның барысы да республика эшчеләре кулы белән төзелә һәм реконструкцияләнә, ләкин алар барысы да, элеккечә үк, Союз үзәге һәм Союзның Россия Федерациясендәге органнары кулында була.

Бер үк вакытта сугышка кадәрге бишьеллыклар республиканың җитештерүче көчләренең гаять зур җимерелүе чоры була. Хосусый милекчелекнең бетерелүе нәтиҗәсендә республика киң куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтү белән ни-

гездә тәэмин итеп килгән вак һәм урта эшмәкәрләреннән мәхрүм ителә. Бөтен җиңел һәм азык-төлек сәнәгатен үз кулында туплаган Союз хакимияте аларны үстерү турында аз кайгырта. Иң зур икътисади җимерелүләр 1929—1935 елларда үткәрелгән массакүләм коллективлаштыру аркасында килеп чыга. Кулакларны юк итү кампаниясе барышында барлык нык крестьян хуҗалыкларының һәм күпчелек урта хәлле крестьян хуҗалыкларының җитештерү потенциалы һәм мөлкәте конфискацияләнә, таланып бетә. Җитештерелгән бөтен продукциясен дәүләткә тапшырырга мәҗбүр булган колхозлар терлекләрнең баш саны буенча 1916 сугыш елы дәрәҗәсенә 1941 елда да ирешә алмыйлар. Рәсми статистика мәгълүматларына караганда, 1916 елда республика территориясендә 609,0 мең баш мөгезле эре терлек исәпләнсә, 1941 елда бу сан 524,0 меңгә генә җитә. Бөртекле ашлык хуҗалыгында да үсеш чамалы була. Бөртекле культураларның гомуми чәчү мәйданы 1928 елда 2516 мең гектар булса, 1940 елда ул 2633,7 мең гектарга кадәр (4,6 процент) үсә. 1928 елда бөртеклеләрнең тулай җыемы 1709,8 мең тонна булса, 1940 елда ул 1849,3 мең тонна (үсеш 8,1 процент) тәшкил итә.

Союз үзәге тарафыннан кабул ителгән планлы бүленеш (планово-распределительная) системасы, асылда, республиканы үз бюджетыннан мәхрүм итә. Димәк, автономиянең тагын бер атрибуты юкка чыгарыла дигән сүз. Республиканың барлык керемнәре Союз һәм Россия Федерациясе казнасына китеп бара. Дәүләт бюджеты расланган вакытта үзәк хакимият ел саен Татарстан Республикасы бюджетының микъдарын үзе билгели. Татарстан Советлары съезды, үз чиратында, әллә ни үзгәрешләр кертмичә генә, моны раслый. Хәлбуки бу бюджет республиканың чын финанс мөмкинлекләрен чагылдырмый. Үзәк хакимият республиканы Союз дәүләте донорына әверелдерә. Бу хәл Татарстанның социаль-мәдәни үсешен тоткарлый, халыкның матди тәэмин ителешен бик нык түбәнәйтә.

ТАССР Конституциясен кабул итү. 1937 елның 25 июнендә Татарстан Советларының XI гадәттән тыш съезды Татарстан АССР Конституциясен кабул итә. Ул 1936 һәм 1937 елларда кабул ителгән Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Конституцияләре нигезендә төзелә. Бу вакытта Татарстан Автономияле Республикасын үстерүнең икенче чоры тәмам-

лана. Беренче чорга 1925 елда, республиканың бишьеллыгы көннәрендә йомгак ясала. Бу татар милли хәрәкәте белән Союзның хакимият органнары арасындагы компромисс нигезендә Татарстан АССРның аякка басуы чоры була. Икенче чорда, бигрәк тә 1929 елдан соң, татар милли автономиясенең асылы бөтенләй үзгәрә. Татар милли хәрәкәте тыелганнан соң, ятим калган Татарстан тулысынча коммунистик абсолютизм тырнагы астында кала.

1939 елда үткәрелгән халык санын алу мәгълүматлары буенча Татарстан халкы 2915,3 мең кеше тәшкил итә. Ирләр 46,6 процент, хатын-кызлар 53,4 процент була. Халыкның 21 проценты шәһәрләрдә яши. 1940 елның гыйнварында республикада 63 район, 21 шәһәр һәм эшчеләр поселогы, 1683 авыл Советы, 4502 авыл исәпләнә. 1920 ел белән чагыштырганда халык составында татарлар саны 2,2 процентка кими һәм 48,8 процент тәшкил итә.

Татарстан Советлар Союзының мөһим сәнәгать базасына әверелә. Рәсми мәгълүматларга караганда, 1938 елда республикада 14 932 сәнәгать предприятиесе эшли. Аларда эшләүчеләрнең (өйдә эшләүчеләрне исәпкә алмыйча) уртача еллык саны 110 618 кеше тәшкил итә. Республиканың эре сәнәгатендә эшләүче татарларның саны 32 мең була, һәм бу тармакта эшләүчеләрнең 37,4 процентын тәшкил итә. 1926—1927 еллардагы бәяләр буенча 948 426 мең сумлык продукция җитештерелә. Кооперацияләнгән һәм кооперацияләнмәгән кустарьлар, ягъни вак һөнәрчеләр, халыкның 2,2 процентын тәшкил итә. Татарстан Союз фондына авыл хуҗалыгы продукциясен даими рәвештә җибәреп торучы төп төбәкләрнең берсе була. 1939 елда бу продукция дәүләт хуҗалыкларында (53 совхозда) һәм дәүләти-кооператив хуҗалыкларда (3893 колхозда) җитештерелә. Крестьяннарның 5,4 проценты аерым хуҗалык алып бара.

1937 елда кабул ителгән Конституция Төп Закон гына түгел, ә идеологик документ та була. Анда социалистик җәмгыять төзелү нәтиҗәсендә Татарстанда барган үзгәрешләр бәян ителә. Республика икътисадында хосусый милекчелек бетерелүе, аның урынын социалистик сектор (дәүләт секторы) алуы; Татарстанда җәмгыятьнең ике дус сыйныфтан — эшчеләр һәм крестьяннардан торуы; республикада гомуми сайлау хокукын һәм яшерен тавыш бирүне тәэмин итә торган сайлау системасы кертелүе билгеләп үтелә. Конституциядә граждан-

нарның төп хокуклары — хезмәткә, ял итүгә, белем алуга хокук, сүз иреге, матбугат иреге игълан ителә.

Конституция республиканың закон чыгару органы итеп башында Президиум торган Югары Советны раслый. 1938 елның июнендә Югары Советның I сессиясендә Югары Совет Президиумы Рәисе итеп Г. Ә. Динмөхәммәтов сайлана. Хезмәт ияләре Советлары район, шәһәр, поселок һәм авылларда дәүләт хакимияте органнары дип игълан ителә. Бер үк вакытта, Конституция дәүләт хакимияте органнарының ВКП(б) өлкә, шәһәр, район комитетларына буйсынырга тиешлеген раслый. Конституциянең махсус статьясы, Коммунистлар партиясе — хезмәт ияләренең барлык оешмаларының, шул исәптән җәмәгать оешмаларының да, дәүләт оешмаларының да җитәкче үзәге, дип бәян итә. Республиканың Гербы итеп Россия Федерациясе Гербы кабул ителә, тик анда «РСФСР» дигән сүз астына кечерәк хәрефләр белән «Татарстан АССР» дигән сүзләр өстәлә. Татарстан Флагы итеп РСФСР Флагы раслана, һәм аңа өстәмә рәвештә «ТАССР» дип язып куела.

СССРда гадәткә кергән күренеш — сүзнең эштән аерылуы яңа конституцияләр, шул исәптән Татарстан АССР Конституциясе кабул ителгәннән соң да сакланып кала. Гражданнарның хокуклары һәм ирекләре, шул исәптән җәмәгать оешмаларына берләшү хокукы тантаналы төстә игълан ителгән булуга карамастан, милли җәмәгать оешмаларын булдыру хокукы торгызылмый. Татарлар хезмәт ияләренең «интернациональ» җәмәгать оешмаларында һәм башка оешмаларында гына катнаша алалар. Татар милли хәрәкәте элеккечә тыелган хәлдә кала. Татарларга бары тик «интернациональ» коммунистик хәрәкәттә генә катнашырга рөхсәт ителә. Татар җәмгыятен «сыйнфый яктан чистарту» практикасы сакланып кала. Конституцияне кабул итү хакимият органнарының законсызлык актларын туктатмый. Моннан соң да рәхимсез репрессияләр дәвам итә.

Милли мәдәният. 30 нчы елларда совет идеологиясендә ике төрле мәдәният — үткән заманның буржуаз-милләтчелек мәдәнияте һәм социалистик мәдәният дип аталган хезмәт ияләре мәдәнияте турындагы миф киң таралыш ала. Менә шул мифка нигезләнгән совет сәясәте милли мәдәнияткә (милли мәгарифкә, фәнгә, милли әдәбиятка һәм сәнгатькә) яңа сынаулар алып килә. Татар җәмгыятенә татар милли мәдәниятен аның «реакцион үткәненнән» арындыру кампаниясе

көчләп тагыла. Мәдәниятнең милли атрибуты сыйфатында бары тик татар телен генә саклап калырга тәкъдим ителә. Бәйсез Татарстан чорының рухи мирасы (фәне, мәдәнияте, сәнгате) реакцион ислам мирасы дип, феодаллар-байлар мирасы дип игълан ителә һәм гамәлдән чыгарыла. Татарстанның Россия империясе составындагы чорының милли-мәдәни мирасы аның элеккеге чыганакларыннан ясалма рәвештә аерып күрсәтелә һәм ике өлешкә: ислам мәдрәсәләрендә (Мәрҗани һ.б.) тудырылган бай сыйныфлар мәдәниятенә һәм рус уку йортларында эшләгән (Хәлфиннәр һ. б.) яисә рус демократлары белән хезмәттәшлектә (Каюм Насыйри һ. б.), ә соңрак большевистик юнәлештәге рус социал-демократлары белән хезмәттәшлектә эшләгән (Гафур Коләхмәтов һ. б.) татар мәдәнияте эшлеклеләре тудырган демократик мәдәнияткә бүленә. Өстен сыйныф вәкилләренең иҗатына кагылышлы мәдәни мирас ислам-милләтчелек мәдәнияте мирасы дип күрсәтелә һәм тыела. Татар халкы билгеле бер вакытка үзенең мәдәни мирасы хәзинәсеннән ирекле файдалану хокукыннан мәхрүм ителә. Рәсми совет сәясәте татар халкын элек артта калган халыклар рәтенә куя. Гади рус халкында, Совет хакимиятенә кадәр татарларның хәтта үз мәгариф системалары да булмаган, дигән ялган караш урнаша.

Әмма әлеге миф уңышка ирешми. Совет хакимиятенең татар милли мәдәниятен өр-яңадан төзергә маташуы барып чыкмый. Татар милли мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре татар мәдәниятенең бердәмлеген яклап чыгалар. Галимҗан Ибраһимов, Һади Атласи һәм башка күпләр татар халкын мең еллык бай мәдәни мирасыннан аеруга каршы чыгалар. Кызганычка каршы, мондый чыгышлары өчен алар гомерләре белән түли. Татар милли мәдәниятенең күп кенә башка эшлеклеләре дә, милләтчелектә гаепләнеп, репрессиягә эләгә. Бу катлаулы чорда татар мәдәнияте хезмәткәрләре яңа тактикага күчә. Аларның күпчелеге коммунистик мифны сүздә таныйлар, гамәлдә исә милли мәдәниятнең тарихи берлеген яклыйлар. Нәтиҗәдә милли мәдәният коткарып калына.

30 нчы елларда милли мәдәниятнең үсүе өчен татар автономиясенең саклануы да үз ролен уйный. Сәяси һәм икътисади өлкәләрдә татар милли автономиясе деформацияләнүенә карамастан, бу автономия татар милли мәдәниятендә 20 нче елларда башлангыч алган уңай традицияләрнең үсүен тәэмин итә. Татар милли мәдәниятенең XX гасыр башындагы югары

казанышлары сакланып кына калмый, милли мәгариф системасы, матур әдәбият, театр, музыка, сынлы сәнгать югарырак дәрәҗәгә күтәрелә.

Татарстанның рәсми статистикасы, автономиянең егерме еллыгы билгеләп үтелгәндә (1940 ел), республикада (аның составына кермәгән, татарлар тупланып яшәгән төбәкләрне исәпкә алмыйча) милли мәдәният үсешенә йомгак ясый. 1939/40 уку елында Татарстанда мәктәп яшендәге 577 мең укучысы булган 3694 башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәп исәпләнә. Аларда укучыларның 281 меңе (49,5 процент) татар балалары була. Параллель рәвештә өлкәннәр өчен махсус мәктәпләр челтәре эшли. Татар укытучыларының саны 10 607 кеше исәпләнә. 1939/40 уку елында 14 югары уку йорты булып, аларда 11 мең студент, шул исәптән 1900 дән артыграк (17,2 процент) татар студенты укый. Техникумнарда һәм махсус урта уку йортларында барлыгы 13 393 студентның 5839 ы (43,6 процент) татар студенты була.

30 нчы елларда татар милли әдәбиятында яшь талантларның шактый зур төркеме формалаша, һәм ул, тулылана барып, татар әдәбиятын Советлар Союзының әдәбият дөньясында беренче позициягә чыгара. Алар арасында республика бишьеллыгын үзенең «Чаң» дип аталган беренче шигырьләр җыентыгы белән сәламләгән һәм киләчәктә күренекле татар әдибе һәм галименә әверелгән Нәкый Исәнбәт тә була. Шул ук елларда Кави Нәҗми, Таҗи Гыйззәт, Гомәр Толымбай, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Әхмәт Фәйзи, Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Әхмәт Исхак, Муса Җәлил, Сибгат Хәким кебек олуг язучыларның иҗади каләме формалаша. Алар чыгышлары белән бер Татарстан АССРдан гына түгел, Түбән Новгород, Саратов, Уфа, Оренбург һ. б. төбәкләрнең татар җәмгыятьләреннән килгән талантлар булалар. Аларны туплаган Татарстан Язучылар берлеге 1934 елда төзелә һәм татар автономиясе канаты астында эшли.

Әлеге язучыларның уңышы аларның татар милли традициясенә тугрылыклы булулары белән билгеләнә. Алар үзләрен Кол Галидән башлап Габдулла Тукайга кадәр булган татар милли мәдәнияте вәкилләре традицияләрен дәвам иттерүчеләр, аны үстерүчеләр итеп хис итәләр, татар милли дәүләтчелегенең үсеш перспективалары белән рухланып, иҗатларын тагы да үстерәләр. Гаяз Исхакыйдан башлап Галимҗан Ибраһимовка кадәр булган, революциянең һәм совет репрессия-

ләренең рәхимсезлегеннән җиңелмәгән, сынмаган өлкән буын язучылары образы алар өчен милләткә хезмәт итү үрнәге булып тора.

Татарстан АССР оешу белән Казанда Галиәсгар Камал исемен алган Татар дәүләт академия театры төзелә. Ул XX гасыр башы милли театр сәнгатенең лаеклы варисы була. 1926 елда профессиональ татар театр сәнгатенең егерме еллыгы тантаналы төстә билгеләп үтелә. Шул ук елны Касыйм Шамил, Мохтар Мутин, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Кәрим Тинчурин, Бари Тарханов һәм Зәйни Солтановка Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә. 30 нчы елларда татар театр сәнгатенә Камал III, Мәрьям Рахманкулова, Фәхри Насретдинов, Фоат Халитов, Мөнирә Булатовалар кебек яңа талантлы алмаш килә.

Татар дәүләтенең яклавы татар милли музыкасын яңа дәрәҗәгә күтәрә. 1925 елда, Татарстан АССРның бишьеллыгына Солтан Габәши, Василий Виноградов һәм Газиз Әлмөхәммәдов язган татар милли операсы «Сания» премьерасы була. Төп партияләрне Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Мәрьям Рахманкуловалар башкара. 30 нчы елларда талантлы татар композиторларының бөтен бер плеядасы үсеп чыга. Композитор, пианист, дирижер, җәмәгать эшлеклесе Салих Сәйдәшев (1900—1954) әнә шуларның берсе була. Җәләл Садриҗиһанов музыка өлкәсендә Салих Сәйдәшевне шигърияттәге Габдулла Тукай белән чагыштыра. Үзен тыйнак кына итеп Тукай маршының авторы, 1914 елда беренче татар кыллы оркестрын оештырган Заһидулла Яруллинның шәкерте дип атаган Салих Сәйдәшев ике чордагы — революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы чорлардагы — татар милли музыкасының җанлы элемтәсен гәүдәләндерә. Күпсанлы җырлары, симфоник оркестр өчен булган әсәрләре, музыкаль драмалары белән халык ихтирамын һәм мәхәббәтен казана.

1939 елда Казанда композитор Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы белән Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла. 1940 елда биредә Мансур Мозаффаров иҗат иткән «Галиябану» операсының премьерасы була. Татар милли мәдәнияте опера белән беррәттән XX гасырда алдынгы урыннарга чыккан балетка һәм комедиягә дә байый. 1942 сугыш елында театр Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен куя. 30 нчы еллар азагында Заһидулла Яруллинның улы Фәрит Яруллин, Габдулла Тукайның мәшһүр поэмасы

образларын музыкада гәүдәләндереп, «Шүрәле» балетын иҗат итә. Музыка белгечләренең бәяләмәсе буенча гаҗәеп талантлы һәм үзенчәлекле бу әсәр соңрак сәхнәдә гәүдәләнеш таба һәм шул вакыттан бирле театр сәхнәләреннән төшми. Татар халык җырларын музыкаль эшкәртү киң колач ала, камера-инструменталь әсәрләр — сонаталар, пьесалар һәм музыканың иң югары жанры булган симфонияләр иҗат ителә. 1939 елда Татарстан АССР Композиторлар берлеге оештырыла.

Татар дәүләтчелеге канаты астында 20 нче елларда ук милли сынлы сәнгать нык кына үсеп китә. 1936 елда Татарстан Рәссамнар берлеге оеша. Республика карамагында булган милли фән учреждениеләре челтәре киңәя. 1925 елда оештырылган «Татарстан белем җәмгыяте» эшен 1928 елда республика Халык Комиссарлары Советы каршында оештырылган «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» дәвам итә. Татар дәүләт Тел, әдәбият һәм тарих институты төзелә. Бу институтта, шулай ук Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында, педагогия институтында татар тел белеме (Латыйф Җәләй), әдәбият белеме (Мөхәммәт Гайнуллин), фольклористика (Хәмит Ярми), тарих, археология һәм этнография (Х. Г. Гыймади, Н. И. Воробьев, Н. Ф. Калинин) буенча фәнни тикшеренүләр һәм хезмәтләр бастырып чыгаруның яңа чоры башлана.

Татар дәүләтчелегенең бозылуы-үзгәрүе шартларында мәдәният үсеше зур кыенлыкларга да очрый. 1939 елның 5 маенда республиканың Югары Советы Президиумы, ВКП(б)-ның Татарстан өлкә комитеты күрсәтмәләрен үтәп, татар имлясын кириллицага нигезләнгән рус алфавитына күчерү турында Указ чыгара. 1939—1940 елларда мәктәпләр, 1940 елның 1 гыйнварыннан вакытлы матбугат яңа алфавитка күчә.

Яңа алфавит кертү Татарстан халык мәгарифе органнарының милли мәктәпләрдә рус телен өйрәнүне көчәйтү турындагы Союз хөкүмәте карарын үтәүләре белән бер үк вакытта алып барыла. Татар һәм рус телләре имлясы бер төрле булуы, чыннан да, татар мәктәпләрендә рус телен өйрәнүне җиңеләйтә. Хәер, рус телен өйрәтүнең яхшыртылуы татарлар өчен уңай әһәмияткә ия була. Ләкин хакимият органнары бу мәсьәләдә алган курс бер яклы гына булып чыга. Игътибар үзәгенең татар мәктәпләрендә рус телен өйрәтүгә күчерелүе милли телне өйрәтү проблемаларының онытылуына китерә. Алай гына да түгел, татар милли мәктәпләре челтәре гомумән

тарая бара. Яңа алфавитка күчү икенче бер тискәре процессны да тизләтә. Укырга һәм язарга латин язуы нигезендә өйрәнгән өлкән яшьтәге күп кенә татарлар кириллица буенча укый һәм яза белмәүчеләр булып кала. Яңа алфавитка күчүнең тискәре йогынтысы татар милли мәдәниятен үстерү өлкәсендә аеруча сизелә. Бу татар милли мәдәнияте өлкәсендәге икенче «сыйнфый чистарту» сыманрак бер нәрсә була. Феодаллар-байлар әсәрләре, сыйнфый яктан зарарлы әсәрләр дип игълан ителгән революциягә кадәрге татар әдәбияты гына түгел, Татарстан АССР яшәүнең беренче чорындагы буржуаз-милләтчелек әдәбияты дип бәяләнгән әдәбият та яңа алфавитта кабат бастырылмый. Димәк, латин имлясында бастырып чыгарылган гаять зур милли мәдәни хәзинә массакүләм кулланудан чыгарыла дигән сүз. Элек татар мәдрәсәләрендә өйрәнелгән Көнчыгыш телләрен (гарәп, фарсы һәм төрек телләрен) мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укыту туктатыла. Мәктәпләрдә Көнбатыш Европа халыклары телләрен укыту кертелгән булса да, татар интеллигенциясе бу телләрне белү дәрәҗәсе буенча революциягә кадәргедән артта кала.

ИКЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ

Бөек державаларның хәрби сәясәте. XX гасырның 30 нчы елларында дөньяга инде икенче тапкыр бөтендөнья сугышы куркынычы яный. Бөек державалар арасында беренче булып сугыш уты кабызу юлына Германия баса. 1933 елда бу илдә хакимият национал-социалистлар партиясе — Гитлер партиясе кулына тапшырыла. Германиянең яңа хөкүмәте алты ел идарә итү дәверендә илне «оттырышсыз сугышка әзерли». Германия халкын сугышка психологик яктан ике төп лозунг астында хәзерлиләр. Бу лозунглар беренче бөтендөнья сугышында җиңелү хурлыгын юып төшерү һәм, дөньяда яңа тәртип урнаштырып, немецларга «нордик арийлар» гына лаеклы булган югары дәрәҗәле тормыш рәвешен тәэмин итү кебек максатларны күз алдында тота. Генерал Мольткеның берьюлы ике фронтта сугыш алып баруның Германия өчен һәлакәтле булачагы турындагы искәрмәсе исәпкә алына. 1939 елның августында Сталин, СССР белән инглизләр һәм французлар арасында барган сөйләшүләрне өзеп, Гитлерның һөҗүм итешмәү турындагы ике яклы шартнамә төзү тәкъдимен кабул итә. Шулай ук Европада йогынты сфераларын бүлешү турында

«Молотов — Риббентроп» пакты төзелә. Гитлерның яшерен планы бик гади була: сугышның башында, СССРның «эндәшмәвеннән» файдаланып, Көнбатышта Бөекбританияне, Францияне һәм аларның союзникларын тезләндерү, ә аннан соң Көнчыгышта Россиягә каршы сугыш ачу.

Германия хөкүмәте үзенә союзниклар булдыру турында да кайгыртып куя. Национал-социализм идеологиясенә якын торган Муссолини хөкүмәте (Италия) һәм Азия континентына хаким булырга омтылган Япония хөкүмәте бу сугышта Германиянең союзниклары булырлар, дип уйланыла. Россиянең традицион рәвештә Төркиягә каршы юнәлдерелгән сәясәте төрекләрне бу сугышта Германия ягына этәрер, дип фараз кылына. Ниһаять, Германия сугыш алып бару өчен кеше һәм матди ресурслар, резервлар туплый: зур армия булдыра, аны техник яктан яхшылап коралландыра, өйрәтә, солдатларны һәм офицерларны милләт өчен җиңүле сугышның зарур булуына ышандыра.

Дөньяга сугыш куркынычы янауда җаваплылык Англия-Франция блогы өстенә дә төшә. Икенче бөтендөнья сугышының башлануы вакытына Бөекбритания һәм Франция, шулай ук аларның булачак союзниклары АКШ әлегә хәрбиләштерелмәгән державалар булалар. Шулай да бай һәм куәтле бу илләрнең Гитлерга каршы коалиция нигезен тәшкил итү, калган бөтен дөньяны үзләре тирәсенә туплау, дөньядагы конфликтларны сугышсыз гына хәл итү мөмкинлекләре була. Әмма алар булачак сугышта Германиянең национал-социализмын һәм совет коммунизмын маңгайга-маңгай бәрелештерүне үзләре өчен кулайрак күрәләр. Англия-Америка-Франция сәясәтчеләренең исәпләүләре буенча, сугыш бу һәр ике көчне зәгыйфьләндерергә, дөньяда тәртипнең үз вариантларын урнаштыру өчен юл ачарга тиеш була. Советлар Союзының сталинчыл җитәкчелегенең гаепле булуы да хәзер инде сер түгел. Ул вакытта бу җитәкчелек сугыш ярдәмендә совет коммунизмының хакимлек итү зонасын киңәйтү мөмкинлегеннән тәмам исергән була.

Менә шундый шартларда икенче бөтендөнья сугышы чынбарлык булып әверелә. Сугыш 1939 елның көзендә Германиянең Польшага һөҗүм итүе белән башланып китә. Моңа җавап итеп Бөекбритания һәм Франция Германиягә сугыш игълан итәләр. Баштарак бу сугыш Германиягә гел җиңүләр генә китерер кебек тоела. Польшаның бик тиз җиңелүеннән

соң, 1940 елгы сугыш кампаниясе барышында, Францияне дә кертеп, бөтен Көнбатыш Европа Германиягә буйсындырыла. Немец самолетлары көн саен диярлек Лондонны бомбага тота. Германия гаскәрләре Африкага десант төшерә һәм анда да инглизләрне кысрыклый башлый. 1940 елның декабрендә япон авиациясе Америка Кушма Штатларының Пирл Харбор хәрби диңгез базасына җимергеч һөҗүм ясый. Дөньяда яңа тәртип урнаштыруда беренче адым Германия өчен уңышлы гына башлана сыман. Англия-Франция блогы бу вакыт эчендә һаман чигенә, ләкин өметен өзми. 1940 елда сугышка АКШ килеп кушылганнан соң, бу өмет реаль гәүдәләнеш ала башлый.

СССРның халыкара акцияләре. 1939 елда Совет — Германия мөнәсәбәтләренең яхшыруы СССР өчен уңыш китерәчәк кебек тоела. Германия белән һөҗүм итешмәү турындагы шартнамә илнең турыдан-туры сугышка катнашуын кичектерә, ә «Молотов — Риббентроп» пакты территорияне киңәйтү өчен юл ача. Советлар 1939 елның 17 сентябрендә Украинаның элек Польша составына кергән көнбатыш өлкәләрен Украина ССРга, ә Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрен Белоруссия ССРга кушу буенча хәрби операция үткәрәләр. Совет гаскәрләрен Литва, Латвия һәм Эстониягә кертү юлы белән Совет хөкүмәте аларны да СССРга куша. Финляндиягә каршы канкойгыч авыр сугыштан соң 1940 елның 12 мартында төзелгән солых шартнамәсе буенча Карелия муентыгы, утраулары белән бергә Выборг култыгы, Ладога күленең көнбатыш һәм төньяк ярлары СССРга күчә. 1940 елның 31 мартында СССР Югары Советы бу территорияләрдә һәм Карелия АССР территориясендә Карело-Фин ССР төзү турында карар кабул итә. 1940 елның июнендә элек Румыния составына кергән Бессарабия һәм Төньяк Буковина (Черновцы өлкәсе) СССР составына күчерелә. СССР составында Днестрның сулъяк ярындагы Молдованы (Украина ССР составындагы Молдавия АССРны) һәм уңъяк ярдагы Молдованы (Бессарабияне) эченә алган Молдавия ССР төзелә. Төньяк Буковина Украина ССР составына кушыла. СССР элеккеге 11 урынына 16 союздаш республикадан торучы Союз дәүләте булып әверелә. Димәк, СССР дөнья сугышында рәсми төстә катнашмаган хәлендә дә территориаль отышлар ясый башлый. Бу турыда Германия хәзергә бернәрсә дә эндәшми. Англия-Франция блогы исә Мәскәүнең ил территориясен киңәйтү буенча кылган гамәл-

ләрен агрессия дип бәяли. СССР Милләтләр Лигасыннан чыгарыла.

СССР хөкүмәтенең гадәттән тыш чаралары. 1941 елның башында Германиянең СССРга һөҗүм итү ихтималы көчәя. Бик күпләр, Гитлер, Көнбатышта беренче җиңүләренә ансат кына ирешеп, анда озак тоткарланмас, вазгыятьне сәяси җайга салу эшләрен кичектереп торыр да, үзенең сугыш машинасын Көнчыгышка борыр, дип уйлый. Бишьеллыклар дәвамында хәрбиләштерелгән СССР, үз чиратында, совет социализмы тормышчанлыгын раслау максатында җиңүле сугышка исәп тота.

Дөрес, бу сугышка хәзерлек әле төгәлләнмәгән була. Совет дипломатиясе илнең сугышка керүен ахыр чиктә 1942 елның җәенә кадәр кичектерергә тырыша. Бер үк вакытта гадәттән тыш чаралар күрелә башлый. Җәмгыятьне оппозицион көчләрдән, ә кораллы көчләрне мөстәкыйльлеккә омтылучы хәрби башлыклардан арындыру бара. Алар өлешчә атып үтерелә, ә күбесе Төньяктагы һәм Себердәге ГУЛАГ лагерьларына сөрелә. 1941 елның маенда Сталин СССР Халык Комиссарлары Советы Рәисе итеп билгеләнә. Аның абсолют хакимияте партия функционерларының күпсанлы армиясе, Дәүләт иминлеге һәм Эчке эшләр халык комиссариатларының куәтле структуралары һәм армиядәге сәяси органнар белән тәэмин ителә.

Икътисадның сугышка юнәлдерелүе көчәя. 8 сәгатьлек эш көне һәм 7 көнлек эш атнасы кертелә, эшкә соңарып килгән һәм рөхсәтсез киткән өчен җәза билгеләнә. Колхозчылар эш көннәренең айлык мәҗбүри минимумы билгеләнә. Аны үтәмәгән өчен шулай ук җәзага тарталар. Дәүләткә авыл хуҗалыгы продуктларын (ашлык, ит, сөт һ. б.) мәҗбүри тапшыру микъдары колхозлар өчен аларга беркетелгән сөрү җирләре исәбеннән билгеләнә. 1939 елда Авиация сәнәгате, Кораллар, Сугыш припаслары, Суднолар төзү халык комиссариатлары булдырыла. Яңа хәрби заводлар эшли башлый. Яңа төр танклар (Т-34), реактив артиллерия установкалары, яңа самолетлар эшләнә. Сугышка кадәрге ике ел эчендә илнең кораллы көчләре составы 2,8 тапкыр арта һәм 5 миллион кеше тәшкил итә.

СССРның сугышка керүе. Сталинның тырышуына карамастан, СССРның икенче бөтендөнья сугышына керүен кичектереп торып булмый. 1941 елның 22 июнендә, якшәмбе көнне иртүк, Германия, һөҗүм итешмәү турында Совет — Германия

шартнамәсен бозып, хыянәтчел төстә, СССРга каршы киң масштаблы сугыш хәрәкәтләре башлый. Германия белән сугыш көтелгән булса да, ул кинәт башланып китә. Сугыш Германия өчен уңайлы, ә СССР өчен начар шартларда башлана. Немецларның бөтен Европа буйлап җиңүле төстә үткән сугыш машинасының даны ул чакта бик югары була. Англия-Франция блогы Германия белән киң масштаблы сугыш хәрәкәтләре башлап җибәрүдән әле бик ерак тора. Чынбарлыкта СССР Германиягә каршы берьялгызы сугыша.

Ул вакытка әле коралланү дәрәҗәсе һәм сугышу осталыгы буенча арттарак булган Кызыл Армия Баренц диңгезеннән алып Кара диңгезгә кадәр ике мең километрга сузылган гаять зур фронтта немецларның бик көчле һөҗүменә түзәр дип исәп тотып булмый. Өстәвенә ул саклый торган территорияләрнең шактый өлешендә (Балтыйк буе республикаларында, Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендә, Молдавиядә, Карело-Фин республикасында) Совет хакимияте әлегә ныгып урнашырга өлгерми.

Сугышның беренче көннәрендә, СССРның шактый тирән тылындагы шәһәрләрне бомбага тотып, механикалаштырылган җир өсте частьлары белән ил территориясе буйлап алга ыргылып, Германия командованиесе Совет Армиясенең сугышчан рухын, каршылык күрсәтү рухын сындырырга, халыкка психологик басым ясарга, Совет дәүләт органнарында каушау тудырырга омтыла. Германия сугышны башка республикаларга түгел, фәкать Россиягә каршы гына игълан итә дип сөйләнеп, Гитлер Союзга таркаулык кертергә, аны бүлгәләргә исәп тота.

Ләкин Гитлер бу исәпләрендә ялгыша. Советлар Союзы таркалмый һәм бирешми. Совет хөкүмәтенең илне тупларга көченнән килә. Үзенең радиодан мөрәҗәгатендә 3 июльдә Сталин бу сугышны бөтенхалык сугышы дип, *Бөек Ватан сугышы* дип атый. СССРда яшәүче халыкларның күбесе сугышның Ватан өчен баруын яхшы аңлый. Бу сугышта Германия гаскәрләре ягына чыккан һәм, алар исәпләгәнчә, Россияне коткару өчен, шулай ук үз республикаларын коммунистик абсолютизмнан коткару өчен немецлар белән иңгә-иң сугышкан кешеләр хәлиткеч көч булып оешып җитә алмый. Әмма андый көчләр дә була. Шул уңайдан республикаларның историографиясендә бу сугышка карата төрле караш формалаша.

Англия-Франция блогы да исәбендә ялгыша. Германиянең СССРга һөҗүм башлавының беренче көннәрендә үк Черчилль һәм Рузвельт үз хөкүмәтләре исеменнән, Бөекбритания һәм АКШ бу сугышта СССРга булышлык итәчәк, дип белдерәләр. Ләкин алар үзләре СССРның бирешмәячәгенә аз ышаналар. Әмма СССР бирешми, 1944 елның җәенә кадәр Европада Германиягә каршы чынлыкта берьялгызы сугыш алып бара һәм моның белән союзникларының Тын океандагы, Африкадагы, Көньяк Европадагы сугыш хәрәкәтләрен җиңеләйтә.

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ТАТАРЛАРНЫҢ МИЛЛИ ӨЛЕШЕ

Татар җәмгыятенең сугышка мөнәсәбәте. Сугыш башланган вакытка бердәм милләт тәшкил иткән татар җәмгыяте дәүләти яктан бүлгәләнгән хәлдә кала. Гомуми саннары 5,5 миллионнан артып киткән татарларның 1,5 миллион чамасы Татарстан Автономияле Республикасында яши. Калганнары республика территориясеннән читтә, башлыча Россиянең Татарстан белән күрше булган Идел-Урал төбәге республикаларында һәм өлкәләрендә, Себердә, Урта Азиядә яшиләр. Татар җәмгыятенең бу сугышка мөнәсәбәтен һәрьяклап күз алдына китерү һәм татарларның аңа керткән өлешен тулырак ачыклау өчен татарлар җитәрлек дәрәҗәдә тупланып яшәгән барлык төбәкләрдәге материалларны өйрәнергә һәм гомумиләштерергә кирәк булыр иде. Хәзергә мондый эш фәкать өлешчә генә башкарылган. Шуңа күрә без нигездә Татарстан АССР материалларына нигезләнеп фикер йөртәчәкбез.

Сугыш алдыннан булган чорда татар җәмгыятендә коммунистик абсолютизмнан ризасызлык көчәя. Икътисади өлкәдә бик күпләр хосусый милекчелекнең бетерелүе һәм хосусый эшмәкәрлекнең тыелуы, нык-таза крестьян хуҗалыкларының туздырылуы, сәнәгать һәм сәүдә эшмәкәрләренең экспроприацияләнүе белән ризалашырга теләмиләр. Татар җәмгыяте татар мөселман руханиларына каршы Россия тарихындагы чираттагы репрессияләргә, мәчетләрне ябуларга, мәсхәрәләүләргә, ислам белем системасын җимерүгә китергән сугышчан атеизм сәясәтен дә кире кага. Татар җәмгыяте, барыннан да элек милли интеллигенция, милләтләрнең тиздән кушылачагына йөз тоткан империячел сәясәт белән, рус дәүләт унитаризмының көчәюе белән ризалашырга теләми. Татар халкы

болай да бик нык кысылган автономияләренә юк ителү куркынычы янаганын аңлый. Һәм бу ризасызлык озак вакыт үзен сиздермичә кала алмаячак, барыбер бер өскә бәреп чыгачак иде.

Ул вакытта эш социаль кризиска кадәр барып җитми. Башланып киткән сугыш башка проблемаларны мәйданга чыгара. Барыннан да бигрәк, составына Татарстан АССР да кергән Россиянең дәүләт бәйсезлеге проблемасы, татарларның гомуммилли мәдәни һәм рухи тормышы җирлеге булган СССРның киләчәге проблемасы алда тора. Дәүләтара проблемаларны хәл итү чарасы буларак сугышка татар җәмгыятенең мөнәсәбәте катгый рәвештә тискәре була. Ә менә бу сугышның үзенә карата ул бертөрле мөнәсәбәттә генә тормый. Татар җәмгыятендә җыелып килгән ризасызлык кызуы бераз сүрелә төшә, ләкин юкка чыкмый. Бу ризасызлык татар җәмгыятенең билгеле даирәләрендә Россиядә тамырлары сакланган идеянең — «Россия патша хөкүмәтенең сугышта җиңелүен теләү» идеясенең — хәзерге хөкүмәткә нисбәтән баш калкытуы өчен нигез була. Советлар Союзының җиңелүе коммунистик абсолютизмның юкка чыгуы өчен тышкы этәргеч итеп карала. Илнең үз эчендә бу идея бары тик тирән подпольеда гына яши. Шушы идея тарафдарлары рәхимсез эзәрлекләнә. Хәлбуки татар милли оппозициясенең шактый өлеше яшәгән чит илләрдә хәл башкачарак була. Биредә бу сугышта Германиянең җиңүен кулайрак күргән татар эмигрантлары хәрәкәте формалаша һәм эш итә башлый. Аны «Идел-Урал» дигән газета нәшер иткән шул ук исемдәге комитет җитәкли. Комитет һәм газета, Россиядә коммунистик абсолютизмның җимерелүе Көнбатыш демократиясенең үзләштерелүе өчен, димәк, демократик татар дәүләтчелегенең тергезелүе өчен юл ачачак, дигән фикердә тора.

Татар җәмгыятендәге күпчелек исә оборонабчылык яклы була һәм сугыш бөтен халык сугышы, Ватан сугышы, дигән бәяләү белән килешә. Татарстан Республикасында һәм аннан читтә яшәгән татарларның төп массасы бу сугышта ил халкы белән бер сафта була.

Татарстанда хәрби мобилизация. Сугыш башлану белән хакимиятнең бердәм Мәскәү үзәгенә тупланауы үзенең иң югары ноктасына җитә. Илдә хакимиятне Дәүләт Оборона Комитеты (ДОК) гамәлгә ашыра. Бу Комитетта СССР хөкүмәте Рәисе Сталин җитәкчелек итә. 19 июльдә Сталин оборона

халык комиссары итеп билгеләнә. 8 августта ул СССР Кораллы Көчләренең Югары Башкомандующие һәм Югары Башкомандование Ставкасының Рәисе вазифасын да үз өстенә ала. Ставка тирәсенә Г. К. Жуков, Н. Г. Кузнецов, Н. Ф. Ватутин, Н. А. Василевский, Н. Н. Воронов, К. К. Рокоссовский, Л. А. Говоров, Д. Д. Лелюшенко кебек күренекле хәрби эшлеклеләр туплана башлый. Хәрби икътисад белән СССР Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары Н. А. Вознесенский җитәкчелек итә.

Татарстан сугышка юридик яктан автономияле республика саналган хәлендә керә. Ләкин унитар абсолютизм шартларында аның дәүләт хакимияте органнары үзәк дәүләт таләпләрен генә үти. Татарстан АССР Югары Советы сугышка керү мәсьәләсен тикшерми, 1943 елның урталарына кадәр аның сессияләре бөтенләй үткәрелми. Югары Совет Президиумы (Рәисе — Г. Ә. Динмөхәммәтов), хөкүмәт (С. Х. Гарифуллин) югарыдан төшерелгән күрсәтмәләргә рәсми законлы төс бирү белән генә шөгыльләнәләр. Барлык мәсьәләләр Союз үзәгендә хәл ителә. Ә үзәктән килгән карарларны гамәлгә ашыру бөтенләе белән турыдан-туры Политбюрога буйсынган ВКП(б) өлкә комитетына һәм аның беренче секретаре Александр Алемасовка йөкләнгән була.

ВКП(б) өлкә комитетының структурасы шактый киңәйтелә. Аның составында оборонага, авиация сәнәгатенә, җиңел сәнәгатькә, транспортка, сәүдәгә һәм җәмәгать туклануына җитәкчелек итүче секретарьлар булдырыла. Авылда дәүләт органнары структурасына кермәгән сәяси бүлекләр (политотделлар) төзелә. Алар ВКП(б) райкомнары белән беррәттән колхоз һәм совхозлар эшчәнлегенә сәяси һәм хуҗалык контролен тормышка ашыра.

Сугыш вакыты законнары буенча республикада мобилизация үткәрелә. Сугышның беренче айларында ук хәрби комиссариатлар командирлар составындагы, сержантлар һәм рядовойлар составындагы 195 мең кешене армиягә чакыралар. 1 октябрьдән 17 яшьтән 45 яшькә кадәр булган гражданнар өчен гомуми хәрби укулар башлана. Сугыш елларында Татарстанда җиде укчы дивизия, 91 нче аерым танк бригадасы оештырыла, һәм алар Татарстан АССР Югары Советы Президиумының шефлык байраклары белән фронтка озатыла. Алар республиканың үзе кебек үк күпмилләтле була һәм сугышта күп кенә фронтларның төрле армия корпуслары һәм фронт

армияләре составында катнаша, республика белән даими элемтәдә тора, республикадан тулыландыру өчен көчләр ала, аның делегацияләрен кабул итә.

Татарстан тыл районы булып кала. Республиканың көнбатыш чикләрендә дошманның разведка самолетлары күренүен һәм Казан тимер юлының көнбатыш участокларының 1941 елның көзендә бомбага тотылуын исәпкә алмаганда, сугыш хәрәкәтләре турыдан-туры аңа кагылмый. Шулай да 1941 елда Казан янында оборона сызыгы төзелә һәм Оборона комитеты булдырыла.

Хәрби сәнәгать. 30 нчы елларда җирле сәнәгатьнең зур булмаган предприятиеләрен исәпкә алмаганда, Татарстанның бөтен сәнәгате диярлек хәрбиләштерелгән, аны идарә итү үзәкләштерелгән була. Сугыш башлану белән республикадагы сәнәгать предприятиеләренең эше Союз хөкүмәте төзегән хәрби-хуҗалык планы нигезендә үзгәртеп корыла. Күпчелек предприятиеләр хәрби продукция җитештерүгә күчерелә. Болардан тыш Татарстанда көнбатыштагы фронт яны республикаларыннан һәм өлкәләреннән эвакуацияләнгән сәнәгать предприятиеләре дә урнаштырыла. Андыйлар арасында Мәскәү авиация заводы, Ленинград металл эшкәртү заводы, Вышний Волочек текстиль комбинаты һәм башкалар була. А. Н. Туполев, С. П. Королев, В. М. Петляков, В. П. Глушко, С. А. Чаплыгин, В. М. Мясищев һ. б. кебек күренекле хәрби техника конструкторлары Казанга күчеп эшли башлый. Сугыш елларында Казан авиация заводы сугышка 10 мең ПЕ-2, ПЕ-8 самолетлары бирә. Татарстан фронтны сугыш техникасы, сугыш кораллары, кием-салым белән тәэмин итүнең мөһим базасына әверелә. Сугыш елларында Татарстанда сәнәгать өчен нефть чыгару башлана. Беренче нефть фонтаны 1943 елның 2 августында Лениногорск районының Шөгер авылы янында Г. Х. Хәмидуллин бораулаган 1 нче номерлы скважинадан бәреп чыга. Татарстан нефтен чыгаруның башлангычы була бу. Ул вакытта да, соңрак республика җир мае чыгаруны елына 100 миллион тоннадан артыкка җиткергәч тә, бу нефть бөтенләе белән Союз ихтыяҗларын каплауга китеп бара.

Татарстан тылдагы йөкнең иң авырын тартып барган хәрби базаларның берсенә әверелә. Хәлбуки сугышка кадәр үк инде республика сәнәгате энергия кытлыгын, бина-корылмалар, чималлар җитешмәүне кичерә башлаган була. Азык-төлек, торак җитешми, шәһәр һәм поселокларның санитария

хәле, коммуналь хезмәт күрсәтү дәрәҗәсе түбән кала. Күпчелек ирләр фронтка киткәнлектән, эшчеләр саны, бигрәк тә квалификацияле эшчеләр саны кими. Эвакуацияләнгән предприятиеләр урнашу белән эшче көчләр кытлыгы, җитештерү мәйданнары, энергия җитешмәү тагын да кискенләшә.

Республика фронт барган районнардан эвакуацияләнгәннәрне кабул итә. Аларны республиканың үз азык-төлек фонды һәм торак фонды хисабына тәэмин итәргә кирәк була. 1942 елның язына республикада 266 мең эвакуацияләнгән кеше урнаштырыла. Казанда һәм республиканың башка шәһәрләрендә 15 мең бала тәрбияләнә торган 97 балалар оешмасы урын таба. Сугыш елларында республикада булдырылган һәм җирле ресурслар хисабына җиһазландырылган 50 эвакогоспитальдә 334 мең яраланган сугышчы дәваланып чыга. Казанда СССР Фәннәр академиясе фәнни көчләренең өчтән береннән артыграгы, Белоруссия ССР Фәннәр академиясе хезмәткәрләре урнаша, «Советский писатель» нәшриятының күп кенә китаплары басыла.

Республикада сугыш белән бәйле рәвештә туган барлык проблемалар бары тик хезмәтне интенсивлаштыру, хезмәт дисциплинасын ныгыту, азык-төлек белән тәэмин итүне минималь дәрәҗәдә катгый нормага салу, энергияне, торак һәм производство мәйданнарын экономияләү һ. б. хисабына гына хәл ителә. Предприятиеләрдән үз белдегең белән китү армиядәге дезертирлыкка тиңләнә. 1942 елның февраленнән республикада дәүләт учреждениеләрендә, предприятиеләрендә эшләмәүче 16 яшьтән 55 яшькә кадәр булган ирләрне һәм 16 яшьтән 45 яшькә кадәр булган хатын-кызларны производствода һәм төзелештә эшләү өчен мобилизацияләү турында хөкүмәт указы гамәлгә керә. Эш көне озайтыла.

1941 елның 1 ноябреннән дәүләт оешмаларында һәм предприятиеләрендә эшләүчеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына икмәк, ит, балык, май, ярмалар сатып алу өчен азык-төлек карточкалары кертелә. Предприятие һәм оешмаларда эшләүчеләргә индивидуаль һәм коллектив яшелчәчелек өчен бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрендә өстәмә рәвештә бәрәңге һәм яшелчәләр җитештерү рөхсәт ителә. Җирле сәнәгать органнары киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча кече предприятиеләр булдыра. Дүрт сугыш елы тыл хезмәткәрләре өчен авыр сынау еллары була. Алар, иске-москыга киенеп, ачлытуклы яшәп, атналар буенча цехлардан чыкмыйча эшлиләр,

әмма йөкләмәләрне төгәл үтәргә тырышалар. Хатын-кыз һәм бала-чагага бигрәк тә авырга туры килә.

Сугыш еллары авылы. Авыл сугышка коллективлаштыру белән башланган реформаны төгәлләмәгән хәлдә килеп керә. Моңа кадәр илне туендырып килгән хосусый крестьян хуҗалыклары бетерелгән була. Аларны алмаштырган колхоз һәм совхозлар әле ныгып өлгермәгән. Уйланылганча, алар дәүләт ихтыяҗларын гына түгел, колхозчы һәм совхоз эшчеләренең үз ихтыяҗларын да канәгатьләндерергә тиеш була. Чынбарлыкта исә колхоз һәм совхозлар хәтта уңыш мул булган елларда да дәүләткә ашлык тапшыру планнарын зур кыенлык белән үти. Колхозчыларга бүлеп бирү һәм совхоз эшчеләренә түләү өчен уңышның бик аз өлеше генә кала яисә бөтенләй калмый.

Союз хөкүмәте колхозчыларга һәм совхоз эшчеләренә зур булмаган шәхси хуҗалык (өй тирәсендәге җир кишәрлеге, чикләнгән күләмдә терлек) тотарга рөхсәт итә. Күмәк хуҗалыкта (колхозда яки совхозда) җитештерелгән бөтен нәрсә дәүләткә тапшырыла. Эшчеләргә һәм колхозчыларга шәхси куллану өчен үз хуҗалыкларында җитештерелгән продукция генә кала. Шул керемнәрдән алар әле тагын салым түлиләр, армиягә ярдәм күрсәтәләр, фронтовикларга бүләкләр җибәрәләр, авыл мәктәпләрен, хастаханәләрне дә игътибарсыз калдырмыйлар. Башка сүз белән әйткәндә, авыл халкы шәһәрдә яшәүчеләргә караганда авыррак хәлдә була. Яз көннәрендә күпләргә кырда кыш чыккан орлык, бәрәңге белән тукланып торырга туры килә, һәм бу хәл каты авыруларга сәбәп була. Аларны сугыш елларының даими юлдашы ачлык сагалый. Хәер, колхозлар дәүләт өчен бердәнбер котылу чарасы була, чөнки алар, елдан-ел киметеп булса да, дәүләткә авыл хуҗалыгы продукциясе җибәреп торалар.

Авылда хезмәт шартлары бик күпкә начарлана. Ирләрне армиягә җибәреп бетергәннән соң, авылдагы хезмәткә яраклы кешеләр саны бик нык кими. Сугышның беренче айларында ук 3 меңнән артык йөк машинасы, 400 гә якын иң яхшы трактор, шактый күп ат фронтка озатыла. Яңа техника, запас частьлар һәм ягулык-майлау материалларының килүе кими. Кул хезмәтенең өлеше арта. Күп кенә колхозларда дәүләткә тапшырыласы ашлыкны хатын-кызлар, бала-чагалар еш кына кул арбалары белән илтәләр. Чәчү мәйданнары, уңыш кими, җәмәгать секторында да, йорт тирәсе хуҗалыкларында да хайваннар саны азая, тулай уңыш күләме төшә. 1941 елда

Татарстан дәүләткә 656 мең тонна ашлык тапшырган булса, 1942 елда бу 412 мең тоннага кадәр кими.

Милли рух күтәренкелеге. Сугыш, илнең матди куәтенә сынау булу белән бергә, хакимлек иткән коммунистик идеологиянең көчсезлеген дә ачып сала. Сугыш алды елларында һәм сугыш башлангач та, Союзның хакимият органнары Россия — Германия сугышын фашизм белән коммунизм бәрелеше итеп күрсәтергә тырышалар. Ләкин тиздән алар коммунистик идеологиянең халыкны берләштерә, туплый торган рус идеясе дә, бөтенсоюз идеясе дә булмавына һәм була да алмаячагына ышаналар. Рус халкының барлык катлауларын рухи берләштерүгә омтылып, Совет хөкүмәте рус милли идеясе ярдәменә мөрәҗәгать итә. 1941 елның 7 ноябрендә Кызыл мәйданда сөйләгән речендә Сталин фронтка китүче солдат һәм офицерларны русларның милли хәрби даны традицияләренә турылыклы булырга чакыра. «Бу сугышта сезне бөек бабаларыбыз Александр Невский, Дмитрий Донской, Кузьма Минин, Дмитрий Пожарский, Александр Суворов һәм Михаил Кутузовның батыр образы рухландырсын!» — ди ул. 1942 елдан башлап армиядә русларның хәрби-тарихи традицияләре торгызыла. Командирларны офицерлар дип, кызылармиячеләрне солдатлар дип атап йөртә башлыйлар. Хәрби дәрәҗәләр (сержант, старшина, лейтенант, капитан, майор, полковник, генерал) торгызыла, погоннар кертелә. Суворов һәм Нахимов училищелары ачыла.

Хакимиятнең православие чиркәвенә мөнәсәбәте йомшара. Амнистиягә эләккән күп кенә дин әһелләре үз урыннарына кайтарыла, алар вәгазьләрендә солдат һәм офицерларны Ватан өчен сугышчан батырлыкларга рухландыра. Коммунистлар партиясе гимны «Интернационал» Дәүләт гимны булудан туктый. Яңа Дәүләт гимнында «Бөек Русьның» Союздагы башка халыкларны берләштерүдәге алдынгы роле ассызыклап әйтелә. 1919 елда Совет хөкүмәтенең бөтендөнья коммунизмы идеясе символы итеп оештырылган Коминтерн таркатыла. Бу фактлар әле Совет хакимиятенең коммунизм идеологиясеннән дә, бөтендөнья коммунизмы сәясәтеннән дә ваз кичкән булуын аңлатмый.

Ил эчендәге һәм халыкара аренадагы коммунистик көчләргә генә йөз тотуның чикләнгәнлеген аңлап, Совет хөкүмәте барлык патриотик көчләр белән хезмәттәшлек итәчәге турында белдерә.

Читләтеп кенә булса да СССР халыкларының милли берлеге идеясе танылa. Союздаш республикаларда Кызыл Армиянең милли частьларын оештыру башлана. Рус булмаган халыкларның милли тарихларының рус халкы белән берлектә чит ил басып алучыларына каршы көрәшен чагылдырган сугышчан традицияләренә мөрәҗәгать итү гадәти бер күренешкә әверелә. Чиркәүләр белән беррәттән мәчетләргә һәм башка халыкларның гыйбадәтханәләренә билгеле күләмдә ирек бирелә.

Республикалардагы милли институтларга Союз үзәгенең басымы йомшару Татарстанда да сизелә башлый. ВКП(б) Татарстан өлкә комитетының Беренче секретаре посты элек татарларның үзләренә ышанып тапшырылмаган булса (сугыш вакытында аны Алемасов, Колыбанов, Никитиннар били), 1944 елның июненнән бу вазифаны моңа кадәр өлкә комитеты секретаре булып эшләгән Зиннәт Моратовка (1905—1988) тапшыралар. Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Рәисе булып Динмөхәммәтов, Халык Комиссарлары Советы Рәисе булып Шәрәфиев калалар. Элек тыелган мәчетләр ачыктан-ачык эшли башлый, яңалары ачыла. Милли хәрәкәтнең легальләшүенә әле ерак булса да, милли идея татар җәмгыятендә үз позицияләрен торгыза башлый.

Татарларның милли тормышын тулысынча (мәдәни, икътисади һәм сәяси сфераларда) тергезү татар милли идеясе асылын тәшкил итә. 20 нче еллар азагында һәм 30 нчы еллар башында татар милли хәрәкәтенең һәм аның оешмаларының теләсә нинди төре, шул исәптән совет яклы булганнары да, бөтенләйгә тыелганнан соң татар милли идеясе даими рәвештә бастырылып килә иде. Ул милләтчелек идеясе дип, советка каршы идея дип игълан ителде. Әмма бу идея, бик куәтле булып, татар интеллигенциясе сафларында, барыннан да элек язучылар даирәләрендә легаль булмаган сыенып урын таба. 30 нчы елларда күп кенә татар язучыларына, татар милли идеясенә турылыклы калганнары өчен, коммунистик хакимият органнарының җәзасын күп тапкырлар татырга туры килә. Мәсәлән, Нәкый Исәнбәт тирәсенә тупланган «Җидегәнчеләр» дип аталган бертөркем язучыларның 1935 елда кулга алынулары мәгълүм. Шуннан соң башланган яңа репрессияләр Галимҗан Ибраһимовка, Гадел Кутуйга һәм башкаларга да кагыла. Шуңа да карамастан аларның берсе дә милли идеядән ваз кичми.

40 нчы елларда, аерым алганда сугыш елларында, татар милли идеясе яңа рәвешләрдә чагылыш таба. Инде әйтеп үтелгәнчә, сугыш башлану белән татар оппозициясенең бер өлеше, бу сугышны якларгамы яисә аны кире кагаргамы, киләчәктә дә Россия белән барыргамы яисә башкачамы, дигән сорауны куя. Шулай да татар җәмгыятенең зур өлеше XX гасыр башында ук тәгъбирләнгән татар милли идеясе традицияләренә турылыклы булып кала. Ул русларга да, Россиягә дә түгел, ә империячел идеягә каршы була. Татар милли идеясенең асылы сугыш вакытында да шулай кала. Татарларның милли тергезелүе коммунистик абсолютизмны юк итү контекстында, Россияне демократик яңарту контекстында карала.

Татар милли идеясен йөртүчеләр, аны кыю пропагандалаучылар булып элеккечә үк, беренче чиратта, татар язучылары кала. ВКП(б) әгъзалары булу-булмауларына бәйсез рәвештә, алар милли идеяне советка каршы идея итеп тә, Союзга каршы идея итеп тә санамыйлар. Язучылар әлеге Союзның империячел асылын гына кабул итмиләр. Аларны Союз үзәге идеологиясенең һәм сәясәтенең милләтләргә каршы булган сыйнфыйшовинистик, атеистик юнәлештә торуы борчый. Сугышның үзендә алар аның рәхимсез җимергеч көчен генә түгел, Союзның империячел асылын бетерү өчен, татар халкын милли тергезүгә юл ачу мөмкинлеген дә күрәләр. Сугыш вакытындагы либеральләшү шартларында милли идея милли традицияләргә, милли тарихка ихтирам төсендә легаль милли татар матбугаты сәхифәләрендә чагылыш таба, татар милли радиосы тапшыруларында яңгырый.

Татарстан Язучылар берлегенең 53 әгъзасыннан 25 е фронтка китә. Гражданнар сугышы чорыннан аермалы буларак, бу сугышта татарларның милли хәрби частьлары оештырылмый. Татарлар гомумроссия хәрби частьларында сугышалар. Татарстанның үзендә оештырылган хәрби частьлар да шундый була. Фронтта нәшер ителгән татар телендә чыгучы армия газеталары татар сугышчылары өчен милли рух чыганагы хезмәтен үти. Бу газеталарның редакцияләрендә Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Нур Баян, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Габдрахман Әпсәләмов, Абдулла Әхмәт, Ибраһим Гази, Әхмәт Ерикәй, Риза Ишморат, Гадел Кутуй, Шәйхи Маннур, Шәрәф Мөдәррис, Мөхәммәт Садри, Хатип Госман, Гали Хуҗи, Афзал Шамов һ. б. татар язучылары эшли. Тылда калган татар

язучыларының һәм журналистларның да күпчелеге фронттагы каләмдәшләренә кушыла.

Татар сугышчыларының фронтта күрсәткән батырлыклары, эшче һәм колхозчыларның тылдагы тырыш хезмәте турындагы мәкаләләр һәм хәбәрләр милли үзаң күтәрелүенә этәргеч була. Фронтта сугышкан татар солдатлары һәм офицерлары арасында, тылда хезмәт иткән татар эшчеләре һәм колхозчылары сафларында милли үзаң чагылышы көчәя. Татар зыялылары халыкның милли традицияләре турындагы темаларга, аның рухи истәлекләренә ешрак һәм кыюрак мөрәҗәгать итә башлый. Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә Нәҗип Җиһановның борынгы татар дәүләте чорындагы халык көйләренә нигезләнеп иҗат ителгән «Алтынчәч» (Муса Җәлил либреттосына) операсы куела. Татар халык эпосы «Идегәй» басмасы әзерләнә. Татар матбугатында Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык эпосы «Идегәй»нең 500 еллыгы» мәкаләсе дөнья күрә.

1943 елның мартында республика матбугатында һәм Союз күләмендәге «Правда» газетасында, шулай ук татар телендә чыга торган фронт газеталарында татар милли рухы белән сугарылган «Татар халкының татар фронтовикларына хаты» басылып чыга. Бу хатны язуда Татарстанның танылган язучылары катнаша. Хатка бер миллион ярымнан артыграк татарстанлы кул куя. Ватанга мәхәббәтнең милли традицияләре рухында һәм милли тарихка мөрәҗәгать итеп язылган бу хатны барлык фронтлардагы татар сугышчылары бик җылы каршы ала, һәм ул фронтовикларның тыл хезмәтчәннәре адресына патриотик рухтагы күп кенә җавап хатларына сәбәп була.

Татар милли тормышын Россия белән союз сакланган хәлдә тулы күләмендә тергезүгә юнәлдерелгән татар милли идеясен «урта юл» (центристский) идеясе дип атарга мөмкин булыр иде. Бу идея, ягъни татар милли мәдәнияте үзенчәлеген һәм автономиясен саклау идеясе яклылар Россия белән сәяси һәм икътисади интеграция идеясе өчен көрәшүче татар коммунистлары элитасы белән ризалашмый. Алар шулай ук Россиядән бөтенләй читләшү, Совет хөкүмәтенең җиңелүе ягында торучылар белән дә килешми. Сугыш елларында килеп туган либеральлек «урта юл»дагылар позициясен ныгыта. Күп кенә татар коммунистлары да бу линиягә йөз белән борыла башлый.

«Җиңелү тарафдарлары» татар җәмгыятендә үз позицияләрен югалта.

1942 елның җәендә «Идел-Урал» комитетының активистлары (герман гаскәрләре составындагы «җиңелү тарафдарлары») чакыруы буенча татар хәрби әсирләреннән һәм чыгышлары белән Идел-Уралдан булган хәрби әсирләрдән дүрт милли батальон («Идел-татар легионы») оештырыла. 1943 елда немец командованиесе боерыгын үтәү өчен, немец офицерлары командалык иткән бу батальоннарның беренчесе совет партизаннары хәрәкәтен бастыру максатында Белоруссиягә, өченчесе шундый ук максат белән Украинага, ә икенчесе һәм дүртенчесе француз каршылык күрсәтүчеләрен юк итү өчен Франциягә җибәрелә. Немецлар тылында хәрәкәт иткән татар милли идеясен яклаучы җәлилчеләр, бу батальоннардагы легионерларны Татарстанга һәм Россиягә тугрылык сакларга чакырып, яшерен эш алып баралар.

Соңрак немецлар бу төркемне фаш итәләр. 1944 елның 25 августында бу төркемнән 11 кеше (Муса Җәлил, Гайнан Курмаш, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Габдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Фоат Сәйфелмөлеков, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров) Берлинда, Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелә. Ә аларның легионерлар арасындагы эше нәтиҗәсез калмый. Батальоннарның дүртесе дә, немец командованиесенә каршы баш күтәреп, совет партизаннары һәм француз каршылык күрсәтүчеләре ягына чыга.

Татар сугышчылары фронтта. Татар милли идеясенең көче, татар милли рухының ныклыгы фронтта аеруча ачык чагыла. Татар сугышчылары гаҗәеп батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Русларның җиңүгә керткән өлешен, гадәттә, бөтен Совет Армиясе мисалында күрсәтәләр. Татар сугышчылары төрле хәрби частьларда хезмәт иткәнлектән, татарлар керткән милли өлешне күрсәтеп бирүе кыенрак. Күренекле рус тарихчылары Ю. М. Кораблев һәм Г. А. Куманев билгеләп үткәнчә, тикшерелгән 200 укчы дивизия составында татарлар уртача 2,69 процент тәшкил иткәннәр, гомумән алганда бу бик зур процент. Татарстанда оештырылган гаскәрләрдә бу сан тагы да күбрәк булган.

Фронтта ирешелгән уртак җиңүгә татарстанлылар (татарлар, руслар һәм башка милләт вәкилләре) керткән өлешне Җ. И. Гыйльмановның «Татарстан хезмәт ияләре Бөек Ватан сугышы фронтларында» китабы һәм «Татарстан АССР тари-

хы»ның «Татарстан Бөек Ватан сугышы (1941—1945) чорында» бүлеге буенча күзалларга мөмкин. Безнең уртак җиңүебезгә татарлар керткән милли өлешне тулырак күрсәтү өчен Татарстанда яшәүче татарларның гына түгел, Союзның башка төбәкләрендә яшәгәннәренең дә катнашуын исәпкә алу кирәк. Әле сугышка кадәр үк Кызыл Армия солдатлары һәм офицерлары арасында татарлар сан ягыннан руслардан, украин һәм белоруслардан кала дүртенче урында торган. Бу традиция 1918—1920 еллардагы гражданнар сугышында катнашкан татар хәрби частьларыннан ук килә.

Чик буе гаскәрләре, пехота, артиллерия, саперлык частьлары һ. б. составында, авиациядә һәм флотта татар сугышчылары әлеге сугышның беренче көннәреннән үк катнашалар. Литвадагы хәрби зиратларның берсендә элек Татарстанда яшәгән укытучы, Литва — Польша чигендә немецларның беренче һөҗүмнәрен кире кайтаруда катнашып һәлак булган чик сакчысы Даутовның кабере бар. Чик сакчылары төркеме белән бергә Карелиядә дошман юлына киртә куйган өлкән лейтенант Н. Ф. Кайманов бу сугышта Татарстаннан беренче Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Татар халкының батыр улы майор П. М. Гаврилов җитәкчелегендәге укчы полкның солдат һәм офицерлары, Польша — Белоруссия чигендәге Брест крепостен дошманның котырынып һөҗүм итүләреннән саклап, аны айдан артык үз кулларында тоталар. Республикада оештырылган Татарстан Югары Советы исемендәге 86 нчы укчы дивизия сугышның беренче көнендә үк Польша чигендә сугышка керә. Балтач районы егете, танкка каршы дивизион командиры Х. И. Ибраһимов сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Моннан соңгы елларда да татар сугышчылары Көнбатыш фронтлардагы гаскәрләрне тулыландырып тора, ә 1945 елда Көнчыгышта Япониягә каршы сугышларда да катнаша.

Оборона сугышларында. Сугышның башлангыч чорында совет гаскәрләре көч буенча үзләреннән күпкә өстенрәк дошманга каршы авыр сугышлар алып бара. Бу вакытта әле союзниклар тарафыннан да бернинди ярдәм булмый. Шушы көннәрдә Совет Армиясе солдатлары һәм офицерларының киләчәктә җиңүгә илтәчәк көчле батырлык рухы формалаша.

Шушы чорларда батырларча көрәшкән күп кенә татар каһарманнары турындагы истәлекләр дә сакланып калган.

1941 елның октябрендә Брянск тирәсендә татар язучысы, соңрак Германиядәге яшерен оешма эшендә Муса Җәлилнең көрәштәше Абдулла Алиш әсир ителә. 1942 елның 2 июлендә Новороссийск янында немецларның берьюлы биш катеры һөҗүменә дучар булган хәрби катерда каты яраланып, Чистай районының бер керәшен авылында туып үскән генерал П. Г. Новиков әсир төшерелә. 1936 елда Испаниядәге сугышта подполковник сыйфатында катнашкан Петр Новиков 1941 елда сугышны Прут елгасы районында 241 нче укчы дивизиянең командиры, полковник буларак каршылый. Одессаны, аннары Севастопольне саклауда катнашкан бу кеше, Ленин ордены кавалеры, дошман ягына чыгудан баш тарта, хәрби әсирләр лагерьларында газап чигә һәм бер әсирне мәсхәрәләүдән яклап һәлак була. 1941 елның июлендә Көнбатыш фронттагы 20 нче армиянең 18 нче укчы дивизиясе составында Смоленск тирәсендә С. А. Таһиров (соңрак аңа полковник дәрәҗәсе бирелә), Татарстан Югары Советы депутаты, гаубицалар дивизионы командиры Шаһи Садыйков, Балтач районыннан лейтенант Харис Җамалиев, Б. Х. Кадермәтов һ. б. каһарманнарча сугышалар. Шул ук елның сентябрендә Могилев янындагы оборона сугышларында соңыннан Советлар Союзы Герое исемен алган Сәхиб Майский командалыгындагы 519 нчы укчы полк катнаша. Турыдан-туры Мәскәү янында Волоколамск юнәлешендә ныгытылган район белән полковник, ә аннары генерал Сәедгәрәй Гайнетдинов командалык итә.

Сугыш кызганнан-кыза бара — безнең сугышчыларның каһарманлыгы торган саен көчәя. Бу аеруча Мәскәү тирәсендәге сугышларда күзәтелә. Бирегә Татарстаннан 146 нчы, 334 нче, 352 нче укчы дивизияләр җибәрелә. Алар составында күп кенә татар сугышчылары була. Тула өчен барган сугышларда подполковник Хәбиб Вәлиев җитәкчелегендәге танкка каршы истребитель полкы батырлык үрнәкләре күрсәтә. 1941 елның көзендә Актаныш районы егете Фәрваз Хөсәенов үзенең барысы 283 кә җиткән сугышчан очышларының беренчесен башлый. Тәтеш районы егете Әнвәр Әбдрәшитов та сугыш башында ук үзенең хәрби очышларын башлап җибәрә. 1941 елның декабрендә 352 нче һәм 334 нче укчы дивизияләр безнең гаскәр һөҗүмнәрендә катнашалар. Алексеевск районында туган полковник Зәки Кутлинның 270 нче укчы дивизиясе дә 1942 елның гыйнварында дошманга каршы һөҗүмдә катнаша.

Мәскәү янындагы тарихи бәрелешләрдә безнең гаскәрләр сугыш алып баруның гаҗәеп рәвешләрен кулланалар. Сухиничи тимер юлында Заһир Гайнанов һәм Петр Ткаченколар, кулларына танкка каршы гранаталар бәйләме тоткан хәлдә, һөҗүм итүче ике немец танкына каршы шуышып китәләр һәм, аларны шартлатып, үзләре дә һәлак булалар. Ноябрьдә Тихвин шәһәре өчен барган сугышларда рядовой Илдар Маннанов ике немец танкы белән кара-каршы торып көрәшкә күтәрелә һәм бер танкны сафтан чыгара. Әбрар Җәләлев исә немец бомбардировщигына каршы берьялгызы көрәшкә чыга һәм, кул пулеметыннан атып, очкычны бәреп төшерә. Гыйнварда өлкән сержант Мөлеков төркеме, төнге караңгылыктан файдаланып, фронт сызыгын үтеп чыга һәм дошман тылындагы күперне шартлата, дошманның өч танкын һәм 15 автомашинасын юк итә. 1942 елның февралендә дошман көчләренә разведка ясауда күрсәткән батырлыгы өчен Чувашстанда туып үскән татар егете Геннадий Гобәйдуллинга Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Бу сугышларда катнашкан танкистлар һәм очучыларның батырлыклары турында да әйтми үтү мөмкин түгел. Алар арасында Әхмәтгәрәй Рамазанов та була. Ул 1942 елның маенда Икенче һава армиясенең хәрби советы әгъзасы итеп тәкъдим ителә. 1941 елның августында безнең авиациянең Берлинга ясаган һава һөҗүмендә Әлмәт егете очучы Габдулла Галиуллин һәм Ульяновскида туып үскән штурман Гали Борхан да була.

1942 елның апрелендә генерал-лейтенант Ю. В. Новосельский җитәкчелегендәге 146 нчы укчы дивизия 50 нче армия составында сугышка керә. Дивизия алдына немецларның каршылык сызыгын өзү һәм дошман тылында эш иткән генерал Беловның атлы корпусына ярдәмгә килү кебек катлаулы бурыч куела. Дивизиягә бу заданиене дошман самолетлары һәм танкларының көчле һөҗүме астында үтәргә туры килә. Дошманның көчләрен үзенә җәлеп итеп, дивизия Белов гаскәрләренең хәлен җиңеләйтә, әмма үзе кешеләр составының яртысыннан артыграгын югалта. Дивизиянең батырлыклары Калуга өлкәсендәге Куян тавында каты сугышлар барган урынга куелган һәйкәл белән мәңгеләштерелгән.

1941—1942 еллар көзе һәм кышының авыр көннәрендә башка фронтларда да безнең сугышчылар күрсәткән каһарманлыкка сокланмый мөмкин түгел. 1941 елның сентябрендә Ленинградтан ерак түгел «Пантера» су асты көймәсе стар-

шинасы Әхмәт Мотаһаров «Октябрь революциясе» линкорына пике ясап һөҗүм иткән немец очкычын атып төшерә. Ростов янындагы операцияләрдә майор Фәрит Фаткуллинның эскадрильясе бер һава бәрелешендә генә дә биш немец очкычын бәреп төшерә.

1942 елның җәендә совет гаскәрләре инициативаны кулда тота һәм үстерә алмыйлар. Ленинград янында 2 нче удар армиянең язмышы фаҗигале була. Бу армиянең 327 нче укчы дивизиясе составында өлкән политрук Муса Җәлил дә хезмәт итә. Немецлар камап алган армиянең сугышчылары, азык-төлексез һәм коралсыз калып, камау боҗрасы аша ярдәм ала алмыйча, камалыштан вак төркемнәр белән мөстәкыйль рәвештә чыгарга дучар ителәләр. «Отвага» исемле армия газетасы хезмәткәре Муса Җәлил дә шундый карарга килә. Көчләр тигез булмаган бәрелешләр барышында, боҗрадан чыгу юлын эзләп, ул берничә тапкыр каты яралана һәм 26 июньдә, аңын югалткан хәлдә, немецларга әсирлеккә эләгә.

Тамырдан борылыш. Хәрби тарихчылар фикеренчә, сугышта Кызыл Армия файдасына булган тамырдан борылыш ил язмышы өчен хәлиткеч 1942—1943 еллар җәе — кышында хәзерләнә һәм гамәлгә ашырыла. Бу борылышның үзәгендә Сталинград сугышы тора. Нигездә рус сугышчылары белән комплектлаштырылган Кызыл Армия русларның милли армиясе булып кала бирә. Рус булмаган милләт вәкилләре якынча 30 процент тәшкил итә. Кызыл Армиянең Югары Башкомандующие хәрби частьларга карата таләпне бик нык көчәйтә. 1942 елның 28 июлендә Оборона халык комиссариатының 227 нче номерлы боерыгы чыгарыла. Анда «Югары Командованиенең боерыгыннан башка бер адым да артка чигенмәскә», «паникерлар һәм куркаклар шунда ук юк ителергә тиешләр», дигән таләп һәм күрсәтмә бирелә. Һөҗүмгә баручыларның артына тоткарлау отрядлары куела башлый, штраф батальоннары барлыкка килә. Көнбатыш төбәкләрнең немецлар кулында калулары аркасында, фронтны матди яктан тәэмин итү Союзның көнчыгыш республикалары һәм өлкәләре җилкәсенә төшә. Татарстан да шулар арасында була.

Татарстан әлеге тамырдан борылышны әзерләүдә үзеннән бик зур өлеш кертә: егет һәм кызларын фронтка озата, бөтен икътисади егәрлеген туплап, самолетлар, сугыш кораллары, кирәк-ярак, кием-салым, азык-төлек җибәреп тора. Күп кенә татар сугышчылары әлеге борылыш этабының үзәге булган

Сталинград фронтында көрәшәләр. Татарстанда оештырылган 147 нче укчы дивизия, 91 нче аерым танк бригадасы шушы фронтка җибәрелә. Генерал А. А. Волохин командалык иткән 147 нче укчы дивизия генерал В. И. Чуйковның 62 нче армиясе составына керә һәм июль-августта Сталинградка килү юлларында, шәһәргә ыргылучы дошман көчләрен тоткарларга омтылып, авыр оборона сугышларында катнаша.

Кышын сугыштагы тамырдан борылыш тагы да үстерелә. Фельдмаршал Паулюсның Сталинград янында чолгап алынган группировкасын юкка чыгару өчен барган сугышларда генерал М. С. Шумиловның 64 нче армиясе составында полковник Гани Сафиуллин командалык иткән 38 нче укчы дивизия катнаша. Дивизия, аерым алганда, немецларның 297 нче пехота дивизиясен тар-мар итә һәм дивизия белән командалык иткән генерал фон Дриттер җитәкчелегендәге штабны әсир төшерә. Башка фронтларда да борылышны тәэмин итү өчен безнең армиягә шулай ук бик күп көч сарыф итәргә туры килә. Калинин фронтының 49 нчы армиясе составында эш иткән 146 нчы укчы дивизия 1943 елның 8 мартында һөҗүмгә күчә һәм Варшава шоссесын өзә. 4 нче удар армия составындагы 334 нче укчы дивизия Смоленск өлкәсендә дошманның көч ягыннан өстен булган частьларына каршы авыр сугышлар алып бара. Көнбатыш фронтның 5 нче армиясе составындагы 352 нче укчы дивизия Гжатск шәһәрен азат итү өчен сугыша.

Сугышның икенче елында, безнең бөтен армиябез кебек үк, татар сугышчылары да, нигездә, оборона сугышларында катнашалар.

Ватан язмышын хәл иткән бәрелешләр. 1943 елның 5 июлендә Курск һәм Орел яннарында башланган бәрелешләр Бөек Ватан сугышының һәм икенче бөтендөнья сугышының язмышын хәл итә. Совет гаскәрләре инициативаны тулысы белән үз кулларына ала һәм тәмам җиңүгә ирешкәнгә кадәр аны кулдан ычкындырмый. Бер елдан соң, 1944 елның җәендә, Германия чикләрендә Икенче фронтны ачып, союзниклар да, ниһаять, үз бурычларын үти. Ләкин һөҗүм барганда да сугыш сугыш инде ул. Ул халыкның иң сәләтле, иң инициативалы, иң яхшы өлешен йота тора. Ул тылда шундый зур хезмәт куеп җитештерелгәннәрне үзенә суыра, сугышка кадәр үк булдырылганнарны җимерүен дәвам итә. Дөрес, бу чорда тыл хезмәтчәннәрендә дә, сугышчыларда да рух күтәренкелеге сизелә.

Курск-Орел бәрелешләрендә катнашкан татар сугышчыларының батырлыклары һәркемгә билгеле. Дошманның Орел группировкасына каршы торган Үзәк фронтта Поныри станциясе тирәсендә Бөгелмә егете капитан Рәхмәтуллин батальоны үз позицияләрен каһарманнарча яклый.

Немецларның Белгород группировкасына каршы торган Воронеж фронтында да җиңүгә татарлар керткән өлеш шактый зур була. Прохоровка янындагы атаклы танк бәрелешендә катнашкан 10 нчы танк корпусы татарстанлыларның шәхси акчаларына җитештерелгән, ян-якларына «Татарстан колхозчысы» дип язылган 200 танк белән коралланган була. Корпус белән Алабуга районы кешесе генерал-лейтенант В. Г. Бурков командалык итә. Әлеге бәрелештә күп кенә безнең якташлар, шул исәптән В. Халиков, К. Уразов катнашалар.

Татарстан хезмәтчәннәреннән бүләккә бирелеп, фюзеляжларына «Совет Татарстаны» дип язылган 102 ПЕ-2 самолеты 202 нче авиация дивизиясе составында дошманга һава һөҗүмнәре ясый.

Август аенда Көнбатыш фронт гаскәрләре үткәргән Смоленск тирәсендәге һөҗүм операциясендә 146 нчы укчы дивизия катнаша. Һәм ул Спас-Деменск шәһәрен азат итә. Сентябрьдә Калинин фронтында 334 нче укчы дивизия частьлары Велиж шәһәрен азат итә. Азат итүчеләргә рәхмәтле булган Велиж кешеләре шәһәр урамнарының берсен соңрак Казан урамы дип атый. Дивизиянең биш офицерына шәһәрнең мактаулы гражданы дигән исем бирелә. Хәрби командование документларында Көньяк фронтның Миус операциясендә һәм Таганрог шәһәрен азат итүдә катнашкан 148 нче укчы дивизиянең күп кенә татар сугышчылары батырлыгы билгеләп үтелә. 902 нче укчы полк сугышчысы Казан егете Абдулла Салихов үз тормышы бәрабәренә немец дзотын тончыктыра һәм Миус елгасының көнбатыш ярында һөҗүм алып барган полкташларына юл ача. Новороссийск шәһәрен дошманнан азат итү өчен барган сугышларда 318 нче укчы дивизиянең өлкән сержанты Мансур Вәлиуллин да аның батырлыгын кабатлый.

Азов хәрби флотилиясе корабльләре составындагы бронекатерда Әгерҗе районы егете Советлар Союзы Герое өлкән лейтенант Асаф Абдрахманов та дошманга каршы кыюлык һәм тапкырлык белән сугыша. Ул немецларның диңгез базасы булган Мариуполь портындагы бәрелештә катнаша,

дошманга каршы 30 дан артык очыш ясый, Керчь бугазында десант төшерү операцияләре вакытында һөҗүм итүчеләргә ярдәм итә.

Днепрны кичкән вакытта, Киевны һәм бөтен уңъяк Украинаны азат иткәндә дә татар сугышчылары тиңдәшсез батырлыклар күрсәтәләр. Бераз көньяктарак һөҗүм иткән Воронеж (Беренче Украина) фронты гаскәрләре Днепрга килеп чыга һәм аны Киевтан бераз төньяктарак кичеп үтә. Сугышып алган плацдармнарын Киевтан 20 километрга төньяктарак булган Лютеж шәһәренә кадәр киңәйтә. Бу операциядә үзенең танклары белән елганың уң ярында плацдармны беренчеләрдән булып яулаган өлкән лейтенант Ф. Шәрипов та катнаша. Ноябрьдә танкистлардан Ф. Шәрипов, Д. Ногманов һәм күп кенә башка татар сугышчылары Киевны азат итүдә турыдан-туры катнашкан частьлар составында булалар.

1944 ел — илнең бөтен территориясен немец гаскәрләреннән һәм Германиянең союзниклары көчләреннән азат итү елы — бигрәк тә истә калырлык була.

Кырымны азат иткән вакытта (Дүртенче Украина фронты һәм Аерым Диңгез буе армиясе) очучылар Мостафа Касыймов һәм Муштаков дошманның авиация базасын самолеттан торып фотога төшерү кебек катлаулы бурычны башкарып чыгалар. Операция тәмамланганда гына самолет зарарлана, Касыймов үзе авыр яралана, шулай да самолетын җиргә төшерә ала, рәсемнәрен кайтарып җиткерә һәм үзе санчастьта вафат була. Шул ук апрель аенда очучы-штурмовик Тимерлан Ишмөхәммәтов дошманның үзйөрешле баржасын батыра, әмма кире кайтканда дошман самолетларына тап була, алар белән сугышка керә һәм дошманнарның берсен бәреп юк итә. Оренбург егете очучы Шамил Әбдерәшитев Кырым операциясенә әзерлек барышында дошманның ике самолетын атып төшерә. Ә майда Кырым операциясе тәмамланганда ул, алты истребительдән торган төркем башында, Херсонес борынында урнашкан дошман аэродромын һөҗүмгә тота. Бурыч уңышлы үтәлә, ләкин һөҗүмнән чыккан вакытта аның самолеты атып төшерелә. 240 тан артыграк сугышчан очыш ясаган һәм дошманның 16 самолетын бәреп төшергән Шамил Әбдерәшитевкә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1944 елда булган Львов-Сандомир операциясендә генерал М. Е. Катуковның 1 нче танк армиясе танкисты Советлар Союзы Герое лейтенант Гали Шәмсетдинов батырлык күрсәтә.

Ул 13 июльдә дошман оборонасының алгы сызыгындагы «заслон»ны юк итү өчен җибәрелгән беренче батальоннар составында була. Ул вакытта Т-34 танкы 85 миллиметрлы туп белән коралландырыла. Бу сугышта Шәмсетдинов дүрт «юлбарыс» танкын яндыра. Армия газетасы «Шәмсетдиновка дан!» дигән шигырь бастырып чыгара. Ул чакта Львов шәһәре чикләренә бәреп кергән частьлар арасында Советлар Союзы Герое гвардия майоры Әхмәтулла Ишмөхәммәтовның мотомеханикалаштырылган батальоны да хәрәкәт итә. Август аенда генерал А. О. Ахманов танкистлары «Татарстан колхозчысы» танкларында Яссы-Кишинев операциясендә катнаша. Монда 69 нчы гвардия укчы дивизиясе сугышчылары батырлык үрнәкләре белән кабат дан казана.

1944 елның гыйнвар-февралендә татар сугышчылары Волхов фронты (командующие — генерал К. А. Мерецков), Ленинград фронты (командующие — генерал Л. А. Говоров), Икенче Балтыйк буе фронты (командующие — генерал А. И. Еременко) гаскәрләре составында Ленинград өлкәсен азат итүдә катнаша. Алар пехота, танк, артиллерия, авиация, саперлар частьларында үз тормышларын да аямыйча көрәшәләр. Псков өлкәсенең Овсищево авылын азат иткәндә сержант Газинур Гафиатуллин үзенең отделениесе белән беренче булып танкка каршы туплар батареясы янындагы дзотка килеп җитә, аны күкрәге белән каплап, һөҗүм итүче полкташларына юл ача һәм үзе батырларча һәлак була. Аңа үлгәннән соң Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә.

1944 елда Белоруссияне азат итү буенча бик зур операциядә Дубровка авылы янында 334 нче укчы дивизиядән Вәли Хаҗиев, Двина елгасын кичкәндә батальон командиры капитан Булат Янтимеров, Бобруйск янында штурм авиациясе очучысы майор Мисбах Хәлиуллин, Минскины азат итү вакытында үзйөрешле туплар дивизионы командиры капитан Абдулла Җиһаншин һ. б. сугышчан каһарманлык үрнәкләре күрсәтәләр. Генерал Ф. Г. Булатов җитәкчелегендәге 352 нче укчы дивизия дә бу операциядә үз өлешен кертә. Дивизия «Оршанская» дигән исем ала, ә аның укчы полкларына «Минский» дигән исемнәр бирелә. Минскины азат иткәннән соң, дивизия частьлары, сугыша-сугыша, Неман елгасы аша чыга һәм, туктап тормастан, Гродно шәһәре бистәләренә бәреп керә. Каһарманлыгы белән сугыш башында ук үзен данга күмгән Брест шәһәре һәм крепосте июль ахырында генерал-лейтенант

Якуб Чанышевның Беренче Белоруссия фронты составында хәрәкәт иткән 96 нчы Кызыл байраклы корпусы гаскәрләре тарафыннан азат ителә.

Тиздән совет гаскәрләре барлык урыннарда да СССР чикләренә барып чыгалар. 215 нче дивизия командиры генерал А. Казарян солдатларда дәүләт чикләренә беренче барып чыгу теләгенең бик көчле булуы турында искә ала. Аның дивизиясе участогында бу теләкне беренче булып татар сугышчысы Миңгали Гарипов гамәлгә ашыра. Ул дошман даими ут астында торган бер километр чамасы ераклыктагы чик буе елгасы ярына шуышып бара да флягасына елга суын тутырып кире кайта.

Казарян бу вакыйганы «Беренче совет солдаты Советлар Союзының дәүләт чигенә барып чыкты»,— дип бәяли.

Капитуляция һәм оккупация. Икенче бөтендөнья сугышының соңгы, йомгаклау актлары Көнбатышта — Германиянең капитуляция ясавыннан һәм союзниклар гаскәрләренең аның территориясен оккупацияләвеннән, ә Көнчыгышта Япония капитуляциясеннән һәм аның территориясен АКШ гаскәрләренең оккупацияләвеннән гыйбарәт була. 1944 елда немец гаскәрләре һәм Германия союзниклары гаскәрләре СССР территориясеннән куыла. Ноябрьдә Сталин: «Үткән ел совет җирләрен немец-фашист басып алучыларыннан тулысынча азат итү елы булды»,— дип нәтиҗә ясый. Ләкин бу әле сугыш тәмамланды дигән сүз түгел. Союзниклар Германия территориясен (көнчыгыш өлешен — Советлар Союзы, көнбатыш өлешен — АКШ, Англия һәм Бөекбритания) оккупацияләп, аның тулысынча капитуляция ясавына ирешү турында килешәләр. Ләкин немецлар капитуляциягә риза булсалар да, Германия территориясенең оккупацияләнүенә каршы чыгалар. Моннан тыш әле Япония капитуляциясе проблемасын да хәл итәсе була. Биредә дә союзниклар «берсүзсез капитуляция һәм оккупацияләү» шартын куялар. Капитуляция белән ризалашкан Япония шулай ук оккупацияләнү белән килешергә ашыкмый. Һәр ике якның үз сүзендә нык торуы аркасында, сугышның тәмамлануы ярты елдан артык вакытка кичектерелә. Сугышны дәвам иттереп, союзникларның хакимиятләре үзләренең комсыз державачыл максатларын күздә тоталар. Көнбатыш союзниклар Германиянең зур өлешен, Япония һәм башка илләрне коммунизмга каршы булачак көрәш өчен үз якларында ныгытып калдыруга ирешмәкче булалар. Советлар Союзы 1939 елгы Совет-Германия

килешүе һәм Финляндия белән төзелгән солых шартнамәсе нигезендә алган территорияләрен саклап калырга, шулай ук Көнчыгыш Пруссиядә яңа территорияләр алырга, Көньяк Сахалинны кире кайтарырга, Курил утрауларында ныгып калырга, Көнбатышта һәм Көнчыгышта коммунизм йогынтысы зоналарын киңәйтергә планлаштыра. Сугышның дәвам иттерелүе совет халкы һәм аның армиясе өстенә, дөньядагы башка халыклар җилкәсенә өстәмә авыр йөк булып төшә.

Татар сугышчылары да хәрби бурычларын намус белән үтәүләрен дәвам иттерәләр. Илдән читтә сугыш хәрәкәтләрендә катнашу алар өчен хәрби яктан гына түгел, ә социаль-сәяси яктан да әһәмиятле була. Польша һәм Чехиядә, Болгария һәм Словакиядә, Венгрия һәм Румыниядә, ә соңрак Германиянең үзендә үткән сугыш юлларында, шулай ук Италия, Франция һәм Бельгиядә Каршылык күрсәтүчеләр сафларында сугышканда, алар капиталистик дип аталган тормышны беренче тапкыр үз күзләре белән күрәләр, бу илләрдәге гади халык белән танышалар, союзник армия солдатлары һәм офицерлары белән очрашалар, немец гражданнары белән, элек хәрбиләр булган немецлар белән аралашалар, аларны күзәтәләр. Безнең солдатлар өчен яңа һәм кызыклы булган күп нәрсә аларны билгеле уйлануларга этәрә. Шул ук вакытта алар биргән антларына тугрылыклы кала, сугышның соңгы этабының да Ватан өчен мөһим һәм кирәк икәнлегенә ышана, үз илләрендә дә тормышның яңача көйләнәчәге турында хыяллана.

1945 елда генерал В. И. Чуйковның 5 нче армиясе составындагы 146 нчы укчы дивизия Польшаны азат итүдә катнаша. Удмуртиядә туып үскән Советлар Союзы Герое лейтенант Закир Солтанов 16 гыйнварда бертөркем сугышчылар белән беренчеләрдән булып боз өстеннән Висла елгасы аша чыга һәм Варшаваны азат итүдә катнаша. Генерал П. С. Рыбалконың 3 нче гвардия танк армиясе составында сугышкан Апас егете танкист Рәхим Җиһаншинның батырлыгы аерым билгеләп үтелә. Разведка төркеменә кергән башка танкистлар белән бергә ул Варта елгасы аша салынган күперне кулга төшерүдә катнаша, ә аннары дошманның килеп җитешкән өстәмә көчләре белән бәрелеш вакытында үзенең ут капкан танкын дошман тупланган төркем өстенә юнәлтә.

31 гыйнварда Будапешт янында автоматчылар взводы командиры, армиягә Чүпрәле районыннан алынган Советлар

Союзы Герое лейтенант Зариф Алимов батырларча һәлак була. Өч дәрәҗә «Дан» ордены кавалеры Рөстәм Халитов, дошманның каршылык күрсәтүен җимереп, танкында Австриянең Корнебург дигән шәһәре үзәгенә бәреп керә. 1 апрельдә 69 нчы укчы гвардия дивизиясе частьлары Австриянең Эйзенштадт шәһәрен ала һәм Венаны азат итүгә үз өлешләрен кертә. Подполковник И. Баһавиевнең реактив артиллерия дивизионы Чехословакияне азат итүдә катнаша. Биредә Алабугада туып үскән егет, 60 нчы армиянең разведка төркеме составында сугышкан өлкән сержант, «Дан» орденының тулы кавалеры Р. Х. Гайнуллин аеруча зур батырлык күрсәтә.

Сугышларның иң көчлесе немецларның үз җирләрендә була. Көнчыгыш Пруссиядә генерал Ф. Г. Булатов дивизиясе частьларына көчле сугышлар алып барырга туры килә. Апрель аенда күп кенә татар сугышчылары Кенигсберг (хәзерге Калининград) шәһәрен штурмлауда катнашалар. Ахун Мөхтәсимов, Яхъя Ибраһимовлар һава сугышларында батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Танкист Сабир Әхтәмов дүрт немец танкын, бер үзйөрешле тупны, ике бронетранспортерны сафтан чыгара. Февраль аенда сугышларда күренекле татар шагыйре Фатих Кәрим һәлак була. Сугышчы Абделхәй Сабиров, көрәштәше Фролов белән берлектә, шәһәр ачкычын кулга төшереп һәм бер бина түбәсенә кызыл байрак беркетеп, Кенигсбергны штурмлау каһарманы булып танылa.

Сугышның йомгаклау операциясе — Берлин операциясе — аеруча зур корбаннар бәрабәренә хәл ителә. Рейхның көнчыгыш чикләрен тәшкил иткән Одер һәм Нейсе елгалары буйлап урнаштырылган немецлар оборонасы сызыгын өзгәндә, 175 нче укчы гвардия полкы солдаты, «Дан» орденнарының тулы кавалеры, Әгерҗе егете М. А. Усманов каһарманнарча һәлак була. Одер һәм Нейсе елгаларындагы плацдармнардан апрельдә башланган Берлинны штурмлау операциясендә 146 нчы укчы дивизия дә катнаша. Шәһәргә төньяк-көнчыгыштан һөҗүм алып барып, дивизия сугышчылары Штеттин тимер юл вокзалының бер өлешен һәм шәһәр бистәләрен кулга төшерәләр. Һөҗүмне тагы да үстерә барып, 30 апрельдә алар Берлин үзәгенә барып чыгалар, Рейхстаг янындагы сугышларда катнашалар. Империя канцеляриясен штурмлаучылар сафларында подполковник Исхак Гомәров командалык иткән 1050 нче укчы полк та була. 1 майда Гомәров

капитуляция турында тәкъдим белән килгән немец генералын кабул итә һәм аны генерал В. И. Чуйков янына алып бара.

Беренче Украина фронты составында Советлар Союзы Герое Хәмзә Богданов командалык иткән 22 нче гвардия укчы дивизиясе Берлинга көньяктан һөҗүм алып бара. Шәһәргә һавадан бомба һөҗүмнәре ясауда самолет фюзеляжларына «Совет Татарстаны» дип язылган эскадрильяләр катнаша. Ул вакытта Советлар Союзы Герое очучы Тимерлан Ишмөхәммәтов Берлинга җиде сугышчан очыш ясый.

Берлин урамнарында үзенең сугышчан юлын Мәскәү яныннан ук башлаган минометчы старшина Фәттахов, туп төбәү командиры старшина И. Халиков, пулеметчы Г. Галиев, сержант Г. Мостафин, рядовой Г. Газизов, Беренче Украина фронтының «Ватан намусы өчен» газетасы хезмәткәрләре шагыйрь Мөхәммәт Садри һәм язучы Риза Ишморат һ. б. батырларча сугышалар. Корбан Тимергалиев һәм Ислам Насыйбуллиннар биредә «Дан» орденының тулы кавалеры дәрәҗәсенә ирешәләр. Тупчы сержант Габдулла Гарифуллин, үзенең сугышчылары белән, Беренче Белоруссия фронты частьлары һөҗүм алып барган юнәлештәге биек бина манараларының берсенә 23 апрельдә кызыл байрак беркетә. Составында 146 нчы укчы дивизия сугышкан Өченче һөҗүм армиясе командующие генерал В. М. Шатилов соңрак, Рейхстагны штурмлау сугышларын тасвирлап, Николай Хәбибуллин (Азнакай районы егете Кәлимулла Хәбибуллин) егетләре үз тупларын ишегаллары аша өстерәп бардылар да, аны Кенигс-плацның төньяк-көнчыгышында урнаштырып, дошманның Рейхстаг бинасындагы ут нокталарын юк итәргә тотындылар, дип билгеләп үтә. Рейхстагны штурмлау өчен юл шулай ачыла. 1 һәм 2 майда берничә штурм була һәм дошман хакимияте символы булган Рейхстагның язмышы хәл ителә. Рейхстаг бинасы түбәсенә кызыл байрак беркетүнең дә берничә очрагы була. Рус егете М. Егоров һәм грузин егете М. Контария «Җиңү байрагы» китабында (1975) татар сугышчысы Г. Заһитовның (иптәшләре белән бергә: А. П. Бобров, А. Ф. Лисименко, М. П. Минин) 30 апрель кичендә әле аларга кадәр үк Рейхстаг түбәсенә күтәрелүе һәм байрак беркетүе турында язалар.

Сугыш нәтиҗәләре. Татарстанның җиңүгә керткән өлеше шактый зур. Нык үскән хәрби сәнәгате, авыл хуҗалыгы өчен

бай мөмкинлекләре, квалификацияле кадрлары һәм уңайлы стратегик хәле Татарстанны Советлар Союзының иң мөһим тыл базаларының берсенә әверелдерә. Сугыш елларында Татарстан фронтка үзенең 700 меңгә якын кешесен озата. Республикада булдырылган «Хәтер китабы»на сугыш кырларыннан әйләнеп кайтмаган һәм яралардан госпитальләрдә вафат булган 320 мең кешенең исеме кертелгән. Фронтларда күрсәткән батырлыклары өчен 250 дән артык татарстанлы — татарлар, руслар һ. б. милләт вәкилләре — Советлар Союзы Герое һәм «Дан» орденының тулы кавалеры дәрәҗәсенә ирешәләр. Союз буенча исәпләгәндә, бу рус, украин, белоруслардан кала дүртенче урын дигән сүз.

«Бөек Ватан сугышы» дип аталган 1941—1945 еллар сугышы татарстанлылар тормышына гына түгел, бөтен ил буенча таралган татар халкы тормышына да зур үзгәрешләр кертә, тирән эз калдыра.

Сугыш елларында татар халкының милли үзаңы үсеше, күтәрелеше дәвам итә. Милләттәшләребезнең фронтта күрсәткән батырлыклары — Туган илгә тугрылык үрнәкләре алар. Фронттагы каһарманлык, тылдагы хезмәт энтузиазмы, ислам тормышының җанланып китүе, интеллигенция арасында милли идеянең яңа үсентеләре шытуы татар халкына милли тергезелү өчен яңа офыклар ача. Халкыбыз үз тормышына яңа күзлектән карап фикер йөртә, яңа милли перспективаларга сусавын тоя.

СУГЫШ САБАКЛАРЫ ҺӘМ ДӨНЬЯ БЕРЛЕГЕ

Тынычлыкка, азатлыкка таба. Тарихчыларның күпчелеге, икенче бөтендөнья сугышы котылгысыз булмаган, һәм аны берничек тә аклап булмый, дигән карашта тора. Бер илнең яисә илләр төркеменең теләсә нинди формадагы тоталитар хакимлеге — дөнья өчен һәлакәтле күренеш. Сугыш елларында уннарча миллион кешенең һәлак булуы, юк ителүе йөз миллионнарча кешенең мохтаҗлыкта, бәла-казалар эчендә яшәве шушы хакыйкатьне раслый.

Халыклар һәм дәүләтләрнең бер-берләреннән бәйлелегенең көчәюе халыкара мөнәсәбәтләрнең юридик нормаларын эшләүне таләп итә. Кешеләрне күпләп юк итү коралларын, барыннан да элек атом коралын куллануны коллектив рәвештә тыю, ә тора-бара андый җитештерүне туктату һәм

сугышны, гомумән, халыкара проблемаларны хәл итү чаралары арсеналыннан төшереп калдыру юлына кучәргә кирәк була. Мөстәкыйльлек өчен җитлеккән һәм аның өчен актив рәвештә көрәшүче халыкларны колониаль бәйлелектә көчләп тотуның гадел булмавы турындагы идея җәмәгатьчелек аңына сеңә бара. Эчке сәясәттә исә җәмәгатьчелек фикере аерым шәхесләргә һәм азчылыкка карата көч куллануның теләсә кайсы формасыннан (сәяси, идеологик, рухи формаларыннан) ваз кичүне таләп итә.

Дөньяда яшәүче төрле диндәге һәм төрле караштагы кешеләр иҗтимагый һәм халыкара мөнәсәбәтләрдә тынычлык, демократия, шәхес иреге, милли-дәүләти суверенлык кебек гомумкешелек кыйммәтләренә таянырга теләүләрен һәм бу теләкне гамәлгә ашыруда ныклык күрсәтәчәкләрен белдерәләр. Бу теләкләрнең гәүдәләнеше сыйфатында Берләшкән Милләтләр Оешмасы төзелә (1945), Тынычлыкны яклаучыларның бөтендөнья хәрәкәте оеша (1946), Кеше хокукларының гомуми декларациясе кабул ителә (1948), колонияләрне бетерү процессы башлана. Җир йөзендә БМО әгъзасы булган йөздән артык яңа бәйсез дәүләт барлыкка килә.

Союзниклар каршылыгы. Сугыштан соңгы дөнья төзелеше буенча җәмәгатьчелек фикере белән килешкән, гадел карарлар кабул итүдә бергәләп катнашкан союзниклар бу карарларны аңлауда, һәм, иң мөһиме, аларны тормышка ашыруда капма-каршы яктан торып эш итәләр. Дөнья үсеше перспективаларын аңлауга ике төрле, ягъни базар мөнәсәбәтләренә нигезләнгән либераль-капиталистик (АКШ, Бөекбритания, Франция) һәм планга нигезләнгән дәүләти-социалистик (СССР) карашларның булуы ачыклана. Якларның һәркайсы үз карашының өстенлекләрен исбатларга тырыша. Идеологик көрәш башланып китә. Аңа сәяси көрәш килеп кушыла, яңа хәрби-сәяси блоклар төзелә башлый.

Икътисади һәм хәрби яктан дөньяның иң куәтле державасы булган АКШ үзен «ирекле дөнья»га керүче барлык илләрнең гаранты дип игълан итә. Европаның сугыш нәтиҗәсендә бөлгенлеккә төшкән илләренә икътисади ярдәм күрсәтүне күздә тоткан «Маршалл планы» эшләнә (1949), АКШ химаясе белән хәрби-сәяси НАТО оешмасы — Төньяк Атлантика пакты (1949) төзелә. Бөекбританиянең элеккеге премьер-министры Уинстон Черчилльнең: «Атлантиканың теге һәм бу ягындагы англосакслар хәзер берләшергә һәм коммунизмга

җимергеч удар ясарга тиешләр»,— дип белдерүе зур сенсациягә әверелә. Әлбәттә инде «коммунизмга» дигән сүз астында СССР күздә тотыла.

СССРның коммунистик җитәкчелеге, үз чиратында, капитализмның һәм социализмның бергә сыеша алмаулары турындагы күптәнге идеягә, башка илләрдә социалистик революцияне «этәреп җибәрү» сәясәтенә әйләнеп кайта. Таратылган Коминтерн урынына Коминформ (Коммунистлар партияләренең информация бюросы — 1947) төзелә. Шул Коминформ аша КПСС Польша, Чехословакия, Венгрия, Болгария, Румыния, Албания, Югославия, Көнчыгыш Германия коммунистларына социализмның совет моделен көчләп тага. Социализмның дөнья системасы оешу турында игълан ителә, бу системаның хәрби-сәяси оешмасы булган Варшава шартнамәсе төзелә (1955). Ике хәрби-сәяси блок арасында тарихта *салкын сугыш* дип аталган конфронтация башлана. Үзара бәйлелектә булган бердәм дөнья ике төрле сәяси һәм җәмгыяви-икътисади системалар каршы торуының кискенләшүен һәм бу кискенләшүнең тискәре нәтиҗәләрен тоя башлый.

СССР хөкүмәтенең эчке сәясәте. Сугыштан соң чама белән ике ел дәвамында Союз хөкүмәте «көтеп тору» тактикасын куллана. Ул сугыш чорында туган либеральлеккә әледән-әле идеологик һөҗүмнәр ясау белән чикләнә, әмма аны бөтенләй чикләүгә үк бармый. Рәсми пропаганда сугыш вакытында хәрби һәм хезмәт дисциплинасын тәэмин иткән, гаять зур илнең барлык матди һәм кеше ресурсларын үзәк кулында тупларга һәм аларны «бәһасеннән тормыйча җиңүгә ирешү өчен»файдаланырга мөмкинлек биргән коммунистик абсолютизмга мәдхия укый. Җиңүнең даны-шөһрәте коммунистик система белән халык арасында бүленә.

Союз хакимиятенең эчке сәясәтендәге кискен борылыш 1948 елда башлана. Гитлерның төп оппоненты һәм национал-социализмны җиңүче сыйфатында тәкъдим ителгән Сталин илне коммунистик абсолютизм режимына таба борырга карар итә. Халык массаларын дулкынландырган реформалар турындагы идеяләр рус халкының һәм илдәге башка халыкларның милли мәнфәгатьләренә каршы булган чит ил империалистларының һәм эчке дошманнарның казынулары итеп игълан ителә. Америка Кушма Штатлары рус халкының һәм славян халыкларының, шулай ук СССРдагы бүтән халыкларның күптәнге дошманы итеп тасвирлана. Германия Федератив

Республикасына карата дошманлык хуплана. Илдә сугышка кадәрге эчке дошман образы яңадан тергезелә. Сугышка кадәрге сыйнфый дошманнар рәтенә сугыш вакытында теге яисә бу рәвештә немецлар белән хезмәттәшлек иткән һәркем — немецларның төрле хәрби частьларында хезмәт итүчеләр, шулай ук оккупацияләнгән өлкә һәм республикаларда староста, полицай, рухани вазифасын башкарганнар өстәлә. Сугыш елларында безнең сугышчылардан 5,7 миллион кеше, шул исәптән 1941 елда 3,9 миллион кеше немец әсирлегенә эләгә. Хәрби әсирләр белән мөгамәлә турындагы 1929 елгы Женева конвенциясенә кул куймаган Союз хөкүмәте аларның барысын да әсирләр дип түгел, ә хыянәтчеләр, җинаятьчеләр дип игълан итә. Аларның барысын да Ватанга кайткач, ышанычлылармы, юкмы икәнлекләрен ачыклау өчен, кимсетеп-түбәнсетеп «фильтр» аша үткәрәләр. Аларның бер өлеше иректән мәхрүм итү урыннарына озатыла. Рәсми мәгълүматларга караганда, 1939 елда ГУЛАГ (Лагерьлар баш идарәсе) системасында 1 317 195 тоткын, шул исәптән татар милләтеннән булган 24 899 тоткын була. Монда да татарлар, рус, украин, белоруслардан кала дүртенче урында торалар. Сугыш башланган вакытта ГУЛАГ системасындагы тоткыннарның гомуми саны исә 2550 мең була. 1941—1944 еллар эчендә лагерьларга 2550 мең кеше китерелә һәм 3400 мең кеше чыгарыла. 1945 ел башында анда 1450 мең тоткын исәпләнә. Сугыштан соң лагерьларга репрессиягә яңа эләккән кешеләр килеп тула. Кайбер тарихчыларның исәпләүләренә караганда, 1953 елга бу система бер миллион кешегә тулылана. Безнең халык тагын лояль кешеләргә һәм «халык дошманнары»на аерыла.

Халыкның социаль активлыгы. Коммунистик абсолютизмны торгызуга һәм җәмгыятьтә шәхси хакимиятне ныгытуга юнәлеш тотып, Сталин бик нык ялгыша. Совет җәмгыяте сугышка кадәрге чорга караганда шактый алга киткән була. Җәмгыятьтә яңа бер сыйфат — хакимият башында торучыларга карата тәнкыйди мөнәсәбәт формалаша. Дөрес, коммунизмның уңай мөмкинлекләренә ышану әле саклана. Шул ук вакытта кешеләр, сугыш вакытында «җиңүгә бәһасеннән тормый ирешү» сәясәтенең нигезлеме, түгелме икәнлеге турында уйлана башлыйлар. Аларны илнең ярлы хәлдә яшәве борчый. Илне сугыштан соңгы торгызу берьяклы гына алып барыла. Бар булган акча илнең сугышчан куәтен арттыруга,

шул исәптән атом коралын һәм аны җиткерү чараларын булдыруга, Советларга йөз тоткан социалистик илләрнең һәм азатлык яулаган элеккеге колониаль илләрнең хөкүмәтләренә хәрби-сәяси булышлык күрсәтүгә юнәлдерелә. Ә илнең үз халкын, инде башка төрле азык-төлек продуктлары турында әйткән дә юк, туйганчы икмәк белән тәэмин итәрлек тә мөмкинлеге калмый диярлек.

1945 елның июнендә Мәскәүдә үткәрелгән Җиңү парадында ясаган чыгышында Сталин гади кешеләрне җәмгыятьнең «шөрепчекләре» дип атый. Ә баксаң, әлеге «шөрепчекләр» «юлбашчыларның» ни сөйләүләре һәм ни кылулары турында мөстәкыйль рәвештә хөкем йөртә башлаганнар икән ич. Әнә КПСС Үзәк Комитеты секретаре А. А. Жданов 1947 елда, фәлсәфә фәненә бернинди катнашы булмаса да, философларны фәнни хезмәт язарга өйрәтергә алынып, алар алдында абруен какшата. Хәер, Сталин үзе дә, фәнни хезмәткәр булудан бик ерак торса да, тел белеме, политэкономия, фәлсәфә өлкәсендәге «ачышлары» белән халык алдында көлкегә кала. Ә бераз соңрак Л. И. Брежнев та үзенең «Кече җир»е белән «дан казана».

Сугыштан соңгы Советлар Союзында милли фактор. Сугыш елларында совет милли сәясәтенең либеральләшүе, рус халкында һәм Союздагы башка халыкларда милли үзаңның үсүе Союз дәүләтендә милли факторның әһәмиятен башкача бәяләүгә этәрә. Кешеләр милли нигилизм сәясәтен кире кага башлый. Россия Федерациясе рус милли тормышын җайга салуда Союз үзәгеннән күбрәк мөстәкыйльлек алырга омтыла, бу эштә инициатива күрсәтә. Моңа кадәр КПСС Үзәк Комитетына буйсынып килгән өлкә комитетларын турыдан-туры үзендә берләштерергә тиеш булган Россия Федерациясе Коммунистлар партиясен төзү, Россия Федерациясе башкаласын Свердловскига күчерү һ. б. проектлар эшләнә. Союз үзәгенең моңа мөнәсәбәте үзенчәлекле була. 1945 елның 24 маенда Кремльдә ясаган чыгышында Сталин рус халкын Союзда «җитәкче халык» дип белдерә. Мәсьәләне болай кую, руслар үзләренең милли тормышларын, элеккечә үк, бөтен Союз күләмендә үстерә һәм җайлый алалар дигән сүз була.

Рус булмаган халыкларның союздаш һәм автономияле республикаларына карата милли сәясәтнең үзгәртелүе мәсьәләсе дә актуальләшә. 1941—1944 елларда Союзда депортацияләнгән халыклар трагедиясе әле барлык кешеләрнең хәтерендә була. 1941 елның августында СССР Югары Советы

Президиумы Указы нигезендә Идел буе немецларыннан бер миллионнан артык кеше яшәү урыннарыннан читкә чыгарыла һәм аларның автономияләре бетерелә. 1943 елның октябрендә шундый ук указ нигезендә Эчке эшләр халык комиссариаты (НКВД) гаскәрләре «калмык милләтеннән булган шәхесләрне» (93 139 кеше) күчереп урнаштыру «операциясе» үткәрә. Алдан хәбәр итмичә һәм аңлатып тормыйча, әйберләрен ярым-йорты гына алырга рөхсәт итеп, аларны товар вагоннарына төйиләр дә Алтай һәм Красноярск крайларына, Омск һәм Новосибирск өлкәләренә озаталар. Идел буе немецлары милке ничек таланса, аларның да калдырып киткән мал-мөлкәтен шундый ук язмыш көтә. Карачайларны (68 327 кеше), чечен һәм ингушларны (496 460 кеше), балкарларны (37 406 кеше), Кырым татарларын (183 155 кеше), Грузиянең көньяк чик буе районнарыннан Месхети төрекләрен, көрдләрне, хемшилларны (91 095 кеше) — барысы ике миллионнан артык кешене әнә шулай «күчереп урнаштыралар». Шулай итеп, Союзның кайбер милләтләре тулысынча үз тарихи ватаннарыннан көч кулланып мәхрүм ителә. Аларның Конституция белән гарантияләнгән автономияләре берниндиi нигезсез юкка чыгарыла. Унитар дәүләт шартларында теләсә кайсы республиканы шундый законсызлык көтәргә мөмкин.

Мондый чара Татарстан Республикасын читләтеп үтә. Сугышта Татарстанның, татар халкының роле бик зур була шул. Хәер, 1944 елның августында республикада «милләтчелек характерындагы җитди кимчелекләр һәм хаталар» турында Союз партия үзәгенең шом салган карары кабул ителә. Бу карарда, аерым алганда, Татарстанда «Алтын Урда тарихы бизәп күрсәтелә, Идегәй турындагы, ханнар, феодаллар турындагы дастан популярлаштырыла», дип искәртелә. Бу карар, дәһшәтле кисәтү рәвешендә, сугыштан соң да үзенең көчен саклый.

ТАТАРСТАН СУГЫШТАН СОҢГЫ ЕЛЛАРДА

Сугыштан тыныч тормышка күчү. Татар сугышчылары туган якларына Союз дәүләте алдындагы бурычларын үтәгәнлек хисе белән, горурлык хисе белән кайталар. Аларны өйдә көтеп алучылар да җиңү горурлыгы кичерә. Бу сугышта ятып калганнар өчен бергәләп кайгыралар, исән-имин кайтканнар өчен чын күңелдән шатланалар. Тормышларында туачак уңай

үзгәрешләргә өметләре якты була. Ә хәзергә күп нәрсәдә үзләрен нык чикләп булса да үз хуҗалыкларын, ил хуҗалыгын күтәрергә әзер торалар. Сугышта ил алдындагы бурычны намус белән үтәгәнлек хисе аларда милли тергезелү өметен дә үстерә. 1946—1947 елларда Союзның хакимият структураларында СССРның яңа Конституциясе һәм КПССның яңа программасы проектлары тикшерелә. Ил икътисадының үзәкләштерелүен киметү, хуҗалык итү хокукларын урыннарга күбрәк бирү, партия органнарын хуҗалыкны идарә итү функцияләреннән азат итү һәм бу функцияләрне дәүләт органнарына кайтарып бирү мөмкинлекләре турындагы хәбәрләр җәмәгатьчелеккә дә барып җитә.

Ә хәзергә Татарстанда дәүләт идарәсе системасы элеккечә кала бирә. 1947 елның февралендә республиканың Югары Советына сайлаулар булып үтә. Югары Советның беренче сессиясендә Татарстанны социаль-икътисади һәм мәдәни үстерүнең сугыштан соңгы беренче бишьеллык планы раслана. Үзәккә буйсынучы эре сәнәгать предприятиеләрен үстерүгә кагылышлы күрсәткечләр планда төп урынны алып тора. Үзәккә буйсынучы җиңел сәнәгать һәм азык-төлек сәнәгате, җирле сәнәгать, авыл хуҗалыгы, торак төзелеше, социаль сфера, мәгариф һәм мәдәният зур булмаган средстволар белән канәгатьләнергә тиеш була.

Фактта республикада хакимият фәкать үзәккә генә буйсынган ВКП(б) өлкә комитеты карамагында кала. Республикада сугыш вакытындагы либеральләшү чорында хакимияткә килгән Зиннәт Моратов өлкә комитетының Беренче секретаре булып эшләвен дәвам итә. Ул үзе һәм аның либераль фикердәге командасы республиканы милли тергезү сәясәте ягында торалар. Ләкин бу теләкне, бу омтылышны гамәлгә ашыру үзләре әгъза булып торган партия белән араны өзми торып мөмкин булмый. Республиканың партия оешмасы составында татарлар ул вакытта партия әгъзаларының нибары 40 процентын гына тәшкил итәләр һәм чыгачак карарларга йогынты ясый алмыйлар. Милли мәнфәгатьләрне яклау үзәк хакимияте тарафыннан милләтчелек чагылышы, буржуаз идеологиягә йөз тоту дип бәяләнер иде. Ул чакларда «милләтчелек карачкысы» татарларны җитәкче эшкә күтәрүне дә тоткарлап тора. 1950 елда өлкә комитеты ясаган бер хисапта җитәкче эшкә күтәрелгән 288 кешенең 103 енең татар булуы зур казаныш итеп күрсәтелә.

1946—1947 елларда республика җитәкчелегенә буржуаз милләтчелеккә юл куйганы өчен тагын бер җитди кисәтү ясала. Революциягә кадәрге күпчелек татар язучылары әсәрләре «милләтчелек әдәбияты» дип игълан ителә, һәм аларны бастыру тыела, мәктәпләрдә татар әдәбияты тарихын укыту сәгатьләре кыскартыла. Татарстан тарихы Россия тарихының төбәкне өйрәнү бүлекчәсе итеп кенә укытыла. Театрлар репертуарына «чистарту» үткәрелә. Мәчетләр, руханилар эзәрлекләүләргә дучар ителә. Мәктәпләрне советлаштыру белем бирүнең милли системасын басып китә. Татарстан АССРның бердәм автономияле дәүләт структурасы буларак яшәвенә куркыныч яный. 1952 ел башында республикада КПССның ике өлкә комитеты (Казан һәм Чистай өлкәләре) составында Татарстан край комитеты оештырылу турында игълан ителә. Ләкин бу карар озак гомерле булмый һәм бер елдан соң юкка чыгарыла.

Татарстанның сугыштан соңгы икътисады. Сугыш елларында республиканың икътисады бик нык какшый. Хәлне җайга салу өчен күпчелек сәнәгать предприятиеләренең профилен үзгәртеп, аларны куллану товарлары җитештерүгә көйләргә, яңа техника белән тәэмин итәргә, яңа технологияләр кертергә кирәк була. Авыл хуҗалыгында колхоз һәм совхозларны яңа техника һәм агротехнология белән тәэмин итү, колхозчылар һәм совхоз эшчеләре хезмәтенә түләүне бик нык арттыру таләп ителә. Союз хөкүмәте Татарстан өчен мондый юлны кире кага. Республика сәнәгатенең хәрби юнәлеше саклана. Аны реконструкцияләү илнең хәрби-сәнәгать комплексы кысаларында үткәрелә, һәм ул бары тик хәрби заказларны канәгатьләндерү өчен генә эшли. Аның бу өлкәдәге күрсәткечләре Союздагы иң яхшы күрсәткечләрдән санала. Шулай ук тулысынча Союз үзәгенә буйсынган нефть чыгару Татарстан эре сәнәгатенең икенче бер тармагына әверелә. 1946 елда Баулы нефть ятмасында сәнәгать ихтыяҗларына сыек ягулык чыгару башлана. 1947 елда Шөгер ятмасы да «кара алтын» бирә башлый. Ә 1948 елда илдә тиңе булмаган Ромашкино ятмасының яңа скважиналары нефть агымын тагын да көчәйтеп җибәрә. Республикада союзкүләм «Татнефть» берләшмәсе оештырыла.

Киң кулланылыш товарлары җитештерүче предприятиеләр Россия Федерациясе буйсынуында кала. Аларда мех әйберләре, кием-салым, аяк киеме, тукымалар, трикотаж,

сабын, фанера, күн, язу машиналары, фотожелатин, кетгут, теш дәвалау инструментлары һ. б. товарлар җитештерелә. Республика кешеләренә бу продукцияне җитештерү мактанычы гына кала, ә товарлар Россия Федерациясе карамагына күчә. Алга киткән сәнәгать республикасы дигән даны чыккан Татарстан чынлыкта үз сәнәгате булмаган төбәк хәлендә кала бирә. Рәсми мәгълүматлар раславынча, җирле сәнәгать вак предприятиеләренең 1950 елга продукция җитештерүе сугыш елларындагыга караганда нибары 27 процентка үсә.

Союз хакимиятеннән дә, Россия Федерациясеннән дә берминди ярдәм алмаган авыл хуҗалыгында да җитештерү шактыйга кими. Колхоз һәм совхозлар тракторлар һ. б. техниканы дәүләткә тапшырылган авыл хуҗалыгы продукциясе хисабына гына ала алалар. Рәсми мәгълүматларга караганда, 1950 елда республикада бөртекле ашлыкның тулай җыемы сугышка кадәрге 1940 елдагы (1849 тонна) белән чагыштырганда 300 мең тоннага кимрәк (1527 тонна) була. Шул ук 1950 елда бөртекле культураларның уңышы нибары 6,3 центнер тәшкил итә. Җыеп алынган бөтен ашлык дәүләткә тапшырыла. Колхозчылар һәм совхоз эшчеләре исә үзләренә куллану өчен икмәкне дәүләткә тапшыру бәясеннән кыйммәткәрәк сатып алалар.

Республика колхозлары һәм совхозларының терлекчелек продуктлары җитештерү күләме элеккечә үк түбән кала. Авылда җитештерү буенча халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыклары өстенлек итә. 1951 елга мөгезле эре терлек баш санының 53,9 проценты, шул исәптән сыерлар санының 75,6 проценты, сарык һәм кәҗәләр санының 52,4 проценты, дуңгызларның 5,8 проценты алар өлешенә туры килә. Бөтен җитештерелгән итнең 74,4 проценты, сөтнең 85 проценты диярлек, йонның 58 проценты, йомырканың 87 проценты нәкъ менә шул секторга карый. Терлекчелектә колхоз фермаларының һәм совхоз көтүләренең өлеше әллә ни зур булмый.

Республикада, бер яктан, азык-төлек продуктларына һәм киң куллану товарларына ихтыяҗ белән, икенче яктан, ул товарларны халыкка сату арасында зур аерма (дисбаланс) күзәтелә. Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы алып бару өчен уңайлы шартлары булган республика үз халкын хәтта җитәрлек кадәр икмәк белән дә тәэмин итә алмый.

Чикләнгән автономиянең саклануы. 1953 елда Сталин үлә. Коммунистик пирамиданың — шәхси диктатура режимының

югарыгы катын сүтеп кору башлана. Ә коммунистик система үзе, аның хосусый милекчелекне һәм хосусый эшмәкәрлекне тыюы, кешенең дәүләткә абсолют буйсынган хәлгә куелуы шул килеш кала. Хакимият башына килгән коммунистик аристократия (номенклатура) — Сталинның көрәштәшләре булган кешеләр төркеме (Г. Маленков, Л. Берия, Н. Хрущев) — шәхес культыннан ваз кичүләре һәм Коммунистлар партиясенең авторитеты астында коллектив җитәкчелеккә күчүләре турында белдерергә ашыгалар. Сакланып калган коммунистик режим шартларында сәяси реформаның ахыргы чиге әнә шул була. *Реформаның асылы Сталинның шәхси диктатурасы системасын бер партиянең авторитар диктатурасы белән алыштыруга кайтып кала.*

Илдә «сәяси җылыну» дигән атама бирелгән чор башлана. 1956 елда ул вакытта гамәлдә булган рәвешендә ГУЛАГны бетерү турында карар кабул ителә. Союз үзәге белән республикалар арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә либеральләшү сизелә башлый. 1957 елда репрессиягә эләккән халыкларны (совет немецларыннан һәм Кырым татарларыннан кала) үз Ватаннарына кире кайтару башлана. Союз хакимиятенең «союздаш республикаларының хокукларын киңәйтергә», «автономияле республикаларның статусын күтәрергә» теләве турында тантаналы белдерүләр ясала. Ә чынбарлыкта исә яңа лидерлар шундый декларацияләрдән ары китми. Союз төзелешендәге унитаризм системасы саклана, республикаларны үзәктән торып идарә итү системасы ныгый. Бөтен бу системага «киңәшеп эш итү демократиясе» рәвешен бирергә карар ителә. КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы составына, чиратлаштырып, Украина, Белоруссия, Казакъстан, Үзбәкстан һәм Азәрбайҗан кебек союздаш республикалар лидерлары кертелә.

Татарстан бу процесска катнаштырылмый. Автономияле республикаларның статусын күтәрү турындагы белдерүләргә карамастан, Союз хөкүмәте биредә чикләнгән автономия системасын ныгыта. Союз үзәге 1957 елда өлкә комитетының Беренче секретаре итеп Зиннәт Моратов урынына Үзбәкстанда, Бурят-Монгол Республикасында, Башкортстанда милли республиканы үзәк мәнфәгатьләренә буйсындыру мәктәбен үткән Семен Игнатьевны җибәрә. Аның Татарстан өлкә комитетының Беренче секретаре постында дүрт ел дәвамында эшләү дәвере Татарстанның Союз үзәгенә абсолют буйсынуы нигезендә үзара аңлашу урнаштырылу белән билгеләнә. 1961 елда

Игнатьев үзен алыштырачак кеше итеп Казан университетын тәмамлаган, шунда ук кандидатлык диссертациясе яклап эшкә калдырылган, ә соңрак партия аппаратына күчкән утыз өч яшьлек Фикрәт Табеевны тәкъдим итә.

Фикрәт Табеев хакимияткә килү белән, автономияле республиканың дәүләт аппараты үзәкнең административ-территориаль органы буларак ныгытыла. Республиканың күбесенчә руслардан торган партия кадрлары белән комплектланган дәүләт структуралары, барыннан да элек, үзәк ихтыярын үтәү режимында эшлиләр. Үзәкнең ышанычын аклау өчен алар республикада Союзныкы һәм Россия Федерациясенеке булган сәнәгать предприятиеләре эшенә һәм шундый ук яңа предприятиеләр төзүгә кагылышлы барлык күрсәтмәләрнең төгәл үтәлүенә ирешергә тырышалар, дәүләткә авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру планнарын үтәү өчен, колхоз һәм совхозлар белән бик тырышып җитәкчелек итәләр. Фикрәт Табеев Союзның һәм Россия Федерациясенең хакимият структураларында бик зур ышаныч казана.

Республиканың дәүләт структурасы республика халкына хезмәт итүне үз эшчәнлегенең шулай ук мөһим булган икенче өлеше дип исәпли. Бу хезмәт үзе ике өлештән тора. Беренчедән, ул Союзның бүлеп бирү үзәге тарафыннан республикага җибәрелүче беренче дәрәҗәдә кирәкле товарларны, торакны, социаль һәм мәдәни кыйммәтләрне эшчеләр, колхозчылар һәм хезмәткәрләр арасында бүлүгә контрольлек итә. Икенчедән, республиканың дәүләт структурасы, гәрчә үзәк аның ролен территориаль администрация дәрәҗәсенә кадәр төшергән булса да, үзен татар милли дәүләтчелеге органы итеп күрсәтергә тырыша, татар милли мәдәнияте турында кайгырта, аның эшлеклеләрен яклый һәм хуплый. Милләтчелектә гаепләүләргә, шау-шулы фаш итүләргә чик куела, революциягә кадәрге мәдәни мирасны халыкка кайтарып бирү мәсьәләсендә цензура йомшартыла. Татар халкының бик борынгы заманнардан бирле килгән тарихын бәян иткән «Татарстан АССР тарихы» дип аталган гомуми баш астында 1955—1960 елларда ике томлык басма дөнья күрә. Татар халкының революциягә кадәрге тарихы турында сүз барганда «Татарстан» төшенчәсе рәсми төстә кулланыла башлый.

Халыкка кайтарылган мәдәни мирас арасында үзәк карарлары тарафыннан тыелганнарның, мәсәлән, «Идегәй» халык дастанының булмавы, Алтын Урдага бирелгән рәсми билгелә-

мәләрнең үзгәртелмәве, гражданнар сугышы елларында ак-гвардиячеләр ягында калган ислам эшлеклеләрен, татар милли хәрәкәте вәкилләрен реабилитацияләү турында сүз кузгатылмавы максатында, хакимият органнары күзәтчелеге оештырыла. Бу органнар бөтен Советлар Союзында рус халкына «өлкән туган» дип карау, Коммунистлар партиясенең «җитәкче һәм юнәлеш бирүче көч» буларак кабул ителүе турында да кайгырталар.

Милли тергезелү идеясе тарафдарлары. Татар халкы аңында теге яисә бу рәвештә даими яшәп килгән милли тергезелү идеясе сугыштан соңгы елларда массаларны тагы да үзенә җәлеп итә. Моның сәбәпләре күп була. Җәмгыятьне төрлечә бүлгәләгән, аны рухи ярлыландырган, тарихи мирасның шактый өлешеннән мәхрүм иткән сыйнфый теләктәшлек идеясенең абруе кими төшә. Хәлбуки сыйнфый идея матди муллыкка китерми. Милли-дәүләти консолидациягә ирешкән дөнья халыклары үрнәгенең дә әһәмияте зур була.

Милли тергезелү идеясе татар җәмгыятенең демократик караштагы өлеше һәм, барыннан да элек, татар милли интеллигенциясе тарафыннан тиешенчә бәяләнә. Фәнни интеллигенция, язучылар даирәләре закон кысаларында милли тергезелү теләген эзлекле рәвештә гамәлгә ашыра башлыйлар. Аерым алганда, алар әле һаман тыелганнар исемлегендә калган милли эшлеклеләр исемнәрен халыкка кайтаруга керешәләр. Әйтик, академик Мансур Хәсәнов Галимҗан Ибраһимовны реабилитацияләү мәсьәләсен күтәрә (1969), хакимият моның белән килешә. Хакимият хупламаса да, соңрак язучы һәм галим Ибраһим Нуруллин Гаяз Исхакый исемен халыкка кайтару инициативасы белән чыга. Ничек кенә булмасын, 80 нче елларда «Идегәй» дастаны һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы кебек милли хәзинәләребез бастырып чыгарыла. Әнә шулай, хакимият органнарының я хуплауларына таянып, я каршы торуларын җиңеп, милли аңның белем-мәгърифәт нигезе һаман байый бара.

Татар милли зыялылары, барыннан да элек әдип-язучылары эшчәнлеге шул вакытта ук инде белем-мәгърифәт кысаларына гына сыймый башлый. Алар Кеше хокукларының гомуми декларациясе белән яхшы таныш булалар, колониаль системаның җимерелүен һәм яңа бәйсез дәүләтләр барлыкка килүне кызыксыну белән күзәтәләр, халыкара практикада расланган «суверен хокук», «суверенлыкка хас булган хокук-

ларны ихтирам итү», «тигез хокуклылык һәм халыкларның үз язмышларын үзләре хәл итү хокукы», «халыкара хокук бурычларын намус белән үтәү», «милли азчылыклар яисә төбәк мәдәниятләре» (1975 елгы Хельсинки Декларациясе) кебек юридик нормаларның асылын аңларга тырышалар. Бер үк вакытта алар Советлар Союзы республикаларында милли факторның социаль әһәмияте үсүен кызыксынып күзәтәләр.

Шулай итеп, республиканың хакимият структураларыннан читтә һәм алардан бәйсез рәвештә, татарларның милли тергезелүе проблемалары, тагы да үстерелеп, билгеле төсмерләр ала башлый.

Милли тергезелү проблемалары. Татарларның милли тергезелүе проблемалары яңа гына барлыкка килгән проблемалар түгел. Алар татар милли хәрәкәтендә XX гасыр башларында ук формалаша һәм тәгъбир ителә. Бу проблемаларны хәл итү юллары 1906—1920 елларда «Иттифак» партиясе, Мөселман комитеты, Татар эсерлары партиясе, Мөселман социалистлар комитеты программаларында һәм программ белдерүләрдә, татар социал-демократларның «Урал» газетасы битләрендә, Бөтенроссия мөселман съездлары, Милләт Мәҗлесе, Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе, Россия Мөселман Коммунистлар партиясе карарларында татар халкының милли таләпләре төсендә чагылыш таба. Бу вакыт эчендә татар милли хәрәкәте оешмалары аларны өлешчә хәл итүгә, шул исәптән 1920 елда Татарстан АССР оештыруга һәм Россия Федерациясенең татарлар яшәгән өлкәләрендә милли-мәдәни автономияне гамәлгә ашыру буенча татар (татар-башкорт) оешмалары булдыруга ирешәләр.

Советлар Союзында коммунистик абсолютизм режимы урнаштырылганнан соң, татарларның милли тергезелүе проблемаларын хәл итү туктатыла. Татар милли хәрәкәтенең күп кенә казанышлары юк ителә, ә милли хәрәкәт үзе тыела. Хәлбуки бу хәрәкәтнең татар иҗтимагый аңында тупланган тәҗрибәсе саклана. Сугыштан соңгы елларда татар милли тергезелү проблемалары күтәрелгәндә бу тәҗрибә башлангыч нигез булып хезмәт итә.

Татар милли автономиясен кризистан чыгару бу проблемалар арасында иң мөһиме була. Союз хөкүмәте тарафыннан бетерелгән *сәяси автономияне торгызу* һәм *бу автономияне республиканың Союзга турыдан-туры керүе белән беркетеп кую; республиканың табигый байлыкларын аңа кире*

кайтару һәм аның үз милкен (дәүләт һәм хосусый милкен) булдыру юлы белән республиканың икътисади мөстәкыйльлегенә ирешү; татар мәдәниятенең һәм татар теленең ролен күтәрү, татар теленә дәүләт теле статусы бирү кебек, бер-берсе белән бик нык бәйләнгән өч төрле бурычны хәл итү мәсьәләсе дә алда тора әле.

Татар җәмгыятенең үз республикасы территориясеннән читтә калган өлешенең милли тормышын тергезү проблемасын хәл итү дә татар милләтенең язмышы өчен бик мөһим мәсьәләләрдән санала. Башлыча, алар (4 миллион чамасы кеше) үзләренең тарихи территорияләрендә яши һәм Россия өлкәләре һәм республикалары территорияләрендә кала. Аларның күпмедер өлеше киләчәктә үзләренең милли республикалары белән кушылу мөмкинлегеннән баш тартмый. Икенче бер өлеше (татар диаспорасының бер миллионга якын кешесе) Хельсинки Декларациясе нигезендә, җәмгыяви-мәдәни һәм милли-мәдәни автономиянең төрле (территориаль һәм экстерриториаль) формаларын булдыруның 20 нче елларда гамәлгә ашырылып та, соңрак Союз хөкүмәте тарафыннан юкка чыгарылган хокукын торгызырга теләр иде.

Бу ике төп проблема белән беррәттән татар милли тергезелүенең тагын бер аспекты да була. Элекке Россия империясе кысаларында милләт булып оешкан татар халкының күпчелеге Союз составыннан чыгу турындагы мәсьәләне кузгатмый. Үзенең суверенлыгын торгызу һәм Союзга ике яклы шартнамә нигезендә турыдан-туры (Россия аркылы түгел) керү аның өчен иң оптималь вариант булыр иде. Татар милли хәрәкәте Союзны унитар дәүләттән чын мәгънәсендә федератив һәм демократик дәүләткә әверелдерүдә этәргеч ролен үз өстенә ала.

Милли хәрәкәтнең яңа этабы. 60 нчы елларда татарларның милли тергезелүе проблемалары максатчан идея буларак формалаштыру сферасыннан гамәлгә ашыру сферасына күчә башлый. Союз хакимияте һәм аның урыннардагы вәкилләре халык массаларыннан ераклашкан саен, милли хәрәкәт өчен мәйдан тагы да киңәя генә. Үзе идарә иткән чорны бәяләп, Н. С. Хрущев 1960 елда: «...Партиядә һәм илдә урнашкан хәлдән без Үзәк Комитет Президиумында бик канәгать. Хәл бик әйбәт!»— дип белдерә. Мондый оптимизм Татарстан җитәкчелеген дә читләтеп үтми. Халык исә Союзда һәм республикадагы хәлдән канәгать булмый. Галәмгә Җирнең

ясалма иярченен җибәргән, атом-төш коралына, стратегик ракеталарга ия булган, хәрби-сәяси «Варшава шартнамәсе» оешмасын үз хисабына тоткан илдә әле һаман авыр кул хезмәте хакимлек итә. Сәнәгать эшчеләренең 40 проценты, авыл хуҗалыгында эшләүчеләрнең 70 проценты кул көче кулланып хезмәт итә. Иң кирәкле товарларга, хәтта икмәккә дә кытлык хөкем сөрә. Эшчеләрнең ризасызлык гамәлләре рәхимсез бастырыла.

1962 елда Союз хөкүмәте республика автономиясенә яңа «һөҗүм» ясый. Хрущев игълан иткән реформа нигезендә республиканың Югары Советы һәм Министрлар Советы саклана, ләкин аларның төп бурычы республикада дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру түгел, Татарстанда урнаштырылган Союз һәм Россия Федерациясе предприятиеләре белән җитәкчелек итүдән гыйбарәт була. Авыл җирләрендәге җирле хакимият органнары (халык депутатларының район һәм шәһәр Советлары) бетерелә, ә алар урынына 17 авыл хуҗалыгы производство идарәсе булдырыла. Параллель рәвештә, сәнәгать предприятиеләренең эше өчен җавап бирүче идарәсе булган сәнәгать зоналары оештырыла. Халык бик зур канәгатьсезлек белән каршы алган бу реформага тиздән чик куела. Союздаш республикаларда бу реформа гомумән үткәрелми. Татарларның иҗтимагый аңында, Татарстан Автономияле Республика булып калган хәлдә, аның милли тергезелү перспективасын шактый озакка югалтуы ихтимал, дигән фикер урнаша. Халыкның хакимияттән читләшүе һаман дәвам итә. 60 нчы еллар татар милли хәрәкәтендә яңа этап башлануын хәбәр итә.

Татар милли тергезелүенең уйланылган, реаль һәм тормышчан максатлары Россия җәмгыятенең демократик өлешендә һәм Союзның башка республикаларында да уңай бәяләнә. 1963 елда СССР Фәннәр академиясе оештырган һәм Кыргызстанның башкаласы Фрунзе шәһәрендә булып үткән Бөтенсоюз фәнни конференциясендә төп докладчыларның берсе М. Д. Каммари СССРда милли мөнәсәбәтләрнең үсеше «кайбер, мәсәлән, Татарстан кебек иң зур автономияле республикаларның союздаш республикага әверелү юлы белән барачак, республиканың ил чигендә булу-булмавына... зур әһәмият бирергә кирәк түгелдер, мөгаен», дигән караш белдерә.

Татар милли хәрәкәтендә яңа этап Союзның барлык республикаларында, шул исәптән рус җәмгыятендә дә сәяси

оппозициянең активлашуы чорына туры килә. 1965 елның декабрендә Мәскәүдә БМОның 1948 елгы Декларациясендә игълан ителгән кеше хокукларының һәм ирекләренең үтәлүен таләп иткән беренче демонстрация үткәрелә. Бу демонстрациядән диссидентлар (башкача фикерләүчеләр хәрәкәте) дип аталган рус милли оппозициясе хәрәкәте үсеп чыга. Бу хәрәкәтнең рухи остазларының берсе атаклы рус язучысы А. И. Солженицын була. Ул, рус халкы өчен зур афәт булган коммунистик режимны катгый рәвештә кире кагып, рус җәмгыятен бу режимнан котылу өчен көч табарга чакыра. Галим А. Д. Сахаров рус диссидентларының тагын бер олы рухи остазы була. Коммунизмның шундый ук көчле дошманы буларак, ул рус җәмгыятен гомумсоюз күләмендә яңартып кору (модернизация) юлына басарга һәм, Союзның башка халыклары белән берлектә, социалистик системаны капитализмга якынайту һәм хәтта аны капитализм белән берләштерү (конвергенция) юлыннан барырга чакыра.

Украинада, Әрмәнстан, Грузия, Литва, Эстония һ. б. республикаларда аерым кешенең генә түгел, милләтләрнең дә хокукларын һәм ирекләрен саклауны таләп итүче хокук яклаучылар хәрәкәте җәелеп китә. Алга таба бу чыгышлар милли-демократик хәрәкәтләргә үсеп әверелә.

Союзның хакимият органнары бу хәрәкәттә катнашучыларның абруйларын төшерү, аларга яла ягу, аларны җинаятьчеләр итеп эзәрлекләү юлы белән әлеге «крамола»ның тамырына балта чабарга алына. А. И. Солженицын илдән куыла, ә А. Д. Сахаров Түбән Новгородка сөрелә. Оппозициянең меңнәрчә активистлары кулга алына, сөрелә. Милли республикалардагы күп кенә диссидентлар зыян күрә. Кайбер республикаларның җитәкчеләренә җәза бирелә. Грузия компартиясе секретаре В. П. Мжаванадзе эшеннән алына. Украинаның партия лидеры П. Е. Шелест, милләтчелектә гаепләнеп, башка эшкә күчерелә. Җәзага тартылган җирле җитәкчеләр үз республикаларының халкы арасында да, башка республикалардагы коллегаларында да сизелерлек яклау тапмыйлар. Халык хакимияттән торган саен ныграк читләшә. Л. И. Брежнев хөкүмәте, аның республикалардагы наместникларының социаль таянычы югала.

Татарстан Россиядәге торгынлык системасында. 70 нче еллар башы Союз хөкүмәтенә тагын бер борчу китерә: икътисади планнар җимерелә. Хәрби яктан Көнбатыш держава-

ларны узып китүгә юнәлдерелгән халык хуҗалыгы илне азык-төлек һәм сәнәгать товарлары белән торган саен начаррак тәэмин итә. Бигрәк тә товарларның түбән сыйфатлы булуы хафаландыра. СССР җитәкчеләренең 1962 елда биргән: «Икенче унъеллык ахырына (1970—1980 еллар) коммунизмның бөтен халык өчен матди һәм мәдәни муллык тәэмин итәргә тиешле матди-техник базасы булдырылачак»,— дигән популистик вәгъдәләренең үтәлмәячәге көн кебек ачык була.

Л. И. Брежнев һәм аның торгынлыктагы булдыксыз хөкүмәте ил өстенә янаучы сәяси һәм икътисади һәлакәтне кисәтергә сәләтсез булып чыга. Иске номенклатура сафларына реформатор көчләрнең килү юлын каплаган һәлакәтле документ — «кадрларның даимилеге» турында карар кабул ителә. Дәүләтнең кайбер функцияләрен җәмәгать оешмаларына тапшыру һәм илдә коммуналь үзидарә элементларын кертү турындагы элекке карар гамәлдән чыгарыла. Икътисади проблемалар хәл ителә булып күренсен өчен, коммунизм төзелешләре дип аталган гигант предприятиеләр кору турында хәбәр ителә. Союз хакимияте органнары союздаш республикаларның хокукларын киңәйтү һәм автономияле республикаларның статусын күтәрү турында үзләре үк ясаган тәкъдимнәрдән ваз кичәләр. Юридик әдәбиятта, милли дәүләт, гомумән, дәүләтләр беткәнгә кадәр үк бетәчәк, дигән идея зур бер яңалык итеп тәкъдим ителә.

СССР Конституциясе яңадан языла. 1936 елгы Конституциянең 13 нче статьясында: «Совет Социалистик Республикалар Союзы — тигез хокуклы совет социалистик республикаларының ирекле рәвештә берләшүләре нигезендә оештырылган Союз дәүләте» диелгән була. 1977 елгы Конституциядә «Союз» дигән атама саклана, әмма Союз дәүләте үзе «күпмилләтле бердәм Союз дәүләте» (70 нче статья) дип билгеләнә. Икенче төрле итеп әйткәндә, республикаларның шартнамәле союзы (шартнамә нигезендә төзелгән союзы) төрле милләтләрнең бердәм Союз дәүләтенә әверелдерелә. Коммунист лидерлар әйтүенчә, унитар дәүләт (күпмилләтле бердәм Союз дәүләте) республикаларның чикләре бетерелүен, бу чикләрнең гап-гади бер формаль күренеш кенә булып калуын, Советлар Союзында яшәүче милләтләрнең берләшүен, бертөрле «гомумилеккә» әверелүен белдерә. 1971 елда ук инде Союз хакимияте: СССРда «кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — совет халкы барлыкка килде»,— дип игълан итә. 1976 елда, бөтен ил кысаларында

«бердәм хуҗалык организмы» оешты, дип белдерелә. 1981 елда, партиянең XXVI съезды трибунасыннан Л. И. Брежнев: «...бердәм совет халкы мәдәниятенең формалашуы бара»,— дип игълан итә. Ә бит мондый белдерүләр Леонид Брежневның шул ук съездда: «Социалистик илләр социализм өчен көрәш һәм социалистик төзелеш юлларының, формаларының милли үзенчәлеккә ия булу хокукын яклап чыктылар»,— дип икърар иткән бер вакытта ясала.

1975 елда СССР Хельсинки Декларациясенә кул куя. Ләкин хакимият органнары аның нигезләмәләрен үтәмиләр. 1979 елда күрше Әфганстанны социалистик лагерь илләренә кушу мөмкинлеген «тоеп», авантюраларга хирыс Брежнев командасы бу илне оккупацияләү турында команда бирә. Советлар Союзының Хельсинки Декларациясе буенча Көнбатыштагы партнерлары аның бу гамәлен хыянәтчел һөҗүм дип бәялиләр. Акция уңышсызлыкка очрый. Союз хөкүмәтенең тышкы сәясәте шуннан соң аякка баса алмый. Хәтта союзниклары да СССРдан йөз чөерә.

СССР халыкара изоляциядә кала. Илнең үз эчендәге социаль-икътисади һәм сәяси торгынлык тирәнәя. Татарстанда да шундый ук хәл күзәтелә. Республиканың җитәкчеләре (Фикрәт Табеев командасы, ә соңрак Рәшит Мусин һәм Гомәр Усманов командалары), татарларның милли тергезелүе идеясенә һәм аның проблемаларына теләктәшлек күрсәтсәләр дә, чынлыкта Мәскәү вәкилләре булып кала бирәләр, үзәк ихтыярына буйсынып эш итәләр. Республикада функцияләрнең бүленгән булуы тагын да ныграк төсмерләнә башлый. Татарстанның дәүләт хакимияте структурасы бар игътибарын үзәкнең икътисади планнарын үтәүгә туплый. Милли тормышны тергезү проблемалары исә аякка басып килә торган милли хәрәкәт җилкәсенә төшә.

Татарстанда дәүләт сәнәгате. СССРның 1936 елгы Конституциясендә әле автономияле республиканың дәүләт булуы турында нигезләмә сакланган була. Конституциядә болай диелә: «Автономияле республиканың иң югары дәүләт хакимияте органы булып АССРның Югары Советы тора» (89 нчы статья), «Автономияле республиканың Югары Советы АССРның бердәнбер закон чыгаручы органы булып тора» (91 нче статья). Россия Федерациясе составындагы автономияле республикаларны санаганда, Татарстан Республикасы алфавит тәртибендә түгел, ә иң беренче куела. Мөгаен, монда аның Союз күләмен-

дәге әһәмияте исәпкә алынгандыр. Автономияле республиканың икътисады турында Конституциядә бер сүз дә әйтелми. Татарстан АССРның 1937 елгы Конституциясе бу мәсьәләгә ачыклык кертә: «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы — эшче һәм крестьяннарның социалистик дәүләте» (1 нче статья), «ул дәүләт хакимиятен автономия башлангычларында гамәлгә ашыра» (13 нче статья). Бу Конституциянең 6 нчы статьясы, республиканың инде үз мөлкәтеннән мәхрүм ителгәнлеген раслап, икътисади автономияне сызып ташлый. Анда болай диелә: «Җир, җир асты байлыклары, урман-сулар, завод-фабрикалар, шахталар, рудниклар, тимер юл, су, һава транспорты, банклар, элемтә чаралары, дәүләт тарафыннан оештырылган эре авыл хуҗалыгы предприятиеләре (совхозлар, машина-трактор станцияләре һ. б.), шулай ук шәһәрләрдәге һәм сәнәгать пунктларындагы коммуналь предприятиеләр һәм төп торак фонды дәүләт милке, ягъни бөтенхалык байлыгы булып тора».

СССРның 1977 елгы Конституциясе «бөтенхалык (бөтенсоюз халкы) байлыгы» булып киткән икътисадка карата автономияле республиканың компетенциясе мәсьәләләре буенча ачыклык кертә. Татарстан хакимият органнары функциясенә, 83 нче статья нигезендә, Татарстан территориясендә урнашкан Союз һәм Россия буйсынуындагы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшчәнлеген координацияләү һәм аларга контрольлек итү керә.

70—80 нче елларда Татарстан Союзның һәм Россия Федерациясенең иң эре сәнәгать үзәкләреннән берсе буларак яши бирә. Хәрби-сәнәгать комплексына керүче Союз предприятиеләре беренче планга куела. Аларның иң зурлары арасында Ленин исемендәге Дәүләт фәнни-тикшеренү предприятиесе, С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация производство берләшмәсе, Казан вертолет заводы, Казан моторлар төзү производство берләшмәсе, «Электроприбор» заводы, Казан төгәл машиналар җитештерү берләшмәсе, «Терминал» заводы, Серго исемендәге завод, Горький исемендәге завод, «Свияга» производство берләшмәсе, «Сокол» тәҗрибә-конструкторлык бюросы һ. б. бар. Бу предприятиеләр, нигездә, хәрби заказлар үти, Татарстанның сәнәгать продукциясенең яртысын диярлек биреп бара. Алардагы бөтен технология яшерен сер булып саклана. Республика чит ил гражданнары өчен ябык була, дөнья өчен «ак тап» булып кала.

Алда санап үтелгәннәрдән соң нефть һәм нефть химиясе комплексы предприятиеләре килә. Алар шулай ук Союз буйсынуында тора. Бу предприятиеләр республикадагы сәнәгать продукциясенең 20 проценттан артыграгын эшләп чыгара. 1970 елда «Татнефть» берләшмәсе буенча нефтьне еллык чыгару 100 миллион тоннадан артып китә. 80 нче еллар азагына Союз ведомстволары Татарстандагы ятмалардан чыгарылган 2 миллиард 300 миллион тонна сыек ягулыкны үзләштерә. 70—80 нче еллар эчендә Союз министрлыклары Татарстанда яңа нефть химиясе предприятиеләрен — Түбән Кама «Нефтехим», Түбән Кама «Шин» производство берләшмәсен, Казан органик синтез заводын урнаштыралар. Бөтен илдә җитештерелгән бутилкаучукның 75 проценты, полиэтиленның 25 проценты, автомобиль шиннарының 15 проценты шушы предприятиеләр өлешенә туры килә. 70 нче еллар уртасында Кама йөк автомобильләре заводы КамАЗ сафка баса. Республикада урнаштырылган электр станцияләре елына 40 миллиардтан артыграк киловатт-сәгать электр энергиясе эшләп чыгара.

Барлык бу байлык, республикадагы нефть, газ, урман, җир кебек табигый байлыкларны файдаланып, Татарстан халкы кулы һәм гакылы белән барлыкка китерелә. 1974—1984 елларда дөнья базарында нефть бәяләре шактый югары була. Шуңа да карамастан Татарстан чәчәк атучы илгә әверелми. Татарстан нефтеннән килгән миллиард долларларны Союз хакимияте нәрсә өчен генә файдаланмый, әмма Татарстан өчен түгел. Татарстандагы дәүләткүләм предприятиеләр техника һәм технология ягыннан Көнбатыштагы шундый ук предприятиеләрдән артта кала, алардагы «ноу-хау»ны файдалана алмый. Алар шулай ук халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә дә йогынты ясамый. Татарстан халык куллануы товарлары җитештерү буенча артта кала. Алар республика сәнәгате җитештергән барлык товарларның биштән бер өлешен генә тәшкил итә. Татарстанда җитештерелгән халык куллануы товарларының җан башына күчереп исәплгәндә күләме Латвиядә җитештерелгәннең 45 процентын, Белоруссиядә җитештерелгәннең 53 процентын гына тәшкил итә. Татарстан Республикасына Союз үзәге биргән акчага «хрущевка» дип атап йөртелгән гади генә торак йортлар, «архитектура бизәкләре» кертелмәгән мәдәният сарайлары гына төзергә мөмкин була. Мәчетләр, чиркәүләр, тарихи-мәдәни истәлекләр

хәрабәләр хәлендә кала. Республиканың башкаласы Казан тузган торак йортлар һәм җимерек тарихи ядкәрләр шәһәренә әверелә. Эшләүчеләрнең хезмәт хакы барлык илләрдәге, шул исәптән охшаш продукция җитештерүче колониаль илләрдәге белән чагыштырганда иң түбән дәрәҗәдә кала бирә. Хәлбуки рус халкы бу исәптән баеган, Россиянең башка төбәкләрендә муллык хөкем сөргән, дип тә әйтеп булмый. Ил байлыгының төп өлешен шапырынучан Союз хакимияте социализм белән капитализм арасындагы мәгънәсез ярыш мичендә яндырып бетерә.

Татарстанда дәүләт авыл хуҗалыгы. Татарстан АССРның 1937 елгы Конституциясе буенча Татарстанда авыл хуҗалыгы дәүләт-колхоз хуҗалыгы һәм шәхси хуҗалык булып әверелә. Совхозлар саф дәүләт хуҗалыгы санала. Колхоз җитештерүе дәүләт милкенә һәм кооператив милеккә нигезләнә. Җир (сөрү җирләре һәм печән болыннары), колхозларга хезмәт күрсәтүче машина-трактор станцияләре Союз дәүләте карамагында була. Колхозлардагы җәмәгать предприятиеләре һәм аларда эшләүчеләр, инвентарь, терлек, колхозларда җитештерелүче продукция, җәмәгать биналары колхозларның җәмәгать милке дип игълан ителә. Колхозчының шәхси ярдәмче хуҗалыгы кечкенә генә җир кишәрлегеннән һәм йорт-җирдән, каралты-кура һәм продукция бирүче мал-туардан, вак авыл хуҗалыгы инвентареннан гыйбарәт була (6 нчы һәм 7 нче статьялар).

Колхозчыларның шәхси ярдәмче хуҗалыгы һәм совхоз эшчеләренең шундый ук шартларда формалашкан шәхси ярдәмче хуҗалыклары, шулай ук зур булмаган җирле сәнәгать предприятиеләре республика милли икътисадының әле сакланып калган утраучыкларын тәшкил итәләр. Әнә шулар нигезендә республика халкының азык-төлеккә ихтыяҗының яртысыннан артыграгын (икмәкне исәпкә алмыйча) канәгатьләндереп килгән республика колхоз базары эшли.

60 нчы еллар башларында Союз хөкүмәте бөтен илдә «шәхси баю»га каршы көрәш җәелдереп җибәрә. Колхозчыларның һәм совхоз эшчеләренең шәхси ярдәмче хуҗалыклары бу көрәшнең үзәгенә куела. «Колхозларның җәмәгать хуҗалыгы колхозчыларның шәхси ихтыяҗларын яхшырак тәэмин итәчәк» дигән лозунг астында алып барылган коммуналаштыру хәрәкәте Татарстан авылларында да җәелдерелә. Яңа салымнар бу хуҗалыкларга авыр йөк булып төшә, аларны бөлдерә.

Яшелчә үстерелә торган шәхси теплицалар юкка чыгарыла. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләр саны бик нык киметелә. Үз хуҗалыгыңны алып бару өчен уңайрак вак авылларда яшәүче колхозчыларны эшчеләр поселокларына охшатып төзелгән үзәк утарларга күчереп утырту кампаниясе башлана.

1960 елда республикада ит җитештерүдә бу секторның өлеше 42 процент була. 1958 елда әлеге сектор республика җитештерә торган сөтнең 31 процентын, йомырканың 66 процентын бирә. 1977 елда СССРның яңа Конституциясе турындагы докладында Брежнев, ярдәмче хуҗалыкларны «спекулятив керемнәр алу максатларында файдалану очраклары» бар, дип белдерә. Авыл һәм шәһәрләрдәге шәхси ярдәмче хуҗалыклар тәмам бөлгенлеккә төшә. Колхозчылар, совхоз эшчеләре һәм авылларда яшәүче башка кешеләр төп керем чыганакларыннан, ә шәһәрләрдә яшәүчеләр үзләренең шәхси ярдәмче хуҗалыклары продукциясеннән мәхрүм ителә.

Колхоз, совхоз кебек җәмәгать хуҗалыкларының җитештерүчәнлеге барыбер түбән кала. Рәсми мәгълүматларга караганда, республика авыл хуҗалыгының тулай продукциясе күләме 1969 елдан 1979 елга кадәр, ягъни 10 ел эчендә, 21 процентка гына арта. Бөртекле культураларның уңышы 20 ел эчендә (1961—1980 елларда) 50 процентка гына күтәрелә. Шушы ук 20 ел эчендә республикада ит җитештерү 54 процентка арта.

Җитештерүнең бик әкрен темплар белән үсүе колхозчыларның һәм совхоз эшчеләренең керемнәрен бик нык киметә, авылдагы вазгыятьне катлауландыра. Колхозларда ризасызлык аерата көчле була. Шәхси ярдәмче хуҗалыклардан килүче керемнең зур өлешеннән мәхрүм ителгән авыл кешеләренә җәмәгать хуҗалыгында эшләгән өчен бик түбән түләнә. Рәсми мәгълүматларга караганда, колхозда эшләнгән 1 көн өчен колхоз әгъзасы 1965 елда 2,01, ә 1978 елда 3,69 сумлык продукция ала. Союз хөкүмәте илдә азык-төлек проблемасының кискенләшүен танырга мәҗбүр була. Илдә махсус Азык-төлек программасы кабул ителә. Әмма шушындый авыр хәлгә дә карамастан, авыл хуҗалыгы җитештерүен дәүләтләштерү һаман дәвам иттерелә. Зыянга эшли торган дип аталган күп кенә колхозлар совхоз итеп үзгәртелә. Республикада колхозлар саны 1950 елгы 2443 тән 1973 елда 550 гә калдырыла. Шул ук вакыт эчендә совхозлар саны 43 тән 248 гә җиткерелә. Азык-төлек программасының үтәлеше бик зур кыенлыклар белән бара.

ТАТАРСТАНДА 90 НЧЫ ЕЛЛАР РЕФОРМАЛАРЫ

ТАТАРСТАНДА ДЕМОКРАТИК ХӘРӘКӘТ

СССРда үзгәртеп кору. 80 нче елларның урталарына Союз хакимияте кризисы соңгы ноктасына җитә. Хакимияттән читләшә барган халык Россия өлкәләре һәм республикаларында оппозициягә таба авыша бара, реформалар үткәрүне таләп итә. Моңа җавап йөзеннән Союз хакимияте бу мәсьәләдә инициативаны үз кулына алырга карар кыла һәм КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре постына партиянең Ставрополь край комитетының Беренче секретаре урынын, ә аннары 1978 елдан КПСС Үзәк Комитеты секретаре урынын биләп торган, сәясәтче буларак үзен инде таныткан кырык дүрт яшьлек Михаил Горбачевны чакыра. 1985 елның апрелендә Горбачев илне кризистан чыгару буенча *үз программасын* тәкъдим итә, һәм ул программаны «үзгәртеп кору» (перестройка) дип атый. Ул вакытта Горбачев халык ризасызлыгы сәбәбен икътисад өлкәсеннән генә эзләргә кирәк дип уйлый. Ә зыялылар арасындагы канәгатьсезлекнең нигезләрен башкача фикер йөртүнең эзәрлекләнүендә күрә. Шулардан чыгып, *радикаль икътисади реформалар, хәбәрдарлык, иҗтимагый тормышны демократияләштерү, карашлар төрлелегенә юл кую* кебек лозунгларны үзгәртеп коруның нигезе буларак тәкъдим итә.

Үзгәртеп коруны уңай кабул иткән Совет җәмгыяте коммунизмны модернизацияләү белән генә канәгатьләнми. Тиздән үзгәртеп коруның *альтернатив программасы* да эшләнеп тәкъдим ителә. 1988 елда, иҗтимагый тормышны демократияләштерү игълан ителүдән файдаланып, А. Д. Сахаров ирекккә чыгарыла һәм Мәскәүгә кайта, оппозициянең рухи остазы буларак актив сәяси эшчәнлек башлап җибәрә. Легаль оппозиция барлык республикаларда, шул исәптән Россиядә һәм

Татарстанда да, көч туплый башлый. Б. Н. Ельцинның сүзләренә караганда, нәкъ менә шул вакытларда ул Сахаровның «рухи остазлыгын» кабул итә һәм рәсми оппозиция формалаштыруны үзенең төп бурычы итеп куя.

Үзгәртеп коруның оппозиция тарафыннан тәкъдим ителгән демократик программасы эзлекле рәвештә коммунизмга каршы юнәлдерелгән була. Аның лозунглары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: *СССР Конституциясенең җәмгыятьтә КПССның монополиясе турындагы 6 нчы статьясын гамәлдән чыгару; гамәлдәге Союз үзәген бетерү юлы белән союздаш республикаларның мөстәкыйльлеген тану; республикаларның конфедерация нигезендәге яңа Союзын төзү; яңа Союзда республикаларны союздаш республикалар һәм автономияле республикалар итеп бүлүне бетерү, аларның статусын тигезләү; базар хуҗалыгын таныган хәлдә, хосусый һәм җәмәгать милке тигезлеген танып, радикаль икътисади реформа үткәрү; кеше хокукларын халыкара стандартлар дәрәҗәсендә тормышка ашыру*. Коммунистлар хакимияте тарафыннан һәм оппозиция тарафыннан тәкъдим ителгән югарыда әйтеп үтелгән *ике программаның* язмышы 1989 елның мартында парламентка халык депутатлары сайлау барышында хәл ителергә тиеш була.

Татарстанда үзгәртеп кору. Үзгәртеп коруның Горбачев тәкъдим иткән программасы Татарстанда ике төрле каршы алына. Кайбер җитәкчеләр Мәскәү тәкъдим иткән бу программаны Татарстан Республикасы шартларында гамәлгә ашыруны хуплыйлар. Республиканың Югары Советы Татарстан АССРның 1986—1990 елларга икътисади һәм социаль үсеш планын кабул итә. Бу план Союзның һәм Россия Федерациясенең XII бишьеллык дәүләт планнары билгеләгән кысаларга яраклаштырылып төзелә. Хуҗалыкны, социаль сфераны үстерүнең төп юнәлешләре һәм структурасы үзгәрешсез кала. Татарстан сәнәгате тулай продукциясенең 45 процентын җитештереп килгән оборона комплексы предприятиеләре продукция җитештерүне 1,4 тапкыр арттырырга тиеш булалар. «Татнефть» производство берләшмәсенең 193 миллион тонна «кара алтын» чыгаруы планлаштырыла, нефть химиясе предприятиеләрендә продукция җитештерүне 28,5 процентка арттыру күздә тотыла. Бишьеллыкта Татарстанда яңа трактор заводы һәм атом электр станциясе төзү планлаштырыла.

Бишьеллык планда икътисадның социаль якка юнәлдерелүен көчәйтү: хезмәт хакын күтәрү, азык-төлек продукциясе,

киң кулланылыш товарлары җитештерүне, торак төзелешен арттыру, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен киңәйтү күздә тотыла. Ләкин социаль сферага акча бүленеше бик түбән кала. Шуңа күрә социаль программа алдан ук үтәлмәүгә дучар ителә. Планда шулай ук авыл хуҗалыгы өлкәсендә гомумсоюз һәм гомумроссия фондына ит, сөт, йомырка, бәрәңге, җиләк-җимеш һәм яшелчә продукциясе тапшыру буенча катгый йөкләмәләр билгеләнә. Гомумроссия фондына тапшырудан артып калганнарның барысын да җирле республика ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен юнәлдерү һәм аларны предприятиеләрнең ярдәмче хуҗалыклары, халыкның шәхси хуҗалыклары, коллектив бакчачылык һәм яшелчәчелек продукциясе хисабына тулыландыру планлаштырыла.

Республика җәмәгатьчелегенең демократиягә йөз тоткан өлеше, бигрәк тә галимнәр, язучылар, шагыйрьләр һәм сәнгать эшлеклеләре Горбачев командасы игълан иткән үзгәртеп коруга башкачарак мөнәсәбәттә торалар. Алар үзгәртеп коруны милли тергезелүнең инде билгеле проблемаларын хәл итү юлыннан барырга мөмкинлек бирүче процесс буларак кабул итәләр. 1988 елда Горбачевның: «Сәяси системада тамырдан реформа үткәрү бурычы куела»,— дигән белдерүеннән соң, күп тә үтмичә, зыялыларның милли тергезелү идеясе белән йөргән төркеме Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) дип аталачак үз оешмасын булдыру инициативасы белән чыга.

Татар милли тергезелү идеяләрен массалар арасында аңлатуга кучү процессы шактый элегрәк, ягъни хәбәрдарлык һәм фикерләр плюрализмы игълан ителгән вакыттан ук башлана. 1988 елга инде республикада милли тергезелү идеяләрен ачыктан-ачык пропагандалаучылар — Фәүзия Бәйрәмова, Равил Бохараев һ. б. сәяси мәйданга чыга. 1988 елның октябрендә матбугатта ТИҮне оештыручыларның берсе булган Казан дәүләт университеты доценты Марат Мөлековның «Үзүзеңә һәм башкаларга ихтирам белән» дигән мәкаләсе басыла. ТИҮне күпмилләтле Татарстанның «демократик хәрәкәте» дип атап, Мөлеков җәмәгатьчелеккә бу хәрәкәтнең максатларын бәян итә: Татарстанның союздаш республика статусы алуына ирешү, чит илләр белән багланышларны киңәйтү, Татарстанда татар теленә дәүләт теле статусы бирү, республиканың икътисади мөстәкыйльлегенә ирешү.

Сәяси мәйданда советлар заманы өчен күнегелмәгән милли оешманың пәйда булуы татарстанлыларның «интернацио-

наль державачылык» рухында тәрбияләнгән бер өлешен билгеле дәрәҗәдә аптырашта калдыра. Кайбер иҗтимагый көчләр, Горбачевның, «милләтчелек ул теләсә нинди рәвештә дә сукыр», дигән билгеләмәсен яклап һәм «Вечерняя Казань» газетасы сәхифәләрен файдаланып, Татарстанны Россиядән аерырга маташуда ТИҮне гаепләп чыга. Әмма тиздән татарстанлыларның күпчелеге (татарлар, руслар һәм башка милләт вәкилләре) ТИҮгә һәм аның программасына башка күзлектән якын килә башлый. Бу бигрәк тә яшьләргә кагыла. Хәер, ТИҮ игълан иткән программа Татарстан Республикасы җитәкчелегенең дә каршылыгына очрамый. Бу җитәкчелек союздаш республика статусына ирешүнең моңа кадәрге күп еллар дәвамында җәмәгатьчелекнең зур теләге булып килгәнлеген аңлый. Чөнки «хакимлек итү һәм буйсынган хәлдә булу» мөнәсәбәтләренең партнерлык мөнәсәбәтләренә әверелүен Татарстан белән Россия мөнәсәбәтләрен бөтенләй өзү дип бәяләү дөрес булмас иде.

1989 елның февралендә Татар иҗтимагый үзәгенең Оештыру съезды була. Аның эшендә Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарыннан, Россия Федерациясенең күп кенә республикалары һәм өлкәләреннән, татарлар яши торган территорияләрдән, союздаш республикалардагы, Мәскәүдәге, Санкт-Петербургтагы татар диаспорасыннан 586 делегат катнаша. Үзенең резолюцияләрендә съезд моңа кадәр игълан ителгән программ максатларны хуплый һәм аларга татарлар яшәгән чит төбәкләрдә дә татар милли тормышын торгезү турындагы таләпләрне өсти. Бу территорияләрдә татарларның социаль-мәдәни оешмалары эшенә яңа этәргеч ясала. Татар иҗтимагый үзәгенең программасы һәм уставы кабул ителә.

Татарстанда оппозиция һәм дәүләт хакимияте структуралары арасындагы диалог башлану Татар иҗтимагый үзәге эшчәнлеге белән бәйле. ТИҮ съездының эшендә партия өлкә комитеты вәкиле сыйфатында аның идеология бүлеге җитәкчесе Олег Морозов катнаша. Ул, КПССның Татарстан өлкә комитеты ТИҮ белән хезмәттәшлек итәргә әзер, дип белдерә. СССР Югары Советына халык депутатларын сайлау көннәренә Татарстан әнә шундый шартларда якынлаша.

Союз һәм Россия парламентларында демократик оппозиция. 1989 елның мартында СССР Югары Советына булып үткән сайлаулар Горбачев командасына җиңү алып килә. Аның Союзны яңартырга вәгъдә итүе, шулай ук Көнбатыш

демократиясенең СССРдагы үзгәртеп кору программасын яклавы сайлаулар нәтиҗәсенә уңай йогынты ясамый калмый. Шул ук вакытта Югары Совет составына шактый зур төркем альтернатив депутатларның, шул исәптән Андрей Сахаровның сайлануы хакимият өчен һич көтелмәгән хәл була. СССР тарихында беренче тапкыр парламентта коммунистларның курсына шактый йогынтылы рәсми оппозиция пәйда була. 100 гә якын депутат, шул исәптән Татарстаннан да, А. Д. Сахаров җитәкчелегендә үзләренең Регионара депутатлар төркемен булдыралар. А. Д. Сахаров төркемнең ул вакыттагы хакимияткә карата конструктив оппозиция буларак бурычларын һәм эшчәнлек юнәлешен билгели. Төркемнең 14 декабрьдә Кремльдә үткәрелгән җыелышындагы чыгышында ул үзенең көрәштәшләрен тагын бер хәлиткеч адым ясарга, ягъни Конституциянең 6 нчы статьясын һәм шушы статьяга мөнәсәбәте булган башка статьяларны юкка чыгарырга өнди.

Оппозициянең парламентта интенсив эшчәнлеге башлана. А. Д. Сахаров парламентның Конституция комиссиясе составына сайлана. Ул беренчеләрдән булып комиссиягә Конституциянең үзе төзегән проектын тәкъдим итә. Бу проектта сүз гамәлдә булган Союзга, Горбачев командасы тәкъдим иткәнчә реформа үткәрү турында түгел, ә «КПССның җитәкче роле»ннән башка гына, Союзны «социалистик» дип билгеләмичә генә, аны яңадан конструкцияләү турында бара. Бу Союзның беренчел структур өлешләре булып гамәлдәге союздаш республикалар һәм суверенлык алган автономияле республикалар торырга тиеш була. Башта РСФСРны реформалаштыру һәм аның җирлегендә Россия Республикасын һәм башка милли республикаларны төзү, шулай ук Россия Республикасын дүрт икътисади районга: Европа Россиясенә, Уралга, Көнбатыш Себергә, Көнчыгыш Себергә бүлү күздә тотыла. Барлык республикалар, шул исәптән Россия Республикасы, ирекле рәвештә Европаның һәм Азиянең Суверен Совет Республикалары Союзы дип аталачак конфедерациягә берләшергә тиеш була.

Оппозиция үзгәртеп коруны яңа сәяси юнәлеш билгеләү юлы белән генә түгел, ә бәлки социаль-икътисади стройны да тамырдан яңартуга йөз тотып алып барырга тәкъдим итә. Алар фикеренчә, үзгәртеп кору барышында тигез хокуклы җәмәгать милке һәм хосусый милек базар хуҗалыгына нигез-

ләнгән икътисади структура булдыруга китерергә, җир, җир асты байлыклары һәм башка ресурслар республикалар карамагында калдырылырга тиеш иде.

1989 елның 14 декабрендә А. Д. Сахаров вафат була. Союз парламентындагы демократик оппозиция көчсезләнә, әмма ул союздаш республикаларда һәм автономияле республикаларда көчәеп китә. 1990 елның февралендә республикалар парламентларына халык депутатларын сайлауларда демократик оппозиция күпчелек тавыш җыюга ирешә. Россия Федерациясе үзе үрнәк күрсәтә. Россия халык депутатларының июль башында булып үткән беренче съездында Югары Совет Рәисе итеп оппозиция лидеры Борис Ельцин сайлап куела. 12 июньдә съезд Россия Федерациясенең дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итә. Бу хәл Россия Федерациясенең Союз составыннан чыгуы дигән сүз була. Союзның Россия Федерациясеннән башка яши алмаячагы ачыклана. Союз хакимияте структурасы, КПСС һәм аның лидеры Михаил Горбачев фактта хакимиятсез кала.

Хәлне төзәтергә омтылып, Горбачев командасы 1990 елның 2 июлендә Союз халыкларына «Гуманлы демократик социализмга» дигән мөрәҗәгать белән чыга. Бу мөрәҗәгатьтә ул «авторитар бюрократик стройдан демократик социализм җәмгыятенә» күчүне тәэмин итәргә вәгъдә бирә. Мөрәҗәгатьтә шулай ук монополизм сәясәтеннән һәм идеологиясеннән ваз кичү; халык куллануы товарларын җитештерү өлкәсендә хәзерге заман куәтле индустриясен булдыру; СССРны унитар дәүләттән халыклар дуслыгына таянган бергәлеккә әверелдерү; автономияле республикаларның конституцион статусын күтәрү, хокукларын киңәйтү; милли мәсьәләләрне хәл иткәндә көч куллануның теләсә нинди формасын гаепләү; СССР халыклары телләренең иркле рәвештә үсүен һәм тулы хокуклы файдаланылуын тәэмин итү; тышкы сәясәтне демократияләштерү; конфронтациядән хезмәттәшлеккә күчү; Әфганстаннан гаскәрләрне чыгару декларацияләнә.

Матур вәгъдәләрнең күп булуына карамастан, республикалардагы демократик парламентларны яңадан социализм кочагына кайтару Горбачевның кулыннан килми. Балтыйк буе республикалары гына түгел, Россия, Украина, Белоруссия дә бу юлдан баш тарталар.

Татарстанда демократик хәрәкәт. 1989 елның азагында 1990 елның башында Татарстанда республика парламентына

халык депутатларын сайлауларга хәзерлек барышында һәм аларны үткәрү чорында демократик хәрәкәт аеруча активлаша. Демократик үзгәртеп кору яклы кешеләр өчен республика матбугаты һәм җирле газеталарга, радиога юл ачыла. Аларның үз матбугат органнары эшли. «Халык хокукларын гарантияләмичә кеше хокукларын гарантияләп булмый» дигән лозунг астында «Республика» газетасы чыга башлый. Бер үк вакытта хакимият структурасында М. Ш. Шәймиев (партия өлкә комитетының Беренче секретаре), М. Г. Сабиров (Министрлар Советы Рәисе), В. Н. Лихачев (партия өлкә комитетының дәүләт оешмалары һәм хокук бүлеге мөдире) составында Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итүгә йөз тоткан җитәкчеләр командасы барлыкка килә. 1989 елның 4 ноябрендә Татарстан Республикасының Югары Советы Татарстан АССР Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында Закон кабул итә. Сайлау системасы демократияләштерелә, сайлауларның альтернативлыгы һәм сайлау округларының күп мандатлылыгы күздә тотыла.

Татарстанның Россия һәм Союз составындагы мөстәкыйльлеге турындагы таләп, төп лозунгка әверелеп, демократик хәрәкәтнең һәм дәүләт хакимиятендәге демократик канатның позицияләрен якынайта. Асылда милләтчелек белән сугарылмаган мөстәкыйльлек республиканың күпмилләтле халкын канәгатьләндерә, һәм ул мондый мөстәкыйльлекне яклый. Сепаратизмнан азат булган мөстәкыйльлек таләбе Россиянең һәм Союзның чын демократик көчләре тарафыннан да уңай кабул ителә. Ул вакытта ортодоксаль коммунистлар яклаган унитаризм мөстәкыйльлек белән сыеша алмый. Республикадагы демократик көчләрнең «Татарстанның СССР һәм Россия Федерациясе составында суверенлыгы өчен!» дигән лозунгы сайлауларда «Бердәм социалистик Союз өчен!», «Бердәм социалистик Россия өчен!» дигән лозунглардан өстен чыга.

А. Д. Сахаровның автономияле республикаларга суверен республика статусы бирүне күздә тоткан демократик программасы татар демократик хәрәкәте өчен зур таяныч була.

Демократия дулкынында Татарстан тагын бер кат үзенең СССР составындагы дәүләт статусын союздаш республикалар статусы белән тигезләү турындагы мәсьәләне күтәрә. 1989 елда СССР халык депутатлары съездында М. Ш. Шәймиев Союз Конституциясенең 71 нче статьясына төзәтмә кертү турында тәкъдим белән чыга, һәм бу төзәтмә нигезендә автономияле

республикалар яңа Союзның тулы хокуклы субъектлары итеп саналырга тиеш була. Бу төзәтмә тавышка куела һәм кабул ителә. Татарстан яңа Союз шартнамәсен хәзерләү барышында да бу позициядән читләшми. Автономияле республикаларның Союз шартнамәсенә союздаш республикалардан соң түгел, алар белән беррәттән кул куярга тиешлеге күздә тотыла.

1991 елның августында булып узган, тарихка «фетнә» дип кереп калган вакыйгалар ил вазгыятен бик нык үзгәртәләр. Союз фактта яшәүдән туктый. Тиздән, 1991 елда, аның таркалуы турында рәсми рәвештә игълан ителә. Татарстанның суверенлыгы өчен көрәш Россия Федерациясе кысаларында алып барыла башлый. Россия Федерациясе парламентында Россия Федерациясенең дәүләт суверенитеты турындагы Декларация проектын тикшерү барышында Татарстан Республикасыннан сайланган депутатлар Россия Федерациясенең мөстәкыйльлеге идеясен актив төстә яклап чыгалар. Бу бигрәк тә Декларация проектының 5 нче пунктына кагыла. Бу пунктта Россия Федерациясенең бөтен территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең һәм Россия Федерациясе законнарының өстенлеге турында, халыкның милли байлыкка, аннан файдалануга, аның белән эш итүгә хокукы турында, Россия Федерациясенең шартнамә нигезендә башка республикалар белән бер союзга берләшүе турында бәян ителә. Башка республикаларда кабул ителгән декларацияләр дә шундый ук рухта була. 16 июльдә Украинада кабул ителгән Декларациядә аерым алганда болай диелә: «Суверен милли дәүләт буларак Украина ССР үзенең хәзер гамәлдә булган чикләрендә украин милләтенең үзбилгеләнү кебек аерылгысыз хокукын гамәлгә ашыруы нигезендә үсә».

Кызганычка каршы, Россия Декларациясе Россия демократик хәрәкәтенең автономияле республикаларга суверен республика статусы бирү турындагы сайлау алды вәгъдәсе дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Россия парламентындагы Автономияара депутатлар төркеменең автономияле республикалар суверенлыгын тану турындагы катгый тәкъдименә карамастан, Декларациянең 6 нчы пункты «автономияле республикаларның хокукларын җитди киңәйтү» дигән бернәрсә дә вәгъдә итмәүче күптәнге формула белән чикләнә. Татарстанның демократик хәрәкәте мондый пункты булган Декларация проектына каршы чыга. 14 июльдә Казанда ТИҮ тарафыннан оештырылган массакүләм митингта катнашучылар

М. С. Горбачевка һәм Б. Н. Ельцинга мөрәҗәгать кабул итәләр. Анда Татарстанның суверенлыгын чикләү өчен Россия Федерациясенең дә, СССРның да бернинди нигезе юк дип белдерелә. Бу мөрәҗәгать шул ук вакытта Россия Федерациясе Советлары съездында укыла. Автономияара депутатлар төркеме Декларациягә автономияле республикаларның суверенлыгы формуласын кертү турындагы таләпне кабат яклап чыга. Бу төркемгә Татарстан депутаты Мөхәммәт Сабиров җитәкчелек итә. Ләкин Татарстан авазын тагын ишетергә теләмиләр. Һәм бу таләпнең кабул ителмәве Декларациянең зур кимчелеге булып кала.

СУВЕРЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Татарстан Республикасы дәүләт суверенитетын игълан итү. Татарстан үзенең эчке халәте белән суверенлыгын игълан итүгә әзер була. Союз үзәге һәм Россия Федерациясе үз чиратларында бу факт белән исәпләшмичә кала алмыйлар. Яңа Союз шартнамәсен әзерләгәндә, Горбачев Татарстанның Союз шартнамәсенә мөстәкыйль рәвештә Россия Федерациясе белән рәттән кул куюына ризалык бирә. Ләкин шартнамәгә кул куячак республикаларның фактта мөстәкыйльлек алачакларына тулы ышаныч булмый. Кул кую өчен хәзерләнгән шартнамә «дәүләтләр союзын» түгел, бәлки «Союз дәүләтен» күздә тота. Россия Татарстанны үз зонасында калдырырга тели, дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә автономияле республикаларга суверенитет бирү турында пункт кертүдән баш тарта. Август башында Ельцин Россия Федерациясенең Югары Советы Рәисе сыйфатында Татарстанга килә. Журналистларның турыдан-туры биргән: «Сез татарларга аерым фатир (суверенлык.— *Авт.иск.*) бирергә әзерме?»— дигән сорауларына Ельцин: «Әзер. Ләкин Татарстан суверенитеты нинди булыр, аның атамасы нинди булыр, анысын,— мин тагын кабатлап әйтәм,— сез инде Татарстанның Югары Советы сессиясендә үзегез хәл итәрсез... Әйе, әлбәттә, мин шулай ук Россиянең демократик үзгәртеп коруларда бердәм катнашуын теләр идем, чөнки Россия аларга радикальрәк рәвештә барачак»,— дип җавап бирде.

Татарстан демократик хәрәкәтен республиканың Россия Федерациясендә яки Союз составында тору-тормавы түгел, ә Татарстанның нәкъ менә дәүләт суверенитеты мәсьәләсе

кызыксындыра. Татарстанның яңа парламентының беренче адымы Югары Совет Рәисен сайлаудан гыйбарәт була. Рәис итеп бердәм кандидат М. Ш. Шәймиев сайлана. 30 августта **Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация** кабул ителә. Комиссия кушуы буенча Декларация проектын депутат Ф. Ш. Сафиуллин укый. Регламент буенча, проектны тикшерү барышында чыгыш ясарга теләүчеләр саны чикләнми. Депутатларның фикерләрен килештерү нәтиҗәсендә Декларациянең азаккы варианты эшләнә. Декларациядә болай диелә:

Югары Совет:

«1. Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итә һәм аны Татарстан Совет Социалистик Республикасы — Татарстан итеп үзгәртә.

2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора.

3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, сәяси инанулары нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, кешегә тигез хокуклар һәм ирек гарантияли. Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт телләре сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә. (...)

5. Бу Декларация Татарстан ССР Конституциясен эшләү, Татарстан ССР законнарын үстерү өчен, Татарстан ССРның Союз шартнамәсен, РСФСР һәм башка республикалар белән шартнамәләр әзерләүдә һәм төзүдә катнашуы өчен... нигез булып тора...»

Бер үк вакытта Татарстанда Халык хакимияте нигезләре турындагы Закон, ягъни дәүләт хакимияте структураларын партияләрнең теләсә нинди басымыннан азат итүне гарантияли торган мөһим документ кабул ителә.

Дәүләт суверенитеты турындагы Декларация, 1917 елда Идел-Урал Республикасын игълан итү белән башланып киткән милли азатлыкка ирешү циклының дәвамы буларак, Татарстанда суверен Татарстан Республикасы оешу өчен юл ача. Декларациянең «Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлекле», дигән белдерүе күпмилләтле Татарстан җәмгыятен тагы да берләштерә.

Татарстан суверен республикасы җиде миллионлы татар милләтен социаль һәм мәдәни туплаячак фактор итеп карала. Республика үзенең милли дәүләтчелеге территориясеннән читтә дә татарларның мәдәни һәм рухи үзәге сыйфатында эш итү мөмкинлекләре ала. Үзенең социаль-икътисади потенциалы һәм тигез хокуклы хезмәттәшлеккә омтылуы белән суверен Татарстан Россия һәм Союз кысаларында суверен республикаларның яңа федерациясен формалаштыруда уңай йогынты ясаучы әһәмиятле факторга әверелә. Россиядәге һәм Союздагы милли республикалар халыклары һәм дәүләт хакимияте органнары Татарстанның дәүләт суверенитеты игълан ителүне югары бәяләделәр. Татарстанның кыю адымы Россия Федерациясендәге башка автономияле республикалар өчен үрнәк булып әверелә. Тиздән алар чыннан да үзләренең дәүләт суверенитетларын игълан итәләр.

Суверенитетны яклау. Суверенитет игълан иткән республиканы алда әле зур сынаулар көтә. 1991 елның декабрендә элеккеге союздаш республикалар РСФСР, Украина, Белоруссия, Казакъстан һәм башкалар СССР составыннан рәсми рәвештә чыгулары турында белдерәләр. Советлар Союзы юридик төстә таркала. Татарстанга үзенең суверенитетын Советлар Союзы варисы булган Россия Федерациясе алдында якларга кала. Ул вакытта Россия үзенең дәүләт булып оешуында зур кыенлыклар кичерә. Демократик парламентның эшен җайга салып булмый. 1991 елның апрелендә җыелган халык депутатлары съезды Россия демократларының һәм коммунистларының бер-берләре өстенә кызып-кызып гаеп ташлаулары шартларында эшли. Депутатлардан берсе съездны инде яшен яшәгән, законнар кабул итәргә сәләтсез, парламент өстендә тора торган һич кирәксез бер орган дип атый. Кирәкле икътисади программа тәкъдим итәргә сәләтле, эшлекле, абруйлы хөкүмәт булмый. Нәкъ шул көннәрдә акча курсы түбән тәгәри. Шушы вакыйгаларның нәтиҗәсе буларак халыкның бөлгенлеккә төшүе Татарстанга да кагылмый калмый.

Россия Федерациясенең деструктив сәяси көчләре, халык ризасызлыгыннан файдаланып, демократик үзгәртеп корулар, янәсе, Россиянең җимерелүенә китерә дип, яла яга башлыйлар. Автономияле республикаларны демократик суверенлаштыру процессына һәм, бигрәк тә, бу эштә инициатор булган Татарстанга аеруча нык «эләгә». Россия Федерациясе халык депутатларының инде телгә алынган съезды барышында

Югары Советның Милләтләр Советы Рәисе булган Рамазан Абдуллатыйповка газета хәбәрчеләре: «Татарстанның Россия Федерациясеннән чыгуы мөмкинлегенә сез ничек карыйсыз?»— дигән сорау бирәләр. Татарстан әзерләнгән Федератив шартнамәгә кул куячак, дигән ышаныч белдереп, ул, Татарстанның андый ниятләре юк, ди һәм: «Безгә, тормыш итәр өчен, үзебезгә үзебез эшләп табарга өйрәнергә кирәк, бер-беребез хисабына яшәргә түгел, бергәләп эшләргә кирәк»,— дип тә өстәп куя. Барлык республикалар өчен дә уртак булган Федератив шартнамәне хәзерләү турындагы тәкъдим шул ук съездда 5 апрельдә кабул ителә. Ул Татарстан тәкъдим иткән ике яклы шартнамәне алыштырыр, дип күздә тотыла.

Съезддан соң Федератив шартнамәгә риза булуын таләп итеп, Татарстанга басым ясау башлана. 1992 елның 13 февралендә Россия Федерациясенең Конституция суды, Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең кайбер нигезләмәләре Россия Федерациясе Конституциясенә туры килми, шуңа күрә аның көче юк, дигән вердикт чыгара. 19 мартта, Федератив шартнамә белән ризалашырга кирәк, дигән тәкъдим белән Татарстанга Б. Н. Ельцин мөрәҗәгать итә. Татарстанга тискәре мөнәсәбәттәге кайбер Мәскәү сәясәтчеләренең, янәсе, республикада хакимият башына килгән милли элита Татарстанны Россиядән аерырга тели, дигән белдерүләре ешая. Бу көчләр ТИҮне, «Азатлык» яшьләр оешмасын, Фәүзия Бәйрәмова җитәкләгән «Иттифак» («Бердәмлек») партиясен милләтчелектә, сепаратизмда гаепли.

Татарстан түзә, бирешми. 1992 елның 31 мартында милли республикалар һәм Россия Федерациясе үзәк белән Федерация субъектлары арасында вәкаләтләр бүлешү турындагы шартнамәгә кул куялар. Татарстан бу шартнамәгә кул куюдан баш тарта. Ул үзенең дәүләт суверенитеты турындагы Декларациясенә тугрылыклы кала, вәкаләтләрне үзәккә Федерация субъектының үзе тапшыруы принцибына корылган ике яклы шартнамә төзелүен, ягъни федерацияне югарыдан түгел, ә түбәннән төзүне тәкъдим итә.

Параллель рәвештә республикада Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә халык мөнәсәбәтен ачыклау өчен чакырылган референдум үткәрүгә әзерләнәләр. 1992 елның 21 февралендә республика парламентының референдум үткәрү турындагы карары кабул ителә. Референдум БМОда әгъза булып торучы дәүләтләрдән килгән күзәтүчеләр

катнашында 21 мартта үтә. Күтелгәнчә үк, күпмилләтле Татарстан җәмгыятенең күпчелеге (референдумда катнашканнарның 61,4 проценты) Татарстан Республикасының «Татарстан — ике яклы дәүләтара шартнамә нигезендә Россия Федерациясе белән ассоциацияләшкән суверен республика, халыкара хокук субъекты», дигән формула аша билгеләнгән статусын яклап тавыш бирә.

Референдум, Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларацияне раслап, төзеләчәк Россия — Татарстан сәяси шартнамәсенең төп параметрларын билгели. Бу шартнамә Татарстан дәүләт суверенитетының гомумхалык тарафыннан раслануы фактына нигезләнергә, Татарстанның Россия Федерациясенә, үз индивидуаль статусын, икътисад, фән-техника, мәдәният өлкәсендә чит илләр белән мөстәкыйль рәвештә бәйләнешкә керү хокукын саклаган хәлдә, ирекле рәвештә керүен теркәргә тиеш була. Референдум нәтиҗәләре Татарстан Республикасын тану һәм аның белән дәүләтара килешүләр төзү полосасын ача. Башкортстан Республикасы белән Татарстан Республикасы арасындагы Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы 1991 елның 16 августында Уфада кул куелган шартнамә суверен Татарстан тарихында беренче шундый килешүләрнең берсе була.

1991 елның 12 июнендә Татарстан Республикасы Президентын сайлау Татарстанның дәүләт суверенитетын раслаучы акт була. Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын игълан итүгә, бу суверенитетны яклауга һәм саклауга Минтимер Шәймиевнең зур өлеш кертүен исәпкә алып, татарстанлылар аны беренче Президент итеп сайлап куялар. Минтимер Шәймиевкә, күпмилләтле Татарстан җәмгыяте ихтыярын җиткерү шартларында, Россия — Татарстан шартнамәсен төзү турында сөйләшүләр алып бару һәм бу шартнамәгә кул кую вәкаләте тапшырыла. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе делегацияләренең 1992 елның 30 мартыннан 2 апреленә кадәр дәвам иткән киңәшмәдә ике арада төзеләчәк килешүнең беренче йомгаклау беркетмәсе эшләнә. Бу беркетмәдә «Татарстан Республикасының Россия Федерациясе белән үзенчәлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруы зарурлыгы турында» әйтелә.

Татарлар һәм татарстанлылар. Сәяси картада суверен Татарстан Республикасы урын алу белән татар халкының милли тормышын торгезү проблемасы дәүләти һәм социаль-

мәдәни юнәлешләрдә хәл ителә башлый. Татарстан Республикасының үзендә, күпмилләтле суверен дәүләттә, «татарстанлылар» дигән гражданлык төшенчәсе астында күпмилләтле Татарстан җәмгыяте формалаша башлый. Шул ук вакытта Татарстан Республикасыннан читтә булган татар халкының шактый киң тарихи территориясендә социаль-мәдәни тергезелү процессы тизләнә. Бу процессларның һәр икесе, берберсен тулыландыручы процесслар буларак, татар халкының язмышында аеруча әһәмиятле урын тоталар.

1992 елның маенда Казанда гомумреспублика проблемаларын һәм аерым милли-мәдәни проблемаларны тикшерү, аларны хәл итү юлларын билгеләү өчен татар, рус, чуваш, мари, удмурт, мордва, еврей, немец һәм башка милләтләрнең иҗтимагый-сәяси һәм милли-мәдәни оешмалары вәкилләре җыела. Бу съезд Татарстан Республикасында милләтләр арасындагы ышанычны һәм гражданлык татулыгын ныгыту юнәлешләрен билгели, республикада дәүләт суверенитетын ныгыту сәясәтен хуплый, Россия һәм аның составына керүче республикалар һәм өлкәләр, якындагы һәм ерактагы чит илләр белән тигез хокуклы бәйләнешләр үстерү кирәклеген яклап чыга. Татарстан Республикасының милли-мәдәни җәмгыятьләре ассоциациясен (ММҖА) оештыру турында карар кабул ителә. Республиканың күп конфессияле ил булуы да исәпкә алына. Конфессияләрнең вәкилләре, барыннан да элек мөселман һәм православие диннәре руханилары, диннәрне үзара ихтирам итү һәм гражданлык татулыгын үстерүне яклап чыгалар.

Милли-мәдәни җәмгыятьләр һәм конфессиональ учреждениеләргә матди җирлек әзерләнә. Конфессияләргә гыйбадәт кылу урыннары кайтарып бирелә. Милли җәмгыятьләр телевидение һәм радиода эфир вакыты алалар. 1993 елның августында чуваш телендә атналык «Сувар» газетасы нәшер ителә башлый.

1992 елның февраль башында Казанда җиде миллионлы татар халкының Бөтентатар милли корылтае булып үтә. Аның эшендә Татарстаннан, Россиядәге һәм БДБ илләрендәге татарлар тупланып яши торган территорияләрдән 800 делегат катнаша. Фикер алышу нигездә Татарстан Республикасының статусы, татар милли телен тергезү, татар милли мәгарифе һәм мәдәнияте мәсьәләләре тирәсендә бара. Татарстанның дәүләт суверенитеты бертавыштан хуплана. Татарстан Респуб-

ликасыннан читтә яшәүче татарларның социаль-мәдәни тормышын тергезү процессын координацияләү өчен махсус милли орган булдыру зарурлыгы турында фикер кузгатыла.

Татар милли хәрәкәтенең ике аспектлылыгы (татар милли дәүләтчелегенең формалашуына булышлык күрсәтү һәм тулаем татар милләтенең социаль-мәдәни тергезелүен тәэмин итү) 1992 елның июнендә Казанда булып үткән Бөтендөнья татар конгрессында шактый ачык чагыла. Конгресс утырышын 19 июньдә Татарстанның Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров ача. Конгресска Башкортстаннан, Үзбәкстан, Казакъстан, Төмән өлкәсе, Урал, Идел буе, Мәскәү, Санкт-Петербург, Себер һәм шулай ук АКШтан, Төркия, Финляндия, Германия, Польша, Япония, Австралия, Кытай, Швеция, Норвегия, Румыниядән вәкилләр килә. Конгресс Казан шәһәрендә урнашкан Башкарма Комитетын оештыра. Башкарма Комитетның Рәисе итеп профессор Индус Таһиров сайлана. Халыкара оешма итеп танылган Башкарма Комитет Татарстан Республикасының хакимият органнары белән, аларны алмаштырмыйча гына, хезмәттәшлек итәргә тиеш була. Комитетка «Татарстан Республикасының социаль-икътисади, милли-мәдәни һәм сәяси үсешенә, һәрьяклап ярдәм итү», «барлык татарларның этникрегиональ мәнфәгатьләрен хәл итүдә, Татарстан җиреннән читтә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә гомумдемократик кагыйдәләргә таянып, гадел арадашчы булу...» вазифалары йөкләнә.

Конгресс дөнья халыклары һәм дәүләтләренә Татарстан Республикасын суверен дәүләт итеп тану турындагы үтенеч белән мөрәҗәгать итә.

Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү. Татарстан Республикасы Конституциясен эшләүгә Казан хокук мәктәбе вәкилләре, халык ышанычын казанган Татарстан сәясәтчеләре, фән һәм мәдәният эшлеклеләре, шулай ук ерак чит илләрдән халыкара экспертлар җәлеп ителә. Конституция Идел буе татарларының (болгар һәм татарларның) IX—XVI гасырлардагы милли дәүләтенең һәм Татарстан Автономияле Республикасының тарихи тәҗрибәсен игътибарга алырга, Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларация кабул ителгәннән соң 90 нчы елларда республикада урнашкан социаль-икътисади чынбарлыкны чагылдырырга, Россия унитар дәүләтенең шартнамәле конституцион федерациягә әверелә баруы тенденциясен исәпкә алырга тиеш була.

Конституция проектын хәзерләү барышында татарстанлылар Татарстанның дәүләт буларак аякка басуының төп принципларын — суверенитет һәм Россия Федерациясе составында республиканың үз статусы булуы принципларын — яклауларын дәвам иттерәләр. Федераль үзәкнең 21 мартта булып үткән референдум нәтиҗәләре белән исәпләшмәскә маташуы Татарстанда кайтаваз булып, җавап реакциясе тудыра. Борис Ельцин Президент сайлаулары барышында татарстанлылар яклавына ирешә алмый.

Татарстанның үз хокукый дәүләтенә һәм заманча гражданлык җәмгыятенә ия булып, цивилизацияле илләр гаиләсенә керү омтылышы республикадан читтә яшәүче татарлар арасында да киң яклау таба. Татарстанның үз мөстәкыйльлеген хокукый юл белән саклап калуга һәм шул ук вакытта Россия белән, рус халкы белән дустанә хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен саклауга юнәлдерелгән принципиаль сәясәте Россиянең демократик җәмәгатьчелеге тарафыннан да хуплана. Татарстанның демократик тәҗрибәсе Россия Федерациясендәге башка республикаларның да игътибарын җәлеп итә. Чит илләрдә дә Татарстанны тану һәм аңа булышлык күрсәтү процессы башлана.

Матбугатта игълан ителгән Конституция проекты республикада һәм аннан читтә дә игътибар белән өйрәнелә. Конституцияне тикшерү барышында республиканың суверенитеты, республиканың федераль үзәк белән үзара мөнәсәбәтләре, милекчелек һәм базар мөнәсәбәтләре турындагы, шәхеснең хокуклары һәм ирекләре, милләтара һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр, гражданлык һәм телләр турындагы мәсьәләләр игътибар үзәгендә тора. Моңа кадәр демократик иҗтимагый хәрәкәт даирәләрендә куелган *милли азатлыкка ирешү* һәм *милли тергезелү* максатлары гамәлгә ашырылырга тиешле конкрет төсмерләр алалар. Суверенитет, мәсәлән, һәр кешенең яхшы тормыш шартларын үзенә үзе тудыра алу һәм үз хезмәте нәтиҗәләреннән файдалану хокукларын яклау мөмкинлеге бирәчәк халәт буларак кабул ителә.

Татарстан Республикасының Конституциясе проекты халыкара хокук экспертизасын да уңышлы үтә. Экспертиза бу проектның халыкара демократик стандартларга туры килүен раслый. Татарстан Республикасы дәүләт суверенитетының төп параметрлары турында бөтенхалык тавыш бирүе нәтиҗәләренә ихтирам саклап (21 мартта булып үткән референдум),

республиканың Югары Советы **1992 елның 6 ноябрендә Татарстан Республикасы Конституциясен бертавыштан кабул итә.** Татарстанның моңа кадәр дә республика Конституциясен кабул итү тәҗрибәсе була. Хәзер исә сүз Россия Федерациясе составына тигез хокуклы, үзенең яңа статусы булган мөстәкыйль субъект сыйфатында иркле рәвештә керергә теләк белдергән суверен Татарстан Республикасы Конституциясе турында бара.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 1 нче статьясында болай дип белдерелә:

«Татарстан Республикасы — республиканың күпмилләтле барлык халкы ихтыярын һәм мәнфәгатен чагылдыручы суверен демократик дәүләт.

Дәүләт суверенитетын һәм вәкаләтләрен халык билгели.

Дәүләт суверенитеты — Татарстан Республикасының төп билгесе».

Татарстан Республикасын хокукый дәүләт дип күрсәтеп, Конституция законнарның өстен булуын һәм аларны тайпылышсыз үтәү зарурлыгын билгели, *закон чыгару* (Дәүләт Советы йөзендә), *башкару* (Министрлар Кабинеты йөзендә) һәм *суд* (республиканың Югары суды йөзендә) хакимиятләренең аерым-аерым булуын раслый. Конституциядә «Татарстан Республикасы законнары, әгәр алар Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләренә каршы килмәсә, аның бөтен территориясендә өстенлеккә ия» (59 нчы статья) дип, «Гомумтанылган халыкара хокук принциплары һәм нормалары Татарстан Республикасы законнарыннан өстенрәк санала» (62 нче статья), дип күрсәтелә.

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе мөнәсәбәтләренең асылы 61 нче статьяда билгеләнә: «Татарстан Республикасы — Россия Федерациясе — Россия белән вәкаләтләрен һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты». Конституция, Татарстан Республикасының үз гражданлыгы бар, дип игълан итә. Граждан белән дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр иң югары социаль кыйммәт булган кеше хокуклары өстенлегенә нигезләнә. Граждан һәм дәүләт бер-берсе алдында үзара җаваплы. Республика гражданнары, милли хокуклар һәм ирекләрне дә кертеп, шәхси, сәяси, социаль-икътисади, мәдәни хокуклар һәм ирекләргә ия. Конституциядә шулай ук Татарстан Рес-

публикасы гражданнарының Конституцияне һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә тиешлеге күрсәтелә.

Конституция нигезендә республиканың икътисади системасы аның хуҗалык мөстәкыйльлеген тәэмин итәргә тиеш. Җир, җир асты, су, урман һәм башка табигый ресурслар, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы, дәүләт бюджеты акчалары, дәүләт банклары активлары, шулай ук Татарстан халыкларының тарихи, мәдәни хәзинәләре һәм республика территориясендәге башка төрле мөлкәт бөтенхалык байлыгы дип игълан ителә. Республикада граждан белән дәүләт арасындагы, кулланучы белән җитештерүче, эш башкаручы белән эш бирүче арасындагы социаль хезмәттәшлеккә нигезләнгән икътисади мөнәсәбәтләрне үстерү күздә тотыла. Икътисади реформалар милекнең күптөрлелеге (хосусый милек, дәүләти һәм коммуналь милек, җирле үзидарә милке һәм җәмәгать оешмалары милке) һәм аларны хокукый яклау өчен тигез шартлар тәэмин ителгән социаль базар хуҗалыгының аякка басуына китерергә тиеш. Хуҗалык эшчәнлеген җәмгыять мәнфәгатьләрендә җайга салу — дәүләт кулында.

Конституциянең 11 нче бүлеге дәүләт хакимияте системасында аерым бер урын алып торган президентлык институтын шәрехли. Татарстан Республикасы Президенты — дәүләт башлыгы, иң югары вазифалы кеше, «Татарстан Республикасында шәхес хокуклары һәм ирегенең, республика суверенитетының, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен үтәүнең гаранты».

Казан шәһәре Татарстан Республикасының башкаласы дип игълан ителә. Татарстан Республикасының Дәүләт флагы раслана. Шагыйрь Ренат Харис бу символыбыз белән бәйләнгән горурлык хисләрен:

Яшелле-аклы-кызыллы
Туган илем әләме.
Кул изәгәндәй җилфердәп,
Ул дөньяны сәламли,—

дигән шигырь юллары аша белдерә.

Татарстан Республикасының Дәүләт гербы ян-ягында калкан ясалган канатлы ак барс сурәтеннән гыйбарәт. Калкан — саклану, яклау символы. Гербта һөҗүм итү символы юк.

Республика Конституциясе — Татарстанда иң зур юридик көчкә ия булган дәүләт акты. Конституциянең кабул ителүе белән Татарстан Республикасы суверенитеты игълан ителү һәм аның закон көченә керүенең республика күләмендә барган процессы тәмамлана. Татарстан Республикасы суверенитетының танылуы, барыннан да бигрәк Россия Федерациясе тарафыннан танылуы проблемасын хәл итәсе кала.

Татарстан Россия Федерациясенең Конституцион Җыелышында. Демократик Конституциянең кабул ителүе Татарстанда социаль-сәяси тотрыклылыкны шактый ныгыта. Республика Президентының, Татарстан Югары Советының һәм Хөкүмәтенең (Министрлар Кабинетының) һәр як та кабул итәрдәй шартларда Россия Федерациясе белән дәүләтара шартнамә төзү вәкаләтләре раслана. Ул шартлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: Россия Татарстанның суверенитетын таный, Татарстан хакимият вәкаләтләренең бер өлешен иректе рәвештә Россия Федерациясенә тапшыра. Бу шартлар Республиканың Россия Федерациясе белән сөйләшүләргә дустанә ниятләр белән баруы — Россия мәнфәгатьләрен тануы һәм ихтирам итүе, үз халкының суверен хокукларын яклавы, Федерациягә керүче республикаларның ирекле һәм тулы хокуклы хезмәттәшлегенә нигезләнгән яңа федерациянең аякка басуы турында кайгыртуы хакында белдерә. Россиянең халык депутатлары съездында ясаган чыгышында Татарстан Республикасының Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Безнең максат сепаратизм түгел, ә үзара хезмәттәшлекнең һәм мөнәсәбәтләрнең заман таләбенә җавап бирерлек яңа формаларын эзләү, аерылып чыгарга ниятләнү түгел, ә Татарстан халыкларының законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен якларга омтылу»,— дип белдерде.

1993 ел Россия белән Татарстан сөйләшүләре өчен уңайлы булмый. 1992 елда илнең икътисади хәле тагы да авырлаша, Россия Федерациясенең закон чыгару һәм башкарма хакимиятләре органнары арасындагы каршылык та күз күнә аеруча кискенләшеп китә. Президент Ельцинның игътибары күбесенчә шул мәсьәләләргә юнәлтелә. Үзенең позициясен ныгыту максатларында ул Россия Федерациясенең яңа Конституциясен хәзерләргә һәм аның нигезендә үзенә буйсыначак тыңлаучан парламент формалаштыру эшенә керешә. Мәскәүдә Конституцион Җыелыш эшли башлый. Җыелышта катнашкан М. Ш. Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан

делегациясе демократик канатның республикалар суверенитетын конституцион тану турындагы тәкъдимен яклап чыга. Татарстанның үзе өчен ике мәсьәлә: Россия Федерациясе Конституциясендә Татарстанның суверенитеты турындагы Нигезләмәне беркетү, бу Конституциядә Татарстанның Россия Федерациясенә Татарстан Конституциясе һәм Россия — Татарстан Шартнамәсе нигезендә аерым статус белән керүен чагылдыру мәсьәләләре аеруча мөһим була.

Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Республикасы вице-президенты Василий Лихачев чыгышларында бәян ителгән тиешле тәкъдимнәрне республикалар вәкилләре дә яклый. Хәлбуки Җыелыш әгъзаларының күпчелеге «Бердәм Россия иле — бердәм Россия дәүләте» тезисы ягында кала. Конституцион Җыелыш Федератив шартнамәдә теркәлгән һәм «суверен республика» дип аталган формуладан гомумән баш тарта. Моның белән килешмәгән Татарстан делегациясе Конституцион Җыелышны ташлап чыгып китә һәм анда кабул ителәчәк карарлар өчен җаваплылыкны үз өстеннән төшерүе турында белдерә. Татарстанлылар һәм республикадан читтә яшәүче татарлар аларның бу адымын хуплый. «Интерфакс» хәбәрчесенә биргән интервьюсында В. С. Лихачев республикаларның мәнфәгатьләренә кагыла торган, аларны боза торган Конституцион Җыелыш нигезләмәләрен билгеләп үтә. «Болардан тыш,— ди ул,— халыкларның үзбилгеләнү хокукы федерацияне төзү принцибы итеп билгеләнмәгән, һәм бу хәл, йомшак кына итеп әйткәндә, беркадәр аптырау һәм гаҗәпләнү уята».

Татарстанны изоляцияләү федераль үзәкнең кулыннан килми. Россиядә һәм чит илләрдә уңай бәяләнгән «Татарстан инициативасы» дигән феномен туа. 1993 елның 6—8 сентябрендә Казанда «Федерализм: глобаль үлчәнеш һәм Россия үлчәнеше» дигән темага халыкара конференция булып үтә. Анда Татарстан, милли республикалар, Мәскәү галимнәре һәм сәясәтчеләре, АКШ, Һиндстан һәм Испаниядән хокук белгечләре катнаша. Төп дискуссия федерацияне ничек төзү мәсьәләсе тирәсендә бара. Федераль үзәкнең рәсми вәкилләре «Федерацияне, бу эшкә төбәкләрдән вәкилләр җәлеп итеп, «югарыдан торып» төзергә кирәк» дигән тезис ягында торалар. Башкача әйткәндә, бу, федераль үзәк һәм республикалар арасында вәкаләтләрнең һәм эшләрнең чикләрен билгеләүдә үзәк беренче урында торырга тиеш дигән сүз була.

Конференциядә катнашучыларның күпчелеге исә федерацияне «Федераль үзәкнең хокуклары һәм вәкаләтләре Федерация субъектлары аңа күпме тапшырса, шулкадәр булырга тиеш» дигән формула буенча «түбәннән торып төзү» ягында тора. Башкача әйткәндә, бу — Федераль үзәк республикалар тапшырган күләмдәге эш һәм вәкаләтләрне генә башкара ала дигән сүз. Конференциянең йомгаклау документында: «Субсидиарлык принциплары нигезендә, нәкъ менә дәүләтләр-республикалар рәвешендә үзбилгеләнүче халыклар федерациянең характерын билгеләргә тиешләр дә» дигән нәтиҗә ясала.

Конференция Россия белән үзара мөнәсәбәтләрнең Татарстан сайлаган формасын хуплады. Конференциянең йомгаклау документында болай диелә: «...Татарстан Республикасы Конституциясендәге 61 нче статьяның Татарстанны «Россия Федерациясе — Россия белән вәкаләтләрен һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты», дип игълан итүе Россия Федерациясенең дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә, халыкара хокук принципларына һәм нормаларына каршы килмиләр».

Әмма федераль үзәк үз дигәненнән чигенергә теләми. Шартнамәне Татарстан тәкъдим иткәнчә төзүгә бармый. Россия — Татарстан мөнәсәбәтләре торган саен кискенләшә. Федераль үзәк 12 декабрьгә Татарстан Республикасының принципиаль карашын искә алмаган Россия Федерациясе Конституциясен кабул итү буенча бөтенхалык тавыш бирүе (референдум) билгели. Моңа җавап итеп татарстанлылар тавыш бирүгә килмиләр. 1994 елның башында Татарстанда РФның яңа парламентына — Федерация Советына һәм Дәүләт Думасына сайлаулар игълан ителә. Сайлаучыларның тавыш бирүгә килмәүләре аркасында, сайлау комиссиясе Татарстанда бу сайлауларның узмавы турында хәбәр итә. Һәм Россия Федерациясенең яңа парламентында Татарстан Республикасы вәкилләре катнашмый. Татарстанлыларның — татар, рус, башка милләт вәкилләренең — ихтыяры белән исәпләшмичә, федераль үзәк фактта республиканы федерациядән читтә калдыра булып чыга.

Россия — Татарстан Шартнамәсе. Россия — Татарстан мөнәсәбәтләренең хәл ителмәгән килеш калуы һәр ике якны да борчый. Россиядә президент республикасын законлаш-

тырган яңа Конституция игълан ителгәннән соң, Б. Н. Ельцин Татарстан Республикасына карата позициясен бераз йомшарта, килешмәүчәнлеккә этәргән көчләрдән читләшә башлый. Сүлпән генә дәвам иткән Татарстан — Россия сөйләшүләре яңа импульс ала. Россия Федерациясе парламентына Татарстаннан депутатлар сайлау 13 мартта кабат үткәрелә. Барлык 9 депутат та (Федерация Советына — 2, Дәүләт Думасына — 7) сайлана.

Россия — Татарстан Шартнамәсенә кул куюга хәзерлек компромисслар рухында һәм шактый кызу темпларда бара. Татарстан делегациясе, шартнамә — ул ике суверен дәүләт арасындагы, ике халыкара хокук субъекты арасындагы килешү, дигән формуланы кертүне бу юлы таләп итми башлый. «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы шушы Шартнамә нигезендә берләшәләр (ассоциацияләшәләр)» дигән формула урынына, Татарстан Республикасы Россия Федерациясе белән дәүләт буларак берләшә һәм бу берләшү Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә генә түгел, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә дә, шулай ук әлеге Шартнамә нигезендә дә башкарыла, дигән формула кабул ителә. Компромисс Шартнамәнең исеменнән үк күренеп тора. Яклар Федератив шартнамә формуласыннан да («Хакимият эшләре һәм вәкаләтләренең чикләрен билгеләү турында»), Татарстан делегациясе тәкъдим иткән беренче варианттан да («Хакимият эшләрен һәм вәкаләтләрен үзара тапшырышу турында») читләшәләр. Иң соңгы вариант болай яңгырый: «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасындагы Шартнамә. Татарстанга тапшырыласы эшләрнең һәм вәкаләтләрнең күләме ягыннан әлеге Шартнамә Федератив шартнамә һәм Федерация Конституциясе белән чагыштырганда демократиялерәк. Шартнамәдә Татарстан Республикасының үз байлыгы һәм мөлкәте белән мөстәкыйль рәвештә эш итү, Татарстан Республикасының дәүләт органнары системасын, аларны оештыру тәртибен һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгеләү хокукы раслана; федераль органнар һәм республика (РТ) органнары тарафыннан билгеләнә, җыела торган федераль һәм республика (РТ) салымнарының чикләрен билгеләү күздә тотыла, Татарстан Республикасы гражданлыгы таныла; Татарстан Республикасының үз

милли банкын булдыру, Татарстан Республикасы судлары хөкем иткән кешеләрне ярлыкау, Федерациянең башка субъектлары белән килешүләр төзү хокукы теркәлә. Шартнамә Татарстанга тышкы икътисади һәм мәдәни мәсьәләләр буенча килешүләр төзү, хөкүмәтнеке булмаган халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашу вәкаләтләре бирә. Әйтеп үтелгән һәм аларга охшаш вәкаләтләр Россия Федерациясе өчен яңалык булса да, дөньядагы демократик федерацияләрдә инде гамәлгә ашырылган, һәм алар халыкара мөнәсәбәтләр өчен гадәти күренеш була.

Шартнамәдә Татарстан белән Россия арасында килеп чыгуы мөмкин булган каршылыкларны үзара киңәшүләр юлы белән хәл итү механизмы билгеләнгән. Килеп туган бәхәсләр һәр ике якның «килешүе тәртибендә» хәл ителергә тиеш. Килешүче якларның берсе Шартнамәне боза торган законнар кабул иткән очракта, икенче як бу законнарның кабул ителүеннән ризасызлыгын белдерә ала.

Үзенең рухы һәм формасы ягыннан Шартнамә халыкара стандартларга якынлаштырылган. Ул татар һәм рус телләрендә төзелгән һәм анда, һәр ике текст бер үк көчкә ия, дип теркәлгән. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы чикләнмәгән. Хәзерге этапта ул Татарстанның дәүләт хакимияте органнары белән Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнары арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы төп документ булып тора.

Россия Федерациясе — Татарстан Республикасы Шартнамәсенә 1994 елның 15 февралендә Мәскәү шәһәрендә кул куела. Ике президент та — Б. Н. Ельцин һәм М. Ш. Шәймиев — бу документка зур өметләр баглый. Әлеге Шартнамә аша Татарстан Россия Федерациясе составында «үзенчәлекле статус» алуга һәм Россия белән аерым мөнәсәбәтләр (шартнамәле мөнәсәбәтләр) урнаштыруга ирешә.

Россия — Татарстан Шартнамәсенең әһәмияте ике яклы локаль мөнәсәбәтләр кысасы белән генә чикләнми. Бер үк вакытта ул Россия Федерациясен яңартуның өметле башлангычы буларак та бәяләнә. Федерацияне оештырганда милли үзенчәлекләр һәм тарихи традицияләр төрле факторлар арасында аерата әһәмиятлеләре дип таныла. Канада галиме Алан Блейкли әлеге Шартнамә уңае белән: «...Россия яңа милләтне түгел, ә нәкъ менә яңа федерацияне төзергә маташа»,— дип белдерә. Россия парламентының Федерация Советы рәисе

урынбасары Василий Лихачев әйтүенчә: «Россиянең хокук системасы кысаларында яңа тармак — федераль хокук тармагы формалаша».

Милли икътисад формалашу. Татарстан АССР 20 нче еллар ахыры — 30 нчы еллар башында мөстәкыйльлегенең төп өлешен сәяси мөстәкыйльлеген югалта һәм шуның белән милли икътисадыннан да мәхрүм ителә. 1990 елда Татарстан суверенитеты игълан ителү вакытына аның территориясендәге бөтен мөлкәтнең нибары 2 проценты гына республиканың үз карамагында була. Файдалы казылмаларны да кертеп, бөтен мөлкәтнең 85 проценты Союз карамагында, ә калган өлеше Россия Федерациясе карамагында була. Дәүләт суверенитеты игълан ителү республиканың милли икътисадын татарстанлыларның үз карамакларына кайтарып бирү өчен юл ача. Россия Федерациясе белән сәяси Шартнамә төзелгәч һәм аңа кул куелгач, Татарстанда, законлы нигезләрдә, милли икътисадны яңадан формалаштыру процессы башлана.

Әлеге процесс авылларда кызурак темплар белән бара. Дәүләти-кооператив хуҗалыклардан хосусый-кооператив хуҗалык итеп үзгәртелгән элеккеге колхоз һәм совхозлар үзләре җитештерә торган продукцияне Союз фондына һәм Россия Федерациясе фондына мәҗбүри тапшыру йөкләмәсеннән азат ителәләр. Үз продукцияләренә үзләре хуҗа булып алгач, алар бу продукцияне мөстәкыйль рәвештә сата башлый һәм моның өчен Татарстан предприятиеләре белән турыдантуры бәйләнешләр урнаштыра. Кооператив хуҗалыклардан аерылып чыккан крестьяннарның хосусый хуҗалыклары (фермер хуҗалыклары) барлыкка килә. Милекнең төрле формаларын тәшкил иткән бу хуҗалыклар һәм предприятиеләр республиканың милли икътисадына нигез сала һәм дәүләт ярдәменә таяна башлый.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгына кискенләшеп баручы бөтенроссия кризисы шартларында эш итәргә туры килә. Комбайн, тракторлар паркы, гомумән авыл хуҗалыгы машиналары паркы кечерәя, кредит алу кыенлаша, шәһәр халкының сатып алу мөмкинлеге кими. Читтән кертелгән азык-төлек товарлары белән көндәшлек (конкурентлык) итәргә хәзерләнмәгән җирле җитештерүчеләргә базарда үз урыннарын табу һәм бу урыннарны саклап калу кыенлаша. Дәүләт ярдәме кризисның иң кискен чорында алар өчен бердәнбер котылу чарасы була.

Татарстан Республикасы[1]



[1] Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше/Төз. Б. Х. Сыромолотов.— Казан: «Барс» нәшрияты, 1992.

Татарстан Республикасы сәнәгатендә милли икътисадның аякка басуы бик авыр шартларда башланып китә. Россия белән төзелгән икътисади килешү (1992 ел) нигезендә Татарстан нефть чыгару һәм нефть химиясе сәнәгатеннән, шулай ук КамАЗ һәм кайбер башка предприятиеләрдән (оборона предприятиеләрен исәпкә алмаганда) килгән керемнең бер өлешен алуга ирешә. Хәрби сәнәгать комплексы предприятиеләре исә тулысынча Россия карамагында кала. Хосусыйлаштыру барышында сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка хезмәт күрсәтү тармакларында татарстанлыларның күп кенә хосусый предприятиеләре оеша. Эрерәк предприятие һәм оешмаларның акцияләре, өлешләп, дәүләт, федераль үзәк һәм предприятиеләрнең үзләрендә эшләүчеләр, шулай ук аларга үзләренең ваучерларын керткән башка татарстанлылар кулына күчә. Татарстанның Милли банкы, акционерлар банклары, кыйммәтле кәгазьләр базары барлыкка килә. Транспорт предприятиеләре — Татавтотранс, Татфлот, Татаэрофлот, халыкара аэропорт эшли башлый. Милли икътисад формалашу белән бергә базар хуҗалыгына яраклашкан идарә системасы оештырыла. Җитештерү берләшмәләре, акционерлар җәмгыятьләре, холдинг компанияләре, сәүдә йортлары, биржалар барлыкка килә. Икътисадны кризистан чыгару, республика хуҗалыгын, шул исәптән Россия карамагында калган предприятиеләрнең хуҗалык эшчәнлеген җанландырып җибәрү республика хөкүмәтенең икътисади сәясәтенең төп максаты булып әверелә.

* * *

Татар халкының бөек улы Габдулла Тукай зур горурлык белән: Тарихта «без әсәрле, эзле без»,— дип язган иде. Чыннан да, халыкара хезмәттәшлеккә йөз тоткан, хезмәт сөючән татар халкының күренекле шәхесләргә, социаль гамәл-вакыйгаларга бай булган үзенчәлекле милли тарихы борынгы Идел-Урал, Евразия-Россия һәм, гомумән, дөнья цивилизацияләренең олуг сәхифәсен тәшкил итә.

Борынгы Грециянең бер гакыл иясе: «Бу дөньяда иң кыен нәрсә нидән гыйбарәт?»— дигән сорауга: «Үз-үзеңне танып белү»,— дип җавап биргән. Бу — халык кебек зур бер кешеләр гомумилегенә дә кулланырлык фикердер, мөгаен. Дөнья тарихында «үз эзеңне» калдыру — зур милләтләргә генә хас сыйфат.

Милли идея формалаштыру барышында тарихтан гыйбрәтле нәтиҗәләр ала белүгә дә тиз һәм җиңел генә килеп булмыйдыр. Шуңа да карамастан, әлеге дәреслектә татар халкының милли тарихын һәм дә бу халыкның бүген «Татарстан» дип аталган үз иленең милли тарихын кыскача бәян итү бу юнәлештә фикер йөртү өчен билгеле бер нигез хезмәтен үтәр, дип өметләнәбез.

Татарстан милли тарихының гомумцивилизацион чагылышы бүгенге көндә түбәндәгечә күзаллана. Бик борынгы Идел-Урал тарих алды заманнарында ук инде төньяк төрки цивилизациясенең бишеге, ватаны булып әверелә. Ул вакытларда үзләренә яшәү өчен, башлыча, урманлы Идел-Уралны үзләштергән фин-угор этно-кабилә берлекләре белән беррәттән, урман-далалы Идел-Уралда төньяк төркиләрнең этно-кабилә берлекләре дә социаль яктан формалаша.

Төньяк төрки кабиләләрнең соңрак «Татарстан» дип аталган этник территориясе Көнчыгыш Европадагы урта гасыр дәүләте булган Идел буе Болгарының географик ареалына (биләгән мәйданына) әверелә. XV гасырда аңа Идел-Урал буендагы төрки-татарларның (Идел буендагы төрки-татарларның) милли дәүләте — яңа заманга йөз тоткан Казан ханлыгы алмашка килә.

XVI гасырда Татарстанның Россия империясе составына кертелүе татар халкын билгеле бер вакытка милли дәүләтчелегеннән мәхрүм итә. Шушы вакыттан башлап аның шул ук үз тарихи территориясендә дәвам иткән социаль-икътисади һәм рухи-мәдәни тормышы рус дәүләте хакимияте астында бара.

Бүгенге көндә Татарстан үзгәрешләр эчендә кайнаган Россия кысаларында кала, яңарып килүче Россия Федерациясе субъекты булуында дәвам итә. Россия Федерациясе, үз чиратында, Татарстан белән мөнәсәбәтләрен ике яклы Шартнамә нигезендә корырга ризалаша, фактта Татарстанның дәүләт суверенлыгын таный. Алга таба Татарстан яулап алган бу суверенлыкны саклап калырга гына түгел, аны яңа эчтәлек белән тулыландырырга, аерым алганда, Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте төзелүен тәэмин итәргә кирәк булыр.

Бүген мондый перспектива инде төсмерләнә. Татарстан — Россия Федерациясендә үз Конституциясенә ия булган суверен демократик дәүләт ул. Республиканың милли икътисадын

аякка бастыру һәм үстерү процессы бара, мәдәни һәм әхлакый тергезелүнең яңа этабы башланды. Татарстан Фәннәр академиясе төзелде, югары һәм урта белем оешмаларында да милли тәрбиягә игътибар артты. Татарстанда яшәүче төрле милләт вәкилләренә рухи һәм мәдәни үсешкә киң мөмкинлекләр ачылды. Җәмгыять һәм хакимият органнары белән уңай мөнәсәбәтләр урнаштырган конфессиональ оешмалар да бу мөһим эштә үз урыннарын табарга тырышалар. Республика мөселманнарының берләштерелгән съездында Татарстан Мөселманнарының Диния Нәзарәте (ТМДН) оештырылды. Мәрҗани мәчете комплексын торгызу һәм мөселманнарның мөкатдәс корылмасы Колшәриф мәчетен күтәрү эшләре бара, Ислам университеты ачылды. Христиан дине корылмаларына да республикада зур игътибар бирелә. Казан Кремлендә Благовещение соборы яңартыла, яңа чиркәүләр төзелә.

Татарстан бүгенге көндә мөстәкыйль рәвештә халыкара аренага чыга. Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә чит илләр белән тыгыз элемтә урнаштыра.

ВАКЫЙГАЛАР ХРОНОЛОГИЯСЕ

Б э. кадәр 100 меңьеллык — палеолит чоры. Ыруглык җәмгыяте. Идел-Урал төбәгендә яшәгән бик борынгы кеше торулыклары.

Б. э. кадәр 14—13 меңьеллыклар — неолит революциясе. Җәмгыятьнең җитештерү хуҗалыгына күчә башлавы.

Б. э. кадәр 8—5 меңьеллыклар — ыруг-кабилә строена күчә башлау дәвере. Хәзерге заман тел гаиләләре дивергенциясе (аерылып чыгуы). Идел-Уралда төньяк төрки кабиләләр формалашу.

Б. э. кадәр 4—2 меңьеллыклар — бик борынгы «Урал культурасы»ның формалашуы.

Б. э. кадәр 2—1 меңьеллыклар — кабилә берләшмәләре субрегиональ культураларының — Ананьино, Казан тирәсе, Пьяный Бор, Имәнкискә культураларының формалашуы.

Б. э. кадәр II гасыр — безнең эраның V гасыры — Идел-Уралдагы төньяк төрки кабилә берлекләренең Урта Себер яссытаулыгындагы элгәреге Һун империясе һәм Төньяк Кара диңгез буендагы Һун империясе белән бәйләнешләре дәвере.

VI—VII гасырлар — төньяк төрки кабилә берлекләренең Төрки каһанлыгы белән бәйләнешләре чоры.

732 ел — Күлтәгин баһадур истәлегенә Урхун-Енисей төбәгендә таш һәйкәл куелу (бу һәйкәлдә Себер татар кабиләләре берлеге турында да сүз бара).

VII—IX гасырлар — төньяк төркиләрнең элгәреге дәүләт оештырылмасы — «Биарым». Биләр һәм Болгар шәһәрләренә нигез салыну.

VII—VIII гасырлар — элгәреге төньяк төрки дәүләт оештырылмаларының Кара диңгез буе Болгары белән бәйләнешләре чоры.

IX гасыр — төрки болгарлар дәүләте Идел Болгарының беренче адымнары.

922 ел — Болгарда ислам динен кабул итү.

X гасырның икенче яртысы — төрки рун кулъязмаларының кәгазьгә күчерелүе (Дуньхуан истәлеге).

985 ел — Киев Русе һәм Идел Болгары арасында дәүләт шартнамәсе төзелү.

1004—1005 еллар — Казан шәһәренә нигез салыну.

X—XIII гасырлар — Болгар дәүләтенең Чехия, Дәшти Кыпчак, Караханилар дәүләте (Көньяк Казакъстан, Төньяк Үзбәкстан) белән сәүдә-икътисади бәйләнешләре чоры.

1006 ел — Болгар белән Киев арасында сәүдә шартнамәсе төзелү.

XI гасыр — Болгар тарихчысы Ягъкуб бине Ногманның һәм Болгар хокук белгече Хәмид бине Идрисинең иҗат итүләре чоры.

1185 ел — Болгар дәүләте һәм Владимир кенәзлеге арасында солых шартнамәсе төзелү.

1223 ел — монгол басып алучыларын кире бору.

1229 ел — Болгар дәүләте белән Владимир кенәзлеге арасында хезмәттәшлек турында шартнамә төзелү.

1236 ел — монголларның Болгар илен яулап алулары.

XIV гасырның азагы —Идел буе Болгары башкаласының Казанга күчерелүе.

1445 ел — Идел буе татарларының мөстәкыйль милли дәүләте — Казан ханлыгы төзелү.

1469 ел — Казан белән Мәскәү арасында солых төзелү.

1551 ел — Иван IV нең Казанга каршы агрессиясен кире кайтару.

1552 ел — Казан ханлыгының рус гаскәрләре тарафыннан басып алынуы.

1670 ел — татарларның Степан Разин җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында катнашуы.

1708 ел — Россия хакимият органнары тарафыннан Казан губернасы оештырылу.

XVIII гасыр — татар милли сәүдә капиталы һәм милли мануфактура җитештерүе формалашу.

1773—1775 еллар — татарларның Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында катнашуы.

1775 ел — Казан губернасы территориясе кечерәйтелү (аның составында 13 өяз калдырыла).

1782 ел — Казан татар бистәләре эшләрен алып бару өчен татар ратушасы оештырылу.

1788 ел — Уфа шәһәрендә Мөселман Диния Нәзарәте оештырылу.

XIX гасыр — татар эшмәкәрләренең җитештерүдә машиналар куллана башлавы.

XIX гасырның урталары — татар мәгърифәтчелегенең формалашуы.

1860—1870 еллар — Татарстан Россия реформалары йогынтысында.

XIX гасырның икенче яртысы

— татар дини реформаторлыгы үсеше;

— Казанда яңа заман татар милли мәдрәсәләренең эшли башлавы;

— дөньяви татар мәктәпләре ачылу;

— Казанда Татар укытучылар институты ачылу;

— яңа татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе — Габдулла Тукайның дөньяга килүе.

XIX гасыр азагы — XX гасыр башы — милли-азатлык хәрәкәтендә яңа идея (милләтнең һәрьяклы үсешен тәэмин итү) формалашу;

— Сәүдә йортлары, татар эшмәкәрләре җәмгыятьләре барлыкка килү.

1905 ел — татарларның сәяси партиясе «Иттифак әл-мөслимин»нең I съезды үткәрелү.

1905 ел, 2 сентябрь — Казанда Хөсәен Ямашев җитәкчелегендәге татар социал-демократлар оешмасы формалашу.

1906 ел — татар социалист-революционерлар (ТСРП) партиясе төзелү.

1910 ел — П. А. Столыпин хөкүмәтенең «Идел буе төбәгендә татар-мөселман йогынтысына каршы тору» чаралары үткәрүе.

1917 ел, апрель — Казанда Мулланур Вахитов инициативасы буенча Мөселман социалистлар комитеты (МСК) төзелү.

1917 ел, 26 октябрь — Казан губернасында хакимиятнең Советлар кулына күчүе.

1917 ел, 20 ноябрь — Уфада Үзәк Россия һәм Себер төрки-татар мөселманнарының Милләт Мәҗлесе утырышы ачылу. Идел-Урал Республикасын (Штатын) игълан итүне әзерләү буенча коллегия төзелү.

1918 ел, 17 гыйнвар — Россия Федерациясенең Милләтләр эшләре халык комиссариаты каршында Мөселман эшләре комиссариаты оештыру турында Декрет игълан ителү.

1918 ел, 28 март — Совет хакимиятенең Идел-Урал Республикасы оешмаларын таратуы.

1918 ел, март — Россиянең мөселман эшчеләре конференциясе тарафыннан Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе төзелү.

1920 ел, 26—27 сентябрь — Татарстан Советларының I Оештыру съезды ТАССР төзелү турында игълан итә.

1921 ел, 25 июнь — Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советы Декреты белән татар теленең «барлык дәүләт оешмаларында» рәсми тел дип игълан ителүе.

1922 ел, 30 декабрь — Татарстан Советлар Союзы составында.

1926—1929 еллар — Татарстанда федераль үзәкнең абсолют хакимияте урнашу. Милләтчелектә гаепләп, репрессияләр ташкыны башлану.

1929 ел, февраль — латин алфавитына (яңалифкә) күчү.

1929—1933 еллар — Татарстанда крестьян хуҗалыкларын коллективлаштыру.

1936 ел — Татарстанда Рәссамнар берлеге оешу.

1937 ел, 25 июнь — ТАССР Конституциясен кабул итү.

1939 ел, май — кириллица нигезендә төзелгән алфавитка күчү.

1941—1945 еллар — Татарстан Бөек Ватан сугышында.

1945 ел, 30 апрель — өлкән сержант Газетдин Заһитов һәм аның иптәшләре Рейхстаг түбәсенә күтәрелгән һәм анда Җиңү байрагы беркеткән көн.

1946 — 1955 еллар — Татарстанда сугыштан соңгы торгызу эшләре.

60 нчы еллар — Татарстанга союздаш республика статусын таләп итү хәрәкәте.

1987 ел — Татарстанда милли тергезелү идеяләренең легальләшүе.

1989 ел, февраль — Татар Иҗтимагый Үзәге (ТИҮ) оештырылу.

1990 ел, 30 август — Татарстан Республикасы дәүләт суверенитеты игълан ителү.

1991 ел, 12 июнь — М. Ш. Шәймиев Татарстан Республикасының беренче Президенты итеп сайлана.

1992 ел, 21 март — референдумда татарстанлылар Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын яклап чыгалар.

1992 ел, 6 ноябрь — Татарстан Республикасының Югары Советы Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итә.

1994 ел, 15 февраль — Мәскәүдә Россия — Татарстан Шартнамәсе төзелә.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш

Курсның предметы һәм тарихи кыйммәтләрне бәяләү ориентацияләре 3

Тарих фәне. «Татарстан» төшенчәсе. «Татарлар» төшенчәсе. Өйрәнү предметы. Тарихи кыйммәтләрне бәяләү ориентацияләре.

I бүлек

БИК БОРЫНГЫ ТАТАРСТАН

Идел-Урал цивилизациясенең башлангычы 11

Идел-Уралның геосферасы. Идел-Уралның этносферасы. Идел-Уралда элгәреге ыруглык строе кешесенең яшәеш культурасы.

Бик борынгы төньяк төркиләр цивилизациясе 13

Неолит революциясе. Татарстанда неолит, бронза һәм тимер дәверләре. Идел-Уралдагы төрки кабиләләр. Төньяк төрки кабиләләр таралып урнашкан территорияләр. Тораклар. Хуҗалык. Сәнгать. Рухи мәдәният.

II бүлек

БОРЫНГЫ ТАТАРСТАН

Борынгы бөек цивилизацияләр системасы 25

Гомуми характеристика. Нил елгасы үзәнлеге. Елгаара өлкә цивилизациясе. Зороастр Ираны. Борынгы Һинд цивилизациясе. Борынгы Кытай цивилизациясе. Борынгы Урта диңгез буе. Борынгы Европа цивилизациясе.

Борынгы Татарстанда элгәреге дәүләт оештырылмалары ... 31

Мәсьәләнең куелышы. Идел-Уралдагы элгәреге дәүләт оештырылмаларының төньяк төрки этник нигезе. Борынгы Биләр. Элгәреге дәүләт оештырылмаларының барлыкка килүе.

Бүгенге Татарстан территориясендә борынгы дәүләт оешуның алшартлары 36

Борынгы Көнчыгыш Европа. Азакки Һун империясе. Кара диңгез буе Болгары. Хәзәр каһанлыгы. Борынгы Татарстандагы элгәреге дәүләт оештырылмаларының тышкы багланышлары. Кара диңгез буе болгарлары борынгы Татарстанда.

Борынгы татар дәүләте Идел буе Болгарының формалашуы 43

Беренче адымнар. Багдадка йөз тоту. Болгар — Багдад мөнәсәбәтләре. Ислам динен кабул итүнең алшартлары. Багдад вәкиллегенең Болгарга килүе. Идел Болгарында иҗтимагый тормыш. Дәүләт төзелеше. Территориясе. Халкы. Хуҗалыгы. Сәүдә. Рухи тормыш. Мәдәният.

III бүлек

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫ XI—XV ГАСЫРЛАРДА

Иҗтимагый стройның һәм дәүләт төзелешенең ныгуы 58

Дәүләти берләшү. Иҗтимагый тормыш һәм дәүләт төзелеше. Тышкы сәяси үзгәрешләр. Болгар — Русь мөнәсәбәтләре. Идел буе Болгары һәм Кыпчак иле. Ерак илләр белән багланышлар.

Социаль-икътисади тормыш 69

Шәһәрләр иле. Авыл тормышы. Мәдәни тормыш.

Идел буе Болгары һәм Алтын Урда 77

Идел буе Болгарының халыкара хәле. Монголларның Идел Болгарына бәреп керүе. Сәяси бәйсезлекне югалту. Идел буе Болгары һәм Җучи улусы. Алтын Урда дәүләтенең формалашуы.

XIII—XIV гасырларда Идел буе Болгарында иҗтимагый тормыш 84

Сәяси структура. Яңа җирләр үзләштерүне дәвам итү. Икътисад. Мәдәният. Урдада болгавыр чор һәм аның нәтиҗәләре. Казанның күтәрелүе. Алтын Урда дәүләтенә тарихи бәяләмәләр.

IV бүлек

ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЕ

Казан татар дәүләте формалашу 97

Идел буе Болгарының дәүләт мирасын саклау. Казан тәхетендә татар династиясе. Тотрыклылыкка ирешүнең беренче адымнары. Хезмәттәшлеккә йөз тотып. Территориясе. Халкы.

XV—XVI гасырларда Идел буе татарларының милли дәүләте 105

Дәүләт төзелеше. Дәүләт идарәсе системасы. Икътисадны савыктыру. Милли мәдәният. Тышкы сәясәт үзенчәлекләре. Татарстан — Россия мөнәсәбәтләре. Казан — Кырым мөнәсәбәтләре. Татарстан — Россия мөнәсәбәтләренең кискенләшүе.

Бәйсезлек өчен сугыш 122

Көнчыгыш Европада империя төзүгә таба борылыш. Иван IV нең 1551 елгы агрессиясен кире кайтару. Казанның җиңелүе. Оккупациягә каршы көрәш. Россия хәрби администрациясенә каршылык күрсәтү. Россия ни ота соң?

V бүлек

ТАТАРСТАН РОССИЯ ИМПЕРИЯСЕ СОСТАВЫНДА

Россия колониализмы астында 138

Россия колонияләштерүенең үзенчәлекләре. Сәяси колонияләштерү. Икътисади колонияләштерү. Этник ассимиляция сәясәте.

Милләт буларак саклану 144

Милләт буларак саклану идеясе. Икътисади яктан сакланып калу. Милли-мәдәни һәм рухи яктан сакланып калу. Халык чуалышлары. Милли үзенчәлекне саклау.

Милли тергезелүгә таба 150

Мәгърифәт җилләре. Россиядә мәгърифәтчелек һәм яңартып кору идеяләре. Татарстан территориясен административ бүлгәләүнең төгәлләнүе. Татар җирләрендә дәүләт хакимияте. Тергезелүнең икътисади кыенлыклары. Рухи һәм мәдәни изүгә каршы тору.

Милли тергезелүнең төп юнәлешләре 158

Яңа милли ориентирлар. Милли хәрәкәт бурычлары. Татар шәһәрләре һәм бистәләре. Татар авылларын тергезү. Милли сәүдә капиталының барлыкка килүе. Мануфактура эшмәкәрлеге. Машина кулланучы сәнәгать. Милли мәдәниятне тергезү приоритетлары. Татар исламындагы реформаторлык. Милли мәгариф һәм мәдәният. Татар мәгърифәтчелеге. Милли һәм социаль ризасызлык чагылышлары.

Милли азатлык юлына басу 184

Дөньяда яңа тарихи тенденция. Россиядә милли азатлык проблемалары. Милли консолидация. XX гасыр башына татар җәмгыяте. Сәнәгать концентрациясе. Сәүдә эшмәкәрлеге эреләнү. Аграр мәсьәләнең кискенләшүе. Милли әдәбият. Милли театр. Милли мәгариф системасы. Фән. Вакытлы матбугат.

Иҗтимагый-сәяси хәрәкәт 197

Татар җәмгыятендә сәяси хәл. Милли-либераль хәрәкәтнең формалашуы. Татарларда беренче сәяси партия. Россия Дәүләт Думасында татар оппозициясе. Россиянең реакция юлына басуы. Рус социалистлары. Татар социалистлары.

VI бүлек

ТАТАРСТАН 1917 ЕЛ РЕВОЛЮЦИЯСЕНДӘ

Россия демократик республикасы һәм Татарстан 207

Патша монархиясен бәреп төшерү. Вакытлы хөкүмәт. Татар милли хәрәкәте Февральдән соң. Милли хәрәкәтнең радикальләшүе. Мөселман социалистлар комитеты. Бөтенроссия мөселманнар съезды. Вакытлы хөкүмәт белән конфликт. Милли хәрәкәт консолидациясе. Халык хәрәкәте.

Милли республикага илтүче юл 221

Россиядә Октябрь перевороты. Рус җәмгыятенең Совет моделе. Совет хөкүмәтенең милли сәясәте. Идел-Урал Республикасы. Мөселман эшләре комиссариаты. Идел-Урал Республикасын тарату. Татар-Башкорт Республикасы. Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе. Россия Мөселман Коммунистлар партиясе. Россиядә гражданнар сугышы. Татар халкы гражданнар сугышында.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү 241

Социалистик ориентация. Россия Мөселман Коммунистлар партиясенең I съезды. Совет милли сәясәтендәге үзгәрешләр. Татарстан Автономияле Республикасы турындагы Нигезләмә проекты. Республиканың статусы һәм хакимият структурасы. ТАССР Ревкомы. Автономияле Татарстан Республикасын игълан итү.

VII бүлек

ТАТАРСТАН СОВЕТЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДА

Татар җәмгыятендәге үзгәрешләр 254

Дөньяда геосәяси вазгыять. СССР төзелү. Совет автономиясе статусы. Союз шартнамәсе һәм Татарстан. Татар милли хәрәкәте эш иткән ике мәйдан.

Автономия юлында 262

Кыен башлам. Ачлыктан котылу чаралары. Хөкүмәт алмашыну. Татарстанда яңа икътисади сәясәт. Милли мәдәният яңа шартларда. Совет Татарстанының бишьеллыгы.

Россия коммунистик абсолютизмы һәм Татарстан 274

Коммунистик абсолютизмның алшартлары. Сталин хакимиятенең ныгуы. Татарстан үз автономиясе сагында. Татарстанда үзәк хакимияте. Икътисади үзгәртеп корулар. ТАССР Конституциясен кабул итү. Милли мәдәният.

Икенче бөтендөнья сугышы .... 2[illegible]

Бөек державаларның хәрби сәясәте. СССРның халыкара акцияләре. СССР хөкүмәтенең гадәттән тыш чаралары. СССРның сугышка керүе.

Бөек Ватан сугышында татарларның милли өлеше 299

Татар җәмгыятенең сугышка мөнәсәбәте. Татарстанда хәрби мобилизация. Хәрби сәнәгать. Сугыш еллары авылы. Милли рух күтәренкелеге. Татар сугышчылары фронтта. Оборона сугышларында. Тамырдан борылыш. Ватан язмышын хәл иткән бәрелешләр. Капитуляция һәм оккупация. Сугыш нәтиҗәләре.

Сугыш сабаклары һәм дөнья берлеге 322

Тынычлыкка, азатлыкка таба. Союзниклар каршылыгы. СССР хөкүмәтенең эчке сәясәте. Халыкның социаль активлыгы. Сугыштан соңгы Советлар Союзында милли фактор.

Татарстан сугыштан соңгы елларда 327

Сугыштан тыныч тормышка күчү. Татарстанның сугыштан соңгы икътисады. Чикләнгән автономиянең саклануы. Милли тергезелү идеясе тарафдарлары. Милли тергезелү проблемалары. Милли хәрәкәтнең яңа этабы. Татарстан Россиядәге торгынлык системасында. Татарстанда дәүләт сәнәгате. Татарстанда дәүләт авыл хуҗалыгы.

VIII бүлек

ТАТАРСТАНДА 90 НЧЫ ЕЛЛАР РЕФОРМАЛАРЫ

Татарстанда демократик хәрәкәт 344

СССРда үзгәртеп кору. Татарстанда үзгәртеп кору. Союз һәм Россия парламентларында демократик оппозиция. Татарстанда демократик хәрәкәт.

Суверен Татарстан Республикасы 352

Татарстан Республикасы дәүләт суверенитетын игълан итү. Суверенитетны яклау. Татарлар һәм татарстанлылар. Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү. Татарстан Россия Федерациясенең Конституцион Җыелышында. Россия — Татарстан Шартнамәсе. Милли икътисад формалашу.

Вакыйгалар хронологиясе 372

Сабирова Д. К., Шәрәпов Я. Ш.

С12 Ватаныбыз тарихы: Югары уку йортлары өчен дәреслек.— Казан: Мәгариф, 2001.— 383 б.: к. б-н.
ISBN 5-7761-0964-7

Татарстан тарихы, хәзерге заман тарих фәне таянган кыйммәтләр яктылыгында, ил һәм дәүләт тарихы буларак бәян ителә. Китап югары уку йортлары студентлары, укытучылар һәм Татарстан тарихы белән кызыксынучы киң даирә укучылар өчен чыгарыла.

Учебное издание

Сабирова Дания Киямовна
Шарапов Якуб Шарафович

ИСТОРИЯ НАШЕЙ РОДИНЫ

(Древнейший период — конец XX века)

Для высших учебных заведений
(на татарском языке)

Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Тышлык рәссамы
һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Корректоры *Р. Ә. Фәйзуллина*
Компьютерда биткә салучы *Л. Г. Зиргизова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.05.2001. Форматы $60 \times 84^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 22,32 + форз. 0,23. Нәшер-хисап табагы 21,43 + форз. 0,39.
Тиражы 3500 д. Заказ Ч-26.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.



TATGÖSIZDAT OJOMUMI ƏDƏBIAT SEKTORЬ QAZAN 1934